Альберт Хәсәнов

ҖӘНБӘТ ҖӘВЕРЕ

Повестьлар, хикәяләр,
публицистик язмалар

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2007

УДК 821.512.145-3
ББК 84(2Рос=Тат)-4
Х91

Хәсәнов А.Б.

Җәнбәт җәвере: повестьлар, хикәяләр, публицистик язмалар / Альберт Хәсәнов. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. — 478 б. — 2000 д. — ISBN 978–5–298–01585–1

Танылган язучы, публицист Альберт Хәсәновның яңа китабына аның соңгы елларда иҗат иткән «Җәнбәт җәвере», «Төшмәсен лә күзең матур ярга», «Чатан» һәм башка повестьлары, милләт, халык язмышына, тарихыбызга багышланган публицистик язмалары һәм шулай ук табигать, кече туганнарыбыз хайваннар турында сөйләүче хикәяләре урын алды.

ISBN 978–5–298–01585–1
© Татарстан китап нәшрияты, 2007
© Хәсәнов А.Б., 2007

Җәнбәт җәвере

Кәрван башы Әбү-Бәкер

Кече кызым Гүзәл Яңа ел алдыннан гына унике кадак авырлыктагы тагын бер малай алып кайтты. Нарасый баланың үә-үәсенә, тик имчәк баласыннан гына килә торган дөньяда бер татлы әчкелтем искә тәмам тансыклаганыек. Бу тантаналы вакыйга бөтен гаиләбезгә сөенеч өстенә сөенеч, шатлык өстенә шатлык булды. Миндә оныклар байтак. Барысының да үз холкына тиң кушаматлары бар. Монысына «Миш-шәр!» дип тактым кушаматны. Атасы Буа мишәре булгач, улы да мишәр булмый кем булсын?!

Бу оныгыма барыннан да бигрәк үзем сөендем. Түбәм болытларга ашты. Кызымны да бүләккә күмеп бетердем. Түтәлдән генә казып алган шалкан кебек тыпырдап торган сау-сәламәт бала алып кайтканы өчен. Юкса ил өстендә Кара кош йөри, соңгы вакытта яшь аналар акыл һәм физик яктан сау-сәламәт балаларны сирәгрәк апкайта башладылар. Баланың, нарасыйның кайсы да татлы. Гарибен дә юынтык су белән чүплеккә чыгарып түгә алмыйсың. Бер утырып елыйсың да бөтен җирен үбә-үбә карый, үстерә башлыйсың.

Ә таза-сау, сәламәт баланың нинди зур бәхет икәнен олыгая барган саен тирәнрәк аңлыйсың, сөенәсең. Тфү, тфү, күз генә тия күрмәсен үзенә дип кабатлап кына торасың. Әйе, шулай туган сәгатеннән үк үсәм дип торган оныгым булгач, ул көннәрдә кая басканымны белмәдем. Әнисе дә терелеп бүлнистән кайткан көннәрендә үк мәчеткә йөгердем. Араларыннан иң сөйкемлесен, иң гыйлемлесен сайлап, мулла абзыйны алып кайттым. Сәдакасын да мулдан биреп, оныгыма Биктаһир дип исем куштырдым. Сөйгәндә, кулга алып яратканда кушу өчен «Миш-шәр!» кушаматын да көчендә калдырдым.

Баланың берсе дә еламый гына үсми. «Үә-үә» дип елавы — аның яшәү рәвеше. Анысына сөенергә генә кирәк. Әмма кадерле вә тансык Биктаһирыбыз кичләрен сыны катып елый, балакаем. Әнисе кулына мин аны болай да имезергә генә бирә идем. Ә хәзер улымны кулымнан төшермим. Күкрәгемә кысам. Әлли-бәлли итеп карыйм. Ә бала үзен кая куярга белми.

— Тансыгым, кай җирең авырта соң, кашкалы колыным, таем! — дим.

Зәңгәр сәдәф кебек матур күзләрен миңа төбәгән сабый:

— И-и, дәү әтием, һич түзәр хәлем юк, эчем бик авырта, — дип, теле белән генә әйтми.

Ә табибларның сүзе бер: «Это все временно. Пройдет!»

Пройдет та пройдет, балага менә хәзер авыр. Түзәр хәле калмый, сыны ката. Андый чакта киңәш бирүчеләр күп була бит. Бүсере бардыр баланың, өшкерә белүче әбигә алып барырга кирәк, диләр. Институтта укыган елларымда, алай-болай өчлегә, икелегә биреп стипендиядән колак кага күрмим тагын дип, марксизм-ленинизм тәгълиматларын да бик тырышып өйрәнгәнием. Ә башыңа төшкәч, башмакчы буласың. Кочагыңда нибары ике-өч атналык тансыгың ыңгырашканда атеистлык онытыла, егетләр. Әгәр сез дә чын егет булсагыз, мине шундук аңларсыз. «Әнә чуаш Тумбарлысында авыл кергәч тә берьялгызы яшәп ятучы, бик оста өшкерүче чуаш карчыгы бар», — диләр. Машина яллап, шунда чыгып китәбез. «Шөгердә бик оста өшкерүче татар әбие бар», — диләр. Машинага улымның йә әнисен, йә дәү әнисен дә утыртып анда барып кайтабыз. «Иң оста, иң шифалы өшкерүче әби Карабашта», — дигәч, анда чыгып йөгерәбез.

Таксистлар да керә башладылар хәлебезгә. «Бик оста өшкерүче әбиләр Әлмәттә, Бөгелмәдә, Баулыда!» — дип, өйгә шалтыраталар. Аларга да ипле бит даими клиент белән эш йөртү. Әлмәткә барып кайту өчен өч йөз сорыйлар. Әбиләргә һич дәгъвам юк, өшкерүен бик тырышып өшкерәләр. Әмма бераз көтәргә кушалар, бүсереннән менә бүген үк, шушы сәгатьтә үк котыла алмас, диләр. Ә миңа улымны бу газабыннан бүген үк котылдыра торган өшкерүче әби кирәк. Шулай итеп, әйләнә-тирәбездә балалар өшкерүче бер әбекәй дә калмагандыр. Чуашы, мукшысы, маржасы, татары!

Әйтмәгәнем булсын, әллә аларның өшкерү шифасы тиде, басылды, бетте аның эч авыртуы. Хәзер менә инде айларын тутырып, бер теш чыгарып утыра. Торулары Әлмәттә аларның. Әнисе бераз ял итсен дип, ике-өч атнага үзебезгә алып кайтканыек. Әллә шул теш чыгаргангамы, бер кичне температурасы нык күтәрелде оныгымның. Бер төн эчендә җиде үлдем, җиде терелдем. «Баланың баласы балдан татлы» дип бер дә юкка гына әйтмәгәннәр шул.

Тигез, җитешле тормыш белән яшәгәндә, сау-сәламәт, көн саен бер һөнәрен арттыра барган баланы карау бетмәстәкәнмәс шатлык вә сөенеч кенә. Биктаһирыбыз мин җыр көйләгәнне бик ярата булып чыкты. Җырга минем ул хәтле осталык юк. Мин аңа «Зәңгәр шәл»дән: «Менә-ә сиңа-а, Галәви, ачкычларны-ы калды-рам. Өйгә-ә кара-ак кермәсен. Өй-не яхшылап сакла!» — дип җырлыйм. Шуны

ике кат җырлап чыкканчы кочагымдагы бала изрәп йокыга китә. Бала әзрәк көйсезләнә башласа да, әнисе миңа китереп бирә.

— Дәү әтисе, «Галәви»не җырла! — ди.

Ни хикмәт, киң итеп тын алып шушы җырны көйли башлауга, улым изрәп йоклап та китә.

Бүген инде җиде айларын тутырып килгән бик тансык оныгым Биктаһир турында шулай тәмләп, озаклап сөйләвемнең үз хикмәте бар. Тәрҗемәи хәлемә багышланган повестька кереш, ягъни увертюра булсын дип яздым мин аны. Оныгымны кочагыма алып йөргәндә, бишек җырлары җырлап тирбәткәндә, йә Ходаем, минем үземне дә кемнәрдер шулай кадерләгәннәрдер, төн йокыларын калдырып бишектә тирбәткәннәрдер, кулларында күтәреп йөрткәннәрдер дигән уйлар өере килеп биләде күңелемне. Җиде дистәне тутырып киләм бит инде. Ходаемның рәхмәте, узган ел сабан туенда түтәлдә качып үскән кыяр төсле түгәрәк Аксубай мишәре белән бил алыштым бит әле. Күзем дә исән-сау. Янымнан озын ботлы чибәр кызлар узганда, машина фарасы кебек яналар. Алар узган якка муенымны остеохондроз кузгалганчы борып озатып калам. Колакларым да «мә!» дигәнне бер чакрымнан ишетеп алалар. «Бир!» дигәнне генә ишетмәмешкә салышам, мыштым гына узып китмәк булам. Шөкер, әлегә аяклар да йөгерәләр. Шахмат тактасы артына утырсам да, көндәшем спорт мастеры ук булмаса, беренче разрядлыларга гына биреште юк. Матка ук булдыра алмасам, партияне пат белән тәмамлыйм. Хөрмәтләләрем, бу мактануым түгел, эш менә нәрсәдә — 1937 елның шыксыз салкын декабрендә туып, мин дә сыным катып елаганмындыр. Сөте агып торган тулы күкрәген каптырырга әнием юк. Шыгыр-шыгыр бишектән алып биләүләремне алыштыручыларның, авызыма имезлек каптыручыларның мин берсен дә белмим. Аларга рәхмәт тә әйтә алмадым, мыскал игелек тә күрсәтмәдем. Хәзер менә алар рухына ара-тирә сәдака биргәлим. Ходай үзе кабул итсен дә бу изге җаннарның рухына җиткерә күрсен.

Әйе, салкын төннәрдә кычкырып елап уянсам, мине кулларына алып юатучыларны, авызыма имезлек каптыручыларны, мамык шәлгә төреп янәдән бишегемә салучыларны мин белмим. Шулай килеп чыккан инде. Чөнки мин алты көннән каравыл кычкырып ятим калганмын. Сез ышанмассыз да, әмма күз алдыгызга китерегез: әнкәсеннән алтынчы көнне калган баланы карау ай-һай кыен булгандыр. Кендек кутырым да төшмәгән бала бит әле. И-и-и, аннарымы?! Мин күп тапкырлар кулдан-кулга йөрдем. Алары хәтта үзем белә башлагач та булды. Чүплеккә илтеп ташлаган песи баласы кемгә генә килеп сыенмый?! Минем дә куены җылы, ышанычлырак бер җанга килеп сыенасым килгән, шундый ышанычлы җанны эзләгән чакларым күп булды.

* * *

Без — Җәнбәтнекеләр. Кушаматыбыз да шулай. Безнекеләрне «Җәнбәт җәвере — җиде табын» дип йөрттеләр. Җәнбәт бабамның җиде улы булган. Аларның берсен дә башка чыгармаган ул. Башлы-күзле иткәч, булган улларының барысына да ак өй салып, бер ат, бер тана биреп, барысын да үз утарында калдыра барган. Капкаларын ачып җибәрсәләр, алар ишегалдыннан бер көтү сарык чыккан. Утыз-кырык баш ат, ун-унбиш дөя асраган. Безнең нәселнең тәмам кызыл балчыгына төшеп сөйләсәң, ул болайрак. Җәнбәт бабам пәһлевандай көчле-куәтле, кырыс холыклы кеше булган. Җиде улының җиде дусты! Авыл җыеннарында, җир бүлешкән чакларда аларга каршы чыкмаганнар. Җиде-сигез авылга баш үрәтник тә тарантаслы, рессорлы атын алар капкасына китереп бәйләгән, кунарга Җәнбәт бабайда кала торган булган. Казнага яхшы атлар үстереп биргәч, үрәтник белән дә симез каз ботларын бер табында кимергәч, чымырдап утырган әче балны бер мичкәдән чөмергәч, Җәнбәт бабам бер улын да солдатка бирмәгән. Бабамның җиде килене бишәр бала гына тапкандыр. Аның нәсел-ыруы нык үрчегән, бик көчле булган. Мин — шуның бер очы гына. Минем әтием — җан дустым, акыллы киңәшчем — Габделбарый. Мин, заман кушканча, Бариевич йөрим. Әтием дөнья бәясе егет иде. Урыны җәннәтнең үзәк президиумында, хәтта политбюросында булсын! Әтинең әтисе, ягъни минем бабам — Хәсән. Хәсән бабамның әтисе — Әхмәтҗан. Аннары Әбү-Талип. Аннары Әбү-Җәнбәт.

Хәсән бабамның әтисе Әхмәтҗан күп бала үстергән. Әхмәтҗан бабамның бертуган абыйсы Әбү-Бәкер бер дә өйләнмәгән. Ул бик танылган, бик бай сәүдәгәр булган. Унбиш-егерме дөядән торган кәрван йөрткән. Иран, Әфганстан, Пакыстан, Һиндстан җирләренә кадәр барып чыгып, Казан каласына хуш исле чәй, дарчин һәм башка аш тәмләткечләр, Кытай чынаягы, ефәк шәлләр, кәшемир яулыклар ташыган. Аның элекке Дөбъяз районы зур базарлы Алат авылында һәм Казанның үзендә берничә кибете булган. Кибетендә приказчиклары сәүдә иткәндер инде. Әбү-Бәкер агай бер сәяхәттән кайтып мунчалар керсә, бераз ял итсә, икенче кәрван белән тагын илләр гизәргә чыгып киткән. Кунакка, бераз ял итәргә ул һәрчак Дөбъяз районы Кече Солабаш авылына күп балалы энесе Әхмәтҗанга кайткан. Җәнбәт бабай бит Кече Солабашныкы. Ун-унике яшьләремдә, Дөбъяздан Ташлы Кавал авылына кунакка кайтканда, Солабаштан чыгып бер урынга җиткәч, әтием тарантасыннан төшеп, тәһарәт алып, чыкылдап торган коммунист булса да, кыйбла якка карап, белгән догаларын укыр иде. Бу урынны сәрви, сирень, шомырт, балан агачлары бизи. Күптән ташланган йорт урыннары, моржа төпләре сизелә.

Әти, соңыннан миңа аңлатма биреп:

— Улым, бу җирләрдән узганда, син дә тезләнеп бер дога кылырга онытма. «Җәнбәт җәвере — җиде табын» бабабызның утары урыннары бу! — дия иде.

Миңа соң, ул чакта ни беләм? Чыңгызхан, Александр Македонский ставкасы бу, дисәләр дә, мыскал да исем китмәгән булырые. Үсә төшкәч, дөнья таный башлагач, ул якларга бер кайтканыем. Җәнбәт бабам утары утырган җирләрне сөреп, солы чәчкәннәр. Йорт урыннары алай да төсмерләнә. Зур-зур ташлар, янган кирпечләр күренә. Солы басуы өстендә бик озак уйланып йөрдем...

Безнең Кече Солабашка беренче пианиноны да әлеге сәүдәгәр Әбү-Бәкер абзый алып кайткан. Бу — 1851 еллар тирәсе.

Әтием Габделбарыйның әбисе Гайниҗамал абыстай — мулла кызы — бик матур итеп пианинода уйнаган. Җәйге тын кичләрдә, көтүләр кайтып, малларны барлап абзарларга япкач, күрше-тирә киленнәре, бәйрәмчәрәк киенеп, Әхмәтҗан бабай өе алдына җыела торган булганнар.

— Абыстай, әргәнеңне тыңларга килдек, башка эшләреңне куеп торып чак кына уйнамассыңмы? Йөрәкләрне өздереп, әллә нинди сагышлы моңнар агыла бит аннан, — дия торган булганнар.

Киленнәрнең кич утырып үзләре чиккән батист алъяпкычлары астында йә ике йомырка, йә чәй тәлинкәсе белән тары, карабодай, солы оны. Болары, хәзергечә әйтсәк, музыка тыңларга килүчеләрнең музыкант абыстайларына гонорарлары. Абыстайлары да ялындырып тормый. Төпләре исле гөлләр белән тулы, урамга караган өч тәрәзәсен дә төбенә кадәр ачып җибәрә. Җитез бармаклары белән пианино клавишлары өстеннән йөгереп уза. Иген үстереп, күп итеп аяклы мал асрап яшәгән өч мәчетле татар авылы урамнарына моң агыла. Боларын миңа әтием Габделбарый сөйли иде.

1863–1936 елларда яшәгән дин эшлеклесе Хәсәнгата Габәши, 1891–1942 елларда яшәгән Хәсәнгата улы композитор, педагог Солтан Габәши, 1941 елны туган күренекле археолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты Солтан улы Рөстәм Габәши — бу нәсел дә «Җәнбәт җәвере — җиде табын» ыруының бер тармагы. Пианино моңнарын кече яшьтән үк тыңлап үскәнлектән, Солтан Габәшигә көйләр чыгаручы, профессиональ композитор булып китәргә бу бик зур этәргеч булгандыр. Бу затлы музыка коралында өч-дүртләп көйне әтием үзе дә бик йөгерек уйный, кушылып җырлап та җибәрә иде.

Әхмәтҗан бабамның өлкән абыйсы Әбү-Бәкер агаебызның балалары булмаган. Гел кәрваннар куып йөргәнлектән, әллә өйләнергә дә өлгермәгән?! Фотосы исән әле. Ул бик ярау кеше булган. Кыска гына кара сакаллы, кысыграк күзле, бераз юанаеп килүче агайның өс-башы шәрык зыялыларныкына охшаш, бик затлыдан. Кулында балдаклар. Куен кесәсенә салган сәгатьнең алтын чылбыры күренә. Үз балалары булмаганлыктан, Әбү-Бәкер абзый энесенең балаларын бик яраткан. Ә бер кайтуында энесе Әхмәтҗаннан тугыз-ун яшьләрендәге улы Хәсәнне, ягъни минем булачак бабамны, аңа арка кашучы малай итеп бирүен сораган.

— Курыкма да, борчылма да, балигъ булып җитешкән көннәренә үземнән зур өлеш чыгарып, йөреш маллы бай сәүдәгәр итәрмен. Казанда кибет ачып бирермен, — дигән.

Безнең татарда арка кашыту бик табигый хәл. Бүгенгечә әйтсәк, массаж бит инде. Гел юлда, гел сәфәрдә, кайчак еш кына ачык һавада, шалашларда кунарга туры килгәнгә, Әбү-Бәкер агайның да аркасы кычытуы бик табигый. Арка кашудан да бигрәк, әлеге ун-унбер яшьләрендәге бабам Хәсән кәрван ялга туктаган бер җирдә самовар куеп чәй кайнатырга тиеш була. Алай череп баеган Әбү-Бәкер агайның башка ялчылары да булгандыр. Әмма алар ятлар. Алардан теләсә нинди этлекне, мәкерне көтәргә була. Эчәсе чәеңә йоклаткыч салырга да күп сорамаслар. Ә бу малай — үз каныңнан, үз нәселеңнән. Хәсән бабам Һиндстан чәен чәйнектә үзе пешереп, беренче касә чәйне дә үзе эчеп күрсәтә торган булган.

Андый шартларда малай кеше тиз җитлегә. Ул тиз арада кәрванны барлап, малларга күз-колак була башлый. Безнең Хәсәновлар нәселенә нигез салучы Хәсән бабам Әбү-Бәкер агасы белән күп дөньяларны кичә, исәп-хисап эшенә төшенә, күп телләрдә сөйләшә: япон, фарсы, һинд телләрен белә. Кәрваннар куып, Казанга, Мәкәрҗәгә шәрык тауарларын ташыйлар.

Шулай берчакны мул тауар төяп Әфганстан якларыннан кайтканда, Әбү-Бәкер агабыз кәрванына дала пиратлары, бүгенгечә әйтсәк, рэкет һөҗүм итә. Аму-дәрьяны кичкәндәрәк була бу фаҗига. Атыш, кырылыш, кан кою башлана. Юлбасарлар аларны алдан ук көтеп, сагалап торып, нык хәзерлек белән каршы алганнар. Кәрван сакчылары, дөя куучыларның күбесе сатлыкҗаннар, шундук бандитлар, юлбасарлар ягына чыгалар. Атыш вакытында Әбү-Бәкер агабыз да һәлак була. Инде егерме тирәләрен тутырып килгән, кәрван башы булып йөргән минем булачак бабам Хәсәнне юлбасарлар әсир итәләр. Кул-аягын бәйләп үзләре белән алып китәләр. Бер кышлакка илтеп зинданга ябалар. Кем икәнен күреп торалар бит, бик зур күләмдә йолым билгелиләр.

Үземнең алты көннән ятим калган балачагыма җитү өчен, җәмәгать, бу вакыйгаларны, ярсу аргамакка атланып, аны бертуктаусыз камчылап язам. Аягына богау салгач, караңгы зинданга илтеп япкач, Хәсән бабама йолым җибәргәнне көтеп ятарга гына кала. Ә бу чорларга Әбү-Бәкер агасы белән бергә байтак капитал туплап өлгергән булырга тиешләр. Әмма үзе юкның күзе юк. Әбү-Бәкер абзыйның һәлак булуын белгәч, Казандагы туганнары сөенгәннәр генәдер. Кеше малына кызыгып, көнләшеп яшәүчеләр азмыни бу дөньяда? Ә бу байлыкларның хаклы варисы Хәсәнне коллыктан ни

дип йолкып алырга? Ятсын шунда сөяге черегәнче. Шушы яклардан узган Казан сәүдәгәрләре аша, үзен коткарырга акча сорап, туганнарына күп хатлар җибәрә бабам. Әмма Казаннан бер тиен дә килми. Ул арада акча көтә-көтә дүрт ел узып китә. Тора-бара аның богауларын салдыралар. Далада куй көтә башлый, әлбәттә, башка көтүчеләр карамагында. Җирле халык — төрекмәннәр белән дуслаша. Җиде-сигез телдә бик иркен сөйләшкән бабам кышлакта балалар укыта. Җирле халык аны нык ихтирам итә. Ә йолым акчасы килми дә килми. Хәтта аның хәл-әхвәлен белешкән кеше дә юк.

Бабама егерме дүртләр тирәсе, ул качарга ниятли. Дала сукмаклары ябык. Аны хәзер эләктерәчәкләр. Качсаң, Аму-дәрья буйлап боз өстеннән камышларга яшеренеп кенә качарга була. Шулай качып барганда, бабам бәкегә юлыга, суга чума. Чыга алмыйча байтак сәгатьләр азаплана. Бәхетенә, аны бер чабан төрекмән күреп ала. Ул аны коткарып өенә алып кайта. Төрле шифалы үләннәр төнәтмәсе белән дәвалый, аякка бастыра. Әмма Казанга бабам үпкә авыруы ияртеп кайтып төшә. Беренче эше итеп сәүдә эшләрен тәртипкә китерә. Хәзерге Бауман урамы, «Татар ашлары йорты»на каршы ике катлы пулатта ул чакта ук кибет була. Бабам шунда баш приказчик булып «йомшак алтын», ягъни затлы мехлар белән сәүдә итә башлый. Үпкәсе борчый башласа, төрекмән якларына, Аму-дәрья буйларына кымыз эчәргә баргалый. Аннары өйләнеп җибәрә. Беренче баласы — минем әтием Габделбарый — 1914 елда, аннары әтиемнең бик яраткан сеңлесе Марзия апа туа. Тукай урамында, трамвай тукталышы белән янәшә генә, аскы каты таштан, өскесе юан бүрәнәләрдән салынган җыйнак кына ике катлы йорт бар иде. Ялгышмасам, бу йортның аскы катында 17 нче аптека иде. Бу йорт — Хәсән бабамның өе. Бай, җитешле тормышта яшәгән булсалар кирәк. Әтиемнең: «Асраулар, өй хезмәтчеләре тоттык, әтине эшенә пар ат җиккән тарантас белән килеп алаларые», — дип сөйләгәне хәтеремдә. Хәзерге кара «Волга» дип укыгыз!

Бик укымышлы, кешеләргә бик шәфкатьле, бик юмарт бабам утыз сигез яшендә, һаман да шул үпкәсе шешеп, шушы йортта вафат була. Шундый бай башы белән аңа ярлы кызы димләмәгәннәрдер инде, хатынлыкка ярлы кызы алмагандыр. Бай кызлары бит алар байлыкның кадерен белмиләр, аларга булган байлыкны әрәм-шәрәм итү генә хас. Бабамнан өелеп калган мал-мөлкәтне бүлешергә «Җәнбәт җәвере — җиде табын» варислары күп табыла. Алай да арада аек акыллылары да булган икән. Мал бүлешеп күп тарткалашсаң, Бауман (ул чактагы Проломный) урамындагы кибетнең дә кулдан ычкынып куюы бар. Нәселгә ят, чит затларны кертү дә мәслихәт гамәлләрдән түгел. Әллә нинди бозык затларга тап булуың ихтимал. Ә бабамның утыз ике яшьләрендә тол, ике канатсыз калган хатыны — минем әбием Васфикамалны тиз генә арада янә ике канатлы итәргә кирәк. Дүрт яшьлек улы Барый, ике яшьлек кызы Марзия бар барын. Әмма аларның ни комачавы?! Малың мул икән, балалар йөк була димени?! Җәнбәтләләр — бабамның туганнары — ике бала белән яшьли тол калган киленнәрен тиз генә Ярулла абыйга кияүгә бирәләр. Бабамның туганнан туганы була ул. Миңа сөйләүләре буенча, Ярулла абый бик мут кеше булган. Ырынбур ягыннан атлар да, сарыклар да китереп саткан. Сыраны да мичкәсе белән эчкән, маржалар белән дә гүләйт иткән, акчага кәрт тә уйнаган. Бер тиен акчасыз йөргән чаклары да күп булган, Ырынбур якларыннан чабыш атлары китереп саткан, бай чакларында артыннан ияреп йөрүче хәер сораучыларга вак көмешләрне учлап-учлап та сипкән. Юкса аны «йомшак алтын» кибетендәге баш приказчик урынын саклау, мал-мөлкәтне тагын да арттыру нияте белән өйләндерәләр. Кая ул?! Мондый байлыкка чумгач, Ярулла абый гүләйт итүдән айнымый. Өстәвенә нәкъ ике елдан соң әбием Васфикамал кинәттән вафат булып куя. Ярулла абыйны балдызына, ягъни әбиемнең бертуган сеңлесе Бибикамалга өйләндерәләр. Төп максат — нәселгә ятларны кертмәү. «Йомшак алтын» кибетен кулдан ычкындырмау. Ярулла абый белән Бибикамал апа никахыннан Әнвәр абый белән Рауза апа туалар. Хәзер барысы да мәрхүм инде. Кеше баласы кемгә хажәт? Тукай урамындагы әлеге асты таш, өске каты юан бүрәнә йортта әти белән аның сеңлесе Марзия апага урын калмый. Аларны приютка илтеп тапшыралар. Әтием приютта танылган шагыйребез Мөхәммәт Садри белән бер бүлмәдә торган. Бу — 1922–1926 еллар. Әтигә ун-унике яшьләр. Алар икесе дә шигырь язганнар. Бу ике «өметле яшь шагыйрьләр» янына һади Такташ килеп йөргән. Аларга куен дәфтәрләре, карандашлар биреп китә торган булган. Һәр килгәнендә малайларга берәр бөтен ак ипи дә кыстырып килгән. Ашау ягы приютта бик кысынкы иде, дип сөйләр иде әтием.

Әти белән Мөхәммәт абый гомер буе бик дус яшәделәр. Без Дөбъязда торганда, әти районның «Колхозчы» газетасы редакторы иде. Мөхәммәт абый безгә бик еш кунакка кайта. Йә булмаса, тарантас җигеп, Казанга үзем килеп алам. Мөхәммәт Садриларга үзебез дә кунакка бара идек. Инде мин әдәбиятка килеп, байтак кына китаплар чыгаргач та, Мөхәммәт абый, миңа исем-фамилиям белән дәшмичә: «Барый улы, балачак дустымның малае», — дип йөртә иде.

Тормышның көлкеле ягы күп аның. Әтиләр торган приют хәзерге Горький паркы каршындагы кызыл кирпечтән салынган зур йортта булган. Ул бина хәзер дә исән, хәзер анда хәрби госпиталь. Бераһы бу йорт Татарстан коммунистларының Югары мәктәбе дә булып торды. Җитәкче урыннарда эшләргә гыйлемең саерак дипме, әтине шунда укырга җибәрделәр. Үземә әни табу тарихымны алда язармын әле. Әни белән икәү шунда без әтинең хәлен белергә киләбез. Әни күчтәнәчкә күкәй пешереп, Казан кабартмасы салып баргандыр инде. Әти безгә бер капчык сохари киптереп куя. Үзләреннән

калган ипи сыныкларының бер телемен дә әрәм итми. Ул чорларда ни дәрәҗәдә яшәү, тереклек итүебезгә үзе бер шәрех. Әти безгә нәкъ менә приютта үзләре яшәгән бүлмәгә туры килүе турында сөйләгәние. Хәл белергә Мөхәммәт тә килеп китә, приютта бергә яшәгән егерменче елларны бик рәхәтләнеп искә төшереп утырабыз, дигәние.

Кайчакларны, тырнак астыннан гел кер эзләгән кебек, ул заманның тетмәсен тетеп салабыз, әмма бу власть яшь буын, балалар турында нык кайгырткан. Приют яшеннән чыккач, әтине, ФЗӨгә (фабрика-завод өйрәнчекләре мәктәбе) күчереп, трамвай йөртүчелеккә укытканнар. Аннары ул Казан урамнарын дер селкетеп трамвай йөрткән. Төнге сменаларда трамваен чабыш аты кебек «камчылаган». Бар хутына җибәрсәң, трамвай ул самолет урынына оча, дип сөйләрие. Очар инде, бар, рельстан чабучы машина! Аларын инде энекәшләр белән бер-беребезгә күз кысышып кына тыңларыек.

Казан урамнарын дер селкетеп трамвай йөрткәндә, аны комсомолга алганнар, педучилищега керткәннәр. Аны тәмамлагач, мин туачак Дөбъяз районы Кече Кавал авылы җидееллык мәктәбенә директор итеп җибәргәннәр. Шунда ул әнием Шәрәфелбәнат белән танышкан. Әнием бик чибәр булган. Бу юлларны мин үземдә сакланган фотоларга карап язам. Ул Мәскәүдә яшәгән. Кистергән чәчле, шул заман модасында, бик затлы киемнәрдән. Әтием фатирга төшкән урта хәлле агайның кызы, җәйге ялга авылга кайткан булган. Әтием белән шулай танышканнар. Башта ук шуны искәртеп куйыйм әле. Әтием совет үстергән, аның кырыс вә сыйнфый тәрбиясен алган, җаны-тәне белән советка бирелгән зат иде. Аның яраткан җыры:

Итек, шинель, фуражканы
Без киябез бит аны.
Яшәсен совет власте,
Без сөябез бит аны!

Сикереп менә, сикереп төшә
Кызылармеец атларга.
Бүгеннән үк чыгып китәм
Совет илен сакларга, —

иде. Башыннан фуражкасын төшермәде. Кибеттә булмаса, тектереп киде. Хром итектән башка аяк киемен танымады. Кышын фетр, җәен хром итек киде. Тормыштагы көндәлек кимчелекләрне дә, хәерчелекне, нигә тотынсаң, шул нәрсәнең җитешмәвен дә ул власть гаебе итеп түгел, ә урындагы җитәкчелекнең булмаганлыгы, үз эшләренә салкын каравы итеп кабул итте. Безгә дә — балаларына — шулай дип аңлатты. Коммунистлар партиясенең ялкынлы пропагандисты булып яшәде һәм шулай үлеп тә китте.

Әнием мандолинада уйнаган, матур тавыш белән җырлаган. Миңа авырлы чакта, балама киертермен дип, йоннан бик матур күлмәкләр бәйләгән, чиккән. Нигәдер, күңеле сизепме:

Биек тауларның башында
Бригадирлар җир бүлә.
Бик яратып сөйгән ярлар
Йә аерыла, йә үлә, —

дип җырлый торган булган.

Матур итеп чиккән күлмәкләрен, йомшак йоннан бәйләгән кофталарын миңа киертеп шатланырга, мине кулларына алып үчти-үчти итәргә насыйп булмаган шул бәгыремә. Байтак еллар узгач, туганнарым миңа аның тагын бер җырын җиткерделәр.

Үзем җылыйм, үзем җырлыйм,
Үзем карлыган өзәм.
Эчем тулы утлар яна,
Яшьлегем белән түзәм, —

дип җырлаган ул.

Үләсен, мине ятим калдырасын сизде микән әллә җанашым, алтын алмам? «Әни!» дип әйтәсем, берәрсенең җылы кочагына барып сыенасым килгән минутларым күп булды тормыш юлымда.

Болай була ул. Бу кадәресен, бераз үсә төшкәч, мин әтидән бәйнә-бәйнә сораштым. 1937 елның кышы бик холыксыз килә. Инде декабрь уртасы, әле кар күренгәне юк. Салкыннар еш кына егерме-егерме биштән өстә булып ала. Юлга чыгыйм дисәң, ни арба, ни чана җигешле түгел. Минекеләр бәбәй көтәләр. Декабрьнең шундый шыксыз бер киченде әнием тулгаклый ук башлый. Әти — коммунист, мәктәп директоры. Авылның иң алдынгы карашлы кешесе.

— Беренче һәм көтеп алган баламны кендек әбисе ярдәмендә тудырып торырга! Мин, коммунист башым белән! — дип, ишегалдына арба җиккән ат белән кайтып керә.

Аяк атлый алмаслык катлак, даңгор-доңгыр дип тормый. Әнине бездән унике чакрымнардагы Мәмдәл участок больницасына алып чыгып китә. Дөрес, арба өстенә калын итеп йомшак печән түшәгеннәр, калын киезләр салганнар. Әнине дә җылы толыпка төреп утыртканнар.

Әмма алар басу капкасын чыгуга караңгы төшә. Декабрьдә көннең озынлыгын үзегез беләсез, нибары бер карыш. Алар артыннан ук котырып буран чыга. Алар адашалар. Ул елларда Ильич утлары юк бит әле. Төннәрен авылдан читкә ике адым китү белән адашасың. Әтием, атын йөгәненнән җитәкләп, Мәмдәлгә таң алдыннан гына килеп керә. Ачы тулгаклары килгәндә, юлда әнием карга да төшеп-төшеп утырган булырга тиеш. Әти аларын ук әйтмәде. Бу кадәресе — әбием фразы. Мин туганмын. «Шыр кычкырып килеп чыктың якты дөньяга, улым», — дип әти сөйләде. Әмма больницада бик салкын булган. Бүлмәләренә ягылмаган. Мин тугач, әти әнине кире алып кайтып киткән.

Кышның бу чорында авыл җирендә дә җылы почмаклар аз була. Мин яхшы хәтерлим, без үскән чорларда да иң җылы итеп яккан өйләрдә дә иртәнгә чиләктәге су чырый торганые. Авыл җирендә иң җылы җир — җылы итеп яккан мунча. Дер-дер килеп калтыранучы әниемне Габдрахман бабамның ак мунчасына кертеп салалар. Шунда температуралап ут эчендә биш көн ята ул. Хәзерге заман булса, көчле антибиотиклар кадап, терелеп тә киткән булырые, бәгырькәем. Алтынчы көнендә генә аңына килә.

— Баламны китерегез, — ди. Китерәләр.

— Биләүдән чишегез, — ди. Чишәләр.

— Иреннәремә якын китерегез. Үбеп үлим, — ди. Үптерәләр.

— Балама күкрәгемне каптырыгыз, — ди. Каптыралар.

— Бик якты хыяллар белән күтәргәнием сине, балам, — дип башымнан сыйпый. — Үләм, бәхил бул! Дөньялыкта бәхет белән, дәрәҗә белән яшә! — дип авыр тын ала. — Баламны ташлый күрмәгез! — дип пышылдый да җан бирә.

Мин һаман да имчәк кабып ятам икән әле. Әнием җан биргәндә, умарта корты, елан чаккандай, кинәттән чыр итеп елап җибәргәнмен. Әнием кая, нигә миңа ими бирмисез дигәндәй, сыным катканчы елаган чакларым күп булгандыр инде. Аларны кем санап, кем исәпкә алып торган...

Ал булганчы, гөлләр булсам,
Сулар сибәрләрие.
Сабый чакта үлгән булсам,
Сагынып сөйләрләрие, —

дип тә җырлыйбыз бит. Әнием исән калган булсачы... Ә Тәңребез башкачарак күрсәтмә биргән шул. Юк, хәерлегә юрамыйм мин моны. Әнием исән калсын иде...

— Улым, әниеңнән алты көнлек кенә калсаң да, алай елак бала булмадың, — дип, әтиемнең күп тапкырлар сөйләгәне булды.

Ул бит мәктәп директоры, гел мине карап утыра алмагандыр. Ә менә бабам Габдрахман белән дәү әнием Маһруйбикәгә эләккәндер. Мин көйсезләнгәндә, ими сораганда кая керер җир тапмаган чаклары күп булгандыр. Җитмәсә, әнием мәрхүмә булгач, дәү әтием, дәү әнием белән әтием арасында кискен конфликтлар башлана...

Дәү әнием урта бармак буе гына вак куыклар, ягъни шешәләр табып алган. Менә шуларга кәжә сөте салып, икесе дә икешәрне култык асларына салып тоталар икән. Кайнар да түгел, салкын да. Нәкъ менә кеше тәне температурасы. Мин елый, ашарга сорый башласам, авызына имезлек куеп, шул шешәне каптыралар икән. Салкынны каптырсаң, миңа салкын тиюе бар. Кайнарны бирсәң, авызым пешәр. Дәү әнием Маһруйбикә белән дәү әтием Габдрахман бер ел тулганчы мине шулай караганнар, авызымнан әлеге татлы шешәләрне өзмәгәннәр. Витамин-мазар җитешмәүне булдырмас өчен пешкән дөге, пешкән солы суы эчерткәннәр. Эчең катса, кара җимеш суы, эчең борса, шундук шомырт суы эчертә идек, дип сөйләрләрие. Ана сөтен бер тапкыр да татып карамагач, ничек рахит булмады икән миңа, дип тә уйлаганым бар. Болай хасиятләп карагач, ничек булсын инде ул рахит? Төнге йокыларын калдырып, мине туп кебек түгәрәк итеп тәрбияләгән дәү әтием Габдрахман белән дәү әнием Маһруйбикәгә меңмең рәхмәтле мин. Әмма аларны исән чакларында бер әчмуха хуш исле һинд чәе, бер кадак татлы мармелад белән сыйлый алмавыма үкенәм. Чал чәчемне уып үкенәм шуңа, гәрчә гаеп миндә булмаса да. Сәбәпләре бик зурдан аның. «Тормыш — якасыннан алып, инәсен ормыш» дип юкка гына әйтмәгәннәр шул инде.

Дәү әнием Маһруйбикә дөньяның бер чибәре булган. Аларын миңа күрше карчыклары әйтә иде. «Чибәр хатын тоттым, яхшы ат җиктем, улым, син дә миңа охшарга тырыш», — дигән сүзләрне исә ничәмә тапкырлар дәү әтием Габдрахманның үз авызыннан ишеттем.

Эт каешы

Бик еш күрсәтте миңа бу тормыш азау тешләрен. Үз ихтыярымнан башка, нарасый хәлемдә кулдан-кулга, өйдән өйгә күчеп йөрүләр аеруча күңелсез көннәр булып истә калган.

Шундый бер эпизод бүгенгедәй күз алдымда. Сугыш алды еллары инде бу. Миңа яшь ярымнар-ике яшьләр булырга тиеш. Без Дөбъяз районы Иске Көек авылында яшибез. Ул елларны укытучыларны авылдан авылга, районнан районга бик еш күчереп торалар иде бит. Әтине мәктәп директоры итеп шушы авылга күчергәннәр. Май-июнь айлары булса кирәк, бик матур кояшлы көн. Мин, туп кебек түп-түгәрәк малай, бик кыенлык белән генә тып-тып басып, өйалды баскычыннан җиргә төшмәк булам. Кулымда — өстенә вак тоз сибелгән ипи кыерчыгы. Аста, җирдә, җылы, тәмле сөт белән тулы җилене җиргә тияргә торган карт кәҗә мин төшеп җиткәнне көтә. Минем кулдан ипи алырга өйрәткәннәр аны. Бу акыллы җанның ап-ак бөдрә йонлы ике бәтие янында ук. Алар минем көндәшләрем. Әмма мин җиргә төшеп җитеп, кәҗәгә ипи кыерчыгын каптырам да җылы сөт тулы имчәкләрне эләктерәм. Рәхәтләнеп җиргә ятып имә дә башлыйм. Авызыңны ачып торсаң, имчәкләрне бөдрә йонлы бәтиләрнең эләктерүе бар. Шунда, баскыч төбендә үк, ниндидер ике хатын да бар. Кемнәрдер инде алар?.. Мине сөяргә кергән күрше хатыннарымы, әллә башкалармы? Батист яулыкларының бер чите белән күзләрен сөртә-сөртә, авыл хатыннары тын гына елыйлар.

— И-и, балакай, и-и, бәхетсез нарасый! — дип кабатлыйлар. — Әнисе исән булса бу баланың!..

Минем аларда эшем юк. Миңа шундый рәхәт, авызым тулы җылы сөт. Миңа бүтән берни кирәкми. Кикерә-кикерә имәм. Дөнья матур, дөнья киң. Миннән күреп, карт кәҗәнең ике бәрәне дә бер имине эләктермәкчеләр. Мин инде усалланып беткәнмен, тегеләрне этеп кенә җибәрәм. Ә кәҗәкәй, изге жан, мин аның сөтен имеп туймыйча, баскан җиреннән кузгалмый. Шулай өйрәткәннәрдер инде. Бераздан имүемнән туктап, кәҗә астыннан башымны чыгарып, елап торган хатыннарга гажәпсенеп карыйм. Ни дип елый икән бу бичаралар? Ни җитми икән боларга? Әнә көн нинди матур... Кояшлы...

Кан тартмаса, жан тарта дигәндәй, беләсезме, миндә, гомумән, кәҗәләргә карата тирән туганлык хисе бар. Аларны туганнарымдай сөясем, ипи катысы белән сыйлыйсым килә. Көтүләренә кушылып, текә тау битләренә үрмәлисем килгән чаклар да була. Кәҗә асраганыбыз юк. Асрасаң, суярга туры килүе бар. Аларга мин пычак күтәрәмме соң? Аллам сакласын!

* * *

Тормыш аңа хәтле дә ал да гөл булмагандыр. Әмма бер яшь тулгач, күрә башлый минем башкайлар күрмәгәнне. Дәү әтием белән дәү әнием мине «Әти кәкәй!» дип әйтергә өйрәтәләр. Әти исә «Дәү әти, дәү әни кәкәй!» дип әйтергә өйрәтә.

Дәү әтием Габдрахман белән дөньяның бер чибәре дәү әнием Маһруйбикә, әниемнең кырыгы узу белән:

— Барый кияү, син әле бик яшь. Янәдән өйләнерсең, яңа гаилә корырсың. Балаларың тагын булыр. Альбертыбызны безгә бир. Кызыбызның төсе бит. Үзебез үстерик, — дип, әтидән мине сорый башлаганнар.

— Кышкы катлакта җәһәннәм астындагы урыс бүлнисенә чыгып китеп, мәк чәчәгедәй балабызның башына җиттең, — дип тә ычкындырганнар бугай.

Тормыш булгач, бер-береңне гел мактап, башыннан сыйпап кына тормыйсың шул. Колачын җәеп, мине кочарга килгән әтиемә:

— Әти кәкәй! — дип әйткәннәрем хәтеремдә.

* * *

Дәү әтием Габдрахман җай чыккан саен мине Кече Кавалга урлап китә. Ә җае чыгып кына тора. Әти көнозын мәктәптә. Үзе директор, үзе дәресләр дә алып бара. Мине генә каравыллап утыра алмый.

Бүгенге яшь гаиләләр нарасыйларның «пес-пес» проблемаларын, памперс кулланып, җиңел генә хәл итеп куялар. Шулай булырга тиеш тә. Тормышта гел шулай. Арыш-бодай көлтәләрен чабагач белән пәч тә пәч бәреп кыйнаганчы, комбайн аша уздыру мең өлеш уңай да, ипле дә, тизрәк тә. Без нәни, без нарасый чакларда хәзерге памперслар, әлбәттә, юк иде. Аның каравы төпсез ыштаннар хутта иде. Башкача мөмкин дә түгел. Бер яшеннән тәпи йөреп киткән, әмма әлеге «пес-пес»ен әйтә белмәгән нарасыйга төпле ыштаннар каян юнәтеп бетерәсең? Урам бурзае төсле, туктаган бер җирендә пес-пес итеп йөргән малайга диген. Кадерле әби-бабайларыбыз, әниләре булганнарның әниләре без шайтаннарына төпсез ыштан кидерәләрие шул.

Дәү әтием Габдрахман мине әтием кулыннан чираттагы урлап китүләренең берсендә үзем дә ишегалдындагы чирәмлектә төпсез ыштан киеп гамьсез уйнап йөри идем. Велосипедына атланып, ишегалдына ажгырып әти килеп керде. Керү белән мине кочагына алды. Мин чыр-р итеп кычкырып җибәрдем. «Дәү әти кәкәй! Дәү әти кәкәй!» — дип кабатлап елый ук башладым. Еламаска соң, миңа төпсез ыштан киертүнең икенче хикмәте дә бар. Бу юлы урлап китүендә дәү әти мине сөннәткә утыртты. «Пес-пес»емнең башы кутырлы, каз мае сөртеп, чүпрәк белән бәйләп куйган хәлдә. Кая анда төпле ыштан, төпсезе белән дә ботымны ерып, көчкә атлап йөрим.

Белмим, бәлки, фантазиям продукты гынадыр. Сөннәтче бабайны, ата алдакчыны, бүген дә хәтерлим төсле. Бик хәйләкәр бабай иде бугай ул. Кыркыган чал чәче, кыска сакалы, кысык күзләре истә калган. Мине алдап-йолдап алар сәкегә утырттылар. «Менә шушы төенчектән, улым, сандугач очып чыга», — дип, башта җайга гына төенчеген чиште. Сынык чалгыдан ясаган, агач саплы пәкесен чыгарды. Аны мич алдындагы утлы күмергә тыгып торды. Үзенчә дизенфекция ясавы булгандыр инде. Мин, дәү әтиемнән күбрәк такылдаучы, чын тел бистәсе, телемә остарып, сәкедә утыра бирәм. Картларга акыл сатам. Төенчектән сандугач очып чыкканны көтеп утырам. Ул арада дәү әтием белән әлеге карт мине шалт төртеп аударылар да, шалт Мөхәммәтҗан, сөннәтләп тә куйдылар. Пәкесе нык үткен булгангамы, башта берни сизмәдем дә. Аннары гына шырыйлап кычкырып җибәрдем.

Сөннәтче бабай:

— Менә, менә, улым, сандугач чыкты бит! — дип, минем авызга кошчык рәвешендәге таш сыбызгы каптырды. Фью-ю-ю! Сызгыра.

Ярама сибәргә дип төйгән нарат череген үз янчыгыннан чыгарганые, дәү әтием:

— Юк, юк, кордаш, үз нигезебез череген сибик! — дип, мич артыннан гына үзебезнең өй бүрәнәсе череге сипте. Чүпрәк тә урадылар төсле.

Дәү әнием:

— Балам, ятып тор, бераз ятып тор! — дип иркәләп маташса да, минме соң ятып торучы.

— Дәү әти кәкәй! Дәү әти кәкәй! — дип дулап, урамга ук чыгып киттем.

Әтием Кече Кавалдан ераста, Чуаш Илендә мәктәп директоры.

Әти килгән көнгә «пес-пес»емнең башы кутырлап, бәлкем, төзәлә дә башлаган булгандыр. Мине кулына күтәреп алгач кына авыртып киткәндер. Башка чакны, дәү әтинең өйрәтүе буенча мин аны: «Әти кәкәй! Әти кәкәй!» — дип каршы ала идем, бу юлы исә, аны капкада күрүгә: «Дәү әти кәкәй!» — дип кочагына ташландым.

Дәү әтиемнең мине сөннәткә утыртуын белеп алгач, әти җикеренде инде. Бер дә галәмәт. Нишләгәнен белмәде.

Дәү әтием:

— Кияү, шулхәтле кызмасаңчы, улым. Ул бит үзебезнең мөэмин мөселман баласы, кайчан да булса бер сөннәткә барыбер утыртасы бар иде бит, — дип, читкәрәк китеп кенә акланып торды.

— Мөселман баласы түгел, коммунист улы ул! Без коммунистлар халыкларны андый категорияләргә аермыйбыз. Безнең лозунг: «Барлык илләрнең дә пролетарийлары, берләшегез!» — дип, үз концепциясен сөрде, дәү әтиемне сыйнфый артталыкта гаепләде, судка бирәм, дип янады.

Әти мине үзе укыткан Чуаш Иле авылына алып кайтып китте. Бераһы аларның арасы нык суынып торды. Суынып тору гына түгел, ныклы платформага корылган политика иде бу. Мин Кече Кавал турында гомумән онытырга тиеш идем. Үгилек турында сүз дә булмаска тиеш. Төптәнрәк уйласаң, дөрес политика инде. Максат бит — мине бәхетле итү. Мин үземне ятим итеп тоймаска, үз әнием, үз әтием дип яшәргә тиеш. Әмма безнең татарда үз эченә күп мәгънәне туплаган «бала тәресе» дигән төшенчә бар. «Тәрә»нең нәрсә икәнен барыбыз да яхшы беләдер. Әнә шул «тәрә»не берәү дә муенына үзе теләп такмый. Әмма тормыш тактыра. Менә шул «бала тәресе» дә әллә кемнәр белән аралаштыра, дуслаштыра, бер табынга утырта.

Сугышны без, әти фронтта йөргәндә, Ташлы Кавалда уздырдык. Сугыштан соң әти, Дөбъяз райкомында эшли башлагач, безне үз янына алдырды. Бу 1948 еллар. Ул чорларда миңа унбер-унике яшьләр. Кече Кавалда дәү әтием Габдрахманның барын миңа оныттырганнарые инде. Үз әниемнең үлүе турында да сүз кузгаткан кеше юк. Безгә, Дөбъязга, Кече Кавалдан бер матур гына карт килеп йөри. Әти аңа бик ягымлы. Күкәй тәбәсе кыздырып, чәй куя. Әти аны үз авылына Суыксуга җиткәнче ат белән озаттыра. Миннән! Бик сәер карт бу. Кече Кавалдан безнең Дөбъязга чаклы унсигез-егерме чакрымнар араны аягына чабата киеп килә. Дөбъязга керер алдыннан гына чабатасын салып, аягына штиблет кия. Чабатасын әрекмән арасына яшерә. Мин аны тарантас җигеп Суыксуга кадәр озатканда, әлеге карт авылны чыгу белән атны туктата. Йөгереп кенә әрекмән арасына кереп китә, аннан чабата киеп, штиблетын төенчегенә төреп чыга. Мин әзрәк сизенәм, гади генә карт түгел бу бабай. Югыйсә әти аны озатып куярга атын бирмәс иде. Бабай тарантас түрендә, ә мин, кучер буларак, кузлада. Кулымда дилбегә, камчы. Унбер яшьләремдә генә булсам да, атны җилле тотам. Шулай сүз куешканнардыр инде. Шунда әлеге матур карт, улым, мин синең дәү әтиең бит, дип, ник бер сүз ычкындырсын. Ничек түзгәндер, җанашым? Алай да, вакыт-вакыт үрелеп, аркамнан сөеп куяр иде. Шулай да сизә идем, бу сөйкемле карт безгә кай ягы беләндер бик якын җан. Шулай булмаса, әти үзенең кара айгырын бирер, бар. Шуннан соң дәү әтием, мин бит барын да беләм, шулай кирәк булгач нишлим соң, дип, ник бер кочып алып, чал сакал баскан битеннән суырып үпмәдем икән, дип, хәтта бүген дә бик үкенәм. Үзем дә оныклар үстерә башлагач, дөньяга карашлар үзгәрде... Ләкин кул изәп вагон артыннан чабудан файда юк, поезд инде күптән китте. Үкенечләрдән, үкенечләрдән, үкенечләрдән тора узган гомер. Бәлкем, һәркемнеке дә алай түгелдер ул? Ә минеке шулайрак... Ләкин сагынычлы үкенечләрдән.

Әти мине кемгә дә булса бирәме соң, җүләр! Бала җанлы зат иде ул. Туган-тумача дигәндә, гомеренең соңгы көненә хәтле җанын бирергә әзер булды. Ир кеше хатынсыз тора алмый. Әниемне җирләп, кайгылары бераз сүрелгәч, Асия исемле бер апага өйләнеп караган ул. Әтине күрше Чуаш Иле авылындагы мәктәпкә күчергәннәр, хуҗасыз йорт биргәннәр. Өйләнеп җибәрү белән, приютта калган сеңлесе Марзия апаны, әни бер, ата башка туганнары Әнвәр абый белән Рауза апаны алып кайткан. Минем белән дүрт бала, әти белән бишәү без. Мондый ала-кола төркем белән кем, нинди хатын торсын, егетләр, үзегез уйлап карагыз. Асия апа безне ташлап кача.

Институтта укып йөргән елларны миңа Ташкент якларыннан бик җылы хат килде. Асия ападан иде ул. Бездән котылгач, Ташкент якларына киткән булган. Шунда бик әйбәт кешегә тормышка чыккан.

«Альберт, улым, мин сине үз балам кебек яратканыем. Менә хәзер дә оныта алмыйм. Бу турыда тормыш иптәшем Шәүкәт абыеңа да елый-елый сөйләгәнем бар. Бер җаен табып, берәр айга туры үзебезгә кунакка килеп чык. Өс-башыңны да карап җибәрербез. Тормышыбыз җитешле. Сине бик күрәсем килә», — дип язылганые ул хатта.

Мәктәп директорының эше тавык чүпләп бетерешле түгел. Бигрәк тә безнең әти кебек эшенә муеннан чума торган кешенең. Әти мәктәптә чакта ат белән килеп, мине дәү әти белән дәү әни урлап китәләрие. Берәр атнадан, үзе белән участковый Хәбри абыйны да ияртеп, әти мине менеп ала. Аңарчы мине янәдән «Әти кәкәй!» дип әйтергә өйрәтеп куялар. Дәү әтиемнең кызы өчәү — олысы Рабига апа, аннары Мәрьям апа һәм минем мәрхүмә әнием Шәрәфелбәнат булган. Рабига апаларның Яңа бистәдәге өйләренә институтта укыган елларымда татарда иң затлы ризыклардан саналган әлбә ашарга барып йөри идем.

Әниемнең уртанчы апасы Мәрьям апа һәм аның ире Кәшиф җизни Мәскәүдә кибет тотканнар, алтын беләнме шунда, алка-йөзек, балдак-беләзекләр беләнме сәүдә иткәннәр. Балалары булмаган. Боларның гозер-тәкъдимнәре бөтенләй реаль җирлектә.

— Барый, җыйган малыбыз чутсыз. Ятларга калмагае дип кайгырабыз. Балаларыбыз юк. Бир безгә Альбертыбызны уллыкка. Безгә зур юаныч булыр. Сиңа шуны документлап ышандырабыз: баланы карап үстерербез, укытырбыз. Бар мал-мөлкәтебезне аңа яздырырбыз. Егерме яше булгач әйтербез: «Балакаем, син безнең улыбыз түгел. Әниең мәрхүмә. Әтиең исән. Бар, бәхетлебез, алдагы көнеңне үз әтиең белән күр. Картлыгыбызда безне дә ташлама», — диярбез. Габделбарый, хөрмәтле киявебез, зинһар, бир бу баланы безгә. Үз каныбыз бит, бертуган, бер карында яралган сеңлебез баласы! — дип ялынганнар.

Әти бирәме соң?!

Әти мәктәп эшләре белән мәшгуль булып йөргәндә, Мәрьям апалар да мине Мәскәүгә өч-дүрт тапкыр урлап киткәләделәр. Әти, җанашым, мине аннан да барып алып кайта. Аның үзенә дә әле нибары егерме өч яшь кенә.

Поездда кайткан чакта әтинең:

— Улым, Мәскәүгә, Кәшиф җизниләреңә бүтән китмисеңме инде? — дигән соравына:

— Трактор алып бирсәң, китмим, — дип шарт куеп утыруларым хәтеремдә.

Ул чорларда трактор районга берәү. Малай-шалайның аннан да ныграк исен китәргән нәрсә юк инде авыл җирендә. Гөрелдәве генә ни тора. Ян-якка, әйләнә-тирәгә нинди тәмле әчкелтем ис тарата. Ә кузгалып китсә, аяк астында җир дер селкенә.

Бер сүз кузгаткач, әйтеп бетерим инде. Йөз дә ике яшьләрен тутырып, Мәрьям апаны Яңа бистә зиратына быел гына җирләдек әле. Мине үз улы итәргә бик теләгән беренче ире Кәшиф җизни сугышта югалды. Яралыларны санитар поездында Мәскәү белән Ленинградтан Ташкент госпитальләренә ташыган. Сугыш башлангач, эвакуация белән Мәрьям апа да Казанга кайткан. Кәшиф җизнинең поезды бер тапкыр Казан аша узган. Яралыларны бушатырга Казанга кайткан Кәшиф җизни хатынын күрергә бер сәгатькә пропуск алган. Адрес буенча Мәрьям апа фатирын эзләп тапкан. Килсә, ишек бикле. Мәрьям апа хәрби заводта эштә. Кәшиф җизни кире вокзалга йөгерә. Килсә, состав кузгалып киткән. Саратовта гына үз составын куып җитә ул. Әмма анда аны дезертир дип «тройка» кулга ала. Хәрби чор, вак кына җинаять өчен дә беркемне дә кичермиләр, берәүгә дә ташлама да, шәфкать тә юк. «Тройка» Кәшиф җизнине атарга дип хөкем чыгара. Җизни бит поездын куып җиткән. Шуның өчен генә нүжәли атарлар икән? Хәрби трибунал архивы аша тикшерттек. Трибунал аңа амнистия ясап, хөкемен егерме биш елга калдырган, Себергә озаткан. Унбиш-егерме елга каторгага хөкем ителүчеләрне Свердловскида җыеп алганнар да алгы сызыкка, штрафбатка озатканнар. Кәшиф җизнәбез шунда хәбәрсез югалган.

* * *

Мин инде тел бистәсенә әйләнеп барам. Әмма әлегә әни юк. Әти өйләнеп кенә җибәрә алмый. Бер авызы пешкәч, шикләнә торгандыр. Артында озын койрыгы, ике яшьлек дегет чиләге булганга, аңа иргә — кияүгә бик атлыгып та тормаганнардыр. Коммунист, мәктәп директоры башы белән әтиемнең дә теләсә кемне аласы килмәгәндер.

Безнең Җәнбәтләр нәселеннән әтиемнең әтисе Хәсән бабамның энесе Галимҗан абый Ташкент тирәсендәге бер заставада командир иде. Ул бик каһарман кеше булган. Басмачылар белән аяусыз көрәшеп күп орденнар алган. Миңа ике-өч яшьләр тирәсендә Галимҗан абыйларга кунакка бардык. Үзе гаскәре белән тау араларында чик бозучыларны аулап йөргәндә, басмачылар, заставага һөҗүм итеп, аның хатынын, кызын суеп чыкканнар.

Галимҗан абый мине алдыннан төшерми. Бүгенгедәй хәтеремдә, чалт иткән кояшлы мәйдан. Бездәгечә, бүрәнәдән бурамаган, балчыктан сылаган өйләр. Галимҗан абый баш өстенә җәймә корган, талчыбыктан үргән кәнәфидә утыра. Җәймә күләгәсендә кояш ул кадәр кыздырмый, түзәрлек. Мин Галимҗан абый алдында карбыз ашыйм. Моңарчы күргән нәрсәм түгел, бик ошады ул миңа. Биленә озын кылыч таккан бер кызылармеец башта безнең янга авызлыгын чәйнәп торган кара айгыр алып килде. Аңа атландырып, мине бер түгәрәк әйләндерде. Әнисез үсеп, кулдан-кулга ияреп, мин эт каешына әйләнеп беткәнмендер. Куркып тормадым, айгырга шундук менеп атландым. Кызылармеец аннары ап-ак ат алып килде. Аңа атланып тагын бер түгәрәк әйләндек. Аннары баскан җирендә биеп торган бер алмачуар айгыр алып килделәр. Аңа да атланып карадым.

— Улым, айгырларның кайсын ошаттың? — дип сорады Галимҗан абый.

Башта мин:

— Өчесен дә! — дидем.

— Oho! Зәвык бар синдә! — дип көлемсерәп куйды Галимҗан абый.

Аннары мин алмачуар айгырга төртеп күрсәттем.

— Улым, алмачуар айгыр синеке! — диде командир абыебыз.

Галимҗан абыйда кунакта без ун көннәр генә торганбыздыр. Мине көн саен атка атландырып йөрттеләр. Күбенгәнче карбыз-кавын ашадым. Берничә көннән Галимҗан абый да мине әтидән уллыкка сорый башлады.

— Барый энем! Син бит минем якын туганым. Без — Җәнбәтнекеләр. Бир миңа уллыкка шушы малайны. Мин аннан бер дигән Кызыл Армия командиры ясыйм. Командарм Котовский, Маршал Тухачевский итеп үстерәм! — Галимҗан абый мине кулларына күтәрде. — Йә, егетем, минем улым буласыңмы?

Мин инде андый хәлләргә күнеккән. Шундук спекуляция юлына бастым:

— Кылычыңны миңа бирәсеңме?

— Бирәм! Мә, так!

— Револьверыңны да бирәсеңме?

— Бирәм.

— Алай булгач, булам синең улың!

Бу минутларда әтием ничек түзеп утыргандыр? Мин хыянәтченең колак төбенә ничек берне тамызмагандыр? Аңа карап әти мине калдырмады. Галимҗан абый, күп күчтәнәчләр биреп, безне поездга озатты. Вагонга керер алдыннан мине кочагына алды.

— Әтиең калдырмый, бирми бит. Юкса үзеңнән бер дигән кавалерия генералы ясый идем инде. Алай да исән-имин үсә күр, шайтан малае. Күргән хәтле арада да күңелемне бик юаттың. Гомер онытмам инде сине, — диде. Вагонга да үзе күтәреп кертте.

Әтине хатынлы иттем

Мин һаман әнисез бит әле. Моның нинди зур фаҗига икәнен миндәй әнисез калган нарасыйлар гына белә булыр. Шушыны раслау өчен бер мисал китерим әле. Укучыларыма гыйбрәт өчен. «Ватаным Татарстан» газетасының Әлмәт төбәге буенча үз хәбәрчесе булып эшләгән елларымда Алабуга балалар йортына, ягъни шул ук, әлеге дә баягы детдомга, приютка барып чыктым. Бу чорларда сүзем үтемле агай бит инде мин. Ятим балалар янына ничек инде буш кул белән керәсең? Дипломатыма күп итеп конфет-печенье, өреп тутыра торган шарлар, куыклар алдым. Башта ук әйтеп куйыйм, «детдом», «приют» дигән сүзләргә мин хәтта бүген дә бераз шикләнү белән карыйм. Чөнки әтиемнең ата-ана назына, балам дип иркәләү-сөюенә иң мохтаҗ чаклары шунда узган. Балалыгымның бер чатаграк чорында үзем дә чак кына эләкми калдым. Алла саклады инде...

Барып кердем. Бүлмәләр буенча йөртәләр мине, корреспондентны. Җәннәт эчендә яшиләр биредәге балалар. Һәр бүлмәдә идәндә дә, стеналарда да затлы келәмнәр! Бүлмәләрдә заманча җиһазлар, телевизорлар. Ашау-эчү, ризыкларның затлы булуы турында сөйләп тә торасы юк. «Әкият бүлмәсе» — чын әкият дөньясы! Ата-аналы балаларга мондый рәхәт тәтиме икән әле? Балаларның әле берсен, әле икенчесен алдыма алып сөям. Матурлар, көрләр, чисталар. Миңа алар биргән, алдымны күмгән конфетлар минекеннән дә затлырак, кыйммәтлерәк, тәмлерәк. Әмма менә ни хикмәт, алдыма кайсы баланы алсам да, маңгаема төбәп:

— Абыем, син кемне алырга килдең? Кемнең әтисе син? — диләр.

Мондый сорауга минем җавабым әзер түгел. Чөнки андый сорауны көтмәгәнием. Аптырабрак, ыкмык торуымны күреп:

— Абыем, минем әтием бул! Абый, мин сине бик яратам. Ал мине моннан! — диләр.

Өч-дүрт яшьлек балалар болар. Өс-башлары ал да гөл. Торган җирләре, әйткәнемчә, җәннәт. Әмма адәм баласы өчен үз өең, үз куышың белән, ярлы-бетәшкән, очын очка көчкә-көчкә ялгап яшәгән булса да, үз гаиләң, үз туганнарың белән яшәү тиңдәшсез зур бәхет икән. Ә мондый теләк — бу бичаралар өчен мәңге тормышка ашмастай хыял. Менә шулай, җәмәгать, хәлләр.

Кайсы баланы алдыма алсам, шунысы:

— Син кемне алырга килдең? Минем әтием бул, мин сине бик яратам! — диләр.

Бер генә малайны йә кызчыкны алып китәргә дә булыр иде. Бу турыда гаиләм белән дә сүз булганые. Миңа анда көләч йөзле, кысык күзле, бик матур вьетнаммы, кытаймы малае бик ошаганые. Кочып-кочып алды инде муенымнан. Тәмам сырышты. Киткән чакта чак аерып алдылар. Шул малайны алып кайтып, үз улым итеп үстерергә ният бар иде. Әйе, берәр баланы алыр идең дә, алар бит анда йөзәү. Ил буенча... Ил буенча күпме?

...Мин һаман әнисез әле. Бер авызы пешкәч, өйләнгән хатыны ташлап качкач, әти дә башлы-күзле булырга бик ашыкмый, ахры. Култык астына кыстырган портфелен бер дә төшерми. Ә минем өзелеп әниле буласым килә. «Күп балалы мәктәп директоры» дип даны чыккач, әти олы сеңлесе Марзия апаны Казандагы тегүчеләр хәзерли торган училищега урнаштырып кайтты. Кече сеңлесе Рауза апаны кире детдомга илтте. Янында уникe-унөч яшьләрендәге Әнвәр абыйны гына калдырды. Мине кararга яки миңа бераз күз-колак булырга. Мин дә усал, телгә дә бик оста. Марзия апа белән Рауза апаның әйткәннәрен колагыма да элмим, тарткалашам, әрепләшәм, сугышам. Бар сүзгә тыгылганым, чаманы белми күп сөйләшкәнем өчен миңа шул чакта ук «дәү әти» дигән кушамат тактылар. Мин Әнвәр абыйдан гына бераз шүрлим. Чөнки ул кеше-кара күрмәгәндә генә минем маңгайга шундый каты итеп чиертеп ала, корт чаккандай була.

— Әгәренки әләкли калсаң, «дәү әти», абый мәктәпкә төшеп киткәч, шушы нахал маңгаеңа тагын биш чикләвек кундырам, — дип кисәтә.

Приютта үскән, юньләп тәрбия күрмәгән бу хулиганнан тагын ни көтәсең? Ике дә уйламый кундырачак. Әләкләшми идем. Өстәвенә, мин аны бик ярата идем. Юк, Әнвәр абыйдан гына түгел, әтидән дә шүрли идем, чөнки ул, абау, кызу канлы кеше. Бер кызсамы?!

И-их, малайлар, минем шулхәтле әниле буласым килә. Чөнки Әни заты бернинди долларлар, фунт-стерлинглар белән дә бәяли алмаслык олуг Бәхет ул! Моны әнисез нарасыйлар гына түгел, ана булу бәхетенә ирешкән әлеге изге затлар үзләре дә танырга тиешләр. Чөнки ул — Әни заты — һәркем өчен бер генә. Ә бер генә данәдәге теләсә нинди әйбергә бәя бирү бик кыен шул. Ана булу бәхетенә ирешүчеләргә бигрәк тә! Шушы алтын хакыйкатьне күпләр белми дә бугай...

Минем белән уйнап йөргән, борын төпләре куыклы, битләре чат кутыр, өс-башлары минекеннән дә шапшаграк малайларны әниләре ничек кочып үпкәннәрен, һавада чөя-чөя, шап-шап сөйгәннәрен күрәм. Ә мин кемнән ким? Нигә минем генә әнием юк? Бу турыда мин әтидән болайрак уйлана башладым. Инициативаны үз кулыма алырга да ниятем бар. Бу турыда чынлап торып уйланам, планнар корам. Ятим балага акыл да иртәрәк иңәме соң? Иңә-иңә! Ятимлек — бик авыр йөк ул.

Без, һәр көн иртән-иртүк торып, әти, Әнвәр абый, мин, өчәүләп мәктәпкә төшеп китәбез. Китмичә, мине кая куйсыннар. Өчәүләп бер буш йортта яшибез. Ул чакларда авылда балалар бакчасы юк. Әтидә портфель, Әнвәр абый кулында сумка. Бик сорагач, миңа да йозагы ватык бер сумка табып бирделәр. Әтидән калышмыйм. Аныңча кыланам.

Урамда очраткан бар халык миннән кызык өченме:

— Улым, әтиең кем синең? — дип сорыйлар.

— Дилектол! — дим киерелеп.

— Ә син кем?

— Мин дә дилектол! — дим. — Әти дә дилектол, мин дә дилектол, — дип раслыйм. — Икебез да дилектол.

Укыту сәгатьләре беткәнче мин көне буе мәктәптә учительскаяда буталам. Кайсы укытучы иярtсә, шуның дәресенә керәм. Әтинең: «Улым, беркая да китмә, мин дәрескә керәм», — дигән сүзен еш ишетәм. Ул, директор буларак, укытучыларның дәрес бирүләрен тикшерергә керә бит инде. Эше, вазифасы шул. Әти авызыннан шул сүзне мин дә тулы мәгънәсе белән эләктереп алдым. Укытучыларның дәресләренә бик теләп керәм. Бераз рәсем ясап утырам, дәресен ошатмасам, чыгып та китәм. Ә еш кына, ике кулым өстенә башымны салып, рәхәтләнеп йоклап чыгам. Шунысы гажәп, мин йоклаганда, уяна күрмәсен дип, балалар класста тып-тын утыралар икән.

Тагын шунысы гажәп, бу юлларны мин бераз уңайсызланыбрак, тартыныбрак кына язам. Мәктәпнең учительскаясында көненә күп тапкырлар мине барысы да һавага чөя-чөя сөяләр. Мин аңа күнегеп беттем. Менә шул чакта барысы беравыздан дигәндәй:

— Карагыз әле, бу малайның маңгай чәчләре уелып кергән, зур үскәч язучы булыр бу! — диләр.

Нилектән шулай юраганнардыр? Гаҗәп бит, әй! Ә мин ул чакта язучының кем икәнен каян белим? Белсәм дә, бик кирәгие миңа язучы булу. Галимҗан абыйлардан кайтканнан бирле, кайда бичәүкә йә чабата киндерәсе күрсәм, шуны аркылы-торкылы тәнемә урыйм. Көне буена ул чуалып бетә.

— Мин командир булам! — дим. Билемә Әнвәр абый ясап биргән агач кылыч тагып йөрим. Ә тәнемә портупея итеп аркылы-торкылы ураган киндерәләрдән әтием мине кичләрен пычак-кайчы белән кискәләп кенә арындыра. Кызыл Армия командиры була алмадым бит, әй, гәрчә кокардалы фуражка, галифе чалбар, шыгыр-шыгыр хром итек миңа бик килешсә дә. Язучылык эшенә дә үзем дә сизми керешеп киттем шикелле. Ә профессиональ язучы дәрәҗәсе алганчы һаш-хлорны, ягъни аш тозын күп потлар ашарга туры килгәндер... Әмма үкенечкә түгел.

Ә мин һаман әнисез. Узган көзне әти директор булып эшләгән Чуаш Иле җидееллык мәктәбенә, Арча педагогия училищесын тәмамлап, озын толымлы бик матур апа килде. Өммегөлсем исемле. Ягымлы шундый. Озын толымнарын кулымда тотып, кыш эчендә аның алдында күп утырдым. Менә шушы Өммегөлсем апага кыш эчендә чынлап торып мәхәббәтем төште. Шушы апаны каерып алып әнием итәсем килә. Ләкин ничек? Нибары өч яшьлек ташбаш, яфрак колак башым белән менә шушы турыда иртә-кич тынмый уйлана башладым.

Әтине ФЗӨдә укыткан чакта ук фоторәсемгә төшерү эшенә дә өйрәткәннәр. Фотосөючеләр түгәрәгенә йөргәндер инде. Авыл җирендә бик тә кирәкле бу матур һөнәрен ул гомеренең соңгы көннәренә хәтле ташламады. Фотоаппаратлары да күп иде. Шул ике ярым-өч яшьләремдә төшкән фото сакланган, әй. Аннан миңа киң маңгайлы, бүрткән фасоль борчагыдай тулы битле, җәлпәк борынлы, зәп-зәңгәр зур күзле бер малай карый. Болай яшәү рәвеше начар булмаска тиеш аның. Башында бүрек, өстендә якалы пальто. Тик шул зәп-зәңгәр күзләрендә генә тетрәндергеч сагыш, моң сизелә. Әнисез булганга инде. Ай, бу әни дигән зат! Бер булмаса, долларга да алып булмый шул аны. Булганнарының кадерен белегез, укучыларым!

1941 елның бик матур кояшлы иртәсе, апрель ахыры-май башы. Атлаган саен «дәрескә кереп» туйганмындыр. Мәктәп ишегалдында уйнап йөрим. Ишек төбендә генә янгынга каршы куелган су белән тулы зур гына агач мичкә. Малайлар ясап биргән кәгазь корабларны бу мичкәдә минем күп тапкырлар йөздергәнем бар. Бу юлы, карасам, янымда гына, ямь-яшел чирәмлектә бик матур, берләре чуар-чуар, берләре сап-сары тавык чебешләре йөри. Мин боларны берәм-берәм сулы мичкәгә тутыра башладым. Үзем исә: «Йөзәләр! Йөзәләр!» — дип шар ярам. Өч-дүрт көнлек чебешләр ничек йөзсеннәр инде? Алар түгел, аларны басып чыгарган чуар әнкәләре дә йөзә белми бит! Чебешләр шундук төпкә китеп баралар.

— Башың да бетмәде инде, тәре баласы, чукынган нәрсә! — дип, чебешләрнең хуҗасы Нуржиһан апа килеп җитте.

Ул — мәктәптә җыештыручы. Бер-бер усаллыгым тимәсә, алай ук дип каргамас иде. Ачуын китергән чакларым булгандыр. Бер минут тиктормас бер шыптый малай идем бит.

— Йә Ходаем! Йә Ходаем! Күр инде бу бәлане! — дип, бот чабып еларга кереште.

Үземне дә мичкәгә генә саласы да, директор баласы бит. Мин үзем әлегә берни аңламыйм. Аптырашта. Ни дип елый бу Нуржиһан апа?

Тавышка, дәресен ташлап, әти йөгереп чыкты. Чыккан хутка ук миңа указка белән берне сыптырды. Әйтәм бит, әти бик кызу канлы кеше иде. Эшнең болайга баруын, дилбегәнең көпчәккә нык чорналуын сизеп, мин чаж — учительскаяга ычкындым. Керү белән — чож өстәл астына. Анда эләксәм, мине эт өстереп тә таба алмыйлар. Бу юлы әтине дә тыешлы түгел. Урындыкларны тибеп кенә очырып, өстәлләрне урыннарыннан дуылдатып күчереп, мине өстерәп чыгармакчы була. Әмма тотарсың мине, бар. Тотмый гына торсын әле! Чөнки өстәлләр астында рәтен-җаен мин генә белгән сукмаклар, лабиринтлар бар. «Дәрескә керәм» дигәч тә, озын кышны шул лабиринтларда уйнап уздырдым бит мин. Өстәлләр астында аулак, мине беркем дә борчымый.

Әмма бу юлы әтинең, җанашымның, ачуы тәмам ташып чыккан. Эләктерә калса, эш харап! Хәл критический ноктада.

Шунда мин егетегез бер өстәл астыннан атылып чыктым да:

— Әни-и-и! — дип кычкырып, теге күптән күзем төшеп йөргән озын толымлы, матур апаның муеныннан ике кулым белән кочып та алдым.

Әти мине җиңел генә йолкып алырга, өстәлгә салып ярырга бик очынып килгәние дә, «Әни-и-и!» дип кочып алган матур апам:

— Иптәш директор! — дип башлап, бик күп сүзләр әйтте.

Хәзер уйлыйм: педагогика фәненең балаларга каршы физик көч куллануны хупламавын, Макаренконың «Педагогик поэма»сын, нәрсә ярамаганны балаларга тел белән аңлатырга, төшендерергә киңәш ителгәнен, баланың нәкъ менә холкы формалашкан чорда физик көч куллануның аны рухи яктан гарипләндерергә мөмкинлеген искә төшергәндер ул сүзләр.

Бу матур апага мин исә сөлек булып ябыштым. Үзе дә мине кочагына ныграк коча төште.

— Бу олы юл юлбасары, чын бандит, тел белән әйткәнне аңлый торган җанмы соң? — диде әти, сукранып. — Җыештыручыбыз Нурҗиһанның сигез чебешен сулы мичкәгә батырган бит! — Әти кулындагы указкасын өстәлгә ыргытты да, ишекне тибеп кенә ачып, бүлмәдән чыгып китте.

Әти дары булып кыза, әмма тиз кайтып төшә торган гөнаһсыз бер җан иде, җанашым. Бераздан ул янәдән әйләнеп керде. Ә мин әле һаман да матур апа кочагында.

Әти хәзер йомшак тавыш белән:

— Улым, әйдә өйгә кайтыйк. Ачуым басылды инде. Нурҗиһан апаңны да ризалаттым, — диде.

— Юк, кайтмыйм мин синең белән. Өйгә кайткач, син мине брезент каешың белән ярасың.

— Кит инде, улым. Кайчан ярганым бар инде? Ят кеше алдында гомердә булмаган хәлләрне уйлап чыгарма инде, зинһар! Гөлсем апаң безнең турыда әллә ниләр уйлап куяр.

— Бер дә уйлап чыгармыйм. Сөтле чүлмәкне аударгач, әйбәтләп кенә ярдыңмы? Ярдың.

— Ул кичне сөтсез калдырдың бит. Ботка да пешерә алмадык. Бер-ике төшергәнмендер инде. Шуны да искә алып тормасаң, улым. Үзең дә бигрәк вакчыл инде.

— Кул сәгатеңне өстәлдән төшереп җибәргәч, бирдеңме кирәкне? Шыр кычкыртып...

— Ярар, ярар, улым. Бүтән бармак белән дә чиертмәм. Әйдә өйгә кайтыйк. Синең белән генә түгел, өйдә синнән башка эшләр дә муеннан. Әйдә киттек.

— Әнием безнең белән кайтса гына кайтам.

— Гөлсем апаң синең әниең түгел, улым. Син аны уңайсыз хәлгә куйма инде. Бераз байый төшкәч, җәйге ял акчаларын алгач, Мәмдәл базарына чыгарбыз да күңелеңә иң охшаган апаны сайлап алырбыз.

— Миңа беркем дә кирәкми. Менә минем әнием. Син минем әнием бит? — дип эндәштем кочагында утырган матур апага.

Матур апам да, әтием дә бик уңайсыз хәлдә — аптырашта... Минем аларда эшем юк.

— Менә минем әнием. Мин аны үзем таптым, — дип, Өммегөлсем апага сыенганнан-сыена гына барам.

— Әнием кайтмаса, мин да кайтмыйм. Аның белән калам. Шулай бит, әнием?

Башка чакта сүзгә кесәгә керүчеләрдән түгел иде әтием. Бу юлы ул да тамак кырудан ерак китә алмады. Баскан җирендә таптаныбрак торды да:

— Кич педсовет бит әле бүген. Мин өйгә кайтып тиз генә ашарга әзерли торам. Алайса, бергәләп кайтыгыз. Бездә кунак булырсыз. Көтәм, — диде. — Сез, иптәш Кәримова (монысы әниемнең фамилиясе), гафу итегез инде, әнә шундый беспардонный бала булып үсеп килә бу малай. Сез физик көч кулланмаска киңәш итәсез. Аны туры юлга чыгару өлкәсендә брезент каеш белән булмаса, тал чыбыгы белән бер яхшы гына ярсаң, бер дә зыяны булмас иде дип саныйм.

— Тал чыбыгы, имеш! Фу! Кит әле! — дип, мин дә сүзгә кушылдым. Чөнки аны да татыганым бар. Әйтәм бит, әтиемнең вакыт-вакыт гөлт итеп кабына торган холкы белән минем татымаган нәрсәм калмагандыр. Беркемгә дә бирергә теләмәсә дә, миннән туйган, тәмам гарык булган чаклары күп булгандыр инде бичарамның.

Ашарга әзерлим, дип зурдан кубып, авыз тутырып сөйләве шуннан гыйбарәт аның. Кайта да керосинкада, ярып, чикмәнле бәрәңге пешерә. Соңыннан чәй бик тәмле була дип, бәрәңгегә тозны да мулдан тондыра. Өстәл артына түгәрәкләнеп утырып, шул «чикмәнле бавырсак»ны әти, Әнвәр абый, мин көнбагыш маенда йөздереп-йөздереп алып сыпыртабыз гына. Кайчакларны бәрәңге арасыннан савытны юганда төшеп калган мунчалалар да чыга. Аларны без ипләп кенә бер читкә алып куябыз. Безнең гаиләдә гаеп итеш булмады. «Чикмәнле бавырсак»тан соң күп итеп кәҗә сөте салып, авызны пешерә-пешерә куе такта чәй эчәбез.

Күрше хатыннары керткәндә, әти йомырка да пешерә. Аны да кабыгы белән. Шуңа күрә инде олыгайгач та, сүз иярә сүз чыкканда: «Мин дөньяда ике ризык пешерә беләм: шуның берсе кабыклы бәрәңге, икенчесе, мин сиңа әйтим, парин, кабыклы йомырка», — дип, шушы сүзләреннән үзенә бер тәм табып сөйләрие.

Аңа карап, гел чикмәнле бәрәңге генә ашап тормыйбыз. Күрше хатыннары безгә еш кына чумар ашы кертәләр. Хәзерге яшьләр беләме икән? А-ай-яй, егетләр, тәмле шулпа ул чумар ашы. Аңа ике-өч кашык катык катып җибәрсәңме! Сөзмә булса, тагын да әйбәт. Телеңне йотышлы шулпа була инде. Газетаның үз хәбәрчесе булып эшләгән елларымда бер зур түрәдән интервью алдым.

— Сез инде бик күп илләрдә булдыгыз. Нинди генә затлы ризыкларны татып карамагансыздыр?! Ә инде ул кара вә кызыл уылдыкларны кашыгы белән ашарга мөмкинлегегез бар. Шулай да иң яраткан ризыгыгыз нәрсә? — дип сорадым.

Әлеге түрә — безнең як нефть корольләреннән берсе.

— Әйе, миңа Җир шарының барлык континентларында да кат-кат булырга туры килде, — дип килеште. — Ә иң яраткан ашым минем беләсезме нәрсә? Куе итеп әче катык каткан арыш чумары. Кайларда гына булсам да, шушы ашны сагынып кайтам.

Кочагында утырган матур апаны, әти өчен әлегә иптәш Кәримованы, үзебезгә тәки алып кайттым. Өстенә тастымал ябып, әти өстәлгә үзенең фирменный, чат тоз «чикмәнле бавырсагы»н чыгарып куйган. Керосинка өстендә борыны китек яшел чәйнек кайнап утыра. Әтинең чәе дә әзер.

Әмма мин бусагадан атлап керүгә:

— Әгәренки әни чыгып китсә, бәрәңгене дә ашамыйм. Хәдичә апа кайнар чумар шулпасы кертсә дә, кашык та тыкмыйм, — дип, әтигә кискен ультиматум куйдым. Әнисезлек мине тәмам туйдырды.

— Иптәш Кәримова да чыгып китмәс. Нигә китсен икән? Ризыктан өстен булу берәүне дә бизәми, — дигән булды әти дә.

Без кулларны юып бәрәңге ашарга утырдык.

— Әнием, мин сине бик яратам. Мин сине беркемгә дә бирмим. Беркая да җибәрмим, — дип, өстәл янында әнине тагын бер кочып алдым, чытырдап ябыштым. Аңа да артка чигенергә бер адым хут калмады.

Бераздан ул:

— Онытмадыгызмы соң? — диде.

— Булмыйча! Пакеты белән ташып кына торам, — диде әти.

— Атланмаегыз, ике-өч чи йомыркагыз?

— Барысы да әнә шунда, шкафта.

Әни алдына алъяпкыч ябып алды.

— Керосинкагыз артык төтенли икән. Тәрәзә кашагагызга әнә корым утырган. Су җылытып, чайкап эләрмен.

Аның бу сүзләрен әти дә, мин дә колакларны тырпайтып тыңладык. Бу мин тапкан әнинең бездә калырга ризалык бирүе түгелме соң? Ярабби!

Әти дә:

— Керосинканың фитильләрен күптән караган юк. Кул җитми, искергәннәр. Шуңа төтенли булырлар. Хәзер алыштырып куям мин аны, — диде. Йөзендә шатлык билгесе.

Әни исә, матурым, зур кыюлык белән:

— Алайса, чәй янына мин төче коймак пешереп бирәм, — диде. — Чәй төче коймак белән тәмлерәк.

— Төче коймак! Төче коймак! Ура, мин аны бик яратам, — дип хуплап кул чаптым мин. Әйтерсең моңа кадәр мин чәйне гел төче коймак белән генә эчкәнмен. — Әнием, мин сине барыннан да күбрәк яратам!

Шулай итеп әниле булдым, әтине хатынлы иттем. Алар тиз арада аңлашып, тату гына яшәп киттеләр. Берсеннән котылсаң, яңа проблемалар туа. Үз әниемнең әтисе белән әнисе, Габдрахман бабам белән Мәһруйбикә әбием, болай да туктаганнар иде инде мине урлаудан. Әти аларны прокурорга чакыртып нык өркеткән. Яңа әнием аларның эзен бөтенләй суыту ягында булды, ахры. Кече Кавалдан тагын да ерагаю ниятеннән без Кече Көек авылына күчендек.

— Кече Кавалда әбием, бабам бар, Мәскәүдә — Кәшиф җизнәй белән Мәрьям апам, — дип сөйләшеп утыруларымны әнием бер дә килештерми. Үз әнисе булганын онытсын, үгилекнең эзе дә калмасын дип тырышуы булгандыр инде үги әниемнең.

— Тапкан түгел, баккан кадерле, — дия иде ул. Мине дә үги түгел, тик үз баласы гына итәсе килгәндер.

Минем анда-монда эшем юк. Әниле булган көнне үк мин аңа без яшәгән өйгә каршы гына болыннан күп итеп юа, акбаш, кузгалак җыеп кердем. Мин ятимне кочагына сыендырганы өчен гомер эчендә күп бүләкләр бирдем. Укып чыгып, беренче хезмәт хакымнан бик кыйммәтле Һиндстан йон кофтасы бүләк иттем. Әниле булуның нинди зур бәхет икәнен әнисен бер жуеп, янәдән тапкан бала гына беләдер.

Күп тә узмады, сеңлем Гөлкәй туды. Казан университетын тәмамлагач, математик ире белән Мәскәү янындагы бер ябык шәһәргә җибәрделәр аларны. Шунда яшәп яталар. Мәскәүгә китап чыгарырга барган саен шунда кунак булам. Олы кызым, Гөлнарым, Мәскәүдә укыган чакта, төп «база»быз алар булдылар.

Мөмкин түгел иде

Нәкъ шулай! Никадәр генә боргалансам, сыргалансам да, миңа язучы булмый калу мөмкин түгел иде. Моңа әтинең тырышлыгы һәм мине чорнаган мохитнең тәэсире чиксез булды. Өченче-дүртенче сыйныфларда укып йөрим. Малайлыкның иң тәмле чоры бу. Әлегә өйдә дә эшләрнең авырларын кушмыйлар. Борыныңа да кызлар исе керә башламаган. Кызлар исе керсә, беттем, диген инде. Төнге йокыларыңның тәме калмый. Синең күзеңә авылның гына түгел, ә дөньяның бердәнбер матурыдай күренгән берәр яшьтәшеңне, әйтик, күрше кызын ук үземә карата алырмынмы дип, йокыдан гына түгел, ашаудан каласың, валлаһи.

Әйе, әлегә малайлыкның иң тәмле чорын кичерәм, тәмам онытылып уйнау белән мәшгуль. Билдә — агач кылыч, кулда — калкан. Сугыш уеннары уйныйбыз. Чөнки экраннарга «Тahир һәм Зөһрә», «Чапаев» кинолары чыкты. Беренчесендә чаж да чож кылыч белән чабышалар, икенчесендә Анька-пулеметчица «максимка» пулеметыннан сиптерә. Шушы киноларны клубта көнаралаш күрсәтеп торалар. Ә-ә, нәкъ менә малайлар киносының өченчесе дә бар — «Мы из Кронштадта». Совет моряклларының тиңдәшсез батырлыгы турында. Аны да үлеп яратып карыйбыз. Һәр өчесенең дә эчтәлеген яттан беләбез. Мин, көн саен әтинең эш бүлмәсенә кереп, кинога акча сорыйм. Кинога егерме тиен алу өчен, мин аңа дүрт куплетлык шигырь язып керергә тиеш.

— Кая, шигыреңне күрсәт, — ди ул.

Ә мин әле өлгермәдем.

— Нәрсә турында языйм соң?

Әти үзенә каршы өстәлдә үк утырган җаваплы секретаре шагыйрь Самат абый Шакирдан:

— Бу яфрак колак нәрсә турында язсын? — дип киңәш сорый.

— Әнә сыерчыклар килгән. Оя сайлыйлар. Яз шул турыда, — ди Самат абый.

Һи-и, дүрт куплетлык шигырь чыгару минем өчен чүп ул. Шакмакка-такмакка корылган булса да, биш минутта гатувый. Әти, давай кинога егерме тиенеңне!

— Бармы соң бу тишек борында бераз өмет? — дип сорый әти Самат абыйдан.

— Булыр төсле. Бу темага шома гына шигырь чыгару өчен минем үземә кимендә ике көн кирәк.

Әмма чын сәнгать кешеләре генә кичерә торган иҗади кризис периодлары миндә ул чакларда ук булып куя иде. «Әнә бозау. Кahәр төшкере, сыер җилемен сөртергә дигән тастымалны чәйнәп тора. Шуның турында яз!» — дигән заказ да бирәләр. Без редакция бинасында ук яшибез. Бер-берсенә кушып салган җиде кисәктән торган озын йорт ул. Шул бинаның ике кисәген без билибез. Әйләнәсен биек койма белән корып алган ишегалдыбыз бик зур. Редакция аты белән бергә, сыер, тана, бозау, аңгыра казлар, юып кына алган баскычыңны шундук пычратып торучы тавык холерасы асрыйбыз. Әти холера дип атый аларны. Аяк астына туры килгәннәрен тибеп тә очыргалый. Болар өстенә ике-өч айга бер итәк көчекләр табып торучы Сарбай исемле ана этебез бар. Галәмәт усал!

Алпут утары түгел бит ул! Дәүләт учреждениесе! Канса да канис, редакция бу! Районның иң баш тәрбия үзәге! Ярамый безгә бөтен ишегалдын биләп, мал үрчетеп ятарга, дип, әти еш кына сукранып та ала. Ул чорларда партия җитәкчеләренә сыер асрарга ярамый иде. Аның өстеннән жалу да язгалыйлар, сыер-бозау асрый, тавыклар тота, дип. Дүрт бала да, әти-әни үзләре, әнинең әнисе Шәрифә әбием дә безнең белән. Җиде кашык уйнатабыз өстәлдә. Мал тотмасаң, нәрсә ашарга соң?

Бозау әнинең тастымалын чәйнәп торганда, шигырь язу кайгысымы? Мин бозау авызыннан тастымалның калган өлешен йолкып өлгерергә ашыгам. Әтинең законнары кырыс. Егерме тиенне аннан җиңел генә ала алмыйсың. Иҗади кризис кичергәнлектән, башыңда шигырь тумаса, аның янына Тукайның берәр шигырен ятлап керергә тиешсең. Ул үзе бу бөек шагыйребезнең йөзләрчә шигырен яттан белә иде. «Шүрәле»не сөйләргә ярата иде. «Шүрәле»нең татарчасын, русчасын, алманчасын мин дә яттан беләм. Русчасын, татарчасын кызларым да, оныкларым да беләләр. Дөнья әдәбиятының шедевры «Шүрәле»не кытай теленә тәрҗемә иттерергә җае чыгып тора. Кытайның Шаньдун каласы университетында минем хайваннар, кош-кортлар дөньясына кагылышлы хикәяләр җыентыгым чыккан. Шул университетның «Институт Пушкинского языка» кафедрасы, ирле-хатынлы ике профессор тәрҗемә иткәннәр. Шушы араларда гына миңа Мәскәүгә килеп чыккан кытай язучысы шалтыратты. Китабымны да алып килгән икән. Кунакка дәштем, киләм, диде. Безнең Лениногорскида ике кытай гаиләсе яши. Якыннан аралашабыз, кунакка йөрешәбез. Кытай, Шаньдун университеты белән эш йөрткәндә, алар миңа бик булышалар. Чөнки мин конверт тышына кириллица белән язган адресны кытай почтальонкалары танымый бит. Адресны кытайча язарга туры килә. Хат алай тизрәк йөри. Телефон аша аралашу мөмкинлеге дә бар. Әмма вакыт аермасы ипсез. Бездә төнге ике булса, аларда иртәнге җиде. Менә шундый чакларны үзенең кытай фамилиясен русчага Мунин дип төзәткән кытай дустым ярдәмгә килә.

Минем үземә бөек Тукаебыз белән җитәрлек дәрәҗәдә горурлана белмибез кебек тоела. Бәлкем, аның үзен һәм иҗатын артык яраткангадыр? Әмма Тукай дөньяда үзе дә бер генә, «Шүрәле»се дә! Белгәнемчә, Шүрәле образы дөньяда башка бер генә әдәбиятта да юк шикелле. Ә дөнья дигәнебез киң бит...

Әтидән мирас булып калган матур традицияне онытмадык. Оныкларым электрон автоматлар белән уйнарга йә «Макдоналдс»ка барырга акча сорый башласалар, башта Габдулла Тукай агаларының берәр шигырен сөйләп күрсәтергә тиешләр. Рус мәктәбендә укысалар да, алар моны кыен эшкә санамыйлар. Ә менә Бөгелмәнең татар-төрек лицеен тәмамлап килүче олы оныгым Арыслан язучы булыр, ахры. Ул бүген дүрт телдә сөйләшә, татар һәм рус телләрендә искитмәле матур шигырьләр яза. Мин аны әлегә бераз «авызлыклап» торам.

— Улым, башта укуыңны яхшыга тәмамла әле. Чыгарылыш сыйныфы бит. Шигырьләргә аннары тотынырсың, өлгерерсең, — дим.

Башта ак шигырь белән мавыкты. Хәзер чыкылдап торган эчке ритмлы, музыкаль агышлы рифмаларга күчте. Мин түгел, лицейның рус һәм татар теле укытучылары мактый аның шигырьләрен.

...Язучы булып китми һич мөмкин түгел иде шул миңа. Безгә еш кына кунакка Мөхәммәт Садри, Гали Хуҗи, бар язучыларның котын алып торган бик усал тәнкыйтьче, ул чорларда «Кызыл Татарстан» газетасының әдәбият бүлеге мөдире Фәтхи Балыкчы кайталар. Ул безнең күрше, партиянең почетлы ветераны, Кышкы Сарайны алуда катнашкан Садыйк абыйның кияве. Соңыннан озак еллар «Социалистик Татарстан» газетасының баш мөхәррире булган Рәис абый Сабиров — күрше Мәмдәлнеке. Ләкин ул Мәмдәлдән алда башта безгә кайта. Кара айгырны җигеп, мин аны Биектау станциясенә барып каршы алам.

Безгә күрше генә «Кызыл юл» районы газетасын язучы Рафаил абый Төхфәтуллин чыгара. Ул елларда район газеталары өчен «Халыкара күзәтү»не Казаннан радио аша бирәләрие. Радиодан алучы булып бер кызый эшли. Гыйлеме дә, кругозоры да бик чамалы. Әйтик, чираттагы күзәтүдә радиодан «Халыкара империализмның башында Америка президенты Дуайт Эйзенхауэр» дип бирәләр. Радиодан алучы кыз шушы исемне хатасыз гына яза аламы инде? Моңарчы аңа таныш, ишеткәне булган исемме? Әтинең исә: «Эчке этләр министры Л.П.Берия», — дип язып авызы пешкәне булды. Чак исән калды. Шуңа күрә ул миңа: «Кызыл Юл» районына шалтырат. Рафаил абыеңнан белеш, «Эйзенхауэр» ничек языла икән? Хата китә күрмәсен. Рафаил абыең язучы ул. Ипләп кенә сөйләш», — ди. «Кызыл юл» районына көндезләрен бик теләп тә шалтырата торган түгел. Линиягә чыгып булмый, район үзәге белән миннән башка да сөйләшүчеләрнең чуты юк. Барлы-юклы бер линия булгандыр инде ул. «Әллү! Әллү!»не тамагың ярылганчы кычкырсаң да, сине линиягә кертмиләр. Кичке уннар тулгач кына сөйләшергә мөмкинлек туа. Рафаил абыйдан «Эйзенхауэр» сүзенең ничек дөрес язылышын аныклыйм. Бу бик матур кешегә, олы язучыга карата ихтирамым, мәхәббәтем шул чакта ук туды.

Мин институт тәмамлап Лениногорскига эшкә килгәч, Рафаил абый, гаиләсе белән Әлмәткә күченде. Чын мәгънәсендә дуслыгыбыз шунда башланды. Ул минем ике китабымны җәмәгатьчелек тәртибендә редакцияләп бирде, Язучылар берлегенә кергәндә дә тәкъдимнамәне беренчеләрдән булып ул язды. Минем әлеге берлеккә керүем үзенә күрә берәгәйле комедия булды. Ул турыда аерым бүлек язарга ниятлим.

Рафаил абыйның иҗатына багышлап үзем дә ике-өч зур-зур мәкалә бастырдым. Искитмәле матур кеше иде ул. Сугыштан нык имгәнеп, инвалид булып кайткан. Билендә һәрчак корсет йөртте.

— Башымда ат дагасы хәтле мина кыйпылчыгы утыра бит, энем. Башымның бер генә минут та диңгез булып шауламаган чагы юк, — дип сөйләрие.

Язучылар берлегенең Әлмәт бүлегенә җыелышка баргач, мин кунарга аларга керәм. Әтием кебек якын кеше бит. Елга бер уздырыла торган әдәби киңәшмә — ел йомгагына баргач, мин Рафаил абыйны үзебезнең Дөбъязга кунакка алып кайтам. Бик теләп кайта. Җитмәсә, анда аның яшьлек дусты Әгъзам абый Җәләлиев бар. Мәктәп директоры. Әгъзам абый — татар театры тарихына кагылышлы бик күп мәкаләләр язып торган зат. Туфан дустым Миңнуллин да «Әлдермештән Әлмәндәр»енә исемне Әгъзам абый күрше Әлдермеш мәктәбендә директор булып торган чакны, аларда кунакта булганда алган. Мин Казаннан алып кайткан кунакка барыннан да бигрәк әтием сөенә иде...

Мин бишенче класстан әтидә корректор булып эшли башладым. Җәмәгать тәртибендә, әлбәттә.

— Улым, бу санны бик җентекләп укып чык. Бер генә хата да кала күрмәсен. Мин райкомга менеп киттем әле, — дип, алдыма буяу исләре аңкып торган, үзе редактор булган «Колхозчы» газетасын китереп сала.

Әзерлисе дәресемне бер читкә куеп карап чыгам. Газетада бирелгән материалларга кандала булып ябышам. Әтинең җаваплы сәркәтибе Самат абый да укыган, штатлы корректорлары да бар. Әмма алардан соң да берәр хәреф хатасы табу минем өчен дәрәҗә! Табам да!

Ә менә алтынчы класстан мин үземнең әтидә конюх, ягъни күнних, ат караучы булып тордым. Штатта, хезмәт хакы алып. Район авылларына чыгып газетага материаллар тупларга, редакциянең башка хуҗалык эшләрен башкарырга дип, аңа ат тоту каралган. Әти атларның бер дигәннәрен, ягъни райкомның беренче секретаре бахбайларыннан гына калышканнарын тотты. Безнең гаилә атка мөкиббән иде. Әти айгырлар ярата. Арада бик холыксызлары да очрый. Бер айгырыбыз уртанчы энемнең сул иңбашын умырды. Икенче бер тиле айгырыбыз кече энемне тибеп очырды. Җене кагылудан куркып, энемне бер әбигә өшкертергә үзем алып йөрдем. Әтигә, коммунист башы белән, өшкерүчегә барырга ярамый. Ишетеп алсалар, шундук райком бюросына чакырачаклар. Анда күп сөйләшеп тормыйлар.

— Клади партбилет на стол! — дип кенә сөйләшәләр.

Әти дә, без малайлар да айгырлар яратабыз. Әни җәй көнендә, безне дә төяп, Ташлы Кавалга кунакка кайта. Аңа кара тарантаска җигелгән алмачуар бия булсын. Янында колыны да йөгереп торсын.

Әтинең штатный күннихы — мин. Күннихның хезмәт хакы ике йөз егерме сум. Әмма шушы хезмәт хакын бик азсынып, аңа күннихлыкка берәү дә атлыгып тормый. Ул елларда бер капчык арыш оны

алтмыш сумнар тора иде булса кирәк. Күннихлыкка егетләр алгалый ул. Тегеләре бераз гына эшлиләр дә китәләр. «Сезнең бу хезмәт хакына дүрт капчык арыш оны алып була бит! Нигә китәсез, дивана башлар!» — дип, әти аларны орыша.

Атың булгач, аны ашатырга-эчертергә, астын чистартып торырга да кирәк шул. Бер генә атна чистартма — тирес бөтен абзарыңны баса.

Әтинең башында — каракүл күн бүрек. Өстендә — кыршылганрак булса да күн пәлтә. Аягында — ак фетр. Ул елларны район җитәкчеләре шундый мода белән киенә иде. Нигә ул гына калышып торсын әле?! Әмма бу киемнәр белән ат янына килә дә, атны җигә дә алмый бит инде ул. Атны рәхәтләнеп мин җигәм. Камыт бавын тартырга гына көчем җитми. Аны әти белән икәүләп тарттырабыз. Әти каяндыр кайтса, аны каршы алып, тугарырга кирәк. Өйдән очып чыгып тугарам мин аны. Ат бит ул! Иртән мәктәпкә киткәнче үк, иртәрәк торып, салам турап, кайнар башак болгатып бирәм. Шундый чакта биябезнең тәкатьсезләнүен күрсәң, әй! Гомер буе ач торган диярсең. «Кая тыгыласың! Суынсын бераз! Авызыңны пешерәсең бит!» — дип, биямнең йә айгырның танавына төртеп-төртеп алам. Яратып инде. Унөч яшьлек малай бит мин ул чакта...

Әйе, унынчыны тәмамлаганчы, әтиемдә күнних булып тордым. Штатта. Уч тутырып акчасын алып. Аттестатлы булгач, университетка барып карадым. Геолог булырга иде исәп. Рус теленнән сочинениене өчкә генә яздым. Конкурс көчле иде, калган имтиханнарны биреп тә тормадым. Барыбер уза алмам дидем. «Шалтырап», үз-үземнән оялып, Дөбъязга кайтып төштем. Мин имтиханнар тотып йөргән арада, минем «акция»ләр нык үскән. Минем укырга керә алмавыма әтидән дә болайрак сөенүче булдымы икән?! «Улым, булганым, Ислейтар лесхозына барып, редакциягә кыш чыгарлык утын хәзерләргә делянка сөйләшеп кайт. Йөз егерме-йөз утыз кубометрларсыз да кышлый алмабыз. Син кайтканны көттем. Казаннан илле рулон кәгазь алып кайтасы бар. Газета чыгарырга кәгазебез тагын ике-өч санлык кына калды. Илләт болыныннан биш гектар печәнлек сөйләштем. Киләсе атнада, редакция кызларын да җыеп барып, шул печәнне чабып кайтырсыз. Юкса кышын ни ашатырбыз», — дип тезә генә минем алга бурычларны.

Университетка керергә маташып йөргәндә, Арча ягыннан килгән бер бик чибәр кызга күзем төште. Ул да керә алмады. Имтихан тота алмау хурлык бит ул. Оятыңнан җир тишегенә керердәй буласың. Мондый кыен хәлдә безнең ул чибәркәй белән сүз алышу, аңлашу булмады. Бер-беребезне ошатуыбызны күзләрдән аңладык. Адресын гына аласы булган икән лә. Аңа да кыюлыгым җитмәде. Бәлки, алдагы сезонда очрашмый калмабыз әле. Аңа хәтле торса. Берәрсенең җылы кочагына чуммаса. Киләсе елда укырга керә алмасам да, барыбер эзләп табармын әле мин аны.

Бу кызга күзем төшүнең нәтиҗәсе шул булды: мин Дөбъязга маймыл сурәте төшерелгән галстук тагып кайттым. Дөбъяз халкы бик нәзберек, зәвыклы публика, андый купшылыкны бер дә килештерми.

— Барый малае укырга керә алмаган. Аны гына көтеп торалар дип барган булгандыр инде. Тот капчыгыңны! Ә муенына стиляга булып муенчак тагып кайткан. Күрсәң, тәгәрәп китешле, — дип көлүчеләр дә булды.

Исем китте инде бик! Минем күңел түренә хәзер теге Арча ягы кызы кереп оялады. Әллә шул Арча ягына барып чыгып, бер айкап кайтыйммы дип тә уйланам. Барсам, әлбәттә, табам инде. Укырга керә алмавым башка сукты.

Әти исә:

— Улым, бу матур галстукны каян кулга төшердең соң? Колхоз базарыннан алдыңмы, әллә Бауман урамында сәүдә итә торган кытайларданмы? Казанга барганда тагарга миңа да биреп торырсың, — дигән булды.

Әтинең тел төбен әлегә аңлап бетермим, әмма мине шулай җумалавының сере булырга тиеш. Мин дә, бик тирәнгә кереп тормыйча, мәсьәләне кабыргасы белән куйдым:

— Унны бетергән башым, шундый галстук таккан муеным белән мин синдә бер көн дә күнних булып тормыйм. Оялам. Бөтен Дөбъяз көлә миннән галстуклы күнних дип, — дип әйтеп салдым.

Көлмәслек тә түгел. Ул галстукны мин муеннан төшермим генә түгел, йоклаганда салырга да онытам. Арбага ике буш мичкә салып, Дөбъяз урамына җәйгән калтыр-колтыр шоссе юлдан дөбер-шатыр суга төшеп китәм. Минем муендагы төсле фасонлы галстукларны ул заманнарда бик танылган стилягалар гына тага иде.

Әти тиз төшенде минем халәтне.

— Улым, мин сине бүгеннән үк үземә завхоз итеп алам. Тик син эшеңдә генә кал, — диде.

Редакция штатында завхоз урыны каралмаган. Вазифасы шул ук инде, ат карау. Әмма исеме — завхоз! Күнних түгел инде. Бигрәк тә безнең Дөбъяз аурасы, менталитеты өчен. Завхоз — дәрәҗәле эш урыны!

Кырт итеп өс-башны карадык. Егет кеше бит мин хәзер. Кулга «Победа» сәгате алып тактык.

Шул сәгатьне беренче такканда, әни:

— Улым, сәгатеңне бик саклап тага күр. Беренче таккан сәгатең нинди булса, хатының да шундый булыр, — дип кисәтте.

Начар хатынга юлыкмагаем дип, ул сәгатьне озак еллар бик саклап тактым...

Әти дә укытучы, әни дә укытучы. Ә нигә миңа да укытучы булмаска?! Укытучы — авыл җирендә иң кадерле кешеләрнең берсе. Җәйге ялы гына да ни тора! Өч ай бит. Укытучы булырга хәл иттем. Документларымны Болак буендагы педагогия институтына илтеп тапшырдым. Тарих факультетына. Беренче имтихан рус теленнән, язмадан. Шуның белән кисәләр бит инде абитуриентларны. Ә мин рус теленнән курыкмыйм. Чөнки «Колхозчы» газетасы «Колхозник» исеме белән русча да чыга. Аның да штаттан тыш корректоры мин. Нимесчәне дә яхшы беләм. Аны безгә Казаннан кайтып-килеп йөргән Гайшә апа укытканые. Бик төпле белем бирде ул безгә. Һенрих Һейне, Шиллер теленә мәхәббәт тәрбияләде. Алманча мин бүген дә яхшы беләм. Алар белән тәрҗемәчесез сөйләшәм. Бер елны Ромашкино нефть мәйданына Алманиядән кунаклар килгәние. Шунда бер төркемгә тәрҗемәче булып йөрдем. Укытучыбыз Гайшә апага рәхмәт! Аның уңганлыгы нәтиҗәсе.

Теге чакта, университетка имтихан биргәндә, икебез дә провалга очраган бик чибәр Арча кызы һаман да күңелдә әле минем. Ошаганые ул миңа. Берочтан аны да очратмаммы дип йөрим.

Актлар залына йөзләп абитуриентны кертеп тутырдылар. Рус теленнән сочинение язабыз. Артыма борылып карасам, миннән өч-дүрт парта гына артта Арча кызы утыра. Менә сиңа мә! Телепатия! Ул безләп карамаса, мин дә борылмаган булыр идем. Сәламләгәндәй итеп авыз чите белән генә елмаеп алды. Үзем сочинение язам, Тургеневның Базаровын мактыйм, үзем имтиханнан чыгу белән Арча кызына җайлап кына сүз кату планын корам. Планлы эш таркалмас, ди бит китап. Бәлкем, кулына иң кыйммәтле туңдырма алып тоттырырмын, бәлкем, кинога кереп чыгарга тәкъдим ясармын. Имтихан арасында кайтып-килеп йөрергә исәбе булса, Арча поездына озатып куярмын. Мондый чибәрләргә вакытыңны сарыф итсәң дә, кесә расхуты чыгарсаң да стоит! Шундый ныклы вә төпле уйлар белән коридорга чыксам, Арча кызы озын буйлы, киң күкрәкле бер курсант кочагында. Алтын алка колакта, чибәр кызлар кочакта! Ачу килде, әлбәттә. Килмәскә соң! Нинди якты планнар корганыем бит.

— Әй-й-й! Казан хәтле Казанда Арча кызыннан чибәррәкләр дә табылыр әле, — дип юаттым үземне. Юатмыйча! Утырып еламам ич инде.

Чыннан да шулай булып чыкты. Кызларның иң чибәрләрен генә сайлап йөрдем мин, валлаһи. Кайберләренең фоторәсемнәрен әле дә саклыйм. Әмма шулар арасында иң чибәре минем гомерлек хәләлем — Мәдинәм-гөлкәем. Вәләкин шунысы да бар, шушы яшькә җитеп, аның миңа өздереп кенә: «Яратам мин син холыксызны», — дип әйткәне юк әле.

Мишәр әйтмешли, ошбу «йөрәк маем» да җиңел генә төшмәде минем кулга.

Йөргән, сөйгән кызыңны, гомерлек хәләлең булырдай ярыңны көндәшләрең кулыннан борын җимереп, кан коеп та алмагач, аның ни тәме дә, ни яме! Шулай булмыйча! Башкалар башкача уйласыннар, пажалыста. Үз фикерләрендә калсыннар. Әмма Мәдинәм-гөлкәемне, «Мин тырышып хатлар язам, синең исеңдә дә югымны», ярты институт егетләре белән сугышып бетеп, үземнеке иттем. Үкенмим дип әйтергә була төсле. Көнчелек галәмәте дә миндә колакларымнан гына түгел, түбәмнән ашкан. Мөхтәрәм Пушкин әфәнде дә Дантес белән хатыны Натали аркасында атышкан. Гадәти булмаган физик көчен күрсәтү өчен цирклларда да чыгыш ясаган бөек язучы Куприн әфәнде, аш өстәле артында матур гына сөйләшеп утырганда хатыны һәм китапларының редакторы Даманскаяга берәр автор күбрәк игътибар күрсәтсә, кулына ике чәнечке алып, алардан штопор ясап, өстәлгә ыртыта торган булган. Кешелек сыйфатларыбыз арасында байтак кына тискәре якларыбыз булганга, бер сүз белән — Язучы дип атамадылар микән безне, әй?!

Кара кашлы нечкә билкәем!

Инде бер башлагач дигәндәй, калганын да әйтеп бетерим. Комсомол юлламасы белән бик еракка, чирәм җирләргә, Казакъстан далаларына поездда барганда күзем төште минем аңа. Күңел күзе күрмәсә, маңгайдагы күз ботак тишеге генә шул. Товарищеская, 5 урамындагы тулай торагыбызда, ике еллар бергә яшәп, моңарчы мин аны ничек күрмәгәнмендер? Без яшәгән тулай торак Бөек Ватан сугышы елларында хәрби госпиталь булган. Анда биш йөзләп студент яшибез. Аларның берсе укуга чыгып кына китә, икенчеләре кайта. Каян барын да белеп, күреп, танып бетерәсең? Әмма минем күзем төшкән кара каш, берараны күзем төшкән Арча чибәре генә түгел.

Халык телендә «Телячий вагоннар» дип йөртелгән, авыр йөкләр, аяклы эре маллар төяп йөртү өчен махсус ясалган вагоннарда зур бер эшелон булып барабыз. «Телячий» дигәч тә, йөз чыерыр җиребез юк, вагоннар бик чиста. Әле кичәле-бүгенле генә дигәндәй, пилорамнан гына чыккан хуш исле, сап-сары сагызлары тамып торган сороковка нарат-чыршы такталардан, һәр вагонда ашау-эчү өчен өстәлләр, йоклар өчен ипле тапчаннар бәреп чыкканнар. Хөкүмәт ул ягын да караган, соңыннан бу вагоннарга без барып урган, суктырган, җилгәргән чирәм җирләр бодаен төяп җибәрәчәкләр икән.

Бездән бер вагон гына алда инфак кызлары баралар. Алар артыннан без — истфаклар, литфаклар, хим-биофаклар. Омск, Томск калаларын артта калдырып иксез-чиксез Кулунда далаларына чыккач, безнең состав тизлеген бөтенләй әкренәйтте. Теләсә, аны ташбака да узып китә ала. Без, истфак

егетләре, поезд барган хутка үз вагоннарыбыздан сикереп төшәбез дә, инфак кызлары барган вагонга үрмәлибез.

Инфак кызлары үзләренә күрә түгел, галәмәт фыртлар. Күз кысып, каш сикертеп, сүз катармын димә. Чөнки күбесе Казан кызлары, бай, төпле, дәрәҗәле гаиләләрдән. Дөрес, чибәрлекләре дә чиктән ашкан. Үзебезнең бүлмәдән дүртенче курста укыган бер физмат егете Рифкать, күрше генә бүлмәдә торган бер инфак кызы Валяга гашыйк булып, тәмам акылдан шашып, үләм, асылынам дип йөрде. Шаяртып кына:

Любовь для Вали забава,
А для Рифката страдание, —

дип җырлаштыра идек.

Гомумән алганда, инфак кызлары үзебезнең институт егетләрен кешегә дә санамыйлар. Аларга тик авиация институты яисә Казан авиация училищесы курсантлары гына булсын. Сәбәбе бик гади: КАИ тәмамлаган егеткә чыкса, инженер хатыны гына булачак. Укуын тәмамлагач та, Казанда йә башка зур шәһәрдә яшәячәк. Курсантка чыкса, офицер, капитан-майор, хәтта генерал хатыны булып куюы да бик ихтимал.

Ә инде чәчен чәчкә пединститут тәмамлаган берәр тарихчы, математик, химик, географ белән бәйләсә, нинди перспектива көтә? Аны белү өчен, биш сумыңны тотып, багучы чегән карчыгы каршына да барып торасы юк. Болай да билгеле. Ике-өч чит тел белгән ул бичаракайны иренә ияреп республиканың берәр глубинкасына китү бәхете көтә. Язын-көзен аягында тирән кунычлы резин итек. Чупыр да чупыр рәхәтләнеп из авыл сазын. Планканы иң югары өлгесенә куйганда да, бу чибәркәйне мәктәп завучы йә директоры хатыны карьерасы көтә. Иртән самый тәмле йокыңны бүлеп, сыер саумый да, көтү кумый да хәлең юк. Гаиләң ишәеп киткәч, нарасыйларыңа сөтне авыл җирендә тагын каян аласың? Әгәр үзең сөтлебикә асрамасаң. Аларга үпкәләп тә булмый, инфак кызларының башында корыч логика!

Шунлыктандыр сорамый-нитми генә вагоннарына менеп утырганга, аякларны асылындырып сәгатьләр буе барганга да инфак кызлары безгә берни дә әйтмиләр. Алар өчен без тешләми торган чебеннәр. Алар үз эшләре белән мәшгуль. Бизәнгәне алдына көзгесен куеп бизәнә, чәчен тараганы тарый бирә. Тапчан өстенә сузылып ятып, дөньяга гамьсез карап, китап укып баручылары да бар. Вак кына йомышлары төшеп, ара-тирә безгә дә сүз каткалыйлар. Ләкин... тиешле интервал саклап. Әйтәм бит, прәме үләрсең аларның кыланышларыннан! Араларыннан кайберләре үзләрен бүгеннән үк Генштаб офицерлары хатыннары итеп хис итәләрме инде?

Менә шушы берсеннән-берсе сылу инфак кызлары арасында бер кара кашы, нечкә биле аеруча шәп. Әллә миңа гына шулай тоеламы? Анысын аның кем тикшереп торган? Менә шул чибәркәйгә күзем төште бит, әй. Белмим, үземә каратып булырмы? Нигә карамас икән? Болай үзем дә кеше карамаслык, кызлар күзе төшмәслек егет түгел шикелле. Гарип-гораба да түгел, агып-тамып торган җирем дә юк. Алай гынамы диген. Өстемдә өр-яңа шакмаклы күлмәк-ковбойка. Өр-яңа зәңгәр комбинезон. Чәчне дә, юлга чыгар алдыннан гына, шул чорларда иң модный саналган «Канадка» стилендә алдырганыем. Сизәм, вагонда баручы инфак кызлары безнең тарафларга да барыбер ара-тирә күз аткалыйлар. Әмма минем күз төшкән әлеге Кара каш, нечкә бил генә тапчаны өстенә сузылган да инглиз телендә ниндидер бер роман укып бара. Ул китапларны кышын укып туймагандырмы?

Әнә шул тапчан өстендә китап укып барган Кара кашны бик ошатуымны минем белән рәттән утырып барган ахирәт дустым, бик ышанычлы егет, Сергач мишәре Равилгә дә әйттем.

— Сиздем инде, сиздем. Иртән тору белән мине колагымнан шушы вагонга өстерисең бит, — ди.

— Сизсәң, менә шул. Нишлим икән?

— Сүз кать, атәм сиңа, сүз кать! — ди ул, мишәрчә тәвәккәллек белән.

— Андый батырлыгым булса, синнән киңәш сорап торыр идемме? Кыюлыгым да җитми.

— Записка я-аз! — ди Сергач мишәрләречә иҗекне сузып. — Үз күз алдыңда илтеп поручать итә-ә-әм.

Анысы да булмый миннән. Андый чакта аның кирәкле сүзләре дә күңелгә килми бит. Минем башта әллә нинди Наполеон планнары туып куя. Әмма шуларның берсен генә тормышка ашырырга да кыюлыгым җитми.

Безнең эшелонның хәрәкәт графигын махсус шулай төзегәннәр, ахры. Без һәр кичне берәр зур шәһәр вокзалында туктыйбыз. Аннары, автобусларга утыртып, шәһәр читендәгерәк берәр хәрби гарнизон ашханәсенә кайнар аш ашарга алып китәләр. Беренче тапкыр Свердловскида туктап бик яхшы ашаттылар. Омскида да ашадык. Ә Томскида ашханәдә кызларыбызны солдатлар сырып алдылар. Ул чорларда әле армиядә өчәр-дүртәр ел хезмәт итәләр иде. Солдат егетләр барысы да парадка чыгарга хәзерләнгәннәрме диярсең. Барысы да өр-яңа кием-салымнардан. Аларга берни кирәкми, соңыннан хатлар язарга кызларыбыздан адресларын гына сорыйлар. Үзләре исә һәр кызыбызга, күтәрә алганча

пакетларга төреп, банка-банка тушенкалар, сгущенкалар өләштеләр. Офицерлары да шунда ук. Соңыннан кызларыбызны автобусларга кадәр озатып куйдылар.

Икенче көн иртән без янәдән инфак кызлары барган вагонга сикердек. Ниһаять, әлеге чибәркәйнең дә безгә гозере төште бит, әй. Равил каршына килеп, бер сгущенканы ачып бирүен сорады.

Ахирәтем Равил бик толковый егет, миңа таба ымлады.

— Әнә минем дустым Альберт бик оста ача банкаларны, — диде.

Әлеге Кара каш минем янга күчте. Колакка ятышлы матур тавыш белән:

— Үзебез белән пычак алырга да онытканбыз. Менә шушы банканы ачып кына бирмәссезме? — диде.

Бу минутта мин кирәксә амбразура капларга әзер идем. Куертылган сөт банкасы капкачын бер каеруда ачып ташладым.

— Кара, әй, кайчаннан бирле бер поездда барабыз, исемегез ничек була соң? — дип сорарга да өлгердем.

— Мәдинә минем исемем, — диде ул, чак кына елмая төшеп.

— Исемегез үзегез кебек матур икән. Нәкъ җырдагыча. Мәдинә-гөлкәем буласыз инде алайса, — дидем.

Шунда безнең күзләр күзгә-күз очраштылар. Белмим, нинди, кайсы сизү органым беләндер бу чибәркәйнең мине ошатып каравын сиздем. Тойдым. Аны аңлатуы кыен. Әмма сизәсең. Ләкин аның бу серле карашы минем йөрәккә ялкынны өсти генә төште. Шушы караштан соң аңа артык игътибарлы булсам да килештермәс дим. Игътибарсызрак булсам, мин бит сиңа ничек мәгънәле итеп карадым, ә син шуны аңламадың дияр төсле. Ә йөрәк яна, шунда үзен тотып бер сөйләшер идең дә, урыны юк. Тукта, ашыкма, ашыккан ашка пешкән, дип тынычландырам үземне. Ул чирәм җирләргә барып кына җитик. Шунда бер аулак җирме, почмакмы табып:

— Мәдинәм-гөлкәем, сине беренче күрүемдә үк баш түбәмнән гашыйк булдым. Хәзер менә мәңге сүнмәс мәхәббәт утында янам! — диярмен.

Нүжәли аңламас икән? Әйтәм бит, үзем дә бит кызлар күзе төшмәслек егет түгел. «Канадка» стилендә алдырган чәчемне гел уңай якка тарап, брионлап кына торам.

Вак яңгыр сибәләгән июль иртәсендә безне Павлодарга китереп төшерделәр. Анда тагын күрешеп-сөйләшеп булмады. Безләрне, өсләре брезентлар белән ябык йөк машиналарына төяп, Павлодардан биш йөз чакрымнар ераклыктагы Биш Карагай районына алып киттеләр. Анда да күрешеп булмады. Биш Карагай районына җибәрелгән студентларны факультетлап-факультетлап төрле җәйләүләргә тараткannар. Чөнки без килгән «1 Май» совхозының үзенең генә дә уналты мең гектар чәчкән бодае бар. Урып бетерешле булмады.

Уракка төшәргә әле иртәрәк. Бодай ямь-яшел утыра. Аның өлгергәнен тагын ике-өч атналар көтәргә туры киләчәк, диләр.

Без бит акча эшләргә килгән егетләр. Эш бирегез, дидек. Литфак, татфак, биофак кызларын бер җәйләүгә җыеп, сарык йоны алырга билгеләделәр. Кызларның күбесе авыл җиреннән. Безнең татар кызларының белмәгән эшләре бармы соң аларның? Самолет ангары кебек иркен ындыр табагына без меринос сарыкларын ташып торабыз. Кызларыбыз, нәкъ авыл абыстайларынча:

— Нишли? Ни дип кабалана? Чыда! Чыда! — дип тынычландыра-тынычландыра, җырлар да көйләп, аларны кырка да башладылар.

Алай гынамы?! Дөньяда иң югары сыйфатлы әлеге меринос сарыклар йонынnан алар үзләренә матур башлыклар, шарфлар, хәтта джемпер-кофталар да бәйләргә өлгерделәр.

Безне, истфак егетләреннән егермеләп студентны, бер машинага төяп, байтак кына ара алып бардылар да шыр дала уртасында төшерделәр.

— Менә шушында кое, аларча кодык казырга кирәк! — диделәр.

Казып чыксак, акчасын да ярыйсы гына алачакбыз икән.

— Булдырасызмы? — диделәр.

— Булдырмаска! — дидек. Әйтерсең моңа чаклы без гомер буена кое казып йөргән осталар.

Бу тарафларда «1 Май» совхозының ун мең башлап сарыгы көтүли. Кое суы, төче су шул сарыкларны сугарырга кирәк.

Әйләнә-тирә далада иң тирән җире күкрәк авызына да җитмәгән, үзләре берсеннән-берсе зур күлләр чутсыз, санап бетергесез. Әмма алар барысы да тозлылар. Сарыкларга суны әлегә машина белән ташып эчертәләр.

Коены казырга алынуын алдык. Әмма рәтен-җаен беребез дә белми. Беренче көнне үк шактый гына тирән чокыр казып ташладык. Совхоз җитәкчеләре, әллә ни тирән казырга туры килмәс, төче су күп булса өч-дүрт метрлардан чыгар, дигәннәрие. Болай булганда без коены ике-өч көннән казып та өлгертәчәкбез. Ә икенче көн иртән торып килсәк, бар казыганыбыз гөрселдәп ишелгән. Комлык бит. Ул көнне ишелгән комны өскә бәрдек. Иртәгесен килешебезгә тагын шул ук хәл. Прәме аптыраш. Нәрсә эшләргә дә белгән юк. Җиде-сигез көн эчендә без берьюлы ун авиабомба шартлагандай киң

котлован казып ташладык. Әлегә суның исе дә, төсе дә, дымы да юк. Болай барганда безнең эшнең очы да, кырые да күренми.

Арабызда өлкән яшьтәгерәк сабакташыбыз Хаммат абый, авылга кайтып, бер казакъ картын алып килде. Җир йөзенә койма ярыгыннан гына карагандай үтә кысык күзле, чал чәчле, сөйкемле генә бер карт. Башта без казып ташлаган котлован читенә утырып рәхәтләнеп көлде. Ә хикмәт бик гади икән. Кое казыган чакта җирне бер метр гына тирәнлеккә казыйсың. Карагай агачыннан метрга метр итеп бура бурап аны шул чокырга төшереп утыртасың. Аннары инде шул бура эченнән казып, комны чиләкләр белән өскә бирәсең.

Казакъ аксакалы бураның өч-дүрт эргәсен үзе бурап та бирде. Китте безнең эшләр хутка. Эченнән комын алып торгач, җир үзеннән үзе бураны кыса, аска батыра бара. Өч метр ярымнарга җиттек дигәндә, су да чыкты.

Ничәмә мең баш меринослардың барысына да җитәрлек булсын дип, әле су чыккач та, коены метр ярымнарга тирәнрәк казыдык, тирәнәйттек.

Арабызда оста балтасын уйнатып кына тотучылар да бар булып чыкты. Унбиш көннәр дигәндә коеның өстен, башын да матур итеп яптык. Сарыклар эчәр өчен улаклар ясадык. Коены ачу тантанасы булды. Тантанага Биш Карагай районы үзәгеннән дә, хәтта Павлодардан да җитәкчеләр килгәннәрие. Безне кат-кат кинога төшерделәр. Комсомолның Павлодар өлкәсе егетләре безгә кыйммәтле бүләкләр — кемгә фотоаппарат, кемгә кул сәгатьләре, кулдан бәйләгән йон башлыклар, бумази күлмәкләр өләштеләр. Мондый иксез-чиксез далада бер йотым төче су — баш бәясе! Тантанада чыгыш ясаган һәр кеше шул турыда сөйләделәр. Транзисторлы радиоалгычларның әле күренә генә башлаган чагы. Бригадабызга «Спидола» радиоалгычы бүләк иттеләр.

Аннары безне «1 Май» совхозыннан җиде генә чакрым ераклыктагы җәйләүгә китерделәр. Әлеге җәйләү пединститут студентларының төп штабы икән. Бөтен җәйләүгә бер кое. Аның да суы эчәргә яраксыз. Эчәргә, ашарга, юынырга суны совхоздан озын арбага җигелгән ата ялкау һәм киребеткән ике үгез белән ташыйлар. Чиратлашып. Алар белән суга бару бер-ике тапкыр миңа да эләкте.

Һәркайсына бишәр йөз литр сыеклык керешле ике зур агач мичкәне тутырып җәйләүгә кайтырга чыгасың. Ике мичкәдәге су мең литрлар була бит, ягъни йөз чиләк дигән сүз. Шул йөз чиләкне, авызы бик ипсез, җитмәсә, үзе тирән коедан алып чыгарып тутырырга кирәк бит әле. Инде җайга гына кайтканда, әлеге ике «МУ-2» кинәттән генә тискәреләнеп, кәҗәләнеп куялар. Киреләнделәрме, баш очларында ник атом бомбасы шартлатмыйсың, озын койрыкларын мәгънәсезгә уңга да, сулга болгап, сәгатьләр буена кузгалмый тора бирәләр.

Инфакларны бездән унбиш чакрымнар читтәге җәйләүгә илткәннәр. Күңел түреңә мәхәббәт дигән сандугач оя корырга ниятләсә, бер дә харап икән ул. Поездда килгәндә күңелем төшкән Кара каш дала уртасында кое казыганда да бер минутка да исемнән чыкмады. Ни сыкрансаң да, аны кешегә чыгармыйсың инде. Егетләрнең теле зәһәр, көлкегә калуың бар. Чулпан атлы егетебез, моннан бер айлар гына элек өйләнеп, хатынын Казанда калдырып килгәние. Беркөн ул таң алдыннан хатынымны бик сагынам дип елап яткан. Аннары аның күзен ачырмадылар.

Үзебезнең төп җәйләүгә кайткач, мин дә тынычлыгымны тәмам жуйдым. Кара кашым гел күз алдымда гына тора. Аларның җәйләве безгә күрше генә «Семеновский» совхозы белән янәшә икән. Ә бу совхозга эшелоннары белән химия-технология институты студентларын китергәннәр. Химиклар кичләрен безнең кызлар янына җәйләүгә танцыга килеп йөриләр, ди. Алтын җирдә ятмый. Менә шунда берәрсе минем кара кашымны эләктереп куйса? Әй, бер уйласаң, чын тиле баш инде мин. Ничек, каян килеп минеке булсын әле ул? Поездда килгәндә бер мәртәбә куертылган сөт банкасын ачып биргән башым белән! Эчтә минем Везувий вулканы дөрли. Соңармагаем!.. Дөрләсә дә... Түзми хәлең юк.

Үз группабызда ук Бикмөхәммәт атлы, ә без Хаммат абый дип кенә йөрткән инде шактый өлкән яшьтәге сабакташыбыз бар. Лаеш районыннан. Коммунист. Армияләрдә дә булган, комсомол-партия курсларын да күп бетергән, бик киң эрудицияле сабакташ. Үзеннән ун яшьләргә яшь студент егетләр арасына килеп эләгүе үзе бер повесть.

Безнең арага килеп эләккәнче Хаммат абый үз авылларында тарих фәне укыткан. Дөньяга карашы төпле, диапазоны киң, Хаммат абый биргән дәресләрне мактап кына торганнар. Ярар, үзебез чыгарган карар дигәндәй, көннәрдән бер көнне алар мәктәбенә әле яңа гына институт тәмамлаган бер чибәркәйне җибәрәләр. Әле бит Хаммат абый да өйләнмәгән егет. Ике яшь йөрәк тиз арада уртак тел табып өйләнешеп җибәрәләр. Күп тә узмый, Хаммат абыйның законлы хатыны Нажия апаны башта завуч, аннары мәктәп директоры итеп үк билгелиләр. Анысы да бик хуп.

Әмма тормыш гел син дигәнчә генә бармый. Сикәлтәләр очрап тора. Чираттагы педсоветларның берсендә директор Нажия ханым законлы иренә бөтен педколлектив алдында:

— Иптәш Гарипов, төпле генә педагогик белемегез булмаган башыгыз белән югары белемле, дипломлы педагогларга каршы төшеп утырмагыз әле, зинһар, — дип әйтеп куймасынмы?! Ирләр күтәрә торган түбәнсетүме бу? Бигрәк тә Хаммат абый холкы белән, егетләр!

Инде өйгә кайткач, Хаммат абый мәсьәләгә ачыклык кертмәк була. Ә Нажия апа күп уйлап тормый:

— Бикмөхәммәткәем, үпкәләмә дә, авызыңны да турсайтма. Хәзер югары белемлеләр заманы. Бәхәс купкан өлкәдә син чеп-чи надан. Надан башың белән бөтен коллективка каршы төшеп маташтың. Мине уңайсыз хәлгә куйдың, — дип үк ычкындыра.

Шул көздә Хаммат абыебыз, хатынын, ике баласын авылларында калдырып, безнең белән институтка керү имтиханнарын тотты. Безнең белән бер тулай торакта яши башлады. Чирәм җирләргә дә барды. Армиядә ул шофер булып хезмәт иткән. Бу һөнәре аңа чирәм җирләргә килгәч тә ярап куйды. Машина белән комбайн бункерыннан ындыр табагына бодай ташыды. «Нажия апагызга үч итеп укыйм!» — дип, гел бишлегә генә укыды. Коммунист булгач, институтта да факультетның партбюро әгъзасы булды. Мыскал эчкерсез, һәркемгә ярдәмчел егет ул Хаммат абыебыз. Группада үзен бик ихтирам итәбез.

Чирәм җирләргә килеп төшкәч тә пединститут студентларына өлкән иптәш итеп билгеләделәр. Кулына иске генә полуторка машинасы да бирделәр. Ул кичләрен әле теге, әле бу җәйләүгә барып чыгып студентларның хәлен белешә, арагызда алай-болай авырып китүчеләр юкмы, дип сораштыра.

Килгәнрәк шәпкә безгә мул итеп дуңгыз ите тураган ашлар пешерделәр. Аны кызларыбыз гына түгел, егетләр дә ашамыйлар. Пешкән дуңгыз ите һәр көн өстәлдә бер табак булып өелеп кала. Бу мәсьәләне дә Хаммат абый хәл итте. Безгә мул итеп сарык һәм елкы ите салган ашлар пешерә башладылар.

Аптыраган үрдәк арты белән күлгә чумган, ди.

— Хаммат абый, бу серемне сиңа гына чишәм. Инфак кызлары арасында патша кызыдай бер чибәргә күзем төште. Шуны бер күреп сөйләшәсе иде. Ләкин бер дә җае юк. Бик ераклар бит, — дип, эчемә сыймый башлаган серемне менә аңа чиштем.

— Сереңне как раз вакытында чиштең, — диде ул. — Анда барыбызга да премияләр язганнар. Безнең кызларга сарык йонын сыйфатлы алганнары өчен. Безгә кое казып биргән өчен. Инфаклар да тик ятмаганнардыр. Премия аларга да бар. Иртәгә шуларны өләшергә барабыз. Әйдә, минем секретарь булырсың. Исемлек төзеп, һәркайсыннан кул куйдырып, премияне син өләшерсең, — диде ул.

— Әй, Мөхәммәт абый, әле дә син бар бу дөньяда! Мең яшә! — дип, кочып ук алдым үзен. Бармыйммы соң! Берочтан җилкәңә тегермән ташы да салып барасың дисәләр дә, эh тә димичә риза.

Хаммат абый машинасын тимер өчаяк өстендә утырган зур казанда нидер пешерүче кызлар янында туктатты. Минем кара кашым да шулар арасында. Алар арасыннан биш кызны, иң чисталарын, иң пөхтәләрендер инде, аш пешерүчеләр итеп билгеләгәннәр.

Юлда мин әллә нинди кыю планнар корып, үземне ничек тотасымны, матурыма нинди сүзләр әйтәсемне энәсеннән-җебенә кадәр уйлап бетереп килгәнием. Аны күрүгә, ул планнар әллә кая очтылар. Шунда бит инде килеп күрешәсе генә. Ни хәлләр, диясе. Аның өчен генә мине берәү дә дар агачына ботымнан асып куймас иде. Юк инде, каушадым да төштем. Әллә бик яраттым инде бу кара кашны? Әллә үзем булмаган, пешмәгән бер җанмы?

— Кызлар, бу арада сул уч төпләрегез кычыткандыр әле, шәт? — диде Хаммат абый. Ул теләсә кем белән бик тиз уртак тел таба.

— Юк. Әллә ни сизмәдек, — диештеләр кызлар.

— Кычыткандыр, кычыткандыр. Сизмәгәнсез генәдер. Сезгә премия акчалары алып килдек бит.

Кызлар шунда ук уйсурак җиргә өстәл чыгарып куйдылар, берәм-берәмләп чиратка бастылар. Мин акча өләшә башладым.

— Иптәш казначей, син кызларыбыздан ялгыш кына бездетный тота күрмә тагын. Юкса халыкара скандалга юлыгырбыз, — дип, Хаммат абый минем белән шаяртып та ала әле.

Әнә минем кара кашымның да чираты җитеп килә. «Минем» дим бит. Барыбер минеке булачак.

Шунда Хаммат абый минем колакка гына:

— Күрәсеңдер, кара кашыңның да чираты җитеп килә. Авызыңа су кабып утырма. Шушында ук бер җылы сүз әйт! — дип пышылдады.

— Ни дип кенә әйтим соң? Каушадым бит әле. Маңгайга бөртек-бөртек тирләр чыкты.

— Ведомостька кул куйганда, бармак очыннан гына тот та: «Беләсезме, сезгә бер бик чибәр егеттән сәлам алып килдем», — диген. Кызлар алар бик любознательныйлар. Ул: «Кемнән, кемнән? Мин ул егетне күреп беләмме соң?» — дип сорар. «Беләсегез килсә, әз генә көтегез», — диген. Көтми калмас, кызлар андый подходны килештерәләр алар.

— Аннары нишләрмен? — дидем Хаммат абыйга. Бу соравыма хәтта ул да аптырап калды.

— Сиңа тәмам чәйнәп каптырырга, син бит нарасый бала түгел. Әзрәк үз сельсоветыңны да эшләт. «Әйдәгез, әзрәк кенә читкә китик», — диярсең. Ә инде читкәрәк киткәч, ык-мык торма, туп-турыдан: «Сезгә күп сәлам җибәрүче егет менә мин ул!» — диярсең. «Мин сезне бер күрдем һәм шуннан бирле өзелеп яратам!» — дисәң дә артык булмас.

Ул арада кара кашымның да чираты җитте. Мине бик өйрәнеп карый төсле. Әмма карашы ягымлы, өметле. Ведомостька кул куйган чагында гына нәкъ бармак очыннан гына элəктереп алдым.

— Мәдинәкәй, мин сезгә бер бик чибәр егеттән бик кайнар сәлам алып килдем, — дидем.

— Нинди егеттән ул? Мин аны беләмме? — диде матурым, елмаеп. Кара кашымның керфекләре дә ничек озын икән.

Абау, матурым, керфегең!
Бирче миңа бөртеген.
Чит җирләргә чыга калсам,
Төсең итеп йөртермен, —

дип чак җырлап җибәрмәдем.

— Акчаларны өләшеп кенә бетерим, чак кына көтегез. Аннары әйтермен, — дидем.

Күрәм, кара кашым бераз читкәрәк китеп басты. Көтә бит!

Бикмөхәммәт абый кабыргага төртте.

— Бир монда кәгазьләреңне, акчаны үзем өләшеп бетерәм. Ә син кузгал. Каушама, җебеп төшмә. Күз карашы ягымлы. Ул да сине ошата. Сценарийдан читкә тайпылма, нәкъ мин өйрәткәнчә эш ит!

Үзем дә аңлыйм. Мондый чакта чакматаш, ут очкыны булырга кирәк. Тәнемдә, җанымда булган бар кыюлыгымны җыйдым учыма. Бардым янына.

Ул, елмаеп кына:

— Нинди егеттән бик кайнар сәлам алып килдең? — диде. — Чибәрме соң үзе? Мин беләмме аны?

— Кирәк егет үз сәламен үзе җиткерсен. Мин беркемнең дә сәламен күтәреп килмәдем. Сине үзем бик сагынып килдем, — дип әйттем дә салдым. Шушы минутта җир икегә ярылса, шул ярыкка кереп китәрлек булып кызардым. Тез буыннарым йомшагандай булды.

Бу хәлдән кара кашым мине үзе чыгарды.

— Үзем дә шулай уйлаганыем аны, — диде ул, миңа төбәлеп карап.

— Чынмы?!

— Чын булмыйча! Вагонда килгәндә сәгатьләр буе миңа төбәлеп карап утыра идең бит. «Бу истфак егете сиңа бесповоротно втюкался, смотри!» дип, миңа кызлар күптән әйттеләр инде.

— Втюкался шу-ул, — дидем. — Ә химия-технология институты егетләре сине урларга җыенмыйлармы соң?

Кара кашым тагын бер матур итеп елмаеп алды.

— Мине урларга дип иртән генә тулы бер делегация килгәние. Бер юлга кире бордым әле. Йөрмәгез, дидем.

Шунда бит үземә дә, Мәдинәм-гөлкәем, мин сине өзелеп яратам, башкаларга берүк карый күрмә инде, дип кенә әйтәсе дә бит.

Бар күрешүебез, бар сөйләшүебез шул булды. Хаммат абыйга шул күрешү дә озак тоелган.

— Калганын икенче килгәч сөйләшерсез, — дип, машина янына чакырды.

Бу җәйләүгә моннан соң да ике-өч килдек әле. Ике арада туып һәм ныгып килгән эчкерсез дуслык мөнәсәбәтләрен тагын да ныгыту йөзеннән кара кашыма бу юлы биткә сөртә торган йомшак кремнар һәм үтә дә хуш исле кытай ислемае алып килдем. Аларны ул рәхмәт әйтеп алды. Әмма бер рәхәтләнеп сөйгәнеңне кочагыңа алып сөйләшергә һаман җай чыкмады. Кая карама кеше күз алды. Күрсәләр, аның сүзе чыга... Яхшыдан яманы күбрәк була.

Ә кайткан чакта безне Пекин — Мәскәү поездына, купелы вагоннарга утыртып озаттылар. Һәркемнең булган барча кесәсе акча белән тулы. Ул елны чирәм җирләрдә уңыш бик мулдан булды. Хезмәт хакын безгә дә бик мулдан түләделәр. Студент халкының кулына хисапсыз акча гына бир икән. Кем нәрсә кыланганын белми башлады. Арабызда укырга кергәнче армияләрдә булган, яшь кенә башкайлары белән бик күпне күрергә өлгергән студент егетләр дә бар. Ә һәр разъездда «Чистый спирт питьевой» саталар. Һәр купеда шушы зәхмәт күренә башлады. Моңарчы башка да кермәгән кызларны бүлешү башланды. Безнекеләр безнең кызлар янына кергән физмат егетләрен тәпәләп чыгардылар. Химфак, геофак кызлары купеларыннан безнең егетләр иреннәрен күптереп, күлмәкләрен ерттырып кайттылар. Купе саен кереп:

— Булачак педагоглар, мәктәпләргә барачак укытучылар бит сез! — дип, оялтырга тырышып, институт партбюросыннан бер ханым йөри анда. Аның сүзенә колак салган кеше юк. Татарстан радиосының булачак югары квалификацияле дикторы Эльс Гаделевне атаманлыкта гаепләп, сигез иптәше белән бер разъездда составтан төшереп калдырдылар. Эльс белән без бер бүлмәдә яшибез. Миңа ничектер тимәделәр тагын. Ә инфакларның кайсы вагонда, ничәнче купеда кайтуларын да белеп булмады. Чит вагонга йә берәр купега килеп керсәң, кем икәнеңне сорап тормыйлар, хәзер тәпәләп чыгаралар.

Эльс һәм аның юлдашлары, ниндидер тиз йөрешле поездга утырып безне узып китеп, алдагы бер разъездда безнең составка тагын десант төшерделәр. Янәдән разборка, аңлашу булып алды.

Ул елны Казакъстанда бодай белән тары егылып уңганнар иде. Инде сентябрь урталары җитте. Безгә күптән кайтып китәргә вакыт. Вузларда укулар башланды. Ә кырда әле чабылмаган бодайның очы да, кырые да күренми. Безне солдатлар алыштырырга тиешләр иде. Алар һаман да күренмиләр.

Ситуация җитди. Студентлар да кайтып китсәләр, ындыр табакларындагы миллионнарча тонна бер дигән чи бодай дөрләп яначак. Аларны сәгать саен астын-өскә әйләндереп, җилгәреп торырга кирәк. Мәскәүнең рөхсәте белән безне 14 октябрьгә кадәр алмашка бер дивизия солдат килеп җиткәнче калдырдылар.

Шулхәтле ерак җирләрдән исән-сау, кесәләр тулы акча белән кайткач, һәр студент, туган-тумачаларга зур бүләкләр алып, туган-үскән якларына кайтып, әти-әнисен күреп килде. Янәдән институтта җыйналып, берәр айлар укыгач, комсомолның Татарстан өлкә комитеты инициативасы белән безне Опера һәм балет театрына «Чирәм җирләрне үзләштерүдә катнашкан батырлар» слетына җыйдылар.

Казанга кайтып төшү белән, бик затлыдан үземә бик килешле кәчтүн-чалбар алып кидем. Аякта Чехословакиянең үзендә теккән фасонлы кара туфлиләр. Октябрь ахырлары-ноябрь башлары бит инде бу. Салкынча. Минем өстә затлы җилән, башта өр-яңа фетр эшләпә. Көзге алдында шактый таптандым да киттем слетка. Бу егетне шушында ук тотып ал да хет Төньяк, хет Көньяк Америкага бүген үк тулы вәкаләтле илче итеп җибәрергә була дигән катгый фикер белән. Илчелеге, миңа дисә, чәнчелеп китсен. Слетта мин һичшиксез кара кашымны күрәчәкмен. Менә ни өчен шулай фырт киендем, көзге алдында таптандым.

Слетта нәрсә буласы билгеле инде. Башта безне мактап сөйләделәр. Катнашучылар арасыннан да сүз алып сөйләүчеләр булды. Барыбызга да грамоталар бирделәр. Кыйммәтле бүләкләр өләштеләр. Атаклы артистларыбыз катнашында зур концерт карадык. Аннары танцылар. Фойеда театрның симфоник оркестры прәме йөрәкләрне өздереп Иоһанн Штраусның берсеннән-берсе матур вальсларын уйныйлар. «Зәңгәр Дунай», «Вена урманнары әкиятләре»н аккордеонда мин үзем дә яратып уйныйм.

Карасам, фойеның бирге башында бер җәйләүдә булган иптәш кызлары вә егетләре белән минем кара кашым да тора. Күрдем дә чүт егылып китмәдем. Аның өстендә беләктән генә җиңле кып-кызыл бик матур кофта. Аксыл төстәге озын итәктән. Аякларында тик театрларда гына кия торган биек үкчәле бәрхет туфлиләр. Чәчен матур итеп ясаткан. Прәме курчак инде! Ал да кач! Туп-турыдан каршына килеп бастым да вальска чакырдым. Чыктык зал уртасына. Вальста әйләнәбез. Шуннан инде мин аны кич буе кулымнан ычкындырмадым. Тулай торагыбызга да култыклап алып кайттым. Озын сүзнең кыскасы, шуннан кулдан ычкындырмадым инде мин аны.

Икебез дә бер тулай тораста яшибез бит. Мин икенче катта, 26 нчы бүлмәдә. Кара кашым өченче катта, 37 нче бүлмәдә. Аның 37 нче бүлмәдәге караваты нәкъ менә минем 26 нчы бүлмәдәге караватым өстендә. Алай гынамы?! Минем караватым башындагы стенадан эт эчәгесе генә юанлыктагы тимер торба өченче катка уза. Нәкъ менә минем кара кашым караваты очына килеп чыга. Кирәк чакта, шушы торба аша гына сөйләшү өчен мин Морзе азбукасы төзедем. «Тук-тук-ту-ук!» булса — «Син өйдәме?», «Ту-ук, ту-ук, тук, тук, тук!» булса — «Әйдә кинога барабыз!» була. Аның шунысы гаҗәп. Мин бүлмәдә юк чакта, егетләр шаярып кына булса да өченче катка шушы азбука белән берничә тапкыр шакып караганнар. Мишәр әйтмешли, минем йөрәк маем аларның берсенә дә җавап бирмәгән. Бик тәжрибәле радистлар төсле минем шакуымны почеркымнан таный иде.

Сөйгән кызың белән бер тулай тораста торуның уңай яклары күп инде аның. Үзебезнең бүлмә егетләре белән Профсоюзная урамындагы ит-колбаса цехына еш кына колбаса бушатырга йөрибез. Цехтан чыккан чакта, анда эшләгән хатыннар да, ишек төбендә торган агай да, култык астыңа күпме колбаса кыстырсаң да, берни әйтмиләр. Студентлар бит! Икенче атнаны «Светоч» конфет фабрикасына шоколад конфетлар бушатырга барабыз. Аннан да күтәрә алган кадәр конфет күтәреп кайтабыз. Тулай торакка күтәреп кайткан хәзинәләрне башта кызларга өләшеп чыгабыз. Бу церемониал күңелгә үзенә бер аерым рәхәтлек бирә. Кызларыбыз арасында, бичаракайлар, хөкүмәтебез биргән шул нибары егерме ике сум стипендиягә табынып яшәүчеләр дә күп. Илнең иң хәерче елларында укыдык без. Шул нибары егерме ике сумга ай буе аша да киен, оек-капрон да ал, мунчага да бар. Без егетләр алай ярлы яшәмибез, җаен да, акчасын да табабыз. Сөйгән кызларыбыз белән хәтта ресторанларга да йөрибез. Нигә йөрмәскә, әллә хакыбыз юкмы?!

Кара, әй, бу хикәямне миңа менә шушы җиреннән генә башларга булгандыр. Кара кашым белән икебез дә пединститутның Болак буендагы яңа бинасында укыйбыз. Тарих факультеты икенче-өченче катларны били. Инфаклар дүртенче катта. Икебезнең дә лекцияләр сәгать икеләрдә бетә. Кем алданрак чыкса, Болак буенда көтеп тора. Лекцияләрдән чыккач, мин кара кашымны берәр яңа кино йә спорт ярышлары карарга чакырмак булам. Матурым башын гына селки. Минем ише бер урында бер минут утырып тора алмаучыларга инфакта укырга язмасын. Берьюлы ике тел өйрәнү белән генә түгел, аларга бер төн эчендә тәрҗемә итеп килергә бик зур текстлар да бирәләр. Тәрҗемә өстенә әллә ничәшәр бит текстларны күңелдән ятларга да әле. Мәхәббәт турында уйларга вакыт та калмый.

Без Бауман урамы буйлап тулай торакка кайтырга чыгабыз. Шушы урамда безнең өчен бик изге бер урын бар. Кызыл чиркәүгә каршы гына анда «Блинная» дигән кафе ачтылар. Бүген дә бар ул. Мин Казанга килгән саен анда кереп, хозурланып утырып чыкмый калмыйм. Күңелгә әллә нинди матур хатирәләр килә.

Бауман урамы буйлап без 5 нче трамвайга, Арча кырына, үзебезнең Товарищеская, 5 кә ашыгабыз. Кара кашымның Теодор Драйзерның романыннан ун битлек өзек тәрҗемә итәсе бар. Безнең тарих факультетында укулар алай авыр түгел. Александр Македонский походлары да, Наполеонның Россиягә бәреп керүе дә бер уку белән истә кала. Үземнең хәтер балачактан ук яхшы иде. Әмма инфакта мин укый алмас идем. Телләрне өйрәнү, бигрәк тә һәр сүзне дөрес итеп әйтү өчен ай-һай зур түземлек кирәк.

Алай да мин сөйгәнемне «Блинная»га кереп чыгарга өндим. Төш тирәсе бит. Керәбез. Икебезгә дә берәр порция төче коймак-беленне алабыз. Һәр порция унике тиен. Һәр тәлинкәдә икешәр коймак. Уртасына тычкан күзе хәтле генә май тамызалар. «Блины» өстенә икебезгә дә берәр порция оладья дигән коймак алабыз. Анысы унөч тиен. Һәр тәлинкәдә икешәр оладья. Аларның өстенә көнбагыш бөртеге чаклы гына алма повидлосы салалар. Бөтен чыгым илле тиенгә баса.

Мин үземнең алдагы беленне дә, оладьяны да күз ачып йомган арада бөкләп тә куям. Ике тәлинкәдәге дүрт данә коймак егет кешегә нәрсә генә инде ул? Мәдинәм-гөлкәем үз алдындагы төче коймакны да миңа таба шудыра. Үзе оладьяны гына чемченеп утыра. Менә ант итеп әйтәм, шундый чакларны ул, минем төче коймакка бер дә галәмәт тәкать тота алмавымны күреп: «Менә исән-сау гына укып чыгып, берәр районга китеп мәктәптә эшли башлагач, мин сиңа һәр көн торышыңа, майда гына йөздереп, өеп бер таба коймак пешереп куярмын. Төче коймакларны мин үзем дә бик оста туглыйм», — дигән чаклары да булды. Булды-булды, икмәктер, булды. Ә хәзер «әйтмәдем» дип бара. «Әле кияүгә дә чыкмаган, чыгасы-чыкмасы да тәгаен генә билгеле булмаган кешемә мин ни дип андый вәгъдәләр бирим», — ди.

Өйләнеп куярга, башларыбызны бер мамык мендәргә салырга мин анысы шушы минуттан ук әзер. Ә кара кашым аяк терәп: «Анысы аның бездән качмас, башта укуыбызны тәмамлыйк, кулларыбызга дипломнар алыйк», — дип бара. Йөрәк маем белән сүз көрәштерүнең мәгънәсез, абсолют перспективасыз шөгыль икәнен мин аның белән аралаша башлаган көннәрдә үк төшендем.

Ни генә булмасын, сөенечләремнең баштан ашкан чаклары. Җан сөйгән ярыңны култыклап кына түгел, бармак очларыннан гына тотып бергә атлау да сөйләп биргесез җан рәхәте бит ул. Дөресен әйтим, бу асыл кошны мин аягыннан бик нык каптырдым дип уйлап бетергәнием инде. Алай булып чыкмады шул. Авыл агайлары әйтмешли, тәртә бавы нәкъ тауның очына менеп җиткәндә өзелә язды. Күпләрне сокландырып, ә бәлкем, кайберәүләрне көнләштереп тәдер әле, ике ел ярымнар бертуган абый белән сеңел төсле бик тату йөргән идек. Менә дипломнарны гына алыйк та бөтен тулай торакны аякка бастырып туй ясарбыз дип тора идек. Бер группада укыган дусларыбыз да бездән шуны көтә. Хәтта ашыктыралар. Казаннан киткәнче сезнең туегызда гүләйт итеп китәсебез килә, диләр.

Дәүләт имтиханнары тоткан көннәрдә бер дә көтмәгәндә генә арабыздан кара мәче узды. Кая ул чәчәк бәйләмнәре тотып загска язылышырга бару?! Күрешкәндә хәтта исәнләшмибез дә. Башларыбызны читкә борып узабыз. Үзебезнең группа егетләре, нечкә билем группасы кызлары бөтен көчләрен җигеп, безне татулаштырырга тырышалар. Әмма тырышулары һич кенә дә барып чыкмый. Чөнки икебез дә киребеткәннәр.

Ә вакыт рельстагы вагон кебек, текер-текер алга тәгәри генә.

Дәүләт имтиханнарын тапшырдык. Дипломнар алдык. Подъемный акчаларын бирделәр. Бер группада укыган, бер бүлмәдә торган егетләрем берәм-берәм каникулларга таралыша, эшкә юллама алган районнарына таба таралыша башладылар. Биш йөзләп студент яшәгән тулай торак буп-буш калды. Үзләренең 37 нче бүлмәсендә минем йөрәк маем, үзебезнең данлыклы 26 нчы бүлмәдә каңгыраеп мин берүзем яшәп ятам. Нечкә билем дә кайтып китми, мин дә беркая да кузгалырга җыенмыйм. Мөмкин дә түгел. Бу үзсүзле җанкисәкне мин башымны жуеп яратам. Ансыз бер минут та яши алмам төсле. Өченче катка менеп, бүлмәсе ишеген ничә катлар шакып карадым. Ишеккә якын да килми.

Үзем төзегән Морзе азбукасы белән бик җылы сүзләр дә шакып карыйм. Шунда кулына калай кружка алып йә әлүмин кашык алыпмы ике генә тапкыр «Тук-тук!» итсә, бүлмәләренә очып менеп җитәм бит инде. Юк, җавапсыз. Бу ни хәл инде? Нишләргә дә белгән юк.

Үзәк ял паркында ремонт эшләре бара. Аптырагач, шунда барып, көнлеккә ялланып, кәйлә белән асфальт чабып кайттым. Эше авыр булгач, яхшы гына түлиләр. Шуннан тәмам арып кайтышлый, чәйгә ак булки алыйм дип керсәм, минем җаныем да шунда. Мине күреп алды да күрмәмешкә салышкан булды. Күрмәмешкә салыша алмый. Чөнки кибеттә без икәү генә.

Шунда, ни булса, шул булыр дип, беләгеннән тәэсирле генә итеп тоттым да:

— Менә шушы иң кыйммәтле тортны алам да сине үз бүлмәбезгә чәйгә дәшәм! Ай-ваеңа карап тормыйм, өстерәп алып төшәм! — дидем.

Шунда ул Тоньяк боз океаныннан агып килгән айсбергларыңны да эретерлек итеп елмаеп җибәрде. Кибеттән без бергә кайттык. Торты да гаҗәеп тәмле иде.

Икенче көн иртән загска гариза бирергә йөгердем. Хәзер анда тәртипләр ничектер, безнең заманда гариза биргәч бер айлар чамасы көтәргә кирәк иде. Берәр нәрсәгә алынсам, мин соң аның очына

чыкмый калучымы инде? Менә кулыбызда дипломнар, эшкә китәсебез бар, дигәч, иртәгә килерсез, дип җибәрделәр. Анда бит свидетельләр белән барырга кирәк. Ә безнең беркемебез юк. Нечкә билемнең бер группада укыган иптәш кызы Нина Кропотова Казанда калган икән. Аны эзләп таптык. Ике яктан да свидетельләр Нина Кропотова һәм үзебезнең тулай торак коменданты дөнья бәясе акыллы, кешелекле апа Францисса Карловна булды.

Мондый истәлекле көнне тантаналы шартларда билгеләп китми дә булмый. Ул чорларда Казан Кремле астында гына «Поплавок» ресторaны бар иде. Кичке якларда, үзебез белән Нинаны да алып, өчәүләп шул ресторанга төшеп утырдык. Акча бездә бер букча. Подъемныйлар да кесәдә. Ял паркында да эшләп алдым. Менюны кулга алып: «Кызлар, матуркайларым, бу кичтә җаныгыз ни тели, шуны китертәбез!» — дидем. Шулай димичә! Асыл кош хәзер тулысы белән минеке; паспортында — печать, кулында — алтын йөзек. Алай да ышанып бетмим төсле әле.

Үч иткәндәй шыгрым халык бүген ресторанда. Белгән булсак, икенчесен сайлаган булыр идек. Безнең белән янәшә үк өстәлдә дүрт егет утыра. Дүртесе дә кыска җиңле күлмәктән. Дүртесенең дә беләкләрендә симез хәрефләр белән язылган татуировкалар. Оркестр карлыга-карлыга «Ландыши, ландыши»ны уйный. Теге егетләрнең әле берсе, әле икенчесе минем кызларны биергә чакыра башладылар. Мин өстәл саклап утырам. Тегеләр бераздан бөтенләй оятсызландылар. Өстәлләрен безнең өстәлгә үк китереп терәделәр. Мин кызларымның берсе белән дә биергә чыга алмыйм. Чөнки икенчесе ялгыз кала. Ә тегеләрнең берсе минем нечкә билемә тәмам сөлек булып ябышмакчы, атлаган саен аны чакыра. Минем матурымнан:

— Сез бу ресторанда бүген нинди уңай белән соң? — дип сораган.

Мәдинәм-гөлкәем:

— Әнә теге чибәр егет белән без бүген загста язылыштык. Ул минем законлы ирем, — дип миңа ымлаган.

— Әнә шул дистрофикмы?! Тапкансыз инде егет! — дигән авызы тимер тешләр белән тулы егет. Авызына берне тартсаң, бер сукканда бер взвод тешләре коелачак инде аның.

Аларның мыскыллы карашларын мин инде күптән тоеп утырам. Ләкин мин берүзем бит, алар дүртәү. Алай да ситуация тәмам куерып китеп контрольдән чыкмагае. Тегеләр аның саен нахаллана баралар. Җитмәсә, ярыйсы гына исерекләр. Исерек ни кыланмас?

Мин кызларыма:

— Сез хәзер туалетка гына дип кузгалыгыз да ярга чыгып Кремльгә таба йөгерегез. Мин сезне шунда үзем табармын, — дидем.

Монда инде күп сөйләшеп тору юк. Алар шулай эшләделәр дә. Кызларым китеп ун минутлар үткәч, официант белән расчет ясап, мин дә урынымнан тордым. Чыга гына башладым, тегеләрнең дә икесе артымнан иярде. Тукта, кая ашыгасың, диләр. «Дистрофик» дип алар ялгыштылар бугай. Диплом яклаган студентның берсе дә бурсык кебек симез булмый инде. Берүзе ун йомырка өстендә айдан артык утырган ана каз кебегрәк буладыр.

«Поплавок» ресторанына ун-унике метрлар чамасы сыгылмалы басмадан керәсең. Монысы үзенә бер экзотика, янәсе. Чыкканда да шулай. «Тукта, тукта! Кая ашыгасың?» — дип, алар миңа төн караңгылыгында нәрсә әйтмәкче булганнардыр. Арттан куып җитеп, иңбашыма кулын салуга, сул коверкот белән бирдем моңа берне. Мин бит гомерлек сулагай. Үзебезнең пединститутның спорт дәрәҗәсен саклап, Мончегорск каласына хәтле ярышларга барган, хәтта призлар алып кайткан боксер бит әле мин. Ул хәтле «дистрофик» дигәч тә. Теге егет бер нинди притензиясез басмадан чупылт суга. Икенчесенә уң коверкот җитә калды. Үзем исә туфлиләремне салып ике кулыма тоттым да элдерт елга порты ягына. Тавыш-гауга да, арттан куа чыгучылар да булмады. Портта такси тотып, кызларымны Кремль төбеннән барып алдым.

Тулай торагыбызның комендантының инде бик өлкән яшьтәге ханым Францисса Карловна мине ярата иде. Тораклa биш ел торып һәрчак актив булдым, концертларда аккордеон уйнап катнаштым. Өйләнештек дигәч, ике урынлы гына бер җыйнак бүлмәнең ачкычын биргәние ул. Урамда инде төн уртасы. Нинаны кая куясың? Ташлап китә алмыйсың. Шул ике урынлы бүлмәгә бу кичтә берүземә ике кыз алып кайтып кундым.

* * *

Әй-й, вакытның ничек тиз узуын күр син. Җитмеш белән барабыз лабаса!

Инде менә бер-беребезне бер минутка да кулдан ычкындырмыйча җитәкләшеп йөри башлавыбызга кырык биш еллар узган. Ә мин һаман да ара-тирә: «Мәдинәм-гөлкәем, дөресен генә әйтче, зинһар, син мине яратасыңмы», — дип сорап куям. Аның җавабы бер инде. «Кит әле, юк белән башымны катырма», — ди. Әгәр дә мәгәр яратмаса... Әгәр яратмаса, һәр көн иртән торышыма өеп бер таба төче коймакны майда гына йөздереп пешереп куймас иде, дип юатам инде үземне.

Яшьлегемдә сөйгән ярым, аннары никахлы хатыным Мәдинәм-гөлкәем белән, артык узынмыйча, кирәкмәгәнгә үрелмичә, булганыннан канәгать булып, байтак озын һәм тату гомер кичердек. Ике кыз

үстердек. Әмма Җәнбәт җәвере өстендә канат җилпегән Кара кош безнең гаилә өстенә дә килеп чыкты. Бабам Хәсән ятим үскән. Әтием Барины ике яшендә приютка илтеп тапшыралар. Мин әнием-бәгырем Шәрәфелбәнаттан алты көндә калганмын. Оныгым Арыслан әнисеннән җиде яшендә калды. Аның әнисе олы кызым Гөлнараны рәхимсез чир нибары утыз өч яшендә алып китте. Әгәр исән булсамы?! Ул матурлыгы, ул зиһене, ул акылы, ул төпле белеме, кешеләрне яратуы белән бик зур кеше йә берәр танылган галим, йә күренекле дәүләт эшлеклесе булган булыр иде. Ләкин Мәңге Зәңгәр Күкнең җиденче катындагы иң өстәге бухгалтериядә адым саен безне кемнәр беләндер бутыйлар булса кирәк. Безнең Җәнбәт җәверенә карата бөтен җиһан алдында ничәнче буын рәттән зур гаделсезлек кылына. Әлбәттә, зур ялгышлык бу. Җәнбәтнекеләр беркайчан да кемнәрнеңдер өстеннән йөргән, эзәрлекләгән, кемнәрнедер нахакка рәнҗеткән, кемнәрнеңдер хәләл ризыгын-малын тартып алган ыру-нәсел түгел. Бу турыда төпле петиция язып, Хак Тәгаләнең үзе алдына барырга җыенам әле. Бу башбаштаклыкка һич кичекмичә чик куюын сораячакмын. Бу турыда Мәдинәм-гөлкәем белән дә киңәшеп карыйм. Ул да хуплый. «Кирәк, кирәк, озакка суздыйча гына барып, приемда булып кайт әле, — ди. — Кирәк санасаң, икәү барабыз».

Вәт, малай, булды хәлләр...

Мин: «Язучы булмыйча, башка һөнәр иясе булырга мөмкин дә түгел иде», — дип шар ярып әйтеп салганыем бит. Кем әйтмешли, ул шапырыну яшьлегем хатасы була язды бит, әй. Язучы булам, дип йөрсәм дә, сәгате суккач, маңгаема салкын тир чыгарып, шиккә калдым. Булырмы соң бу егетлек миннән? Халыкка, укучыларыма әйтер сүзем бармы? Фикер иясеме соң мин? Язучылар берлегендә буш арба булмаммы? Мин бик хөрмәт иткән, өйләренә кунакка йөргән, соңыннан миңа Язучылар берлегенә әгъза булып керергә бик җылы рекомендация биргән Габдрахман Әпсәләмовка шулай берзаман: «Язучы булуы бик кыен, тема табуы да бәла, язганыңны басмыйлар», — дип зарланып алган идем.

— Альберт, энем, браткам! — дип гаҗәпләнде остазым минем бу сүзләремә. — Язучылыкка кем сине чакырып китерде? Кем бәйләп тота? Ташла да йөгәнеңне әнә яшел болынга кач. Койрык чәнчеп, рәхәтләнеп уйнакла!

Аның бу сүзләре миңа гомерлек сабак булды. Язучылык чире бер йоккач, тиз генә котыла торган чир түгел шул ул. Казанга килгән саен Габдрахман абыйларга сугылам. 1966 елда яшь язучыларның зур семинары булганые. Мин Әпсәләмов җитәкләгән төркемгә эләктем. Шуннан дуслашып киткәниек. Остазымның хәләле Маһинур апа да якты йөз белән каршы ала. Килгән саен дипломатыма Алманиянең үзендә эшләнгән хатын-кыз бизәнү әйберләре тутыра. Ул елларда мондый әйберләр кибетләрдә юк иде әле.

— Мәдинәң театрларга бизәнеп барсын. Язучы хатыны әйбәт киенгән булырга тиеш. Безгә халык бик төпченеп карый, — ди.

Лениногорскида театрлар елына бер йә ике була. Аларына да йә бара аласың, йә юк. Маһинур апа ул чакта әле бакчага гына йөргән кызларыма да Винни-Пух, Барби, тагын әллә нинди курчаклар биреп җибәрә. Мондый затлы әйберләрне аларга уллары Булат Мәскәүдән алып кайткандыр инде.

Мин килеп керешкә Маһинур апа төче коймак өлгертә.

— Сыйлыйм әле үзеңне мишәр коймагы белән, — дип елмая.

Габдрахман абый пианино өстенә коньяк куя.

— Барган чакта син тоткала бу әйберне. Мин менә бик тотар идем дә, бармый. Ярамый, — ди.

Бер рюмканы салып алдыма ук куя. Мин оялам. Әмма кайнар коймакны вареньега мана-мана ялтыратам гына.

Аларга соңгы баруымда Габдрахман ага паралич сугудан терелеп кенә килә иде. Шундый матур, ачык йөзле агам ямьсезләнгән. Ятып торган җиреннән бүлмәгә таякка таянып кына чыкты.

— Күр инде, күр, бу паралич дигән зәхмәт мине нишләтте, — ди. Мин килгәнгә бик шат. Беренче соравы болай булды: — Вакытың бармы?

Иртәнге ун-унберләр тирәсе бу. Бөгелмәгә билетны соңгы рейска, кичке тугызга гына алганыем. Ул елларда Бөгелмә аэропортына очкычлар көненә ун-унике рейс оча иде.

— Вакытым бар, бар, — дидем абзама. — Кумасагыз, кичке сигезгә кадәр кала алам.

Габдрахман ага өстәлгә бер кочак хат чыгарып салды. Барысы да китап укучылардан килгән.

— Алар бит минем хаста икәнемне белмиләр. Җавап көтәләрдер. «Әпсәләмов тискәре кеше икән. Үмер эчендә бер хат яздым, шыңа да җавап язмады дип» мине орыша булырлар. Вакытың булгач, языйк шуларның бер унына җавап, — диде. — Әнә коньякны да тоткалап утыр. Карап тору өчен генә куелмаган ул.

Хатларның нинди эчтәлеклеләре генә юк. Кайсы акыллы киңәш, кайсы социаль мәсьәләләрдә ярдәм сораган. Үзләренең «Мишәрстан якларыннан»: «Бик инде писатель булырга келим, желанием кечле, кьадан, ницек башлыйм? Выгодасы булырмы?» — дип язганнары да бар.

— Безнең мишәр шандай, шандай, выгодасыз эшкә алынмас, — дип елмая остазым.

Мин костюмымны салып урындык артына элдем. Җиңемне сызганып, хатларга җавап язарга керештем.

«Габдрахман абый янымда басып тора. Ул әле каты авырудан соң терелеп кенә килә. Аның әйтеп торуы буенча сезгә бу хатны яшь язучы Альберт Хәсәнов яза», — дип башлап киттем. Бәлкем, ул хатлар кайбер укучыларның архивларында саклангандыр да. Ул көнне мин төп-төгәл алтмыш хатка җавап яздым. Араларында үзебезнең Лениногорскидан килгән хат та бар иде. Бу иптәш Мәскәүнең Ломоносов исемендәге университетның философия факультетын тәмамлаган. Философ! Акыл иясе! Хәйлә дигән нәрсәнең мыскалы да юк аларның миләрендә. Аларның берләре — материяне беренчел дип, икенчеләре — рухны алга сөрүчеләр. Араларында тормыштан үз теләкләре белән китүчеләр дә очрый. Бу философ мәктәптә балалар укыта икән. Туган якны тирәнрәк өйрәнү максаты белән аларны күрше-тирә авылларга походларга да алып чыгып китә. Походларда йөрү өчен ходовой гына җыр кирәк. Бер походка чыккач, бүкән өстенә утырганнар да балалар белән бергә җыр чыгарганнар, көен дә тапканнар. Шуның өчен бу иптәшне район газетасында бик нык тәнкыйтьләп язып чыкканнар. Бу философның тәрбия ысуллары совет тәрбиясе калыпларына туры килми, дип эзәрлекли дә башлаганнар...

— Кайткач ук горкомыгызның беренче секретарена кер. Минем исемнән сөйлә. Бу кешене эзәрлекләмәсеннәр, зинhар. Ә hәйкәл куйсыннар. Чын педагог — менә ул! Балаларны табигать кочагына алып чыгып, аларны хыял дөньясына чумдыра. Җыр чыгарганнар икән, рәхмәт кенә. Рәхәтләнеп җырласыннар. Шуннан кемгә зыян?! Рәхмәт әйтәсе, кулын кысасы урында, — дип, Габдрахман абый бу сүзләрне үзе әйтеп торды.

Кайткач, чыннан да, горком секретарена кердем. Якладым ул абзыйны. Бу турыда сүз шуның белән тәмам булып торсын.

Габдрахман Әпсәләмов. Бу олуг зат белән аралашкан минутларым күңел түремдә матур хатирәләр булып саклана. Берчакны мин Казанга ял көнендә кичке якта гына килеп төштем. Мондый чакта кая, кемгә барасың? Туганнар да, дус-ишләр дә бар барын. Әмма алар дачаларындадыр. Кем дә булса бардыр әле дип, Язучылар идарәсенә киттем. Барсам, эш бүлмәсендә Зәки абый Нури утыра. Зәки абый белән дус булмаган кеше юктыр ул. Без аеруча дуслар. Бер чорны без аны үзебезнең Лениногорскидан ТАССР Верховный Советына депутат итеп күрсәттек. Мин аның ышанычлысы булып йөрдем. Белоруссия партизаны, Минск каласының почетлы гражданины, үзенчәлекле шагыйрь Зәки абыйның ышанычлысы булу үзе бер дәрәҗә! Мине ярата иде ул. Килгән чакта ярдәм сорап гариза яздыра. Яшьләр фондыннан. Яхшы номерларга урнаштыра. Сөйләшеп утырырга кичләрен үзе дә килеп чыга. Бу юлы Зәки абый хәл-әхвәлне дә сорашып тормады.

— Беркая да китмә! Шушы тирәләрдә генә бул. Бүген дустың Әпсәләмгә кунакка барабыз, — диде.

Идарә каршына кара «Волга» белән Габдрахман абыйның улы Булат килеп туктады. Башта без остазымның Боровое Матюшинодагы дачасына машинага төяп ризыклар илттек. Икенче рейс белән язучылар килде. Шәүкәт Галиев, Нәби ага Дәүли булуын хәтерлим. Нәби ага немецлар кулында әсирлектә булган. Мин әдәбиятка килгән чорларда язучылар арасында аңа кырынрак, хәтта бераз мыскыллырак карау сизелә иде. Заман шаукымы. Әмма Габдрахман абый аңа бик җылы мөгамәләдә булды. Ихтирам итмәсә, чакырмаган да булырые. Зәки абый янында чыраеңны сытып утыра алмыйсың, уен-көлке сүзне сибеп кенә тора. Табын артында бик күңелле утырдык. Миңа урынны верандага җәйделәр.

— Безнең монда салкынчарак кичләрен. Өшемисеңме? — дип, Габдрахман абый яныма чыкты. — Салкынча булса, толып чыгарам. Хәлләреңничек? Язып буламы?

«Сине соң язучы булырга кем чакырып китерде. Кыен булса, йөгеңне ташла да болынга кач» дигән сүзләреннән соң мин бернигә дә зарланмыйм. Гомерлек сабак булды аның бу сүзләре.

— Ә Язучылар берлегенә керүең ни хәлдәрәк тора? Барлык документларың да әзерме? Рекомендацияләреңжитәме? Безнең мишәрдә: «Кала кала-кала да губернага әйләнә», — диләр. Калмасын. Бар нәрсә дә үз вакытында кадерле. Минем рекомендациям дә иртәгә союзда булыр. Шуннан соң да нүжәли алмаслар икән?! Хәер, бик мөмкин. Мин хәзер хаста. Сүзем үтми башлады, — дип янымда утырды. — Тыңла алайса, үзеңә бер мәзәк сөйлим. Карендәшләремне борчымый-нитми генә үлим әле дип, тау куышына кереп яткан филне тычканнар кыерсыта икән. Филне тычканнар җә-берләсен инде! Кеше ышанырлык хәлме диген. Теге шайтаннар, филнең озын борыны эченә кереп оя корып, борын сеңерләрен кимерәләр икән. Үзем дә шул хәлдә бит, — дип, Габдрахман ага көлеп куйды. — Иҗатымны, язган әсәрләремне тәнкыйтьләүчеләр күбәйде...

Мин шул көнне үк кайтып киттем. Икенче көнне сәгать уннарда ул дәвердә Язучылар берлегендә җаваплы секретарь булып эшләгән Равил Фәйзуллин өйгә шалтыратты.

— Сиңа тагын бер рекомендацияне Габдрахман ага Әпсәләмовның тормыш иптәше Маһинур апа идарәгә китереп үз кулы белән минем кулга тапшырды, — диде.

Минем берлеккә керүем тарихта бер мәзәк булды ул. Яшьлекнең бер чорында керәсе, әгъза булып торасы килә анда, шайтан алгыры, инглизләр әйтмешли, чьорт побьюрый. Бүгенге яшьләр өчен бүген дә шулайдыр. Дәрәҗә бит! Аларга карата бик игътибарлы булырга кирәк. Шул ук вакытта берлекне буш балластлар белән дә тутырырга ярамый. Әдәбиятыбызга керткән өлешләре пүчтәк кенә булса да, андыйлар төркемнәргә берләшәләр, корылтайлар вакытында үзләрен начар тоталар, күкрәк сугалар, әллә нәрсәләр даулыйлар. Берлеккә әдәбиятыбыз йөген төп тәртәгә җигелеп тарту өчен кергәннәрен оныталар. 2002 елның азагында Язучылар берлегенең утырышына туры килдем. Шунда берлеккә әгъза итеп Габдрахман ага Әпсәләмовның онукасы, ягъни Булатның кызы Альбина Булатовна Әпсәләмованы алдылар. Рус телле икән. Төкле аягы белән килгән коллегабыз булсын. Бүлеккә алуны сорап гариза язганчы, ул инде ниндидер әдәби премияләрнең лауреаты да булырга өлгергән. Арабызга буш балласт кермәдеме дип шикләнергә урын юк. Болар өстенә ул бабасы язган телне дә ныклап өйрәнергә теләге барлыгын әйтте. Ә менә мин берлеккә алай шома гына кереп китә алмадым.

«Казан утлары»нда басылу — дәрәҗә. Ул — синең язучы булып җитүеңне раслый торган фактор. Минем анда басылган беренче хикәяләрем «Яшь наратлар» белән «Гомер иткән нигез» иде. Аларны басарга Ибраһим абый Гази тәкъдим итте. Әмма журнал папкасында алар ничектер озаграк яттылар.

Ибраһим абый, мине очратып:

— Басылдымы синең теге ике хикәяң? Әллә мин күрмәдемме? — диде.

— Күренми шул әле, — дидем.

Ул чакта Язучылар берлеге рәисе Ибраһим абый журналга шалтыратты.

— Ибрай вакытын кая куярга белми дип уйлыйсызмы әллә сез анда? Яшь авторның ике хикәясен сайлап алып, кулымны куеп басарга тәкъдим иттем. Ә сез һаман да сузасыз. Бу санга ук кертегез, — диде дә трубканы ташлады. Ибраһим ага шундыйрак холыклы кеше иде. Әмма классик! Зур талант иясе.

Аның белән дә әкәмәт хәлләргә тарып беттем.

Мин вышкалар монтажлау конторында эшләгән чорларда безнең Лениногорск сайлаучылары Ибраһим абый Газины РСФСР Верховный Советына депутат итеп күрсәттеләр. Наказлар да бирделәр әле. Китапханәбез юк, депутат булып сайлангач, китапханә салырга булышырсыз, диделәр. Хәзер бер дигән китапханәбез бар. Олуг шагыйребез Габдулла Тукай исемен йөртә.

Булачак депутатыбыз башта сайлаучылары белән очрашуга килде. Андый зур каләм остасы, Язучылар берлеге рәисе килгәч, шәһәр җәмәгатьчелеге шау итте. Ә мин аны каршы алырга да, беренче көнне Нефтьчеләр сараенда аның белән булган очрашуга да бармадым. Минем хәтта диссидент хәленә төшеп, оппозициядә торган чорым. Берсе артыннан берсе хикәяләр шапылдатуны туктаттым да «Сукмаклар» дигән роман язып ташладым. Өч йөз алтмыш биш бит. Нәшрият исәп-хисабы белән уналты табак! Илья Ильф, Петровлар стилендә, өлгереп җиткән социализм шартларында яшәү рәвешебезгә карата ачы сарказм вә ирония белән. Роман басылмады. Халык шагыйре, Тукай премиясе лауреаты Гамил абый Афзал, очрашкан саен, ул бик көчле романыңны кайчан бастырасың инде, дип аптырата иде. Гамил абый — неподкупный мужик, начар әйберне мактамас. Менә шул романны, кулъязма хәлендә генә кулга төшереп, чираттагы әдәби ел йомгакларында тетмәсен тетеп, тәнкыйтьләп чыктылар. Бәлкем, өстән шулай кушкан булганнардыр. Югыйсә, мин анда кызыл җепкә урап, дөньялыкта олы тормыш юлына һәркем кыска гына булса да үз сукмагын салып чыгарга тиеш дигән фикер үткәргәнием. Әйе, олы юлга үз сукмагыңны салып чыгарга кирәк. Кемдер салган сукмактан түгел. Шушы басылмаган әсәр өчен мине Лениногорск Солженицыны дип атадылар.

Югыйсә Солженицын исеме тагарлык берни дә юк төсле тоела әсәремдә. Әмма япь-яшь башым белән андый ярлык алгач, мәрхәмәт юк инде миңа. Нәшриятка да юллар ябык. Подпольега күчеп, юрганымны башымнан бөркәнеп, өнемә кереп ятсам гына инде. Сүземнең очын истән чыгармыйм. Бу хәлләр нәкъ менә безнең калага депутатлыкка кандидат булып Ибраһим ага Гази килү алдыннан булды. Җитмәсә, бергә аралашып яшәгән дустым, көнчелеген тыя алмаганмы, минем өстән Ибраһим абыйга аноним хат җибәргән. Каян сүзен, каян нахак бәлаләрен табып бетергән, унтугыз бит язган! Минем эшкә чыкмыйча атналар буе эчеп ятуым, дүрт-биш хатын алып аеруым, плагиат белән шөгыльләнүем, тагын әллә нәрсәләр турында. Хәтта: «Альберт Хәсәнов чит ил разведкасына хезмәт итмиме икән», — дигән җирләре дә бар. Шушы иптәшнең минем өстән анонимка салуын мин белмим бит. Күрешкәндә елмаеп кулын бирә, дуңгыз. Кулак нәселеннән булуымны да онытмаган. Зәки абый Нури күрсәтте ул хатны миңа. Зәки абый тормыш сөюче, бик шат күңелле кеше иде.

— Минем турыда шундый анонимка язсалар, мин бик сөенер идем әле. Язгалыйлар, әмма болай ук тәэсирле түгел, — дип укытты ул аны миңа, көлә-шаяра. — Әмма эшең кәкәй. Ибрай бу хатны йөзен балан кагы капкандай сытып укыды. Мә, разберись, синең яраткан партизаның, дип миңа сузды.

Соңыннан Ибраһим абый ул хатны үземә бирде. Әмма аңлашканчы әле биш пот тоз ашыйсыбыз бар иде.

Ибраһим Газины Лениногорск төбәгеннән депутат ясарга йөргән чорда безнең горком секретаре Ядкәр Гариф улы Шәфиков иде. Бик дус кеше. Лениногорскига икебез дә бер елны килеп, мин редакциядә эшли башладым, ә ул, авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап, совхозның бер бүлекчәсенә башлык итеп билгеләнде. Икебезне дә шунда ук комсомол шәһәр комитеты бюросына сайладылар. Шәфиков җитәкләгән совхоз бүлекчәсендә малларны уңышлы кышлату турында мәкалә дә язганыем. Менә аны КПССның шәһәр комитеты җитәкчесе итеп күтәрделәр. Беркөн кичтән ул шалтырата.

— Син бүген кичен башлыгыгыз белән очрашуга нигә килмәдең? — ди.

Мин — ык та мык.

— Кичә өч җирдә очрашуда булдык. Ул агаегыз белән уртак тел табуы кыен. Үзен мактап бер сүз әйттерми. Кыскасы, минем бүген колхозларга чыгып китәсем бар. Без аны «Хрущев кунакханәсе»нә урнаштырдык. Иртән йокыдан торышына каршына барып баскан бул. Бер алдына, бер артына төш. Башлыгың бит. Кирәге чыгып куюы да бар.

Ядкәр Гариповичка мин бит барын да ачып сала алмыйм. «Солженицын» булуымны да әйтә алмыйм.

— Хет үтер, булмый миннән, — дидем. — Яратмый ул мине-е-е-е! Аңлыйсыңмы, яратмы-ы-ый!

— Син кем? Девка что-ли? Нигә дип ул сине яратырга тиеш? Менә мине яратучылар да күк йөзендәге йолдызлар хәтледер дип әйтә алмыйм, һич тә. Яшибез бит әле. Бу сиңа минем тарафтан җиткерелгән дәүләт күләмендәге әһәмиятле партпоручение. Үтәми генә кара! Минем холыкны беләсең, Бюрода информацияң...

— Белүен беләм дә, Ядкәр...

— Разговор окончен. Немедленно приступай к исполнению!

Бездә «Хрущев йорты» дигән затлы-элиталы кунакханә бар. Аны Н.Хрущев киләсе булгач, махсус салып куйганнар иде. Анда хәзер дә иң зур кунакларны гына кертәләр. Көз айлары бу. Иртүк торып шунда киттем. Аягым бер дә тартмый. Тауга каршы тегермән ташы тәгәрәтү миңа мең өлеш җиңелрәк булырые. Иртәнге җиде тулмаган әле. Барсам, Ибраһим абый бакчада йөри. Өстен яфрак баскан сукмак буйлап ике кулын артка куйган, каршы килә. Сәламемне алдымы-юкмы, хәтерләмим. Әмма коточкыч җирәнеп карады төсле миңа. Кунакханә биек таш койма белән әйләндереп алынган. Эчтәге хәлне ят күзләр күрмәсен өчен. Ишегалды тыныч. Аннан башка беркем дә юк. Бераздан моны иртәнге чәйгә дәштеләр. Кереп китте. Мине чакырмады. Мин тышта калдым. Анысы гына чурт с нимсәнә, нимесчә әйткәндә — доннер веттер!

Бераздан горком егетләре белән горком машинасы килде. Ике-өч хезмәт коллективында булдык. Ә кичен янәдән Нефтьчеләр сараенда очрашу. Хәтта үз биографиясен, шәҗәрәсен дә юньләп белмәгән бер мокыт-обыватель булачак депутатының иҗатын каян чамаласын? Кандидатның иҗат юлын якыннан белүче буларак, төп чыгышны миңа ясарга куштылар.

— Татар совет әдәбиятының күренекле вәкиле, проза остасы, тәрҗемәче һәм актив җәмәгать эшлеклесе Ибраһим Гази, ягъни Ибраһим Зарифулла улы Мингазиев 1907 елның 4 февралендә, Татарстан АССРның Кама Тамагы районы Иске Карамалы авылында ярлы крәстиян гаиләсендә туа, — дип башлап киттем инде. Бик яшьли ятим кала, дип тә өстәдем. Аннары иҗат юлы турында сөйләп киттем. Үзем бик яратып, онытылып укыган «Онытылмас еллар» романын, Татарстан нефтьчеләренең батыр хезмәтен, нефть чыккан якларда яңа кешеләр җитлегүен сурәтләүгә багышланган «Гади кешеләр» романын язды, дип сөйләдем. Андый чакта мактау сүзләре әйтми дә булмый. Депутатлыкка хөрмәтле кандидатыбыз Тукай премиясе лауреаты, ике тапкыр Почет билгесе һәм Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары кавалеры, дип тә әйттем. Ибраһим абый президиумда утыра бит. Трибунадан мактаганда миңа шулхәтле усал итеп карый, теше җитсә, шатырдатып чәйнәрие. Мин бит аның өчен сөйләмим, залда утырган кул чабучылар өчен сөйлим. Горком, горисполком кешеләре өчен дә.

Әлеге кичке очрашудан соң безне «Урал» ресторанына алып бардылар. Горком кешеләре мине Ибраһим абый белән рәттән утыртмакчы булалар. Мин мөмкин кадәр читтәрәк урын сайлыйм. Ибраһим ага исә шуннан, ерактан торып та миңа: «Син, егетем, монда ни дип ияреп килдең инде?» — дип карый.

Шулай берчакны язучыларыбыз күрше Чуашстанга очрашуга барганнар. Бер кунак йортында чуаш кызлары Ибраһим аганы бик кыстыйлар икән. Көмештәй саф ангалабыздан авыз итмәсәгез, ап-ак капрон күлмәгегезне пычратып, муеныгызга салабыз, дигәч, шул самогонны кабып, өч сәгать буена йотмый утырып, урамга чыгу белән төкереп ташлаган Ибраһим абый бит ул! Бу турыда бер күрешкәндә шагыйрь Сибгат ага Хәким сөйләгәние. Аннары Ибраһим абыйның үзеннән дә сорадым.

— Капрон күлмәкләрнең чыккан гына чагы. Ул күлмәкне портфелемнән алып кигән генә идем. Муеныңа салабыз, дигәч, каптым шул ангалаларын. Ләкин йотмадым, — дип, агай үзе дә раслады.

Менә шушы гомере буена бер рюмка тотмаган кешегә җай табып кара! Җәмгыять, үз өстенә төшкән бурычын, нинди дә булса берәр олуг затны хөрмәтләгәндә, аңа күпме рюмка тоттыруы белән бәяләмәкче була. Шундыйрак заманнар килде бит. Ә бу очракта әлеге олуг зат — камил аек! Хәтта исен күтәрә алмый. КПССның шәһәр комитеты секретаре Ядкәр Шәфиков та агай белән шул җирлектә

уртак тел тапмаганнар бугай. Шәфиков аны сыйламакчы булган, агай баш тарткан. Аның мыскал да капмаганын кем белсен?

— Егетләр, васыять итеп әйтәм, мин үлгәч, ягъни аягымны сузгач, мине, зинһар, зиратның корырак җиренә җирләгез. Юкса миндә коточкыч раматиз бит, — дигән сүзләр дә аныкы. Галәмәт тә шаян телле юморист иде ул. Аның «Замана балалары»н тәгәри-тәгәри көлеп укыдык ич.

Ресторанда чакта, өстәлнең теге башында утырсам да, булачак депутатыбыз исәнлегенә рюмкалар тотканда, күзлеге аша мине усал мөгезләп:

— Нәрсә утырасың? Эч! — дип куя. Эчүен яшереп, кәнфитләнеп утыра дип уйлый инде. Минем өстән язылган анонимкада мин бит «последний алкаш» дип күрсәтелгән.

Ике көннән соң горком егетләре безгә бөтенләй иярми башладылар. Очрашулар тәртибен минем кулга тоттырдылар. Хезмәт коллективларыннан билгеле сәгатьтә килеп алалар, очрашудан соң кире китереп куялар. Очрашу вакытында сайлаучылар кайбер наказларын әйтәләр. Аларын да мин теркәп барам. Ара-тирә Ядкәр Шәфиков шалтырата. Күп сөйләшеп тормый.

— Партиянең Лениногорск шәһәр комитеты сезнең эшчәнлектән канәгать, — ди дә трубканы куя. Горком канәгатьтер дә... Әмма безнең арадагы үзара мөнәсәбәтләребез булачак депутатыбыз белән дөбер-дөбер кайнау ноктасына җитте. Беркөн очрашудан кайткач, аяз күк йөзенә бихисап йолдызлар калыккан матур кичтә, кунакханәгә кереп китәр алдыннан, Ибрай абыем, күзлеген сөртә-сөртә:

— Син, энем, чыннан да шома егет икәнсең, ничәнче көн минем тирәмдә ни дип бөтереләсең? Язучылар берлегенә керәсең киләме? Әллә китап чыгарып булмасмы дип чуаласыңмы? — диде. Сүзләрен сирәк тешләре аша сыгып чыгарды.

Олы язучы, Язучылар берлеге рәисе, сиңа базар карчыгы түгел, тупас сүзләр әйтеп орышмас ич инде. Әмма минем өчен аның бу сүзләре бик тупас тоелды. Минем дә түземлегем соңгы чиккә җиткән булгандыр.

— Ибраһим абый, авырга алма, яме. Сез мине сөймәгән кебек, минем дә сезне күрәсем килми. Коммунист буларак, горком кушканны үтәп йөрим бит. Үтәмәсиең дә, шушында яшисе бар. Бер поручение биргәниек, шуны да үтәмәде, диярләр. Сине озатып йөрергә алар куштылар. Шәфиков үзе кушты... Югыйсә ике аягымның берсен дә... — дип тездем дә салдым. — Ибраһим абый, тәмам гарык мин сездән...

— Шулай мени-и-и! — дип суздыл ул. Йөзе күзгә күренеп үзгәреп китте. — Ә мин тагын, пеләш бәрән... Син, зинһар, мине гафу ит. Әйдә, кереп чәй эчик.

— Юк, юк, Ибраһим абый, чәйләп тораммы соң! Киттем, киттем...

— «Юк, юк» түгел. Бу юлы менә минем белән чәй эчәргә мин поручение бирәм. Анда бик яхшы бильярд өстәле бар. Бераз шар тәгәрәтеп алырбыз.

Икенче көнне безгә Шамил абый Бикчурин, Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге җитәкчесе Әдип абый Маликов, минем ахирәт дустым Нәҗип Мадьяр кушылды. Ул кичне безгә кунакка кайттык. Мәдинәм-гөлкәемнең әнисе Миңлесәрвәр әниебез күп итеп өчпочмак пешергәние. Компаниясе шундый: бик күңелле итеп сөйләшеп утырдык. Ибраһим абый безгә фронтта дивизия газетасында эшләвен, сугышта күргәннәрен сөйләде.

—Полуторка машинасында алгы сызыктан штабка тораташ булып каткан мәетләр түшәлгән юлдан кайтабыз. Бер урында кар көртенә чумдык. Буксовайт итә башладык. Зыр килеп бер урында әйләнеп утырган арт көпчәкләргә дә, кар астыннан гына өстерәп чыгарып, мәетләр тыгабыз, — диде.

— Кемнәрнеңдер газизләре, бердәнберләренең гәүдәләре бит инде алар! — дидек без, әсәрләнеп.

— Сугыш! Фронт! Алар турында уйлап торырга вакытың бармы диегез. Приказ үтәргә ашык. Үтәмәсәң — трибунал! Анда күп сөйләшеп тормыйлар. Алып чыгалар да шалт маңгаеңа берне! Синең дә үле гәүдәңнең юл түшәргә китүе ихтимал, — дип куйды агабыз.

Аннары ул пианино артына күчеп утырды. Тукайның «Өзелгән өмид»ен уйнады.

И мөкатдәс моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнәмен, айрылабыз, ахрысы!

Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңелем кошы,
Шат яратса да, җиһанга ят яраткан Раббысы.

Булмадың, алтын ярым — салкын ярым, син дә минем
Бер елмаюың берлә тормыш юлым яктырткычы!

Күз яшең дә кипмичә еглап вафат булган әни!
Гаиләсенә җиһанның ник китердең ят кеше?!

Үпкәнеңнән бирле, әнкәй, иң ахыры тапкыр син,
Һәр ишектән сөрде улыңны мәхәббәт сакчысы.

Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы, —

Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы!

Шушы юлларны үзе пианинода уйнап әйтте дә моңарчы бик кырыс күренгән Ибраһим агабыз сулкылдап елап та җибәрде. Маңгаен, йөзен ике кулы белән каплап, инструмент өстенә сыгылып та төште.

— Шуңа күрә дә бөек Тукаебыз дибез аңа. Әнә нинди юллар язган Татар поэзиясенең иң биек Олимпы!

Үз тирәсенә бер ялагайны, бер куштанны якын җибәрмәгән гаять кырыс булып күренгән өлкән каләмдәшебез үтә дә йомшак күңелле булып чыкты.

— Сез, яшьләр, Тукаебызны укыйсызмы соң? — диде ул, яшьләрен сөртеп. — Алдыңда Тукай томнарын тотмыйча, аларга атнага бер булса да күз салмыйча торып, талантлы әсәр язып булмыйдыр ул.

Аннары без тәмләп чәй эчтек. Ибраһим ага әниебезнең өчпочмакларын да мактап-мактап ашады.

Ибраһим абый безгә депутат булгач та килеп йөрде. Сайлаучылары наказ иткән китапханә төзелеше белән дә даими кызыксынып торды. Казанга баргач, теге анонимканы да кулыма бирде.

— Саклама, яндыр, — диде. — Шуны язып утырганчы, матур бер хикәя язса, исеме әдәбиятка керер иде. Достоевский андыйларның йөзен бик белеп ачкан, — диде.

Ул дустым байтактан мәрхүм инде. Мин аңа мыскал да үпкә тотмыйм. Урыны җәннәттә була күрсен. Алга табарак бик хәтәр бер әйбер әйтергә җыенам әле. Аның мәрхүм булуына мин дә сәбәпче түгел микән?

Ибраһим абый, сайлаучылары алдында отчет тотарга килгәндә, мин аны каршыларга Бөгелмә аэропортына барып баскач:

— Син, шома егетем, бу юлы да партпоручение үтәргәме, әллә мине күрәсең килеп ихлас күңел белән килдеңме? — дип елмаеп, күз кысып сорап куяр иде.

Кичләрен ул җәяүле сәйранга чыгарга ярата. Шамил абый Бикчурин белән икәүләп без аны Лениногорскиның әллә нинди почмакларыннан әйләндереп алып кайтабыз. Лениногорскида Муса Җәлил белән бергә әсирлектә булган, аны күреп белгән Зиннур абый Мөхәммәдиев яшәде. Аны күреп сөйләшергә Гази абый Кашшаф та килгәләде. Зиннур абыйның истәлекләрен ул китабына да кертте. Зиннур абый шәһәр читендәгерәк баракның егерме квадрат метрлы гына бер бүлмәсендә биш җан булып яшәп, буровойда эшли. Әле тулысынча акланмаган. Горком кешеләре минем аның янына барып йөрүемне бер дә килештермиләр... Өстәл сукмыйча гына шелтә ясаганнары да бар. Зиннур абыйларга Ибраһим аганы да алып бардык.

— Җәлилне үз күзең белән күрдеңме? Аралаштыгызмы? Ниләр сөйләгәне хәтереңдә? — дип, бик җентекләп сораштырып утырганые.

Беренче китабым

Беренче китабың беренче балаң кебек бик кадерле була икән ул. Беренче китабым «Озын аяк»ны чыгарырга дустым Шамил абый Бикчурин бик булышты. Бу егетне Ибраһим абый да бик ярата иде. Ул аны «турыга үскән җиз кадак» дип йөртә иде. Шамил абыйның озын буйлы вә җиз төсендәге чәчләре өчендер. Шамил абый ач борчак кузагы төсле юка, ә мин биш көн җылы суда тоткан фасоль борчагы төсле йомры. Әкъли белән Чакли инде. Бик тату, бик дус яшәдек без аның белән. Гаять талантлы кеше иде ул. Язучылык хезмәтенең бик нечкә серләрен чиште ул миңа. Бер тәлинкәдән ашаган, һәрчак берәр хәтәр эзләп кенә йөргән тиле башларыбызны бер мендәргә салып йоклаган төннәребез дә күп булды. Бикчи дустым мине үзенә ияртеп Хисам абый Камалга алып барды. 1966 ел инде бу. Хисам абый — Татарстан китап нәшриятында яшьләр-балалар редакциясе башлыгы. Казанда транспорт ягы мәңге-мәңге катлаулы. Метро чын куәтенә сафка баскач, бераз рәтләнерме, юкмы?

Хисам абый сыңар аягы белән кичен өенә кайтып йөри алмый. Трамвай-автобуска әле ике аягың белән дә керешле түгел. Обком кушуы буенча аңа нәшрият каршында гына бер бүлмәле фатир биргәннәр. Нәшриятның байтак эшләрен, үз вазифаларын ул күп чакны шушы фатирыннан торып кына башкара. Авторлар белән дә эшли.

Хисам абый белән Шамил Бикчи — күптәнге ахириләр. Ул бит Шамил абый кебек үк — Әлмәт районыннан. Болар өстенә аның Лениногорскида бертуган сеңлесе дә бар. Җәен туган якларына кунакка кайткач безгә дә килә. Аның кайтуы Шамил абый белән миңа зур бәйрәм була. Машинасын парткомнардан алабыз. Без аны үзе теләгән җирләргә, буровойларга, промыселларга алып барабыз. Шул ягы да әйбәт, ул безнең кесәдән бер тиен дә чыгартмый. Алай гынамы?! Шамил абый белән икебезне һәр кичне «Урал» ресторанына алып керә. Бикчинең җил тегермәне хәтле канатларын як-якка җәеп, изәп-изәп сөйләгәнен сәгатьләр буе тыңлап утыра. Йөзеннән елмаю китми.

— Бикчинең сөйләгәннәре бары да дөресме соң? — дип, миннән сорап куя әле.

— Булмыйча! Үзем шаһит! — дип куәтлим.

Казанга бу килүебездә дә туп-туры Хисам абыйның Островскийдагы фатирына киттек.

— Ләбибә, монда кереп чык әле, — дип, ул нәшриятка шалтыратты, Ләбибә апа Ихсановаы дәште.

Ләбибә апа Хисам абый редакциясендә, аның кул астында эшли, редактор. Ләбибә апа тиз арада кереп тә җитте.

— Шамил бик талантлы бер егет алып килгән. Менә үзе дә монда утыра. Шуның китабын быелгы ел планына керт тә җибәр, — диде.

— План расланган бит инде.

— Расланса, резервта урын бар бит. Резервтан җибәр.

Шуның белән шалт Мөхәммәтҗан! Мәсьәлә хәл ителде дә куйды. Ләбибә апа, матурым, байтак кына яшь авторларның беренче китапларын чыгаргандыр. Минем дә беренче китабымны чыгаруын оныткандыр. Ә мин Ләбибә апаның юбилейларына телеграммалар сугам, күрешкәндә битеннән үбәм. Шушы хәлгә сәерсенеп, аптырап калучылар да була.

— Ләбибә апам — минем беренче китабымның редакторы! — дим мин аларга.

Аннан соң өч китабымны Мәхмүт абый Хөсәен чыгарды. Шулай ук дөнья бәясе егет иде. Гвардия майоры, тупчы. Аның редакциясеннән дә китапларымның ничек чыгып китүләрен сизми дә калдым. Башка кайбер редакторлар төсле авторның кәҗә маен сыкмый иде ул. Утыра да үзе эшли. Төзәтә. Коррективаларын кертә. Автор стилен дә саклый. Юкса тәмам маемны сыккан редакторларга да эләккәләдем. Аларга да мең рәхмәт. Маемны бит китабым начар чыксын дип түгел, укучы аны кулына бер алгач, бер тында укып чыгарлык булсын дип сыктылар.

Бер җәйне Мәхмүт абый һәм гаиләләребез белән Кырымда украиннарча Коктейбель, Кырым татарлары телендә Күк Түбә дип аталучы иҗат йортында ял иттек. Мәхмүт абыйның белмәгән кешесе юк. Мине Булат Окуджава белән таныштырды. Аның гитарада уйнап җырлавын тыңладык. Сугыш каһарманы, Советлар Союзы Герое, танкист Татьяна Левченко да безнең сменада ял итте. Кара диңгездә хезмәт иткән бер су асты көймәсе коллективы Т.Левченконы үзләрендә чыгыш ясарга кунакка дәшкән. Безнең иҗат йорты «Голубой залив»та урнашкан. Моряклар су асты көймәләрен ярдан бер чакрымнар эчтә туктатканнар. Ярга катер белән чыктылар. Мәхмүт абый — бик көчле трибун. Шигырьләрен дә яттан бик оста сөйли. Моряклар арасында үземә генә кыен булыр дип, Левченко үзе белән Мәхмүт абыйны да дәште. Мәхмүт абый мине дә иярте. Ул заманда су асты көймәсенә эләгү өчен Мәскәүнең үзеннән рөхсәт кирәк иде. Ә Татьяна Левченко — Советлар Союзы Герое, Мәхмүт абый — сугыш ветераны, гвардия майоры. Ә минем белән «вакланып» та тормадылар. Бик матур, бик күңелле чыгыш булды ул. Соңыннан безгә армейский йөз грамм бирделәр, украин борщы белән сыйладылар. «Командирские» дигән циферблатлары төнлә дә янып торган кул сәгатьләре бүләк иттеләр.

Шулай бер кичне, диңгез ярында учак ягып утырганда, Мәхмүт абыйга урыс шагыйрьләре төрттерә башладылар:

— Махмут, какой ты поэт? Вот сочини нам тут же двоестишие, скажем, про... буи, что качаются на волне.

— Вот в море лежат, на волне качаются буи, похожие на русские ...уи! — дип, шундук әйтеп тә салды.

Ah итәрлек шигырь юллары түгелдер, әмма шундый чакта югалып калмавы исне китәрә Мәхмүт абыйның. Иҗат йортыннан без аның белән нык дуслашып кайттык. Кызык, кешегә ярдәмчел, колоритлы егет заты иде.

Хәзер уйлап-уйлап куям да, карале, язмыш мине нинди олуг затлар, әдәпле, ярдәмчел кешеләр белән таныштырган, эш йөрттергән икән дип сокланам, сөенәм. Кызганыч ки, күбесе юк инде дөньяда. Берәм-берәм әлеге моржасыннан төтен чыкмый торган, тәрәзәсез, ишексез йортка күчеп баралар. Алар адресына әйткән җылы сүзләрем якты рухларына изге догалар булып иңсеннәрие!

* * *

Мин бит әле һаман да берлек әгъзасы түгел. Ибраһим ага исән булса, аның «шома егет»е булып шалт кына кереп китә идем дә... Ул көтмәгәндә генә йөрәге тотып вафат булып куйды. Минем заманда Союзга керү өчен ике китап авторы булу кирәк иде. Бер карасаң, әллә ни кыен шарт та түгел. Әмма бу шартның төбендә бик мәкерле бер хәйлә ята. Китабымны чыгарыгыз әле, дип, нәшрият каршына бару өчен берлек әгъзасы булу кирәк. Чөнки син — профессиональ язучы. Ә әгъза булу өчен кимендә ике китап чыгаруың шарт. Койрыгын алса, томшыгы ябыша, томшыгын куптарса, койрыгы ябыша. Ләкин мине ике китабым чыгу белән генә берлеккә якын да китермәделәр. Алты китап чыгаргач кына алдылар. Берлеккә керү өчен, иҗатлары алдында син баш игән һәм алар да сине таныган өч язучыдан җылы гына рекомендация кирәк. Аларын гына мин дә юнәткәнием. Алмадылар. Аннары мин сигез рекомендация китердем. Соңыннан уникегә җиткердем. Миңа рекомендация бирүчеләр арасыннан

Г.Минский, Б.Камалов, Р.Төхфәтуллин, Х.Сарьян, Х.Камал, Г.Әпсәләмов, Р.Фәйзуллин, А.Расих, Х.Туфан исемнәрен бүген дә тирән ихтирам хисе белән искә алам.

Берлеккә керергә беренче омтылыш ясаганда алмауларының сәбәбе мондый булган. Рекомендацияне беренче булып миңа Габдрахман ага Минский язды. Дөньяга объектив карашлы, бик күркәм кеше иде ул. «Казан утлары»нда басылган хикәяләремне укыган да:

— Нишләп читләтеп кенә йөрисең? Әйдә, союзга керергә әзерлән. Рекомендацияне үзем бирәм, — диде.

Ул чакта кабул итү комиссиясенең рәисе Фатыйх ага Хөсни иде. Аларның арасына кара мәче йөгергән чак булган икән. Берлеккә Габдрахман ага Минский тәкъдим иткән егетне алсалар, аның төркеме көчәя төшә бит. Стоп! Ашыкмасын әле. Фатыйх абый миңа отказ бирдерә. Минем кем икәнне белеп җиткермәгән, ахры, картлач. Минем тел бит беләүләгән пәке, бритва. Тормышта «янсам» да, шул телем аркасында гына «яндым» инде. Әле хәзер дә, урамга-мазар гына чыкканда да, Мәдинәм-гөлкәем миңа, таныклык кенәгәңне алдыңмы, дими, авызыңны клейлы тасма белән ябыштырып чык, зинһар, ди. Югыйсә бер чыгуда урамнан биш дошман табып керәсең, ди. Әлбәттә, начар гадәт.

Ул чагында, җай килгәндә, Фатыйх абыйны да «чукып» кына торам.

— Гариф абый Ахунга яраргa тырышып, бик җитди әдәби җыеннарда проблемалар күтәрәсе урынга гел буш сүзләр сөйлисең, публиканың башын төрле уен-көлке белән катырасың, — дип тә «чукып» алганым булды.

Ярты взводка торырлык күренекле язучыларыбыздан рекомендацияләр китергәч, берлеккә мине барыбер алдылар. Кабул итү комиссиясе рәисе урыны да атаңнан калган мирас, патшалык түгел. Аны да корылтай саен алыштырып торалар. Кулында власть барында гаделсезрәк кыланuыннан Фатыйх ага да минем алда уңайсызлана төсле. Кеше дигәнең олыгая барган саен йомшагракка әйләнә, авыр сүзне дә кичерә, читкә тайпылып, ашыгучыга юл куя. Яшьләр исә кечкенә генә җәберне дә онытмый, аларга гафу итү хисе дә ят. Мин дә, Фатыйх абыйны күрү белән, йоннарымны күпертәм. Бу үпкәне күпмегә сузарга була, пнимаешь? Әдәби ел йомгакларының берсеннән соң, нәшрият баскычыннан төшкәндә, Фатыйх абый минем җиңемнән тотты.

— Альберт, энем, синнән йөз сум, миннән йөз сум. Брудершафт ясыйбыз. Киттек «Кызыл шәрекъ» ресторанына. Канса да канис, безгә аңлашырга кирәктер бит инде, — диде ул. Шап иттереп аркама да сугып куйды.

Мин ике куллап риза булдым. Фатыйх абыйны култыклап алдым. Киттек. Анда бик күңелле итеп утырганнан соң, Фатыйх абый мине үзенә алып кайтып китте. Бу вакытта аның үз җәмәгате мәрхүмә иде. Нәшриятта дүртенче катта машинистка булып тутырган тавык төсле тулы гәүдәле бик матур ханым, Әминә апа эшли иде. Аңа минем дә хикәяләр, повестьлар бастырганым булды. Хатыны мәрхүмә булгач, Фатыйх абый шул Әминә апага өйләнгәние. Мине иәртеп кайтканга Әминә апаның әллә ни исе китмәде. Әмма соңыннан Фатыйх абый нык үкенгәндер. Китә белмичә мин аларның тәмам тәкатен корыттым бугай. Ул көннәрдә футбол буенча дөнья чемпионаты бара иде. Без Фатыйх абый белән иртәнге өчкә-дүрткә кадәр матч карыйбыз. Берсе артыннан икенчесен күрсәтәләр. Аннары көндезге уникегә хәтле йоклыйбыз. Иллә дә нык коры закон игълан ителгән чор бу. Ак башлы яртыны талон буенча гына бирәләр. Фатыйх абыйлар торган йортның аскы катында гастроном. Аның директоры — безнең Биектау егете Мидхәт. Танышып та өлгердек.

— Мидхәт энем, бик кадерле кунагым бар иде бит. Бер коньяк бирә күр, — дип, Фатыйх абый записка яза.

Мин аскы катка төшеп китәм.

— Кадерле кунак, син әле китмәдеңмени? — дип каршылый мине Мидхәт. Алай да шкафыннан бер коньяк чыгарып бирә.

Әминә апа безгә бәрәңге кыздыра. Шул коньяк белән кыздырган бәрәңгене кетер-кетер китереп башны төзәтәбез дә янәдән матч карарга керешәбез. Өч кич кундым мин аларда.

— Әйдә, синең белән күңелле икән. Тагын бер генә матч карыйк инде, — дип, Фатыйх абый мине үзе җибәрми.

Әмма Казан халкында бәрәңге санаулы гына була. Бәрәңге запасларына тәмам корт төшердем бугай мин аларның. Аның каравы тәмам аңлаштык! Бер-беребезгә мыскал да үпкәбез калмады.

Шәҗәрәмә кагылышлы бу әсәремне кече оныгым Биктаһирдан башлаганыем бит. Ходайның рәхмәтедер инде, әлегә «әннә», «мәммәм» дип тә әйтә алмаган башы белән ике сүзенең берендә «дәти, дәти!» дип кабатлый. «Дәү әтием!» дип әйтергә маташуы бит шук малайның. Хәер, шулай булырга тиеш тә! Шушы сүзнең иң тулы мәгънәсендә ахириләр бит без аның белән.

Шушы тулы гәүдәле матур малайны кочагыма алам да янә тирән уйларга чумам. «И-и Раббым», — дип куям. Мине дә шулай сөйгәннәрдер инде. Күп кешеләр кулында булсам да, аларның барчасы алдында да бурычлы бит мин. Нинди авыр, кырыс елларда исән калганмын. Күзем дә исән, колагым да акмаган. Ачлы-туклы яшәүдән күтәнем дә төшмәде. Югыйсә андый яшьтиләремне дә күп күрдем.

Әйе, әтине хатынлы иттем, үзем әниле булдым. «Әти кәкәй!» дип әйтеп кенә кара, хәзер авызыңа шапылдаталар. Бер-ике тапкыр ярыйсы гына эләкте дә, иренем дә шешеп чыкты. Үзем тапкан Өммегөлсем әниемне мин үз әнием дип кабул итәргә тиеш. Больше никаких гвоздей! Мондый политика алып барырга әле соң түгел. Ул кадәресен үзем дә аңлый-төшенәм бугай. Үги әни нәрсә инде ул, ачуым да бер килмәгәе. Дөньяда үз әниең булсын! Өммегөлсем әнием — минем үз әнием. Бетте-китте и вәссәлам! Моны миннән дә бигрәк әни үзе дә теләде бугай. Без аның белән бик тиз дуслашып, үз кешеләр булып киттек. Ул мине алдына алып сөя. Мондый чакларны минем түбәм күккә аша. Моңарчы ана назы күргән баламы? Кечкенәдән үк үзсүзле бер шыптый бала булганмындыр инде. Йә берәр нәрсәне аударам, йә өй ачкычын яшереп куям. Әти чын педагогика фәне белән бөтенләй таныш түгел. Югыйсә директор үзе. Берни булса, миңа берәрне сыптырырга гына тора. Әни бирми, кочагына ала йә итәк астына яшерә.

Әти ни кырыс торса да, ара-тирә Габдрахман бабам да килеп чыга. Аның гозере бер инде, әтидән мине сорый.

— Габделбарый, әнә яшь хатыныңнан бала-чаганы өй тутырып табарсыз, Әлбиртебезне бир миңа, — дип ялынып, ялварып сорый.

Бер кызы — Мәрьям апам — Мәскәүдә кечкенә кибет тоткач, алтын алка, беләзек-йөзек белән сәүдә иткәч, бабам да авылда урта хәллеләрдән саналган.

— Габделбарый, иң яраткан киявем идең бит. Бир миңа Әлбиртне, башка кешем юк, бар йорт-җиремне, мал-мөлкәтемне аңа калдырам. Игелеген бергәләп күрерсез, — дип ялвара.

Аның елый-елый ялваруын мин дә күреп торам, килеп башыннан сыйпыйм, сакалын сыпырам. Мине хәзер аның кулына сөяргә дә бирмәскә, янына да җибәрмәскә тырышалар. Кече Кавалда әбием-бабаем барын мин бөтенләй онытырга тиеш икәнмен. Әтиемнең, үз әнием Шәрәфелбәнатның әтисе Габдрахман бабамны, бүтән киләсе булма, гаиләмне бутап йөрмә, күземә дә күренмә, дип куып чыгарган чаклары да булды. Өммегөлсем әнием алай да бабамны почмак якка гына дәшеп чәй эчертә, әбиемә күчтәнәч итеп чәй-шикәр төргән төенчек тә тоттыра иде.

Әтиемне һич кенә дә танылган сәүдәгәр Әбү-Бәкер агасына ияреп бөтен Шәрекъ илләрен йөреп чыккан, аш тәмләткеч товарлар төягән кәрваннарны ком чүлләре аша куган, күп телләрдә сөйләшкән, Казанның Проломный урамында пайлар белән кибет тоткан өлкән приказчик Хәсән бабамның улы димәссең. Кеше дигәнең һай ничек үзгәрә! Ул — гамәлдәге системаның үз баласы. Система аның миен үз идеологиясе белән мөлдерәмә итеп сугарган. Әйе, аның яраткан җыры да:

Итек, шинель, фуражканы
Без киябез бит аны.
Яшәсен совет власте,
Без сөябез бит аны, —

булырые.

Системаның төпле ышанычлысы иде ул. Теленә килгәнне сөйләде, бернидән куркып тормады. Пышылдап кына сөйләшкән чагы булмады. 1937, 1947, 1952 үтә кырыс репрессия елларында да аңа ник берәрсе кырын карасын! КПССның Дөбъяз райкомы пленумнарында кайчак бик кискен чыгышлар ясаган чаклары да булды. Залдагылар исә аның чыгышларын, партия халыкка дөресен ярып салырга тиеш, дип кул чабып кабул итәләр иде. Алай да инде Ватан сугышыннан соң язмыш аны корулы мылтыгын прәме маңгаена терәп бик нык сынап алды. Өлешеңә тигән көмешеңнән авыз итми булмый икән ул. Хәер, болары турында соңрак сөйләрмен.

Әнигә яучылар килде...

1942 елның язы иде.

Әти беркөнне:

— Броньне алдылар. Үзебезнең Дөбъяз районы егетләреннән тагын бер полкмы, батальонмы туплыйлар. Мине шунда комиссар итеп билгеләделәр, — дип кайтты. — Әнисе, син миңа юл капчыгы җый, бераз сохари, бер пар җылы оекбаш тык.

Әнинең кулында елак сеңлем Гөлкәй. Әнвәр абый Казанга барып хәрби заводта токарь өйрәнчеге булып эшләргә урнашып кайтты. Башына яңа бүрек кигән. Өстендә зәңгәр бушлат. Билен каеш белән буган. Аягындагы калын олтанлы ботинкасыннан бик тәмле булып ачы дегет исе килә.

— Син анда, энем, дөнья хәлен белеп булмый, минекеләрне ташлап бетермә, ни дисәң дә, син — егет кеше, — дип озатты аны әти Казанга.

Әнвәр абый, чыннан да егет булып җитлегүен раслап, кесәсеннән «Прибой» папиросы чыгарды. Аны кабызды. Берне әтигә дә сузды. Башка чак булса, әти аның кирәген биргән булыр иде. Хәзер исә папироска иртә үрелгән энесенә акыл бирep торыр чакмы?

— Энем, иртәгә мин дә фронтка чыгып китәм. Әллә кайтам, әллә юк... Кайтмасам, җиңгәңә балаларны үстереш. Берүзенә генә кыен булыр, — диде. — Авыл советы Айсылу белән сөйләшеп кайттым. Сезне өч атка төяп, Ташлы Кавалга илтеп куячаклар, — дип, әнигә дә сүз катты. — Сугыш әллә ни озак бармас. Мин әйләнеп кайтканчы шунда торып торырсыз. Ризамы шуңа?

Риза гынамы соң? Ташлы Кавал — Өммегөлсем әниемнең туган авылы. Анда аның үз йорт-җире белән әнисе Шәрифә әбием яшәп ята.

Шәрифә әбием гомере эчендә ундүрт бала тапкан. Шуларның икесе генә исән. Берсе — улы Шәйдулла абый, икенчесе — минем әнием Өммегөлсем. Шәйдулла абый әле өйләнергә дә өлгермәгән. Сугыш башлану белән аны фронтка алганнар. Шуннан аның бер хәбәре дә килмәде. Әбием аны соңгы сулышына кадәр көтте. Китап ачтырды да китап яптырды. Сандыктан буй-буй зәңгәр сатин күлмәген ала. Ука белән чиккән камзулын кия. Бер генә таба төче коймак пешерә дә, аны каз мае белән майлап, югары очтагы багучы, китап ачучы Әсмакамал апайларга менеп китә. Шәйдулла абыйга китап ачтыра. Әсмакамал апай да бик хәйләкәр. Шәйдулла абый, бәлкем, сугышның беренче көннәрендә үк һәлак булгандыр. Бер хәбәре дә юк. Хәрби комиссариат та ләм-мим.

Фал китабын ачып җибәрү белән:

— Шәйдуллаң исән бит, Шәрифәҗамал. Беләсеңме, кайтырга җыена бит бу егет. Түлке нәрсәдер итәгенә чорналып тота балакайны. Җибәрми генә. Юкса үзе бик талпынып та карый, — дип сүзен сүзгә укый Әсмакамал апай.

Дипломат булгандыр ул. Беренчедән, әбиемнең өметен сүндерәсе килмәгәндер... Икенчедән, «Улыңны көтмә инде. Шәйдуллаң һәлак булган», — дисә, әбием аңа төче коймак тыгып бүтән менми бит инде. Багучы апайның дипломат булмый хәле юк. Бу кадәресе инде сугыш бетеп, байтак еллар узганнан соңгы хәлләр. Әсмакамал апайның шушы сүзләреннән соң әбиемнең йөзе ачылып китә. Бик матур карчык иде ул. Дөньяда мин эчкерсез ярату белән яраткан затларның берсе иде.

— Әсмакамал, әйтеп кенә бетермисеңдер. Берәр маржага өйләнгәндер ул. Йә йортка кергәндер. Мимеч җирендә калгандыр. Ул мимеч маржаларын бик чибәр диләр бит. Шул маржасы җибәрми торгандыр. Әйтеп бетер барын да! — дип, әби Әсмакамал апайдан фал китабында ачылганнарның барын да укып бетерергә куша.

Шәрифә әбием бик булган, бик уңган, бик зирәк акыллы карчык иде. «Әбием ядкаре» дигән, соңыннан «Дружба народов» журналында «Несказанный свет» исеме белән басылган повестемда аның кабатланмас образын иркенләп бирдем. Повесть журналның премиясенә лаек булды. Журналның ул чактагы баш редакторы, күренекле шагыйрь Сергей Баруздин аның хакында: «Один из талантливейших вещей литературного года», — дип язганые. Ул, гомумән, татарларны бик ярата иде. Шоферы да татар егете. Җитмәсә, чыгышы белән безнең Лениногорск районы Бәкер авылыннан.

Мин Мәскәүгә китап чыгарырга килгән чакларны Сергей Алексеевич миңа:

— Альберт, моя «Волга» в твоем распоряжении, — дип әйтер иде.

Мәскәүгә килгән кеше күбрәк җир астында, метрода йөри бит. Берни күрми. Ә Мәскәүдә үз күзең белән күрергә кирәкле тарихи урыннар санап чыккысыз. Сергей Баруздинның шоферы Исмәгыйль белән без Мәскәү урамнарын айкыйбыз гына. Сергей Алексеевич ул чакта СССР Верховный Советы депутаты. Шул хокук белән ул мине иң дәрәҗәле «Москва», «Россия» кунакханәләренә урнаштыра, кайтканда поездга билет алып бирә. Минем дә аңа нинди дә булса яхшылык эшлисем килә. Ул моны сизә. Танылган шагыйрьгә, СССР Верховный Советы депутатына нәрсә эшли алам инде мин?!

— С тебя, дорогой, я требую только одно. Принеси в мой журнал еще и еще такие же талантливые произведения, — дип аркамнан кага.

...Сүзем сугыш чорында калган иде бит. Мәктәптә укыткан әнине район мәгариф бүлегенә инспектор итеп куйдылар. Сугыш бара дип кенә бер бала да мәктәптән читтә калмасын дип, ул район авыллары буйлап чаба башлады. Әбием белән икәүләп без аңа чабата ясап өлгертә алмыйбыз. Бер кием чабата аңа бер әйләнеп кайтуга да түзми.

Сугыш башлануга ике-өч ай да узмагандыр, йорт-җирләре безнең бакча артында гына булган Шап-Шап Шакирның улы озын Вәлиәхмәт абый, уң кулын янбашыннан ук өздереп, фронттан кайтып төште. Үзе болай җил тегермәне буйлы егет. Алар яшьлекләрендә минем Өммегөлсем әнием белән бераз йөргән булганнар. Йөргәннәр дип, бер очта яшәгәч, күрше егете Вәлиәхмәт абый әнине бер-ике тапкыр кичке уеннан озата кайткандыр инде. Вәлиәхмәт абый әле өйләнмәгән. Аны бер кулсыз килеш сугышка да бүтән алмаячаклар. Ә минем әни, әти фронтка киткәч, мин үгиен ияртеп, сеңлем Гөлкәй белән Ташлы Кавалга, әнисе йортына кайтып төште. Әти фронтта, хат-хәбәре дә юк. Әллә кайта, әллә күптән инде батырларча һәлак булган. Менә, малай, әнине яшьли йөргән егете Вәлиәхмәт абыйга димли башладылар. Бу никахка мин дә, сеңлем Гөлкәй дә әллә ни комачаулык итмәскә тиеш. Сеңлем Гөлкәй — чирләшкә. Менә-менә үлеп куюы бар. Ә мине — Казанга, детдомга!

Көннәрдән бер көнне Вәлиәхмәт абыйлардан яучылар менде. Вәлиәхмәт абыйның апасы белән ике сеңлесе әнине яшь чагындагы мәхәббәтенә кыстап-кыстап димлиләр. Бишектәге авыру сеңлем бүген булмаса, иртәгә үләсе. Ә мине Казанга озатырга киңәш итәләр. Кирәксә, үзебез булышабыз, диләр.

— Бу маңка малайның әтисе коммунист бит. Ә коммунистларның ятимнәрен Казанда җыялар икән. Ач та, ялангач та булмас. Аларны анда әйбәт ашаталар, җылы кием дә бирәләр икән, — диләр. Миннән дә котылгач, әни бөтенләй ирекле каласы икән. Вәлиәхмәт абыйның бер сеңлесе — авыл советында секретарь, икенчесе — салым җыю инспекторы.

Беркөнне болар мине туп-турыдан Казанга озатырга кирәкле кәгазьләрне үк тотып килеп керделәр. Ул детдом дигән җирнең мин нәрсә икәнен дә белмим. Казанда да булганым юк. Әмма мине коточкыч бер җиргә озатырга йөрүләрен сизәм. Әни дә өйдә юк, ичмасам. Кайчакларны ул берәр атна йөреп кайта. Түр яктагы зур сәке астына кереп постым болардан. Аннары күз күрер тагын.

— Юк эш белән йөрисез, кызларым, — дип каршылады аларны әбием.

Алар өчесе дә сәкедә утыралар. Мин сәке астында тыңлап ятам.

— Әйе, дөрес әйтәсез, бер сынык ипигә җаның сатышлы. Юк чак. Илдә ачлык. Әмма мин бу малайны беркемгә дә бирмим. Сугыш кырында моңарчы күрелмәгән кан коеш бара. Әнә хат ташучы Расфирә похоронкаларны авылга ташып кына тора. Ир заты кырыла. Сугыштан соң ирләрнең бәясе баш бәясе генә тормас. Ә бу малай бүген үк пычкы башы тота. Ике-өч елдан бөтенләй кул арасына керәчәк. Ундүрт бала тапканымны искә алып, картлык көнемдә Ходай аны миңа бүләк итеп биргән. Игелеген күр, дип. Җүләрләр сез. Бүгеннән кул арасына керергә торган ир затын ятларга бирәмме соң? Үзем ачтан үлсәм үләм, бу малайны гына үстерәм инде. Ир-ат заты булган нигезгә пәри-җен, шайтан ияләшми, мал куна.

— Бу коммунист малаеның ир-атлыгын әйтер идем инде, Шәрифә абыстай, — диде кызларның берсе.

Мин аста барысын да ишетеп ятам. Әбием авызыннан мондый сүзләр чыккач, җан керде миңа. Суган салган кәрҗиннәрне, шомырт-миләш, балан тутырган чүлмәкләрне аударып чыктым сәке астыннан. Карга Әминәсенең ботын тешләп умыруымны бөтен Ташлы Кавал белә. Сәке астыннан пәрәвез челтәрләренә уралып чыктым, тешләремне ямьсез чытырдатып куйдым.

— Апа, бу азгын малайның бик ямьсез тешләшә торган гадәте бар. Беләгеңнән каптырмасын, — дип, кызлар, берсен-берсе кисәтеп, тизрәк чыгып ычкыну ягын карадылар.

Әбием дә күз кысып алды. Тешләремне шытырдатып, өстәвенә һау-һау дип өреп, кызларны капка төбенә хәтле озата бардым. Берсенең юри генә итәгеннән эләктереп тарттым. Шыр-шыр кычкырып качтылар кызлар.

Ашыйсы ризыгы бетмәсә, адәм баласы хәлләнә икән. Сеңлем Гөлкәй дә күзгә күренеп тернәкләнә башлады.

«Эчке этләр министры»

Ошбу җиһанда яшәгәч, тереклек иткәч, һәркемнең тормышында үзенә бер куанычы, сөенече, мактанычы һәм дә горурлыгы буладыр инде ул. Ә минем куанычым, мактанычым, горурлыгым әтием булды. Мин аны бүген дә, үзем оныкларымның дәү әтисе булгач та, өзелеп сагынам. Исән булсамы әгәр?! Өрмәгән җиргә дә утыртмый, учымда гына кадерләп йөртер идем. Һай матур да, үзенә бер сөйкемле егет иде ул. Ә тормыш аны күп тапкырлар бөгеп-бөгеп китереп сынады. Әмма ул бирешмәде. Һаман да матур, сөйкемле булып, үзе яшәгән дөньяны бизәүче кеше булып калды. Ирекле холкы, төпле фикере, мәрхәмәтле, шәфкатьле, һәркемгә ярдәмчел йөрәге белән!

Заманында әти Дөбъяз халкына ник ярдәм итте. Кемнең малаен ФЗӨ мәктәбеннән калдыртты, кемнекен төрмәдән юллап алды. Ялгыз карчыкларның улларын армиядән кайтартты. Грамоталы да булгач, зур урында да эшләгәч, бар халык кайгы-хәсрәте белән безгә килә иде. Килгән кеше идәнеңне таптый, кем килсә дә, булганын өстәлгә чыгарып, чәй куймый да хәлең юк. Әни бик еш кына аны әрли дә торган иде югыйсә. Хәер, кемнең хатыны иреннән канәгать? Кайсы хатын иренең бар гамәлләрен хуплап, «җә» дип кенә тора? Анысына инде барыбыз да күнегеп киләбез. Иң яхшысы — алар белән булашмау, бер тоткан юлыңнан атыңны куалау.

Әти искитмәле йомшак-мамык телле, җор телле иде. Ике сүзнең берендә калҗа-калҗа юмор, шаян сүз катыштырып җибәрә. Һәр гаиләдә була торгандыр инде ул, атаң-анаңның яшәү рәвешләреңә дә, сөйләмнәреңә дә әзрәк тәнкыйть белән карыйсың бит. Алтынның кадерен базарга чыккач кына беләсең. Мин дә шулайрак идем. Әтинең никадәр уникаль булуын дөньяга чыккач кат-кат төшендем.

Өйләребезгә көлеп, елмаеп, шаярып килеп керүче «Чаян» журналын байтак еллардан бирле Рәшит Зәкиев җитәкли. Рәшит, Казан университетын тәмамлаганнан соң, юллама белән безнең Дөбъяз районы «Колхозчы» газетасына әти кулы астында эшләргә кайтты. Мин ул чакта әле институтта укып йөрим. Әти аны үз улы кебек кабул итте. Мин кайчакларны хәтта алардан көнләшәм дә. Кара айгырны җигеп, тарантасның түренә утырып, икәүләп авылларга чыгып китәләр. Аннан рәхәтләнеп укый торган, матур,

мамыклы тел белән язылган мәкаләләр пәйда була. Рәшитнең мәкаләләре аеруча җанлы чыга. Аларда әтинең йогынтысы да сизелә. Шуңа күрә мин хәтта бүген дә, Рәшит дустым белән күрешкән саен:

— Их, Рәшит, молодец егет тә булып чыктың бит. Әтинең бар тел байлыгын үзеңә йоктырдың бит, — дим.

Рәшит Зәкиев — Азнакай районы Тымытык авылыннан, муллалар нәселеннән. Төпле гаиләдән. Аның бертуган абыйлары да икешәр институт тәмамлаган егетләр.

Рәшит исә «әтинең бар тел байлыгын үзенә йоктырдың» дигәнгә, күзләрен хәйлә белән генә кысып, мыек астыннан матур гына елмая.

— Барый абыйда тел байлыгы миңа да, сиңа да җитәрлек иде. Сыкранма, синең дә кесәң буш түгел, язган бер әйбереңнән Барый абый теле, сүзе, фикерләве сизелә, — ди. Һәрхәлдә, моңа икебез дә шат.

Алдагы бүлектә мин әтинең, Ватан сугышы башлангач, бер авыз сүз русча белмәгән, кулларына мылтык та тотып карамаган ярау гәүдәле район егетләренә комиссар булып, сугышка чыгып киткән җирендә туктаган идем. Аларны башта сугыш уеннары уйнатырга Суслонгерга җибәргәннәр. Анда эләккән бәхетсезләрнең ничек ачтан кырылулары турында белмәгән кеше юктыр. Әсәремнең бу урыннарын аеруча шәрехләп менә ни өчен язам. 1942 елның салкын кыш урталары бу. Сугышка алынасы яшьләрне утыз-кырык кеше туплыйлар да, әлдермешләрне — Алатка, Алат егетләрен Әлдермешкә илтеп, сугыш уеннарына өйрәтәләр. Русча бирелгән команда буенча ятарга, торырга, йөгерергә, шуышырга күнектерәләр. Аларны өйрәтүчеләр инде сугышта булып бер кат яраланырга өлгергән солдатлар булдымы икән соң? Әмма барысы да рәхимсезләр иде. Безнең Ташлы Кавалга да иллеләп егет китерделәр. Колхоз аларны ашата, кундыра. Шушы рәхимсез инструкторлар типсә тимер өзәрдәй, тегермән ташын тауга каршы тәгәрәтердәй егетләргә «солома!», «сено!» дип кычкырып торсалар да, тегеләре сафларда абынмыйча гына йөреп килә алмыйлар. «Скоты!» дип кычкыралар аларга инструкторлар, кулларындагы шома чикләвек таяклар белән яралар гына бичараларны. Кай җирләренә туры килсә, шунда сугалар. Мин дә, биш яшь тирәләрендәге малай, күрше малайлары белән көн буена шул бичаралар белән бергә. Артларыннан калмыйбыз. Шушы хәлне күреп, авыл халкы зар елый. Ә минем Шәрифә әбием яшь рекрутларның җилкәсендә чикләвек таягын аеруча җитез уйнаткан бер инструкторның кулын барып тоткаными, теге урыс әбиемне сукты да очырды. Аның итәгенә мин барып ябышканыем, әлеге урыс мине күтәреп алып, айкап торып, кар көртенә тондырды. Чак муеным сынмады. Алай да чикләвек таяк маңгаена туры килеп башы тишелгән бер егетне, канын юып, башын бәйләргә әбием өйгә алып керде. Анысына рөхсәт бирделәр. Әбием беркатлы шул.

— И-и, балакаем, нигә шулай кыйнатасыз? Сез күп бит, — дип сөйләнә.

— Абыстай, мең рәхмәт инде сиңа. Кулларың нәкъ минем әниемнеке төсле йомшак, җылы икән, — дип, әлеге егет йотлыгып-йотлыгып бер касә кайнар чәй эчте. — Әлегә ярамый карышырга. Шундук трибуналга озатачаклар. Менә кулга корал алыйк әле, бу җәберләүләрнең, бу кыйнауларның барын да чыгарырбыз...

— Минем дә бердәнбер улым Шәйдулламны сугыш башлану белән алганнарые... — дип, әбием бу егетнең кесәсен чикләвек белән тутырды, лесникка дип хәстәрләп куйган тураган тәмәкесен бирде, иптәшләреңне дә сыйла, балам, дип, куенына бер түгәрәк ипи тыкты.

Бер капчык сохари киптереп, ун стакан тәмәке туплап, Суслонгерда иза чиккән әти янына әни дә барып кайтты. Аннары аннан байтак кына хат килмичә торды. Кара көзлектә, шыбыр-шыбыр яңгыр яуганда, капканы шакыдылар. Бу юлы аны әни чыгып ачты. Ир тавышы. Әти тавышы! Мин сикереп торып басканыем. Әни, кереп:

— Ят! Тыныңны чыгарасы булма! — диде.

Теге ир дә шуның белән юк булды. Әти булган ул. Аны мунчада яшереп тотмакчы булганнар. Яшерерсең, бар! Ташлы Кавал халкының белмәгән нәрсәсе бармы соң аның? Әтиләрне Суслонгердан поездга төяп, Мәскәү юнәлешенә озатканнар. Мәскәүгә тәмам килеп җитәрәк алар составын немец самолетлары бомбага тотарга керешкән. Төн. Дөм караңгы. Ә самолетлардан немец десантчылары коела. Ә боларда бернинди корал да юк. Бомбежкадан исән калган солдатлар урманга сибеләләр. Әти дә йөгерә. Составның тетмәсен тетеп бетерәләр. Исән калганнарны баштанаяк коралланган десантчылар кыра. Әти ничек кирәк алай, үз бәхетеннәнме, балалары бәхетеннәнме, исән кала. Соңыннан кемгәдер күренгәндер, учетка-мазар баскандыр. Аны бер атнага гаиләсенә җибәргәннәр. Ә халыкка күренергә теләмәвенең сәбәбе бар. Аның кайтуын да күргәннәр, кем капкасын шакуын да күреп калганнар.

— Барый, минем Габидуллам кая, минем Шәүкәтем кая? — дип, күрше хатыннары килә башлаган.

Аларга ул барын да сөйләп тормагандыр, һәркемгә күңел юатырдай сүзен тапкандыр. Әмма бу турыда ул озак еллар узгач кына, бик нык салган чагында гына елый-елый искә алгалый иде. Тиздән аны янәдән военкоматка чакыртып алдылар, тагын фронтка чыгарып җибәрделәр.

Әмма язмышның аны иң кырыс кыскычлар белән сынавы сугыштан соң булды. Ул инде Дөбъяз районы «Колхозчы» газетасын чыгара иде. Сугыштан соңгы елларда Казан халкының урта хәлле гаиләләрендә ял көннәрендә Кабан күленә көймә белән чыгу модасы бар иде. Кеше арасында көнчелек-

соклану белән телгә керәсең килсә, көймә белән Кабанга чык. Гармун белән! Бүген Канар атауларына барып гаиләң белән ял итү чүп ул. «Алар үткән ялда Кабан күленә көймә белән чыкканнар!» дигән сүз — «бәхет» төшенчәсенең ул чактагы иң биек ноктасы. Яңа бистәдә үз өйләре белән торып, 22 нче заводта өлкән мастер булып эшләгән Рәхимҗан абыйларга без дә гаиләбез белән кунакка килдек. Рәхимҗан абый Җәнбәтләр нәселеннән, әтинең якын туганы. Үзләре дә безгә бик еш кайталар. Ул көймәләрне шунда яр буенда прокатка биргәннәрдер инде. Аңа кимендә ун-унике кеше сыя. Кабан буйлап сәяхәткә чыгучылар ашарга-эчәргә алалар, һәр көймәдә гармунчы. Чыр-чу, бала-чага. Мондый көймәләр белән су өсте тулы. Әмма бер көймә икенчесе яныннан узып киткәндә, хуҗалар бер-берсе белән, моңарчы таныш булмасалар да, туганнарча сәламләшәләр. Бер-берләренә үзләренең әче балларын татып карарга тәкъдим итәләр.

Шулай бер тапкырында без ярдан кузгалып кына киттек. Бөтен Кабан өстен тутырып «Рамай» көен суздырырга дип, Рәхимҗан абый кулына тальянын гына алды, ат менгән берәү безне, кулын изәп-изәп, ярга чакыра.

— Булмас ла. Безне чакыруы түгелдер. Башка берәүне дәшәдер, — диештеләр безнекеләр.

Әти алай да ярга таба ишәргә кушты. Чыксак, кара айгырны ак күбеккә төшергән кеше — шагыйрь Самат абый Шакир. Ул чакларда ул әтидә җаваплы секретарь булып эшли иде. Миңа яшь чагымнан ук язучы булмыйча, башка һөнәр иясе булырга хут та булмады. Әтинең бар дуслары — язучылар. Мөхәммәт абый Садри белән детдомда бергә үскәннәр. Безгә Кави Нәҗми, Әхмәт Ерикәй кайта иде. Чөнки Ашыт якын. Әти аларны Ашыт буена балыкка алып йөри. Дөбъяз үзе дә Казанга терәлеп кенә тора. Казан халкына авыл катыгын соңгы елларга хәтле Дөбъязлар ташып торды бит инде.

Самат абый белән әти бик шомлы кыяфәттә нидер пышын-пышын сөйләшеп алдылар. Әти, бичаракаем, күз алдында коелып төште. Самат абый кесәсеннән алып аңа ниндидер кәгазь кисәгеме, газетамы бирде. Шуны тотып, әти айкала-чайкала көймәгә керде. Без барыбыз да тыныбыз катып тора бирәбез. Әти, көймә читенә утырып, газета битен ачты, уйга калды. Үз күзләрем белән укыдым. Анда «Эчке эшләр министры Л.П.Берия» урынына «Эчке этләр министры Л.П.Берия» дип язылганые. Шунда әти: «Беттем!» — диде, пулт итте дә суга чумды. Өстендә җиләп иде аның. Чуму белән генә төпкә китмәде. Аның артыннан суга Рәхимҗан абый да сикерде. Яр кырые булганлыктан, әллә ни тирән дә булмагандыр. Аны ярга сөйрәп чыгардылар. Көймәдәгеләр ни булганын да аңлап бетермәделәр бит әле. Аларга еларга гына булсын.

— Газизнең эше генә бу, — дип ыңгырашты әти.

Газиз абый — редакциядә метранпаж. Алар нигәдер гел конфликтка килеп тораларые. Әллә инде аңа Казанга кунакка барырга кара айгырны биреп тормаганмы әти? Араларында нидер булган инде. Менә хәзер шуның үчен алган булса кирәк. «Эшләр» дигән сүздә «ш» хәрефе урынына «т» хәрефе генә куйган. «Этләр» килеп чыккан. Әмма моның өчен ким дигәндә егерме биш ел төрмә яный.

— Без анда бераз саклык чаралары күрдек, — дип, Самат абый әтине тынычландырмакчы була.

Икесе бер атка атланыпмы дигәндәй, алар шул сәгатьтә үк Дөбъязга кайтып киттеләр.

Мондый ситуациядә, бичара әтиемнең башы шундый хәлләргә тарыгач, бер акыллы агай турында искә алып китми ярамас. Ул чорларда Дөбъяз коммунистларының башында Галим абый Шәмсетдинов тора иде. Галим абый, урыны җәннәттә булсын, әз-мәз генә җыештырып укый, әмма бер сүз дә яза белми иде. Кирәкле документларга «Г» хәрефен генә язып имзасын куя. Партиянең сыналган һәм тугрылыклы улы булгач, шул бик җиткән. Документларның барын да сугыш вакытында Ленинградтан эвакуация белән кайткан бик укымышлы һәм булган ханым Лукоянова алып барды. Ә Галим абый, КПССның Дөбъяз райкомы беренче секретаре булганчы, мондый тормыш юлы уза. Бик ярлы бер агайның улы була ул. Армиягә аны көтү көткән җиреннән алалар. Әфган чигенә эләгә, чик сакларга. Басмачыларның нәкъ котырган чагы әле бу. Көн саен диярлек чикне бозып торалар. Бер кичне Галим абыйны да дозорга җибәрәләр. Чик буена килеп кенә баса, теге яктан, көймәләргә төялешеп, басмачылар кузгала. Ниятләре — чикне бозу, безнең якка бәреп керү. Галим абый каушап калмый. Тревога игълан итә, басмачыларга винтовкасыннан ут ача. Ә тегеләр һаман безнең ярга таба йөзәләр. Кыю егет билендәге гранатасын алып тегеләр өстенә тондыра. Ул шартлый, көймә бата. Ике басмачы бу як ярга чыгып егылалар. Галим абый аларны әсир итә. Ул арада бирегә чик сакчыларының көчле отряды да килеп җитә.

Галим Шәмсетдиновны бу батырлыгы өчен Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләклиләр. Үлгәнче тагарга рөхсәт белән наган бирәләр. Армиядән киткән чагында аның кулына: «Бу егетегезне партия эшендә, җитәкче урында файдаланыгыз. Бик ышанычлы, Ленин-Сталин партиясенең сыналган улы!» — дигән кәгазь тоттыралар. Галим абый сугыш вакытында да, аннан соңгы елларда да бездә беренче секретарь булып торды. Беренче секретарь агаебыз авылларга кешеләрен ат чаптырып, әлеге газетаны әти кайтып җиткәнче үк җыйдырып бетергән. «Колхозчы» газетасының тиражы сигез йөз данә тирәсе. Тапканнарының барысын да җыеп яндырткан. Табылмаганнары да булгандыр. Ул елларда кәгазьгә бик кытлык иде. Мужикларга тәмәке төрергә кәгазь юк иде. Кулларына берәр газета кисәге эләксә, алар аны үлсәләр дә бирмиләр. Бу этлекне эшләгән агай да тик ятмагандыр, Казанга да хәбәр

иткән, күрәсең. Яшерен исем белән генә. Ул газетаны эзләп Казаннан да килеп төштеләр. Берәр шундый газетаны табып булмасмы дип, Черек күл агайлары авылларга да чыгып эзләп карадылар. Тапмадылар. Кулга төшкән газетаны безнең Дөбъяз тәмәке пыскытучылары кире бирәләрме соң? Булмаганны! Әти дә кайту белән үк типографиядә җыйган хәрефләрнең барын да таратты, бәлүкләрне эреттерде. Шик тудырырлык мыскал да эз калдырмады. Бу эштә аңа, берни дә белмәгәндәй, Газиз абый да булышып йөрде. Дошманның иң хәтәре шушындый була торгандыр инде ул. Йөзеңә елмаеп караучысы... Ул чакта әтинең башын элмәккә тыгудан йә мәңгегә Магаданга сөрелүдән райком секретаребыз Галим абый Шәмсетдинов кына алып калды. Соңыннан аларның икесен дә: «ВКП(б)ның кыскача курсы»н яттан белеп кенә бүгенге тормышны гөрләтеп алып барып булмый, картлачлар, укырга кирәк», — дип, партиянең Арча кырында урнашкан Югары мәктәбенә укырга да җибәргәннәрие. Телләренә остарышып, кәрт уйнап, шунда укып яттылар.

* * *

Һай, әти белән уздырган ул мизгелләр! Шулай берчакны, мари авылыннан чыккач, әти киерелеп «Гөлмәрфуга»ны җырлап җибәрде: ятимлек күргәнгәме, яшьли кыерсыту-җәбер күргәнгәме, әти матур тавыш белән бик моңлы итеп җырлый иде. Ә бу юлы үзе яраткан «Гөлмәрфуга»ны күтәренке күңел, яхшы кәеф белән җырлап җибәрде:

Агыйделгә төшә яздым, төшә яздым,
Тотмадың беләгемнән, Мәрфуга!
Ай-ли, Гөлмәрфуга, бар суга.
Гөлмәрфуга, барсаң суга,
Сөйләшербез барсын да.

Әтинең матур, моңлы тавышы, кайтаваз булып кайтмыйча, тын гына тугайларга тарала. Кара айгыр да, җыр тыңлый-тыңлый, ипле генә юырта. Нинди матур мизгелләр кичергән чаклар булган икән дөньялыкта. Рәхәтләнеп, сагынып бер искә алып сөйләрлек мизгелләр!

Контра Шәйхи

Ә менә Шәйхи бабамның җыры бөтенләй башкача иде. Совет властен минем Шәйхи бабам кадәр күрә алмаган, аның пычракка кадалуын теләгән тагын берәр җан иясе булдымы икән ошбу җиһанда? Яшерен-мазар, эчтән генә сыкрап түгел, ап-ачык төстә, баш очында ике потлы гер кадәр йодрыгын янап! Боларын мин кәттә сүз өчен генә, ягъни укучыма әйтәсе сүземнең көчен, тәэсирен арттыру өчен генә язмыйм. Дөресе шулай. Югыйсә әлеге власть Шәйхи бабамның алтын-көмеш белән тулы ювелир кибетен дә таламаган, аңа һәр көнне меңнәрчә сум өстәмә табыш, ягъни прибавочная стоимость китереп торган, бер түбә астында йөзләрчә кеше эшләгән завод-фабригын да тартып алмаган. Властьлар аның ике җил тегермәнен алганнар. Алар өчен генә үчле булмагандыр инде бабам. Тегермәнсез яшәп кара син авыл җирендә! Шунлыктан бер тегермәнен киредән үзенә кайтарганнар аңа. Бу властьны система буларак кабул итмәде ул. Шуның өчен карт башы белән кыенны да күп ашады. Кече Солабашның Каенсар юлы өстендәге тегермәненда котырынып, сүгенеп ятканда, аны еш кына тоталар да Дөбъязга төшереп зинданга ябалар. Башта әле күз төпләре күгәргәнче әйбәтләп кенә яралар да. Ярмаска соң! Һәй, минем артымнан милиция егетләре үзләре менгән икән, дип, алар каршына кулын югарыга күтәреп чыкмый бит ул. Карыша. Милиция егетләре аны дүртәүләп-бишәүләп әвереп алып кына җиңәләр. Берочтан шунда куллары туйганчы тукмыйлар да. Чын контра бит. Аның да ниндие әле! Сугыштан соң без Ташлы Кавалдагы әбием йортын калдырып, Дөбъязга, район үзәгенә күченеп килдек. Әти пролетар кавемнән, системаның нык ышанычлы кадры. Детдомда үскәч, шулай булмый ни. Башта райкомда идеология буенча эшләде, аннары «Колхозчы» газетасын чыгарды. Һәрхәлдә, районда беренче обоймада йөри торган җитәкче.

Кичләрен безгә еш кына районның милиция начальнигы:

— Минем егетләр сезнең теге акылы качкан, җенле абзагызны тагын яптылар бит. Тагын контр сүз сөйләгән, — дип безгә шалтырата.

Аның белән әтинең аралары яхшы. Әти шунда ук милициягә төшеп китә. Шәйхи абыйны алып чыга, кунарга үзебезгә алып кайта. Тукмаганнар бабамны. Йөзенә карарлык түгел. Үзе болай зарланмый. Кыяфәте дә горур, Берлинны алган диярсең. Тагын шунысы гажәп: шушы Шәйхи абыйны әти үлеп ярата. Шәйхи бабай — бер тау байлык калдырып, ике нарасыен ятим итеп, үпкәсе шешүдән нибары утыз җиде яшендә үлеп киткән Хәсән бабамның кече энесе. Безнең Җәнбәтләрдән аермалы буларак, ул мыскал да укымаган, чеп-чи надан. Авылдан да китмәгән. Латин хәрефләрен дә, чуерташ чүпләгән сукыр тавык кебек, бик кыенлык белән генә таный иде. Әмма әти аны бик ярата, әтисе

урынына күрә, беркайчан орышмый. Берәр кич бездә кундыргач, тарантасын җиктереп, янәдән тегермәненә менгереп куя.

Күп тә узмый, салган баштан ул:

— Тиздән совет власте бетә икән! — дип сөйләп куя.

Тегермәндә көн эчендә кемнәр генә булмый. Куштаннар, әләкчеләр Солабашта да җитәрлек. Бу сүзләрен шундук милициягә җиткерәләр. Аны янә алып төшеп ябалар.

— Кем әйтте мондый сүзне? — дип допрослыйлар аны.

— Кем әйтсен? Минем тегермәндә кунып киткән Потаниха, Алат урыслары сөйләп киттеләр. Казаннан кайтышлары иде, шуннан ишетеп кайтышлары.

Потаниха, Алат урысларын эзләп кара син, табарсың, бар. Андый хәтәр сүзләрне алар да сөйләп йөрми инде анысы. Шәйхи абыйның җил тегермәне Казан юлы өстендә. Юлчылар, товар белән йөрүчеләр аңа Казанга барганда да, кайтканда да кунарга керәләр. Атларын ял иттерәләр, сбруйларын көйлиләр. Шәйхи абый болай үзе бик булган кеше. Төнгелеккә атларны куярга өсте ябулы абзары бар. Юлчыларга кереп кунарга чәчрәп тир исе, сарымсак исе, тәмәке, үтә әчкелтем аякчу исе аңкып торган, ике тәрәзәле генә, уртасында тимер мич торган, җәен чебен, кышын кандала котырган өе бар. Май сөрткәнме, бал сылаганмы диярсең, аның тегермәненнән җәен-кышын атлылар, юлаучылар өзелмәс иде. Совет властеннан үчен шулай алган.

Базарга төшкән җиреннән Шәйхи бабам безгә сугылса, әти өстәлгә өйдә булган ризыкның иң тәмлесен куйдыра.

Бабамның ашыкмый гына:

— Менә... Үткән атнаны миндә Әтнә мужиклары кунып киттеләр. Казанга тире төяп илткәннәр... Шуннан кайтышлары. Алар сөйләп киттеләр... — дигәнен рәхәтләнеп тыңлап утыра. Шәйхи бабамның сүзен ни белән тәмамлыйсын белеп тә тора инде югыйсә. «Тиздән совет блачы бетәчәк икән» була инде ул сүз.

Шәйхи бабам турында ни өчен шулай озаклап сөйлим соң? Миңа сигез-тугыз яшьләр булгандыр. Потаниха урысларына утыртып, ул мине үзе белән Казанга алып барды. Бабамның аягында тула оек, яңа чабата. Өстендә изүенә озын итеп ак сәдәф тезгән кызыл сатин күлмәк. Җәй көне бу. Тукай урамында бүрәнәләрдән салган йорт каршында басып торабыз. Төп бабам Хәсәннең асты таш, өсте агач йорты бу. Әтием шушында туган.

— Синең йортың бу, улым! Синеке! Сәүит блачы бетәчәк. Көтәргә күп калмады, — дип сөйли бабам.

Бетәр, бар. 1947–1948 еллар бу. Беренчедән, илдә коточкыч ачлык. Икенчедән, Сталин репрессиясенең яңа дулкыны күтәрелеп кенә килгән чорлар. Ә миңа соң, тугыз яшьлек малайга, ике дөнья бер, уртасы камыр. Мин гамьсез калып кулымдагы туңдырманы ялыйм. Авылда үскән малайга күргән нәрсәме?! Туңдырма түгел, төшеңә кермәстәй бәхет минем кулда. Бабам да бик кадерле!

Әлеге йорт алдына Шәйхи бабам мине тагын ике-өч мәртәбә алып килгәләде әле. Аның иң кызыгы шунда. Гомерлек ярым итәргә җыенган Мәдинәм-гөлкәем белән йөри генә башлаган чагыбыз. Конкурентларым муеннан ашкан. Кәләшемне кулыма ныграк ияләндерү максаты белән, әлбәттә, аны да мин хуҗасы булырга тиешле йорт каршына алып килдем. Әйе, ул чорда анда 17 нче даруханә иде бугай. Күрсен, янәсе. Әлегә пружиналары идәнгә хәтле сыгылган караватта, тулай торакта яшәп ятсам да, көтүчеләр, тире җыеп көн итүчеләр нәселеннән түгел. Без «Җәнбәт җәвере — җиде табын»ныкылар! Мәдинәм-гөлкәемнең исе китте. Кыз чагында ул ирис конфеты ярата иде. Кесәм тулы конфет булмаса, мин аны свиданиегә дәшмим дә. Үзе дә чыкмаска мөмкин. Ул инфакта укыды. Берьюлы ике чит тел өйрәнүе җиңел түгел. Дәресләрне бик күп бирәләр аларга.

Укыган чакта матди яктан начар яшәмәдем. Елга порты, Усия, Бакалтай бар ич. Беләкләр таза, җилкә киң. Портка төшәбез дә пароходтан, баржадан паркет, цемент, карбыз бушатабыз. Икенче, өченче курсларда укыганда радиога хәбәрләр дә яза башладым. Татарстан радиосының «Соңгы хәбәрләр» редакциясендә Иванова фамилияле, «Казбек» папиросын авызыннан өзмәгән юан гына бер яһүдә ханым бар иде. Үзебезнең институт тормышыннан ике-өч хәбәр китерү белән ул миңа «Внештатный корреспондент Татарского радио» дигән таныклык бирде. Аның белән башта бүлмә малайларын шаккатырдым. Минем белән тупасрак сөйләшеп карагыз хәзер! Эльс Адылов белән бер бүлмәдә тора идек. Миннән күрә ул да радиога ияләште. Эльс соңыннан гына Гаделевкә әйләнде. Кабатланмас көмешчән тембрлы! Эльс Гадел бер дигән диктор булып китте. Соңыннан «Югары категорияле диктор» дигән дәрәҗә дә алды. Аның артыннан Ильяс Латыйпов та радиога китте. Шулай ук безнең бүлмәдән. Ильяс — тумышы белән Шөгер егете. Ул да диктор, русча текстлар укый. Аннары, пенсиягә чыкканчы, Россия радио һәм телевидениесенең Татарстан буенча үз хәбәрчесе булып эшләде.

...Дүртенче курсларны тәмамлап, җәйге каникулларга икебез ике якка, Мәдинәм-гөлкәем — пионер лагерена җәйге практикага, ә мин, Кавказга альпинистлар лагерена — Альпиниадага китәр алдыннан, йөрәк маемны янәдән Тукай урамындагы аскы каты таш, өсте юан бүрәнәләрдән салынган, закон буенча мин аның төп хуҗасы булырга тиешле йорт каршына алып килдем. Килсәкме?! Бүгенге

Татарстан проспектын нәкъ шул заманнарда сала башлаганнарые. Киңәйтеп, бик иркен итеп. Бик зур гер таккан, атлап йөрешле экскаватор өебезне методик осталык белән җимереп маташа бит, әй! Тонна ярым авырлыктагы гере белән китереп суга, колаклар чыңлап китә. Бу йортка бернинди өмет-мазар тотмасам да, егылып китәрдәй булып карап торам. Хуҗаларына иң кимендә йөз еллап кына тугры хезмәт иткән, әле дә таза-нык нарат өйнең бүрәнәләре шулхәтле карышалар, ямьсез чытырдыйлар, сукраналар, бозык, кыллары чамасыз тарттырылган скрипка сымак чиныйлар. Башка сыймаслык фаҗига булып тоелды бу күренеш. Киң проспект салу өчен бу урамны сүтәргә кирәклеген һәркем аңлый. Тик шуны биредә гасыр буе яткан бүрәнәләр генә аңламыйлар, төшенмиләр. Китереп суккан саен чатнап кына сыналар, бахыркайлар. Моны карап тору бик авыр иде безгә. Алай да ике сәгатьләр чамасы торганбыздыр. Китеп кенә булмый. Тузан монда. Йорт иясе җибәрмиме? Тыз да быз машиналар чаба. Чүп төйиләр. Экскаваторчы егет ялга туктагач, түзмәдем, хәрабәгә таба атладым. Аягыма кадак керүе дә бар, абынып егылуың да мөмкин. Әмма бабаң нигезен, атаң туган йортның көлен күккә очырганда алар турында уйлап тормыйсың инде.

Подвал өлешен караганда борынгы бизмән таптым бит, әй! Бераз күгәргән күгәрүен. Күгәрмичә соң? Монда ул күпме еллар ятты икән? Әмма чылбырлары да, җиз тәлинкәләре дә исән. Һәрхәлдә, безнең көннәрдә кулланыла торган үлчәү коралы түгел инде бу. Борынгырак корал. Бәлкем, аннан Хәсән бабам да файдалангандыр әле.

Тузанын кагып, бераз сөрткәләп, бизмәнне портфелемә салдым...

Ни йодрык янаса да, совет властеның беткәнен тәки күрә алмыйча, Шәйхи бабам туксаннарын тутырып вафат булды. Сиксәннән өстә булса да, чабарга түгел, яшьләргә чалгы кайрарга дип, печән өмәсенә алып чыкканнар. Үзе сораган. Утыз градуслы эсседә, бөтенесе дә бераз көн басыла төшкәнне көтеп, агач күләгәсендә ятканда, ник бер утырып карасын, гел аяк өсте булды, дип сөйләде әти.

— Шәйхи абый, утыр, безнең белән бераз ял ит, — дигәч:

— Колынлы бияләр генә ятып ял итә. Ә нәселле чабыш атларының ятып торганнарын күргәнегез бармы? Алар аяк өсте йоклап ял итә, — дип җавап биргән.

Аны җирләгәндә мин булмадым. Вафатын да авылга кайткач кына белдем. Алай да бик еш искә төшә, сагындыра әтиемнең бу абыйсы. Нибары ике җил тегермәнен тартып алган өчен совет властен җене сөймәгән кеше... Үзсүзле, үз фикерле, көчле ихтыярлы матур кеше иде ул. Үзебезнең «Җәнбәт җәвере — җиде табын» ыруыннан!

Бәгырь җимешем

Эш өстәлемә каршы гына шкафта — үзем язган китапларым. Алар ике дистәләп. Эш көнемне еш кына алар белән гәпләшүдән башлыйм. И-и! Барысы да балаларым, оныкларым кебек якыннар. Аларны дөньяга чыгару өчен күпме йөрәк җылысы, күпме акыл көче салынган. Аларны кулларына алып битләрен ачкан укучыларыма акыл, гыйбрәт, киңәш, йөрәк җылысы бирерлек иткәнем өчен, китапларым миңа рәхмәтлеләр. Китап буларак, алар — ике дистәләп. Әгәр роман, повесть, хикәяләр буларак бүлгәләсәң — бихисап! Әле дә, шөкер, кулымнан каләмне төшергән юк. «Нулла диэс синэ линиэа!» — һич югында бер юл да сызмыйча, бер көнне дә бушка уздырмаска! Күп еллардан бирле үз алдыма куйган таләп, яшәү рәвешем бу минем.

Әллә ни мактанырлык булмаса да, бөтен уңайлыклары белән үз өем, гаражда машинам бар. Бакчамда — үзем утырткан алмагачлар. Кайбер агачта дүрт-биш төрле сорт үсә. Андый осталыкка бер күршем өйрәткәние. Ишегалдымдагы бакчама бәрәңге «падишаһ»ны да бик хасиятләп, җаен белеп, көлен сибеп утыртам. Һәр төптән куш йодрык хәтле сигез-тугыз бәрәңге алу безнең өчен гадәти хәл. Еллары белән егерме-утыз баш умарта тоткан чакларым да булды. Тәңре мине шат, булган, кулыннан эш килешле егет итеп яраткан. Өй артымда гына ун чишмә чылтырый. Барысының да исемнәре «Гөл» белән башлана. «Гөлсем», «Гөлнар», «Гөлшат»... Өемнән илле адымнар читкәрәк атласаң, кара урман башлана. Яз башларында шашып-шашып кошлар сайраганга түзәр хәл калмый. Яшә! Рәхәтлән! Ә күңелнең... тулаем яртысы китек... Аны моң, сагыш, сыкрау баскан. Чал гына түгел, ә ап-ак башымны кая куярга, кайсы ташка бәреп чәлпәрәмә китерергә урын тапмаган чакларым хәттин ашкан. Тәңремнән мең-мең катлар ялынып-ялварып сораган теләгем кабул булмады. «Җанымны ал! Шушы минутта ук! Ә кызыма тимә. Яшәсен! Җиһанны үзенең барлыгы, яшәү рәвеше белән бизәргә дип яраткансың түгелме соң син аны?» — дип үтендем. Күп тапкырлар. Юк икән җиһанда синең гозерләреңә колак салырдай кодрәтле зат. Барысы — бутафория!

Югыйсә әдәпле, инсафлы мәҗүси мин. Күп еллардан бирле җан дустым — эш өстәлемне яратам, аңа табынам. Командировкаларымнан Мәдинәм-гөлкәемнән болайрак аны сагынып кайтам. Беренче эшем итеп аны сыпырам, аны иркәлим.

— Син дә мине шулай сагындыңмы? — дип кочам.

Гармунымны яратам, аңа табынам. Йорт иясе белән дә бик тату яшибез. Каядыр-мазар киткәндә, өйне ут-күздән, су басудан, карак-угрыдан, башка хәвеф-хәтәрләрдән сакларга тулысы белән аңа тапшырабыз. Бу әсәремнең бер урынында: «Миндә бик хәтәр көч-кодрәт бар, тик бу турыда әйтергә генә куркам», — дип авызымнан ычкындырганыем бит. Хәзер дә куркам. Мине шарлатан бу, бераз акылдан да тайпылганмы дип әйтүләреннән түгел. Аларына исем киткән ди бик! Алай да шул хәтәр кодрәтемнең бер чагылышын гына тешемне кысып кына булса да ачам. Үзем белән ни буласын мин күп алдан белеп торам. Йә ап-ачык итеп төшемә керә, йә күңелем сизә. Укыган чакларымда, иң кыен саналган фәннәрдән имтихан биргәндә нинди билет керәсенә кадәр төшемә керә иде. Ләкин шунысы кызганыч, бу көч-кодрәт белән мин идарә итә алмыйм. Гәрчә кайтып-кайтып баш ватканым булса да. Бер карасаң, бик вак детальләр. Кайчак шулай исемә бер таныш җыр төшә. Кара, бу матур җырны күптән радиодан ишеткәнем юк дип уйлап куям. Шушы җыр ун минуттан ук радиода яңгырый. Кара, менә бу егетне күптән күргәнем юк, исән генә йөриме икән дип уйлап куям. Куркам. Әмма әсәремнең ахырындарак әйтми дә булмас... Бу кадәрлесе шушында торып торсын.

Ходайның үзеннән сорап, махсус заказ белән алгандай, бик матур килгән җәй көне. Июнь урталары. Казаннан кайтышыбыз.

Рульдә — киявем Нәфис. Аның янында — олы кызым Гөлнарым.

Казаннан, рак авырулары шифаханәсеннән, чираттагы «химия белән бомбардировкадан» кайтышыбыз.

Хирургия һәм онкология кафедрасы профессоры, танылган хирург Рәфкать Тажиев:

— Шушы яшемә туплаган бөтен осталыгымны җиктем. Мөмкин булганча рак шешләреннән арындырдым... Ләкин бик соң килгәнсез. Озак яшәмәс. Күп булса алты ай гомере бар, — диде.

Бу серне якыннарымның берсенә дә әйтмичә мин сакларга тиеш бит әле. Ә кызым, кошчыгым, баш миемнән алып, табан очларыма кадәр безләп сорый:

— Әтием, мин котылдыммы соң инде?

Шушындый чакта үзеңдә телең камашмаслык нинди көч табарга кирәк соң?! Моңа кадәр мин тормышымда бер дә алдашмадым. Кирәге дә чыкмады. Алдаша да белмим. Хәзер нишләргә? Күземне читкә яшерергә дә ярамый.

— Кызым, моны сиңа мин әйтәм, Аллага шөкер, котылдык! — дим.

Тажиев шулай кушты. «Әйтмә, — диде. — Булган гомерен берни дә белми яшәп калсын», — диде. Үлемнең котылгысызлыгын ачып салмавым өчен кайбер якыннарым соңыннан миңа үпкә дә белдерделәр. Ә белгән булсалар нишләрләр иде? Мәдинәм-гөлкәем бер атнадан ук сизде, белде. Сизмәс, бар...

— Яшермә карашыңны, йөзеңә бер карау белән мин барын да сиздем. Бу кайгы берүзеңә генә авыр булыр. Икәү күтәрик, — диде.

Рәфкать Минһаҗ улы Тажиевның да аягына ятып ялындым:

— Ah, шуны эшләмәдем бит, дип әйтерлек бер үкенечем дә юк. Операция өстәленә кызым белән рәттән сал. Нинди әгъзам кирәк, шунысын кисеп ал. Кызыма күчер. Тик ул гына исән калсын, тик ул гына яшәсен, — дип ялвардым.

Һай, шулай гына булса икән лә соң!

...Нократ елгасы аша салынган күпергә килеп кердек. Ап-аяз, җилсез җылы көн. Баш очыбызда, күк түбәсе астында уйнаган бихисап тургайларның чуты юк. Шашып-шашып сайрыйлар да ук булып җиргә атылалар, машинабызның борын төбеннән үк очып китәләр. Уйнаулары шулай, күрәсең. Болыннарны — чәчәк, алар өстен күбәләк баскан. Күпергә кергәч, кызым машинаны туктаттырды. Чыгып күпер читенә килде. Бездән утыз метрлар аста ургылып-ургылып мул сулы Нократ ага. Су өстендә чүлт-чүлт вак балык уйный. Чуртан куа бугай үзләрен — эре дулкыннар да куба...

— Әтием, ташланыйм шушыннан аска. Мин дә котылырмын. Сез дә... бер утырып еларсыз да онытырсыз. Эзләп тә тормагыз, — диде балам.

Шушы сүзләрне ишеткән ата нишләргә тиеш?!

Дөнья булгач, егет башы күп сынаулар кичә. Тормыш аны минем чал башыма да күп салды. Әмма болай каушап калганым булмады. Сине дә аңлыйм, балам. Тәмам сабырың төкәнгәч, яшәүдән тәмам өметеңне өзгәч шулай әйткәнсеңдер инде, кошчыгым. Шушы хәлләрне күрәсе булганга, кечкенәдән, туган сәгатеңнән шулай өзелеп яратканмындыр инде үзеңне...

Хатирәләр шаукымына бирелеп, өзеп-өзеп, ташлап-ташлап яза торгач, фикерләрне мәрҗән бөртеге итеп тезүдә дә өзеклекләр туа торгандыр инде. Әмма кыйблам бер. Уйнаклатмыйм. Юнәлешне гел шуңа таба тотам. Вәләкин дөнья сагышларыннан котылып буламы соң?! Тик мин сер бирмәскә тырышам: елмайган, шаярган төс чыгарам. Беркемгә берни сиздермәскә маташам. Гөлнарымны Себер трактындагы онкологик авырулар бүлнисенә салдым.

Балакаем, күз нурым:

— Әтием, әйдә, Мәскәүгә чыгып киттек. Акчабыз да, долларларыбыз да җитәрлек. Ә безнең анда белгән профессорларыбыз бар. Миндә бит язва чире генә. Мәскәү профессорлары бераз дәваласа, ярасы хәзер ябылыр, — ди.

Мәскәүнең ата жулик Брантлары, Крандтлары моңарчы да аларның долларларын күп саудылар инде. Ашказаным авырта, дип табын яныннан кузгалып китүгә, киявем Нәфис аны шунда ук Мәскәүгә алып чыгып китә. Ике-өч атнадан алар: «Терелдек!» — дип кайтырларые.

Әмма күп тә узмый, ашказаны кызымны янәдән борчый башлый. Болар янәдән Мәскәүгә очалар, долларларын саудырып кайталар. Ах, шул чакта йөгәнне, дилбегәне үз кулыма алган булсам! Дөнья булгач, адәм баласының ашказаны да, башка әгъзалары да авыртмый тормый, узар, дәваларлар дип уйладым шул. Чөнки студент елларымда үземнең дә ашказаным еш кына «ыңгырашып» куя иде. Кызымның ире дә шулай игътибарлы булгач, араларына кермәдем.

Соңгы тапкыр Лениногорск бүлнисендә тикшергәч, шәһәр онкологы Илья Никитин:

— Сезгә бүген үк Казанга очарга кирәк, — диде. Беләгемнән тотып: — Крепитесь! Крепитесь! — дигән сүзләрен гомердә онытасым юк.

Бәгырь җимешемнең көннәре бик санаулы калган иде шул.

Эш болай, кадерлеләрем. Минем халәт дошманыңа язмасын. Мәк чәчәге кебек, тулып пешкән кура җиләгедәй кызым Гөлнарым көннән-көн сызып китеп бара. Дөньяның бер чибәре, бер гүзәле бит ул. Бии башласа, үкчәсеннән чаткылар чыгара. Урта мәктәпне алтын медальгә тәмамлап, Мәскәүнең нефть институтында инженер булып чыкканые. Рак дигән мәлгунь харап итә бит баламны. Бу фаҗигане бик көчле рухлылар гына күтәрә аладыр. Мин исә күтәрә алмадым. Бу хәлдән котылу чарасын эзли башладым. Әлмәт төбәгендә җиде-сигез районга корреспондент булып эшләгән елларым. Төнлә берьялгызым гына йөргән чакларым да булды. Бүрегемне дә урлап качтылар. Аннары миңа, милиция бүлегенә дәшеп, бер ипле генә револьвер бирделәр. Кул куеп алдым. Мин аны өемнең өске катындагы тимер сейфта саклыйм. Алты зарядлы ул. Бакчага чыгасың да шалт берне маңгаена йә чигәңә. Әнә шул уй төште минем башка. Чөнки кызым, балам: «Әтием, коткарасыңмы мине бу чирдән?» — дип сорый. Оятсыз төстә алдашам: «Коткарам!» — дим. Бакчага чыгасы да, алма агачы төбенә утырып, шалт берне маңгаена. Бөтен кайгы-хәсрәтләреңнән шундук котыласың. Әмма сейф ачкычын таба алмыйм. Ә пистолет сейф эчендә. Мәдинәм-гөлкәемне утлы табага бастырам.

— Бир ачкычны яхшылык белән! Үтерәм бит үзеңне, — дим.

— Мин аны бөтен көчемә айкап бакчага ыргыттым. Кая төшкәнен дә белмим. Чык та эзлә. Минерлар дәш, бәлкем, табарлар, — ди...

Раббым каршына юл тоттым

Башка чара юк, бармыйча булмый иде. Әллә безнең «Җәнбәт җәвере — җиде табын» нәселен башлап җибәргән бабаларыбыз җиде буынга җитешле каргыш алмаганнардыр бит? Юк, бу ни хәл бу? Бабам ятим үскән. Әтиемне дүрт яшендә үк детдомга илтеп тапшырганнар. Мин әниемнән алты көнлек кенә булып калганмын. Кызымның улы Арыслан җиде яшендә калды. Бу ни хәл бу? Кем безнең белән шулай усал шаярта? Чиге бармы моның? Раббым каршына менә шул турыда «икәүдән-икәү» хәл итү ниятеннән бардым. Канса канис, хикмәт нидә соң? Аннан — өстән торып безнең ыру өстенә ни дип ләгънәт яудыралар? Кем тарафыннан, кайчан кылган гөнаһларыбыз өчен? Бер өстәл артында кара-каршы утырып сөйләшү нияте белән бардым аның каршына. Менә шул...

Бүгенге көндә, җәмәгать, гозерең төшеп, Президентыбыз Минтимер Шәймиевкә эләгүе дә бик җиңел түгел. Үзендә түгел гаеп, якыннары, аеруча куштаннары аны шулай халыктан аерырга тырышалардыр. Ә Илбашы халкыннан аерылса, бетте диген инде.

Әүвәл чын хыялыйлар хәленә калдым. «Очты күңелем дөнья читлегеннән»... Җиде кат җир астына төшеп, җиде кат күккә күтәрелеп, барып чыктым бит тәки Хак Тәгаләнең приемныена! Беренче минутларымнан ук нигә килгәнемә үкендем. Анда да — шартларлык булып, соңгы чигенә җитеп күпергән штат. Бер кәнәфидә этешә-этешә өчәү-дүртәү утыралар. Монда да коточкыч бюрократия, әшнәчелек, туган-тумачалык, ришвәтчелек. Бер Ходаем, үзең кичер. Күзеңә карап, кайсына куй сарыгы, кайсына ак тәкә дигәндәй, кулларын сузып, синнән ришвәт көтеп торалар. Кыланышлары нәкъ куначада утырган тавыкларныкыча: үзләре белән янәшә утырган иптәшләрен, җае чыккан саен чукыштырып, канатлары белән бәргәләп, кысрыклап, һаман өскәрәк үрмәләргә тырышалар. Үзләреннән аста утырганнарның башына пәч тә пәч кәкәй яудырып кына торалар.

Дөресен әйтим, Хак Тәгаләнең үзенә үк кереп булмады. Булыр сиңа, тот капчыгыңны!

— Бүген юк бит ул, вакытын белмичә килгәнсез, — диделәр. — Больничныйда, — дигән булдылар.

— Ничек инде больничныйда? Хак Тәгаләнең больничный алырга хакы юк! — дип чәпчеп алмакчы булам.

— Ничек инде хакы юк?! Ул да бит тере җан иясе. Аның да вакыт-вакыт тешләре сызлап куя. Кан басымы да күтәреләдер. Үткән атнаны балыкка барганые, аякларын өшеткән. Хәзер ангина белән азаплана, — дип, ипле генә аңлатты приемныйда утырган бер фәрештә кыз.

Алай дигәч ышандым инде. Бигрәк тә «ангина» дигәч. Аның белән үзем дә еш азапланам. Терелә генә күрсен инде Хак Тәгаләбез. Ансыз калсак нишләрбез?

Юлламама мөһер суктырып саубуллашкан чагында, ап-ак күлмәкле, кара галстуклы чибәр генә бер егет, шулай ук фәрештәләр затыннан:

— Вакытсызрак килгәнсез шул. Нинди гозерләр белән йөрешегез иде соң? Әйтегез, үзебез генә хәл итәрбез, — диде.

— Гозерләр генә түгел, таләпләрем дә зурдан һәм җитдиләрдән иде, — дидем. — Әмма күреп торам, сез аның берсен генә дә хәл итмәячәксез. Чөнки сез биредә бернинди җаваплылыкны да үз өстегезгә алмаслык дәрәҗәдә каешланып беткәнсез. Монда, күрәм, шундый мохит. Чөнки сезне өегездән чыкканда ук эти-әниегез, хатыныгыз, балаларыгыз: «Бер җаваплылыкны да үз өстеңә ала күрмә, үзеңне танытырга теләп инициатива күрсәтмә. Иң изге гамәлләреңне дә ялгыш аңлаулары бар. Көнең узса, бик җиткән, эшеңне, урыныңны гына югалтма», — дип башыгызга тукып җибәрәләр. Җибәрмәскә соң! Мондый абруйлы, дәрәҗәле, җылы урынга гомердә бер генә эләгергә була. Җитмәсә, көндәшләрегез дә бер көтү. Чак кына абынганыгызны, сөртенеп китүегезне генә көтеп тора булырлар...

— Безнең мондагы аппаратның эшчәнлеген, — сез кайсы планетадан, Җирдән килдем, дидегезме әле? — бозыклык чиренә башы белән чумган Җирдәге үлчәмнәр белән үлчәмәгез әле, зинһар, — дип кенә әйтә алды әлеге чибәр егетем. Хак Тәгалә аппаратының якын түрәсе, фәрештәләр өммәтеннән инде, әлбәттә.

— Ни дип шулай безнең ыруны каһәрлисең, нарасыйларыбызны ятим калдырасың? — дип өстәл сугарга барганыем югыйсә Раббым каршына. — Җитте инде! — димәкче идем...

Хыял диңгезенә чумып шулкадәр араны гизеп килгәчтен, берочтан Газраил әфәнде кабинетына да сугылдым. Ул да өйдә юк. Шуңа күрә безобразие икән Җирдә. Өстән контроль юк икән. Җиде кат күк түрендәге ник бер начальник, ник бер түрә эшендә булсын. Газраилне, җәйге ялын уздырырга барча бала-чагасы белән Андромеда йолдызлыгына китте, диделәр. Түрәләр кайда да түрә икән. Ялларын да беләләр кайда уздырырга.

Аның кабинетында әремдәй чал чәчен әйтерсең лә селте белән юган, бите бозау чәйнәгән сөлгедәй җыерчыклы, авызында сыңар теше дә калмаган Әҗәлбикә карчык кына утыра иде. Әллә әз генә салмытдин да? Үзенә күрә түгел, биек үкчәле туфли кигән әле, жубалгы капрон оектан. Мине бик төксе каршылады.

— Анда үлем эзләп шаяруыгыз турында бик төгәл хәбәрдарбыз. Тик утырган юк. Документацияне бик төгәл алып барабыз, — ди бу. — Дөнья йөзендә, кояш нуры астында яшәүнең кадерен оныткансыз дип ишеттек. Хәбәрдар, бик хәбәрдар! Кайбер нәтиҗәләр дә ясарга җыенабыз...

— Булмагаегыз! Анысы минем эш.

— Юк шул, аңгырабаш, кемгә кайчан, нинди әҗәл җибәрү, билгеләү — анысы нәкъ менә минем эш, — дип өстәл үк сугып җикеренә Әҗәлбикә. — Яшьтәшләреңә, иптәшләреңә яшәп туймыйлар. Гомерләрен бер генә көнгә булса да озайтуны ялварып сорыйлар. Тәңренең үзенә телеграмнар яудыралар. Ә син!..

— Нәрсә «син»? Сарыгыңны урлап суйдым мәллә?

— Алай кыланып йөрсәң, дөньядан туйсаң, хатыныңнан пистолетларыңны таптырсаң, момент кыскартырмын гомереңне... Монысы безнең кулда!

— Тот менә моны! — Уң терсәгемне кендегемә терәдем, йодрыгымны күрсәттем. Бу җен карчыгына беренче күрүдә үк ачуым чыкты, селте белән юган чәчләреннән сөйрисем килде.

— Син алаймы әле, ә! — ди бу, шушы сүзләренә бөтен зәһәрлеген салып. Сул кулын баш өстенә күтәреп бармак яный.

— Син уйлаганча! Нәкъ шулай! Менә сиңа!..

— Алайса-а-а! Син тилебашны мин бик тиз акылга утыртам.

— Утыртмый гына тор әле, жубалгы! Синнән куркучыларны куркыт! Ә мин аларны узган инде. Баш өстемә өч кояш чыкса да, дөньяның тәме калмады. Мәк чәчәгедәй кызым юк. Син гаепле. Күзеңне чекерәйтеп син йөрдең бит безнең өй тирәсендә.

Әҗәлбикә белән шушы тарткалашудан соң шундый сәер хәл булды бит, әй. Җәйнең матур бер көнендә киявем, оныгым һәм Мәдинәм-гөлкәем белән кызымның каберен төзәттек. Матур итеп таш яздырганыек, аны куйдык. Кабер әйләнәсенә цементлап ак кирпеч тездек. Кабер өстендәге кызыл балчыкны читкә түгеп, кара туфрак ташыдык, гөлләр утырттык. Аста, кабердә, нибары утыз өч яшендә дөньядан киткән, яшәргә дә яшәргә тиеш булган, өзелеп яраткан кызың ятсын әле! Син шул кабер янында...

Кич җитте. Башкалар автобуска утырып кайтып киттеләр. Без онытым Арыслан белән машинада кайтырга чыктык. Мин — рульдә, ул — янымда. Шунда минем белән хәтта бүген дә аңлап-аңлатып бетерә алмаслык хәл булды.

Көндезге авыр кичерешләрдән соң миең тәмам алҗыган булгандыр инде. Зират чатында, юлның уңайсыз бер җирендә, шып итеп тормозга басасы урында бар көчемә газга басканмын. «Жигули»ебез, юл читендәге тимер багананы аударып, чылбырны өзеп, бетон бүкәннәрне егып, дүрт-биш метр биеклектән ком карьеры төбенә очты. «Онытымны харап иттем!» дигән уй гына узды башымнан. Үзем турында уйларга вакыт юк. Беттек бугай... Котылдым... бу фани дөньядан...

Бераздан аңыма килсәм, Ходаемның рәхмәте, машинам дүрт көпчәгендә карьер төбе буйлап тәгәри. Моторы сүнгән. Кул тормозын тартып туктаттым. Улым да аңына килде. Кабаланып кына ишекне ачты да ут капкандай читкә йөгерде, таш артына ятты.

Бераздан кычкыра миңа:

— Дәү әти, кач! Машина шартлый бит хәзер!

Киноларда, телевизорда һәрчак шулай бит. Һәлакәткә дучар булган машиналарга ут каба, шартлыйлар. Онытым да шуны көткәндер, бала бит. Машинадан чыгып янына килгәч тә таш артыннан алып булмый, дер-дер килә, балакаем. Таш карьерына биш метрлар биеклектән очсак та, машинага әллә ни зыян килмәгән. Йә Ходайның рәхмәте, дүрт көпчәгенә төшкән ул җиргә. Шунлыктан гына исән калганбыздыр. Әгәр әйләнгән булсак...

Сизәсезме, җен карчыгы Әҗәлбикәнең үч алуы бу. Теге чакта бик янап калганые бит. Янәсе, якты дөньядан туеп, әҗәл эзләп йөрсәң, без әле күрсәтербез сиңа күрмәгәнеңне! Юлда очраган «КамАЗ»ны туктатып, машинаны гаражга кайтарып куйдык.

— Машина да булдымы мал! Үзегез исән калгач! — дип, әниең дә ике кулын йөрәге өстенә куеп сөенде. Ничә ел бергә гомер итеп, әниеңнең болай сөенгәнен күргәнем юк иде әле, кызым.

Тормыш гыйбрәтләрдән тора шул. Карьерга очу безгә зур гыйбрәт булды. Елап, сыкрап кына эш чыкса икән ул! Үлгән артыннан үлеп булмый, диләр. Бөтен матурлыгыңның, акыл-зирәклегеңнең, зиһенеңнең дәвамчысы — улың Арысланны аякка бастырасы, кеше итәсе бар бит әле. Белеп, тоеп ятасыңдыр, балам, егетебез әлегә гел бишкә укый. Күп олимпиадаларда катнашып, гел җиңеп кайта...

Кызым, васыятьләреңдә кат-кат сорадың, баламны ташламагыз, дидең. Ташлыйбызмы соң?! Синнән дә якынрак, синнән дә кадерлерәк тагын берәү бармы соң безнең өчен?! Арыслан тугач, мин бит аны синнән дә болайрак ярата башладым. Аның йодрыклары зур иде. Онытым үземә охшаган, мин бу егеттән йә балта остасы, йә краснодеревщик ясыйм дип кертә идем бит аны чәп-чәпләргә.

— Кыз бала булса, сездә генә калырые. Кыз баланы карау, үстерү әти кешегә кыенрак. Арыслан әтисендә үссен, — дип әйттең васыятеңне. — Сез дә инде байтак яшь белән барасыз. Сезнең белән ул-бу хәл булса, улыма әтисенә ияләнү кыен булыр. Арыслан әтисендә үссен. Әтисенә дә васыять итеп әйтеп калдырам. Кыенлыкларга тап булганда, сезгә таянсын, — дидең...

* * *

Узган җәйне әти-әниләре, Биктаһирның абыйсы Искәндәрне дә алып, җәйге ялга җылы якка бардылар. «Бу эсседә юлда баланы чирләтерсез», — дип, нибары ун айлык Биктаһирны бирмәдек. Үзебездә калдырдык. Дәү әти булуның бар тәмен, бар ләззәтен, бар бәхетен янә дә бер рәхәтләнеп татыдым бу җәйдә. Шар кебек түп-түгәрәк ун айлык малай алпан-тилпән йөри, мин сиңа әйтим, ишегалдын икегә яра бу! Килә-килешкә башын пәке белән «под Фантомас» алып җибәрдем. Ишегалдына ванна чыгарып куйдым. Өстән июль кояшы кыздырып тора. Ваннадагы суы суынып китсә, чәйнектән кайнарын өстәп торабыз. Көненә бишәр тапкыр коендырабыз. Суда сәгатьләр буена үрдәк булып чупырдый бу, әй! Тавык шулпасында пешкән куе токмачлы аш салынган тәлинкә тотып, дәү әнисе дә яныбызда гына тора. Укробын тураган, катыгын туглаган. Онытыбыз тамакны ваннада кырын яткан килеш кенә ялгап ала. Әнкәсен имүне «юк-бар эш бу» дип инде ул күптән ташлады. Бар ашаганы — катык туглаган токмач ашы.

Нәкъ шушы көннәрдә безгә Бөгелмәдән кунак төште. Нибары утыз өч яшендә яман шештән вафат булган олы кызым Гөлнарның улы, олы онытым Арыслан килгәние. Биктаһирны карашырга ул да бик булышты. Бу ике туган егетләр тиз арада нык дуслашып киттеләр. Моңа да сөенеп туя алмыйм. Бу малайларда Җәнбәт җәвере ыруының каны ага бит. Үскәч тә бер-берләрен ташламаслар әле. Ташламасыннар иде, йә Раббым! Ул фикерне инде үзләренә тукып кына торам. «Бу дөньяга мин мәңгегә килмәгән, зинһар өчен, берүк шәҗәрәләрегезнең очын җуймагыз!» — дим.

Әйе, без — Җәнбәт ыруыннан! Әйе, бабам ятим үскән. Әтиемне дүрт яшендә үк детдомга илтеп тапшырганнар. Мин исә әниемнән алты көнлек кенә булып калганмын. Кызымның улы Арыслан җиде яшендә калды. Пәйгамбәребез сәлаллаһү галәйһиссәлам Үзе дә бик яшьли ятим калган бит. Шагыйрь әйтмешли:

Әллә ниләр кирәк сыман

Бу адәм баласына.
Барысы да сынау юкса,
Сынау гына барсы да.

Әллә ниләр кирәк сыман
Бу адәм баласына.
Кала бары шул кирәкне,
Кала... табасы гына...

Аллага шөкер, сер бирмәдек. Адәм балаларына хас булганча, лаеклы яшәргә тырыштык. Тырышабыз. Җәнбәт ыруы дәвам итә!

Дулкыннар аяк чала...

Заманында чаңгыда узышу буенча спорт остасы булган, илле яшьләрен чәчләренә чама белән чал төшереп кенә тутырып килүче, төскә-биткә ирләрчә кырыс чибәр Мөнир Хуҗин дүрт йолдызлы «Идел балкышы» кунакханәсенә яхшы кәеф, күтәренке күңел белән кайтып керде. Башкалада яшәүче дусларында, шул Кәтүк Нәҗипләрдә инде, кунакта булып, нык сыйланып, кызмача хәлдә кайтты ул. Дусты Нәҗип белән моннан чирек гасырлар элек төзүчеләр институтында, бер бүлмәдә яшәп, бер тәлинкәдән ашап, бер төркемдә укыганнар иде. Дипломлы булгач, үсеп җиткәч таралышкан кош балалары кебек, һәркайсы «илнең кырларына таралышсалар» да, алар бер-берсен югалтмадылар. Нәҗип үзе карсак, үзе капкорсак, хәзер Кабминда зур гына түрә. Йомшак кәнәфигә хуҗа булу теләге укыган чагында ук бар иде Кәтүкнең. Күңелеңдә булган теләгеңне тормышка ашыра алгач, шәп инде. Егетләрчә!

Мөнир исә, Казанга эш белән килгән саен, беренче кичен шушы сабакташы Нәҗиптә куна. Байтак еллар шулай. Башта алар Кәтүкнең (нык карсак булганлыктан, бөтен төркем Нәҗипне шулай атап йөртә иде) Танкодром районындагы биш бүлмәле фатирында кунак булалар. Әмма кичке уннар-унберләр тирәсендә ике ахири сабакташ Кәтүкнең биш бүлмәле фатирын тарсына башлыйлар. Хуҗа министрлыкның гаражыннан кизү «Волга»ны чакырта. Кәтүкнең хатыны Нажияне дә алып, «Акчарлак» ресторанына стриптиз карарга менеп китәләр. Соң, яшәгәч яшәргә инде! Ошбу җиһанга беребез дә мәңгегә килмәгән. Якты дөньяда барыбыз да бер атнага кунакта гына лабаса! Илле яшьләрең тулганда аны аеруча сиземлисең икән.

Бу юлы Мөнир кочагына сыра шешәләре тутырып сабакташына килеп керсә, егыл да кит. Кәтүк дусты култык таякларында. Кирәк бит димәссеңме, Нәҗип көзге каткаклыкта үз ишек төбендә егылып аягын тайдырган. Хуҗабикә ханым да кунакны муенына сөлге урап каршылады, тамагына ангина зәхмәте оялаган икән. Төкреген дә йота алмый, бичаракай.

Дөрес, гадәттәгечә күтәреп алдылар Мөнирне. Зурлап кунак иттеләр. Куна калырга да кыстадылар. Хуҗалар икесе дә мондый хәлдә булганда, кая инде аларны куна калып борчыйсың?

Ике бүлмәле, бер кешелек люкс номерына Мөнир күтәренке күңел белән, авыз эченнән генә «килә ява, килә ява, ияләште бер болыт» дип көйләп кайтып керде. Көй көйләмәскә соң, «Аксыртнефть» идарәсенең капиталь төзелеш буенча бүлек башлыгы Мөнир Хуҗин бу юлы башкалага исәп-хисап эшләре белән һәм соңгы елларда нык искергән кайбер нефть мәйданнарын яңабаштан үзгәртеп кору буенча Министрлар Кабинетыннан бераз акча юллау нияте белән килгән иде. Проектын кабул иттеләр, якладылар, бераз гына акча да ышандырдылар. Хәл итеп бетерәсе мәсьәләләр әле иртәгәгә дә байтак калды. Әмма килүе бушка булмады.

Мөнир бүлмәсенә кереп тунын салды. Костюмын урындык башына элде. Телевизор кабызды. Анда әллә ни кызыгып карардай әйбер тапмады. Суыткычны ачып бер шешә шифалы су алды. Ятып кына йокласа, иртәрәк әле, тугызлар тирәсе генә. Мондый кичтә кочагыңа берәр чибәркәйне сыйдырсаң да бик ярап куяр иде дә бит! Ләкин сиңа кирәк чакта гына кем китереп салсын әле аны синең кочагыңа? Казимирга шакысам инде, дип уйлап алды Мөнир. Шәт, өйдәдер. Мәскәү кунагы өйдә булмыйча, кая барсын? Кызык, гәп корып утырырга бик ипле егет күренде ул кичә Мөниргә. Казимир — Мәскәүдән килгән проектировщик. Кичә кунакханәгә урнашканда танышканнар иде. Итекче итекчене сүгенүеннән таный дигәндәй, ике төзүче тиз арада уртак тел таптылар, кичтән әле барга төшеп сыра эчеп тә утырдылар.

Мәскәү кунагы, тәрәзәсеннән бармагы белән төртеп күрсәтеп, әнә Казан дәүләт университетының ундүрт катлы физика-математика факультеты бинасының проектын мин төзегән идем, дип сөйләде. Казанның танылган белем мәгарәсе шәкертләре әлеге бинада физика-математика серләрен өйрәнгән арада, Казимирдан янә шундый тагын бер бина бастыруын сораганнар. Мәскәү кунагы бу юлы әнә шул йомышлар белән килгән икән.

Физика корпусын бастырганнан соң, Казимир ике ел Сүриядә, өч ел Алжирда эшләп кайткан.

— Шултикле еллар чит илләрдә мал җыйгач, Казимир коллега, син череп баеган әфәндедер инде? Фатирың диварларын доллар белән ябыштырып бетергәнсеңдер, — диде аңа Мөнир, шаярып.

Казимир кулын гына селтәде.

— Хатыным белән барган булсам, баерга була иде, әлбәттә...

— Ә син ялгызың гына бардыңмыни? — дип белдерде Мөнир.

— Беренче баруымда улым укырга гына керде, хатыным Ольга кызыма авырлы. Кая анда гаилә белән бару? Ә миңа утыз ике яшь! Кешнәп торган чак. Куеныңда һәр кич кайнар тәннең булмавы ризыкка, кара ипигә ачлык, киерелеп суларга һава җитмәүдән кыенрак. Агач тишегенә барып бәйләнердәй буласың...

— Ә гади секс өчен үзеңә бер кичкә чакырырдай хатын-кыз җенесенә шулхәтле кытлык идемени?

— Кытлык кынамы?! Мөселман иле. Без, килешү белән килгән белгечләр, бик нык күзәтү астында. Ял көннәрендә, бәлкем, шәһәргә чыгып китәргә дә булыр иде. Ләкин КГБ егетләре кая, ничек басканыңа хәтле күзәтеп торалар. Түзмәүчеләр дә булды. Шунда ук фаш ителәләр, бичаракайлар. Аннары икенче көнне үк самолетка утыртып Мәскәүгә выжылдаталар үзләрен. Документларына «за моральное разложение» дигән печать сугып. Кемнең соң шундый хурлык белән кайтасы килсен? Түзәсең инде.

— Утыз ике яшьлек айгырга ике-өч ел хатын-кыз кочагы күрми тору, чыннан да, коточкыч җәза, минемчә, — дип куәтләде аны Мөнир. — Килешәм. Мин дә түзә алмаган булыр идем.

— Түзмичә кая барасың? Әнә тәмам түзәрлек хәлләре калмагач, озак еллар хатын-кыз назы күрмәгәч, төрмәләрдә утырган ирләр бер-берләренә ябышалар. Өлкәнрәкләре яшьләрне көчлиләр. Җәмгыятьне һич тә бизәми торган гомосекс шуннан тарала. Бер бозылган ирләр ул гадәтләрен иреккә чыккач та ташламыйлар.

— Аннары үзләрен социаль азчылык итеп игълан итәләр әле. Үзләренә ихтирам таләп итәләр, — дип өстәде Мөнир дә. Янәсе, алар кыерсытылырга тиеш түгелләр.

Икесе дә көлешеп алдылар.

— Тәмам аптырагач, һич түзәр хәл калмагач, без дә илчелектә җаен табадыр идек инде шунда, — дип куйды Казимир. — Консульствода җитмешләр тирәсендәге стенографистка Сара бар иде. Кимереп ташланган сөякләр өеме инде. Шыгырдап торган илле долларны өстәленә куймасаң, сөйләшми дә карт карга.

— Башка сыймаслык хәл! Ужас! — Мөнир кулын чапты.

— Сыйдырмый кая барасың?! Чират әле. Ә кыланышын күрсәң. Дөрес, бернинди ләззәт яисә җан рәхәте тату дигән нәрсә юк. Үзенә бер мәгънәсез тән гимнастикасы, киеренкелектән табигый юл белән котылу. Шунысы бар, һәрхәлдә, анонизм түгел инде.

— Ул карт каргагызны әйтәм, менә ул, чыннан да, баегандыр инде?

— Кем белә инде. Аның долларын кем санаган? Һәрхәлдә, Мәскәүгә буш кул белән генә кайтмагандыр.

— Да-а-а, — дип сузды Мөнир. — Ул секс дигән нәрсә адәм баласы тормышында зур роль уйный шул.

— Уйный гынамы?! Ансыз дөнья сансыз! Ә мин Алжирга да ялгызым гына киттем. Чөнки хатынымның әнисе инфаркт белән егылды. Аны берүзен калдырып булмый бит инде. Улым университетка әзерләнү өчен репетиторга йөри башлады.

— Ирлегеңне онытмас өчен тагын партнер эзләргә генә кала, — дип килеште Мөнир.

— Дөрес, мин дә бөтенләй буш кул белән кайтмадым.

— Улымны өйләндереп, фатир алып бирдем. Үземә дача, машина алдым, — дип сөйләп утырган иде Казимир кичә.

Ә бүген кая соң әле? Бүлмәсендә булыр. Кая, шалтыратырга кирәк үзенә.

Шулчак каз чукыгандай гына итеп ишек шакыдылар. Мөнирнең «әйдүк» диюенә, ишектә Казимирның чал башы күренде.

— Әйдүк, әйдүк, Казимир дус. Үзем дә сиңа шалтыратырга тора идем әле, — дип каршылады аны Мөнир.

Казимир исә, ишек катында торган килеш:

— Әй, Мөнир дус, кая йөрисең? Моннан ярты сәгать элек кенә бик чибәр Казан гүзәлкәйләре бу кичне үзләре белән уздырырга чакырып ишек шакыганнарые, — диде. — Мин ни дип әйтергә дә белмәдем. Син булмагач... Баш тарттым...

— Ялгыш иткәнсең, Казимир дускай! Дәшәргә булган. Тотып ашамасларые әле, — диде Мөнир. — Кунакта тоткарландым. Кер, түрдән уз, хәзер бер коньяк ачам.

— Дәшәргә булган шул. Хәзер инде менә үзем дә үкенеп торам, — дип, Казимир түргә узды. Телевизор каршындагы тирән эчле кәнәфигә утырды. — Үкенеч! Берүзем генә базмадым инде. Ә син кунарга әллә кайтасың, әллә юк.

— Ә нигә дәшмәскә диген әле? Башка ир-атлардан безнең кай җиребез ким? — диде Мөнир, минераль су кабып. — Бу кичтә бик ярап куйган булыр иде алар, ялт-йолт күзле, алсу йөзле Казан чибәркәйләре.

Мөнир, көзге алдына басып, матур итеп бәс сарган чәчен артка тарады, чак кына беленеп торган корсагын сыпырды. «Илле яшьләрең тулганда, кхм-кхм, мондый гына кышлык запас үзен ихтирам иткән һәр ир-егеттә булырга тиештер инде ул», — дип сөйләнде. Мөнир көзгедә аңа каршы басып торган чибәр иргә текәп-текәп карады. Бәйләнер җир тапмады, әй. Һәрхәлдә, бу ирнең җәйге иртә таңнан торып, кич көтү кайтканчыга тикле кулыннан балтасын төшерми бура башы чабарлыгы бар иде әле.

— Кхм-кхм, бу кичтә ярап куйган булыр иде алар, баскан җирләреннән ут чыгаручы Казан чибәркәйләре, — дип кабатлады.

Казимир, журнал кыштырдаткан җиреннән башын күтәреп:

— Әле бит вакыт бик соң түгел, бәлкем, тагын шакырлар, Ходайның рәхмәте белән, — дип әйтергә өлгермәде, ярым ачык ишектә күп булса егерме биш тирәләрендәге озынча буйлы, арпа саламыдай соргылт чәчле бер чибәр туташ күренде. Өстендә көрән күн тужурка, аякларында тезләрен дә каплап торган озын кунычлы ботфордлар. Туташкай тышкы кыяфәте белән мушкетерларга да тартым, билендә шпагасы гына юк. Хәер, мондый озын кунычлы итекләрне походларда йөргәндә Петр I патша да киергә яраткан, һәрхәлдә, туташкай тышкы килеш-килбәте белән бер күрүдә үк кызыксыну уята. Нинди йомышлар белән йөрүедер тагын? Бүлмәгә туташкайның үзеннән алда затлы ислемай хуш исе кереп тулды. Тик Парижда гына эшләнелә торганнарының исе иде бугай.

— Егетләр, мин сездәй япа-ялгызларны бер кичкә бәхетле итү, ягъни интим ихтыяҗларыгызны канәгатьләндерү бюросыннан... — диде ул, бер дә тартынмый, бөтен йөзенә елмаеп.

— Бик хуп! Бик хуп! — дип бүлдерде аны Мөнир.

— Кышның бу салкын, шыксыз кичен үзләре шаян, үзләре наян, үзләре беренче чибәрләр, минем кызларым белән уздырырга ниятегез юкмы? — диде ул, йөзендәге елмаюны саклап. — Күреп торам, сездәй бөркетләр белән бер киче үзе бер гомергә тиң, кадерле сәгатьләр уздырырга була. Бер генә яшибез ләбаса!

— Әйдүк, әйдүк, туташкаем! Төкле аягың белән, — диде Мөнир. — Хак әйттегез, бер генә яшибез. Бик вакытлы шакыдыгыз. Сез әйткән дәртле вә изге теләк бездәй бөркетләрдә нигә булмасын икән? Керегез, кер, түрдән узыгыз әле. Без бик шат сезгә. Чәчләрне бәс сарса да, күп тешләрне врач йолкып алып чиләккә бәрсә дә, безнең ир-ат затының сезнең ише җәннәт фәрештәләреннән йөз чөергән чагы бармы икән? Гыж-гыж, ягъни кыз-кыз дип үләр ди бит безнең ир-ат халкы үлгәндә дә...

— Әйдүк, әйдүк, түр кунагы булып узыгыз, — дип, Казимир да торып басты.

— Кызганычка каршы, бу юлы без өчәү, — диде туташкай, эчендә нидер бүлтәеп торган сумкасын бер кулыннан икенчесенә күчереп.

Мөнир тегермән канатларыдай киң кочагын җәйде.

— Ah Алла икән инде! Нигә «кызганычка» булсын, «сөенечкә» диегез. Өчегез дә түрдән узыгыз. Безнең күңелләр киң, сыешырбыз. Менә мин үзем беренче карашка гына кипкән кабак. Ә күңелем киң. Ә минем дустым Казимир исә заманында Рәсәйнең җыелма командасында волейбол уйнаган мастер. Спортны бүген дә ташламаган.

— Киң күңелле егетләр булуыгызны белеп, күреп шакыдык, — диде әлеге туташ, елмайган хәлдә. — Сезне кичә ресторанда күрдек. Үзегезне президентларча иркен тотып, әдәпле утырдыгыз. Шунда ук ошаттык. Ә мин Лариса булам.

— Алай-й-й икән! Без инде кичәдән үк сезнең калпак астындамыни? — дип болганды Мөнир.

Әлеге туташ, ишекне киңрәк ачып, коридорда торган иптәшләренә ым какты. Ишек катында, мин сиңа әйтим, йа Ходай, бирим дисәң колына дигәндәй, тагын ике фәрештә калыкты.

Икенчесе боларның зур зәңгәр күзле, шундук ихтирамга лаек эшлекле кыяфәтле, матур курнос борынлы, куенына куш йодрыкка тиң грушалар тыгып куйгандай калку күкрәкле, бер күз ташлау белән ирләрнең һәрчак комсыз нәфесләрендә шул мизгелдә үк дәрт, өмет уятышлы туп кебек йомры маржа кызы. Ул, ишектә күренү белән:

— Шура, Шурочка, — дип книксен ясады. — Но лишь на половину дура, дурочка. Прошу это сразу учесть.

— Без барыбыз да тик яртылаш кына акыллылар, — дип күтәреп алды аны Мөнир. — Юморыгызны аңладык, уртаклашабыз.

Шура исә, йөзенә артистларга гына хас җитдилек чыгарып:

— Холкым минем иң ужасныйлардан. Кара төсне җенем сөйми: кара күлмәк, кара шәл, кара кешеләр миндә коточкыч аллергия уята, — дип сөйләп китте. Аңламассың, әллә чынлап сөйли, әллә шаярта.

Сүзгә кушылып китәргә җай тапмый утырган Казимир да:

— Кайбер төсләрне мин дә ошатмыйм, — дип куйды.

Ә Лариса исә:

— Шурочка, ярым тилебаш җаным, алдыңа тәлинкәсе белән кара уылдык куйсалар да борын җыерырсыңмы? Уйлап сөйлә, җаным, йә телеңне хәзергә аркылы тешлә, — дип бармак янады.

Шурочка аптырап калмады.

Йөзендә һаман да прокурорларга хас җитдилек саклап:

— Ә кем соң әле безгә кара уылдык тәкъдим итә? Һич югында кашык очына гына элеп булса да, — дип, зур зәңгәр күзләрен уйнатып алды.

— Тукта, ашыкма, балакай, курнос борыным. Мәскәүне дә алай тиз генә төземәгәннәр.

Кунакларның арттан, иң соң кергәне — өстенә кинәттән генә тайфун җиле ябырылгандай, сине бер күз карашы белән аяктан егышлы, карлыгач канатыдай кыйгач кара кашлы, карлыгандай кара күзле, бәхәссез шәрык кызы. Дулкын-дулкын кара чәченә, кояшта янган йөзенә тагын да чибәрлек, сихри гүзәллек өстәп, ачык муенына бик йомшак мамык тукымадан ап-ак шарф япкан. Башың әйләнеп һушыңны җуйсаң, син гаепле түгел. Табигать җавап бирәчәк. Бу җанны ул шулай гүзәл яраткан. Ә син шушы гүзәллекнең корбаны гына.

— Ә мин Марина, — диде ул, үз бәясен белеп.

Моңарчы сугышчан кыяфәтле күренгән, һәр көн иртән кортта икешәр сәгать рәттән теннис уйнаган Казимир да бу күренештән тынсыз калды. Ниһаять, һушын җыеп, кызларның өчесен дә түрдән узарга дәште.

Мөнир исә, бер генә минутка дигәндәй, ишарә ясады:

— Хөрмәтле туташкайлар, игътибарыгыз өчен без бик рәхмәтле. Ни бит, кадерлеләрем... — диде Мөнир, ап-ак тешләрен күрсәтеп. — Минем кызым кияү күргәнме дигәндәй, бу өлкәдә без абсолют профаннар. Килешүләр өстәленә утырганчы, шартларыгызны әйтегез.

— Кунакчыллык, сый-хөрмәт бездән булса, сезнең тарафтан кайнар мәхәббәт була торгандыр бит инде? — дип, Казимир аңа ярдәмгә килде.

Иптәшләреннән бер башка калку, какча гәүдәлерәк Лариса бу сугышчан артельнең башлыгы, бригадиры иде бугай. Ул үзен һаман да бәйсез, ирекле тотып, ике иптәшенә ымлады.

— Товарлар күз алдыгызда. Арабыздан кайсыларыбыз ошый, шуны сайлыйсыз. Исәп-хисапны без халыкара такса белән йөртәбез: йөз доллар!

— Йөз доллар! — дип куйды Казимир, үзе дә сизмәстән телен шартлатты.

— Кхм-кхм, безнең өчен зур акча түгел, — дип коткарды Мөнир аны бу халәттән.

Казимир да, һушына килеп, Мөнирне:

— Әйе, әйе! — дип куәтләде.

Зәңгәр күзле, калку күкрәкле Шура, сүзгә кушылып:

— Акча биржасында долларның курсы шушы сәгатьтә ничек булуы, күтәрелүе йә төшүе безне борчымый. Андый ваклыкларга әһәмият биреп тормыйбыз. Тоньяк полюста да, көньяк полюста да доллар доллар инде ул. Ник, шулай ич? — дип өстәде. Ике бит уртасындагы чокырларны тагын да тирәнәйтеп серле елмайды: — Кирәксә, квитанцияләр дә бирә алабыз.

— Шурочка! «Шура, лишь на половину дура» дип әйтергә сезнең хакыгыз юк. Сез акыл иясе, сез умница! Сезнең һәр сүзегездә президент зирәклеге сизелә, — дип хуплады аны Мөнир.

Казимир да тамагын кырды:

— Чибәркәйләр, шартларыгыз болай түзәрлек, — диде. — Соңыннан без кыен хәлдә калмабыздыр бит, шәт?

Шурочка, аның соравын туры мәгънәсендә аңлап:

— Медицина белешмәләребез үзебез белән, — диде.

Егетләр берьюлы тамакларын кырдылар.

— Күреп торабыз, сез эшлекле кызлар. Ул чакта кичекмичә сөйләшүләр өстәле артына утырдык, — дип, Мөнир учын учка сукты. — Берүк гафу, кадерле кунаклар. Сез киләсен белмәдек. Мин ялт кына буфетка төшеп меним. Болай, бераз авызны чылатмый, сездәй ут кызлар белән гәп корып җибәрә алмабыз без, — дип, Мөнир костюмын кия башлады.

Лариса аңа ашыкмаска ишарә ясады.

— Бер шешә шампан, шоколад плиткәсе сез түләгән такса хисабына керә. Ату бит, йөз доллар дигәч, әнә Казимирның күзләре орбитасыннан чыга язды, — дип, Лариса бүлтәеп торган сумкасын чыжлатып ачты да журналлар өстәленә бер шампан чыгарып бастырды. — Сезгә күп тоелган йөз доллардан өлеш көтүчеләрнең күпме икәнен белсәгез икән сез. Ун доллары ишек төбендә швейцар булып торган отставкадагы милиция майоры Мусинныкы. Бездән җыйган долларларга «БМВ» алды инде.

— Ун процент! Кая шулхәтле комсызлана? — дип сорады Казимир.

— Һәр клиенттан ун процент өлеш чыгармасаң, ул сине кертми генә, аның кулында блат! — диде Шура, ярым көлемсерәп.

— Һәр клиенттан ун процентны администрациядә утырган Марта җыеп бара.

Мөнир, гаҗәпкә калып:

— Ул ит бүкәненә тагын ни өчен өлеш чыгарасыз? — диде.

Моңарчы сүзгә кушылырга ашыкмаган Марина, яңгыравыклы тавышы белән:

— Ә клиентларны безгә кем таба? Кайсы бүлмәдә кемнәр яшәвен ул әйтеп тора бит, — диде. — Марта безнең ышанычлы контрразведчигыбыз!

Лариса, үзенә игътибар сорап, уң кул бармагын күтәрде.

— Без төп мәсьәләдән читкә тайпылабыз. Руслар «Время — деньги!» диләр. Аны югалтмыйк. Сез, егетләр, аңлагыз, эштә без шампаннан гайре градуслы эчемлекләр эчмибез. Не положено!

— Һәр клиент белән аракы чөмерә башласаң, бер атнада тиражга чыгуың бар, — дип куәтләде аны Шура.

Аз сүзле Марина да:

— Ә тиражга чыгар көннәребез алда әле, — диде.

— Бр-р-р! Ул көнгә калганчы мин лутче рельсларга ятам, — диде Шура.

— Алайса, хөрмәтлеләрем, ничек дип әйтим, без сезнең ихтыярда, — диде Мөнир.

Лариса шунда ук:

— Ә без сезнең ихтыяжда, — дип өстәде, күп сүз — юк сүз, дип, үзләренә күрсәтте: — Өчебез дә кала алмыйбыз бит инде. Сайлагыз. Кемгә кайсыбыз ошый. Шунысына сөенегез, сайлау мөмкинлеге бар.

— Альтернатива — демократик җәмгыять казанышы! — дип күз кысты Шура барысына.

Лариса сорауларын маңгайга терәп куйды. Ык-мык тору егетлеккә баллар өстәми. Бүлмә хуҗалары да батырая төштеләр. Казимир, утырган җиреннән торып, Ларисаны кулыннан тотты:

— Карлыгачым, мин сезне үз бүлмәмә кунакка дәшәм. Шушы минуттан ук.

Мөнир ак шарфлы кыйгач кара кашка ымлады:

— Ә минем менә шушы чибәркәй белән күзләрне күзгә төбәшеп, тезләрне тезгә терәшеп Бразилия кофесы эчәсем килә.

— Сезнең күңелгә ошаган бу кара каш, кара күзнең исеме Мөнирә була. Ул татар кызы, — диде Лариса.

— Мөнирә-ә?! — дип кайтарып сорады Мөнир. — Сез шаяртасыз, Лариса!

— Нигә дип?

— Чөнки минем исемем Мөнир.

— Беләбез, — дип елмайды Лариса. — Ишек шакыган бүлмәдәге егетләр турында безгә информацияне Марта һәрчак тулы бирә. Әйттем бит, һәр клиенттан ун процентны без аңа бер дә юкка гына түләмибез.

Шурочка шык итеп аягын тибеп куйды.

— Ә мин? Ә мин тагын артыкмыни? Ah Алла, бу ни хәл инде бу? — дип ризасызлыгын күрсәтте, әлбәттә, шаян тон белән, гаҗәп матур итеп авызын турсайтып.

— Шулай инде, бер бәхетсезгә — гел бәхетсез. Мин гомергә шулай ертык бәхетле булдым инде. Ah, kahәр, миңа клиентларны тагын Кавказ милләте вәкилләре арасыннан эзләргә кала микәнни? Ярый ла Лермонтовның «Безнең заман герое»ндагы Казбек төсле ут чаткысы сине аргамагы җилкәсенә салып, Кавказга урлап качардае туры килсә. Ә бит җиде айлык бүксә үстергәннәре дә туры килә. Бер хәлең юк, һөнәрең шул булгач, долларларын түләгәч, ихтыяҗларын канәгатьләндерергә туры килә.

— Арифметик прогрессия буенча үсә, — дип өстәде Марина.

Шурочкага шул җитә калды. Ул Маринага бармак янады:

— Син, Марочка, тыныңны чыгарасы булма. Сатлыкҗан син. Нинди клиентны тартып алдың. Куркыныч конкурент син, Марина. Борының да минеке төсле курнос түгел, белмим, клиентларны кай ягың белән каратасың? Операцияләргә бүтән мин синең белән чыкмыйм. — Бу үпкә сүзләрен Шурочка йөзендә шаян елмаю саклаган килеш тезә бирде. — Ә сездә, Мөнир дускай, нечкә зәвык дигән нәрсә абсолют юк, кызганыч, — диде ул, аңа бармагы белән төбәп. — Шунда инде мине сайлаган булсаң соң! Мин сине бу төндә бәхет диңгезендә йөздерә идем бит. Чөнки, чал башым, син миңа бер күз ташлау белән ошадың. Жәл, жәл, ни кызганыч, бу төндә башларыбыз бу мендәрдә булмаячак.

Шурочка көзге алдына басып чәчләрен төзәтте, иреңенә иннек якты. Аннары, биек үкчәле итекләре белән шак-шок басып, А.С.Пушкинның «Солтан патша» әкиятендәге:

А потом честные гости
На кровать слоновой кости
Положили молодых
И оставили одних.
В кухне злится повариха,
Плачет у станка ткачиха
И завидуют они
Государевой жене, —

дигән юлларны такмаклап, ишеккә юнәлде.

— Ә мин нисколечко не завидую. Тысячу и одну ночь вам, — диде дә шапылдатып ишекне япты.

Бүлмәдә кинәттән урнашкан тынлыкны бозып, Мөнир:

— Ай-яй бу Шурочкагызның теле! Беләүгә салып кайраганнармы диярсең. Кисми, ялап кына ала.

— Тыштан гына шулай. Чынында эчкерсез җан, ышанычлы иптәш, — диде Мөнирә.

* * *

Мөнирнең күңелендә кинәттән генә «ни белән тәмамланырга мөмкин соң бу тамаша» дигән уй туып куйды. Аның каршында бер төнгә йөз долларга сатып алган товары. Хәзер ул аны нишләтсә дә, хәтта арт ягына тибеп куып чыгарса да хаклы. Әйе, хакы бар. Әмма өч чибәр арасыннан сайлап алып калган әлеге Мөнирә туташ аңа ошый. Аны ошатмау өчен дөм сукыр, дөм чукрак булырга кирәк.

Бер мәлгә тып-тын калган, тик икесенең дә дөп-дөп йөрәк тибешләре генә ишетелгән бүлмәдә, соң хәзер нишлибез дигәндәй, аларның күзләре очраштылар. Мөнирә шөбһәсез елмайды. Мөнир ике буш кулына барып утны сүндерүдән гайре башка эш тапмады. Утларны сүндерү белән дә бүлмә дөм караңгылыкта калмады. Алтынчы каттагы бүлмәгә урамдагы багана башларындагы утлар ашыктылар.

Мөнирә исә, үз бурычларын белеп, ашыкмый гына чишенә башлады. Мөнир кинәттән, авызы кипкән, теле аңкавына ябышкан хәлдә:

— Үзем чиш-шендерәм-м, — дип пышылдады.

Мөнирә, бер дә исе китмичә, профессиональ тынычлык белән:

— Бюстгальтерны ычкындыру сезнең вазифа, кулыгыз салкын түгелме? — диде.

Бу сәер мәхәббәтне хәләл долларларыңа сатып алсаң да, моннан нибары ярты сәгатьләр генә элек ошбу дөньяда барын да белмәгән җанның билләренә кул салу, аны кочагыңа алу әллә ничек бит әле. Моңа ике йөрәкле булу кирәк. Мөнир кесәләрен капшады, шырпы кабы чыгарды, сигарет кабызды. Каршыдагы баганадан, хәйләкәрләрчә күзен кыскалап, бүлмәгә өзек-өзек ут төшә. Мөнир яртылаш кына артына борылды. Караса, өнсез калды, каршында шәп-шәрә сылу. Су анасы! Кагылырга өркерсең. Шунда Мөнир күңелендә һич көтмәгәндә, кисәтүсез-нисез йокысыннан уянган Везувий вулканыдай, комсыз ир-егетлек дәрте уянды. Тотып, җитәкләп, кыстап түгел, Мөнирәне күтәреп алды, инде күптән әзер, күптән җәелгән урынга салды.

Ике башны бер мендәргә салу, тәмле хуш ис килеп торган бер юрган астында калу Мөнир кочагындагы профессиональ күбәләк өчен, бәлкем, күнегелгән, гадәти гамәлдер. Әмма Мөнир өчен бу төнге күбәләкнең кайнар кочагы, үзенчә назы бераз гына ят та, тансык та. Долларны юкка гына түләмәгән. Мөнир кочагында әле генә затлы агачыннан өзгән хуш исле алма төсле, тыгыз тәнле, зифа сынлы сылу. Мөнирә очраклы төнге күбәләк кенә түгел иде. Иреннәр иренгә тию белән Мөниргә ул бәясе алдан түләнгән арзанлы секс кына түгел, ә башын җуярлык үз җан якынлыгын тәкъдим итте. Һәрхәлдә, Мөнир шундый тәэсирләр кочагында калды.

Котырынган чагында бар дөньяның котын алып котырынган Везувий вулканы да бераз хәл җыеп алырга, ялга туктарга ярата. Мәхәббәт тә шулай. Хәтта түләүлесе дә. Мөнир, сул кулын баш астына салып, берара тын гына ятып торды. Мөнирә аның уң кочагында, тыны да чыкмый. Маргарин түгел, татлы, хуш исле атланмай булып эреп төште. Әллә йоклап та киттеме? Илле тирәләренә җитеп моңарчы кичермәгән, бераз сәеррәк, бераз гына шөбһәлерәк тә халәт эчендә ята Мөнир. Үз кочагында яткан хатын-кызның чын мәгънәсендә тәмен белү чорын ир-ат халкы шушы яшьләрдә кичермиме икән? Юктыр, ир-ат өчен хатын-кыз һәрчак татлы зат... Торды да, аяк очларына гына басып, душ астына китте. Салкынча гына итеп су ачты. Коена башлады, Мөнирә дә йокламый икән.

— Ә мине нигә чакырмыйсыз? — диде ул, юрган астыннан башын чыгарып.

— Ah Алла икән! Кил! Урын монда икебезгә дә җитә.

Ике күкрәген генә сөлге белән каплап, Мөнирә дә душ бүлмәсенә керде. Әнисе сүзен тыңлап кечкенәдән гел кишер кимергәч, Мөнир озын буйлы булып үсте. Мөнирә аның култык астыннан гына.

Коену бүлмәсендә ут махсус тонык янамы. Хәер, йөз илле шәмле лампаның монда һич тә кирәге юк. Душ астына басучыларның тәнен генә түгел, җанын да мең вә мең җылымса тамчылар иркәли. Үзе белән янәшә баскан туташның курчактай матур, төз, сылу буй-сынына Мөнир янә бер сокланды.

Ә Мөнирә үзен бик иркен тота. Халыкта аларны профессиональ күтләкләр диләр бит инде. Әмма Мөнир бу минутта айлы кичтә түгәрәк күл уртасында тирбәлгән аккошны күз алдына китерде. Чөнки Мөнирә, чыннан да, нәкъ су өстендә җайга гына тирбәлгән ара-тирә әле бер, әле икенче канатын барлаган аккоштай, әле бер кулын, әле икенчесен баш өстенә күтәреп, үзенә бер ләззәт белән юына иде. Әйтерсең сәхнәдә балет биюе башкара!

Мөнир, картлач, үзе өчен уңайсызланды. Эштән кайткач диван таптаучы гына булса икән, юк бит. Эш бүлмәсендә әле һаман да ике потлы гер тота. Бүлмәсенә кереп, пәлтәсен чөйгә элүгә, башта шул гер белән уйнап ала. Өендә унар килолы гантельләре ничәү. Җай чыкканда аларны да шалтыр-шолтыр китерә. Кайберәүләр кебек кәбестә-кыяр тозлаганда бастыргыч итеп кенә асрамый. Әмма бу ике айлык бүксәне кая куешлы да түгел. Ни арада калка диген. Бу май катламы, шайтан алгыры, башка чакта, әйтик, пләждә аның үз яшьтәшләре арасында аны бизәр генә иде, бәлкем. Ә биредә уникаль очрак. Мөнир шул чак кына беленерлек корсагыннан да уңайсызланып, эчен эчкә җыярга тырышты.

Ә Мөнирәгә соң ни? Ул мондый гына бүксәләрне күрмәгән дисеңме? Мөнирнең шушы халәтен туры мәгънәсендә аңлап:

— Юкка уңайсызланасыз, хуҗам. Сезнең яшьтәге ир кешенең шундый кышлык запасы да булмаса, аны президиумга да сайламыйлар, — диде ул, шаян тавыш белән. — Андый запаслары да булмаучылар гел аста, сәхнәгә чыгып чүбек сүз сөйләүчеләргә гөп тә гөп кул чабучылар арасында булалар.

— Хуҗам?! Монысы тагын ни дигән сүз була? — дип кайтарып сорады Мөнир. — Сез мине рәнҗетәсез.

— Ә нигә гаҗәпкә калдыгыз? Ике арабыздагы килешү срогы чыкканчы хуҗам булмыйча, сез миңа кем буласыз соң?

— Абау! Ул сүзне алай да бүтән кабатлый күрмәгез. Нык сискәндерде ул мине.

Мөнирә кулындагы мунчалага калын итеп сабын сөртте.

— Аркаңны озаклап ирләрдән ышкытудан да татлы нәрсә юк бу дөньяда, — дип, мунчаланы Мөниргә сузды. — Кичә ванна кергәндә аркамны Эльвира гына ышкыганые. Җиде яшьлек баланың ышкуы инде аның.

— Инде шундый зур кызыгыз да бармыни?

— Булмыйча! Сез уйлаганча кысыр бер алаша түгел лә мин.

Мөнирә аңа һич аңлаешсыз сихри бер гүзәллек белән карады. Бу минутта ул чагыштыру таба алмаслык матур, саф, гөнаһсыз иде. Мөнир, үзе дә сизмәстән, аны кочакларына алды, күкрәк очларыннан үпте.

— Акчам гына җитсен инде түләргә, — диде ул, бераздан тирән тын алып.

Мөнирә аптырап калмады:

— Җитмәгәнен почта аша салырсыз...

Сатып алган мәхәббәт гаҗәп икән ул. Аның һәр минуты үзенчә кадерле. Нәкъ таксида барган кебек инде. Километрлар ишәйгән, үскән саен бәясе дә арта бара. Мөнир сөлге алып, Мөнирәнең чәчләрен, тәнен корытты. Аны ак җәймәгә төреп, кочагында гына янәдән караватына илтте. Суынырга да өлгермәгән урын-җиргә нарасый баладай бик кадерләп кенә китереп салган бу затка карата Мөнир күңелендә кинәттән генә ачу хисе, хәтта нәфрәт уянган төсле булды. Шушы чибәрлеге белән ул бу юлга нигә басты икән? Бер тамагын, кем әйтмешли, саф, намуслы, гөнаһсыз юл белән дә туйдыра алган булыр иде. Аның күңелендә кинәттән генә бу затны үзенеке, бары аныкы гына итү теләге туды. Ә бу мөмкин түгел. Башыңны ташка орсаң да. Азгын җан! Бүген ул Мөнир кочагында иркәләнә. Ә кичә кем кочагында булган? Иртәгә кемнекендә булачак? Янына бүтән ятмаска булды. Кинәттән гайрәте чикте.

Мөнир ишеген йолкырдай итеп суыткычны ачты. Ярты стаканнар чамасы коньяк салды. Аны баскан килеш кенә голт-голт итеп йотып җибәрде.

Мөнирә, юрган астыннан гына ике күзен чыгарып:

— Ә миңа-а-а? — дип сузды. Йөзендә тик сабыйлык.

— Сез бит, градуслы эчемлекләр эчмибез, дидегез.

— Бушлайгамы? Кем эчмәс икән? Бигрәк тә шундый тәмле чәп-чәптән соң, — диде Мөнирә, елмаеп.

Мөнирә, җәймәгә генә төренгән хәлдә, кыска аяклы өстәл артына күчте, ипләп утырды. Мөнир аңа төбенә бер бармак калынлыгы эчемлек салынган стаканны сузды.

Мөнирә стакан төбенә карап башта:

— Бр-р-р, — дип куйды, аннары башын артка ташлап эчеп җибәрде. Кулындагы сәгатенә күз салды. — Китәргә дә вакыттыр инде. Чәчләр кибеп җиткәнне генә көтәм дә. Эльвираның бакчага киеп барасы күлмәкләрен үтүклисем бар иде.

— Нигә ашыгасыз? Сезне куган кеше юк. Иртәнгә кадәр калыгыз. Әгәр миннән туйсагыз, ягъни туйдырсам, мин диванга күченәм, — дип, Мөнир аны китмәскә, таң атканчы калырга кыстады.

Шуңа ихтыяҗлары төшеп, бер-берсен җентекләп өйрәнгәндәй, бер-берләренә төбәлешеп, алар байтак вакыт сүзсез утырдылар. Стаканнарының төбенә генә салып, янә коньяк уртлап куйдылар.

— Мөнирә, сез шуны үзегез сизәсезме, беләсезме, абау чибәр бит сез, — диде Мөнир. — Казанның иң гүзәле түгел микән әле... Әллә мин башымны жуяммы? Син сихерче түгелме? Мине сихерләмәдеңме?

— Аңлыйм тел төбегезне, — дип бүлдерде аны Мөнирә. — Шулай була торып та, ничек проститутка, ягъни профессиональ тәтәй булдыгыз, дип сорамакчы сез. Шул сорауны маңгаема төбәп әйтергә кыюлык җыя алмый утырасыз. Шулай бит?

— Сезнең бу һөнәрегезне иң борынгы профессияләрнең берсе итеп санауларын белсәм дә, сездәй гүзәл туташ белән конкрет очрашкач, шундый сорау туып куйды шул күңелемдә. Җавап таләп итмим. Уздырып кына да җибәрә аласыз.

— Ә нигә җавап бирмәскә диегез әле. Җавабы да әзер булганда, тел очында гына торганда, — дип, Мөнирә ипләбрәк утырды. — Башта төп җавапны шуннан башлыйк. Без соң, профессионаллар, кем алдында, нинди гөнаһ кылган? Сезләрне, долларга бай ирләрне, хет бер кичкә генә булса да бәхетле

итүдән гайре. Чәче таралмаган, өстенә иске халат, аягына тапталып беткән башмак кигән хатыннарыннан тәмам туйган бичараларны дип өстәсәм дә ялгыш булмас. Сез менә инженер-төзүче, хәләл ризыгыгызны төрле проектлар, исәп-хисаплар төзеп, ягъни башыгызны эшләтеп табасыз. Шахматчылар да шулай. Тамакларын пеләш калганчы башларын эшләтеп туйдыралар. Ә менә безнең күршедә генә бер егет бар. Артист. Иртән балконга чыгып җырлап җибәрсә, тавышы баш очыннан очкан самолет тавышын баса. Әллә ничә диск популяр җырларын чыгарды инде. Ризыгын тамагы белән җырлап таба.

— Сез хаклы, — диде Мөнир, сүзнең кая таба барышын төшенеп тә җитмичә. — Пианист — йөгерек бармаклары, боксер — көчле йодрыклары белән.

Мөнирә дәвам итте:

— Футболчы — җитез аяклары белән. Дык итеп китереп тибә дә выжт иттереп капкага тупны кертеп тә куя. Ике бозауга кибәк аерып бирерлек башы булмаса да, киерелеп «Форд» машинасында йөри.

— Кайчак бигрәк усал телле булып куясың, Мөнирә. Футболчы дигәч тә, нишләп аларның башы булмасын, — дип елмайды бүлмә хуҗасы.

— Әй-й, беләм лә мин аларны. Минем үз ирем футболчы иде, — дип кул селкеде Мөнирә. — Ә менә минем бүгенге заман компьютерлары белән бәхәскә кереп, математик тигезләмәләр чишәрлек башым да, конькида төрле фигуралар ясап шуарлык аякларым да юк. Ә минем башка әгъзама сорау зур. Ходай миңа башкасын мул биргән. Барча җиһан базар мөнәсәбәтләренә күчкән заманда нигә мин тамагымны шул юл белән туйдырмаска тиеш? Ихтыяҗ булгач! Сезнең миндә ни эшегез бар? Ә минем — сезнең артымны сөртергә ярамаган әхлагыгызда. Прәме аптыраш, минем үземә ошаган юл белән ризык табуым кайберәүләр тарафыннан гөнаһ санала икән. Гаҗәп! Шулай түгелме?

— Абау, Мөнирә, гүзәлкәем, миңа калса, бик кырыс һәм бик затсыз фәлсәфә бит бу! — дип бүлдерде аны Мөнир. — Бу минутта сиңа чәпәп кенә әйтерлек үткен аргументым да юк югын. Шулай да фәлсәфәңне дә кабул итә алмыйм. Юк, юк, булмый.

Мөнир урыныннан торып йөренеп килде.

— Ләкин мин шуның белән бәхетле. Синең белән уздырган бу мең дә беренче кич гомергә истән чыкмас инде, — дип, янә урынына килеп утырды.

— Фахишә белән кунган кичме? — дип, Мөнирә башын артка ташлап көлеп җибәрде. — Сатып алган мәхәббәт шулай татлы булырга тиеш. Килешәм. Булса, бер йотым гына салыгыз әле, — дип, стаканын сузды. Мөнир икесенең дә стакан төбенә коньяк тамызды.

— Алай да, Мөнирәкәй, теләмәсәң, җавап бирмә. Тормышыңны шушы юл белән бизәргә, дип әйтимме соң, нәрсә сәбәпче булды. Беренче адымны ясарга нәрсә мәҗбүр итте? Бер сүзем юк, бу профессиянең яшәргә хакы барын таныган хәлдә соравым. Зур мохтаҗлыкмы? Ачлыкмы? Әллә башка сәбәпләрме? Әйтик, әллә берәрсенә үч итепме? Андый очракның булуы да бик мөмкин.

— Аның сәбәпләрен кем уйлап торган инде. Хәзер күңелне бай клиентка тап булу, яхшы гонорар эләктерү генә борчый. Ә безнең һөнәр, үзең күрәсең, хәтәр, әмма яхшы түләнә. Анысын да счеттан сыза алмыйсың. Ә соң кемнең бай яшисе килми? Коммунистлар гына ул «не в деньгах счастье» дип, халыкның башын катыралар иде. Счастье именно в деньгах! Бөек Тукаебыз да:

Акчаң барда, бар да дус та, бар да яр.
Акчаң исе чыкмый торса, бар да яныңнан таяр, —

дип, бер дә юкка гына язмаган. «Берәрсенә үч итеп түгелме?» дип сорадыгызмы әле? Андый хәлнең дә булуы мөмкин. Ирем Рәүфне, башсыз футболчыны, машина бәрде. Кулымда — урын өстендәге хаста әнием, өч яшьлек кызым. Эшемдәге түрәм мине сөяркәсе булырга кыстый. Бүлмәсенә чакыра да көпә-көндез диванына аударырмак була. Мин, әлбәттә, күнмәдем. Ә ул мине кыскартып куйды. Кая барырга? Айлык хезмәт хакы алып килмәгәч, очын очка ялгау кыенлашты. Әмма бирешмәскә була. Әнием пенсия ала. Әтисе өчен кызыма да ярыйсы пенсия билгеләделәр. Тора-бара эше дә табылыр иде аның. Мин бит автоматчик, приборлар буенча авиация техникумын тәмамладым.

Ә урамда тормыш гөжли. Чат саен лотоклар калка. Криминал элементлар котырып байый. Халык хәерчеләнә. Миңа да тормыш дулкыннары көймәмне ярга бәреп тәмам чәлпәрәмә китергәнне көтәргәме? Шиш, бәрми генә торсын әле!

Инде бик кызыксынсаң, сөйлим алайса, — дип ачылып китте Мөнирә. — Беркөнне шулай иртәнге якта күрше хатыны Гөлчирә кергән. Бик булган, бик уңган, ут хатын инде. Ул да тол, ике малай үстерә. Яшелчә кибетендә җиләк-җимеш сата, өенә дә эш алып, бөтен ишегалды хатыннарына күлмәк-халат тегә. Кыскасы, кулыннан килмәгән эше юк. Менә шул Гөлчирә кергән. Минем замоклы зур гына сумкам барые. Шуны сорый.

— Каравай ягындагы бакчаңа яшелчә җыярга барасыңмы соң? Гөлчирә апа, нигә сиңа бу зур сумка? — дип сорадым.

— Чукынып китсенсәнә бакчасы, яшелчәсе, — ди бу. — Иптәш хатын белән Төркиягә җыендык. Истанбулны айкап кайтырга булдык әле. Товар, төрле кием-салым бик арзан ди анда. Майлы күзле төрекләргә күз дә кыскаласаң, каш сикертсәң, почти бушлайга үзең күтәрә алганча товар төяп кайтырга була икән.

Мосафирәләргә уңышлы юл теләп сумкамны суздым. Атна-ун көннәр дә узмагандыр, ишекне янәдән Гөлчирә шакый. Йөзе кояш булып балкый. Сумканы суза, кул артың җиңел булды, ди. Миңа бүләккә бик матур йон кофта да алып кайткан.

Миндә аның гына кайгысымы, анда минеке дигәндәй, шуннан соң байтак кына күрешми тордык. Инде кыш өстендә урамда очратсам, Гөлчирә өстендә заманында ЦКның политбюросы членнары хатыннары да кимәгән затлы тун. Кашын буяган, сөрмә тарткан, авызына иннекне бер кашык яккан. Майт якасын димәссеңме?!

— Кемне таладың? — дим.

Көлә. Авызын җыя алмый.

— Кемне булсын? Төрекләрне инде, — ди.

Бу перестройка дигән нәрсә кемнәрнеңдер тез астына сукты. Ә кемнәрнедер йонлач, җылы кочагына кочты. Ут Гөлчирә дә җылы кочакка эләгүчеләр арасында. Күп тә узмады, шәһәр уртасында ике йөз меңгә яңа фатир сатып алды. Моңарчы үзе яшәгән бер бүлмәле фатирын ике үзбәккә отышлы арендага биреп, шәһәр уртасына күченде. Ике улы да, елына унар мең түләп, рабфакка керделәр, икесе дә «Мерседес»та йөриләр. Беркөн кичләтеп Гөлчирә янә безгә килеп чыкты. Элек тә шулай үз итеп кереп-чыгып йөри иде ул. Бу юлы кочагы тулы кәнфит-күчтәнәч.

— Мөнирәкә-әй! — ди бу, күчтәнәчләрен өстәлгә бушатып. — Җир шары әйләнешен тизләтте бит. Син әллә шуны сизмисең? Ә син шушы чибәрлегең белән үз бәяңне үзең белмисең. Кара, кызый, орбитадан төшеп калуың бар.

Мин моның тел төбен әлегә һич аңламыйм.

— Шушы араларда тагын Истанбулга очабыз. Теләсәң, ияртәм. Байыйсың килсә, барасың. Төрекләрдә мал җитәрлек.

Гөлчирә өстендәге затлы өс-башы өстеннән тагын бер күз йөртеп чыктым.

— Яхшы булырые ул, — дидем. — Ләкин анда буш кул белән барудан ни файда? Ә мин яңа эшкә әле урнашып кына йөрим. Кесәм буш.

— Акча турында уйлама син. Акча бездә бер букча. Кирәгенчә үзем биреп торырмын, — ди бу. — Әлбәттә, процентка. Баегач, процентлары белән түләрсең.

Мин ык-мык торган арада, хәрбиләрчә генә кырт кисеп:

— Әзерлән! Әзер тор! Иртәгә кереп алырмын, — диде, лап-лоп атлап чыгып та китте.

Самолеттан чыгышында төрекләр машиналар белән үзләре көтеп торалар икән.

— Наташа, әйдә, миңа утыр. Теләгән җиреңә бушлай илтеп куям, — дип, бер алдыңа, бер артыңа төшәләр.

Рәсәйдән килгән бар хатыннар да алар өчен Наташа! Наташа! Бетте-китте. «Дуслык визиты» белән килгән һәр хатынның үз кибете, үз кибетчесе бар. Үзенә кирәк товарларны шуннан гына ала. Килгән юлы буш кайтмыйм, товарларны да юньрәк бәягә алыйм дисәң, кибет хуҗасы белән бер кич кунасың. Анысы да зур гөнаһ саналмый. Рәсәй хатыннары, Наташалар дигәндә, төрекләр тәкатьсез икән алар, малларын кызганмыйлар.

— Барысы да алай түгелдер инде? — дип куйды Мөнир. — Ул чакта бу ни була соң инде бу?

— Алай түгелен түгелдер дә, — диде Мөнирә. — Әмма анда хәтле баргач, кемнең буш кул белән кайтасы килсен? Ә нәфес? Шул бер баруында баеп яисә тәмам бөлеп, кабалага чумып кайтуың бар. Күрше самолетка биш-алты сумка төягәндә, салонга син бер төенчек тотып кына керсәң, синең белән бер рейста килгән хатыннар синнән бот чабып көләчәкләр әле. Төрткәләп төшереп калдырмасалар. Чартер, ягъни товар ташу рейслары пассажирлары арасындагы үзара мөнәсәбәтләр «тайга законнары»ннан күпкә кырыс, күпкә рәхимсез. Әмма шуны онытма, биш долларга да алырга мөмкин булган шул ук күн куртканы нигә әле унбиш долларга алып торырга. Сиңа ярым бәясенә генә товарын биргән төрек белән бер кич кунудан гына синең бер җирең дә кимеми. Гөлчирә әйтмешли, аннан гына кыек атлый башламыйсың. Бизнес кубызына биергә булгансың икән, әхлак дигән нәрсәне онытып торырга туры килә. Бу нәрсә төрекләрнең хәтта халык авыз иҗатында да чагыла. Алар еш кына: «Минем кызым шулхәтле оялчан, итәген күтәреп битен каплый», — дип сөйләргә яраталар.

— Йә, йә. Килеп төштегез Истанбулга? — дип бүлдерде Мөнирәне бүлмә хуҗасы.

— Килеп төштек. Самолеттан чыктык, — дип эләктереп алып китте Мөнирә. — Гөлчирә мине туптуры үзе белгән, моңарчы да товарлар алган Госман атлы төрек кибетенә алып китте.

Сакал-мыегын кырган, какча гәүдәле, алтмыш тирәләрендәге төрек безне якты йөз белән каршы алды. Башта куе чәй белән сыйлады. Әллә хатын-кыз затын моңарчы бер дә күрмәгән, күзләре ут кебек яна.

— Җаныгыз ни тели, шуны сайлагыз, — дип, каплаулы амбары эченә кертеп җибәрде. Минем кызым кияү күргәнме соң дигәндәй комсызланып ябыштым киштәләрдәге товарларга. Ике бәйләм күн курткалар, йон шарфлар, матур җәймәләр бәйләдем. Ул көнне Казанга самолет бар иде. Госман белән якынча гына исәп-хисап ясап, тагын киләсебезне әйтеп, самолетка ашыктык. Үз машинасы белән илтеп куйды. Казанга кайттык. Безнекедәй товарлар бөтен башкаланы баскан. Товарларыбыз үтми генә. Бигрәк тә минекеләр. Әҗәткә, процентка биреп торган акчага алынган товарлар бит. Бер бәхетсез гел бәхетсез. Гөлчирәнең олы улы «Мерседес» белән бер баланы бәрдергән. Эше судта. Малайны төрмәдән йолып калырга срочно күп акча кирәк. Әҗәтеңне түлә, дип, ул килеп җитте. Каян алып түлим?

Алып кайткан товарларның барысы сатылмый ята. Гөлчирә утны-суны кичкән җан:

— Ул чакта янәдән очтык Истанбулга, — ди.

— Кызымны кибеткә сөткә җибәрергә акчам юк, — дим.

— Истанбулдагы әнә шул Госманга кияүгә чыгасың. Не рассуждай. Төрек бае хатыны булып, май эчендә йөзеп кенә яшәрсең. Апаңа рәхмәт әйт, тилебаш. Мин инде барын да көйләдем. Килеп төшү белән мулла дәшеп никах укытабыз. Бетте-китте, вәссәлам. Син никахлы ир хатыны. Юкса миңа булган әҗәтеңне, кызыкаем, гомер буена да түләп бетерәсең юк. Ә мин синең бер карында яралган апаң түгел. Минем үз проблемаларым да менә муеннан. Карыша-нитә калсаң, кара аны!

Ул Госман дигән төрекнең, балакаем, әллә моңарчы бөтенләй хатын-кыз куены күргәне булмаган, тәмам үтерә язды ул мине. Төнлә дә, көндезләрен дә йокы бирми. Кибетен дә барып ачмый, гел минем өстә. Үтерә дип торам.

— Шултикле үк комсызландымыни? — дип сорады Мөнир.

— Әйтәм бит, үтерә язды, — диде Мөнирә, нарасыйларча беркатлылык белән. — Шул хәлгә күнегеп, һич торып китешле булмады. Кыскасы, бер ай дигәндә качтым мин аннан.

Утлар-сулар кичеп кайтып төштем Казанга. Салкын көз, җепшек кар ява. Ә мин муеннан бурычта. Сырхау әнием урын өстендә. Эльвирам корчаңгы йоктырган, кулы-аягы, колак артлары чат кутыр. Башта аны мунча керттем, күкертле май белән кутырларын майладым. Кутырлар анысы бер атнадан кубып төшәр. Ә менә бурычлар белән нишләргә? Гөлчирә безнең күршедәге фатирына ике үзбәкне кертеп калдырды, дигәнием бит. Икесе дә колхоз базарында өрек-йөзем белән сату итәләр. Бик иркен типтереп яшиләр. Арадан яшьрәге күзләрен бик майландырып карый миңа. Минем белән сөйләшкәндә хәтта иреннәрен ялап куя.

Беркөн шулай өс-башымның да затлысын киеп, чәчләремне дә ясап, махсус рәвештә базарга төштем. Өрек-йөзем сатучылар бүлегенә кердем. Күршебездә яшәгән үзбәкләр мине ерактан күреп алдылар, каршыма йөгереп чыгып, үз яннарына дәштеләр.

Йосыф исемлесе миңа:

— Мөнирә гүзәлкәй, Казанның иң яхшы ресторанына чакырам, барасыңмы? — ди.

— Мин бит бик кыйбат торам, акчаң җитәрме соң, — дидем.

— Акча бездә бер капчык. Ә синдәй чибәр белән бер сәгать утырырга җаным жәл түгел.

Бардык «Акчарлак»ка. Бик күңелле утырдык. Сыйландык.

— Кундыңмы аның белән? — дип бүлдерде аны Мөнир.

— Ә нигә кунмаска?! Беренчедән, Йосыф матур килеш-килбәтле егет. Ресторанга да европача киенеп килгән. Бармаклары тулы алтын йөзекләр. Үз-үзен тотышы да европача. Гыйлеме буенча да югары белемле агроном икән. Мондый егет белән нигә кунмаска, бергә булган сәгатьләр өчен аннан нигә гонорар түләтмәскә диген. Шахматистлар — башлары, скрипкачылар бармаклары белән эшләгән акчаны нигә миңа башка әгъзам белән эшләмәскә? Югары цивилизациягә корылган җәмгыять ләбаса бу! Аның принцибы бик гади: бу җәмгыятьтә акчаны һәркем үз кулыннан килгәнчә ясый. Һәркемнең үз кәсебе.

— Җитте, җитте! Тукта шушында, — диде Мөнир, кискен рәвештә. — Барыбер аңламыйм мин сине. Үзеңә карата, Мөнирәкәй, башка сыймаслык катгый сөйлисең. Бу коточкыч мәрхәмәтсезлек! Миңа бик авыр моңа ышанырга.

— Берүк, Мөнир дускаем, беткән икән бу бичара җан дип уйлый күрмә тагын минем турыда, — диде Мөнирә, беркавым тын гына уйланып утырганнан соң. — Мөнирәне бетерерсең, бар. Мин хәзер суга салсаң, батмыйм, утка салсаң, янмыйм, мин хәзер торпеда ала алмый торган миноносец, акыллым. Апаң хәзер көн узган саен акыл җыя бара. Менә күрерсең, бераз мая туплау белән азык-төлек сата торган кибет йә шунда үтүк, велосипедлар ремонтлый торган мастерской ачып җибәрәчәкмен. Алдагы килүләреңнең берсендә заманча бизәлгән кибет каршында бөерләренә таянып кәттә генә басып торган горур ханым ул мин булып куймагаем. Борының чөереп, сәлам дә бирмичә, кибетемә сугылып, товарларыма күз салмыйча, аларны мактамыйча уза күрмә. Юкса нык үпкәләп калырмын. Киләсе сайлауларда, бәлкем, үземне Дәүләт Думасына депутатлыкка кандидат та итеп күрсәтермен әле. Минем профессия ияләре анда бу сайлауларда да күп тавыш җыеп уздылар шикелле.

— Ул көннәрне тиз арада күрергә язсын, — дип хуплады Мөнир. — Һәрхәлдә, мин ике куллап тавыш бирәчәкмен. Доверенныең булырга да әзер.

Инде таң аткач, тәмам яктырып килгәндә генә, алар икесе дә изрәп йоклап киттеләр. Мөнир сәер бер халәт кичерә. Бер карасаң, чын бәхетсез, икенче карасаң, дөньяның артына тибеп яшәгән бу җан иясенә моңарчы татылмаган ниндидер якынлык, хәтта ихтирам хисе уянды. Бу минутта аның кочагында ут-суларны күп кичкән төнге күбәләк түгел, әйтерсең бишек баласы йоклый. Нарасыйның татлы йокысын бозудан куркып, Мөнир кулын да кузгатмый. Мөнирә үзе дә, әнкәсенең җылы канат астына сыенган бәбкәдәй, аңа сыенганнан-сыена бара. Борыны белән кармалап, кочакта тагын да җылырак урын эзли.

— Тәмам барып капланганчы, текә кыяга бәрелеп чәлпәрәмә килгәнче, тормыш көймәсен берәр ышанычлы ярга юнәлтәсе иде, — дип пышылдады ул. Әллә төшендә, әллә йокы аралаш саташыпмы? — Ләкин дулкыннар ирек бирми, алар аяк чала.

Мөнирә, әнкәсенең җылы имчәген эзләгән кәҗә бәтиедәй, иреннәре белән Мөнирнең иренен эзләде. Ана сөекле нарасыен үпкәндәй, аны пәп итеп кенә үбеп алды, йокысын өзмәде, иреннәрен генә чәп-чәп китерде. Мөнирә гөнаһсыз нарасый йокысы белән йоклый иде.

Алар уянганда иртәнге уннар булгандыр инде. Кунакханә бушап калган. Икесе дә юынып, киенеп, үзләрен тәртипкә китерделәр. Мөнир кунагын уналтынчы катка иртәнге чәйгә алып менде. Бер-берләренә үтә ихтирамлы матур парлар булып алар озаклап чәй эчтеләр.

Мөнирә, үзен тагын да гүзәл күрсәтә торган ак йомшак шәлен муенына салгач:

— Мин алдарак чыгыйм, ә сезне тышта көтәрмен, — диде.

— Ә бергә чыгарга ярамыймыни?

— Авторитетыгыз төшмәсме соң? Монда кемнәр белән чуалганыгызны хатыныгызга җиткермәсләрме?

Мөнир барысына да кул гына селтәде:

— Минем өчен андый барьерлар, андый кысалар күптән яшәми.

Кунакханәдән чыккач, каршыда гына җир асты юлы. Мөнирә ниндидер бер рухи якынлык белән Мөнирнең шарфын төзәтте. Мөнир перчаткасы белән Мөнирә иңбашына кунган кар бөртекләрен какты. Бу пар әйтерсең күп еллар бергә гомер кичергән. Аңлашып, бер-берләрен өзелеп яратышып, әйе, бер-берләрен өзелеп яратышучылар гына бер-берләренә һәрчак шулай игътибарлы булалардыр.

Мөнир Мөнирәне чәчәк сатучы грузин егетләре каршында туктатты:

— Теләгәнчә ал. Кочагың тулганчы, — диде.

Мөнирә бөтен йөзенә елмайды:

— Бик теләп!

— Берәү, икәү, — дип санап, хризантемалар сайларга кереште. — Җидәү! Стоп! Мөселман дөньясында да, борынгы грек мифологиясендә дә җиде иң бәхетле сан бугай. Мин нәкъ җиде хризантема сайладым. Кара, нинди гүзәлләр. Рәхмәт!

— Ә син алардан да гүзәлрәк! — Мөнир Мөнирәне үзенә кочты.

Алда аерылышу минутлары. Мөнирнең күңелен моңарчы кичермәгән, ул татымаган тирән сагыш, моң сарып алды. Мөнирә исә ашыга, әледән-әле сәгатенә карап ала. Мөнирне ул чираттагы клиенты итеп кенә карыймы шунда. Кабаланмый да, дулкынланмый да, дулкынланuын да әллә ни сиздерми. Сиздерер, бар. Хатын-кыз заты туксан тугыз катлы. Әмма Мөнир аның күзләрендә дә тирән сагыш чаткысы күрде. Мөнирә никадәр яшерергә тырышса да, тапты аларны Мөнир.

Үзе исә, шыңшу дәрәҗәсендә борынын тартып:

— Шуның белән шул. Диңгездәге кораблар төсле мәңгегә аерылышабызмыни? Минем сезгә көймәгезне ышанычлы ярга чыгарырга булышасым килә... — диде.

Мөнирә аның бу сүзләрен ишетмәгәнгә, берни аңламаганга салышты. Юк, мондый гозерен ул берәүгә дә әйтмәде.

— Казанга икенче килгәндә, кич уздырырга күңелле кызлар кирәк булса, автоматтан 09 җыегыз. Оператор кыздан 16 нчы номер белән тоташтыруны сорагыз. Мин шунда булырмын. Безнең бу профессия ветераннарына картлык көннәрендә хөкүмәт тарафыннан пенсия каралмаган, гәрчә хезмәтебез җаваплы, кыен һәм хәтәр булса да. Шунлыктан хәләл көчең белән дәүләткә дә хезмәт итәргә туры килә. Ә депутат булып сайлансам, мин бу мәсьәләне, һичшиксез, көн тәртибенә куячакмын, — дип елмайды. — Хәзергә, Мөнир, сау бул, — диде дә китеп тә барды. Әмма Мөнир бүләк иткән хризантемаларны ул гомергә сакларга теләгәндәй, аларны кочагына кочып, бик сак атлады. Каршысына агылган халык төркеме арасыннан узганда да чәчәкләрне ничек саклап баруын Мөнирә күздән югалганчы карап калды Мөнир.

Башкалага Мөнирнең моннан соң да эше төшеп торды, Мөнирәне өзелеп күрәсе, колак яфрагыннан гына булса да үбәсе килеп сагына иде. Мөнирәнең ярга чыгарга усал дулкыннар аяк чалган көймәсен ышанычлы ярга өстерәргә дә конкрет тәкъдимнәре бар иде егетнең. Автоматтан 09 җыеп, шәһәр телефон челтәреннән 16 нчы оператор белән тоташтыруны килгән саен күп мәртәбәләр сорап карады ул.

Башта аннан серле генә итеп:

— Сез кем? — дип сорыйлар.

— Агасы, энесе, дусты, ире, — дип тә карады Мөнир.

Трубкада башта җиңел генә кеткелдәп куйган тавыш ишетелә. Аннары шулай ук серле итеп:

— Юк бит ул. Бүген аның ял көне, — диләр дә трубканы куялар. Ә менә шул 09 салонын эзләп барып керергә Мөнирнең ничектер кыюлыгы җитми. Әмма анда барып чыгарга, ачмасалар, бәреп керергә җыена әле ул. Мөнирәне бер күреп сөйләшми, колак яфрагыннан гына булса да үпми, ә көймәсен ышанычлы ярга тартып чыгармый торып, Мөниргә бу дөньяда яшәүнең максаты югала башлаган төсле тоела.

Йолдызлы учаклар

Башлыклары Шәүкәт Бакиров булган студентлар төркеме Суоми иленә — Финляндия чикләренә яп-якын торган Вуокколо тимер юл разъездына эңгер-меңгерләрдә килеп төште. Студентларның кышкы каникуллары башланды бит. Шәүкәт һәрчак шулай тирәсенә үзедәй хыялыйларны туплый да аларны берәр якка туристик сәфәргә алып чыгып китә. Булмаган җирләре, аяк басмаган почмаклары калмагандыр инде. Төньяк һәм Урта Уралда булдылар. Бөтенсоюз слетларында беренчелекне яулаган Казан егетләрен Кавказ, Кырым да хәтерли булыр. Узган җәйне чал Байкал буйларына да барып чыгып, аның ярларында учаклар кабызып, суында колач салып йөзеп йөреп кайттылар. Беренче курста укыганда, Октябрь бәйрәме көннәрендә Мари тайгасына бер атналык туристик сәяхәткә барып кайтканнан соң төште спортның бу төренә Шәүкәтнең гыйшкы. Менә бу юлы үз күзләре белән Төньяк балкышын күреп кайтырга Кола ярымутравына ук аяк бастылар әле.

Вагоннан чыгып тар гына перронга баскан студентлар сәер бер халәт кочагында калды. Әйләнә-тирәдә абсолют тынлык. Ирексездән әллә соң моңарчы берәү дә булмаган яңа планетага аяк бастыкмы дип уйлап куюың бар. Чөнки монда күк киңлекләренә ак тасмалар сузып, баш очында реактив самолетлар да һава ярмый. Зур шәһәр урамындагы төсле көлтә-көлтә булып троллейбус чаткылары да чәчрәми, осталыкта берсен-берсе уздыра-уздыра, рельслар өстендә трамвайлар да чечетка биешми. Рәсәйнең урта полосаларында яшәп шау-шуга күнеккәннәр өчен бөтенләй ят, һичкайчан татымаган мохит, сәер тынлык. Күз күреме җир-араны йөзеңә-киемеңә сыланышлы сыек сөт сыманрак томан баскан.

Казан студентларын бу тарафларга алып килгән шыгыр-шагыр поезд Вуокколо разъездында ике минутлар чамасы гына торды. Бу полустанокта вагоннан төшүчеләр дә алар гына булды. Сыек томан сарган эңгер-меңгер перронга чыгып басу белән, мондый сәер мохиткә кинәттән генә күнегеп китә алмаган студентлар вагоннан бушаткан әйберләрен — капчык-рюкзакларын сүзсез генә барлыйлар.

Будённый үзе көнләшерлек мәхәббәт мыеклы проводник агай аларны:

— Хөрмәтле турист әфәнделәр, бу тарафларда климат бик кырыс, бик сак йөри күрегез инде, — дип озатып калды. — Тышта кышның самый ыжгырган чагы. Ә сез, яшьләр, күрәм, бик җиңелчә киенгәнсез.

Поезд ашыкмый гына кузгалып киткән чакта, Шәүкәтнең:

— Ихтирамга вә игътибарга лаеклы студент әфәнделәр! Ашыгычлык йә ваемсызлык белән вагонда нәрсәне дә булса онытып калдырмадыкмы? Кабат барлагыз әле. Бигрәк тә акыллы башларыгызны вагон шүрлегендә калдырмадыгызмы? — дигән соравына җавап бирүче булмады.

Тик бераздан гына Фаягөлнең:

— Башкаларда эшем юк. Минеке урынында. Кулым белән капшап торам. Шәт, үземнеке бугай, — дигән яңгыравык тавышы ишетелде. — Викторның да башы урынында. Ә менә Женя алмаган бугай. Хәер, аңа баш ниемә хаҗәт? Булачак физкультурникка. Кулы-аягы исән булса, шул да бик җиткән.

— Алырга булган, — диде Шәүкәт. — Тайга эченә без тулы комплект белән атларга тиешбез. Баш һәркайсыбызга кирәк булачак.

Женя, беркатлылык белән:

— Нигә? Минем башым һәрчак үзем белән, — дип, матур калфак кигән башына төртеп күрсәтте. Аннары нәфесле тавыш белән: — Уму непостижимо, вокруг нас Великое Царство Безмолвия! Ур-ра, господа! — дип, бу җирләргә аяк басуының беренче минутларында ук күңелендә ишелеп туган хисләре белән бүлеште.

Женя Шахтин, вагонда килгәндә үк, үзенең хисле, тәэсирле, фантазиягә бай, шул ук вакытта беркатлырак егет икәнен күрсәтте. Килгән чакта демонстратив рәвештә сумкасыннан К.Марксның «Капитал»ын чыгарып, бик җитди кыяфәттә аның битен-биткә конспектлаштырып килде.

Фаягөл Женяга каныгуын белде:

— Кәбәм, ать, физкультурникка «Капитал» ниемә хаҗәт? Аны конспектлаштырмый торып, ярышларда беренче килә, Казан чемпионы була алмам дисеңмени? — дип иреште рүен белде.

Женя — физкультура һәм спорт факультеты студенты, разрядлы спортчы.

Женя, йөзенә президентлар җитдилеге чыгарып:

— Марксның «Капитал»ын белмәгән башың белән Казанның мэры булырга мөмкинме соң? — диде.

— Абау-у-у! Үлә-ә-әм! — дип сузды Фаягөл. Бу аның яраткан сүзләре. — Кәбәм, ать, син әллә Казан мэры булырга җыенасыңмы?

— Миннән дә кулайрак, хәзерлеклерәк башка кандидатура бармы соң? Әлегә мин башка альтернатива күрмим, — дип куйды Женя, Фаягөлнең төртмәле соравына бер дә исе китмичә.

Фаягөл янәдән:

— Абау-у-у! Үлә-ә-әм! — дип сузды.

Юлда килгәндә, Женя капчыгыннан йомшак сөлгегә төргән өч көпшәле ау мылтыгы чыгарды. Карап торырга уенчык инде менә. Түтәсендә «Маде ин Бельгия» дип сугылган тамгасы бар. Ничек шулай затлы итеп эшли алганнар? Осталар бар икән дөньяда!

Женя, мылтыкны биләүдән чишеп өстәлгә салганнан соң:

— Тс-с! — диде. — Әтинеке! Сорап алырга кыюлыгым җитмәде. Походтан кайткач, әти шытыр-шытыр колакларны борганда, каравыл кычкырасы көннәр алда әле. — Женя серле генә итеп як-ягына каранып алды. Әтисе әйтерсең күрше бүлмәдә генә. — Аның менә бу ике көпшәсе куян-көртлек аулау өчен. Төбәп тә торасы юк, чакмага гына басасы. Өстәге бу көпшәсе жакан белән корыла. Бүрене-аюны бер пуля белән аударып була. Менә күрерсез, Карелия тайгасына аяк кына басыйк, мин сезгә бер карт Топтыгинны шалт аударып бирәм. Барыгызны да аю бавыры белән сыйлармын. Беләсезме, нинди деликатес нәрсә ул. Берүк кадеремне генә белегез. Бу мылтыкны да бер пуля белән бер аюны аудару өчен алдым, — дип куйды Женя, зур зәңгәр күзләрен кысып. Йөзендә тәвәккәллек билгесе. Кем белә, бәлкем, аударыр да. Кулында өч көпшәле, шундый кыйммәтле ау мылтыгы булгач.

Фаягөл Женяга бәйләнүен белде:

— Бу мылтыктан үзеңнең атып караганың бармы соң? Кайсы баштан тотарга икәнен беләсеңме? Әгәр менә миңа бирсәң, мин сиңа атып күрсәтермен.

Фаягөл үзе «Ворошиловский стрелок» значогы йөртә. Бәләкәй калибрлы мылтыктан ату буенча берничә тапкыр шәһәр чемпионы. Фаягөлнең чибәрлеген әйткән дә юк. Моның өстенә ул бик булган кыз, физматның дүртенче курсында укый. Лобачевский стипендиаты. Монысы инде кызда баш та бар, акыл да җитәрлек дигән сүздер. Фаягөл — беренче разрядлы чаңгычы. Шулай булмаса, әлеге ерак сәфәргә Шәүкәт аны алмаган да булыр иде. Фаягөл юлда килгәндә кулыннан йон йомгагын төшермәде. Ирле-хатынлы Ольга белән Олег Антоновларга чаңгыда йөргәндә кию өчен бик матур калфаклар бәйләп бүләк итте. Әмма теле дә бит, ай-һай! Иң яхшысы — аның теленә эләкмәү. Әмма Фаягөл янында тын гына яшәрмен дә димә. Юлда килгәндә Женя Шахтинның шпагасы Фаягөлдән битәр Виктор Ершовныкы белән бик еш кына зың-зың килеште. Дөньяда ике тел бистәсе булса, шуның берсе Виктор. Шәүкәтнең егетләре бу турыда күптән беләләр. Тел бистәсе булса соң? Кояшта да таплар бар...

Дөресен әйткәндә, бу егетләрнең икесе дә, бераз гына түгел, җай чыкканда бөтенләй чаманы җуеп, мактанып җибәрергә яраталар. Поход шартларында анысы да ярый аның. Әмма бу ике егет кайчакта бер-берсе белән «психологик яктан несовместимый» дәрәҗәгә җитеп куялар. Икесе дә эрудитлар, белмәгән нәрсәләре юк. Әмма мактаныша башласалар, берсе икенчесенә юл куяр димә. Бер-берсенә төрткеле сүзләрне яудыра башлагач, боларның берсен бу сәяхәткә алмасак та ярыйсы булган икән дигән чаклары да юк түгел иде Шәүкәтнең.

Женя капчыгыннан ау мылтыгын чыгарып күрсәтүгә, бу ике ярсу йөрәк әле суймаган сарыкның тиресен бүлә башладылар.

Виктор шунда ук:

— Аюларның агы да, сорысы да Кызыл Кенәгәгә теркәлгән. Аларга җир йөзеннән юк булу куркынычы яный. Мин сиңа Топтыгиннарның берсен дә аттырмыйм, — дип чәчрәп сөйләп китте.

Шунда Женяга, ярар, атмамын, дип кенә әйтәсе дә бит. Ә ул, театраль жест ясап:

— Синнән сорап торырмын инде! — дип куймасынмы. — Закон — тайга! Медведь — хозяин!

— Ничек сорап тормыйсың ди? — дип кызды Виктор. — Син браконьер булырга охшыйсың. Шаярып кына кара, шундук акт төзиячәкмен. Барлык иптәшләрдән кул куйдырам да тикшерү органнарына тапшырам. Берләшкән Милләтләр Оешмасына хәбәр итәчәкмен.

— Виктор, кадерлем, гомердә бер тапкыр гына булса да синең аю бавырын татып карыйсың килмимени? Дивана баш булмасана! — дип, аларны бу юлы да Фаягөл килештерергә тырышты. — Син бит үзең дә безне дөньяда иң тәмле балыкларның берсе — чавыча балыгы белән сыйлыйм дип ышандырганыең. Әллә оныттың дамы?

Виктор — Төньяк егете. Мурманск каласында туып үскән. Әти-әнисенең бик кадерле бердәнбер уллары. Бәлкем, аның артык үзсүзлелеге дә шуннандыр. Әти-әниләре икесе дә «Слава» балык флотилиясендә эшлиләр. Әтисе штурман, әнисе шәфкать туташы. Алар диңгезгә икешәр-өчәр айга чыгып китәләр. Балыкны, Атлантиканы аркылыга-буйга иңләп, чавыча балыгын исә Канада ярларына кадәр барып тоталар, дип, ул үзе сөйләп килде.

Виктор унынчы классны да Казанда тәмамлаган. Хәзер дә әнисенең бертуган апасы Варвара түтәйләрендә яши. Виктор чынлап торып вундеркинд, белмәгән нәрсәсе юк. Әмма күп тә сөйләшә инде. Әлегә юньләп кенә бер кыз белән дә йөргәне юк бугай. Чибәрлеге дә ташка үлчим генә. Озын буйлы, яңа гына концлагерьдан азат булган әсирдәй арык гәүдәле, чыраен сыткылар баскан бер егет. О-о, сөйләвен тыңласаң, Дон Жуанның чын үзе инде. Географфакның гына түгел, ә бөтен институтның иң чибәр кызлары тик аңа гына гашыйклар дип саный. Үз сүзләренә сине дә ышандыра әле. Шәүкәт моңарчы да Виктор белән берничә сәяхәттә булды. Слетларда да катнаштылар. Мактанырга яратса да, танылган тел бистәсе булса да, түзәрлек, әйбәт, эчкерсез егет. Шунысы гажәп, чибәрлеге чыннан да юк инде аның, әмма походка чыккач, кызлар ни өчендер гел аның тирәсендә чуалалар. Кызлар авыз ачып тыңларлык сүзләрне, сүз куертырлык теманы таба, эрудициясе белән алдыра. Әле менә поездда килгәндә дә, ничә карасаң, Виктор купесында булдылар. «Кулымда Мурманскидагы иң элиталы йорттагы өч бүлмәле фатирыбызның ачкычы, — дип сөйләп килде. — Поход тәмамлангач, барыбыз да безгә кунакка кайтабыз. Менә шунда генсеклар гына сыйлана торган искитмәле тәмле, прәме телеңне йотышлы чавыча балыгының тозлаганы, ыслаганы, кипкәне, әле генә судан тотканы белән сыйлыйм».

— Беләсезме, бер дус кызларымда кунакта палтус балыгы ашаган идем. Әй-й тәмле дә балык иде, — дип, Фаягөл телен суырып куйды. — Нәкъ син әйтмешли, Виктор, прәме телеңне йотышлы.

— Палтусны чавыча белән чагыштырып буламы соң! Чавычадан ул ун баскычка түбән! — дип куйды Виктор. — Минекеләр аны хәтта Канада ярларына кадәр барып тоталар.

Тәмле, татлы сүз сөйләгәнне кем яратмый инде? Ә Виктор белә кызлар алдында нәрсә сөйләргә кирәген. Кызлар үзләре дә, «безнең Виктор беразын арттыра инде» дип, бер-берләренә еш кына күз кысышып алалар. Үзләре һаман аның тирәсендә. Әгәр инде кызларның игътибарын үзенә җәлеп итә алмый башласа, кесәсеннән шундук карта чыгара. Буби короленә йә карга валетына карта ача башлый. Кызлар аны шундук янә сырып алалар. «Белеп тор, синең «буби королең» Казанның ракетчиклар хәрби училищесында, — дип өстәп тә куя үзе карта ачкан кызга. — Ә синең «карга валетың» авылыгызда. Унынчы классны бергә тәмамлагансыз. «Карга валеты»ның сиңа әйтәсе сүзе бар. Ләкин һаман кыймый йөри. Көт, шушы араларда аның йөрәк түрендәге кыюлык бокалы тулачак. Сәяхәттән кайтышыңа сине эче мәхәббәт белән тулы хат көтәчәк. Үзең дә дөньяга башка күзлектән карый башлаячаксың. Мин әйткәние диярсең».

Кызлар соңыннан:

— Өстенә сыер китереп баскандай туры китереп ача бит картасын. Кара, әй, ничек шулай туры китереп сөйли бу Виктор. Без белми генә йөрибез, әүлия түгелме икән ул? — дип гажәпләнешәләр.

* * *

Казан студентларының кышкы каникуллар чорындагы дүртенче категория кыенлыктагы туристик сәяхәтләре менә шушы сыек томан эчендә утырган Вуокколо разъездыннан башланырга тиеш. Шәүкәтнең кулындагы эре масштаблы картада разъезддан километр чамасы гына читтәрәк нәкъ шушы исемдәге зур гына күл бар. Әлеге разъездга да исемне шушы күлдән алып кушканнардыр. Кола ярымутравы, гомумән, күлләр иле. Җирле халык, беркадәр шаяртып, әмма горурлык хисе белән: «Бездә күлләр күк йөзендәге йолдызлардан күбрәк», — дип сөйли. Дөреслек чыннан да алар ягында түгел микән?

Бу җирләр кайчандыр Финляндиягә караган. Әйләнә-тирәдәге елга, урман, тау исемнәре дә фин телендә. Арада телеңне сындырырлык кыен әйтелешлеләре дә бар. Шәүкәт Бакировның шушы «сугышчан» группасы компас угы белән билгеләнгән азимуттан бер генә градуска да уңга да, сулга да тайпылмыйча, ун көн эчендә ике йөз чакрымнар ара узып, төньяк никель коючыларның берсеннән-берсе матур, күп һәм тирән сулы биш күл уртасына салынган Мончегорск каласына барып чыгарга тиешләр. Ике йөз чакрым җир — яхшы чаңгычы өчен арамыни! Ул аны күп булса биш көндә уза. Лыжнядан, кар өстенә алдан салган эздән. Ә боларның җилкәсендә икешәр потлы капчыклар. Маршрутлары да дүртенче категория кыенлыктагы, ягъни алар барасы сукмактан моңарчы әле берәү дә узмаган. Бу сәяхәтнең бөтен хикмәте дә шунда. Шәүкәт егетләренә моңарчы кеше аяк басмаган тайга, үзен-үзе белми шашып аккан елгалар, кәҗә мөгезедәй текә тау сыртлары аша да узарга туры килмәгәе... Туристик сәяхәтләр походлар кыенлыгы белән түгел, әнә шул серләре көтелмәгән ситуацияләре белән кызыклы да инде. Күңелләрне дәртләндереп, үзенә дәшеп, чакырып тора.

Походлар өчен берсеннән-берсе кызыклы маршрутларны Казанның Туристлар клубы төзеп, раслап тора. Аның кайдан башланасын, кайда төгәлләнәсен дә алар билгели. Җилкәңә ике потлы капчык асып та, ике йөз чакрым араны ун-унике көн эчендә узарга була, әлбәттә. Командаң көчле, хәзерлекле булганда. Көненә егерме чакрым гына чыга бит. Ләкин шунысы бар, Кола ярымутравында кышның бу чорында көннең якты өлеше дүрт-биш сәгатьтән артмый. Иртән сәгать унберләргә генә яктыра. Йокың туеп, уянып, таң атканны, яктырганны көтә-көтә, палаткаңда ятып тәмам интегеп бетәсең.

Сәгать өчләргә яңадан караңгы төшә. Шул нибары дүрт-биш сәгатьтән артмаган көн яктылыгында, сәгатенә дүрт-биш чакрым узып, көнлек нормаңы — егерме чакрым араны үтәргә була... Привал

вакытларында, капчык өстенә утырып, әйләнә-тирәнең хозурлыгына сокланырга, истәлекле җирләрдә фотога төшәргә дә вакыт кала әле. Әйе, командаң көчле, хәзерлекле, оешкан булганда. Ләлә Бәхтиярованы искә алмаганда, Шәүкәтнең командасы мәлҗерәп төшкәннәрдән түгел. Фаягөл үзе генә ни тора! Беренче разрядлы чаңгычы. Стендта ату буенча республика чемпионы. Женя Шахтин — суда йөзү, биеклеккә сикерү, чаңгыда узышу буенча беренче разрядлы спортчы. География факультетының дүртенче курс студенты Виктор Ершов спорт белән алдырмаса, тел белән алдыра. Көнлек маршрутның тик биш сәгате генә юлда уза. Тәүлекнең калган өлеше кар өстендә чытыр-чытыр янган учак янында ашарга әзерләп, ботка өлгергәнне көтеп, палатка тирәсендә таптанып һәм аның эчендә кырын ятып уза. Виктор кебек телгә беткәннәр походта бер дә артык җан түгел. Киресенчә, аларга зур мохтаҗлык була әле. Шәүкәт моңа чаклы Виктор белән Мари урманнарында һәм Төньяк Уралда сәяхәттә булган иде. Бу юлы да аны үз төркеменә бик теләп алды.

Башкалар тагын бер кат әйберләрен барлаган арада, Шәүкәт, куеныннан картасын алып, янәдән маршрутны ачыклады. Толик Бакалин белән бергәләп, азимутны төп-төгәл билгеләделәр. Разъезддан сул якка, алар кузгаласы юнәлештә, күп булса ярты чакрымнар ераклыкта кап-кара булып урман күренә. Аңа кадәр арада өстен калын кар каплаган басу. Женя Шахтин шуып әйләнеп тә килде.

— Искиткеч! — диде ул. — Чаңгыларга канат куелган диярсең. Ап-ак кар өстеннән очалар гына. Мин реактив тизлеккә ирешмәгәем! Чын сенсация булмагае.

Маршрут буенча алар, әнә шул кара чыршы урманын узып, Голая Поляна дигән урман кисүчеләр поселогына чыгарга тиешләр. Туристлар юл өстендә бу беренче торак пункт. Карта буенча исәпләгәнчә, әлеге поселокка күп булса ун-унбиш чакрымнар гына булыр. Шәүкәт кулындагы белешмәгә акка кара белән язылган: «Голая Поляна поселогында йөз урман кисүче яши. Күчмә электр станциясе, җәмәгать мунчасы, почта бүлеге, медпункт һәм бик бай кибете бар». Белешмәгә ышансаң, Вуокколо разъездында да ун торак барак, бик бай кибет-пакгауз бар, дигән. Әлегә исә ишекләренә ат башы хәтле йозак эленгән ике амбар-склад кына сыек томан аша төсмерләнә. Бай кибет-пакгауз шуларның берсе-мазар булса инде. Якын-тирәдә башка бина-мазар да, берәр төрле тере җан иясе дә күренми. Кибет-пакгауз дигәннәре, бәлкем, соңрак, ут алгач ачылыр. Чөнки тайга эченә кереп киткәнче, туристларга үзләре белән, һич югында, ике-өч көнлек ризык запасы аласы иде бит. Казаннан киткәндә, юлга ризыклар алырга ашыкмыйк, Мәскәүгә баргач юнәтербез, анда бит ярты гына бәя, дип алмадылар. Шәүкәт, башкалага килеп төшү белән, вокзал капкасы төбендә торган экскурсия автобусына төяп, командасын Кызыл Мәйданга Кремльне карарга алып китте. Ильич бабайны күрергә. Мавзолейга чиратка бастылар. Егетләре дә, кызлары да — барысы да булачак укытучылар бит. Кызыл Мәйданда да булмый, Кремльне дә күрми ничек итеп класска, балалар алдына керәсең?

Арзанлы ашамлык-ризыклар артыннан чиратка басарга вакыты калмады шул. Ленинградка китәсе поездга чак кына кайтып өлгерделәр. Революция бишеге, илнең төньяктагы башкаласы Ленинградка иртәнге сигезләр тирәсенә килеп җиттеләр. Анда килеп төшкәч тә, Шәүкәт үз командасын янә экскурсия автобусына төяп, Кышкы сарайны карарга алып китте. «Аврора» крейсерында, Петропавел крепостенда булдылар. Эрмитажны карадылар. Көндезге сәгать нәкъ уникедә Петропавел крепостенда туптан тәүлегенә бер атып куялар. Петр I патшадан ук калган традиция бу. Туптан атканны үз колаклары белән ишетеп, үз күзләре белән күрделәр. Тәэсире әйтеп бетергесез булды.

Юлга ашамлыклар алырга тагын уңай җай калмады. Студент халкы кабарына тәгам ризыгы югын өзелеп карыны ачкач, бүредәй булып ачыккач кына исенә төшерә бит ул.

Кышкы каникуллар чорында туристик сәяхәткә чыккан студентларга тимер юл вокзалларында кайсы кассага бассалар да, семафорлар һәрчак ачык, һәркайда «яшел» ут. Бу юлы билетны Ленинградтан туп-туры Мурманскига ук илтеп куя торган тиз йөрешле «Арктика» поездына алдылар.

Шәүкәтнең беренче ярдәмчесе, уң кулы, җан дусты Толик Бакалин гел исенә төшереп торды:

— Егетләрнең капчыкларын кимендә утыз банка куертылган сөт, егерме банка ит консервасы, ун килограмм шикәр, чәй, ярма, сохари, тоз-борыч белән тутырырга безгә күптән вакыт.

Толикның тәҗрибәсе зур. Күп тапкыр туристик сәяхәтләрдә булган, үзе дә группалар җитәкләгән егет. Походта ачлык кичерүнең дә нәрсә икәнен үз җилкәсендә татыганы бар. Әмма аның кисәтүен янә исәпкә алмадылар.

— Алда бит Карелия башкаласы Петрозаводск. Анда безнең «Арктика» айгырын алыштыра икән. Состав Петрозаводскида ярты сәгатьләр чамасы торачак. Шунда барыбыз бергә перронга чыгарбыз да бөтен кирәк-яракны уптым илаһи алырбыз да керербез. Кирәкмәгән проблеманы нигә тудырабыз? — диештеләр егетләр.

Шәүкәт тә килеште. Холкы шундыйрак, күндәмрәк. Әмма бу юлы нык ялгышты килешеп. Җитәкчегә тиешле чакта нык, үзсүзле булу да кирәк. Шәүкәттә ул сыйфат туып кына килә иде шул әле.

Петрозаводскида «Арктика» поезды, бәлки, сәгатьтән артык торгандыр. Бу кала вокзалына ул төнге икеләр тирәсендә килеп туктады. Шәүкәтнең Ленинградны карап тәмам арыган командасы колак төпләрендә кыңгырау шалтыратсаң да, вагон каршында туптан атсаң да уянмаслык тәмле йокыда иделәр.

Вуокколо разъездындагы кибет-пакгаузның да бикле чагына килеп төштеләр бит. Станцияне караучы, битен җирән сакал баскан, кысыграк күзле агайдан барып белеште Шәүкәт. Пакгауз билгеле бер сәгатьтә түгел, ә шушы юлны карап, ремонтлап торучы тимерьюлчылар бригадасы килеп чыкканда гына ачыла икән. Шәүкәт командасы моңарчы, дәүләт паегына күчәргә ашыкмыйча, юлга үзләре алган ризыклар белән тукланып килде.

Казан егете Женя бик бай гаиләдән булса кирәк, һәр кыланышында шулай сизелә. Женяны вагонга хәтле озата кергән әнисе, өстәлгә бик симез пешкән каз, бер кәрҗин пирожки-пироглар, куш йодрык алмалар, термос белән кофе, ике-өч тартма конфет чыгарып өйде.

Буа кызы Фаягөл дә:

— Кичә генә авылга кайтып килдем. Болары сезгә әнием күчтәнәчләре, — дип, сумкасыннан бер кәнди өчпочмаклар чыгарды.

Походларга күп йөргән Толик Бакалинны да тормыш, син, энем, йонлы колагым, сәяхәткә беркайчан буш капчык белән кузгала күрмә, дип, бармак янап кисәткәндер. Аның да сәяхәтләрдә күп йөреп, ярыйсы таушалган рюкзагы буш түгел. Монда ни бит әле: бәлкем, каенсеңлесе дә булып куярдай, башы-аягы, капчыгы-ние белән кырык килодан артмаган Ләлә Бәхтиярованы әлеге походка ул алды бит. Ни белән генә тәмамланыр инде аларның бу сәяхәте. Маршрут кыенлыкларына түзә алырмы икән бу челдемби кызчык? Алда Төньякның кырыс табигате, утыз градуска җитешле салкыннар. Монда тулай торактагы җылы караватың юк. Палаткада кунарга туры килә. Моңарчы әле берәү дә узмаган маршрутта Толикка да җиңел булмас. Кем белә, бәлкем, чыннан да каенсеңлесе булып куяр — Ләлә Бәхтиярова алдында аңа сынату килешмәс. И-и, бу мәхәббәт! Каян килеп чыккандыр, кем уйлап тапкандыр аны? Нинди утларга гына салмый бит егет башын! Толик бит менә шушы челдемби кыз Ләләнең бертуган апасы Миләүшәгә тәмам башын җуеп гашыйк. Бу турыда бөтен институт белә. Толикның хәлен барысы да аңлый. Аеруча егетләр хөрмәт итә үзен.

Ирле-хатынлы Ольга белән Олег Антоновлар юлга зур гына кәбестә бәлеше пешереп алганнар. Аны барысы да мактый-мактый ашадылар.

Олег ике сүзнең берендә:

— Моя жена на все руки мастерица! — дип, хатынын мактап ала.

Әмма юлда өч тәүлектән артык булдылар бит инде. Матурлап үргән кәрҗиннәр дә, юл сумкалары да бушады. Шәүкәтнең үз рюкзагында инде ярыйсы искерә төшкән ике кирпеч кара ипи, ике банка сгущенка, ярты кило шикәр, бераз сохари бар. Алары да юлда аны Женя, Фаягөл, Ольга белән Олег сыйлап килгәнгә генә сакланганнар. Аның капчыгындагы ризыклар хәзер НЗ, ягъни неприкосновенный запас. Аларга кагылырга ярамый. Алда ни күрәселәрен кем белгән.

Пакгауз ачылганны көтәргә йә барып ачтырырга кирәк булган икән аларга.

— Ризыкларны урман кисүчеләр поселогы Голая Полянада алырбыз. Рюкзакларда артык йөк йөрткәнче, — диештеләр егетләр.

Төркем башлыгы буларак Шәүкәт бу юлы да сүзен кисеп кенә әйтә алмады. «Капчыкларыбызны кимендә бер атналык ризык запаслары белән тутырмый торып, бер адым да алга атламыйбыз», — дип өздереп кенә әйтмәде.

— Карта буенча Голая Полянага нибары унбиш чакрым гына бит. Безнең өчен пустяк ара! Бер сәгатьтән шунда булачакбыз, — дип, Женя Шахтин бер төркемне үз ягына аударды. Бу юлы аңа нишләптер хәтта Витька Ершов та каршы төшмәде.

Маршрут белән тагын бер кат танышып, азимутны билгеләгәч, сул якта кап-кара булып күренеп торган урманга таба бик тә кыйммәтле пластик чаңгыларда беренче булып Женя очты. Женя вагонда сөйләп килде: февраль ахырларында Уралда чаңгыда утыз чакрымга узышу буенча Россия беренчелеге булачак икән. Женя шунда катнашып спорт мастеры дигән исем алырга җыена. Казан мэры булырга үз кандидатураларын куйган көндәшләре арасында ул минем файдама көчле аргумент булачак, дип сөйли. Әлеге походка исә кыен шартларда чыныгу алып, физик яктан ныгып кайту өчен язылган икән.

Женя Шахтин артыннан «Ворошиловский стрелок» Фаягөл очты. Маршрутта иң алдан, беренче булып эз салып баручыны төркем җитәкчесе үзе билгели. Аны туристлар үзләре ихтирам белән кәрванбашы дип йөртәләр. Кәрванбашы нык әзерлекле, физик яктан да көчле егет була. Аңа бик еш кына юл салуның бөтен авырлыгын үз җилкәсендә татып, еш кына билдән кар ерып, урман аша узганда балтасы белән уңга да, сулга да кизәнеп, ботакларны чабып, башкалар өчен эз, сукмак салып барырга туры килә.

Женя белән Фаягөл артыннан Валентин Осянин, аннары ирле-хатынлы Антоновлар кузгалдылар. Олег хатынын кочагында гына йөртми. Ни бетмәгән сүз табалардыр. Ничә карасаң, аларның бер-берләренә елмаешып карап, бертуктаусыз пар сандугачлар булып чөкердәшеп баруларын Шәүкәт килештерә. «Менә ичмасам болар пар килгәннәр», — дип уйлап куя.

Урман авызына күп дигәндә ярты чакрымнар гына булыр. Әмма кузгалган берсе тагын да куера төшкән томан эченә кереп югала баралар.

Группа җитәкчесе һәрчак иң арттан бара. Туристлар аны, шаяртып, «алдан баручыларның кесәләреннән коелган тиеннәрне чүпләп баручылар» дип йөртәләр.

Привалны һәр кырык минут саен ясарга килештеләр. Иң соңгылар булып Ләлә Бәхтиярова белән аның җизнәсе булырга җыенган Толик Бакалин кузгалдылар. «Замыкающий» булып Шәүкәт басты. «Пә-рә-мәч!» — дип куяр иде берәрсе. Чаңгыда бару түгел, Ләлә басып та тора алмый. Бер адым атлый да утыра, атлый да утыра. Шушы хәленнән авызын ерып көлә тагын, җитмәсә. Хәер, еласа юатырга туры килер иде әле. Менә сиңа Урал кызы, менә сиңа Чиләбе кызы! Әллә үскән чагында чаңгыга бер дә аяк басмады микән? Бу бичара маршрутны ничек үтәр икән? Әле соң түгел, әллә кире борылып, поездга утыртып Казанга кайтарып җибәрергәме? Алда маршрут көннән-көн кыенлашачак бит.

Шәүкәтне биләп алган борчулы уйларның мәгънәсен бер карауда төшенеп, Толик бер бармагын иреннәренә тидерде: «Тс-с! Бер дә кайгырма», янәсе. Аннары, аның колагына иелеп:

— Безнең өчен борчылма, әгәр чаңгыда атларга өйрәнеп китә алмаса, мин аны рюкзагыма салып аркама атландырам. Баш-аягы белән күп булса утыз кило булыр. — Толик, авыз чите белән генә елмаеп, Шәүкәткә күз кысты. — Утыз килолы гына йөкләр безнең өчен йөкмени ул! Кырымның, Кавказның иң кыен маршрутларын узган егетләргә. Шулай бит?

«Булса да булыр икән егеттә мәхәббәт! Ай-яй ярата Толик шушы Ләләнең бертуган апасы Миләүшәне», — дип янә бер уйлап алды Шәүкәт.

Толик, бераз аклангандай итеп:

— Ләләнең чаңгыда йөри алмаганын мин Казанда ук белә идем. «Үзең белән походка мине дә ал әле», — дип тәмам колагымны ашады бит.

— Шуны белә торып та... — диде Шәүкәт.

— Алмыйча булмады шул. Апасы Миля да сорады бит. Беләсең бит инде минем Миляны ничек яратканны. Ә безнең өчен кайгырма, без сиңа йөк булмабыз...

* * *

Ташбака адымнары белән булса да Ләлә, Толик һәм Шәүкәт тә, ниһаять, урман авызына килеп җиттеләр. Анда ике «психологик яктан несовместимый»ларның ярыйсы гына әйтешкәннәре ишетелә.

— Ә мин сиңа нәрсә дигәнием? Әйттем, кисәттем түгелме? — дип, Виктор Ершов Женя Шахтинның каешларын телә бугай.

Шунысы хак: бер сәгатьтән Голая Поляна поселогына барып керәсе егетләр урман эченә нибарысы йөз илле-ике йөз метрлар гына керә алганнар. Алда стена булып кара чыршы урманы тора. Араларында колач җитмәстәй юан чыршылар да бар. Һәркайсыннан кораб мачтасы ясарлык. Монда, урман эчендә, кар катламы да ике метрлар гына булыр. Егетләрнең күбесе күкрәк авызыннан тирәнлектә, мамыктай тирән кар эчендә. Шул арада янып-пешеп, тирләп чыкканнар. Чабыштан кайткан аргамаклар диярсең, өсләреннән пар күтәрелә. Әле тегендә, әле монда өсләрен мүк баскан гранит ташлар очрап тора. Араларында авыл мунчасы кадәрлеләре бар. Һәркайсын әйләнеп узарга туры килә. Шуларның берсенә төртелеп, килгән хутка ук Женя бер чаңгысын сындырды. Утырып еламый гына. Елап та нишләсен? Елап кына чаңгыны ялгап булса икән. Ә Виктор аны: «Мин бит син аңгыра башны, походка ул чаңгыларыңны алма, дип кисәттем түгелме соң?» — дип орыша икән. Походта чаңгың сынса, беттем диген инде. Тайга уртасында яңасын каян аласың? Шуны истә тотып, Шәүкәт үзләре белән запаска ике пар чаңгы да алган иде. Чөнки узган кышта Урта Уралда авызы пешкәне булды. Маршрутның иң уртасында чаңгысын сындырган бер кызның аягына чыршы ботаклары бәйләп җаннары чыкты.

— Ниемә хаҗәт бу идән такталары? — дип, запас чаңгылар алуга Женя үзе каршы чыккан иде. Аларны бит кәгазьгә генә төреп куеныңа тыга алмыйсың, маршрутта кемдер өстерәп барырга тиеш. Женя хәзер ыңгыраша-ыңгыраша шул чаңгыларны аягына көйләп азаплана.

Шәүкәт группасының физик яктан иң көчле егетләренең берсе — галәмәт аз сүзле Габделбәр Садриев белән Олег Антонов, капчыкларын салып ташлап, кулына пычкы-балта алып, колач җәеп утырган чыршы ботакларын кисәләр. Эчкә таба сукмак салмакчылар.

Женя Шахтинның: «Дүртенче категория кыенлыктагы гына түгел, меңенче кыенлыктагы маршрут бу! Минемчә, бу маршрутны, беренче чиратта корткычлык максатларын күздә тотып, халык дошманнары төзегән. Ма-ма! Я хочу домой!» — дип сукранганы ишетелә.

Аның сүзләрен шундук Виктор эләктереп ала:

— Бик иртә сукранасың, дустым. Кыенлыкларның иң җитдиләре алда әле. Ышанасыңмы, Женя, Варвара апам миңа юлга тыккан тәмле клиндерләрнең соңгысын тел очымда йөртәм. Чикләвек төше тәмнәре килә. Ә иртәгә без нәрсә ашарбыз. Сизеп торам, башкаларның да карыннарында ач бүреләр котыра бугай.

Викторның бу сүзләреннән соң барысы да сискәнеп киткәндәй булдылар. Юлга ашамлыклар алырга тәки өлгермәделәр бит. Шәүкәтнең дә өзелеп ашыйсы килеп куйды.

Барысын да беркадәр тынычландырып:

— Бездән нибарысы ун чакрымнар гына арада Голая Поляна. Анда хәтле генә ничек тә түзәрбез, — диде тарих факультетының бишенче курс студенткасы Мөнәвәрә.

Шундый кешеләр дә була бит. Аларның кешелекле, эчкерсез сыйфатларын алар белән озак вакытлар аралашкач кына күрәсең. Яныңда нинди ышанычлы, яхшы иптәш барын сизәсең. Зур алтын бөртеге тапкандай сөенеп куясың. Мөнәвәрә дә шундыйлардан иде. Поездда барганда да беркем белән дә сүзгә килмичә, өч купены да чисталыкта тотып, савыт-сабаларны да берүзе юып килде.

Виктор, яңадан ашау темасына кайтып:

— И-их, шушы тешләремне мин куш йодрык зурлыгындагы антоновка алмасына батырыр идем, — диде.

— Балованный вы ребенок, юноша Виктор, — диде Женя, бу исемне французчарак итеп, басымны соңгы иҗеккә ясап.

— Иптәшләр, барыгызны да тагын бер кисәтәм. Барыгызның да кулларында компаслары бар. Ун көннән Мончегорск каласына чыгу өчен безгә, бер минутка да читкә тайпылмыйча, йөз кырык җиде градусны төгәл тотарга кирәк. Бер генә минутка ялгышсак та, Мончегорскины гына түгел, бездән нибары ун чакрымнардагы Голая Поляна поселогын да читләтеп үтүебез бар, — дип, Шәүкәт төркем егетләрен тагын бер мәртәбә кисәтүне кирәк тапты.

— Кораб мачталары ясардай чыршылар озын канатларын як-якка дүртәр-бишәр метрга җәйгәннәр. Бозлык чорыннан калган ташларның иң кечесе тегермән ташы хәтле бар. Шулар арасыннан бер градуска да читкә тайпылмый, азимутны төгәл саклап, эз салып кара син. Берничә градуска йә уңга, йә сулга тайпылуыңны сизми дә каласың, — дип, хәтта Габделбәр дә зарланып алды.

Женя Шахтинның әллә чынлап, әллә шаяртып:

— Ма-ма-а-а! Я хочу домой! — дип ыңгырашканы ишетелде.

Толик Бакалин тамагын кырды:

— Әлегә хафаланырлык җир юк. Мин төгәл тикшереп барам. Азимуттан тайпылыш сизелми, — диде.

Ул арада урман эченә куе итеп бастырып караңгы төште. Күк йөзе болытлы, ник бер йолдыз калыксын. Кесә фонарьлары уйнатып кына берни эшләп булмый. Толик белән бер читкәрәк китеп киңәшкәннән соң, палатка куярлык бер иплерәк ачыклык табып, шушында төн кунарга кирәк дигән карарга килде Шәүкәт. Үзләре белән ике-өч фанер көрәк тә алганнар иде. Берәүләр палатка куясы урынның карын көрәргә тотындылар. Икенчеләре калын итеп аска чыршы ботаклары түшәделәр. Аның өстенә брезент җәеп тиз арада гына ун кешелек палатка бастырдылар. Олег Антонов, кулына пычкы алып, шалтырап кипкән чыршыларны вак-вак кыска пүләннәргә турап ташлады. Габделбәр үз аркасында күтәреп килгән миниатюр тимер мичне палатка эченә көйләп куйды. Чыралар телеп, кабызып та җибәрде. Палатка торбасыннан чыккан сыек төтенне барысы да алкышлап каршыладылар.

Профессор портфеленең яртысы кадәр генә тимер мич тайга аланы уртасында биш минут кына элек корып куелган палатканы кырыс табигатьле Төньякның салкын кышкы төнендә егетләр майкадан гына калып йокларлык җылы итте. Алай гына да түгел, палатка эчендә кашыкка салган май эрерлек җылы. Барысы да рюкзакларыннан кереп йоклар өчен махсус тегелгән сырган капчыкларын чыгардылар. Тимер мич гөрли. Габделбәр коры пүләннәрне аның авызына өстәп кенә тора. Ун кешелек палатка эченә туристларның унөче дә бик җиңел сыештылар. Шәүкәт төн буена мичтә утны сакларга ике сәгать саен бер-берсен алмаштырырлык итеп кизүләр билгеләде.

— Кизүләргә йокламаска! — дип кисәтте.

— Башта барыбыз да уң якка ятып бай-бай! Аннары кизү торучының командасы белән сул якка әйләнеп ятарбыз. Шулай команда тәртип белән генә борылып ятмасак, палатканы аударуыбыз бар. Төн уртасында палаткаң авып китсә, шулай ук зур шатлык түгел.

Палатка түреннән Ершовның карлыккан тавышы ишетелде:

— Бу минутларда мин чыннан да күкнең җиденче катында! Турпоходларның, беләсезме, ни өчен берсен дә калдырмыйм? Нәкъ менә шушы минутларның ләззәтен кабат һәм кабат тату өчен. Картлач Җир шарыбыз, күптән майланмаган күчәрен шыгыр-шыгыр китереп, орбитасы буйлап чаба. Әйләнә-тирәбездә моңарчы кеше аяк басмаган серле тайга. Салкын кыш уртасы. Төн. Палатка эчендә тимер мич гөрли. Поэзия! Теләмәс җиреңнән шагыйрьгә әйләнерсең...

— Сиңа поэзия! — дип бүлдерде аны Женя. — Ә мин пластик чаңгымны сындырдым. Әти аны миңа Швециягә командировкага барган җиреннән алып кайтканые. Бу походтан кайткач, Уралда узачак Россия беренчелеге ярышларында катнашырга уйлап тора идем бит. Беренче унлыкка керәм дә керәм. Аңа потенциаль хәзерлекне сизәм. Ә беренче унлыкка керүчеләргә СССРның спорт мастеры исемен бирәчәкләр. Быел да алмасам, тагын кайчан алам мин бу исемне? Ак сакаллы карт булгачмы? Ул яшьтә бу дәрәҗәле исем миңа ниемә хаҗәт? Ә пластик чаңгысыз, белмим, менә мондый такталар өстерәп кенә беренче унлыкка кереп булырмы? — Женя, әллә чынлап, әллә шаярып, янәдән: — О-ой, мама-а-а! Я хочу домой! — дип куйды.

— Поездда килгәндә, «мин сине ак аю ите белән сыйлыйм. Урманга керү белән бер Топтыгинны аударам» дип мактанып килгәниең. Мин, беркатлы, иреннәремне үк ялый башлаганыем, — диде Виктор. — Ә син тәртәләреңне кире бормак түгелме соң?

— Женя Шахтин ике сөйләми. Иртәгә көн яктыру белән берәр чатан аякны жакан белән бәреп аударачакмын. Аның тиресен тунарга пычагыңны кайрап куй. Ә төшке ашка аю бавыры булачак. Моны сезгә мин, Женя Шахтин ышандырам!

— Күрербез, күрербез, — дигән булды Виктор. — Ә Кызыл Кенәгә турында мин бүтән ләм-мим. Бер симезрәк Топтыгинны аударырга миннән рөхсәт. Поход барышында туарга торган экстремаль сәбәпләр аркасында, әлбәттә.

Җылы сырган юрганыннан борын очын гына чыгарган Ләлә:

— Толик, бу урманда аюлар бармыни? Алар безгә һөҗүм итсәләр? Мин куркам, — дип, чак кына ишетелерлек итеп сорап куйды.

— Янәшәңдә мин булганда, бернидән дә курыкма! — дип пышылдады аңа Женя. — Тыныч йокы, тәмле төш!

Кара чыршы очларын сыйпап, палатканы да дер селкетеп, әллә Атлантик, әллә Төньяк боз океаныннан килеп чыккан Төньяк җиле узып киткәли. Төньяк җиленең көчлерәк отрядлары баш очларыннан узганда, кайбер картрак чыршылар, ризасызлык белдереп, шарт-шорт килеп сукранып алалар.

Таң алдыннан сүнә барган йолдызлар төсле, Шәүкәтнең дә командасы сүнә башлады. Фаягөл генә йокламаган икән әле.

— Нәкъ минем аска гына чыршы ботагының бастырык юанлыгын салгансыз бит, хәчтерүшләр, — дип сукранды ул. — Сыртымны каезлый прәме. Бу килештән, иртәнгә чаклы тәмам билсез калачакмын бит. Иртәгә сезгә мине носилкага салып өстерәргә туры килмәгәе...

— Хет бүгеннән носилкага салып өстерәрлек кандидатлар бездә җитәрлек, — диде Олег.

Шушы сүзләре белән ул кемне күздә тоткандыр. Кыска көн эчендә Шәүкәтнең командасы шактый арырга өлгерде. Йокларга да ач килеш яттылар. Әмма берсе дә: «Һич булмаса, чиләктә кар эретеп, берәр чынаяк чәй эчеп ятыйк», — дип шыңшымады.

* * *

Казан студентларының Вуокколо разъездыннан башланып киткән туристик походлары, бер карасаң, көтмәгәндә генә килеп чыкты. Кышкы имтиханнар башланыр алдыннан, Шәүкәтне башкаланың Хезмәт сараена дәштеләр. Барча студентларның табынып яраткан дуслары Иван Иванович Рожков чакырткан аны. Өлкә профсоюзының Яшьләрне патриотик, туган илгә бирелгәнлек рухында тәрбияләү, спорт аша чыныктыру комитетында гап-гади инструктор бу агай. Әлбәттә, бу дәрәҗәле комитетның дәрәҗәле рәисе дә бар. Берничә ел элегрәк бу комитетка җитәкче итеп сәхнәдә күнегүләр вакытында бик уңайсыз егылып аягын сындырган Опера һәм балет театрының балеринасын куйганнар иде. Аягы дөрес ялганмагач, бүтән бии алмый. Ул ханым коммунистлар партиясе әгъзасы булгандыр. Чөнки «Я пойду туда, куда пошлет меня родная партия!» афоризмының иң популяр чоры иде. Төскә-биткә дә бик чибәр, бик югары культуралы, акыл сәләтенә дә ия булгандыр. Әлеге урында озак эшләмәде бу ханым.

— Бу мохит минем өчен ят мохит. Мөгезсез башым белән мөгезлеләр арасына эләктем. Бу кирәкле оешмага зыяннан гайре игелек китерә алмыйм, — дип, эшеннән гариза язып киткән.

Аннары әлеге оешмага җитәкче итеп Казанның кайсыдыр районында идеология буенча райком секретаре булып торган ыргак борынлы, ач яңаклы бер ханымны куйдылар. Анысы бу эшне үзе өчен әллә нык түбәнсенде, яңа шартларга күнегеп, җигелеп кенә эшләп китә алмады. Комитетка килгән яшьләр, спорт җитәкчеләре белән ачылып кына сөйләшеп китә алмыйча газапланды һәм аңа килүчеләрне дә газаплады. Бик ипсез җан булды ул. Бер гайрәте чигеп чыккан кеше аның янына бүтән керми дә. Әле ярый Иван Иванович бар. Ул бөтенләй башка зат. Аңа килгән, ишеген шакыган һәркемне колачын җәеп каршы ала. Иван Иванович Ватан сугышында взвод командиры булып катнашкан. Гвардия өлкән лейтенанты. Орден-медальләре дә хәтсез. Әмма дошман тылына тел эләктерергә баргач, чолганыштан чыкканда, минага басып, бер аягын өздергән. Хәзер шыгыр-шыгыр агач аяк өстерәп, култык таягы белән йөри. Бәлкем, аңа шулай иплерәктер. Эш бүлмәсенә кергәч, башта агач аягын, салып, аны өстәленә куя. Бүлмәгә беренче тапкыр керүче хәтта сискәнеп китә. Чөнки аның әлеге күпне күргән агач аягы сиңа төбәлгән кул пулеметын хәтерләтә.

Шәһәрнең барча администраторлары, туристлары Иван Ивановичны әтиләредәй якын күрәләр. Нинди генә гозер, йомыш белән килсәң дә, ул сине кире бормый. Гозереңне уңай хәл итәргә барыбер бер-бер җаен таба. Төп йомыш шул була инде: шәһәрнең төрле вузларында укыган яисә төрле предприятиеләрендә эшләгән альпинистлар, туристлар, берәр тарафка сәфәргә чыгарга яисә бөтенсоюз күләмендә оештырылган Альпиниадаларда, беренчелекләрдә катнашырга җыенсалар, акыллы киңәш,

материаль ярдәм, юл раскруткаларын күтәрешергә ярдәм сорап, аталары каршына килгәндәй, аңа киләләр. Рожковмы?! Дөнья бәясе агай!

Иван Иванович гозер белән килүчеләрне:

— Ә нигә? Миңа килеп дөрес эшләгәнсез. Эшлибез аны! — дип, үз сүзләренә үзе үк куәт биреп, шап итеп учын учка сугып каршы ала.

— Әгәр аягым булсамы, наныйларым?! Үзем дә сезгә иярген булыр идем. Шәт, чанагыздан тибеп төшереп калдырмас идегез әле. Минем фронтта калдырып кайткан аягым монысыннан күпкә яхшырак иде, — дип тә өсти әле. Шушы хәленә юмор белән карый алгач, ничек инде аны хөрмәтләмисең?

Иван Иванович Рожков Шәүкәтне бу юлы балта асып куярдай куе тәмәке төтене эчендә каршы алды. Сугыш ветераны тәмәкене көйрәтә генә. Аның тәмәке янчыгы да берәр ярлы-ябагайның арык алашасы авызына элә торган солы кормушкасыннан ким булмас.

— Син, Шәүкәт, бу араларда бөтенләй юкка чыктың. Кая югалдың?

— Иван Иванович, имтиханнар чоры җиткәние бит. Ниһаять, «Борынгы заманнар тарихы»н да тапшырдым. Академик Грековның томнарын хәтта чәй эчкәндә дә кулдан төшермәдем.

— Имтиханнар ничек узды соң? Бер кәржин «неуд»лар җыймагансыңдыр бит?

— Тфү, тфү! Ул көнгә үк калмадым. Биш имтиханны да стипендиягә тапшырдым.

— Анысы минемчә булган. Молодец!

Рожковның өстәлендә Шәүкәтнең туризм спорты өлкәсендә ирешкән күрсәткечләре теркәлгән исемлек ята.

— Быел мин ике спорт мастеры, биш кандидат үстерергә тиеш. Яшьләрне спорт белән тәрбияләү — республика комитетының күрсәтмәсе шундый, Шәүкәт. Ә менә сиңа спорт мастерына кандидат булу өчен дүртенче дәрәҗә кыенлыктагы туристик походка җитәкче булу җитми. Нибары бер талпынып аласың калган. Шуны үзең әллә белмисең дәме? Шушы исемлек синең үз кулыңда бармы соң? Быел дүртенче курсны тәмамлыйсың. Кара аны, егетем, бишенче курста күпкә өлгерә алмассың. Уралда атаклы Конжаков, Денежкин кыялары башында булгансың. Болары хуп! Документларда «өченче дәрәҗә кыенлыктагы маршрут» дип кенә бәяләнсә дә, температура атналар буена утыз градустан төшмәгән шартларда әлеге тау очларына менеп әләм кадауны мин егетлеккә саныйм. Өлгергәнлек, булганлык билгесе бу! Э-эх, аякларым исән булсамы?! Бусы да алай зарланырлык түгел, әмма фронтта калдырып кайткан аягым монысыннан күпкә яхшырак иде...

Иван Иванович авызындагы төрепкәсен әле сүндергән генә иде. Самосадны күп итеп салып, яңасын көйрәтеп җибәрде.

— Бу сыңар аяклы карт шайтан мине нинди максат белән чакыртты икән дип уйладыңмы соң син? — дип сорап куйды ул, серле генә итеп.

Шәүкәт иңбашларын җыерды:

— Һәрхәлдә, бер дә тикмәгә генә түгелдер әле, — дип елмайды.

— Дөрес уйлыйсың. Мәскәүдән туристларның Үзәк клубында расланган бик кызыклы бер маршрут җибәрделәр безгә. Беләсеңме кая? Кола ярымутравы буенча маршрут.

— О-о, Кола ярымутравына?! Атаклы Хибин таулары?! — дип сорап куйды Шәүкәт. — Ул якларда булган юк, менә анда барып чыксаң да ярый. Бик теләп.

— Дүртенче дәрәҗә кыенлыктагы маршрут! Тундраны кичәргә теләсә кем кыюлык итмәс. Ә син менә тәвәккәллә! Көчле группа тупла да выждырт. Айкап кайтыгыз шул якларны.

— Маршрут кызыктыргыч. Монче тундрасы! Хибин таулары! Мин алай да бүлмәбезгә кайтып бүрегем белән киңәшләшим әле. Миңа бер тәүлек вакыт бирегез.

— Аңламыйм мин сезне, бүгенге яшьләрне, — дип сөйләп китте Иван Иванович. — Әллә ниндирәк сез, инертный газ сыманрак. Сезне бер оборот белән генә кабызырмын димә.

Иван Иванович, зур сер чишәргә җыенгандай, сөйләшүеннән шып туктап, як-ягына каранды.

— Алайса тыңла, егетем, мин сиңа чынлап торып бер зур сер чишәм. Пока бу турыда берәүгә дә! Бер дә юкка гына дәшмәдем мин сине бирегә. Тс-с берүк! Э-эх, аякларым исән булса, бу экспедицияне үзем генә җитәкләгән булыр идем... Син, Шәүкәт, әзрәк кенә булса да газеталарга күз саласыңмы? Дөнья хәлләре белән өстән генә булса да хәбәрдармы? Караштырып барасыңдыр дип уйлыйм. Син бит идеология фронты көрәшчесе буласы белгеч. Шуны беркайчан исеңнән чыгарма, ишүдән туктасаң, көймәң артка йөзәчәк.

Иван Рожков Шәүкәтнең тарих факультетында укуын гына түгел, Казан каласындагы спортка тартым бар студентларның исем-фамилияләрен, кайда укуларын, кем булырга җыенуларын — барчасын белә торгандыр. Агайның сыңар аягы булмаса да, хәтер-зиһене уникаль иде.

— Кадерле Иван Иванович, сессияләр чорында рәттән биш имтихан бирдем. Кая ул газеталар караштырып бару, — дип елмайды Шәүкәт. — Кызартасыз мине.

— Менә шул шул. Укымаганыңны күреп торам. Әгәр син бу көннәрдә «Комсомольская правда» битләрендә басылган хәбәрләрне укып барсаң, дустым, минем янга беренче булып үзең йөгереп килгән булыр идең. Болай пассив утырмас идең.

Аның бу сүзләреннән Шәүкәт тә әсәрләнеп китте.

— Нәрсә анда, җир йөзеннән эзсез-хәбәрсез югалган Атлантида илен тапканнармы әллә? — диде ул. — Андромеда йолдызлыгыннан безгә кунаклар, гуманоидлар килмәгәндер бит?

— Кызыксынганнар, улым, Атлантиданы да эзли торсыннар. Ә мин «Комсомолка»дан аннан да кызыклырак хәбәрләр укып барам. Тянь-Шань тавы битләрендә янәдән «кар кешесе»н күрә башлаганнар бит, Шәүкәт! Мә, укы! — дип, Шәүкәт алдына «Комсомолка»ның берничә санын куйды. Кайткач укырсың, дип, аларны кире алды. Үзе сөйләп китте: — Газета битләрендә әледән-әле күренеп торган бу хәбәрләр, имеш-мимешләргә генә нигезләнеп, сенсация, укучының игътибарын җәлеп итү өчен генә бирелми. «Кар кешесе»н үз күзләре белән күргән конкрет кешеләрнең исемнәре әйтелә. Югары разрядлы һәр туристка, һәр альпинистка таныш Тянь-Шань тауларындагы атаклы Федченко бозлыгында фәнни-тикшеренү эшләре алып баручы геологларның палатка читенә бәйләп куйган резин көймәләрен алып киткән бит, шайтан! Бу очракта геологлар «кар кешесе»н үзләре күрмәгәннәр. Бу кичтә палаткаларында йоклаганнар. Әмма иртән торып чыксалар, әле яңа гына явып узган җепшек кар өстендә «кар кешесе»нең эзләре чабата хәтле булып ярылып ята икән. Кире кага алмаслык дәлил түгелмени?! Ә куй көтүчеләре үз күзләре белән күргәннәр. Кыргызлар алар үзләре дә япуннар, вьетнамнар кебек вак халык түгел. Эре сөякле алар. Минем үземнең взводта бик ярау гәүдәле ике кыргыз егете бар иде. Әлеге «кар кешесе» иң ярау кыргыз көтүчесеннән дә бер башка калку, бик киң җилкәле, аю да түгел, чын мәгънәсендә кеше дә түгел, бөтен шәрә тәнен куе кара йон баскан, ә күзләре машина фарасы кебек яна, дип сөйләгәннәр. Көч-куәтенә хәйран калганнар. Көтүгә төшеп йөз килолы сарыкны култык астына гына кыстырып алып киткән. Көтүчеләр этләрен өстереп караганнар. Кая ул! Бүреләр өстенә ташланып, аларны буган овчаркалары, койрыкларын бот араларына кыстырып, хуҗаларына сыенган. Көтүчеләрнең яшьрәге аны мушкага алмакчы булып винтовкасын күтәргән. Ә «кар кешесе», кинәттән генә артына борылып, аңа зур йодрыгын янаган. Егетем, шаярма, янәсе.

Иван Иванович шулхәтле дәртләнеп сөйли. Боларның барысын ул әйтерсең үз күзе белән күргән! Ә Шәүкәт әле һаман да аның тел төбен төшенеп бетә алмый.

— Почти сенсация ич бу! — диде Шәүкәт. — Безнең тулай торакның уку залында «Комсомолка»ның подшивкасы бар иде. Берәрсе чәлдереп чыкмаган булса, торакка кайткач яңадан бер танышып чыгармын әле.

— Эш монда ул хәбәрләрне синең укуыңда-укымавыңда түгел бит, Шәүкәт! — дип, өстәлгә йодрыгы белән сугып куйды Иван Иванович. — Эш монда алдагы җәйдә беренчеләрдән булып Федченко бозлыгына барып басуда, шунда десант төшерүдә. Э-эх, әгәр дә мәгәр аякларым исән булсамы?!

Иван Иванович өстәлдә яткан, Казанның таш урамнарында йөреп, трамвай ишекләренә кысылып ярыйсы таушалган агач аягын кулына алды.

— Мин бит гвардеец! Беренче дәрәҗәле Дан орденым да бар. Мәскәүнең Ветераннар клубыннан хат салганнар. Кил, дигәннәр. Чехословакиядән анда протез ясау осталары килгән. Кил, бер дигән ипле һәм җиңел протез ясатып җибәрәбез, дигәннәр. Барып чыксаң ярар иде дә, вакыт юк бит. Эш кала. Бүлмәне бикләп чыгып китә алмыйм бит. Понимаешь?

Сугыш каһарманы, нибары унтугыз яшеннән сыңар аякка калган гвардияче агач аягын кулында әйләндерә бирде.

— Чыдамрак булсын өчен, яшь каен агачыннан үземә үзем ясаган аяк булса да, күнектем мин моңа. Әллә нинди ипле протезлар бирсәләр дә, барыбер үз аягың түгел. Моны алмаштыра алмаслар төсле. Аннары, инде күпме яшисем калгандыр?.. Кабергә дә шушы аягым белән бергә илтеп салыгыз, диярмен. Васыять итеп әйтермен... — Иван Иванович сискәнеп киткәндәй булды: — Стоп! Стоп! — дип маңгаен тотты. — Каян килгән пессимизм бу миндә! Мондый төшенкелеккә бирелә башласаң, в деревянный бушлат сыграть недолго, черт побери! — дип, тиз генә үзен кулга алды.

— Һич кичекмичә Федченко бозлыгына экспедиция оештырырга кирәк. Суга барсаң, иртәрәк бар, соңга калсаң, болгана, диләрме әле? Икенче, өченче кеше булып кына килсәң, бүрекләрнең дә сайлаганнары гына калуы бар, егетем, — дип сөйләп китте ул. — Мин аңа бүгеннән үк хәзерлек башладым. Комсомол өлкә комитетын, СССР Фәннәр академиясенең Казан бүлеген, ДОСААФны кызыксындырдым. Акча белән ярдәм итәргә күндердем. «Кар кешесе»н ауларга, һич югында аны кинога төшереп кайтырга үзебезнең Казаннан экспедиция җибәрергә кирәклеген төшендердем. Барысы да хупладылар. Хупламыйча! Патриотизм хисе һәркайсыбызда җитәрлек. Бу изге максатка үзебез дә армый-талмый өлеш кертәбез бит. Экспедициядә үзләре дә катнашырга теләк белдерүче хәтта бик дәрәҗәле түрәләр дә бар. Монда иң әһәмиятлесе менә нәрсә! Бездән барган экспедиция «кар кешесе»нме, Су анасын аулармы, әллә буш кул белән кайтырмы — эш анда түгел. Чөнки бар экспедицияләр дә гел уңышка очрап тормыйлар. Бернигә ирешми, буш кул белән кайтучылар да була. Бөек философ Сәгъдинең: «Диңгездәге һәр кабырчык та зөбәрҗәт бөртеге белән авырлы булмый», — дигән бик акыллы афоризмы бар. Әйе, без җибәргән экспедиция дә «кар кешесе»н, бәлкем, күрә алмас. Ул үзе дә, әйдүк-әйдүк, хуш киләсез, үзем дә сезне күптән көтә идем, дип, экспедиция әгъзалары

каршына кочагын җәеп, текә Альп кыялары битеннән җыйган родендрон чәчәкләре тотып чыкмас. Мине башка нәрсә дулкынландыра: үзебезнең Татарстан егетләренең даны ераклларга яңгырасын. Без тереклек иткән ошбу картлач дөнья, башка мәшәкатьләрен бер генә минутка булса да онытып торып, игътибарын Тянь-Шань тауларындагы Федченко бозлыгына юнәлткән. Әнә нинди зур фәнни ачышлар ясау максаты белән әлеге бозлыкка аяк баскан Татарстан егетләре турында укысын. Алар өчен борчылсын, янсын, горурлансын. Э-эх! Гомерләр узып бара. Шушы бәхетләләр белән бергә буласы иде. Мин үземне еш кына бөек фантаст язучы Жюль Верн белән тиңлим. Ул да бит геройлары белән су астында йөзмәгән. Мин дә, маршрутларны сезнең белән уза алмасам да, күңелем белән һәрчак сезнең белән. Берәр группаны походка озатсам, чыгып киткән көннәреннән күңелем гел алар белән. Сак кына йөрсеннәр, ул-бу булмагае, хәвеф-хәтәргә юлыга күрмәсеннәр дип йокысыз калам.

Иван Иванович Шәүкәтне үз иткәндер инде.

— Ни бит әле, шайтан, — дип куйды ул. — Мине дәвалаучы врач тәмам аптыратты инде, госпитальгә чакыра. Икенче аягыңны да кисеп алыйк, югыйсә гангрена башлану куркынычы бар, ди. Булса булыр инде. Икенчесен кистермим... Ярар, бу кадәресе минем шәхси борчуым. Ә тел төбем шул. Сине шуның өчен дәштем дә. Кандидатлар туплый башлаган экспедиция составына сине дә кертәм. Кышкы шартларда группа җитәкчесе булып Кола ярымутравында булып кайтсаң, тагын да әйбәт булачак. Команда составын республиканың иң өстәге агайлары раслаячак. Экспедиция командасына кандидатларның туризм-альпинизм өлкәсендә ирешкән дәрәҗәләре зур роль уйнаячак. Диңгез өсте тигезлегеннән җиде мең метрлар биеклеккә, мәгърур Тянь-Шань тауларына бер дә хәзерлексез кешеләр җибәреп булмый. Анысын үзең аңлыйсың.

«Әнә ничек икән бит әле! — дип уйлап куйды Шәүкәт. — Тянь-Шань тауларына, «Кар кешесе» эзеннән әнә нинди кызыклы экспедиция оештырылачак икән. Анда катнашу — күңелендә туардай матур хыялларның пигы, үзе зур бәхет! Эләгәсе иде бу экспедиция составына...»

* * *

Бу һәрьяклап матур агайны Шәүкәт беренче курста укый башлаган көненнән алып һәм дүрт еллар даими аралашып белә. Иван Ивановичның өстендә Шәүкәт аны беренче күргән чактагы һаман шул куе зәңгәр шевиот костюмы. Муенындагы галстугы да шул ук. Әмма кая да булса берәр төбәккә поход оештырырга ярдәм өмет итеп, юлга акча сорап килүчеләргә ул еш кына үз кесәсеннән дә чыгарып йөз сум бирә. Бу акчаны алмый калырга ярамый. Сугыш ветеранын нык рәнҗетүең мөмкин. Бу турыда егетләр яхшы беләләр.

— Монысы, күгәрченкәем, минем өлеш. Мине дә үзегез белән бер походта, бер маршрутта дип уйлагыз. Әгәр аягым булсамы?!

Казанның бар вузларының студентлары туризм белән тәмам җенләнәләр. Монда, бәлкем, Иван Ивановичның да өлеше бардыр. Туризм бит ул, әйтик, чаңгы спортындагы кебек, ун километр араны рекорд минутларда чабып уздың да спорт мастеры булдың яки, штангадагы кебек, йөз килограмм йөкне бер көчәнүдә баш өстенә чөйдең дә чемпион булу гына түгел. Туризмның аның бер көн эчендә, моңарчы әле берәү дә аяк басмаган сукмаклардан узып, мәкерле тау-кыя башларында булып, шашып-котырып аккан елгаларны кичеп, ә кичен исә чарт-чорт янган учак янында утырулары да бар. Ул учак янында күңелдә нинди генә җылы хисләр тумый, нинди генә матур сүзләр сөйләнми, матур җырлар җырланмый. Әйе, әйе, дөньякүләм әһәмияткә ия иң бөек ачышларның да күбесе чарт-чорт янган учак янында, аның җылы нурлары тәэсирендә тумый микән әле? Болары бер хәл. Берәр походта булган һәр турист үзенең туган җирен, яшәгән төбәген ихлас күңелдән сөяргә өйрәнеп кайта. Походта бер булган туристны син аны өендә бәйләп тота алмыйсың. Җае, мөмкинлеге чыгу белән ул берәр группага кушылып походка чыгып китү ягын караячак. Җәяүләп, дөяләргә атланып, байдаркаларга, салларга утырып, җилкәнле көймәләр белән...

О-о, Урал тайгасының уртасында яисә Кавказ тавының иң очында пыскып кына янган учак янында кич уздыру үзе бер җитди гомер, мәңге онытылмый торган матур хатирә! Учагыңны дөрләтеп яндырыр идең дә, утының чамалы. Диңгез өстеннән дүрт мең метрлар биеклектә утын юк. Җылы яратсаң, учак моңын тыңларга теләсәң, бу биеклеккә утынны үз җилкәңдә алып менәсең. Күпме күтәрә аласың, шул чаклы. Хет кубометры белән. Әмма болай да егерме килограммнан артык рюкзагыңа тагын бер бөртек кенә чыра кисәге өстәсәң дә, аяк атлый алмастай арыган чаклар да була. Тик төн уздырасы бозлыкка утынсыз да менеп булмый. Суыкка һич түзә алмас булган чакларда бензинда эшләүче керогаз алып менүчеләр бар. Әмма ул керогазның ни җылысы, ни романтикасы. Эченә салган бер стакан бензин беткәнче аяк очыңа яткан карт мәче төсле гыжлый инде ул. Җегәрлегеңне иң киреенке, иң соңгы ноктасына җиткереп булса да, берәр кочак утын алырга тырышасың. Өстә, бозлыкта, агачлар үсми, утын юк. Менә шунда кинәттән генә син кабызган учакка, бу ни хәл, каян килгән дигән сыман, бөтен галәм шакката. Төнге салкынлыктан бераз якыная төшкәч, шунлыктан тагын да ныграк җемелдәшкән йолдызлар, бераз җылынып алырга дип, синең баш очыңа, син яккан учак тирәсенә җыелгандай

булалар. Чын әгәр, җыелышалар, үзара гәпләшеп җем-җем киләләр. Монысын Шәүкәтнең үзе сынаганы бар.

Институтның Товарищеская урамындагы тулай торагына Иван Иванович яныннан Шәүкәт бик дәртләнеп, очып кайтты. Алда кышкы каникуллар. Менә шул чорда Кола ярымутравына туристик сәфәргә чыгарга хәзерлек тә күрә башлады. Беренче эше итеп институтның Туристлар клубына йөгерде. Анда туризм буенча халыкара спорт мастеры Лев Михайлович Дятловны эзләп тапты. Клубка да җитәкчелек итә. Туризм инде берничә ел рәттән институтта махсус предмет буларак та укытыла... Укытылмыйча! Чөнки институтны тәмамлап мәктәпкә килгән яшь укытучы балаларны туган якны өйрәнү буенча походларга алып чыгарга тиеш бит. Кулына компас алып азимут белән йөри алмаса, урман уртасында кунарга туктап палатка куя, аш пешерә, беренче медицина ярдәме күрсәтә алмаса, бу һөнәрләрне институтта ук өйрәнеп чыкмаса, аннан кайчан өйрәнә? Менә шушы күнегүләрне үзләштерергә беренче курс студентларын берәр атнага Мари урманнарына практик күнегүләргә алып чыгалар.

Лев Михайлович Шәүкәтнең ниятен хуплады. Ул да: «Эх-х, вакыт булса икән. Беренче курс студентларын Мари урманнарына алып чыгасым бар. Башка, бушрак чак булса, мин дә берсүзсез сезгә иярген булыр идем», — дип көрсенде. Шәүкәткә бик җентекләп маршрутны өйрәнергә булышты.

— Учти, маршрут җиңелләрдән түгел. Моңарчы берәү дә балта чапмаган Карелия тайгасы, бихисап күп күлләр аша, Хибин тавы сыртларыннан узарга туры киләчәк. «Көчсез» команда белән бүтән юлга чыга күрмә тагы, — дип, аталарча киңәшләрен бирде туризм буенча халыкара спорт мастеры Лев Михайлович Дятлов. — Ә группаны туплау, егетем, үз ихтыярыңда. Монда бит, үзең беләсең, физик яктан көчле, таза булу гына җитми. Походка чыгучыларның психологик яктан бер-берләренә туры килүче затлар булу шарт. Шулай булмаганда, кая ул ике атна тату, дус булу, бер палаткада куну, бер казан, бер тәлинкәдән ашау? Арада үзен генә сөюче, бик авыр холыклылар да очрый. Андыйлар бер көнлек походка чыккач та иптәшләре белән талашып, кычкырышып бетәләр.

Шәүкәт, сигез егет бергәләп тату гына яшәп, укып яткан бүлмәсенә кайткач, тумбочкасыннан ак кәгазь алып: «Казан дәүләт педагогия институты студентларының Кола ярымутравы буйлап дүртенче дәрәҗә кыенлыктагы туристик походта катнашучылар исемлеге, — дип язды. — Группа җитәкчесе — беренче разрядлы спортчы Шәүкәт Бакиров...» — Анысы үзе була.

Шушыларны язды да уйга калды. Походта катнашырга теләүчеләр күп булыр, ә менә кемнәрне алырга? Группа унике-унөч кешедән артмаска тиеш. Мондый ерак юлга биш-алты кеше генә чыгып китәргә дә Туристлар клубы рөхсәт бирмәячәк. Кыш уртасы. Ерак юл, бөтенләй яңа маршрут. Ерак юлда ни килеп чыкмас? Группа артык ишле булса да кыен, җитәкчелек итү авыр. Группа бүселә, ике-өч төркемгә бүленә башлый. Аларын Шәүкәт яхшы белә.

Кемнәрне алыйм икән дип утырганда, аның башына кылт итеп акыллы фикер килде. Поход уңышлы узсын дисәң, һич икеләнмичә Толик Бакалинны алырга кирәк. Толик — күп походларда булган турист. Картаны су кебек эчә, компасны яхшы белә, юлда, хет очсыз-кырыйсыз дала уртасында, хет куе урман яланында бик оста ориентация ясый. Бу егетнең походлар өчен тагын бер кадерле ягы бар — ул һәркемгә түземле. Юкка-барга беркемгә дә бәйләнми, юктан гына берәүгә дә үпкәләми. Шәүкәтнең Толик белән берничә походта бергә булганы бар. Һәркайсыннан тагын да дуслашып кайттылар.

— Бу походка үземнең ярдәмчем, урынбасарым итеп Толик Бакалинны чакырам! — дип куйды Шәүкәт үз-үзенә. — Бармыйм, димәс, баш тартмас әле.

Шәүкәт, дүртенче катка менеп, Толик яшәгән бүлмәнең ишеген шакыды.

— Кем анда? Бүген бездә прием юк! — дигән тавышны ишетсә дә, Шәүкәт ишекне үзенә тартты. Толик өйдә, монысы иң мөһиме. Караватына кырын яткан. Кулында — «Борынгы Рим тарихы». Дәүләт имтиханнарына әзерләнеп ятуы икән. Толик аны чыраен сытыбрак каршы алды.

— Берсе керә, берсе чыга, иркенләп кенә укырга бирмиләр. Алда госэкзаменнар тора бит, диплом язасы бар. Әллә башны алып бер-бер яры чыгып качасы инде, — дип мыгырданды ул.

— Менә-менә, үзем дә синең янга шундый тәкъдим белән мендем, — дип башлап китте Шәүкәт, кереш сүзләргә вакытын әрәм итмәде. — Барулары, кайтулары белән бу поход күп булса икә атнага сузылыр. Маршрутны гына күр әле. Төньяк Карелия, Кола ярымутравы буйлап бит! Синең бит ул якларда булганың юктыр. Моңарчы без күбрәк Уралны, Алтайны, Кырым-Кавказны штурмладык. Күреп тә, ял да итеп кайтырсың. Мин сине походка дәшәм.

Толикның шундый сәер бер гадәте бар: сиңа бер-бер җавабын биргәнче, башта тып-тын калып, маңгаена төшкән бөдрә чәченең бер чеметемен ашыкмый гына бармагына урый башлый. Озак урый ул аны. Хәйләкәр. Мондый чакта аның башы да сизгер эшли. Вариантларны анализлый. Эшкәртә.

Конкрет кына җавап бирергә ашыкмады, бу юлы да бөдрә чәчен сул кул бармагына озак урады.

— Әгәр дә мәгәр, Толик, син миңа шундый үтенеч белән керсәң, мин ике дә уйлап тормый риза булыр идем. Ә син? Мин сине җан дустым санап йөрим. Ялгышмаганмындыр бит? Җавабыңны бир! Сузма!

— Мин дә бит әле бармыйм дип әйтмәдем, — диде Толик, чак кына елмаеп. Тумбочка өстендә яткан соры фетр эшләпәсенә ымлады. — Эшләпәм белән киңәшергә ирек бир... Кичке поездга чыгып йөгерергә түгелдер бит?

— Алайса, язам сине исемлеккә. Беренче итеп?

— Ашыкма! — диде Толик, бармагына яңа чеметем чәч урап. — Үпкәләмә, бара алмыйм бит... әй.

— Ник? — диде Шәүкәт.

— Беренчедән, бу поход миңа берни дә бирми. Кандидат минимумын мин инде үтәдем. Ә мастерны диплом алгач, юллама белән эшкә килгән җиремдә үтәрмен дип торам. Икенчедән, һәм монысы иң мөһиме, ун көннән мәктәпләрдә диплом алды педпрактика башлана. Мине малайлары бик азгын 47 нче мәктәпкә билгеләделәр. Дәресләремне нәтиҗәле бирә алырмынмы дип, бүгеннән үк ут йотып торам. Дипломга да бит бәяне педпрактиканың ничек узуына карап куялар. Бик теләсәм дә, Шәүкәт, бара алмыйм икән. Үпкәләмә, брат, гафу ит.

— Ә мин менә синең яныңа шулхәтле зур ышаныч белән кергәнием. Бәлкем, кире уйларсың, Бака, — диде.

Уралда үскән Толик татарча да бераз сукалый. Ә Шәүкәт аны дус итеп Бака дип йөртә.

— Арыслан, Юлбарыс, Акула кушаматлары миңа ошыйрак төшә, Шәүкәт. Ә син Бака кушаматы бирдең, — ди Толик, елмаеп. — Ярар инде. Мин бакаларны да хөрмәт итәм. Алар һәрчак шат күңелле, бик чиста су кошлары.

Икенче көн иртән Толик Шәүкәт бүлмәсенә үзе төште. Ишектән керү белән:

— Мин кире уйлап куйдым бит әле, — диде һәм маңгай чәчен бармагына урарга әзерләнде.

— Ур-ра! Ур-ра, Толик! — дип, яткан җиреннән сикереп торды Шәүкәт. — Син саф алтын, син рубин, син чын гений.

Толик «ашыкмый тор» дигән ишарә ясады.

— Күнсәм, егетем, бер шарт белән генә күнәм. Белмим, менә син минем шартыма күнәрсеңме?.. Менә анысы проблема.

— Мин синең мең шартыңны үтәргә әзер, Толик дустым, — дип белдерде аңа Шәүкәт, — хәтта мең дә берне!

— Ашыкма-а-а! — диде Толик. — Ашыккан ашка пешкән. Минем бу шартым чыннан да меңгә торырлык.

— Тормагае! Синең походка китәргә ризалык бирүең мең шартыңны да каплый, — диде Шәүкәт. Алай да бераз сагаеп калды. Йөзе җитдиләнде. — Алай да?.. Әйт шартыңны? Башымны кисәргә булмаса...

— Үзебез белән Ләләне алсак кына күнәм.

— Кайсы Ләләне? Аяклы бәлане?

— Нәкъ үзе! Бәхтиярованы...

Бу исемне ишетүгә:

— Ы-ык! — дип куйды Шәүкәт. Алай да үзен тиз кулга алды. — Синең булачак каенсеңлеңнеме? Шартың чыннан да меңгә тора бит, дускаем.

— Аның кемнең каенсеңлесе буласы әлегә суга сәнәк белән язылган. Кем белә, бәлкем, синең каенсеңлең булыр. Ә бәлкем, кәләшең үк булып куяр? Ә нигә? Кәләш булырлык җире юкмы әллә? — Толик кинәттән генә бик рәсми сөйләшеп китте. — Мин сүземне географфакның икенче курс студенткасы Ләлә Бәхтиярова турында алып барам. Ферштейнешь булыр?

Әйе, андый кызый бар. Тулай торакта яшәүчеләр аны яхшы беләләр. Башы-аягы белән утыз килолардан артмаган, кәҗә бәтиедәй арык, сәер бер кызчык ул Ләлә. Укуын кайчан укый торгандыр, ничә карасаң, этаждан этажга күбәләк кебек очып йөрүче ул булыр. Дәрт борчасы кергәнме күңеленә, әле теге егеткә, әле монысына сүз ката. Әмма барысы да, хәтта беренче курс студентлары да аңа ничектер ташлама ясап, кече сеңелләренә караган төсле карыйлар. Шуны аулак җиргә дәшеп сөякләрен шатырдатучы берәрсе һаман табылмый.

Кайчак шулай була бит, хәтта песиләргә дә җир өстендә уйнау-шаяру аз тоела башлый. Берзаманны ду кубып көтүләре белән түбәгә менеп китәләр. Аларга песи баласы да иярә. Түбәгә чыккан өлкән мәчеләр туйганчы уйныйлар, шаяралар, уйнап туйгач, түбәгә ничек менсәләр, шулай төшеп тә китәләр. Ә песи баласы менгәндә менгән инде, хәзер инде төшәргә курка. Башы әйләнә. Менеп алуларын, коткаруларын сорап мыраулап кычкыра. Ләлә дә нәкъ менә шул песи баласы инде. География факультетында укыса да, әлегә походта да булганы юк. Кая поход, тулай торактан читкә атлаганы юк. Хәер, аны кая да булса ияртергә бик ашыгып та тормыйлар бугай. Чаңгыда хет басып тора ала микән? Дүртенче дәрәҗә кыенлыктагы әлеге поход поляр кругның аръягында узачак. Төннәрен салават күперенән күп бай төсләр белән балкыган төньяк балкышының матурлыгын сөйләп бирешле түгел. Төньяк балкышы — уникаль күренеш. Бу могҗизаны үзен күрергә кирәк. Ләкин... Анысын Шәүкәт үз җилкәсендә татыды. Төньяк Урал да шулай ук поляр круг биләмәсендә. Төньяк балкышыннан соң кайчак бишәр тәүлеккә сузылган күз ачкысыз буран була. Җирле халык аңа күнеккән, юлга, диңгезгә

чыкмый, куышына кереп бикләнә. Алдан ук хәзерлек күрә. Ә туристларга ташлама юк. Буран дип палаткаңда да утыра алмыйсың. Маршрутны барыбер тиешле срокта үтәргә кирәк. Алдан сөйләшенгән, билгеләнгән пунктка вакытында килеп басмасаң, димәк, бер-бер хәл булган. Ике тәүлек кенә көтәләр дә вертолетлар белән эзләргә чыгалар. Анысы инде аның шулай ук мактанычлы хәл түгел.

Шәүкәтне уйларыннан аерып:

— Йә, ничек, бер шартым меңгә торамы? — диде Толик, авыз чите белән генә елмаеп. — Әйттем, кисәттем бит.

— Тора-тора! Ничек кенә тора әле.

— Ә син минем мең шартымны үтәргә әзер идең...

— Үзе дә утыз килодан артмаган булачак балдызың, ике потлы рюкзаклар күтәреп, маршрутта бара алырмы соң? Бу юлы инде миңа уйлап карарга бераз вакыт бир син.

— Уйла, уйла! Менә походларда кия торган шушы җылы калфагың белән киңәш. Ул ни дияр? — диде Толик.

Дусты алдына нинди кыен шарт куюын ул үзе дә аңлый иде. Әмма аның үз хәсрәт-борчулары да бик прастуйлардан түгел иде шул. Өзелеп яраткан кызы Миляны бертуган сеңлесе Ләлә аркылы кулга ияләштерү, үзенеке итү планы аның башында. Миля — татар марҗасы Миләүшә — Толик белән бер класста укып, бер урта мәктәпне тәмамлаганнар. Казанга укырга бер поездда, бер вагонда килгәннәр. Толик — тарих, Миләүшә география факультетына кергәннәр. Толик Миләүшәгә мәктәп елларыннан ук муеныннан, баш түбәсеннән гашыйк, ә тегесе Бакалинны яратып бетермәгән булып кылана. Бу турыда бөтен тулай торак белә. Кайбер егетләр, хәтта кызлар да, Толикны кызганыпмы-кызганалар. Егете чалбар чабуына буталып йөрүче бер баламут булса икән. Чибәр, акыллы, бик әдәпле! Толик Бакалин — коеп куйган талантлы киноартист Баталов! Нәкъ үзе! Дәрәҗәле егетләрнең берсе.

Миләүшә үзе ah итәрлек Сылукай булса икән. Тәмам караңгы төшкәч кенә ярыктан чыгып сайрый торган кәзәнкә чикерткәсе инде. Иртәсенме, киченме, муенын гел мамык шарф белән бәйләгән булыр. Җәен-кышын дигәндәй, борын тартудан туйганы юк. Тик Толик Бакалинга бу турыда әйтмә дә, сөйләмә дә.

— Миляның бит хроническая ангина. Аның ничек газапланганын мин генә беләм, — дип җибәрә. Миләүшә адресына бер мыскыллы сүз дә әйттерми.

Миләүшә — беренче разрядлы волейболистка. Спортчылар киемендә генә залга чыгу белән, аның тал чыбыгыдай сыгылып торган искиткеч матур буй-сынын күреп, егетләр ah итәләр. Ә уйнавы?! Чын мастерларча бит. Аларның командасы күп уеннарда җиңүне Миляның осталыгы аркасында яулый. Миләүшә катнашкан волейбол ярышларын тулай торак егетләре шәһәрнең «Динамо» спортзалына барып карыйлар. Аны һәр удары саен алкышлар белән күмәләр.

Ярышлар барышында залда:

— Миля Бахтияр! Миля Бахтияр! — дигән тавыш кына яңгырый.

Менә шушы Миләүшә Бәхтиярова бер дигән егет Толик Бакалинга нигәдер игътибар итми шул, гәрчә Толик аның аяк табаныннан үбәргә әзер булса да.

Тулай торакның зур спортзалы бар. Шимбә йә берәр бәйрәм кичләрендә бу залда бик зурдан кубып танцылар була. Берочтан пединститут кызлары белән танышып китәргә дип, «Динамо» егетләре, КАИ студентлары, Казанның артиллерия училищесы курсантлары киләләр. Бу кунакларга тулай торак егетләре бераз көндәшлек белән кырынрак карасалар да бер дә тиктомалдан гына бәйләнмиләр. Чөнки тегеләр дә үзләрен «в пределах допустимой нормы» тоталар. Ә инде арада борынын һавага төбәп, мин танылган спортчы, рекордсмен, мин КАИ студенты, булачак авиатор, ә мин булачак генерал, дип йөрүчеләр булса, торак егетләре күп сорап тормыйлар. Андыйларның борынын бик тиз арада каз мае белән майлап алалар.

Миләүшә шушы кичәләрдә танцыга гел кунак егетләр белән чыга. Тегеләре дә гел аның тирәсендә чуалалар. Ә Толикка шушы күренешкә түзеп торырга кирәк бит. Торак егетләре, Толикның хәленә кереп, Миләүшә тирәсендә чуалучы берәр курсантны тукмап алырга да каршы түгелләр. Толик үзе:

— Кирәкми, егетләр, — дип тыя килә.

* * *

— Әгәр Ләләне дә алырга рөхсәт бирсәң, походта катнашырга мин риза, — диде Толик Шәүкәткә. — Минем шартым шул. Килешсәң, по рукам!

Инде төп мәсьәлә хәл ителгәндәй, Толик сорап куйды:

— Тагын кемнәр язылды? Кемнәрне ияртәсең? Өченче дәрәҗә кыенлыктагы турпоходта булмаганнарны алма. Алар белән бәладән башаяк.

«Үзең соң миңа кемне алдырасың, Толик?» — дип әйтмәде инде Шәүкәт. Телен аркылы тешләде.

— Виктор Ершов язылып чыкты.

— Теге «первый красавец» Ершовмы?

— Нәкъ үзе.

Викторның мактанырга яратуын бар туристлар да беләләр. Аның сөйләвен тыңласаң, институтның барча чибәрләре тик аңа гына гашыйк. Шулай булса да, түзәләр аңа. Чөнки эрудит, белмәгән нәрсәсе юк. Кызык итеп сөйли белә. Черт-черт янган учак янында ул король, ул падишаһ. Барысы да аның авызына төбәлгәннәр. Йә Фетны, йә Есенинны яттан укый. Алай аһ итеп гашыйк булмасалар да, кызлар яраталар аны. Аларны сыйларга Виктор үзе дә бик юмарт, кесәсеннән ирис конфетын беркайчан өзми. Мактанчыграк булса соң? Һәркемнең дә бер җитешмәгән ягы була бит инде. Арбаның да көпчәкләре гел бер эздән генә тәгәрәми...

— Тагын Олег кереп язылып чыкты.

— Кайсы Олег?

— Үзебезнең Олег инде.

— Бер дигән егет! — дип хуплады Толик.

— Хатыным белән барабыз, дип, Ольганы да яздырды.

— Болар ышанычлылар, — диде Толик. — Хатыны Ольга да чаңгыда шәп йөри.

Бик чибәр егет Олег. Казанга терәлеп кенә торган Биектау районының Коногоровка авылы побының бердәнбер улы. Бик укымышлы, һәрчак шат күңелле, уен-көлке ярата торган егет. Белмәгән, кулыннан килмәгән эше юк. Кызларның үкчәсе купкан туфлиләрен үз күз алларында ук төзәтеп бирә, клей белән галошларын ябыштыра, киез итекләр төпли. Йөзендә һәрчак елмаю, авызында һәркемгә матур сүз, комплимент. Рухани, чиркәү хезмәткәре баласы булуын да яшерми. Өстендә муеныннан алып кендегенә кадәр ап-ак сәдәфләр тезгән кап-кара күлмәк булыр. Олег белән Ольга бер авылдан, бер үк мәктәптән. Алар да урта мәктәпне бер класста укып, бергә тәмамлаганнар. Икесе дә, имтиханнар тотмыйча, институтка медаль белән кергәннәр. Биология факультетында укыйлар. Аларны Ромео белән Джульетта дип бер дә юктан гына атап йөрмиләр. Олег авыл побының улы булса да, Ольга — авыл урта мәктәбе директоры, Коногоровка башлангыч партоешмасы башлыгы кызы.

Кызын сорап килгән егетне Ольганың әтисе, үтә кызыл фикерле коммунист, беренче килүендә капкадан да кертмәгән. Урта мәктәпне тәмамлаган чагында, чыгарылыш кичәсендә, «фәннәрне үзләштерү өлкәсендә аеруча зур уңышлары өчен» Олегка үз кулы белән алтын медаль тоттырса да, сөйләшү койма аша гына булган.

— Син, Олег, поп малае була торып, авылның партоешма башлыгы кызын сорап килергә ничек батырчылык иттең? Ни йөзең белән? — дип сораган ул, бармак янап, кичәге укучысыннан. — Син, Олег, үзеңә кәләшне поп кызлары арасыннан эзлә инде. Безнең капканың кыңгыравын бүтән басма. Ольганы иңбашларына алтын погоннар таккан Совет Армиясе лейтенантына бирәчәкбез. Беренче сорап килүчегә үк.

Шуннан Олегка нишләргә инде? Сыгылып төшәргәме? Атеизмның көчле, Коммунистлар партиясенең дингә каршы сәясәтенең киң җәелгән чорлары бит.

Олегның әтисе, үз вазифаларына тугры калып, Коногоровкада гына түгел, күрше-тирәдәге авылларда туган һәр баланы чукындыра килгән. Партоешма моңа бик нык каршы булса да. Ике гаиләнең Монтекки һәм Капулетти гаиләләре позициясенә басуы бик табигый. Олег та беренче уңышсызлыктан ук кара кайгыга батучы, сыгылып төшүчеләрдән түгел. Икенче курсны тәмамлаганнан соң, өр-яңа кара сатин күлмәк киеп, Ольгалар капкасының җиз кыңгыравын янәдән баса. Бу юлы Ольганың әтисе аңа өч шарт куйган: минем киявем буласың килсә, беренчесе — муеныңа аскан тәреңне минем алда ук өзеп ташлыйсың. Икенчесе — әтиеңнән баш тартасың. Өченчесе — бүгеннән үк комсомолга керәсең. Ни гаҗәп, әй, Олег комсомол түгел иде шул.

Аңа карап кына аның егетлек сыйфатлары комсомолларныкыннан бер дә ким түгел. Артыграк булмаса әле. Ольганы әтисеннән сорап-сорап та үзенә бирмәгәч, Олег башкача тәвәккәлләде. Алар яшерен язылыштылар, ир белән хатын булып яши башладылар. Әмма бу турыда ике якның да әти-әниләре әлегә белмиләр. Гәрчә Ольганың әтисе тулай торакка атна эчендә кимендә ике тапкыр килеп торса да.

— Каникуллар чорында барыр җиребез юк. Походта булуыбыз яхшырак. Карелия урманнарын күреп кайтырбыз, — дип аңлатты Олег.

— Фаягөл безнең белән барырга тели.

— О-о! — дип хуплады Толик. — Ул бит «Ворошиловский стрелок». Бер дигән чаңгычы. Фаягөл — физмат студенткасы. Таш тамак. Коридорга чыкса, аның тавышы торакның икенче башында яңгырый. Фаягөлнең фотосы ничә ел рәттән институтның Почет тактасында. Ул Ленин исемендәге стипендиат!

— Шул атаклы Карелия урманнарын, Хибин тауларын үз күзем белән күреп, кара чыршы сагызы тараткан хуш исләрне мишәр борынымны киереп иснисем кели. Списокка яз, кәбәм, мине дә яз! — дип, Шәүкәт бүлмәсенә Фаягөл үзе килеп керде. Кайчак шулай юри мишәрчә сөйләшә. — Укып бетергәч күп былса утыз-кырык ызбалы авылга эшкә йибәрсәләр, мондый бәхетләр бәли эләгә, бәли юк. Яз, бер дә беспокоить итмәм, не подведу. Яз, кәбәм, смело яз! Долго думайт итмә. Юкса синеке башыңа бик скоро цал керер. Яисә акыллы башыңнан цәцләрең кацар. Лысый калырсың, атәм.

Фаягөл Шәүкәт өстенә шулай ташкын булып ишелде. Бик чая мишәр кызы ул. Чая гына түгел, бик башлы да, күрәсең. Физматта укып, Ленин стипендиаты булу өчен, академик булып туу кирәктер, биллəhи! Фаягөл — Казанның бер чибәре! Төз ату буенча вузлар арасындагы ярыш чемпионы булса да, сул күзендә аз гына кылыйлыгы бар. Кыек атып, туры тидерә дә куя. Кылыйлык кайчак бер дигән йөзләрне боза, ямьсезли. Ә менә Фаягөлнең битенә, киресенчә, аерым гүзәллек өсти төсле.

Дөньяны аз-маз күрергә өлгергән, институтка хәтле солдат хезмәтендә, флотта булып кайткан өлкән курс егетләре Фаягөлнең бөтен чибәрлеге әнә шул чак кына кылыйлыгында дип саныйлар. Әнә шул чак кына кылый күзен чак кына кысып, бераз гына читкә карап, елмаеп куйса, сине шәм итеп эретә. Аның күңел тәрәзәсен кат-кат чиертеп караучылар күп булды. Әмма Фаягөл, шайтан кызый, бик сирәкләргә генә елмая. Институт егетләренә, тулай торак егетләренә борылып та карамый. Болай үзе бик йомшак күңелле ул.

— Фаягөлгә төшкән күңелемне берни белән юата алмыйм. Әгәр дә мәгәр ул минеке булмый икән, ультиматумым шундый: тотам да суелам, — дип, пычак тотып йөргән физмат егетенең бүлмәсенә кереп:

— Нургали, кәбәм, суелырга думайт итә күрмә инде. Чашма, ташла, ыргыт мине душаңнан. Беләмсең, мин сине миннән мең өлеш чибәр мишәр кызы белән таныштырам, валлаhи, келисең икән — бөген үк, — дип юатып йөрде әле.

Мондый хәлләр бүтән кабатланмасын өчендер инде, тулай торак егетләренә ачык текст белән:

— Үпкәләмәгез дә, артымнан да йөрмәгез. Сезгә кушып үзегез хәтле алтын бирсәләр дә, берегезнең дә кирәге юк, берегезгә дә карамыйм. Биш ел башкалада яшәгәннән соңмы? Тигез асфальт юл өстеннән чык-чык басып биек үкчәле туфлиләр белән йөрергә күнеккәннән соңмы? Сезгә кияүгә чыгып, янәдән авылга, бөтен районга бер дамский залы булган төбәккә кайтыргамы? Билдән пычрак изәргәме? Иртән көтү куып, кичтән кәҗә саваргамы? Ленин стипендиаты башым беләнме?! Никогда в жизни! — дип кисәтә. — Лучше үләм! Юк, мин чегән таборына ияреп китәм... Күрше планеталардан да яучылар килми калмаслар әле. Гуманоидларны атәм... Лучше чит планетага китәм.

Өлкәнрәк курсларда укый башлагач, Фаягөл үз дәрәҗәсен тагын да күтәрә төште. Курсантларның иң чибәрләренә, менә-менә генерал булам дип торганнарына да борылып карамый башлады, шайтан кызый.

— Ул курсантлар белән башымны бәйләп, кып-кыска гомерне дөм кыргый тайга уртасындагы гарнизонда, атлары-этләре белән бар тере җаны унбиш-егермедән артмаган погранзаставада әрәм итәсем барые... Исем китте бик...

* * *

— Фаягөлне дүрткуллап алабыз! — дип янә кабатлады Толик.

Бераз башын кашый төшеп:

— Менә Женя Шахтин да теләк белдерде. Аны алуга ничек карыйсың? — диде Шәүкәт.

— Кайдан ул? Мин аны белмим бугай.

— Спортфактан. Казан малае. Чаңгы буенча СССР спорт мастерлыгына кандидат. Март аенда Ленинградта булачак илле километрга узышларда катнашырга җыена. Сезнең белән походта йөреп кайту минем өчен ныклы күнегү генә булачак, ди.

— Алырга кирәктер, — дип суздыТолик, бармагына бер чеметем чәчен урап. — Авызлыклатмый торган кара айгыр булмастыр бит, шәт?

— Көчле чаңгычы походта зур табыш бит ул. Андый хәзерлеге булгач, без аны алдан юл салып баручы итеп файдаланырбыз.

Шулай hәр кандидатураны өйрәнеп, матур гына сөйләшеп утырганда, Шәүкәт бүлмәсенә, бөтен йөзенә елмаеп, Валентин Осянин килеп керде.

— Карелия якларына походка китәргә җыенасыз икән. Алсагыз, мин дә бик теләп кушылыр идем компаниягә, — диде.

Валентин ике потлы ике герне кулларында очыртып кына йөртә. Кушаматы — Дипломат. Мускуллары уйнап торган, юан беләкле, киң күкрәкле егет. Үзенә бер яратып шөгыльләнгән спорты да юк, ah итеп өзелеп йөргән кызы да күренми. Әмма егетләр арасында авторитеты зур. Галәмәт юмарт ул. Кухняга макарон пешерергә гадәттә зур кәстрүл тотып төшә. Әле юньләп пешеп җитмәгән макаронын мактый-мактый әле тегесенә, әле монысына каптыра-каптыра, үзенә калмый да. Өченче каттагы бүлмәсенә еш кына ерык авыз белән, әмма буш кәстрүл белән менә. Ә кухня тирәсендәме?! Мактап каптырган макароныңны кыстатмый гына йотып барырдай егетләр, хәтта кызлар да тоpакта hәрчак җитәрлек була.

Кызлар янына килгән КАИ студентлары йә училище курсантлары белән конфликт чыккан чакларда, биленә хәтле чишенеп ташлап, уртага Валентин чыгып баса. Йөзендә яз кояшыдай елмаю.

— Мин бу конфликтны тыныч юл белән хәл итү ягында, егетләр, — ди ул, тимер мускулларын уйнатып.

Аның бу сүзләреннән соң кайсыдыр чуар йөрәк, кайнар баш аркасында килеп чыккан әлеге конфликтны ике як та «аннулировать» итәргә әзерләр. Бер-берләренә гафу үтенү грамоталары бирмәкчеләр.

Валентинның шушы сүзләреннән соң яу кырына швабралар күтәреп чыккан торак егетләре дә, шунда ук бил каешларына ябышкан курсантлар да бер-берләренә кул бирешеп, бер-берсен кунакка дәшешеп таралышалар. Валентинга Дипломат димичә соң!

Бакалин, яңадан кайтып:

— Кистереп кенә әйтмәдең бит әле. Ә безне? Безнең икебезне дә аласыңмы соң? — диде. Толикның ике бит уртасындагы бал кашыгы сыярлык кына чокырлары тагын да тирәнәеп куйдылар.

«Бу татар маржасы Миләүшәнең аягын сугып сындырасы бар. Шушындый егеткә дә йөз чөереп карамакчы», — дип уйлап алды Шәүкәт.

— Бик кыен булмасмы икән? Синең балдызыңның чаңгыга басканы да юк түгелме соң?

Толик елмаеп алды.

— Әлегә миңа балдыз түгел бит ул. Ә менә бергәләп Карелия урманнарын кичеп, поляр кругның аръягында булып, төньяк балкышларын күреп кайтсак, мине апасына үтереп мактаса, яраткан балдызым булып куюы да ихтимал. Дипломатия! Тонкая вещь. Понимать надо, Шәүкәт!

— Имәндә бит чикләвек! Ә мин кайда ул дип баш ватам, — дип маңгаена сугып алды Шәүкәт. — Афәрин, Толик. Наполеон башы бар синдә. Апасын сеңлесе аша кулга төшермәк буласың. Шахмат тактасында мондый йөрешне «удачный ход» дип атыйлар. Ни күрсәк тә бергә күрербез. Исемлеккә икегезне дә язам. Так и быть!

Казан тимер юл вокзалына беренче разрядлы чаңгычы Габделбәр Садриев һәм тарих факультетының рус-татар теле бүлегенең бишенче курс студенткасы, бик тыйнак кына бер кыз Мөнәвәрә дә төшкәннәр иде. Аркаларында — рюкзаклары, кулларында — чаңгылары.

«Сезнең белән бергәләп дөнья күреп, илләр гизеп кайтырга дип чыктык әле бу сәфәргә», — дип чәчрәп торган бу яшьләргә ни әйтәсең? Аларны да теләп ияртте Шәүкәт. Чөнки Мөнәвәрәне аерата яхшы белә. Аларның тулай торагында аның кебек тыйнак кыз бармы икән? Шахматны бик оста уйный. Күптән түгел студентларның тулай торагына шахмат буенча халыкара мастер Яков Дамский килгән иде. Мин сиңа әйтим, бу мастер берьюлы утыз тактада сеанс башлады. Шахматта үзләрен бик зәһәр уйнаучылардан санаган егетләрнең берсе дә катнашмый калмады бу сеанста. Уналтынчы тактада уйнарга Шәүкәт тә утырды. Мастер барлык утыз тактада да аклар белән генә уйнады. Беренче булып һөҗүмгә күчү мөмкинлеге аның кулында. Шәүкәт бу олы мастерның атакасына каршы үзе яхшы белгән Каракан защитасын кулланды. Рәтләр арасыннан очып кына йөргән Дамский аңа каршы уйнаучыларны берәм-берәм туздыра башлады. Шәүкәтнең Каракан защитасын бик оста гына тар-мар итеп, егерме алтынчы йөрештә аңа да мат чәпәде. Кыскасы, егерме җиде тактада җиңде. Ике партия ничьяга тәмамланды. Атаклы мастерның куенына Мөнәвәрә генә бер мат кыстырып җибәрде. Әй уынды, әй уынды инде халыкара танылган мастер. Ә фактны танымый хәле юк. Кайда хата җибәрүен анализлау өчен, Мөнәвәрә белән уйнаган партиясен куен дәфтәренә язып алды. Мөнәвәрәгә визиткасын сузды.

— Сезне шәһәрнең Үзәк шахмат клубында көтәбез! — диде.

— Мин бит шахмат белән әллә ни кызыксынмыйм, — булды Мөнәвәрәнең җавабы.

— Ah Аллам! — дип бот чапты Дамский. — Кызганыч, кызганыч. Сез бит бүген үк спорт мастеры дәрәҗәсендә уйныйсыз! Татарстанда мине җиңүчеләр бик аз... Сез менә күпме шахмат сөючеләр алдында маңгайга терәп мат куйдыгыз. Алай да бер килегез әле безнең Шахмат клубына. Мин сезне реваншка чакырам.

— Реваншка гына булса, бәлкем, бер килеп тә чыгармын, — диде Мөнәвәрә, бераз елмая төшеп.

Узган көзне Яльчик күлендә туристларның республика слеты булды. Пединститут командасын колагыннан өстерәп беренче урынга Мөнәвәрә чыгарды. Ярышлар унбиш этаптан иде. Анда байдаркаларда узышу да бар. Өс киемнәрен баш очында тотып егерме биш метр араны йөзеп чыгарга да кирәк. Дүрт километр араны космик тизлек белән узып, тиешле аланны компас ярдәмендә эзләп табасың, беренче медицина ярдәме күрсәтәсең. Иң соңгы этапта, учак тергезеп, иң кыска арада бер чиләк су кайнатып чыгарасың. Үч иткәндәй, коеп яңгыр ява башлады. Командаларның алдан хәстәрләп куйган коры чыралары, кипкән каен тузлары чыланды. Яланда учак тергезеп җибәрергә тырышып, егерме өч команда азаплана. Юк, берсе дә дөрләтеп кабызып җибәрә алмый. Кыеклап яуган яңгыр сызган шырпыларын ук сүндереп кенә тора.

Мөнәвәрә дә җыелма команда составында. Кесәсеннән бармак буе гына шәм кисәге чыгарды да, аны кабызып, учакның иң төбенә төртте. Өстен коры кәгазь, каен тузы кисәкләре белән каплады. Яңгыр өстән күпме генә сибәләмәсен, инде шәм үз эше белән мәшгуль, яна бирә. Күп тә үтмәде, учак дөрләп янып та китте. Ярышның бу этабында иң кирәкле очколарны командасына Мөнәвәрә яулап бирде. Команда җиңү шатлыгыннан үрле-кырлы сикергәндә, Мөнәвәрә үзе әллә ни эмоцияләр күрсәтмәде. Чак кына елмаеп, учак читендә тора бирде.

Аннары тагын шунысы бар: походларда йөргәндә никадәр арыса да, никадәр кыен булса да, үз капчыгын берәүгә дә бирми, берәүгә дә күтәртми. Искиткеч аз сүзле иде. Күп чакларны аның авызыннан сәгатьләр буена ләм-мим сүз чыкмый. Мәктәптә нишләр икән? Балалар укыта алырмы? Татар балаларына рус теле өйрәтергә җыена бит... Ә Кола ярымутравына сәяхәт драмтеатр сәхнәсенә чыгу түгел. Шар ярып монолог укыйсы юк.

— Дөрес иткәнсең, Мөнәвәрә! — дип күреште аның белән Шәүкәт. Хәтта күңеле тагын бер баскычка күтәрелеп китте. Бу кызга карата күңел түрендә күптән инде ихтирам хисе йөртә иде.

— Кичә генә ит комбинатына барып, машиналарга көне буе колбаса төядек. Монысы ит комбинаты директорының сезгә күчтәнәче, — дип, Габделбәр Садриев, вагонга кереп утыруга, өстәлгә мөгезе-мөгезе белән ысланган казылык чыгарып салды. Хуш исле, аппетитны кузгатып, сарымсак исе килеп торган казылык. Студент авызына бик еш эләкми дә бит әле ул. Барысы да бердәм үрелделәр.

Ләлә Бәхтиярова гына баштарак:

— Колбасаны җенем сөйми! Мин аны гомеремдә ашаганым юк, — дип утырган иде дә, аннары Габделбәр үткен пәке белән турап торган түгәрәкләрне үз ягына тәгәрәтә генә башлады. Аппетит ашарга утыргач килә, диләр. Хак сүз икән.

Фаягөлнең:

— Ашама, ашама! Безгә күбрәк калыр, — дигән сүзләре нык тәэсир итте бугай аңа. Бүтән бу турыда сүз кузгатмады.

О, чемпион булам, чемпион булам, дип, гел алга бөгелеп чаба торгач бераз бөкресе дә чыккан чибәр генә егет Габделбәр шул колбасалары аркасында конкурссыз-нисез генә командаңың үз егете булып куйды.

Кышкы имтиханнар чорында барысы да нык арыганнар булса кирәк. Поездга утыру белән, дару капкандай, изрәп йоклап киттеләр. Мәскәүгә хәтле баш күтәреп караучы да булмады. Тик Ләлә генә, гадәтенчә, вагондагы пассажирлар белән тиз арада контактка кереп, күрше купедан: «О-о, туристлар! Сез нинди бәхетле җаннар!» дип кат-кат кабатлаган өч-дүрт студентны ияртеп килгән иде дә, якты йөз белән каршы алучы булмагач, тегеләр кире үз урыннарына китеп бардылар. Ләлә дә үз шүрлегенә менеп, песи баласы урынына бөгәрләнеп ятты.

«Булачак җизнәсе ялгыша бугай, — дип уйлап куйды Шәүкәт. — Бу кызчыкны үлчәүгә бастырсаң, утыз килолар да тарта алмас. Походка ничек түзәр, күтәрәмгә калмасмы?»

Группа җитәкчесенә йоклап бару килешмәс. Ул капчыгыннан Джек Лондонның «Мартин Иден» романын чыгарды. Ләкин романның ике битен укырга өлгерде микән, китапның шап итеп идәнгә төшкәнен дә сизмәстән, Алып батыр йокысы белән гырылдап йоклап китте.

* * *

— Ну-у, братцы-кролики! Йоклап та күрсәтәсез! Чын йокы чүлмәкләре икәнсез, сезне иртәнге чәй көтә! — Чәйгә дәшүче Олег, палатканың бер читен генә ачып, ап-ак карга тезләнгән.

— Бер төн эчендә ишеп тә караган карны, — диде ул, елмаеп. — Кыш бабай, болар тәмам рәхәтләнсеннәр, башларыннан чумсыннар, дигәндер инде.

— Яңа кар как раз безнең файдага! — дип тавыш бирде капчыгы эченнән Женя. — Яңа кар өстендә куян, көртлек эзләре ярылып ятачак. Иртәнге чәйдән соң урманга кереп, бер сәгать эчендә дүрт-бишне бәреп чыгармын. Төшке ашка куян итеннән рагу ашарга әзерләнегез. Моны сезгә мин — Женя Шахтин ышандырам!

Олег белән Ольга инде күптән торганнар булса кирәк. Карны таптап, учак урыны ясаганнар. Очлары җәпле казыклар кагып, чиләкләр асканнар.

Тышкы яктан Ольганың да:

— Чәем суына бит, тизрәк кыймылдагыз, әфәнделәр! — дигән тавышы ишетелде.

Күптән уянса да, капчыгы эченнән тынын да чыгармый яткан Фаягөлнең миниатюр радиоалгычыннан «Нас утро встречает прохладой» дигән популяр җыр ишетелде.

— А нас обильным снегом! — дип өстәде Олег.

— Иртәнге чәебез нидән гыйбарәт соң безнең? — дип җае белән генә сорады Шәүкәт.

— Парижның иң яхшы ресторанарындагы кебек инде, — диде Ольга. — Беренчегә — ботка!

— Бер чиләк суга бер пакет «Завтрак туриста» тондырдык, — диде Олег.

Дөгенең иң түбән сортларыннан яндырып-көйдереп, кирпеч итеп катырган бу пакетларны «Смерть крысам!» дип йөртәләр туристлар үзләре. Шулай да бик арзан булганы өчендерме бу пакетларны бер походка да алмый калмыйлар тагын.

— Олег капчыгыннан бер банка куертылган сөт чыкты. Шуннан кофе кайнаттым, — диде Ольга.

— Кофе?! Шәп! — дип күтәреп алды Женя. Капчыгын актара башлады. — Ә минем кыздырган тавык булырга тиеш. Мин аны салкын урыннарда гына тотып, өч көн саклап килдем. Кайнар кофе йота-йота, биш минут эчендә ботарлап ташлыйм. Менә күрерсез. Сөяген дә ташламам. Минем саңаклар Нил крокодилларыныкыннан бер дә ким түгел.

Палатка эчендә кабер тынлыгы урнашты.

— Үлә-ә-әм! — дип, тынлыкны Фаягөл бозды. — Кемнәр белән чыктым мин бу походка? Син, әниеңнең кешелеккә дигән чибәр улы, минем алда шул кысыр тавыгыңны кимереп утырыр идеңме? Оялмыйча! Хәчтерүш!

— Нигә кимермәскә?! Миңа бит аны әнием пешереп тыкты. Теләсәң, сиңа да бер ботын каерып бирәм. Мә! Әнә Ләлә дә, бу тавыкны күргәч, иреннәрен ялап куйды. Аңа ике канатын каерып бирәм, — дип сөйләнде Женя, берни аңламыйча.

— Иреннәремне мин синең тавыгыңа кызыгып яламадым, — диде Ләлә, бераз карлыккан тавыш белән. — Җил тиеп ярылганга яладым.

Женя үзенекен сөйли бирде:

— Сезнең чиләк суга бер пакет «Завтрак туриста» белән генә мин алдан юл яра алмыйм. Урынымнан кузгалып китә алсам да рәхмәт әйтерсез.

— Женя, сиңа карата болай да туп-тулы булмаган хөрмәтемнән дә колак кагасың килмәсә, бир миңа ул тавыгыңны, — дип кулын сузды Фаягөл. — Мин аны утка ыргытам.

Женя:

— Бирәмме соң, жүләр! — дип, тавыгын күкрәгенә кысты.

Капчыгыннан чыгып, Толик Бакалин торып утырды. Башта ашыкмый гына күзләрен уды. Ул да, Шәүкәт кебек үк, озын төннең күп өлешен үзе өчен дә, Ләлә өчен дә тимер мичне каравыллап уздырды.

Шушы минуттан тайга законы үз көченә керә, — диде ул. — Бары бергә, югы уртак. Капчыкларыгызда булган барлык ризык төрләре, ашамлыклар — безнең шушы тату җәмгыятебезнең уртак байлыгы.

— Шушы минуттан беркемнең дә, бу минем үз байлыгым дип, бер шакмак шикәр, бер кисәк сохари алып суырырга хакы юк, — дип куәтләде Толикны Шәүкәт. — Кемдә нинди ашамлык бар, барысын Толикка тапшырырга. Ә син, Толик, һәр сыныкк сохарины исәптә тот!

— Ә менә минем капчыкта ат дагасы хәтле колбаса кисәге ята, — дип, Габделбәр аны Толикка сузды.

— Аңламыйм мин сезне, әфәнделәр! Сезнең белән бераз шаярып алырга да ярамый. Шундук антипартийный группага теркәргә генә торасыз. Бик тәэсирле, нечкә күңелле коллегабыз Женя Шахтин бу позорны күтәрә алмас дип уйлап та карамыйсыз. Мәгез, пожалыста! — дип, Женя да тавыгын Фаягөлгә сузды. — Берү-үк утка гына ташлый күрмә! Артыннан үзем дә сикерәчәкмен.

— Син мине әллә жүләр дип белдеңме? — дип бот чапты Фаягөл. — Мае тамып торган шушындый тавыкны күрәләтә утка ташларга. Үзеңнең теләгең буенча бер канатын Ләләгә бирәм. Ә менә бу симез ботын, алдан юл яручы буларак, үзең кимер, — дип, Фаягөл тавыкны җиңел генә ботарлап бөтен кешегә өләшеп чыкты.

— Нигә тавыклар ике аяклы гына икән? Унбер аяклы булсалар икән алар, — дип көлешеп тә алдылар әле.

Ашарга такы-токырак булса да, иртәнге чәй күңелле узды. Женя, күп булса йөз метрлар гына читкәрәк китеп, берәр куян аулап керергә бик теләсә дә, Шәүкәт рөхсәт итмәде. Кузгала торыйк, диде. Бу юлы юл ярырга Габделбәр белән Валентин бастылар.

— Ә мин соң кем? Резервистмыни? — дип сорады Женя. Тавык белән булып ала язган хәлдән соң, болар әллә мине чит итәләрме дип соравы булгандыр.

Шәүкәт, аның иңнәреннән кагып:

— Күрәсең бит кар ничек тирән. Эш барыбызга да җитәр. Юл яручыларны ярты сәгать саен алыштырып торырбыз. Голая Полянага бүген ничек тә аяк басарга инде безгә. Мүкәләп булса да, — дигәч, тынычланды бугай.

Толик белән киңәшләшкәннән соң, төшке ашка туктап тормаска дип килештеләр. Ничек кенә булса да бүген Голая Полянага барып чыгарга. Үз алдыннан башта Ләләне, аннары Бакалинны җибәреп, Шәүкәт бүген янә «замыкающий» булды. Сәгатенә карап-карап ала, әмма аның кәрваны ташбакадан да әкренрәк бара. Бу килештән... бу килештән... Голая Полянага бүген җитәрләрме?

— Бу килештән, бу килештән, — дип кабатлый ул авыз эченнән.

Бераздан, лыжнядан читкәрәк чыгып, капчыклары өстендә утырып торган Олег белән Ольганы куып җиттеләр. Ике чаңгы таягына таянып, алар янында Фаягөл дә басып тора. Олег, бераз уңайсызланган кыяфәттә:

— Алдагылар юл ярган арада чак кына ял итеп алырга булдык әле, — диде. — Ольганың күңеле болгана, укшый. «Башым әйләнә», — ди.

— Әллә бер-бер ярамаган әйбер каптыгызмы? Юкса барыбыз да бер үк ризык ашадык бит. Әллә Женяның симез тавыгы бозылганрак булганмы?

Фаягөл, Шәүкәткә якынрак килеп һәм бераз пышылдап:

— Авырлы бит ул! Безнең Ольга авырлы, — диде.

— Авырлы?! Ничек инде авырлы?!

— Бик гади генә авырлы, беләсең килсә... Дүртенче атнасы. Ана булырга җыенган яшь хатын өчен бик нормаль күренеш. Баш әйләнүе, укшуы бер атнадан узачак.

Тәмам аптырашта калган Шәүкәт: «Һы, һы, һы!» — дип тамак кырудан бүтән сүз тапмады.

— Шәүкәт, син безнең өчен мыскал борчылма, — дип, Олег аның җилкәсенә кулын салды. Йөзендә холкына хас үз-үзенә ышанулы йомшак елмаю. — Походка без моны белеп чыктык. Сиңа гына әйтеп тормадык. Алдагы булыр-булмас ике йөз чакрымны мин аны Ольгамны җылы юрганга төреп куеныма тыгып та узам.

Шәүкәт, мәсьәләнең ни дәрәҗәдә җитдилеген хәзер генә төшенгәндәй:

— Ә эти-әниләрегез? — дип куйды.

— Алар үз урыннарында. Аларны хөрмәт итәбез, — диде Олег, Ольгасына яз кояшыдай җылы елмаеп. — Менә киләсе елның сентябрь башына алларына ике игезәк малай кайтарып салсак, шатлыктан кая сикергәннәрен дә белмәсләр әле. Шулай ич, Ольга, кадерлем? Картларга игезәкләр кайтарып тоттырабызмы?

Кәефсезлеге йөзенә чыкса да:

— Һичшиксез! — дип куәтләде Ольга Олегны.

— Беренче бәбәйдән үкме? Ә нигә әле игезәкләрдән башларга булдыгыз?

Олег, ике кулын як-якка җәеп:

— Безнең нәселнең традициясе шундый, — диде. — Мин үзем дә игезәк сыңары. Әти дә, бабам да игезәк сыңарлары. Ә мин нигә алардан калышып торырга тиеш?

— Ул чакта сезне алдан ук котлыйм! Бәбәй туена дәшәргә онытмагыз! — диде Шәүкәт һәм кар өстенә салынган эздән алдагыларны куа китте.

Юлны янып-пешеп һаман да Габделбәр белән Валентин яра. Алар артыннан Фаягөл бара. Шәүкәт Женя Бахтинның Виктор Ершов белән:

— Кар өстендә урман ияләре үткән төндә генә салган эзләрне күрәсеңме?

— Бу тайга куеныдамы?!

— Төрле киек-җанварлар чутсыз булырга тиеш монда. Иртәгә Топтыгин әфәнденең үзен үк аудармасам да, берәр кыр кәҗәсен йә боланны аударып бирәм мин сиңа... Көт тә тор! Үзең тунарсың. Туный беләсеңме? — дип сөйләшеп килгәнен ишетте.

Башка чакны чәчрәп мактанырга яратса да, Виктор бу юлы:

— Балыкның теләсә кайсын, хет акуласын туныйм. Ә дүрт аяклы малларны тунап караганым юк, — диде.

Бу ике, бер-берсенә һәрчак чәнечкеле сүзләр әйтергә әзер булсалар да, һаман бергә.

Габделбәр белән Валентинга ял биреп, Шәүкәт үзе дә бераз юл ярды. Бераздан арттан килүчеләр дә куып җиттеләр.

Шәүкәтнең сораулы карашына Олег, хәрбиләрчә басып:

— Иптәш начальник, безнең полкта гадәттән тыш хәлләр юк, барысы да тәртиптә, — дип рапорт бирде. — Ә нигә туктадык?

— Юл яручылар әнә ничек янып-пешеп чыкканнар. Бераз ял итеп алыйк, — диде Шәүкәт.

Изүләрен ачкан Ләлә килеп туктады. Теле салынган.

— Уф! — дип, ике таягы өстенә таянды. Аның артыннан Толик күренде. Аның җилкәсендә ике рюкзак.

«Әле монысы башы гына, соңыннан ни булыр?» — дип уйлап алды Шәүкәт. Әмма Толикның йөзендә язмышына зарлану чаткылары күренми. Ул, киресенчә, бик бәхетле бугай.

Мондый походларга чыккач, төрле хәлләр булуы мөмкин. Калын урманнарны, биек тау сыртларын, күбеккә батып агучы елгаларны кичкәндә, кайберләрнең аерылып йә адашып калуы да ихтимал. Шунлыктан һәркемнең капчыгында компас, шәм, бер кап шырпы, ут кабызырга каен тузы, бер кашык, бер кружка, бер тәлинкә. Юешләнсә, алмашка бер пар кием-салым, җылы оекбашлар, кереп йоклау өчен махсус тегелгән капчык, тугыз метрлар чамасы капрон реп-шнур, бер банка ит консервасы, бер банка куертылган сөт, бер кило сохари, ярма була. Шул рәвешле һәркемнең рюкзагы унике-унбиш килоларга баса. Аның каравы адашып, иптәшләреннән аерылып калган турист, аны килеп эзләп тапканчы, шул запаслары белән кайгы-хәсрәт күрми, хафаланмый автономияле яши ала. Туристлар арасында иптәшләреңне ташлап калдыру гадәте юк. Ике-өч көн эчендә салам чүмәләсенә төшкән энәне эзләп табарга була...

Шул шәхси йөгең өстенә группа өчен кирәк йөк өстәлә. Шәүкәтнең җилкәсендә ун кеше сыешлы сигез килолы брезент палатка. Валентин дүрт аяклы дүрт килолы тимер мич күтәреп килә. Тайга уртасындагы йә тау сыртындагы палаткаңда шушы мич дөрләгәндә генә Ташкент. Хәтта утыз градуслы салкыннарда да егетләр палаткада майкадан калып йоклыйлар. Мичнең торбалары ике метр озынлыкта булса да, алар кырык сантиметр итеп киселгән. Аларны телескоп сыман итеп берсе эченә икенчесен тутырып була. Алары Олег җилкәсендә. Ике куллы пычкысыз, үткен балтасыз шулай ук походка чыгып булмый. Аларсыз тайга уртасында син ятим. Виктор Ершов аркасына өч су чиләге аскан булыр.

Берсе — аш, икенчесе — ботка пешерү, өченчесе чәй, кофе-какао кайнату өчен. Виктор гомер-гомергә шул чиләкләрне эләктерә. Югыйсә, аларны аскач, ул бик көлке кыяфәткә керә, шалтыр-шолтыр бәреп, яньчеп тә бетерә. Ә кайчакны, өчесен дә каршына куеп, джаз оркестр концертлары бирә. Кызларга шул гына кирәк. Алар гел Виктор тирәсендә чуалалар. Монысы да күпләрнең кулыннан килми торган зур сәнгать!

Габделбәр, зарланмый-нитми, артына таккан бер пар чаңгыны сөйри. Фаягөл белән Мөнәвәрәнең капчыкларыннан фанер көрәкләр баш калкытып тора.

Шәүкәт группасын никадәр генә ашыктырмасын, бүген дә әллә ни ерак китә алмадылар. Голая Поляна һаман күренмәде. Ул арада янә караңгы җитте. Караңгы монда кинәттән һәм бик куе булып төшә. Чатырыңны куйсаң куеп өлгерәсең, өлгермәсәң, кабаланып йөрергә кала. Бакалин белән Осянин чатыр корырга иплерәк урын сайладылар. Кулларына ике саплы пычкы алып, тимер мичкә ягу өчен шалтырап кипкән наратны турарга керештеләр. Кечкенә генә булса да, комсыз мич ул. Кышкы озын төнне чыкканчы байтак утынны көлгә әйләндерә.

Виктор, кабаланып, шалтыр-шолтыр килеп, кичке аш әзерләргә кереште. Бу аның яраткан эше. Кызлар да, әйткәнне көтмичә, палатка куярга урын ясарга, мүк баскан җиргә төшеп җиткәнче казырга керештеләр.

— Бу юлы аска ылысны үзем җәям, — дип сөйләнде кулында ут уйнатучы Фаягөл. — Кичә бит чат ботак бастырыклар өстендә йокладым. Андый йокы йокымыни инде ул! Чак кына радикулит сырхавым кузгалмый калды.

Ул арада, күңелләргә шатлык өстәп, Викторның:

— Тәлинкәләрегезне әзерләгез! — дигән авазы ишетелде. — Мин сезгә борщ по-марсиански пешердем.

Бер чиләк суга бер банка тушенка салган, кара чыршы ылыслары тураган.

— Бу борщ симертми. Ә цинга авыруы белән интегүчеләргә аеруча файдалы, — дип теленә салынуын белде. Ни дисәң дә, «борщ» тәмле иде.

— Телеңне йотарлык. Безнең бүлмәдә мондый ашны «Раскинулось море широкое» дип йөртәләр, — дип мактады Валентин.

Сыек шулпа һәркемгә берәр касә генә тиде. Берәр кисәк кенә булса да сохари өләшмәделәр. «Паекларны кысып Толик дөрес эшли», — дип уйлады Шәүкәт үзенең урынбасары Бакалин турында.

— Э-эх, бер буханка кара ипине күкрәккә терәп кисәсе иде, — дип куйды Женя, касәсен төбенә кадәр ялап. — Чәең дә буламы соң? Мин чәйне клиндер тешләп эчәргә яратам.

— Ә кем соң: «Әйдәгез, әйдә! Киттек. Безне тайга үзенә чакыра», — дип ашыктырды? Кибет ачылганны көттермәде, — дип бүлдерде аны Валентин. — Хәзер инде менә чәйне бармагыңны тешләп эч. Кайнар чәй алай да тәмле.

Көне буе тирән кар ерып килгән егетләрнең бу сыек шулпаны шупырып кына ашыйсы килүләре басылмады. Шәүкәт, байтак уйланып ятканнан соң, һәркемгә тагын берәр кисәк сохари таратырга кушты. Толик аның бу йомшаклыгын килештермәде. Иреннәрен бүлтәйтеп, канәгатьсезләнүен белдерде.

— Ул Голая Полянага иртәгә дә әллә барып чыгабыз, әллә юк. Болай юмартланып, командаңа иртәгә нәрсә ашатмак буласың? — дип мыгырданды ул. Үзенә дигән сохари кисәген Ләләгә сузды. Ләлә аңа үзенекен бирде.

Үзе шунда:

— Кичә үлгән булсам, арыш ипиеннән киптергән сохариның шулай тәмле булуын белмичә каласы икәнмен бит, — дип сөйләде.

Палатка авызында утырган Виктор:

— Иртәгә дә Голая Полянага чыкмасак, ботинка табаннарын кимерергә туры киләчәк. Алары синең сохариеңнан да тәмлерәк. Ышан сүземә, мин әйткәние диярсең.

— Бр-р! — дип куйды Ләлә. Булачак җизнәсе Анатолийга төбәлде. — Толик, ул көнгә үк калмабыз бит.

— Кем белә, кем белә... — булды тегесенең җавабы, һәм ул бармагына бер чеметем чәчен чорнарга кереште.

— Иртәгәме?! Таң гына атсын, — дип сүзгә Женя кушылды. — Обещаниеләрне мин сезгә күп бирдем бугай. Таң гына атсын. Мин бу палатканы кыр куяны, көртлек ите белән тутырам. О-о, танытам әле мин сезгә үземне. Моны сезгә Евгений Павлович Шахтин ышандыра! Ма-ма-а-а! Я пока не хочу домой! — дип сузып, авызын зур ачып иснәп алды ул. Тиздән аның палатканы селкетеп гырылдавы ишетелде. Пышан-пышан килеп, үзара нидер сөйләшеп яткан кызлар көлешеп алдылар.

* * *

Фаягөл йоклаган капчык эченнән радиоалгыч тавышы ишетелде:

Широка страна моя родная...

— Страна-то широка, а в нашей палатке мне страшно тесно, — дип киерелмәк булды Женя.

— Чү-чү! Палатканы аударасың бит, — дип кисәтте аны Фаягөл. — Өеңә кайткач сузылырсың. — Димәк, иртәнге алты гына әле. Яктырганны көтеп ята-ята күзең күгәрер. Бигрәк тә ач карын белән.

— Барыгыз да исәннәрме? — булды Шәүкәтнең беренче соравы. — Поход кыенлыкларыннан туеп, төнлә берәрегез качмадымы дип соравым. Женя, кәефләр ничек?

— Мама, я пока не хочу домой. Янәшәмдә Казанның беренче гүзәле Фаягөл тора бит! — булды аның җавабы.

— Хәчтерүш! — диде Фаягөл.

— Мин бил каешымны кичә соңгы тишегенә күчердем, — дип, Виктор телгә килде. — Каешымда башка тишек юк. Капшап ятам, төн эчендә минем корсак тагын да эчкәрәк баткан. Күз алдыгызда чалбарым төшеп китсә, кызлар, берүк аптырап кала күрмәгез. Алдан планлаштырылмаган авария дип кабул итегез.

Мөнәвәрәнең:

— Бигрәк озын монда төннәр, ята-ята янбашлар оеп бетә. Мин торам инде, кызлар. Чәй кайнатам, — дип сөйләшкәне ишетелде.

Учак кабызганда аңа булышырга дип, Шәүкәт тә торып тышка чыкты.

Мөнәвәрә, Шәүкәтнең колагына пышылдап кына:

— Минем капчыгымда ике килолар чамасы манный ярмасы, берәр пешерерлек макарон, бераз борчак бар. «Үзебез барыбер ашамыйбыз, сезгә походта ярар әле», — дип, бүлмә кызлары биргәннәрие. Болай бозылган-ниткән әйберләр түгел. Шулардан берәр шулпамы, боткамы пешерсәм инде? — диде Мөнәвәрә. — Кичә мин аларны, уңайсызланып, Бакалинга тапшырмый калдырган идем...

— Мөнәвәрә, кая, үзеңне бер кочып үбим әле! — диде Шәүкәт, шатлыгын тыя алмыйча. — Синең бу байлыгың безнең өчен Клондайк! Коткардың! Ач үлемнән коткардың бит!

Женяның да локатор кебек үткен колаклары Мөнәвәрәнең сүзен ишетеп алды.

— Мөнәвәрәкәй, син бит безне ачы үлемнән коткардың. Казан шәһәренең мэры булып алгач, беренче эшем итеп сиңа һәйкәл куйдырам. Мәрмәрдән! Юк, бронзадан! Һәйкәлне ачкан вакытта үзең дә шунда торырсың. Үзеңә дә сүз бирермен.

Шунда ул, кинәттән генә сынган чаңгысын исенә төшереп:

— И-и, инде нишлисе генә булыр! «Фишер и К°» мөһере сугылган чаңгыларым капут. Үзем утырып елар идем, күземнән яшем чыкмый. Минем өчен берәрегез елап алыгыз әле, пожалысты. Казанга кайткач берьюлы ике порция эскимо туңдырмасы белән сыйлармын.

Җылы капчык эченнән башын гына чыгарган Викторның карлыккан тавышы ишетелде:

— Шушы капчыкта яткан килеш кенә кофены өрә-өрә эчәргә мин каршы түгел. Ап-ак французбулкасы өстенә калын итеп маргарин да ягып бирсәгез, тагын да рәхмәтле булырмын.

— Атланмай ягарга түгелме тагын? — диде Фаягөл.

Викторның сүз эзләп кесәгә кергән чагы юк аның:

— Студентлар карынына атланмай хәрәм!

Баш астына салган капчыгын алдына куеп, Толик кыштыр-кыштыр килде. Иртәнге чәйгә ризыкларны бүлде, ахры.

— Җир икегә ярылса да, бүген безгә Голая Полянага җитәргә кирәк. Рационны никадәр кыссам да, нибары бер төшлек сохари комы калды.

— Җитәбез! Бүген дә җитмәсәк! Бәлки, Голая Поляна бездән ике адымда гынадыр, әйдәгез, тыңлап карыйк, эт өргән тавышлар ишетелмиме? — диештеләр барысы бертавыштан.

— Чак кына көтегез. Җил кайсы яктан исә соң? — дип теленә остарды Виктор. — Коймак кыздырган таба исе килмиме? Без килү шатлыгыннан берәрсе төче коймак пешермиме?

Фаягөл Женяга безләп үк төртеп алды.

— Кәбәм, син дә шул коймакны тел белән пешерүчеләрдән икәнсең, өметемне окончательно өздем мин синнән. Ничә көн куян шулпасы ышандырасың. Әлегә һавага төбәп тә атканың юк.

— Менә җыенам бит инде, — диде Женя. — Сез палаткаларны җыйганчы, төн эчендә генә салган эздән китеп, берәр озын колак, кылый күзне момент бәреп керәм. Көндезге ашка как раз булачак. Моны сезгә мин — Женя Шахтин ышандырам. Шахтиннар ике сөйләми.

Иртәнге «чәй» берәр кружка сыек кофе булды. Бу калория белән генә ничек урман ерырга? Толик, мыгыр-мыгыр килсә дә, һәркемгә берәр шакмак шикәр, берәр кисәк сохари өләште. Бераз гаҗәпкәрәк калып аңа төбәлүчеләргә:

— Ашказаннарыгызны әзерли торыгыз. Төшкә симез куян шулпасы булачак. Моны сезгә Евгений Шахтин ышандыра, — диде. — Ә ул безнең ике сөйләшми.

Иртәнге чәй сигезләрдә тәмамланса да, урман эче әле дөм караңгы. Поляр круг артында көн яктысы кайда югалып йөридер, унберләр тирәсендә генә яктыра. Ләлә Бәхтиярова кичә үк чаңгыда аягын кырырга өлгергән. Мөнәвәрә белән Толик учак янында аның аягын Вишневский мае белән майлап

бәйләделәр. Тегесе әрем капкандай чыраен сыткан. Бераз шыңшып алырга да исәбе юк түгел. Шәүкәттән шүрли. «Шыңшырлык булгач, нигә иярдең?» — дисә.

Ә Шәүкәт, аңа күз кысып:

— Үзе егылган еламас! Крепись, Ләлә! — генә диде. — Ә син, вобщем-то, молодчина!

Женя бик җитди кыяфәттә палатка алдына чыгып басты. Ауга җыенды.

— Мин дә синең белән, Женек. Мин бит «Ворошиловский стрелок», ату буенча вузлар чемпионы, — диде Фаягөл.

— Берүк озак мавыкмагыз. Көтәргә туры килмәсен, — дип озатты аларны Шәүкәт.

— Безме? Бер куян артыннан биш сәгать йөрмәбез инде. Момент әйләнәбез. Моны сезгә Женя Шахтин ышандыра, — дип күкрәгенә сукты Шахтин.

Фаягөлнең дә кыяфәте сугышчан.

— Сыңар куян артыннан гына йөрүчеләр без түгел! Кимендә биш симез түшкә көтегез, — диде ул, бөтен йөзенә чибәрлек сибеп торган сул күзен кысып, кашын сикертеп.

Мичне дә җыйдылар. Палатканың да карын кагып бәйләделәр. Габделбәр барысының да чаңгы йозакларын тикшереп чыкты. Шәүкәт белән Толик, алларына карта салып, тагын бер кат маршрутны аныкладылар.

— Голая Полянаны уңдарак калдырып, бераз сулга тайпылмадык микән без? — дип әйтә куйды Толик. — Юкса без аңа күптән чыгарга тиеш идек инде.

— Андый шик минем үземдә дә бар, — дип килеште Шәүкәт. — Ләкин бер алган юнәлешне дәвам итми хәлебез юк. Кире артка әйләнеп кайтып, маршрутны яңадан башлый алмыйбыз бит инде. Тагын бер көн барыйк әле.

— Аннары нәрсә? Бу урман массивында башка торак пунктлар күренми... Финляндия чикләренә барып чыкмасак. Чик бозучылар итеп сакчылар тотып алмасмы?

Алардан байтак уңда ике-өч тапкыр мылтык аткан тавыш ишетелде.

— Безнең Женя бу! — диде Виктор. — Берәр боланны аударды, ахры. Дублет белән бәрде бит.

Шәүкәт әледән-әле сәгатенә карап ала, гасабилана. Кузгалырга да вакыт бит. Алан башында Фаягөл күренде. Үзе янган, пешкән, әлсерәгән.

— Булмый бу хәчтерүштән! — диде ул, кулын өметсез селтәп. — Ике бот арасыннан узган куянга тидерә алмады. «Моны сезгә мин — Женя Шахтин ышандырам», имеш. Ышандыра, пычагым, җебегән нәрсә!

— Ә син? Син нәрсә карап тордың? Күкрәк сугарга син үзең дә Женядан ким түгел. Мин «Ворошиловский стрелок» дип юл буе мактанып килдең түгелме соң? — дип, аны Виктор эләктереп алды. — Менә сезнең белән мин булсаммы?! Буш кул белән кайтмас идем, чөнки минем холкымда җәмгыять алдындагы изге бурычымны тану хисе көчле. Алмадыгыз бит...

— Утырма ачу китереп, — дип, Фаягөл тиз туктатты аны.

— Шултикле кире җан, тискәре баш, башта миңа пушкасын бирмәде. Янәсе, беренче куянны үзе ала. Ике пулясын бушка очыргач бирүен бирде, — дип ачынып дәвам итте. — Әмма мин дә тидерә алмадым. Ничек тидерәсең ди. Билдән кар эчендә торып. Мондый ипсез түтәле пушканы гомеремдә беренче тотуым. Без бит тирларда вак калибрлы винтовкалардан атабыз. Ипле стендлардан, озаклап төбәп атабыз. Косойларның исә синең симез куян ите ашыйсы килүеңдә эше юк. Озаклап төбәп торганыңны көтмиләр, аланга йөгереп чыгалар да, шундук юк та булалар. Койрыкларын гына күреп калабыз. Женяның пушкасыннан атып җибәрүгә, аның түтәсе иңбашыма шундый итеп китереп сукты, чак егылып китмәдем.

— Шуны да белми идеңме? — диде Виктор.

— Белмәдем шулай каты бәрү гадәтен. Син дә әйтмәдең, икенче хәчтерүш. Син дә өстәл янында гына батыр.

Фаягөлнең тәмам ачуы купкан. Андый чакта аның теленә эләкмәү хәерле. Ялан башында, ниһаять, Женя үзе күренде. Йөзендә мыскал да үкенү хисе юк, киресенчә, Берлинны алган диярсең.

— A-ah, шайтан! Өйдә әтинең бер дигән ау эте сенбернар калды. Үзең белән мине дә ал, Женя, дип, шулхәтле шыңшыды. Мылтыкны чөйдән алуга, үрле-кырлы сикерә башлады, мине дә ияртә, ахры, дип шатланды бугай. Алмадым бит. Алган булса-а-ам! Йөк, әрәмтамак булмас иде әле. Әнә Фаечка күрде. Биредә маэмайсыз берни чыгарып булмый. Безнең Юлдаш, сиңа кирәксә, ул озын колак, кылый күзләрне ун чакрымнан куып китереп, каршыңа бастыра. Сиңа чакмага гына басасы кала.

Фаягөлнең ачуы йөзенә чыккан.

— Тәмам гайрәтемне чигереп сөйләмә, ичмасам, Женя! Чын хәчтерүш син! Каршыңа китереп бастырсалар да булмый синнән. Үз күзем белән күрдем бит инде, кәбәм!

— Якының турында кискен фикер йөртмә, башкалар да сиңа яхшы мөгамәләдә булырлар, дигән бер изге китапта, — диде Женя, борынын тартып. — Впрочем, ул китап минем рюкзакта. Буш араларда укырга киңәш итәм.

* * *

— Кузгалдык, кузгалдык! — дип ашыктырды егетләрен Шәүкәт. Үзеннән соң берәүне дә калдырмаска кушып, ярсу йөрәк Фаягөлне бу юлы иң артка, арьергардка куйды. Үзе, бераз юл ярырга ниятләп, иң алга басты. «Голая Полянаны уңда калдырып, нүжәли узып киттек икән?» дигән уй янә дә борчыды аны. Ул чакта бу очсыз-кырыйсыз тайганы күпме ярырга була?

Шулчак аны кызу адымнар белән Мөнәвәрә куып җитте.

— Юлбашчы! Ә, иптәш юлбашчы, — дип эндәште аңа Мөнәвәрә. Бу сәеррәк кызның болай сәер эндәшүенә сискәнеп китәргә өлгермәгән Шәүкәткә: — Әнә теге юан чыршыда балта чапкан эз бар, — диде. — Бүген генә түгел. Әмма таныла. Ап-ачык.

— Балта чапкан эз? — диде Шәүкәт. — Кая, күрсәт.

Үзе, болан сикерүе белән сикереп, Мөнәвәрә ымлаган чыршы төбенә килеп басты. Кулы белән капшады: агачта балта эзе! Моннан кемдер узган! Толикны дәште. Кәүсәгә балта сугып ясаган яраны сагыз баскан. Димәк, тамга ясаган көннән кимендә өч-дүрт ел гына узган.

— Бу тамганы моннан узган аучы салып киткән. Куелык бит. Куе чыршы ботаклары астында хәтта көндез дә ярым караңгы. Агачларның очлары күккә ашкан. Тотып кына ориентир ясарга әйләнә-тирәдә ни берәр тау сырты, ни берәр шаулап аккан тау елгасы юк. Шушы куелыкны ерып чыгу өчен аучы берьялгызы нишләсен? Адашып та китсә? Бер урынга йөз килеп чыкмасын өчен үткән сукмагына әнә шундый тамгалар салып бара. Мондый тамгаларны шушы төбәкләрдә яшәгән аучылар сала. Биредән узган геологларның да салып баруы мөмкин. Урал, Себер тайгаларында без аларга еш тап була идек, — дип аңлатты Анатолий. Агач кәүсәләрендәге балта эзен бармагы белән капшап торганнан соң: — Киттек шушы тамга эзеннән! — диде. — Ул, һәрхәлдә, безне берәр торак пунктка алып чыгачак. Монысы инде тулы гарантия белән.

Ат дагалаганда бака ботын кыстырмый калмаган күк, Виктор Ершов кысылмый калмады.

— Әгәр торак пунктка чыкмасак? Тамга сала-сала барып та, тайганы кичеп чыга алмаган бу бәхетсезнең үле гәүдәсе өстенә килеп чыгарбыз. Аны тантаналы шартларда җирләү миссиясен башкарырбыз. Тайга законы моны да хуплый...

— Алай булуы да бик мөмкин, — дип килеште Анатолий, әмма әлеге тәкъдименә берәү дә каршы чыга алмаслык итеп: — Бүген кичкә түгел, егетләр, төшкә өләшерлек тә ризык юк капчыгымда. Бу хәл белән дә хисаплашмый чарабыз юк, кадерлеләрем, — диде. — Әле тапкан тамганың тиз генә кайсы юнәлештә барганын билгеләргә кирәк. Монысыннан илле-алтмыш адымнар ераклыкта тагын шушындый тамга булыр. Анысын да табыйк та китик шул тамгалар күрсәткән юлдан. Кичкә барыбер нинди дә булса торак пунктка чыгарбыз.

— Ә маршрут?! — диде Шәүкәт. — Ул чакта бит без аннан бөтенләй читкә тайпылабыз.

Анатолий, йөзенә философлар уйчанлыгы чыгарып:

— Сиңа маршрутны саклау кадерлеме, әллә иярткән чыккан егетләреңнең исән-иминлегеме? — диде. — Капчыгымда валчык булып уалган бер уч сохаридан башка кичке ашка тәкъдим итәрдәй нәрсәм юк. Ничә көн килдек, ә Голая Поляна юк. Маршрутка теш-тырнак белән ябышуның да чиге бар. Кем белә, аны әллә Мәскәүдә үк хата җибәреп сызганнар, — дип тә өстәде. — Түзәрләр, түзәрләр дә, ачтан егыла башласалар?..

Кораб мачталары өчен сайлап кисәрдәй кара чыршылар түреннән: «Менә бу агачта да тамга бар! Менә монда тагын берәү!» — дигән тавышлар ишетелде.

— Сыптырдык шул тамгалар артыннан! — диде Бакалин.

— Толик, ни сөйлисең син?! Маршрутны ташласак, печән кибәненә төшеп югалган энә төсле булабыз бит. Кола ярымутравын барыбыз белә: әгәр күчереп тартсаң, аның эченә Көнбатыш Европаның берничә дәүләте сыярлык. Азимутсыз-нисез китсәк, без бу тайганы ерып чыга алырбызмы соң? Бу тамганың да безне кая китереп чыгарасын шайтан белгән, — диде Шәүкәт һаман да бирешмичә. Аларның сөйләшүенә катнашмый гына колак салып торган егетләренә бу юлы бөтенләй башка караш белән күз салды. «Әгәр син полководец булсаң, Генштаб генералларының ялгышлыгы аркасында сазлыкка кереп чумган армияңне корыга алып чыкмас идеңмени?» — дигән сорау куйды Шәүкәт үз-үзенә. Барысы да ачлар бит. Инде өченче көн рәттән карыннарын бер кисәк сохари, бер кружка төссез кофе белән алдап киләләр. Әмма бу турыда Шәүкәткә ихтирам йөзеннән генә әйтми булырлар.

— Сыптырдык шул тамга эзеннән, — дип кабатлады Толик, аның уйларын бүлдереп. — Һәрхәлдә, не пропадем!

Шәүкәт, теләр-теләмәс кенә:

— Башка чара калмагач соң... — диде. Кузгалып күп тә бармадылар, алдан юл яручыларның: «Ур-р-а-а! Ур-р-ра-а-а-а!» — дип кычкырганнары ишетелде.

Ни-нәрсә булганын да белмәгән Толик:

— Әйттем бит! — диде.

Юл яручыларны Шәүкәт тә куып җитте. Тирән итеп салган чаңгы эзеннән кечерәк кенә аланга килеп чыкты. Аның кыл уртасында бурап салган кечерәк кенә өй. Куш йодрык сыярлык кына алгы тәрәзәсе алар аланга чыккан якка караган. Түбәсе бик шома итеп каен тузы белән ябылган. Язын-көзен аланны су баса калганда да коры булсын өчен, өйне субайлар өстенә утыртканнар. Зурлыкка алай зур түгел, һәрхәлдә, авыл агае ак мунчасының өчтән бер өлеше кадәр бар да бар.

— Сунарчы өе бу! — диде Анатолий. — Урал, Алтай тайгаларында йөргәндә дә күп очраттык без аларны. Күп җирләрдә заимка дип йөртәләр. — Шәүкәтнең уйларын күз карашыннан төшенеп: — Шушыннан зуры кирәкми дә. Арыпталчыгып, юешләнеп-өшеп тайгадан чыгучы аучыга җәннәтнең үзе инде. Шушында ул рәхәтләнеп ял итә, ашарына кайнар аш пешереп ашый. Авырып-нитеп китсә дә, җаны тыныч. Аю-бүре һөҗүменнән куркасы юк. Терелгәнче хәл җыя.

Сунарчы өенең кечерәк кенә өйалды ишеген зур таш белән терәткәннәр. Шәүкәт эчкә беренче булып атлады. Башы өй түшәменә асып куйган тире капчыкларга бәрелде. Арадан зуррагын элмәктән алып карарга булды. Капчык эчендә киптергән болан ите. Ялгыз кешегә дүрт-биш пешерергә җитәрлек. Башка капчыкларда таш булып кипкән бербөтен ипи, берәр пешерерлек кенә ярма, бер чеметем чәй, кипкән мүк җиләге, коры каен тузы, ут кабызырга чакматаш.

— Дөньяның бар почмагында төгәл үтәлә торган тайга законы буенча, биредә тап булган ашамлыкларга үзеңнән соң ни дә булса калдыра алсаң гына кагылырга ярый, — диде Анатолий. — Ә без нәрсә калдыра алабыз? Бернәрсәбез дә юк бит.

— Алдыбызда ярты сарык түшкәсе кадәр кипкән болан ите ятканда, күрәләтә ач кунмабыз инде, — диде Шәүкәт. Кискенрәк әйтте. Хәер, ситуациясенә күрә артык кискен чыкмагандыр әле. — Караңгы төшкәнче чиләк ассыннар. Нәрсә калдыру турында соңыннан барыбыз бергә уйлашырбыз әле... Үзең бит «егетләр ачлыктан күтәрәмгә чыкмагайлары» дип кисәттең түгелме соң?

Сунарчы куышының куш йодрык сыярлык кына алгы тәрәзәсе төбендә зур, авыр гранит кисәге.

— Тәрәзәсенең рамы да, пыяласы да юк бит. Берәрсе монда кунган чакта тәрәзәсен чыпта яки тире кисәге белән каплый булыр. Киткән чакта әнә шул ташны куймаса, тиеннәр, ак төлкеләр бу ризыкларны сәгатендә юк итеп чыккан булырлар иде, — дип аңлатты күп йөргән, күп белгән Анатолий.

— Кунарга уйласак, бу телефон будкасына барыбыз да сыймабыз бит. Палатка куя торыйкмы, нишлик? — дип, Олег килеп керде.

— Куймыйча! Монда безнең күп булса ике-өч кызыбыз сыяр, — диештеләр егетләр беравыздан.

Аланга бөтенләй икенче яктан, кар туздырып, Габделбәр белән Валентин килеп керделәр.

— Моннан ике-өч чакрымнар гына ераклыкта тагын бер ташландык йорт бар. Анда кайчандыр совет чик сакчылары торган булса кирәк, — дип хәбәр иттеләр алар.

— Сез анда чикне бозып, диверсантлар хәленә төшә күрмәгез тагын, — диештеләр егетләр.

Шәүкәт белән Анатолий да ул йортны төшеп карарга булдылар. Барак-казарма тибындагы, кат-кат картон-крагиз плиткалардан корган өч бүлмәле өй бу. Түбәсе — дранча. Ишек-тәрәзәләре юк. Әмма, палатка, брезент, фанера кисәкләре белән томалап, биредә бик иркенләп кунарга була. Өй уртасына тимер мичне куеп дөрләтеп җибәрсәң, монда да Ташкент булачак. Ун кешелек палатка эчендә унөч кеше төн куну түгел инде. Романтикасы көчле булса да, ябык палаткада кичке биштән иртәнге тугызга хәтле бер-береңә мичкәдәге селедкалар төсле сыенып, бер хәрәкәтсез яту ялыктыра. Көннең якты өлеше бик кыска бит, дүрт-биш сәгать кенә. Ялыкмый да хәлең юк.

Монда, чыннан да, Бөек Ватан сугышына хәтле чик сакчылары яшәгән булса кирәк, «...нская погранзастава» дигән күгәргән калай кисәге аунап ята.

— Бүгенге чик сызыгы бу тарафлардан эчтәрәк булырга тиеш, — дип куйды Анатолий. — 1939 елгы СССР — Финляндия килешүләре нигезендә без чикләребезне ныгыта төшеп, егерме-утыз километрларга эчкәрәк Финляндия территориясенә кердек. Шулай итми дә булмый иде. Ленинград фин чикләреннән нибары биш-алты километрда гына. Стратегик яктан аеруча әһәмиятле Ленинград — Мурманск тимер юлының кайбер участокларына фин чикләренә нибары ярты чакрым гына. Әгәр хәрби конфликт, сугыш-мазар чыкса, финнар бу стратегик юлны ярты сәгать эчендә өзәчәкләр.

— Толик, политик яктан ныкхәзерлекле син. Юллама белән барасы мәктәбеңә сине директор итеп үк җибәрерләр, — дип куйды Фаягөл. — Синең белән бер мәктәптә, бер коллективта эшләргә бүгеннән үк риза.

— Планканы тагын бер баскычка югарырак күтәр, Фаечка, — диде Мөнәвәрә. — Аны бүгеннән районның мәгариф бүлеге җитәкчесе итеп куярга була.

Толик, авыз чите белән генә елмаеп:

— Әй-й, кызлар, кызартмагыз әле, пожалысты. Сез мине бөтенләй белмисез. Әгәр үлчәүгә салсаң, минем холкымда булган начар гадәтләр яхшыларын шундук басачак, — диде. Үзе кызарып китте.

— Беләбез, беләбез, — диде чәчрәп Ләлә. — Толик, син искиткеч! Мин сине бик яратам!

— Менә сиңа мә-ә-ә! — дип суздыФаягөл. — Боларга хәзер:

Бу бармагың ник кәкре, җизнәкәй?

Сине өзелеп сөйгәнгә, балдызым-ялгызым! —

дип кара-каршы җырлашырга гына кала. Менә күрерсез. Мин әйткәние диярсез...

Хәер, әйтеп торасы да калмаган бугай инде...

* * *

Тынгысыз Габделбәр баракның бер почмагында баядан бирле кыштыр-кыштыр килә.

Шәүкәт, тамагын кырып:

— Бу ташландык казармада нәрсә эзлисең? Заставаның стратегик планын түгелдер ич? — диде шаярып кына.

— Шатлык-кайгылары, киләчәккә өмет-хыяллары белән монда нинди матур кешеләр яшәде икән? Кемнәр булдылар икән алар? Һәрхәлдә, туган-үскән җиреннән аерылып, сөйгән ярын калдырып Ватан чикләрен сакларга баскан ил уллары. Шушы егетләрнең, кем белә, бәлкем, берәрсе бүген дә исәндер әле. Алардан берәр төрле истәлек калмады микән дип актарынуым, — диде Габделбәр. Шунда ук: — Эзләгән табар, ташка кадак кагар, дип бер дә юкка гына әйтмәгәннәр. Менә бит таптым! — дип, баш очына җәбе сынык пычак күтәрде. — Бик истәлекле табыш бу!

Габделбәрнең үз әтисе дә 1941 елның 22 июнь таңын Польша чикләрендә каршы алган, чик сакчысы булган. Башта авылга, өч балалы гаиләсенә, Самат агайның «БВП»сы, ягъни «без вести пропал» дигән кәгазе генә килгән. «БВП», ни дисәң дә, кеше күңелендәге өметне өзми әле ул. Хәбәрсез югалганнарның күпмесе исән булып чыкты. Хатыны Хәдичә апа да, уллары да Самат абыйны сугыш беткәч тә озак көтәләр. Инде дөньялар тынычлангач, Кече Аланга калай түбәләр ябу остасы Каюм агай кайтып килә. Самат агай турында ул сөйли. 22 июнь таңында бәреп кергән Гитлер солдатлары белән бер атна чамасы сугышкач, яралы хәлләрендә икесе дә әсир төшәләр. Самат агай, ике-өч җиреннән яралы хәлдә фашистлар коллыгындагы газапларның барысын татып, Германиянең Вустрау концлагеренда вафат була.

— Менә тагын бер экспонат таптым! — дип, Габделбәр ике тәрәзә арасындагы бушлыктан ниндидер төргәк тартып чыгарды. Төргәген яктыгарак тотып актара башлагач: — Шигырьләр бит! Татарча! — дип кычкырып куйды.

Болай кулга алу белән генә аларны тану кыен. Әмма һәр шигырь астына куелган исеме ачык. Бу шигырьләрне Тәлгать исемле татар егете язган. Фамилиясен генә һич танып булмый. Бу төргәкне ни өчен монда тыгып калдырды икән ул? Ашыгып күченгәннәрме? Килеп алырмын дип уйлаган да, әллә бүтән килә алмаганмы?

— Әллә бу шигъри җанлы татар егете Тәлгатьнең гомерен чыршы ботаклары эченә яшеренеп агач башыннан ата торган чик сакчылары үзара «кукушка» дип йөрткән фин снайперы өзгәнме? Алай булса... Ни үкенеч! — диде Габделбәр. Төргәкне бик пөхтә итеп төреп куенына тыкты. — Мин аларны Казанга алып кайтып Татарстан Дәүләт музеенең әдәбият бүлегенә тапшырам. Андагы белгечләр шигырьләрен дә ачыкларлар, фамилиясен дә танырлар. Авторның кайсы тарафтан булуын ачыкларлар.

Ләлә Бәхтиярова, балаларча наивлык белән:

— Кем белә, бәлки, бу шагыйрь бүген дә исәндер? Менә шәп булыр иде! — диде.

— Чыннан да әйбәт булыр иде! — дип җөпләделәр аны барысы да.

Сунарчы куышын кызлар бик ошатканнар иде. Куышны салучымы бер почмакка бик җыйнак кына итеп мич тә чыгарып куйган. Мич алдына Олег күп итеп коры утын кертеп тутырды: кызлар аучы өендә кунарга уйлаганнар иде. Егетләр чик сакчыларыннан калган бараста кунарга сөйләштеләр. Үзебез генә кунарга куркабыз, дип, кызлар да аларга иярделәр. Аучы өен, бер иркенләп кунсыннар дип, Ромео белән Джульеттага тәкъдим иттеләр.

Чик сакчыларыннан калган казармада йокы капчыкларын җәеп, менеп йокларга бик ипле тапчан-сәкеләр бар. Кызлар шул сәкеләрне сайладылар. Бер-берләренә тыныч йокы теләп ятуларына ярты сәгать тә үтмәде, чыр итеп Фаягөл кычкырып җибәрде. Моңарчы ул: «Үлә-ә-әм!» — дип сузарга ярата иде. Бу юлы: «Үтерәләр!» — дип сузды. Сикереп торып утны кабыздылар, барысы да шытыр-шытыр кашыналар. Барак эчендә әчкелтем бер ят ис йөзә. Кырык еллап буш, ташландык торган баракның стена ярыкларыннан, Чыңгыз хан гаскәре кеби тигез сафларга тезелешеп, кандалалар чыга. Кырык еллар узган бит. Ачы җилле көзләр, үтә дә салкын кышлар булган. Ничек ачка, салкынга үлеп бетмәгәннәр? Шәүкәтнең исенә «Наука и жизнь» журналында укыган бер мәкалә төште. Диңгез төбендә алты йөз ел яткан бер көймә турында язганнар иде. Менә шуны өскә күтәргәннәр. Көймәне кояшка куеп киптерсәләр, күрәләр, кандалалары исән!

Палатка куырга инде соң, дөм караңгы. Ә бараста йоклау турында уйлыйсы да юк. Кандала гаскәрләре белән бил алышып, төнне ничек кирәк шулай уздыралар инде. Төн эчендә керфек тә какмаган килеш юлга кузгалуның максаты юк. Шәүкәт командасына икенче көн ял бирде. Ә кызлар, аучы өендә су җылытып, чәчләрен юдылар, коендылар да бугай әле. Аларның аркаларын ышкып-ышкып юарга теләк белдергән Викторны гына кертмәделәр.

Фаягөл бер минут та тик тора белми бит ул. Икенче көнне барысыннан да иртәрәк торып чаңгыларын кигән. Шәүкәт кисәтеп кенә тора: күз күреме җирдән берәү дә читкә атламасын. Команда членнары бер-берләрен барлап, тавыш биреп, хәбәрләшеп кенә торырга тиеш.

Фаягөл алай да:

— Разминка ясыйм. Оешкан карт сөякләрне бераз язам әле, — дип каршы якка таба атлады. Озак та үтмәде: — Бездән якында гына бер матур күл бар, братцы. Шуңа кечерәк кенә бер инеш коя. Инеш койган төштә минем әнкәйнең кунаклар килгәндә өстәлгә җәя торган эскәтере хәтле генә җирдә су катмаган. Үз күзем белән карап тордым. Менә шул бәкедә менә шушының хәтле ап-ак балыклар йөзә, — дип, колачын як-якка җәеп күрсәтте. — Боз астында һава җитмидер үзләренә, һава суларга бәке авызына җыелып торалар. Менә моның кадәрләре бар. — Фаягөл янә кочагын як-якка җәйде.

— Кая, күрсәт күлеңне! Күрсәт балыкларыңны! — диде Женя, палаткадан чәчрәп чыгып. Кулында мылтыгы. — Казан асыгыз. Уха, балык шулпасы булачак хәзер!

— Балык шулпасы начар булмасые ул. Хәерле сәгатьтә! — дип озатып калдылар аларны Ромео белән Джульетта. Ольганың әллә ризык талымлый торган чоры да җиттеме? — Симезрәге эләксә, мин аны бик тәмле итеп кыздыра да беләм.

Озак та узмады, кемнедер бик матур сүзләр белән орыша-орыша, аланга янәдән Фаягөл килеп керде. Кемне булсын, Женяны инде.

— Хәчтерүш кенә түгел! Хәчтерүшнең хәчтерүше бу!

— Нәрсә булды, Фаечка? — дип, аны Габделбәр каршылады.

— Нәрсә булсын! — диде Фаягөл, ярсып. — Берни дә булмады. Безнең мактанчыгыбыз бәкегә мылтыгын бултыйх! Мин тотып калмасам, үзе дә чума иде.

Фаягөлнең шар яруын ишетми калучылар булмагандыр, барысы «Ah!» итеп куйдылар.

— Тартып чыгарып булмыймы соң? Кызганыч, жәл бит!

— Ничек аласың аны! Бәкенең төбе дә күренми. Тирән.

— Җәй булса, суга чумып эзләп карар идек, — диештеләр егетләр.

Тиздән аланга Женя үзе килеп чыкты.

— Бу утын пүләннәре миңа абсолютно буйсынмыйлар. Ярый әле Фаечка тотып калды, юкса үзем дә чума идем, — дип, мичкә ягарга турау өчен Олег аударган коры чыршы өстенә утырды.

— Тирән анда, төбе күренми дә. Мылтыкны алырга су асты көймәсе белән төшсәң генә... Үтерә, үтерәчәк мине әти. Өйгә мылтыксыз кайта алмыйм мин. Әгәр берәрсе мине уллыкка алса, бик теләп күчәр идем. Андыйларны белмисезме?

Женя моңа кадәр ярым шаярып, ярым чыны белән туристлар арасында бик популяр җырның: «Мама, я хочу домой», — дигән кисәген җырлап йә шыңшып куя иде. Бу юлы коры чыршы өстендә чана тәртәседәй озын аякларын як-якка җәеп:

— Господа, вы не оправдали мое высокое доверие! «Фишер и К°» чаңгымны сындырдыгыз, үземне хәзер чүт бәкегә чумдырмадыгыз, — дип бармак янап, аякларын орыша башлады.

Аннары авыр итеп бер сулап куйды:

— Өч көпшәле ярымавтомат Бельгия мылтыгы Казанда берәү иде. Әти үтерәчәк мине. Мама, не жди к ужину домой родного сына... Мине уллыкка алучы булса, мин бүгеннән үк риза...

Габделбәр палатка эченнән рюкзагын өстерәп чыгарды.

— Мин, иске Алат малае, шушындый зур сәфәргә кармаксыз-таяксыз, буш кул белән чыгаммы инде! — дип, капчыгының өске кесәсеннән йомшак чүпрәк төргәк чыгарды. — Алай балыклары күп булгач, без аларны кармакка эләктереп карыйк. Хәзер аларның как раз ач чаклары. Су өстендә чебен-черки юк, күл төбендәге әкәм-төкәмнәр, бака уылдыклары да язга чаклы комга күмелгәндер.

Габделбәр янына Виктор килеп чүгәләде:

— Суалчаннарың юк бит. Нәрсәгә каптырмак буласың?

— Блесна уйнатып карарбыз. Ачлар дип әйтәм бит, ялтыравыкка да кабарга тиешләр.

— Габделбәр, мин дә синең белән, — дип, аның янына Мөнәвәрә дә килеп чүкте. — Түбән классларда укыган чагымда әтием мине үзе белән һәрчак балыкка ала иде.

— Ул чакта чиләк тә эләктер, — диде Габделбәр.

— О-о, чиләк! Нәфсегезне бик зурдан бүрттерәсез түгелме, җанкисәкләрем! Ул чакта балыклар уйнаган бәкене үзем күрсәтәм. Минем арттан! — дип, Фаягөл выж итеп кенә чыршылар арасына кереп китте.

Күп тә үтмәде:

— Казанга кайткач сөйләсәм, беркем ышанмас, ә менә бу мыеклы шайтанны үзем тоттым! Чак суырып чыгардым! — дип, кармагында дерт-дерт чәбәләнгән, көмеш тәңкәләре ялтырап торган зур гына бер балык тотып кайтып килде.

Бераздан Мөнәвәрә дә күренде. Аның кулындагы чиләктә дә балыклар шупыр-шупыр килә. Берсе, авызын зур ачып һава сулаганы, су чиләген үзенә тарсынып, карга сикерде... Беләк буе гына бар.

— Алар анда әйтерсең безнең килеп чыкканны көткәннәр. Салырга өлгермисең, блеснаны шундук өстерәп китәләр, — диде Мөнәвәрә дә, тәэсирләнеп. — Габделбәр безнең молодец та егет инде. Чүпли генә аларны.

Ромео белән Джульетта шунда ук казан астылар. Менә бәйрәм булды ичмасам! Габделбәр тотып килгән балыкларның күбесен кар өстенә салып туңдырдылар. Аларын капчыкларга бүлешеп юлга алдылар.

* * *

Бик тансык тоелган балык шулпасын ашагач, егетләрнең күңеле җырлый башлады. Тамакта бит хикмәт! Симез балык шулпасын ике, хәтта өч котелок ялтыратучылар да булды. Балык шулпасын Ольга чыннан да бик оста, телеңне йотарлык итеп пешерә икән.

Шәүкәт белән Анатолий карта өстенә компасларын салып, байтактан баш ваталар — кәрванны хәзер кай юнәлештә кузгатырга! Чыршыларга чапкан балта эзеннән китеп, алар маршруттан нык читкә чыктылар. Хәзер менә кайда икәнлегеңне, кай тарафларда булуыңны чамалап кара! Сорар кеше дә юк! Балта эзеннән дә китми булмый иде. Аларны алда ачлык көтә иде.

— Кандалакша безнең менә монда, ике-өч йөз километрлар артта. Чөнки аны узгач, Вуокколо разъездына хәтле тагын ике сәгатьләр чамасы бардык әле, — дип, Толик Бакалин тез өстенә җәйгән картасы өстендә компасын йөртте. — Өч көн ярым эчендә бер урында гына таптанып хоровод биемәдек бит. Егерме-утыз чакрымнар гына уздык та уздык. Ул Голая Поляна поселогын җир упмагандыр бит. Димәк, ул бездән уңда калды. Балта эзеннән китеп, без ярыйсы гына сулга каердык бугай. Никель коючылар башкаласы Мончегорск та бездән хәзер күп уңда. Шушы вакыт эчендә без аңа шактый якынаясы урында кырык-илле чакрымнарга ерагаймадык микән әле?

Толик — Казанда бер тәҗрибәле турист. Карта, компас белән ничек оста эш итүеңне күрсәтүгә корылган республикакүләм ярышларда җиңүче. Әмма хәзер хәтта ул да бераз аптырашта:

— Үзебезнең кайда, кайсы географик киңлектә, кайсы меридиан өстендә басып торуыбызны белсәң икән ул! Ул чакта Мончегорскига иң кыска, туп-туры юлны биш минутта сызып бирер идем.

Ул арада Габделбәр янәдән бер чиләк балык күтәреп менде.

— Әлеге бәке авызына бу күлнең әллә барча балыгы җыелган инде. Кармак салган саен кабалар да торалар, — дип акланды ул. — Шундый эреләр үзләре! Әмма безнең яклардагы балыкларның берсенә дә охшамаган болар.

— Бер карасаң, бик сәер бит, Амур елгасы Ерак Көнчыгышта. Ике ара ун мең чакрымнар гына булыр, — дип аңлатты Виктор. — Әмма бу балыкларны бездә Амур балыгы дип йөртәләр. Мурманскида яшәгән чагымда күрше малайлары белән без дә балыкка йөрдек. Аларны без дә күп тоттык.

Әлеге балыклы күлгә койган инеш өстендә егетләр чаңгы эзе күреп алдылар. Дөрес, бик күптәнге эз. Бу эзне калдыручы әлеге инеш өстеннән моннан хет ике ай элек узган булсын, әмма быел узган бит! Чыршы кәүсәсенә кемдер балта белән моннан дүрт-биш ел элек суккан булса, бу эз быелгы. Күп уйлап тормаска, шул эз белән сыптырырга булдылар. Барыбер кая да булса, хет бер кеше булса да яшәгән җиргә китереп чыгарачак бит. Тере кеше заты да бар икән бит бу тарафларда.

Бу чаңгылы узганда бик җепшек көн булган. Аның артыннан көнне нык туңдырган. Эз боз булып туңган. Юкса аны йә кар катламы күмеп киткән, йә Кола ярымутравының бәйләнчек җиле күптән ашап юк иткән булыр иде. Җил уйнаган ачыклыкларда ул хәзер чак-чак кына таныла.

Шәүкәт бу юлы кәрван башы итеп Олегны куйды. Аның артыннан Ольганы бастырды. Алар артыннан, бераз аксый төшеп, Ләлә басты. Көчле чаңгычыларны барысын уртага бастырды. Юл яру кыен булмаганда, көчлеләрне алга куйсаң, алар ыргылып, группадан аерылалар. Кәрван ике-өч километрга сузыла. Толик белән Шәүкәт янәдән «алдан баручылардан коелган тиеннәрне чүпләп барырга» бастылар.

Юлга кузгалыр алдыннан, Шәүкәт бөтен төркемне бер түгәрәккә дәште. Куеныннан дәфтәр бите алып укый башлады:

— «Аучы өенә бездән соң аяк басачак хөрмәтлебез! Без, Казан студентлары, бу җылы куышны урманда кар күкрәктән, көн бик салкын чорда эзләп таптык. Аның мичен ягып, киемнәребезне киптердек, өс-башларыбызны, чаңгыларыбызны тәртипкә китердек. Безгә кадәр булган ризык запасларыннан да авыз иттек. Ситуациянең җитдилеге аркасында ризык запаслары өсти алмадык. Әмма тайга законнарын тирән ихтирам итеп, бездән соң килүчегә ай буе ягарга җитәрлек күп итеп коры утын турап калдырабыз. Бездән соң бирегә кем аяк басса да, аңа берьялгызы утын әзерләп газапланасы булмас. Бер кап шырпы, бер пычак, бер компас калдырабыз. Бу йорт бездән соң килүчегә дә ышанычлы түбә, җылы куыш булсын. Иң изге теләкләр белән Казан туристлары». Шушындый бер истәлек калдырсак килешерме? — дип сорады Шәүкәт иптәшләреннән.

— Әлбәттә, кирәк! Дөрес эшлибез! — дип хупладылар аны егетләре.

— Дөньяви әһәмияткә ия документ бу! — дип куйды Виктор да. — Копиясен үзебез белән алырга кирәк. Киләчәк буыннарга гыйбрәт булсын өчен!

Инеш өсте такыр. Кар яңа гына трактор таптап үткәндәгедәй тыгыз. Әлеге чаңгы эзеннән ике-өч сәгатьләр ипле генә барганнан соң, елганың ике як ярында да урман сирәкләнде. Уң якта, байтак ераста, болытлар арасыннан борын төртеп, тау түбәләре күренеп ала. Хибин тау сырты шушы булырга тиеш. Алар Хибин сыртын аркылы кисеп үтәргә тиеш бит әле.

Бу тар инеш аларны үзе башлангыч алган икенче бер зур күлгә алып чыкты. Күлнең киңлеге генә дә ике-өч чакрымнар булып, озынлыгы — күз күреме.

Әлеге чаңгычы бу зур күлне дә бик кыю төстә икегә ярган. Мондый иркенлеккә чыккач, Женя Шахтин Олег белән Ольганың адымнарына түзмәгән. Кем дә булса яшәгән төбәккә беренче барып чыгу дәрте дә ашыктыргандыр. Ул бар «җилкәннәрен» бөтен хутка күтәргән, күрәсең, хәтта өч чакрымнарга алга киткән. Ярамый иде дә бит. Тәртип, тәртәдә йөрү юкса зур хәзинә! Футбол кырыдай тигез күл өстеннән очкан гына. Шунда, нәкъ чаңгыда очып барган җирдә, дөберт итеп шартлап, боз аска иңә. Күз күреме кадәр җирдә боз өстенә ургылып су чыга башлый. Мондый хәлдә кем дә шыр җибәрер. Җитмәсә, әйләнә-тирәндә беркем юк. Суның тиздән тезенә, аннан муенына җитүе бар. Барып ябышырга яр да бик ерак. Беттем, әҗәлем шушы икән...

Юкса бик табигый хәл. Походларда күп йөргән егетләргә таныш нәрсә. Мондый күренеш кечерәк кенә авыл буаларында еш булып тора. Боз өстенә туш чыга, диләр аны авылда. Күл өстендәге боз беренче салкыннарда ук каткан. Ә кышын күлгә коючы инешләрнең дә, күлнең дә суы кими. Боз белән су өслеге арасында кайчакларны берәр метрга җитешле бушлык хасил була. Күл өстендәге меңнәрчә тонналы боз катламы шул рәвешчә һавада асылынып тора-тора да гөрс итеп су өстенә утыра. Боз өстенә су, ягъни туш чыга башлый. Боз судан күп тапкырлар җиңел бит. Гөрс итеп утырса да батмый. Әнә нинди гигант айсберглар йөзә.

Женяны аңларга була. Әйләнә-тирәдә беркем юк. Ул басып торган җирне су басып килә. Бичара Шахтин акылын жуяр дәрәҗәдә каушый, курка, шыр кычкыра. Кычкырмассың. Күрәләтә торып бата башласаң...

Югыйсә төркемнең башкалары да шушы боздан киләләр. Су чыга башлау белән, каушамый-каударланмый гына, капчыкларыннан нәкъ шушы очраклар өчен йөрткән брезент оеклар, бахиллалар алып кияләр. Чөнки боз өстенә чыккан туш беркайчан да шайтан сөягеннән дә югары күтәрелми. Алдыңа кара да атыңны куа бир. Боз да артыгын батмый.

Янына иптәшләре килеп җиткәндә, Женя бик авыр хәлдә иде, аягында чак басып тора. Дер-дер калтырый. Барысын кочмак-кочакламак була. Аннары өянәге тоткандай укшып-укшып үксергә тотынды. «Женя! Менә кара, берни дә юк бит. Боз аскарак төшкән дә утырган. Су да бүтән күтәрелми», — дип аңлатып карауның файдасы тимәде. Физик яраны дару сөртеп, яхшылап бәйләп дәваларга була. Ә психик яраны, стрессны алай гына дәвалап булмый шул. Аны җиңәр өчен вакыт кирәк.

Боз өстендә дә күп торып булмый. Өскә чыккан су шунда ук чирап тора. Озаграк торсаң, чаңгыларың белән бозга ябышып катуың бар. Атлый торырга кирәк.

Ни тырышсалар да, Женяны җиңел генә тынычландыра алмадылар. Андый чакта иң яхшысы артык игътибар итмәү. Кеше үз җае белән тынычлансын. Ә Женя билендәге тугыз метрлы репшнурының бер очын калтыранган куллары белән Шәүкәтнең биленә китереп бәйләде. Тирән стресс кичергән кешене аңларга була инде.

Тама торгач, тамчы таш тишә. Чаңгыларны бахиллалар кигән хәлдә өстерәп, тары боткасыдай куе су ерып бару кыен булса да, күлнең очына җиттеләр.

Яр өстенә чыгып басу белән, бер-берсенә терәп үк корган ике чум, ягъни яранга күзләренә чагылды. Яннарында кеше-кара күренми. Күренмәсә дә, барысының да күңелләрендә өмет уянды. Кемнеңдер җылы торагы бит. Берсенең янында бер табаны сынык нарта ята. Геологларныкы-мазар дияр идең, алар яранга кормый. Кирәк булса, палатка тарттыралар.

— Менә шулай, иләгән болан тиреләреннән конус формасында очлап корылган бу шалашлар әле һаман да утрак тормышка күчеп бетмәгән төбәк халыкларыныкы булырга тиеш, — диде Бакалин, алгарак чыгып. — Шушындый ярангаларны без Төньяк Уралда йөргәндә дә очраттык.

Ләлә, балаларча наивлык белән:

— Болар кеше ашаучылар түгелме икән? — дип сорап куйды.

Викторга шул гына кирәк:

— Ашасалар, сине тотып бирәбез. Арабызда иң яше син. Димәк, иң тәмле ит синеке. Ләкин курыкма. Алар синдәй арыкка кызыкмаслар.

Ләлә Викторның шаяруын әллә чынга алды, булачак җизнәсенә сыена төште.

— И-их, шушындый вигвамнарның берсендә рәхәтләнеп куну турында гомерем буе хыялландым! — Бер чум ишек төбенә килеп, Фаягөл чаңгыларын чишә башлады. — Тук-тук, теремок! В теремке кто живет, а-ай!

Аз сүзле Мөнәвәрә дә, бик җитди кыяфәттә:

— Минем белүемчә, вигвамнарны Америка индеецлары гына кора бит. Алар монда ничек килеп чыктылар микән? — дип куйды.

— Җир шарының түгәрәк икәнен Магеллан моннан 500 ел элек исбатлады түгелме соң, акыл ияләре! — дип, Виктор репликасын кыстырырга өлгерде.

Шәүкәт чаңгы таягының очы белән генә чум авызына япкан тирене күтәреп карады. Эчтә дә беркем күренми. Чумнар икесе дә буш. Чаңгысын салырга ниятләгәндә, Толик Шәүкәтнең кулыннан тотты.

— Барлык республикаларның Туристлар клубына Мәскәүдән җибәрелгән хатны хәтерлисеңме? — диде ул.

— Хәтерләмичә! Яхшы хәтерлим.

Ул хатта, походка чыгучы туристларга кисәтү буларак, шул турыда язылган иде. Ленинградның Органик пыяла институты студентлары моннан өч еллар элек Ямал ярымутравына туристик поход оештырганнар. Табигатьнең иң кыргый, иң кырыс холыклы почмагына тугыз кеше — дүрт кыз, биш егет барып төшкәннәр. Кирәк бит, маршрутта бөтенләй күрсәтелмәсә дә, җирле халыкларның законнары буенча беркемгә аяк басарга ярамаган, ягъни табу куелган тарлавыкка да барып чыкканнар. Җирле халык — эвенклар кабиләсенең мәрхүмнәрен илтеп ташлый торган тарлавыкта булганнар бугай. Анда берәүгә дә керергә ярамый дип, эвенклар аларны кисәткәннәр. Ә болар тыңламаганнар булса кирәк.

Кыскасы, группа билгеләнгән вакытка аларны каршы алырга тиешле торак пунктка чыкмый. Андый чакта өч көн көтәләр әле. Өч көн дә уза. Болар һаман юк. Студентларны вертолетлар белән эзләргә чыгалар. Маршрутта күрсәтелгән елга янында палатка күреп алалар. Төшсәләр, палатка эчтән бикле. Әмма үткен пычак беләнме, ниндидер башка корал беләнме яныннан ярылган. Кем эшләгән моны? Палатка эчендә, йокы капчыкларында яткан хәлдә дүрт студентның үле гәүдәсенә тап булалар. Ике егет, палаткадан атылып чыгып, кемнәндер качмакчы, йөгермәкче булганнармы? Аларның гәүдәләрен 20–30 метр читтәрәк тапканнар. Бу мәхшәр төндә ике студентка, палаткаларыннан яланөс чыгып, ни дип елга ярына йөгергәннәрдер? Аларның үле гәүдәләрен инеш ярыннан, кар өстеннән тапканнар.

Студентларның палаткасына аю-мазар һөҗүм иткән дисәң, кан-җәрәхәтләре булыр иде. Туристларның берсенең дә тәнендә көчләп үтерү эзе юк. Вакыйга «ярар, булган-беткән» дип күз йомышлы хәл генә түгел бит. Исеме дөньяга танылган Органик пыяла институты студентларын үтергәннәр. Туристик походка киткән җирләреннән. Прокуратура тикшерүчеләре шушы төбәкләрдә болан асрап, балык тотып, аучылык белән көн итүче бераз гына эскимосларга, бераз гына чукчаларга, эвенкларга, алеутларга тартым кабиләләрнең шаманнарын кысып-кысып кат-кат сорау алалар. Алар барысы беравыздан:

— Без бернәрсә дә күрмәдек, без берни дә белмибез! — дип баралар.

Әмма студентларның табу куелган тарлавыкта булулары фактлар белән раслана. Шаманнар исә: «Ул тарлавыкта мәрхүм алеутларның, эскимосларның җаннары яши. Анда беркемнең дә аяк басарга хакы юк. Мәрхүм чукчаларның рухлары әлеге изге җиргә аяк басучыларны, андагы хәлләрне үз күзләре белән күрүчеләрне шундук юк итәчәкләр», — дип баралар.

Әлеге хатта туристик походка чыккан группаларга җирле халык белән очрашканда бик тәртипле, ихтирамлы булырга, кулдан килгәнчә бүләкләр, көзгеләр, кырыну приборлары, беләзек-йөзек, мәрҗәннәр бирергә тәкъдим киңәш ителгән иде.

— Хәтерләмичә! — диде Шәүкәт. Хуҗалар үзләре күренмичә, бернәрсәгә дә кагылмаска кушты.

Учак кабызып җибәрделәр, палатка куярга да уңай урын таптылар. Женя һаман да үзен кулга ала алмый, бичара, дер-дер калтырана. Аны учакка якынрак утырттылар. Биеклеккә сикерү, дүрт йөз метрга барьерлар аша йөгерүләр буенча Казанның танылган спортчысы буларак, шушы хәлгә төшүеннән ул нык уңайсызлана иде бугай. Куркаклык күрсәтте бит. Бу турыда берәү дә Казанга кайтып сөйләмәс сөйләвен. Туристлар арасында язылмаган шундый закон бар: походлардан тик матур истәлекләр генә алып кайтырга!

— Карагыз, каршы як тау итәгеннән чана өстерәгән алты болан килә. Хуҗалар кайта, ахры, — диде шулчак Фаягөл.

Күп тә узмады, чумнар янына, күп җәпле мөгезләрен айкап, кыңгырау шалтыратып, боланнар килеп туктады. Чанадан ике кеше төште. Иңнәрендә ипле генә ау мылтыклары, икесе дә елмаялар.

— Однако, бездә кунаклар бар икән. Однако, сезгә без бик шат, — дип, кул биреп күрешеп чыктылар.

Шәүкәт үз егетләрен дә хуҗалар белән бик тактичный булырга кисәтеп куйды.

— Хәзер чәй өлгертәбез, түрдән рәхим итегез, — дип, хуҗалар, якты йөз күрсәтеп, кунакларны беренче карашка шыксыз гына күренгән шалашларына дәштеләр. — Хөрмәтле кунакларга без бик шат, однако...

Чумның очында төтен чыгу өчен тишек бар. Кыл уртада сүнгән учак өстендә корымга, майга каткан казан. Учак тирәли җиргә йомшак тиреләр җәелгән. Кереп йоклау өчен махсус тиреләрдән тегелгән мех капчыклар да бар. Хуҗалар каядыр барып кына килгәннәр, ахры. Чөнки казан тулы ит. Зур-зур кабыргалар казан читенә дә чыкканнар. Шәүкәтнең егетләре арасында иреннәрен ялап-ялап куючылар да булды.

Фаягөл андый чакны салпы якка салам кыстыра белә. Йомшак тире өстенә кырын яткан хәлдә:

— Сезнең монда, хөрмәтле хуҗалар, хан сараеннан бер дә ким түгел икән, — дип куйды.

Хуҗалар мактауны килештерделәр. Өлкәнрәк күренгәне, учакка утын өсти төшеп:

— Ә нигә?! Дөньяда ике яшәмибез, — дип елмайды.

Кәрләләр, лилипутлар дип атау ямьсез сүз булыр. Әмма көләч йөзле бу ике кешенең икесе дә гажәеп кыска буйлылар. Толик Бакалин метр да сиксән. Шәүкәт үзе метр җитмеш биш. Ә Женя Шахтин метр да сиксән җиде сантиметр буйлы. Хуҗалар Женяның шулай озын булуыннан бераз шаяртып та алдылар.

— Мондый озын буйлы егеткә иң яхшысы боланнар көтү, однако. Көтүдән читкә аерылган боланнарны ерактан ук күреп алыр иде, — диештеләр.

Әмма Женя меланхолиягә бирелде, үз-үзенә бикләнде. Ярый әле Олег аңа Библия тоттырды. Женя аны бер минутка кулыннан төшерми.

Бу ике егетнең чәчләре дә кызыл, кашлары да, хәтта керфекләре дә кызыл. Беләкләрендәге йоннары да кызыл. «Болар икенче планета кешеләре түгел микән», — дип уйлап куярсың.

Үзләренә шулай җентекләп карауны тоеп:

— Негрлар кара, ә без кызыл. Бездә бит башка җимеш үсми. Туганнан алып үлгәнчегә кадәр гел кызыл мүк җиләге ашыйбыз. Шуңа күрә чәчләребез генә түгел, беләкләребезгә чыккан йоннар да кызыл, — дип, күз кысып елмаештылар.

Барыннан бигрәк Ләлә сәерсенде инде аларга. Атлаганда артка китмәсен өчен табанына тире кисәге каккан киң табанлы һәм бик ипле чаңгыларын киеп-киеп карады.

Әмма матур кешеләр болар. Аяз күк йөзедәй зәп-зәңгәр зур күзләре йөзләренә аеруча бер матурлык бирә. Йөзләреннән эчкерсезлек, нарасыйлык бәргән сыман. Битләренә карап алар әле яшь күренәләр, утыз-утыз биш тирәләре генә булыр. Кунакларга алар чыннан да бик шат. Йөзләреннән елмаю китми, нигә барып тотынырга, нинди кунакчыллык күрсәтергә белмиләр. Үзара һәр сүзләрендә озын сузык авазлар күп булган сәер телдә сөйләшәләр. Чак кына олырак күренгәне, күкрәгенә кат-кат сугып, үзен Сваамэ исемле булам, дип таныштырды. Икенчесе, бераз кыюсызрагы, Оймэн исемле икән. СССРда бик аз санлы саналган саами халкының уллары булып чыктылар хуҗалар. Икесе дә көтүчеләр. Бу чумнар аларның вакытлыча базалары. Ашамлыклар, башка кирәк-яраклар алырга кайтканнар. Ә боланнары моннан шактый еракта, мүк һәм лишайник күп булган тау итәгендәге болынлыкта утлыйлар икән. Шәүкәтнең:

— Ә Голая Поляна кая? — дигән соравына, «ул бит сәвсим икенче якта» дип кул гына селтәделәр.

Үз чиратында Шәүкәт тә:

— Без Казаннан, студентлар, кайберләребез Казан татарлары, — дип таныштырды.

— О-о, татарлар, татарлар. Ишеткәнебез бар, однако. Ә маңгайларыгыздагы ике җәпле мөгезләрегез кая? Аларны салып капчыкларыгызга яшердегезме? — дип, хуҗалар шаяртып алдылар. Күңеленда шулай шаянлык, юмор булмаса, бу киңлекләрдә ялгызлыктан акылың саегуы да бар шул...

Хуҗалар, беренче эшләре итеп, кунакларның барысына да берәр кружка хуш исле кайнар шулпа өләшеп чыктылар. Телеңне йотарлык тәмле шулпа. Күбесе бер мәлгә хәтта телсез калды.

— Хәзер бик тәмле чәй пешерәбез, — дип, учак өстенә корымга баткан чуен чәйнек астылар.

Күрешкәч-танышкач, кайнар ит шулпасыннан да авыз иткәч, Шәүкәт иптәшләренә, кузгала торыйк, дип ымлады. Аның кузгалырга ым кагуын күреп алган хуҗалар дерт итеп сискәнеп куйгандай булдылар. Кулларын әле баш өстенә, әле күкрәгенә куеп, әле як-якка җәеп, нык үпкәләүләрен белдерделәр. «Юк, юк, үзебездә төн кундырмый, иң симез болан ите белән сыйламый сезне аяк та атлатмыйбыз», — дип аркылы бастылар. Үзләре һаман эчкерсез елмаялар. Егетләрнең дә бик кузгаласылары килми.

— Хуҗаларның психологик халәтләрен аңлыйм мин, — дип куйды Фаягөл. — Ят кешеләр, ят йөзләр күрергә алар һәрчак мохтаҗдыр. Өемә шундый кунаклар килеп керсә, мин дә төн кундырмый җибәрмәгән булыр идем. Кая ашыгабыз соң ул хәтле. Әйтерием...

— Безнең Фаягөл дөрес сөйли! — дип куәтләделәр аны егетләр. Өстенә туш чыккан күл өстеннән ничә чакрымнар лыштыр-лыштыр атлап, барысы да ярыйсы арыган, кул-аяклары да нык чыланган иде.

Хуҗалар мул итеп ит тутырып тагын ике казан астылар. Олырак чумнан аз гына читтәрәк бүрәнәдән бурап салган складлары бар икән. Аннан да тәмле ризыклар, куертылган сөт, төрле җимешләрдән компот банкалары алып килделәр. Зур чумның бер почмагына калын итеп тиреләр җәеп чыктылар. Алар үзләрен беркадәр сәеррәк һәм хәтта серлерәк тоталар төсле. Әмма сәбәбен һич төшенерлек түгел. Ит пешеп чыккач, иң зур һәм иң тәмле кисәкне Ләләгә бирделәр. Мондый

игътибардан кызыкай чүт һушыннан китмәде. Ике күзе булачак җизнәсе Толя Бакалинда гына. Күр, янәсе, балдызыңны ничек олылыйлар!

Саргылт-зәңгәр телләрен ялт-йолт уйнатып, дәрт белән янган учак яктысында идәнгә җәйгән йомшак тиреләр өстенә кырын ятып сөяк кимергәндә, хуҗалар телендә «огненная вода», «огненная вода» дигән сүзләр дә ишетелеп киткәләде. Төньяк халыклары туксан алты градуслы спиртны шулай дип йөртәләр. «Их, шайтан алгыры, кунакларыбызны сыйларга «огненная вода»бызның юк чагы бит», — дип зарланышып сөйләшкәннәр икән алар. Шәүкәт тә, Толик Бакалин да аларның үзара сөйләшүен: «Менә сиңа кунаклар! Борын кычытканны басарга күчтәнәчкә «огненная вода»лары да юк», — дип әйтәләр төсле аңладылар. Нишләп булмасын ди аларның «огненная вода»лары. Шундый ерак юлга кем чыксын спиртсыз? Берәрсе кулын-аягын өшетсә, суга төшсә, температурасы күтәрелсә, поход шартларында аны нәрсә белән дәвалыйсың? Бердәнбер дәва — туксан алты градуслы спирт. Тыштан да сылыйсың, эчтән дә кыздырасың. Кичтән кәефсезрәк торган иптәшең иртәнгә җырлап уяна. Чаңгыга беренче булып баса. Шәүкәт белән Толикның капчыкларында аерым очраклар өчен күз карасы кебек саклаган берәр ярты литр чиста спирт. Аны институтта кулга төшерү бик җиңелләрдән түгел. Аны сиңа кем бирсен? Институтта чәче дә ак, йөзе дә ак, кашы да ак, хәтта керфекләре дә ап-ак, тик ике күзе генә кара карлыган бөртеге төсле кап-кара бер бик матур карт профессор Евгений Евгеньевич Петров эшли. Ректорның фәнни эшләр буенча урынбасары ул. Шушы сүзгә бөтен мәхәббәтләрен, тирән ихтирамнарын салып, институтта аны Евгений Евгеньевич дип түгел, ә Ген-ген Ген-генович дип йөртәләр. Аның кечерәк кенә эш бүлмәсендә һәрчак ут яна. Өстәлләрдә, шүрлекләрдә төрле пробиркалар, мензуркалар, спиртовкалар, пыяла банкаларда төрле-төрле препаратлар. Үзе кебек ачык йөзле хатыны Елизавета Петровна аның мәңгелек лаборанткасы иде бугай. Ген-ген Ген-геновичны институтта белмәгән кеше юк. Чөнки имтиханнарны өчлегә биреп стипендиясез калу алдында торган студентлар беренче эшләре итеп аңа йөгерәләр. Профессор Петровның шундый студентлар өчен махсус фонды булгандырмы? Аның ишеген шакучы студентны стипендиясез калдырмый. Берәр тәртипсезлек эшләп, ректор институттан куам дип янаган студент та Ген-ген Ген-генович янына йөгерә. Петров алып кала әлеге егетне.

Шәүкәт тә, Толик Бакалин да походка чыкканда юлга спирт сорап аның каршына киләләр. Үзенә фәнни тәҗрибәләр ясау өчен дип бирелгән фондтанмы икән профессор Петров походка китүчеләргә һәрчак икешәр шешә спирт биреп чыгара. Хәзер менә ничек кирәге чыгып куйды.

Төньяк халыкларында тәкъдим иткән әйберне алмый калу гадәте юк. Алмасалар, бүләктән йөз чөерү, яратмау була бит. Димәк, син бүләк бирүчене рәнҗеттең. Йомшак болан тиресе өстенә ике шешә спирт чыгарып куйгач та, хуҗалар «алмыйбыз» дип баш тартып маташтылар.

— О-о, «огненная вода»! Однако, яхшы әйбер, — дип канәгать булуларын гына белдерделәр.

Кунакларга бераз су кушып, үзләренә су кушып та тормыйча берәр рюмка өләшеп чыктылар. Сваамэ чум читендәге сандыкны актарып, аннан мех бүрек чыгарды. Аны кулында дер уйнатып, тиешле формага кертте. Боланнарның күкрәк авызындагы гына җылы һәм йомшак тиресеннән теккән бик матур бүрек иде бу. Сваамэ аны тотты да Ләлә башына кигертте. Ләлә, бераз аптырап калса да, бүрекне башыннан салырга ашыкмады.

— Абау-у, көнчелегемнән үлә-әм! — дип куйды Фаягөл. — Ләлә, сөен. Синең бәхетең чәчәк ата бит. Лотерея отышы бу! Гомердә бер була.

Бу матур бүрекне кызларның барысы да берәм-берәм киеп карадылар. Барысына да килешә. Затлы әйбер кемгә килешмәс! Ләләгә аеруча!

«Огненная вода»дан бераз авыз иткәч, аннары бик тәмләп кайнар чәй эчкәч, Сваамэ, тамагын кыра-кыра, төрепкәсенә тәмәке тутырды. Нидер әйтәсе, ниндидер сер чишәсе килә иде, ахры, аның. Шәүкәтне үзе белән саф һавага чыгарга дәште.

— Однако, бу араларда көннәр әйбәт тора әле, — дип куйды ул. — Кайчакларны бер җебетеп, бер туңдырып аптырата. Кинәттән каты туңдырып җибәрсә, боланнар боз катламын тишә-тишә тоякларын канатып бетерәләр.

Алар бер табаны сынык чана өстенә утырдылар. Сваамэ Шәүкәтнең иңбашына кулын салды.

— Син капитанмы, однако? — дип сорап куйды ул кинәттән.

— Капитан дип аталмый. Әйе, группаның җитәкчесе.

Сваамэ, тамагын кыра-кыра, төрепкәсен суырды.

— Саами халыклары Норвегиядә, Швециядә, Финляндиядә күпләп яши. Ә СССРда без ике меңгә якын гына. Оймэн СССРда яшәгән саами егетләре арасында иң яхшысы! — диде ул. — Йөгерсә, боланны куып җитә. Атса, куянның тик күзенә генә тидерә. О-о! Андый оста каюр бөтен Төньякта юк.

— Мин дә бик ошаттым аны, — дип килеште Шәүкәт, — бик булган, бик ипле егеткә охшаган. Елмаеп кына сөйләшә.

— Аңа өйләнергә, балалар үрчетергә кирәк. Ике мең генә саами халкы бик аз бит. Аңа тиздән утыз була. Ул һаман өйләнмәгән. Кандалакшага оленеводлар слетына баргач, аңа бик матур бер кыз

ярәштек. Зур туй ясап алырга булган идек. Оймэн, однако, яратмый ул кызны. Ошамый, ди. Нәрсә эшләргә?

— Һе, — дип куйды Шәүкәт.

Сваамэ, кулын як-якка җәеп:

— Ул бер күрүдә сезнең Ләләне ошатты. Минеке булса, ярты көтүемне бирәм, ди. Безнең Оймэн бик бай ул. Ике көтү тота. Берсендә ике йөз илле баш болан. Икенчесендә дә шул чама. Тик ул бик кыюсыз егет. Үзе бу турыда әйтә алмый, миннән үтенде. Калдыр безгә Ләләне! Март аенда Хельсинкида Халыкара ярминкә. Без анда ел саен үзебез эшкәрткән тиреләр белән катнашабыз. Оймэн әйтергә кушты, әгәр Ләлә калса, мин аны Хельсинкига алып барам, иң матур тунны алып киертәм, диде. Син аңа нинди җавап бирәсең?

— Однако, о-о, — дип сузды Шәүкәт үзе дә. — Алай тиз генә җавап бирердәй сорау куймадың бит, хөрмәтле Сваамэ... — Сваамэны үпкәләтмәс, рәнҗетмәс өчен алай да өстәп куйды: — Чум эчендә минем белән янәшә утырган егет — аның абыйсы. Кызга ул хуҗа. Аңа да әйтеп кара. Ләкин ул да уңай җавап бирмәс.

— Оймэн үзе дә шулай ди, бирмәсләр, ди. Юкса ул кызыгызны бик ошатты. Иң яхшы боланнарымны җигеп урлап качар идем, ди.

— Ләләбез бик яшь бит әле. Аңа 19 гына яшь. Икенче курста гына укый. Аңа укуын тәмамларга кирәк. Ә укуын тәмамлагач, бәлкем, направление белән бу якларга саами балаларын укытырга килер. Менә ул чакта...

Сынык табанлы нарта өстенә Бакалин да килеп утырды. Сүзнең ни турыда барганын ишетеп торган, ахры.

— Сваамэ, дөрес аңлый күрегез, мин ул кызны эти-әнисенә исән-имин кайтарып бирермен дип ышандырып алдым бу походка.

— Без дә аңлыйбыз да соң. Оймэн бик ошатты бит шул Ләләне. Учымда гына йөртермен. Кола ярыматавының королевасы ясармын, ди.

Сваамэ, бу турыда сүз шуның белән тәмам, монда булган монда калсын дигәндәй, төрепкәсен чана табанына какты.

— Әйдәгез, чумга кереп, ашыкмый гына тагын бер чәй эчеп алыйк, — дип эчкә чакырды.

Аннары чумның өстәгерәк өлешендәге кесәдән гөсләгә охшаш өч кыллы инструмент алып, аның кылларын чиертте. Саами телендә озын җыр башлады.

— Урманнарыбыз кош-кортка, күлләребез затлы балыкка бай, дип җырлыйм мин, — дип аңлатты Сваамэ. — Күл буендагы аучы йортында бик чибәр егет яши. Аның боланнары бик күп. Әмма кәләше юк. Күл өстенә һәр кичне тулы йөзе белән балкып ай калка. Егет айдан үзенә кәләш табышуда ярдәм сорый. Ай ышандыра, синдәй егеткә дә бер матур кәләш тапмасам, дип елмая. Егет менә бүген дә ай калыкканны көтә. Бәлкем, ай бүген үзе белән алып килер аңа дигән кәләшне. А-ай, айэ-айэ!..

* * *

Бу иртәне алар тәмам яктырып беткәнне көтмәскә, иртәрәк кузгалырга булдылар. Сваамэ, моннан Мончегорскига бик ерак әле, дип аңлатты. Алар чыннан да маршруттан шактый читкә тайпылганнар булып чыкты. Ераста болытлар арасыннан текә сыртлары күренеп киткән тау тезмәсе — Хибинның нәкъ үзе. Мончегорскига барып чыгу өчен аны аркылы кисәргә кирәк. Бу тирәләрдән генә кыен булачак. Сваамэ белән Оймэнның чумнарыннан унбиш чакрымнар өстәрәк перевал бар икән. Йомышлары төшкәндә, дару, патрон, тәмәке алырга алар Мончегорскига шушы перевал аша йөриләр.

— Апатит тавының хуҗасы кайчакларны бик холыксызлана, сак булыгыз, — дип кисәттеләр алар. — О-о, Апатит хуҗасы дуласа, менә шулай килеп дулый, — дип, кулларын бутап-бутап күрсәтте Оймэн. Ә нәрсәдән сак булырга икәнен әйтмәделәр. Хуҗалар кунакларына күтәрә алган кадәр болан ите, чәй, кофе, сөт банкалары бирделәр. Капчыкларында сукыр тычкан чемченерлек тә запаслары булмавын күргәннәрдер инде. Боланнарын җигеп, перевалга таба борылу чатына кадәр озатырга булдылар. Җылы, йомшак тирегә төреп, нарта түренә Ләләне утырттылар. Боланнарны: «һок! һок!» — дип куып бару өчен кулына озын гына шома колга тоттырдылар.

Аерылышкан чакта, алда торган кара чыршы урманына күрсәтеп:

— Тарлавык авызына чаклы бер көнлек юл. Урман эчендә без тамга салган балта эзләре булыр. Шулардан беркая да тайпылмагыз, — дип кисәттеләр.

Хуҗалар белән Ләлә дә бик җылы саубуллашты. Саубуллашмыйча! Шундый игътибардан соң! Хат язышып торырга Оймэнга адресын бирде.

— Оймэн, көтеп тор, киләсе елны, кышкы каникуллар чорында монда тагын киләм әле, однако, — дигән булды.

— Мин көтәрмен, — диде Оймэн да, кып-кызыл булып кызарып.

— Җүл-ләр син, Ләлә! Әгәр миңа шундый тәкъдим ясаган булсалармы, кызыкаем?! Мин берсүзсез калган булырыем, — диде Фаягөл. — Кола ярыматавының королевасы булырга теләмәдең инде, дивана кызый. Соңыннан үкенмәсәң ярый.

— Әйләнә-тирәңдә кыргый табигать. Кешеләрне, үзебезнең группа кызларын сагынудан мин монда бер атнадан егылып үләрмен, — диде Ләлә. Йөзендә бераз икеләнү, тегеләй итсәм дә ярамас, болай итсәм дә аптыраш дигән чалымнар чагылды. «Кола ярыматавының Королевасы булсаң да начар булмасые» дип тә вәсвәсәләнгәндер, бәлкем, яшь кешенең күңеле...

Урман куелыгына бик кыю кереп киткән чаңгычы эзен дә, чыршыларга балта белән суккан тамганы да бик тиз таптылар. Көннең ни арада узганы сизелмәде дә. Палатканы бу юлы, карны тәмам җиргә төшеп җиткәнче көрәп, аска калын итеп йомшак ылыслар түшәп, тигез аланлыкка куйдылар. Кичке аш әзерләүне Ромео белән Джульетта үз өсләренә алсалар да, Ольга янында гел Мөнәвәрә. Бер минут эшсез тора алмаган Габделбәр дә алар янында. Кулында балтасы уйнап тора, коры утынны тау өеме итеп чапкан. Тәмле кайнар аш ашап, кружкаларына өрә-өрә кофе дә эчкәч, палаткага кереп ятарга гына торганда, кинәттән генә төньяк балкышы балкыды. Сөйләп бирешле генә түгел, аның үзен күрергә кирәк. Күк гөмбәзен тулысы белән үз кочагына алып, тотынды уйнарга. Меңәр ваттлы миллион лампочкаларны берьюлы кабыздылар, диярсең. Алардан чыккан нурлар күзләрне чагылдыра. Барысы да палатка тирәсенә сибелделәр.

Хәтта Женя да:

— Шушы балкышны күрү өчен генә бирегә килү барысын аклый, — диде.

— Күрегез, күрегез әле, космостан килгән нейтроннар төркеме җир өслегенә ничек бәреләләр, — дип аңлатмак булды бу гажәеп күренешне белмәгән нәрсәсе булмаган эрудит Виктор. — Бу нурланышларны космостан килеп җир өслегенә бәрелгән нейтроннар лавасы тудыра.

— Ул хәтле, барын да беләм дигәч тә, мин барында бераз телеңне тыяр идең, Виктор, — дип, Фаягөл аңа каршы төште. — Төньяк балкышының серен аңлатсалар, географлар түгел, һәрхәлдә, без — физматлар аңлатырга тиеш. Ә менә мин авторитетно әйтәм: төньяк балкышының сере шушы көнгә кадәр төгәл генә ачылмаган.

Бәлкем, шулайдыр да. Әмма кемнәрдер күк йөзенә меңнәрчә вә меңнәрчә көчле прожекторлар чөйгән диярсең. Дөнья яп-якты. Балкыш уйнаганнан күзләр чагыла. Хәтта өскә кигән киемнәр дә серле тоела. Балкыш хәтта күңелгә дә тәэсир итә. Уйныйсы, йөгерәсе, шатланасы килә. Аның шушындый серле көчен Шәүкәт командасы да татыды. Шатланыштылар, биеделәр, җырладылар да, бер-берләрен кар өстендә дә тәгәрәттеләр. Тагын бер тапкыр чәй кайнатып эчтеләр. Йокларга таң алдыннан, балкыш сүрелгәч кенә яттылар.

Шәүкәт белән Бакалин гына элек йөргән походлары буенча яхшы беләләр: төньяк балкышы уйнаганнан соң, кинәттән генә һава бозыла, җил-давыл кузгала, ямьсез буран чыга. Бәлкем, мондый закончалык юктыр? Бу юлы һава бозылмас, буран чыкмас? Кирәге дә шуның хәтле генә.

— Гомердә бер кичергән мондый тәэсирләрдән соң, мин барыбер тиз генә йоклап китә алмыйм. Мич янында үзем кизүлек итәм, — диде Ләлә. — Төньяк балкышының сәер нурлары әле һаман да күзләремдә уйныйлар. Сөйләп бирә алмастай мизгел кичердек бит. Мин һаман да шул тәэсирләр диңгезендә йөзәм.

— Ай Алла. Андый теләгең бар икән, кем сиңа каршы килсен. Рәхәтләнеп кизүлек ит, — дип хупладылар барысы аның бу теләген. — Кара аны, йоклап китә күрмә.

— Никогда в жизни! Минем кем икәнне беләсез бит инде. Әйттемме — точка! Гранит! — дигән булды Ләлә.

— Эзләп, капшап утырма. Менә пүләннәрне аяк очына гына куям, — дип, Габделбәр палатка эченә ваклап тураган утын пүләннәре кертеп өйде.

Йокы капчыклары эчендә изрәп йоклаган туристлар Фаягөлнең: «Янабыз, янабыз!» — дигән тавышына уянып киттеләр.

Палатканың алгы өлешенә ут капкан. Ялкын телләре, уйнаклый-уйнаклый, палатканың түбәсенә менәргә маташа. Кичтән теленә остарып утырган Ләлә утырган җиреннән йоклап киткән, ахры. Дөрләп янган утын пүләне палатка чабуына төшкән.

Туристлар тышка сикерештеләр. Кар сибеп утны сүндерделәр. Беренче чиратта паниканы бетерергә кирәк иде — Габделбәр ике-өч җирдә учак тергезеп җибәрде. Иң сөенечлесе — барысы да исән. Киемсалымнары, ашау-эчү әйберләре дә исән. Палатканың гына алгы ягы бөтенләй янып беткән. Менә палаткасыз нишләргә? Алда үтәсе юллары байтак бит әле. Ләләгә каты бәрелүдән дә ни файда? Болай да эчендә чыкмаган җаны гына калган, дер калтырый. Әле дә ярый җизнәсе бар, аңа сыенган.

Фаягөл:

— Син, Кола ярыматавы королевасы!.. — дип нидер әйтмәкче иде дә, Толик, бармагын авызына китереп, «бәлкем, хәзергә кирәкмәс» дигән ым ясады.

Төньяк балкышы ялгызы гына балкымаган икән. Буран чыгып килә. Шәүкәт группасын кузгалырга ашыктыра башлады. Ә палатканы нишләтергә инде? Авыр йөк итеп күтәреп йөрткәнче, ташлап калдыру яхшырак булыр.

— Ышту сез! Палаткасыз соң без алда нишләрбез? — дип каршы төште Габделбәр. — Привалга туктаган җиребездә үк аска җәйгән тентны кисеп алам да, янган өлеше урынына тегәбез. Кичкә янәдән бер дигән үз палаткабыз булачак.

— Габделбәр, әле дә ярый арабызда син бар, — дип куйды Фаягөл. — Син миңа чынлап торып ошый башладың, егетем. Йөргән кызың бармы?

— Берүк, Фаягөл, миңа андый сүзләр сөйли күрмә, — диде Габделбәр. — Йә үзеңә гашыйк итәрсең.

— Булса соң! Синдәй егетләрне үземә гашыйк иттермәслек берәр дивана, кикиморамы әллә мин? Уң кулымны калтыратып, сул аягымны өстерәп атламыйм бит әлегә. Габделбәр, син миңа чынлап торып ошый башладың, кәбәм.

— Юк һәм юк! — дип кулын гына селекте Габделбәр. — Әйтмә дә, сөйләмә дә миңа бу турыда. Синең белән баш катырасым гына калганые.

— Абау-у-у! Үлә-ә-әм бит! Күрәсезме? — дип сузды Фаягөл. — Синең муеныңа барып асылынган кеше юк бит әле, тискәре! Әнием әйткәние аны, кызым, тиздән ахырзаман җитә, дип. Җитте дә, ахры. Егетләргә симпатияңне белдерергә дә ярамый. Шундук штыкка күтәрергә торалар. Ничек яшәргә инде хәзер? Прәме шушында, баскан җиремдә үлә-ә-әм!

* * *

Нәкъ Тукай әйткәнчә, кузгалганмы Каф тау арты җеннәре, диярсең. Төньяк балкышы сүнәргә дә өлгермәде, купты давыл, чыкты буран. Җилнең кай яктан килеп искәнен дә белешле түгел. Ике адымнан берни күрешле түгел. Барысы да битләренә ике күз өчен генә тишекләр тишелгән бумази битлекләр алып киделәр. Ком даласында, чүлдә дә бу кадәр булмас. Сине уртага алып бөтерелгән җил авызыңа, борын-колак тишекләреңә кадәр әллә нинди ком бөртекләре, вак таш кисәкләре китереп тутыра. Атламыйча да ярамый. Агачларга чапкан тамга эзеннән алар тарлавыкның нәкъ үзенә чыктылар. Ләкин аңа якын да килешле түгел. Урман эчендә, ышыкта ярый иде әле. Монда, ачыклыкта, җил бөтереп кенә калмый, аяктан ега. Бу хәлдә тарлавыкка керергәме әллә, бераз артка чигенеп, урман ышыгына палатка куеп, давылның басылганын көтәргәме? Шәүкәтнең егетләре, башта гомердә бер күргән төньяк балкышына сокланып, аннары палаткаларында чак кына янып үлми калып, үткән төнне керфек тә какмадылар. Хәзер менә байтак кына ара юл ярдылар. Иң яхшысы — палатка куеп, группаны ял иттерү. Монысы бәхәссез! Каршыларында бөтен хозурлыгы белән Хибин тавы. Шушы кырыс гүзәллеккә сокланганнар да, баскан җирләрендә бер мәлгә катып калган җаннардай, кара чыршылар берәм-берәмләп тә, кайбер урыннарда кулга-кул тотынышып-җитәкләшеп тә тауның итәгенә үк чыгып басканнар. Әмма тау битләре, аның текә сыртлары шыр ялангач. Җәен-кышын дигәндәй, вак тешле тырмалары белән җил тырмалап торган тау ярыкларында нинди үсемлек тамыр җибәрә алсын?

Виктор Ершов битлеген салып тауга ымлады.

— Атаклы Хибин менә шушы инде ул! Тышкы яктан гына шулай шыксыз. Аның эчендә нинди генә казылма байлыклар юк!

Ләлә Бәхтиярова да география факультеты студенткасы лабаса. Юкка гына укып йөрми булыр.

— Танылган минеролог, академик Александр Евгеньевич Ферсман, Хибин тауларын бик ныклап өйрәнеп, көлсу балчыкларны ашлау өчен бик тә кирәкле, фосфорга бик бай апатит минераль ашламасын тапкан. Биредә ул 1920–1930 елларда ук эшләгән. Соңыннан Хибин итәгендә шушы кирәкле ашламаны чыгаручылар шәһәре — Апатит каласы үсеп чыккан.

Ләлә тагын нидер өстәмәкче иде, аны Фаягөл бүлдерде:

— Ләлә, әйт яшерми генә, физик географияне ничәгә тапшырдың?

— Дүрткә, — диде Ләлә, бераз уңайсызланыбрак. — Беренче сорауга яхшы җавап бирдем. Икенчесендә бераз каушап калдым.

— Профессорың артык саран кыланган. Мин булсам, сиңа бишле куяр идем, — диде Фаягөл, башкаларга да мөрәҗәгать белән. — Хөрмәтле академик Ферсман әле егерменче елларда ук аркылыга-буйга узган Хибин каршында нәрсә катып калдыгыз? Ыргылдык тарлавыкка! Әле вакыт бар. Тарлавыкны бертында узабыз да, теге якка чыккач, бер ышык почмак табып, палатка куярбыз. Вперед, друзья! На бруствер! Революция зовет нас на бруствер!

Фаягөлнең мондый ялкынлы чыгышына кем битараф кала алсын? Үзе беренче булып тарлавык авызына таба атлады. Сафларны җуеп, башкалар да берәм-берәм аның артыннан иярделәр. Тарлавыкның зур бүрәнкә сыман авызы алдына баскан бер нәрсәне коточкыч көч белән убырдай йотып торуы турында алар белмиләр, башларына да китермәгәннәр иде. Атлантик океан киңлекләреннән күтәрелеп, көч алып искән җил, кичтән үк күтәрелгән давыл тарлавыкның суыру-йоту көчен уннарча-йөзләрчә арттырган мизгел иде ул. Тарлавык авызына алар нәкъ шул вакытта килеп бастылар. Аның суыру көченә каршылык күрсәтү мөмкин дә түгел иде.

Беренче булып Фаягөл артына утырды. Аның: «Ай-й!» — дип кычкырып куйганы ишетелде.

Башкалар да, тарлавык авызына килеп басканчы ук, тезгән домино ауган кебек, шып-шып ава башладылар. Тарлавыкның суыру көче шулхәтле көчле, аякта һич басып калышлы түгел. Чаңгыларда калу турында уйлыйсы да юк. Атлаган саен очлы ташлар. Алар арасында боз. Җил аларны шулай ук аяк баса алмаслык итеп шомарткан.

Шәүкәтнең командасы карышмак була, тотыныр нәрсә эзләмәкчеләр, тарлавык аларны һаман да эчкәрәк суыра бара. Аякка басарга тырышып карап, яңадан авып-егылып торучылар күп.

— Абау, терсәгем белән барып төштем.

— Чукынсын, штормовка ертылды.

— Йод-марля кайсыгызныкы янында гына? Тез капчыгым ярылды, — дигән авазлар ишетелеп кенә тора.

Тарлавыкның киңлеге илле-алтмыш метрларга, кай җирләрдә йөз-йөз илле метрларга җитә. Кай урыннарда колач җәеп киңәя, кай урыннарда хәвефле төскә кереп артык тарая. Тарайган төшләрдә, югарыда, баш очында, менә-менә өстеңә ишеләм дип, миллион тонна күләмле токымнары янап тора. Барысы да чаңгыларын салып аттылар. Кул җитемле якын булганнар, репшнурларын чишеп, бер-берләренә бәйләделәр. Икәү булганда тартышу ничек тә җиңелрәк.

Кире чыгу турында уйлыйсы да юк. Каршы бара алмаслык һава агымы аларны көчләп-көчләп дыңгычлап эчкә таба куа, суыра. Бу һава агымына йөзеңне куя алмыйсың. Әллә нинди очлы вак ташлар бәреп йөзеңне канатуы, күзеңне чыгаруы бар. Авызыңа чүпрәк япмый аны сулап та булмый. Шунда ук тыгылачаксың. Тарлавыкны аларга барыбер узарга кирәк иде. Аның да бер чиге бардыр бит. Карта буенча тарлавыкның киңлеге сигез-унике чакрымнар. Беркадәресен уздылар бит инде. Академик Ферсманның батырлыгы ихтирамга лаек, дип уйлап куйды Шәүкәт. Ләкин ул Хибин тауларын мондый климатик шартларда өйрәнмәгәндер шул.

Шулчак: «Ы-ы!» — дип ыңгырашкан тавыш ишетте ул. Кем дисә, Толик икән... Берничә генә адымнар читтә, сәеррәк позада егылып ята. Янында ике рюкзагы, артына таккан чаңгылары. Шәүкәт мүкәләп кенә Толик янына ашыкты. Толикның сул аягы табигый булмаганчарак як-якка бөгелгән. Шәүкәт аңа аягын ипләбрәк куярга булышмакчы булды. Толик сүзен дә әйтә алмаслык итеп тешләрен кыскан. Ыңгыраша гына. «Кагыла күрмә» дип ым кага.

Хәлнең артык кискен булуын аңлап, алар янына кайсы абына-сөртенә, кайсы ярым шуышып, Габделбәр, Валентин, Олег килеп җиттеләр.

Башка чакта шулхәтле чыдам, түземле Бакалин аягына кул да тидертми. Карамыйча да булмый. Олег биофак студенты. Врач ук булмаса да, кеше анатомиясен белә, өстән генә булса да өйрәнеп үткән. Башта ул билендәге үткен пычагы белән Толикның чалбар балагын бот төбенә кадәр ярып җибәрде. Шунсыз ни әйтсен?

— Мин рентген аппараты түгел, дустым, — диде ул, Толикны ыңгыраштырып булса да, бармакларын аның сул аягы буйлап йөгертеп чыккач. — Бак, син туганда ук күлмәк киеп тугансың, егетем. Аягың исән, сынмаган. Шуңа сөеник. Тайган гына, минемчә. Бот төбеннән үк каерылган. Түзәргә туры киләчәк. Ике атналар постельный режимнан башкача дәва юк.

Ул арада Толикның аягы күз алдында бүрәнә булып шешә башлады.

— Авыртуына түзәр хәл юк, дайте мне хоть лошадиную дозу анальгина, — дип елмаймакчы була әле үзе. — Мине монда калдырып торыгыз. Тарлавыктан чыгып, бер иплерәк җиргә палатка куегыз, урнашыгыз. Аннары менеп алырсыз. Бер дә көтмәгән җирдә таеп киттем бит...

— Толик, бәгърем, мин синең белән калам, — дип, Ләлә аны башыннан кочып алды. — Толик, ты только не знаешь, как я тебя сильно люблю. Я тебя даже Миле не отдам, пусть она мне родная сестра. Я тебя сама буду любить и никому не отдам. Ты мой, мой! Мой родной!

Шәүкәт капчыгыннан шешә чыгарды.

— Барча сызлауларны баса торган бердәнбер чара, Толик, сиңа шушы, — дип, кружкага голт-голт итеп спирт агызды.

Толик, башын күтәрә төшеп:

— Алай күп салма. Исертәсең, — диде. — Мин исерсәм... бик холыксыз.

— Күпме кирәген мин үзем беләм. Тот шушы килеш. Соңыннан кар кабып куярсың.

— Авыртуына һич түзәр хәлем юк. Файдасы тия, дисәләр, агу эчәргә дә әзер, — дип, Толик, чыраен сытып булса да, кружканы бушатты.

Толикның хәлен аңларга була. Аягы бүрәнә булып шешә. Тарлавыкның нык тарайган төше бу. Җил пуля тизлеге белән исә. Брезент штормовка, ике-өч кат свитер, мех күкрәкчәләр аша да үтеп, чәнечкеле-кытыршы бармаклары белән кабыргаларны капшый.

— Нишләргә соң? — дип, үз-үзенә мөрәҗәгать иткәндәй сорап куйды Шәүкәт. — Толикны монда калдырып тору турында сүз дә булырга мөмкин түгел.

Атлет гәүдәле Женя:

— Җайлап кына салыгыз минем җилкәгә! — диде. — Ничек тә алып төшеп җиткерәм мин аны.

— Синең дә аягыңны сындыруың җитмәгәние! — дип, барысы да каршы төштеләр.

Габделбәр Толик өстенә иелде:

— Толик, хәлең ничек?

Чак кына йокымсырап яткан Толик:

— Әйбәт, — дип елмайды. — Гармунчыгыз булса, чечетка биергә уйлап ятам.

Габделбәр капчыгыннан, палатканың янган өлешенә кушып тегәргә дигән тент кисәген чыгарды. Егетләргә ымлап:

— Шуңа салабыз да дүртебез дүрт почмагыннан алабыз, — диде.

— Дүртебезгә унбишәр кило. Безнең өчен чүп йөк бит ул!

Толик, ярыйсы исереп китсә дә, барысын аңлап, белеп ята.

— Транспортировканың бу ысулына мин категорически каршы, — диде ул. — Таянырга култык таягы бирсәгез, үз аягым белән төшәм.

Күп уйланып торыр ара калмады. Тиздән караңгы төшә башлар. Шул арада йокыга талган Бакалинны тентка салып дүрт башыннан дүртәү күтәрделәр.

Тарлавык кайбер урыннарда кискен борылышлар ясый. Шундый борылышларның берсендә Бакалинны күтәреп килүчеләрне Фаягөл каршы алды. Ул үзен бераз гаепле дә сизә төсле. Группаны үз артыннан тарлавыкка ул иярттe бит.

— Бу борылыштан тарлавык бетә. Анда янәдән тайга башлана, — диде. — Анда тынычрак, болай ук котырмый.

— Менә бу сүзең өчен рәхмәт, Фаягөл, — диештеләр егетләр беравыздан.

Тарлавыктан алданрак чыкканнар палатка куяр өчен урын да әзерләгәннәр, ут кабызып, чиләкләр дә асканнар.

Палатка куйганчы, кар өстенә чыршы ботаклары түшәп, Бакалинны шуның өстенә салып тордылар. Кулларыннан гөл тамган Габделбәр палатканың янган өлешенә камыт энәсе белән тентны тегеп тә чыкты. Палатка эчендә мич дөрләп китте. Чиләктә куе итеп сөт салган какао кайнап чыкты. Ольга һәркайсының кулына, Сваамэның күчтәнәче дип, бишәр прәнник өләште.

Инде бераз баш-күз алгач, бүген кичергәннәрне тагын бер тапкыр күңел түреннән уздыргач, җайлап кына палаткага кереп яттылар. Кемдер, безнең палатка артындагы чыршыда балта эзе бар, урманга чаңгы эзе керә, дип куйды. Тарлавык коридоры буйлап көчле агым булып аккан һава агымы, аннан чыккач, кинәттән генә көчсезләнеп кала. Әмма буран әле һаман котыра. Агачта балта, карда чаңгы эзе булгач, димәк, алда ниндидер торак пункт булырга тиеш бит.

— Буран басылмый торып мин беркемне дә беркая да җибәрмим, — диде Шәүкәт. — Толикны да кузгатырга ярамый...

— Минем капчыктагы болан ите әле безгә биш көн ашарга җитәчәк, — дип куйды Виктор. Бу аның иптәшләрен үзенчә тынычландыруы иде. Озаккарак туктый калсак, нәрсә ашарбыз дип борчылмагыз, янәсе. Аның рюкзагында ул хәтле ит юк, әлбәттә. Холкы шундый, бераз күпертеп сөйләргә булса, аңа бир.

— Сваамэ мине куяннарга капкын куярга өйрәтте. Бер карасаң, бик гади генә ысул, — дип, сүзгә Габделбәр кушылды. — Иртәгә берьюлы унны куям. Берсенә булса да эләкми калмаслар әле.

— Мин бүген барыбер йокламыйм, мич янында үзем кизү торам, — дип, Ләлә авызын ачкан иде дә, аңа барысы да йодрык янадылар. Ул шып булды.

Мичнең утын төне буена сакларга Валентин алынды. Аның әледән-әле:

— Толик, хәлең ничек? — дигән соравына Бакалин, ник ыңгырашып булса да:

— Түзәрлек, — дип куя иде.

* * *

Буранның басылырга һаман исәбе юк. Габделбәр таң беленә башлау белән ун җиргә капкын куеп чыкты. Әмма берсенә дә берни эләкмәгән. Кызларга алай да эш чыкты. Женя теп-тере көртлек тотып килде. Сәер генә көртлек. Качмый да, тыпырчынмый да.

— Безнең палатка артындагы аланга чыктым. Гөлдер-гөлдер килеп утыра ботакта. Якынрак килдем, качмый. Каршына барып бастым. Миндә гаме дә юк. Гөлдер-гөлдер килүен белә. Көч сынашырга көндәшен чакырды, ахры. Килдем дә кочагыма алдым, — дип аңлатты ул.

Көртлеге шундый зур, аннан бик тәмле шулпа пешерделәр.

Егетләр дәррәү кубып палатка белән янәшә генә ылыс ботакларыннан шалаш кордылар. Үзләре әйткәнчә, чумнары бик әйбәт чыкты аларның. Уртада кечерәк учак кабыздылар, шалашның түбәсендә төтен чыгарга тишек калдырдылар. Монда палаткадагы кысынлык түгел, аягыңны теләсә кайсы якка сузарга иркенлек бар. Учак дөрләгәч, шалаш эчендә җылы. Консерва банкасыннан ясаган сукыр лампа яктысында Женя Шахтин Библия укый. Төнлә кизү торып чыккан Валентин рәхәтләнеп йоклый. Габделбәр үз конструкциясе буенча Бакалинга таянып йөрергә култык таягы ясый. Аныңча, бик ипле чыгарга тиеш. Ә Виктор аңа бу култык таягы өчен кайту белән патент алырга тәкъдим итте.

— Әгәр дә син бу җайланмаңны производствога да җибәрсәң, син шунда ук мультимиллионер булачаксың, Габделбәр. Мин сиңа ярдәм итәчәкмен, — ди Виктор. Шундый хыялый, тормышны сөючән егет инде ул.

Шәүкәт төшке ашны ашаганда, тәлинкәсенә төшкән ылысларны чүпли-чүпли:

— Буран һаман басылмый. Мондый буранда безне эзләргә дә чыкмаслар. Югыйсә бүген унөченче төнебезне куначакбыз, — диде. — Толикның да аягындагы шеше кайтмый... Әллә группаны икегә бүлик микән? Берәүләребез Толик белән кала... Икенчеләребез...

— Дүртенче көнен дулый бит инде. Бәлкем, иртәгә басылыр, — диде Олег. — Тамак тук, өстебез бөтен. Студентка тагын нәрсә кирәк? — дип, сырган йокы капчыгы эченә керә башлады.

Тәмле аштан, баллы чәйдән соң, чаңгыларга басып, Фаягөл барысын да әйләнә-тирәне өйрәнеп, әйләнеп килергә чакырды.

Беренче булып Виктор:

— Яхшы хуҗа мондый көнне урамга этен дә куып чыгармый. Мин лутче йокы капчыгыма чумып берәр тәмле төш күрәм, — диде.

Аны башкалар да хупладылар.

— Хәчтерүшләр сез! Чын мәгънәсендә йокы чүлмәкләре! — дип сукранып, Фаягөл үзе дә чаңгыларын чиште.

* * *

Янә яктырып килә. Фаягөлнең транзисторының батареялары утырганмы? Ул аны кырт-кырт кабызып карый. Әмма тавышы юк. Радиоалгычы кабынмагач, Фаягөл үзе:

— Нас утро встречает с прохладой! — дип җырлап куйды. — Бала чагымнан ук шушы җырны яратам.

— Бу иртә безне кояш балкытып каршыласын иде инде, — диде аз сүзле Мөнәвәрә. — Көннәр ничәнче тәүлек кайнанасына үпкәләгән килен кебек тора. Ачылырга да бик вакыт.

Тышта шыгыр-шыгыр кар шыгырдаган аваз ишетелде. Барысы да сагайдылар. Кем булыр бу? Тайгадан аю-мазар чыкмагандыр бит? Барысы да сискәнешеп, яткан җирләреннән торып утырдылар. Тыштан:

— Khм, khм! Бу хан сараеның хуҗалары кем? — дигән ягымлы тавыш килде.

Икенче берәү:

— Мөмкинме? Борчып йөрүебез өчен без адашкан юлчыларны гафу итәрсез, — дип палатка итәген күтәрде.

Көтмәгәндә, өмет итмәгәндә дигәндәй, кинәттән генә пәйда булган бу кешеләрнең тавышын ишетеп барысы да сагаеп калдылар. Тайгада, бигрәк тә чик буенда, кем йөрмәс?

Ике арада туган киеренкелекне бетерү максаты белән, Виктор беренче булып:

— Яхшы ният белән булсагыз, шалашка рәхим итегез.

— Әгәр инде безне, чакырылмаган кунакларны, ипи-тоз, якты чырай, якты йөз белән каршы алырга теләсәгез, үзегез монда чыгыгыз, — диде калын тавышлысы.

Аларның палатка ишеген шакучылар бандитларга, чик бозучыларга, карак-угрыларга да охшамаганнар. Өсләрендә җылы, ипле штормовкалар. Штормовкалары шәмәхә, ә капюшоннары сап-сары. Ерактан ук күренеп торсын өчендер инде. Мондый башлыкны хәтта тайга эчендә дә ерактан ук күреп була. Икесенең дә иңбашларында түтәләре ялтырап торган җиңел винтовкалар, биллә рендә патронташлар. Икесе дә куе кара сакаллы. Керфекләренә кар утырган.

Виктор Ершов — чын артист. Менә хәзер дә, ике кулын нәкъ Ленин кебек ике култык астына кыстырып, Женя Шахтинга ымлады:

— Будущий мастер спорта, понимаете... э-эм, э-эм... — дип, уң кулын маңгаена куйды. Уйлана, янәсе.

— По уничтожению горячих картофельных пирожков! — диде Фаягөл.

Учак янына чыгып басканнар барысы да көлеп җибәрделәр.

— Геологлар без, — диде кунакларның олырак гәүдәлесе. — «Северзолото» трестыннан. Моннан ике чакрымнар өстәрәк шурфлар тишеп, шартлаткычлар куйган идек. Давыл купкач, шартлату эшләрен калдырып торырга туры килде. Менә шуларны тикшерергә менеп барышыбыз. Палаткагызны күрдек тә, күреп, танышып китик дидек.

Үзләрен геологлар дип таныткан әфәнделәрнең буйга кечерәге, кап-кара сакалын ак төкләр басканы:

— Кышкы каникуллар чорында туристик походка чыккан студентлар икәнегезне палаткагызга күз салу белән төшендек, — диде. — Проблемалары юкмы дип сугылдык без. Чөнки палаткагызны ашыгычлык белән, бик ипсез җиргә куйгансыз. Агачларга балта чапкан тамга белән төшсәгез, моннан чакрым ярымнарда бер дигән иркен һәм коры аучылар йорты бар. Кайчакларны анда хәтта без дә кереп кунабыз.

Геологларның олырак буйлысы учактан күмер алып төрепкәсен кабызды. Сафлыгы, чисталыгы мең процент булган тайга һавасына үзенчә бер әчкелтем, бу тарафларда кеше дигән зат баруын раслый торган тәмле ис таралды. Аны барысы яратып суладылар, хәтта тәмәке төтененә түзмәүчеләр дә.

Фаягөл, сул кул бармагын ияк астына куеп:

— Проблемабыз безнең муеннан, — дип, әлеге ир алдына килеп басты. — Палаткада авыру иптәшебез ята... Палатканы да шуңа бик ашыгыч куйдык.

— Кай җире? Күптәнме авыру? Ангинамы? — диде авызына төрепкә капкан геолог.

— Ангина гына булса икән!.. — диештеләр барысы да.

Виктор, янә Ленин кыяфәтенә басып, башындагы калфагын төшеребрәк киеп:

— Ангинаны без аны — пролетариатның сыйнфый дошманын — биш минутта дәвалыйбыз, — дип куйды.

— Иптәшебез аягына баса алмый. Нык ыңгыраша, — диештеләр Шәүкәт егетләре. — Тайдырды, ахры...

Төрепкәле геолог иптәшенә ымлады.

— Юрий Петрович безнең заслуженный врач.

— Миша, алай ук димә инде. Мәскәү медицина институтының дүрт курсын гына тәмамладым, — дип, Юрий Петрович дүрт бармагын күрсәтте. — Аннары — Магадан. Дөрес, ун ел практика миңа күп нәрсә бирде. Ләкин мин барыбер дипломлы врач түгел. Шулай да ярдәмгә һәрчак әзер.

— Юрий Петрович, ул турыда сөйләп торыр чакмы? — дип куйды геологның өлкәнрәге.

Юрий Петрович иңбашындагы винтовкасын агач ботагына элде. Чаңгысын, калын штормовкасын, җылы тире бияләйләрен салды. Мүкәләп палатка эченә кереп китте.

— Берәү булса... берәү булса, түзмәс иде, — дип кабатлады ул, Толик Бакалин янынан чыккач. — Егетебез түземле дә җан икән. Аның янбаш сөяге урынынан чыккан. Аны утырту өчен җиһазландырылган операция өстәле кирәк. Авыруны урынынан кузгатырга ярамый, Михаил. Мин аңа сызлауны бераз баса торган ике төймә бирдем. Башкача ярдәм итә алмыйм. Операция өстәле кирәк.

— Ул чакта болай итәбез, — диде геологларның Михаил исемлесе. Ул бик тәвәккәл кеше күренә. — Юрий Петрович, авыру янында син, сиңа ярдәмгә берәр кыз, учакта утны сакларга ике егет калдырабыз. Калган иптәшләрне мин үзем белән ияртәм. Моннан биш чакрымнар гына аста безнең база. Шунда төшәбез. Төшү белән вертолет җибәрербез. Пойдетмы?

— Пойдет кынамы?! — диде Фаягөл.

— Ул чакта кузгалдык!

Олег белән Ольга аларга каршы бастылар. Алар чәй өлгерткәннәр.

— Берәр кружка кайнар чәебезне эчми сезне беркая да җибәрмибез, — диделәр. — Юлыгызга аркылы ятабыз.

— Тәкъдим эшлекле! — дип, Михаил кулларын як-якка җәйде. — Чәйдән дә олы булып булмас. Безнең дә тамак кипкән иде. Әйдәгез, тәмләп бер чәй эчик алайса.

Учак янында Ләлә Бәхтиярова, геолог Михаилга елышып утырып:

— Сез чыннан да алтын табучылармы? — дип сорады. — Кесәгездә алтыннарыгыз бармы? Кулга тотып, тешкә тидереп карарга буламы?

— Без промышленность максатларында файдаланырлык тау токымнарын эзлибез, — диде Михаил. — Эшчеләребез арасында алай да самородоклар табучылар да бар. Базага төшкәч, тешкә тидереп карый аласыз. Ләкин алтын — каһәрле металл. Аннан ерак торуың яхшы. Самородоклар табучылар да аны тизрәк дәүләткә тапшырырга ашыгалар. Синең кесәңдәге самородоклар иптәшләреңнең күңелендә усал көнчелек, котырган нәфесләр уята.

— Тарих тарафыннан күп тапкырлар расланган факт! — дип куйды Виктор.

Ләлә шундыйрак инде. Балалыгы, наивлыгы йөзенә язылган.

— Юрий Петрович ни өчен дүрт курс кына укыды? Мәскәүнең атаклы медицина институтына керү аңа җиңел булмагандыр? — дип сорарга да кыюлыгы җитте.

Юрий Петрович:

— 58-я статья, часть третья, милая моя! — дип үзе җавап бирде. — Совет властен таратырга маташуым өчен. Студентлар кичәсендә В.Маяковскийның тыелган ике шигырен укыганыем. Шалт, Мөхәммәтҗан, ун ел Магадан лагерьлары. Мин ишәк түгел, дип хет башыңны ташка ор. Ләкин... үкенмим. Ун ел эчендә нинди зур практика алдым. Магадан лагерьлары минем өчен Академия булды.

— Күпме кешене үлемнән коткардым, диген, — дип, Михаил аның аркасыннан кочып алды.

* * *

Геологларның базасы һәр ягы шыксыз тау сыртлары белән чорнап алынган кечерәк кенә инеш яткан бер үзәнлеккә урнашкан. Бер-берсеннән күп булса унбиш-егерме адымнар гына читтәрәк чыршы бүрәнәләрдән бурап салган алты-җиде йорт күренә. Түбәләре калай. Геологларның радиостанцияләре, үз электр станцияләре бар. Тигез мәйданчыкта өсте шифер белән ябулы ангар, читтәрәк вертолет тора.

База халкы студентларны күтәреп кенә алмады. Аларны бирегә алып төшкән геолог Михаил Сергеевич шунда ук вертолетчылар янына чапты. Күп тә узмады, вертолет пыр-пыр килеп һавага күтәрелде. Студентлар килгән якка юнәлеш алып күздән югалды.

— Озаттым вертолетны. Ярты сәгатьтән анда булачак, — дип килде Михаил Сергеевич.

Озак та үтмәде, базага янып-пешеп Габделбәр белән Валентин да килеп җиттеләр. Аркаларындагы рюкзаклары үзләреннән зуррак. Алар Бакалин янында учакта ут сакларга калганнар иде...

— Юрий Петрович Бакалин белән Ләләне Мончегорскига алып китте. Аларны озаткач, палатканы, калган савыт-сабаны җыйдык та сезнең эздән үк монда төштек, — дип сөйләделәр.

Авиаторлар бер йортта, геологлар икенче, шартлатучылар, механизатор-бульдозеристлар, ялланып эшләүче гади эшчеләр — һәркайсы үз өйләрендә торалар икән. Студентларны — кадерле кунакларны — барысы үз йортларында туктарга чакыралар. Прәме аптыраш. Берсенә ризалык биреп, икенчесенә кермәсәң, хуҗаларны үпкәләтүең дә бар. Шәүкәт, мөмкин булса, кызларына аерым йорт бирүләрен үтенде. Барысын сөендергәне мунча булды. Геологлар мунчаны синең иң югары таләпләреңне дә тулысы белән канәгатьләндерерлек итеп салганнар. Ул субайлар өстендә утыра. Аста бульдозер белән уеп куйган бассейн. Арада моржлар булса, кайнар ләүкәдән төшеп, бассейнга чумарга була. Карап торсаң, шундук күзгә чагыла, геологлар монда нигезне ашыгычлык белән генә түгел, ә бик төпле, нык итеп корганнар. Бу төбәктә байтакка төпләнергә ниятлиләр, күрәсең.

Камырны да үзләрендә басалар, ипине дә үзләрендә пешерәләр. Фаягөл белән Мөнәвәрә хуҗаларның пекарняларын карап, бик килештереп чыктылар.

— Әнә теге баштагы, тәрәзәләре бу якка караган өйдә Батя белән Казбек торалар. Егетләреңне шул йортка урнаштыр. Шулай әйбәтрәк булыр, — дип киңәш итте Шәүкәткә геолог Михаил Сергеевич.

Геологлар колониясендә утыз-кырыклап кына кеше булыр. Базаның начальнигы әлеге Михаил Сергеевич. Ә власть Батя кулында шикелле. Һәркем авызында еш кына аның исеме. Колония егетләренә әле теге, әле бу эшне башкарырга күрсәтмәләрне күбрәк ул бирә. Батя уттай янып торган кара күзле, кара сакаллы, киң җилкәле, таза гәүдәле, йөзенә бер багу белән үзенә карата ихтирам хисе уята торган килеш-килбәтле, яше иллеләрдән күп өстә булган бер агай. Барысы да аңа ихтирам белән «Батя» дип дәшкәнлектән, ул үзе дә колониядә барысына «сынок» дип дәшә, күрсәтмәләр бирә, кирәксә, орышып та ала.

База начальнигы Михаил Сергеевич Шәүкәткә егетләре белән Батя биләгән өйдә туктарга киңәш итте.

— Алар Казбек белән икәү генә торалар. Казбек — безнең топограф. Ниндидер сызымнар артыннан Мончегорскига китте. Бүген кайтырга тиеш. Өйләре иркен аларның, урын барыгызга да җитәр.

Шәүкәтне, аның егетләрен Батя якты йөз белән каршы алды.

— Тартынмагыз! Түрдән узыгыз. Үз өегездәге кебек булыгыз, улларым, — диде ул, кара сакалын як-якка сыпырып.

Эчкә кергәч, өй эче тагын да иркенрәк тоелды. Уртада тимер мич гөрли. Бер як стенада ике винчестер, икенчесендә җиде кыллы гитара.

— О-о, гитара! — диде Женя Шахтин. — Кем уйный?

— Казбек. Бүген кайтырга тиеш.

Женя кара чехолдан үз гитарасын чыгарды.

— Күтәреп йөрергә авыр нәрсә түгел дип походка алганыем да, менә кылларын бич өздереп бетердем, — диде. — Бик яраткан гитарам иде, белмим инде, рәтләп булырмы?

— Әниең юлга тыккан пирожкилардан, кыздырган тавыктан башласаң, Женя, синең бу походта югалткан нәрсәләрең күп булды инде, — дип сүзгә ачы телле Виктор кушылды. — Аның каравы, Женя, походка чыкканда маменькин сынок идең. Килешәсеңме? Хәзер бер дигән егет булдың. Синең белән хәзер бер дә икеләнмичә космоска очарга була. Без хәзер синең белән Марс планетасына барып төшсәк тә югалып калмабыз. Син танымаслык үзгәрдең, Женя! Гордись этим!

— Скажешь тоже, — дип куйды Женя, җиңелчә елмаеп. Соңгы вакытта ул чыннан да бик җитдиләнде. «Моны сезгә Женя Шахтин әйтә!» дип күкрәгенә дә дөп-дөп сукмый. — Гитарагызны чиертеп карарга ярыймы?

Батя стенага ымлады:

— Пожалысты, сынок!

Женя, гитараны кулына алу белән, «Бродяга Байкал переходит» дигән җырны виртуоз осталык белән чиертеп алды.

— О-о, сынок, син чын маэстро! — диде Батя.

Батя, сөйләвенә караганда, рус кешесе түгел. Аның сөйләвендә Балтыйк буе, литва, латыш кешесе сөйләме чалымнары чагыла. Нинди хезмәтләре өчендер геологлар колониясенең барча кешесе аны нык ихтирам итә. Хәер, ихтирам ителмәгән затка кем инде Батя дип дәшсен? Батя Ригада зур төзелеш начальнигы булган. Аны «партиягә каршы эшчәнлектә» гаепләгәннәр. Чөнки ул Прибалтика республикаларын артык руслаштыруга, бу республика халыкларының милли йөзләрен югалта баруына,

партконференция трибунасыннан торып каршы чыккан. «Эшчәнлеге» КПССка ни дәрәҗәдә зыян китергәндер, әмма Батя ун еллар чамасы Магадан лагерьлары шулпасын шупырган...

База өстендә вертолет пыр-пыр килгәне ишетелде.

— Мөгаен, Казбек кайткандыр, — диде Батя, плитә өстенә кайнарга чәйнек куйды.

Мончегорскидан Юрий Петрович, Ләлә һәм Казбек кайтып төштеләр. Казбек — эре сөякле булса да, җыйнак, җиңел гәүдәле, сул күзенә кара лента бәйләгән, яшь кенә чибәр егет. Сул күзендәге кара лента да аңа пират төсе бирми, аның тумыштан чибәр йөзен ямьсезләми. Башта ул, һәркайсын күптән күреп белгән төсле:

— О-о, бездә кунаклар бар икән! — дип, егетләрнең барысы белән дә күрешеп чыкты. — Батя! Безнең версия буенча шурфлар салган теге ике култыкта алтын запаслары бай булып чыктылар тәки, — диде ул. — Безнең фикер җиңде!

— Кулагин килештемени? — диде Батя.

— Килешми кая барсын? Лаборатория ясаган анализларга каршы барудан кемгә файда? Ул каньоннарга экскаваторлар китереп куй да, бүген үк алтынын таба башларга була.

Шәүкәткә, аның егетләренә ымлап:

— Егетегез белән горурлана аласыз, — диде Юрий Петрович. — Чын мәгънәсендә бик түземле егет икән. Хәтта хирургларның да исләре китте. Авыруга гомуми наркоз бирергә алар базмадылар. Оча сөяге бит. Әллә утырып бетә, әллә юк. Авыру йоклаган хәлдә булса, каян беләсең? Өлешчә наркоз белән генә егетне шактый азапларга туры килде. Әмма хәзер бары да артта инде. Оча сөяге дөрес утырган. Егетегезнең кәефе яхшы. Барыгызга да сәлам тапшырырга кушты. Ләкин аны атна-ун көнсез урыныннан кузгатырга ярамас. Таеп, абынып-мазар китсә, янә чыгуы бар. Сеңерләрнең тәмам ныгып җитүен көтәргә кирәк. Әлегә ул гипста.

— Мин Толик янында калмакчы идем. Аларның баш хирургы бигрәк усал кеше. «Ходите тут под ногами!» — дип, мине орышып ташлады. Миңа да сезнең янга кайтырга кушты, — диде Ләлә, бик уңайсызланып кына.

— Бик әйбәт булган, кызым, — диде Батя, Ләләгә чәйнектән кайнар чәй агызды. — Сез безгә артык җан түгел, ә кадерле кунагыбыз. Шулаймы, Казбек улым? Ә шикәрне сиңа, кызым, ничә кашык салыйм?

— Батя, нәкъ өстенә бастырып, нәкъ минем фикерне әйттегез. Ләлә кебек чибәр кызлар — Кола ярыматавының бизәге! Андыйлар бүтән юк. Бәлкем, алып та калырбыз әле. Шулай бит, Ләлә?

— Калсам, әнием мине үтерәчәк, — диде ул, балаларча беркатлылык белән. — Кола ярымутравының королевасы булырга миңа бер тапкыр тәкъдим ясаганнарые инде...

— Шулаймыни?!

— Ә менә яңадан андый тәкъдимне без ясасак? Карышмассың бит?

— Белмим-м, — диде Ләлә. — Әниемнән башка... Толик та юк...

* * *

Фаягөл нәкъ үзе теләгән мохиткә эләкте. Геологлар базасында аның кереп чыкмаган өе, танышмаган кешесе калмады. Аның исеме дә биредә яшәүчеләрнең барысының да телендә. Ә кичен ул, кичке чәй янында:

— Телисезме, иртәгә барыгызны да татар токмачы белән сыйлыйм? — дип сорады.

Күбесе аны белми икән.

— Русча домашняя лапша була ул, — дип аңлатты.

— О-о, домашняя лапша! Безнең аны инде бер гасыр татып караганыбыз юк. Кәбестә ашы да борщ, кәбестә ашы да борщ.

— Әгәр сарык ите, бәрәңге, суган, борычыгыз булса, без сезне өчпочмак белән сыйлар идек, — диде Мөнәвәрә.

— Өчпочмакның да нәрсә икәнен белмибез. Әмма сезнең кулдан елан угын да ашарга әзер без, — дип, колония кешеләре бердәм кул чаптылар.

Казан студентлары хуҗалар өчен үзешчәннәр концерты оештырырга булдылар. Барып чыгармы дип, башта бик нык дулкынланганнар иде. Чынлап-чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга, диләр. Бик күңелле узды концертлары. Виктор Ершов сәхнәгә ике тапкыр чыгып Александр Блок, Владимир Маяковский шигырьләрен сөйләп керде. Женя Шахтин гитарада романслар башкарды. Валентин мускулларын уйнатып ике потлы гер күтәрде. Алкышларның иң күбесен Фаягөл җыйды. Аны сәхнәгә кат-кат чакырып җырлаттылар. Геологларның үзләрендә дә талантлар җитәрлек икән. Матур тенор, баритон белән җырлаучылар да, гитарада уйнаучылар да, чечетка биючеләр дә булды. Аннары танцылар башланды. Ирләр күп, кызлар санаулы гына. Алар белән биергә теләүчеләр чиратка басып көттеләр. Олегның хатыны Ольга да бу кичтә иренең кулына бик сирәк эләкте.

Көтмәгәндә генә студентларның килеп чыгуы геологлар колониясе тормышын бөтенләй җанландырып җибәрде. Ир-атларның күбесе берәр ел пәке тидермәгән сакалларын кырып ташлаганнар.

Концертка ап-ак күлмәкләр, матур костюмнар киеп килгәннәр. Батяны да танырлык түгел. Өстендә шакмаклы матур күлмәк, зәңгәрсу төстәге бостон костюм. Сакалын кайчы белән кискәләп матур итеп кыскарткан. «Кызым, кызым!» дип кенә иркәләп, бу кичтә ул Ләләне бер минутка да кулыннан ычкындырмаска тырышты.

Фаягөлгә егетләр запискаларны яудырдылар гына. Барысы да саф йөрәген тәкъдим итә, якыннан танышырга телиләр. Шәүкәт еш-еш сәгатенә карап ала. Кичәнең әлегә очы да күренми. Аларга иртәгә кузгалырга, юлга чыгарга да вакыт.

— Шәүкәт, мин сезне аңлыйм. Әмма өч кич тә кунмый, бездә кунак булмый, мин сезне беркая да җибәрмим, — диде аның иңбашына кулын салып база начальнигы Михаил Сергеевич Кравцов. — Кичә әнә ничек күңелле уза бит. Сезнекеләр дә, безнекеләр дә рәхәтләнеп бер ял итсеннәр. Сезнең бездә кунак булуыгыз безнең егетләр өчен гомердә онытылмас матур бер хатирә булып калачак. Бу мизгел алар өчен озаккарак сузылсын иде. Беләсең, булыр, безнең бит биредә очын һичкайчан таба алмастай чуалган, ватылып челпәрәмә килгән язмышлы контингент.

— Безне инде эзләргә чыккан булулары да мөмкин, — диде Шәүкәт. — Беренче чиратта шул нәрсә борчый. Чөнки без маршруттан бераз читкә тайпылып, болай да өч-дүрт көнгә соңладык.

— Э-э, Шәүкәт! Шул да булдымы проблема! — диде Кравцов.

Алар, шундук радиостанциягә кереп, Мончегорскиның «Туристлар штабы»на үзләренең исән-имин булулары турында радиограмма биреп чыктылар. Шәүкәт иркен сулап куйды. Егетләренең, кызларының мондый кунакчыл кешеләр арасында тагын ике-өч көнләп кунак булуына ул да каршы түгел. Җитмәсә, геологлар мунчаны да аларның иртән торышларына ук өлгертеп куялар. Габделбәр белән Валентин мунчага иртән бер, кичке якта тагын бер барып чабынып киләләр. Кыскасы, мондый эчкерсез игътибарны, саф кунакчыллыкны тагын кайчан, кемнәр тарафыннан татуың, күрүең мөмкин?!

Инде кичәдән кайтып, чәй эчеп, урыннарга сузылгач, Батя җайга гына:

— Инде кешеләрдән дә бик бизелгән, җәннәтнең нәкъ үзедәй тормыш ышандырсалар да, материкта барыбер оя корып булмас төсле, — дип сөйләп китте. — Бер мин генә шулай уйласам икән! Егетләребезнең барысы да шулай уйлыйлар бит. Араларыннан ике-өч егетебез материкка китеп оя корырга омтылып та караганнар иде... Ике-өч ай дигәндә барысын ташлап, янә үзебезнең колониягә әйләнеп кайттылар. Чөнки барысы да, нәкъ минем төсле, совет строена, бөтен кешелек җәмгыятенә тирән үпкәле алар. Барысы да нахакка хөкем ителеп, җимерелгән язмышка дучар егетләр.

— Ничек инде барысы да? — дип гаҗәпсенеп сорап куйды Шәүкәт.

— Гамәлдәге строй үз кешеләренең бертөсле галстук, бертөрле үк күлмәк, костюм, пәлтә киеп йөрүен тели. Башкачарак фикер йөртү турында хәтта сүз дә булырга тиеш түгел. Шуңа да карамастан бөтенләй башкача фикер йөртүчеләр дә җитәрлек. «Инакомыслие» дип атала ул. Гамәлдәге строй кушканча гел бертөсле генә уйлыйсы урынга, кайбер инакомыслящий үҗәтләр «инакомыслие» белән шөгыльләнәләр. Инакомыслиене гамәлдәге строй җинаятькә саный. Аның өчен җәзалары да конкрет: позор белән чит илгә куу, күп сорап тормыйча юләрләр йортына ябу. Иң иплесе, андыйларны иң арзанлы эшче көчләргә әйләндереп, Урал артына тайга кисәргә, Ерак Көнчыгыш шахталарына күмер чабарга озату. База начальнигым Михаил Сергеевич Кравцовтан кала безнең колониядәгеләр барысы да сәяси статьялар, ягъни инакомыслие өчен утырып чыккан егетләр, — дип дәвам итте Батя.

— Казбек тамы?!

— Казбек кына ничек искәрмә булсын? Аның тормыш юлы аеруча сикәлтәле. Ул политкаторжан улы. 1957 елда аның әтисен 50 нче статья белән хөкем итәләр. Малай ятимлектә үсә. Алай да урта мәктәпне алтын медальгә тәмамлый. МГУның геология факультетына керә. Студентлар катламы гомер-гомергә гамәлдәге стройга каршы оппозициядә булганнар. Мисалларны күп китерергә булыр иде. Үзләре яшәгән җәмгыять тәнендәге пычрак тапларны беренчеләрдән булып алар — студентлар күреп алалар бит. Казбек белән дә шулай булгандыр. Алдынгырак карашлы студентларны туплап, алар «Чын коммунистлар партиясе» төзиләр. Партияләренең уставын, программасын раслыйлар. Партия кассасын булдыру йөзеннән, әле ВКП(б) эшчәнлегендә үк киң файдалануда булган экспроприация элементын да гамәлдә калдыралар. Алар аны программаларында «Байларга ясак салу» исемендә калдырганнар. Ә чынында исә, дәүләтне алдап, халыкны талап баючыларны исәпләп чыгарып, кычкыртып талый башлаганнар. Легендар Камо да партия кассасын шул рәвешчәрәк баеткан бит. Әмма аларның берсе дә: «Каравыл, талыйлар!» — дип кычкырмаган. Судка да мөрәҗәгать итмәгәннәр. Беркөнне шулай ачылып китеп Казбек үзе сөйләде. Юкса ул — бик аз сүзле егет. «Чын коммунистлар партиясенең» сугышчан группасыннан дүрт егет чит илләрдән кайтарткан кыйммәтле туннар, паласлар, аяк киемнәрен бушата торган склад директорын исәпләп чыгарганнар, аның каршына барганнар. Мондый җирдә утырган директор жулик булмыйча кем булсын? Илдә ни кием дисәң, шул юк. Ә моның складына дефицит товарлар көн саен составы белән кайтып тора. «Чын коммунистлар партиясе» вәкилләре моның кабинетына килеп керү белән исәнләшеп тә тормаганнар. «Сез халык канын эчүче. Шушы уңай белән сезгә бераз ясак салырга килдек, — дигәннәр. — Ясакның күләме алай зур түгел — өч йөз мең сум, — дигәннәр. — Әгәр килешмисез икән, Плеханов исемендәге Халык

хуҗалыгы институтында укып йөргән улыгызның башын менә шушы матур картон тартмага салып китерербез», — дип өстәгәннәр. Сугышчан группа егетләре башкача сөйләшә дә алмыйлар. «Егетләр! Нинди сүз сөйлимсез? Өч йөз мең сум да акча булдымы?» — дигән хуҗа. Сейфын ачып, ул сумманы шунда ук санап та биргән. Казбек егетләре, шул рәвешчә ясакны биш йөз мең, хәтта бер миллион сумга күтәреп, «Спутник» кунакханәсе, «Пекин» ресторанына хуҗаларына салганнар. Берәү булса, тавыш күтәрер, милиция чакыртыр иде. Ә болар барысы да: «Хөрмәтле егетләр, моннан соң үз итеп йөрегез, йомышыгыз төшкәндә тагын килеп чыгыгыз!» — дип озатып калганнар. Нәрсә дигән сүз бу? Димәк, тавыш күтәрү аларның үзләре өчен зыянлы. Димәк, алар бурларның бурлары.

— Ул кадәр акчаны Казбек егетләре кая куйганнар соң? — диде Шәүкәт.

— Экспроприация актларын затлы ресторанларда кәеф-сафа кору, кызлар белән типтерү өчен ясамаганнар. Бер гөнаһсызга хөкем ителгән политик тоткыннарга ярдәм фонды булдырганнар. Мордовия, Урал, Магадан лагерьларына зур суммаларда акчалар күчергәннәр. Оешмаларына, бәлкем, провокатор үтеп кергәндер. Аларның оешмасы ачыла. Егетләрнең барысын кулга алалар. Суд була. МГУның геология факультеты дүртенче курс студенты Казбекка биш ел бирәләр. Уралда билдән кар эчендә тайга аударганда, конвой башлыгы, аның өстенә җикеренеп килеп, башына таяк белән суга. Башка берәр мәхлук җан булса, дәшми калыр, үткәреп җибәргән булыр иде. Ә Казбек! Казбек — бөркет! Кавказ егете! Хөкем ителгән, гражданлык хокукларыннан мәхрүм ителгән булса да, горурлыгы үзе белән. Аңа таяк белән суккан конвой башлыгына балта белән кизәнә. Конвоир исән калса да, аңа кул күтәрүчегә — расстрел. Казбекны да атарга хөкем итәләр. Камерада хөкем көтеп утырганда, төрмәчеләр аны кулларыннан килгәнчә мыскыллыйлар, җәберлиләр. Көне-төне кыйныйлар. Бу җәберләүләргә түзәр хәле калмагач, Казбек кулындагы карандаш кисәге белән сул күзен чукып чыгара. Түзәр чамасы калмагач...

Шәүкәт, авыр сулап:

— Казбек менә нинди тормыш мәктәбе узган икән?! — дип сузды. — Аның күзендәге кара лентаны күргәч, балачак фажигасе йә эш урынында ялгышлык белән туган хәвеф нәтиҗәсеме дигәнием.

— О-о, безнең Казбекмы?! Исеме җисеменә тиң! — диде Батя, яткан җиреннән күтәрелә төшеп. — Казбек — уникаль шәхес! Тәнре аны үзенең бөтен барлыгы белән җирне бизәп яшәү өчен махсус яраткан төсле тоела миңа. Сирәк очрый торган экземпляр итеп түгелме икән әле. Аңардагы акыл, аңардагы сәләт, Казбектагы баш! Аңа президент булырга да дәүләт белән генә идарә итәргә! Батя Казбек портретын ясарга дип алдына куйган киндеренә төсләрне-буяуларны артыграк тондыра түгелме дип уйлый күрмәгез тагын. Һич юк! Хәер, тик башкача фикер йөртүләре, «Левой! Левой!» дигәндә җиргә уң аяклары белән баскан өчен генә дә башларын совет зинданнарында черетүчеләр арасында мин бер генә чүбек баш та очратмадым.

— Цивилизация үзәкләреннән, зур шәһәрләрдән гел шулай читтә яшәү егетләрегезгә барыбер уңайсыздыр, — дип куйды Шәүкәт.

— Нигә алай дисез? Җәен һәркайсыбызга икешәр ай ял бирәләр. «Северзолото» — бик бай трест. Санаторий, ял йортларына путевкалар бирә. Егетләребез ялларын Кара диңгез буйларында, Кавказда, Кырымда уздыралар. Әмма шунысы сәер, материкта төпләнеп яшәргә теләмиләр. Көз җитү белән, очар кошлар төсле, бирегә әйләнеп кайталар. Тормыш катлаулы шул, — диде дә Батя туктап калды.

Шәүкәт аны йоклап китте дип уйлаган иде.

— Күреп өлгердегезме икән, үзәннең иң аргы очында алты кабер бар, — дип, янә дәвам итте Батя. — Алар да мин сөйләгәнне раслыйлар. Шул каберлектә мин дә үземә корырак урын карап куйдым әле. Дөнья эшен белеп булмый, кеше дигәнең бүген бар, иртәгә юк. Ә юеш кабер мине никак не устраивает. Урал лесоповаллары, Магадан шахталары үзен сиздерә шул. Миндә, егетләр, прогрессирующий ревматизм. Мондый аяклар белән юеш кабергә дә элэксәң, совсем беттем диген. Пропал булачак.

Егетләр берсе дә йокламый икән. Батяның бу сүзләреннән соң барысы гөрс итеп көлеп җибәрделәр.

Ә Батя кинәттән генә:

— Фу-у-у! Таптым сөйләр сүз! — дип куйды. — Стоп! Стоп! Шлагбаумны төшерәм. Нинди паникерлык әле бу? Минем күңелгә каян килеп сырышырга маташа әле мондый пессимизм? Йокламыйсызмы әле?

— Уйлаган да юк, — дигән тавышлар килде юрган асларыннан.

— Ир-ат халкының ни дәрәҗәдә яшьлеген, егетлеген конкрет бәяләргә мөмкинлек бирә торган нинди критерий бар, беләсезме? Белмисез. Әйтик, проспекттан башына эшләпә кигән, кулына калын портфель тоткан джентльмен атлый. Карап тор, урамдагы шома бозлавыкны, малайлар ясаган шугалакны ул әйләнеп узармы, әллә малайлар белән бергә шуып узармы? Шуып узса — егет. Әйләнеп узса — согы сыгылган лимон. Капут! Чынбарлык алдында капитуляция. Миңа Мончегорскида бик еш булырга туры килә. Аның сөзәк урамнарында шугалаклар атлаган саен. Араларында ун-унбиш метр озынлыктагылары бар. Ком сипкәнрәк урын эзләп, минем әлегә шуларның берсен дә әйләнеп узганым юк. Дөрес, кайчак гөрс итеп артка утырган чаклар да була. Ләкин капут — найн! — диде Батя.

— Капут — найн, найн! — дип хупладылар аны егетләр, җылы юрган астыннан башларын гына чыгарып.

— Материкта туган-тумачагыз бардыр бит? — дип сорауны кирәк тапты Шәүкәт.

— Ничек булмасын ди! Ригада хатыным, инде институтлар тәмамлаган кызларым бар.

— Хат алышасыз булыр?

— Хат алышмыйбыз. Мин аларга акча гына салып торам. Мин алардан, алар миннән рухи яктан нык ерагайган. Алар бер, мин икенче социаль җирлек, платформа кешеләре. Ике арадагы бушлыкны һич атлап чыгышлы түгел. Аларның ашларына таракан булып төшмәс өчен, мин ике арада даими интервал тоту ягында... Гәрчә үзләрен бик сагынсам да...

Берара байтак кына вакыт тын торганнан соң:

— Батя! Гафу итегез. Сезне аңлаудан мин бик ерак торам, — дип кенә әйтә алды Шәүкәт.

— Бөтен хикмәт тә шунда, — дип пышылдап әйтте Батя. — Безне аңлавы кыен... Бөтен хикмәт тә шунда шул... Аңларга теләүчеләр дә юк...

Казбек, ике эшче алып, аларга геодолитлар күтәртеп, яз килү белән алтын юдыра торган драгалар куелырга тиешле районда съемкалар ясарга җыена иде. Мин дә сезнең белән, дип, аларга Фаягөл дә иярде. Егетләр сизәләр, шушы коры сөяк Казбек Фаягөлне әллә кай ягы белән үзенә каратты. Концерттан соң да гел бергә булдылар, икәү биеделәр. Менә хәзер дә Казбек аны берсүзсез иярттe. Колониядә Казбектан ни өчендер бераз шүрлиләр.

Төш алларыннан Фаягөл базага:

— Минем трофей! Минем трофей! — дип шар ярып кайтып керде. Кулында үзе атып алган куян.

Ә Казбек аны:

— Фаечка, син чыннан да «Ворошиловский стрелок». Косойны шулхәтле ерак арадан бер атуда алдың. Мин булдыра алмас идем, — дип мактады.

Шәүкәт бу кадәресен үк көтмәгән иде. Кичен чәй янында Батя белән Казбек аның каршына утырып:

— Старшой, сиңа бик җитди үтенечебез бар, — диделәр.

— Тыңлыйм.

— Калдыр безнең янда Фаягөлне, — диделәр. — Беләбез, беләбез, бер кызыңны саами егетләре Кола ярыматавының королевасы итәргә теләгәннәр. Ә без Фаягөлне Кола ярыматавының шаһинәсе, патшабикәсе итәбез.

— Ничек инде калдырыйм, — диде Шәүкәт, кинәт куйган сораудан бераз аптырап калган хәлдә.

— Казбек улымны өйләндерәм! — диде Батя.

— Без Фаягөл белән язылышырга булдык, — диде Казбек.

Ни әйтергә дә аптырап торганда, Фаягөл үзе килеп керде, Казбекка ымлап:

— Шәүкәт, мине аңлый күр. Менә бу пиратка мин бер күрүдә гашыйк булдым. Мин калам, — диде Фаягөл.

Шәүкәт тәмам аптырап калды.

— Ничек инде «калам»? Без бит алай сөйләшмәгән идек, Фаягөл, — дип кенә әйтә алды ул. — Прәме аптыраш сезнең белән. Моннан соң походка чыкканда кызларны бөтенләй алмаска булыр инде.

— Менә хәзер сөйләшәбез. Бер күрүдә ошаттым, яраттым шушы сыңар күзле пиратны. Башка бер сүз дә ишетәсем килми, — дип, Фаягөл Казбекны муенныннан кочаклап алды.

Батя терсәгенә кадәр кара йон баскан ике кулын да өстәлгә салды. «Узган төнне Казбекны безгә бер дә юкка гына мактап чыкмаган икән бу хәйләкәр агай», — дип уйлап алды Шәүкәт.

— Шәүкәт, Сез шушы тату группагызның башлыгы, — дип башлады Батя. — Ризалыкны Сездән сорамый, тагын кемнән сорыйк? Без Сезне нык ихтирам итәбез. Әгәр Сезнең авыздан «Риза!» дигән сүз чыкса, әнә мәйданчыкта вертолет тора, иртәгә барыбыз Мурманскига очып, аның иң матур ресторанарының берсендә зур итеп туй ясыйбыз. Шулаймы, улым?

— «Риза» димәсәм? — дип, Шәүкәт Казбекка төбәлде.

— Казбекларның кем икәнен дә, кызлар урларга оста икәнен дә беләсең булыр. Фаягөлне бүген үк урлап урманга качам. Тайга эчендә бер дигән сунарчы йортлары бар. Бер ел эзләсәгез дә таба алмассыз.

— Әйе, андый вариант та бар, — дип куәтләде Казбекны Фаягөл. — Тотабыз да качабыз. Батя гына белгән Заимкага. Ә Батя — кремень, чакматаш! Аннан кирәкмәгән сүзне тискида кысып чыгара алмыйсың.

— Фаягөл?! — дип куйды башка сүз тапмыйча Шәүкәт.

— Мин инде егерме бер ел Фаягөл.

— Шулай да әллә ничегрәк бит әле. Ашыкмыйсыңмы соң?

— Ничек «әллә ничегрәк»? Теләгән, яраткан, үзем гашыйк булган кешемә тормышка чыгарга, язмышларыбызны уртак итәргә Конституциябез биргән хокукым бар бит минем, кәбәм.

— Әллә күрмисеңме, алар бит бер-берсен үлеп яраталар, — дип, Ләлә кушылмак булды.

— Ичмасам, син тик тор! — диде Шәүкәт. — Ярый әле бу юлы сине сорамыйлар.

— Нигә сорасыннар! Минем Бакалиным бар. Мин аны беркемгә дә алышмыйм. Толик минеке генә.

— Алышмыйм, имеш. Менә кайтыйк кына әле. Мондагы чыш-мышларыңны барысын апаңа сөйләп бирәм. Миләүшә апаң белер синең белән ничек сөйләшергә икәнен, кызый.

— Би-ир, исем китә бик. Яратам мин Бакалинны! Бетте-китте. Беркемгә бирмәячәкмен.

— Фаягөл, минем алга шартларны бик кискен куясыз, башкачарак вариантлар бер дә юкмыни? — диде Шәүкәт. — Кызлар сүзенә ышан син менә.

«Риза түгел» дип тә мин ни генә кыла алам? — дип уйлады ул. Ю-ук, иң яхшысы моннан соң походка кызларны алмау. Моны һич онытылмаслык итеп, мыегыңа киртләп куярга кирәк».

— Вариантлар муеннан! — диде Фаягөл. — Мин күп булса ун-унбиш көннәргә генә калам. Казбек эшләрен тапшырып бетергәнчегә кадәр генә. Аннары Казанга икәүләп кайтабыз. Ул бит геофакның дүрт курсын гына тәмамлаган. Укуын дипломлы геолог дәрәҗәсендә тәмамлау өчен Казан университетына кайтырга килештек.

Хәтта Виктор да:

— Ни арада кабул итеп өлгердегез шулхәтле ике яклы уртак килешүләрне? — дип сокланып куйды. — Әлбәттә, мондый килешүләрдән соң әлеге коммюнике игълан итүегез урынлы.

Батя белән Казбек һәм Фаягөл аларны Мончегорскига хәтле озата бардылар. Больницага кереп Бакалинны да алдылар. Ул култык таякларында. Тайган аягы гипста. Әмма йөзе балкый. Калдырып кайтып китмәүләренә сөенә. Батя белән Казбек бераранын каядыр югалып торганнар иде. Казбек белән Фаягөл Олег белән Ольгага бик матур бәбәй арбасы бүләк ителәр. Батя исә Женя Шахтинга «Фишер һәм К°» чаңгысы алып килгән. Геологлар үзләрендә кунакта булган туристларның барысына да истәлеккә кул сәгатьләре һәм җылы шарфлар бүләк ителәр.

* * *

Күп булса ун-унике көнгә сузылырга тиешле әлеге сәфәрдән Казанга Шәүкәт сынаулар аша чыныккан үзенең сугышчан группасы белән нәкъ ике атна тулган кичтә кайтып төште. Бер атналар чамасы укуларны калдырган өчен ректор Туишев аларны аякларыннан түшәмгә асып куймас куюын. Әмма Шәүкәткә аңлатманы бәйнә-бәйнә язарга туры киләчәк. Аның проектын ул башыннан инде кат-кат кичерде.

Виктор, вокзал каршындагы мәйданга чыгып басу белән, кичке чорда неон лампалары нурына күмелгән шәһәргә ымлады.

— Син бит, егетем, Казан мэры булачакмын, дигәниең. Башкаланы, пожалысты, кабул ит, — дип, Женя Шахтинга төрттерде, реверанс ясап, тезләренә чүкте.

— Мин кинәттән генә ул уемнан кире кайттым бит, әй, Олегка рәхмәт. Ул ярдәм итте, — диде Женя. — Походта кичергән тирән уйларымның очы итеп шундый карарга килдем. Мин Казаныбызның архимандриты йә епископы булырга тиеш. Бер ара чыгу белән Мәскәү читенә урнашкан Загорск монастырена барып кайтам. Архимандрит булу өчен миңа духовный академия тәмамларга кирәк булачак.

— Бу да начар түгел, — дип куйды Виктор. — Ә нигә?! Тавышың, понимаете ли, саф баритон. «Во имя отца, сына и святого духа!» бик әйбәт чыгачак. Буй-сыныңшулай ук килешле, разрядлы спортчы. Кулыңа кадило алып, бөтен чиркәүгә затлы хуш ис таратып, зур-зур атлап йөрүеңне менә хәзер үк күз алдыма китерәм. Ты, сын мой, раб божий Евгений, на верном пути!

Виктор, барчасына мөрәҗәгать итеп:

— Бик матур, истәлекләргә бай булды безнең бу походыбыз, — диде. — Йөгәнемнән җитәкләп бу походка алып чыгуыгыз, йөгәнемнән җитәкләп алып кайтуыгыз өчен барыгызга космик күк җисеме хәтле рәхмәт. Шунысы гына үкенеч, безнең Мурманск каласына хәтле барып җитә алмадык. Сезне диңгездән әле тотып кына алган чавыча белән сыйлый алмадым. Фатирымда аның төсләгәне бар. Әйдәгез, безгә кайтабыз!

— Баритон мой, баритон! Мама, жди родного сына, я вернусь к тебе к ужину! — дип, Женя Шахтин җырлап җибәрде. Аннары киерелеп бер көлеп алды. — Кичке чәйгә, әйдәгез, барыбыз да безгә кайтабыз. Әниембик шат булачак. Братцы-кролики, мин бик сирәк җитди булам. Бу юлы исә ихлас күңел белән чакырам. Әйдәгез, ә? Әниемсезне өрмәгән җиргә утыртмас.

Аларны каршы алырга вокзалга, бер төркем иптәш кызларын ияртеп, Миләүшә дә төшкән иде. Бакалин янына апасын якын да җибәрми Ләлә.

— Толик минеке! Мин аны яратам! — ди.

Апасы Миләүшә дә аптырап калмады.

— Сеңлем, аны монда бүлешеп тормыйк. Башта тулай тораккакайтыйк. Жирәбә салырбыз. Аннары карарбыз, — диде.

Шәүкәтнең күп тапкырлар сынаганы бар. Походлардан йөреп кайткач, иң кыены аерылышу, таралышу мизгеле. Вокзалдан һәркем үз ягына тарала. Әмма вокзал каршындагы мәйданга чыгып баскач, берәү дә трамвайга, автобуска ашыкмый. Һәркем башта иптәшләренең утырып китүен көтә. Чөнки бер аерылгач, кайчан күрешәсең әле. Шул минутларда бер-береңә күңелендә булган иң матур,

иң җылы сүзләрне әйтәсең килгән төсле. Шул ук вакытта андый сүзләр табылмый тора. Тамак төбенә төер утыра. Йотылмый тора.

— Алайса, дусларым, бер генә минутка игътибар! — диде Шәүкәт. — Киләсе җәйне Фәннәр академиясе Тянь-Шань тауларына «кар кешесе»н эзләү буенча зур экспедиция планлаштыра. Миңа ашыкмый гына группа туплый торырга тәкъдим иттеләр. Теләүчеләр булса, исемлеккә бүген үк терким.

— Шәүкәт, берүк масаеп китә генә күрмә. Көтелмәгән кырыс вакыйгаларга бик бай булган поход чорында без сине ихлас күңелдән яратып өлгердек. Афәрин, егет син, Шәүкәт! Без синең белән Айга, Марска, хәтта Андромеда томанлыгына чыгып китәргә бүгеннән әзер! — дип, аны дәррәү куәтләделәр.

— «Кар кешесе»н эзләргә барачак экспедициягә беренче итеп мине яз! — дип чәчрәп, алга Ләлә Бәхтиярова чыкты. — Шушы походта чыныккан кулларым белән мин аны үзем эләктерәчәкмен.

«Хәчтерүш» дип куярга араларында Фаягөл генә юк. Ләләне хәзер танымассың да. Елак Ләлә түгел ул хәзер, ә мадемуазель Бәхтиярова! Поход башында яңа туган бозау кебек аягында да басып тора алмаган шыксыз бер кызый поход ахырына чаңгыда каерып-каерып шуа башлады. Женя өйрәткәнне шундук үзләштерә барды.

Әле үзләренең Чиләбесеннән, әбисеннән мирас итеп килгән, чыраен бозып торган бер колагы күптән сынык күзлеген каядыр тондырды. Геологлар да аны артык үчтек-үчтек иттеләр бугай. Аеруча Батя үз кызыдай яратты. Күзләрне ап-ак кар чагуыннан саклый торган кара күзлекләр бүләк итте. Мадемуазель Бәхтиярова булмаска соң! Шәүкәт ничә тапкырлар үз күзе белән күрде. Маршрутта көйле генә барган җиреннән шып туктый да кесәсеннән көзге чыгара.

— Мин сиңа ошыймммы? Син мине яратасыңмы? — дип, Толикның да башын катырып бетерде бугай. Алай гынамы?! Ләлә хәтта палаткада кунганда да башына бигудилар бәйләп йоклый башлады. Алай гынамы диген. Җае чыккан һәр очракта Ләлә, аеруча Женя Шахтинга ымлап: — Моны сезгә мин — Ләлә Бәхтиярова — Кола ярыматавының королевасы, әйтәм! — дип, күкрәк сугып куя.

— Сез үпкәләмәсәгез, мин исемлеккә беренче итеп үзебезнең Мөнәвәрәне язар идем, — диде Шәүкәт.

Бу бик тыйнак, бик җыйнак, бик пөхтә һәм бик чиста, бик булган, әмма бик аз сүзле кызый егет күңеленең иң аулак почмагын күптән били. Шәүкәт үзе дә Мөнәвәрәнең аңа текәлеп-текәлеп карап торуын күп тапкырлар сизде. Аларның бер-берләренә игътибарлы-өйрәнүле карашлары соңыннан мәхәббәт уты белән кабынып китсә дә, аларның икесе өчен дә көтелмәгән хәл булмас төсле...

Төшмәсен лә күзең матур ярга...

Кирәк бит, аңа студиябезнең барча егетләре муеннан гашыйк. Шулай булырга тиеш тә иде. Күкрәгендә бөек Атилла, бөек Чыңгызхан оныгы йөрәге типкәндә, тамырларың буйлап бер тамчысы кулыңны пешерердәй кап-кайнар кан йөгергәндә, аңа гашыйк булмау мөмкин дә түгел. Ә мин, тиле баш, ярсу йөрәк, муеннан гына түгел, ә кайсысы фетр, кайсы йомшак вилюр эшләпәләрем түбәсеннән гашыйк. Чөнки алар миндә өчәү. Берсе генсек Михаил Сергеевич Горбачевныкы төсле күгелҗем-зәңгәр. Анысын бик тантаналы кичләргә барганда гына киям. Икенчесе — көлсу-көрән. Чөнки нәкъ шундый төстәге затлы җиләнем бар. Аны кисәм бик килешә. Өченчесе — чем-кара, йөк аты төсле. Әлеге чибәркәйгә шушы өч эшләпәм дә гашыйклар.

Алар безнең телевидение студиясенә ирле-хатынлы килеп төштеләр. Икесе дә югары белемле рәссамнар. Икесе дә яшьләр, чибәрләр. Икесе дә гадиләр. Икесеннән дә бер күрү белән яраттыра, үз иттерә торган үзенә бер җылы нур, зыялылык бөркелә сыман. Бәлкем, шуңадыр, бик тиз арада коллективның үз кешеләре булып киттеләр болар. Кырык корамадан тупланган безнең кәҗәле коллективка яраумы?! Ай-һай! Тауга каршы тегермән ташы тәгәрәтүдәй кыен нәрсә ул. Әнә сәнгать дөньясында исемнәре булган ирле-хатынлы Клячкиннарны Заполярьедан ук чакыртып алганнарые. Килүләре белән җиң сызганып эшкә керешсәләр дә, бер ай дигәндә эфирга бер спектакль чыгарсалар да, коллективта үз кешеләребез булып китә алмадылар. Әллә борыннары бик югары булды, әллә телләре артык коры, студия халкы аларны кабул итмәде. Урган арыш камылы арасына кереп адашкан үрдәк бәбкәләре төсле аңгыраеп-каңгыраеп йөрделәр дә Коми ягынамы, Төмән өлкәсенәме китеп бардылар. Хәзер аларны искә алып сөйләгән кеше дә юк.

Вадим белән Клара, Казанны ташлап, безнең нефть төбәгенә килмәгән дә булырлар иде, бәлки. Балыкны — койрыгы, адәм баласын ризыгы йөртә, диләр. Ленинградның сәнгать академиясен кып-кызыл дипломнар белән тәмамлап кайткан башлары белән, башкалабызда фатирдан фатирга күчеп, кандала-таракан белән сугышып, ике-өч еллар азапланганнар. Республика күләмендәге күргәзмәләрдә катнашып, призлы урыннарга да лаек булганнар югыйсә. Ике яшь талант турында үзәк газеталарда язып чыкканнар. Әмма! «Уф! Начар гына булса да үз куышыбыз бит!» дип әйтерлек фатир юнәтә алмаганнар.

Килүләренә бер атна дигәндә, Вадим белән Кларабызга, әлегә бер генә бүлмәле, әмма киләчәктә тагын да иркенрәген бирергә вәгъдә итеп, өр-яңа фатир ачкычын кулларына тоттырдылар. Әй-й, нарасый балалардай сөенештеләр дә инде үзләре, бичаракайлар. Вадим хатынын күптән инде кызчык алып кайтыйк дип аптыраткан. Ә Клара, бәбәй бишеге эләргә ышанычлы матча да булмагач, авырга калырга теләмәгән.

Получка көне иде ул. Без, студия егетләре, җәлт кенә акча җыешып, яңа фатирга күченүчеләргә карават, өстәл, радиоалгыч алдык. Өй туена бүләкләребез шул булды. Ә яһүд егете кинооператор Лева Симонов, беркемгә дә әйтмичә, Кларага үзе йомшак, үзе җылы өй башмагы алган. Аны хуҗабикә аягына үзе үк кидерде. Шул сәгатьтән мин ул кылый шайтанны бөтен аураларым белән күралмый башладым. Сәбәбе бик җитди... Көнләшәм!

Фатирлы булганнан соң:

— Слушай, старина, оказывается, как приятно в этом мире иметь свою законную конуру. Эштән арып кайткач, рәхәтләнеп караватка сузыласың. Ә Клара кухня якта нидер пешерә, чыж да чыж кыздыра. Тамак төпләрен кытыклап өйгә тәмле ис тарала. Сине беркем борчымый. Син хуҗа! Кыскасы — җәннәт! Ялгышмаганбыз. Стоило нам сюда приехать, — дип, Вадимның бик канәгать калып сөйләгәне хәтердә әле.

Клара үзенә гомерлек ярны да сайлый белгән. Вадимы искитмәле чибәр аның. Чак кына бөдрә сары чәчләре, аяз күк йөзедәй зәп-зәңгәр күзләре аның сөйкемле йөзен тагын да ача төшә. Ике битенең дә уртасында кайбер кызларга да тәтемәгән «мәхәббәт чокырлары», понимаешь. Озын буйлы, атлет гәүдәле. Әгәр инде сөйләшеп китсәң, интеллигент, эрудит! Аңа карата синдә шундук ихтирам хисе уята торган ниндидер үҗәтлек көче барын да тоясың. Ә Клараның гүзәллеген тасвирлап та торасы юк. Тасвирлый башласаң, буяуларың җитмәс. Көнчыгыш шаһинәсе, Япония императрицасы.

Шулай кирәк булгандыр инде, төзүчеләр телеүзәкне шәһәрдән биш-алты чакрымнар читкә, шыр ачык дала уртасына салып куйганнар. Безнең студия дә шунда. Анда безне автобус белән йөртәләр. Иртән илтеп куялар, кичен алып кайталар. Казан хәтле Казанның үзендә туып үскән, Ленинград кадәр Ленинградта биш ел гыйлем алган Кларабыз, понимаешь, караңгы бер провинциаль шәһәргә юлыктым дип кенә, безгә килүенең беренче көннәреннән үк аягына чүчинкә алып кимәде. Тышта бик зәһәр телле ноябрь булуга карамастан, Кларабыз һаман капрон оектан, биек үкчәле, фасонлы туфлидән йөри. Без һәр көн иртән эшкә бару өчен шәһәрнең үзәк мәйданындагы җәен-кышын дигәндәй баш киемсез, бер кат костюмнан басып торган бичара Ленин бабабыз һәйкәле янына җыйналабыз. Мондый ач суыкларда гел бер кат костюмнан юлбашчы бабабыз да өши торгандыр, әллә алдагы хезмәт хакыннан башына бүрек, өстенә берәр җылырак җиләп алып киертәбезме, дип шаярталар егетләр. Шоферыбыз тел бистәсе Виктор — бик әйбәт егет. Тын океан флотында өч ел урынына биш ел хезмәт итеп кайткан.

— Океанда безнең өчен үстереп куймаганнар. Биш ел буена бер җылы кочак күрмәдем, — дип сөйләнергә ярата.

Көн саен берәр җылы кочак куенында була да эшкә соңга кала. Унбиш-егерме минутка соңара да соңара инде. Берәр сәгатькә соңарып куйган чаклары да еш була. Безгә нәрсә, без җирле аборигеннар, без чыныккан халык. Өстебездә дә калын. Кларабыз туңа бит. Дөрес, ул сиздермәскә тырыша. Сиздерсә-сиздермәсә дә, күрәбез инде. Капрон оек кышкы аяк киеме түгел. Инде автобуска утыргач, аның тулы, матур балтырларын җылы кул белән уарга егетләр этешә-төртешә чиратка басалар. Әлеге кылый күзле, шалкан борынлы Лева Симонов аеруча өлгерлек күрсәтә. Берәр хатын-кыз заты күрсә, аңа сөлек булып ябышу гадәте аңарда электән үк бар иде. Карап торырга җен бит инде. Әмма нигәдер кызлар үзләре дә аны яраталар. Аларның башларын кинәттән генә әйләндереп җибәрерлек комплиментларны чамасыз күп сипкәнгәдер инде. Андый чакта сүзгә кесәгә кереп тормый ул. Шушы Лева Кларабызның балтырларын авызыннан җылы һава өрә-өрә уа да кочып-кочып та ала.

Вадим да безнең белән бит, әй. «Үз күз алдымда минем хатынны ул кадәр капшамагыз инде», — дип тә әйтми, ичмасам. Әллә яратмый инде дисәң, Клараны яратмау мөмкин түгел. Әллә инде аңарда көнләшү хисе бер дә юкмы? Елмая гына ул. Ә мин булсаммы, җүләр! Күз алдымда хатыныма берәрсе ялгышлык белән генә кагылып китсә дәме?! Ул бәхетсезнең күзен үк чукымасам да, тулы гарантия бирәм, акылга утыртам мин аны. Татарлык артык көчле бугай миндә...

Бу дөньяны һич аңламассың. Менә бит нинди хикмәт, егетләребез тарафыннан мондый игътибар Клараның үзенә дә ошый. Студиягә килгәч, без барыбыз да кинозалга кереп чишенәбез. Егетләр этешә-төртешә, терсәкләре белән юл ярып, Кларага тунын салырга булышалар. Ә Лева Симонов аның тунын кочагына алып кочып та тора әле. Ул инде бигрәк артыгын кылана. Шушы нахал яһүд егетенең, берәр җаен чыгарып, ипи шүрлеген капшап аласы иде. Шунсыз булмас, артыгын кылана.

Прәме аптыраш. Әллә Клараның законлы ире Вадим көнләшәсе урынга мин көнләшәм инде?..

* * *

Вадим әдәбият, драматургия редакциясен сайлады. Чын ижат кешесенә монда чикләнмәгән киң мәйдан. Үзе белән алып килгән бер чемодан төрле буяуларын, төрле зурлыктагы пумалаларын чыгарып тезеп, ихлас күңелдән илһамланып, бер спектакль өчен декорацияләр ясарга кереште. Клараны безнең

редакциягә билгеләделәр. Мин студиядәге иң җаваплы бүлекне — «Соңгы хәбәрләр» тапшыруын алып барам. Рус һәм татар телләрендә эфирга көн дә ике тапкыр чыгабыз.

Тышына бик матур итеп алтын хәрефләр белән язылган китапларны нарасый чакларымда ук әбием кулында күреп үстем. Андый китапларны институтта укып йөргән чакларымда да, китапханә шүрлекләрендә күреп, күп тапкырлар кулыма алганым булды. Бу хәрефләрне шулкадәр матур итеп кемнәр яза икән дип соклана идем. Бар икән ул андый могҗизаларны тудыручылар. Шуларның берсе Ходайның бирмеш көнендә минем каршымда утыра. Клара искитмәле фантазиягә бай, әмма бик затлы зәвыклы каллиграфистка икән. Экран аша укылырга тиешле бер текстка шундый матур титр язып куйды. Тот та күргәзмәгә куй, тот та шундук музейга тапшыр. Мондый әйберне заказ белән эшләтеп булмый торгандыр. Чөнки заказ иҗат иясен билгеле бер калыплар белән чикли. Ә ирекле иҗатның җимешләре бөтенләй башка! Яхшылык гамәлләре кылу кебек. Аларның да чиге юк бит.

Безнең «Соңгы хәбәрләр» редакциясе урнашкан бүлмә телефон будкасыннан чак кына зуррактыр. Бар җиһазы — ике өстәл дә бер телефон. Берсе минем эш өстәле. Икенчесенә кысылып кына Клара утыра. Рәссамнарның киерелеп-таралып, ара-тирә кайнар кофе капкалап эшләргә иркен генә үз бүлмәләре дә бар. Клара ханым миңа каршы өстәлдә утырып эшләүне кулайрак күрә. Алай икебезгә дә иплерәк. Минем кул астыннан чыккан текстка, Татарстан «кара алтын» чыгаручыларының киң хезмәт фронтында, удар вахтага басып, үз-үзләрен аямыйча ирешкән рекордлары турында язмага ул бер генә күз төшереп ала. Менә дигән заставка йә тирән эчтәлекле титр язып та куя. Кайчакларны ул эшенә шултикле бирелеп китә, түбән сыйныфларда укыган мәктәп баласыдай, ирен читенә тел очын чыгара. Кайчакларны тирән сулап, җиңелчә генә ыңгырашып ала. Минем аңа яратып, сокланып караганны сизә инде ул, күрмәмешкә генә салыша. Әгәр инде яңа титр язасы катыргы кәгазь, картон кисәге өстенә ялгыш тап-мазар төшсә:

— Һай, шайтан алгыры! — дип сукранып куя.

— Син русскоязычная! Полутатарка! — дим мин аңа. —Саф татарлар гына белгән бу сукрану сүзләрен кемнән өйрәндең?

— Ничек үрәнмим ди? Берәр эше күле бармаса, минем бабакаем шылай сукрана иде.

— «Үрәнмим», «күле», «шылай», имеш! Мишәрка син! «Өйрәнмим», «көйле» «шулай» дип әйт, шулай сөйләш.

— «Әйт» тегел, «ать» дип атергә кирәктер.

Кайвакыт башын күтәрми язып утыргач, үз эшеннән үзе дә канәгать калып:

— Шапылдаттыммы? Ать дөресен, җәннәткә керерсең, — дип куя.

— Искиткеч чыккан бу! Нык шапылдаткансың! — дим. — Кулларың алтын синең, кызыкай.

— А сердце?

— Анысын әйтә алмыйм, — дим. — Капшамыйча, дөп-дөп ярсып типкәнен үзем тыңлап карамыйча, диагноз куя алмыйм.

— Ә ник тыңлап карамыйсың? Фонендоскоп кирәк булса, безнең өйдә бар, алып килермен.

Аны аңламассың: әллә чынлап сөйли, әллә шаяра.

«Соңгы хәбәрләр» редакциясе булгач, безнең бүлмәдә телефон еш шалтырый. Телефонсыз хәбәрле була алмыйсың. Кайчакта телефонга икәүләп үреләбез. Кулларыбыз очраша. Дөнья булгач, күп чибәркәйләрнең кулларын тоткан бар: күрешәсең дә, кичәләрдә биергә дә чакырасың. Кларaның куллары сихри кодрәткә ия. Ходаем, бу турыда ул үзе генә белә күрмәсен. Мин шаярып кына аның кул аркасын чеметеп алам. Шуннан да тәм табам, җанга рәхәт булып китә.

— Чеметсәң, ныклап чемет, сыгылып китәрлек булсын, — ди Клара. Әллә инде чынлап, әллә шаярып...

Урманнарга керсәң, сызгырып кер, сыгылмаган агач калмасын! Ярлар сөйсәң, шундыен сөй, сокланмаган кеше калмасын! икәнен дә бик яхшы беләбез.

Кайвакыт аңа төбәлеп үзем дә сизмәстән уйга калам. Минем болай да бераз томау төшкән фантазиям мине әллә кайларга алып китә. Клара белән инде, әлбәттә. Вадимны әйтәм әле, сайлый белгән үзенә кәләшне. Эре бөртекле, куе кап-кара чәчләре Кларaның йөзенә килешеп тора. Карлыгач канатыдай икесе ике якка сызылып киткән кара кашлар. Һәркемгә елмаеп карый торган карасу-көрән күзләр, озын керфекләр. Белеп, чамалап кына, әмма сәнгатьчә осталык белән иннек-кершән яккан шома битләр. Шушы төс-битне тагын да бизәп торучы чак кына тыңкыш матур борын, уймак авыз.

— Иптәш редактор, ул хәтле төбәлеп карамагыз әле миңа. Сезнең бу карашыгыз кулымдагы тушьны киптерә. Юк, юк миндә ah итәрлек чибәрлек. Все, что тебя так поражает — это бутафория. Работа на жуткую публику! Лишь! Созданная умелой рукой талантливого художника чисто театральная бутафория! Понимаешь? Чибәрлек өләшкәндә мин мич алдында күмер чүпләп калганмын, — дип, ул мине, хыялларымнан аерып, ошбу фани дөньяга, чынбарлыкка кайтара. — Эзләмә, Ленар, миннән юкны. Самая обыкновенная полутатарка, полумаржа мин.

— Алай димәсәнә, Клара матурым. Үзеңә гашыйк итә торган серле кодрәтең бар бугай синең. Яшермим, менә мине дә баш түбәмнән гашыйк иттең, ахры, — дим. — Беләсеңме?! Вадим бер дигән

егет дип тормас идем. Көннәрнең берендә алмачуар аргамакка атланып килеп чыгар идем дә урлап качар идем үзеңне. Ләкин минем ике кулым, ике аягым да богаулы, койрыгым бозга каткан. Мин өйләнгән. Үз хатыным да яратмаган ризыгым түгел. Тәлинкәгә салып, өстенә добавка өстәтеп ашый торганнардан. Ул да синең кебек полутатарка, дөресен әйтәдерме-юкмы: «Ленар, я тебя очень люблю!» — дигән була. Күпме кешене бәхетсез итеп, без генә бәхетле була алмабыз.

Бу сүзләрне йөрәк янганнан гына әйтүемдер. Хәер, йөрәк тә алай һич сүндерә алмастай дөрләми. Чөнки көн буена без гел бергә. Бер һаваны сулыйбыз. Бергәләп киңәшеп, бер тапшыруны эшлибез. Ул һәрчак күз алдымда. Эштән соң да кинозалга кереп утырабыз, бергәләп эшләгән тапшыруның эфирда яңгыравын карыйбыз. Йөрәкнең янганын басарга шул җитмәгәнмени?

Клара йомшак тастымалга төреп эшкә һәр көн бик тәмле чебуреклар алып килә.

— Академиядә укыганда грузин кызы Сулико белән бер бүлмәдә яшәдек. Чебуреклар пешерергә шул кыз өйрәтте, — дип аңлатты.

Студиядә ярлы гына буфет бар барын. Буфетчы кыз Гөлсинә, шулай ук бетмәс-төкәнмәс мәхәббәт утында янып, базар мөнәсәбәтләренә күчә алмый йөри. Буфеты бер көн ачык, биш көн ябулы була. Халыкның бер ише автобуска төялеп шәһәргә кайтып ашап килә. Ә без төшке ашны, электр плитәсендә чәй кайнатып, үз бүлмәбездә генә ашыйбыз. Төшке ашка безнең янга Вадим да керә.

* * *

Безнең местком башлыгы Антон Журавскийның әллә бер дә сүзе үтми инде. Балалар бакчасына кайчаннан бирле бер урын ала алмый. Әллә инде артыннан да йөрмиме? Өйдә ышанып калдырыр кеше булмагач, мин ике яшьлек кызым Айгөлне үзем белән эшкә алып йөрим. Хатыным Кадриям — укытучы. Ул да дәресләрен калдыра алмый. Бер дәрескә генә соңарса да, кырык малай — кырык башкисәр урамда калачак. Шул бер сәгать эчендә берәр яман эш кылып өлгерсәләр, кем гаепле — укытучы! Башыңны Себер җибәрерләр. Ә кызым миңа эштә бер дә комачауламый. Унбиш-егерме минутлык «Соңгы хәбәрләр»не мин аны ике кулыма гер таксалар да язып ташлыйм. Бигрәк тә каршымда Клара утырганда. Ә кызым өйдән алып килгән курчаклары белән тын гына уйнап утыра. Мәмиләре дә алдында. Бер мизгелгә генә булса да бала чакларына кайтып аның белән бераз курчак уйнап алырга студиянең буй җиткән кызлары, чәчләренә чал кергән ханымнары да кереп-чыгып кына торалар. Кызым әгәр арыса, йокысы килә башласа, почмактагы тумбочка өстендә «Правда» газетасының ике еллык калын тупламасы бар. Йомшак та, җылы да. Шунда ятып бәй-бәй итеп ала. Мин өлгермәсәм, Клара апасы йоклата.

— Кызың бик матур синең. Керфекләренең озынлыгын гына күр, — ди Клара. — Әле менә үскәч кем булыр?!

— Әнисенә охшаган. Әнисе дә шулай озын керфекле, бик чибәр аның.

— Пар килгәнсез. Яңа ел кичәсенә парлашып килгән идегез шул. Мин аны ошатып калдым. Хатының беренче мәхәббәтеңме?

— Әйе. Бер кичәдә иптәш егетем таныштырганые. Вакыт уздырырга ярап торыр дип уйнап кына танышканыем да... Шалт, Мөхәммәтҗан! Гашыйк булдым да куйдым!

— Күрәм, күрәм, яратасың син аны.

— Сүз дә булуы мөмкин түгел. Шушындый матур кыз бүләк иткән кешене ничек яратмыйсың?! Аннары бит, яратмаган ашны хәтта авызга аласы килми...

* * *

Килгән шәпкә Клара безнең белән күбрәк русча гына сөйләште. Бу бичаракай татарча әллә бер сүз дә белмиме дип уйлаган чакларыбыз да булды. Ә студия егетләренең теле зәһәр... Эләкмә. Эләктеңме — беттең! «Татар маржасы» дигән исемне дә аңа егетләребез кушты бит. Героинябыз башта бу сүзләрнең мәгънәсен аңлатуны үтенде. Аннары, башын артка ташлап, калын тавышы белән:

— Ну, черти рогатые, что вы делаете со мной! Мне ведь нельзя так смеяться, а то бөтен битемне җыерчык басачак, — дип рәхәтләнеп көлде, егетләргә бармак янады. — Туктагыз, чак кына көтегез. Бераз әвәләним әле арагызда, аннары күрсәтермен әле мин сезгә «татар маржасын»...

— Чын татар хатыны булу өчен миңа нәрсә эшләргә кирәк? — дип сорап куя ул миннән тора торгач.

— Токмач басарга өйрән, — дим.

Бераздан соң:

— Токмач басарга өйрәндем. Токмачым Вадимга да ошады. Чын татар хатыны булу өчен миңа тагын нәрсә эшләргә кирәк? — ди. Бу өлкәдә әйтерсең мин танылган белгеч.

— Өчпочмак пешерергә, бәлеш салырга өйрән, — дим.

Беркөнне ул эшкә бик күңелсез килде. Тунын да егетләрдән салдыртмады, балтырларына массаж да ясатмады. Мин дә аптырашта, ни әйтергә дә белмим.

— Слушай, Ленар, — ди бу миңа. — Мы с Вадимом очень плохо живем.

— Вашего тонкого юмора абсолютно не понял, — дим.

— Мне не до тонкого юмора. С Вадимом очень плохо живем, говорю. Это так ужасно, когда плохо живешь с любимым. Я не знаю что мне делать! Тамактан ризык узмый. Мин бик кайгырам, күзгә күренеп кәегәм. Миннән бигрәк ул бернәрсә ашамый. Ике йомыркадан гына майда кыздырып, чыжлап торган табада йомырка тәбәсе китереп куям алдына. Кагылмый да. Чебурекларны ура гына иде. Хәзер читкә генә этә. Безнең өйдә крематорий хәзер. Берсе бетешкә, авызына сигаретның икенчесен каба.

— Балакаем, матурым, алтыным, моннан бер атналар гына элек: «Наконец, я беременна! Уже семь недель! Вадим кыз тели, ә мин курнос борынлы, бераз кыланчыграк малайлар яратам. Бер малай кайтарып тоттырам әле мин аңа», — дип сөйләгәниең бит. Тагын нәрсә булды инде? Бер-берегездән биздегез мәллә? Әллә арагызга берәрсе кердеме? Әллә теге кылый күзле еврей малае Лева бутыймы? Взвод командиры солдатларын сафка тезгәндә: «Здравствуйте, орлы!» — дип сәламләгән. Взвод бертавыштан: «Мы не орлы, мы львы! — дип җавап биргән. — Лев Моисеевич, Лев Абрамович, Лев Рабинович, Лев Аркадьевич!» — дип санап киткәннәр. Янәсе, болар бөркетләр түгел, ә арысланнар. Әгәр дә мыскал гына кыек эше булса да, күрсәтермен мин ул еврей малаена кем икәнен.

— Скажешь тоже! Арабызга берәү дә кермәде. Вадимга иң хәтәр конкурент — син. Ә син планканы күтәрмәскә куштың. Вадим эшен яратмый. Бүгеннән үк кире Казанга кайтып китәм, ди.

— Ничек яратмый? Ничек инде яратмый?! Әле кайчан гына шушы бүлмәдә: «Жена есть. Фатира есть. Деньги на тачку начну копить. Как ты думаешь, за год накоплю?» — дип киңәшеп утырганые бит. Прәме аптыраш сезнең белән.

— Как художник пропаду я здесь. Если уже не пропал, дип, төне буе аяк өсте йөреп чыга. Сигарет арты сигаретны сагыз урынына чәйни. Өйне төтен басты, чын мәгънәсендә крематорий.

— Нәрсә сөйли ул?! Миенә су үтеп әллә акылы сыекландымы? Акчаны бит сүбүк көрәк белән көрәп аласыз. Гонорарларны да иң күп көрәүчеләр сез. Иң сөенечлесе — сезне коллектив ярата. Әнә Пермьнән килгән Тукмаковларны үз итмәде бит. Нинди талантлы режиссерлар булсалар да. Ничек шалтор-шолтыр килгән булсалар, шулай кылтыр-калтыр китеп тә бардылар. Югыйсә берәүгә дә начарлык эшләмәделәр. Коллектив кеше дигәнеңне әллә нинди сәерметрлар белән үлчи бит ул. Йә кабул итә, йә юк. Ә сезне беренче көннән үк кызыл, ал флажоклар изәп каршы алды. Хет шул турыда уйлыймы соң ул?

— Ленар, дорогой мой, ә менә миңа нишләргә? Тебе ума у чужих не занимать, бер-бер акыллы киңәш бир миңа, пожалуйста. Вадим мой — мировой егет. Я люблю его, упрямого козла. Әгәр берәр позициягә басса, аны танк белән кузгата алмыйсың. Гранит кыяга әверелә. Бик көчле заряд белән шартлатсаң гына. Ә кирәк чагында гына андый зарядны каян аласың? Кистереп кенә әйт, миңа аның белән китәргәме, әллә калыргамы? Үзең күреп торасың, эшемне сөям, яратам бит мин. Плюс ли это, минус ли, я ведь беременна. Не знаю что делать, прәме аптырагански.

* * *

Ел да бер тапкыр бик купшы, шау-шулы тантаналар белән уза торган нефтьчеләр көнендә үзебездә чыгыш ясарга мин бер атаклы нефть генералын дәштем. Борынына томау төшкәнме, тамагы бераз карлыкканмы, Клара бюллетеньдә иде, ул көнне эшкә чыкмады. Тапшыруны бизәшергә Вадим килде.

Тапшырудан соң өчәүләп шәһәргә кайттык. Нефть генералы безне кунакханәгә, номерына дәште. Бәйрәм көн бит, ул безне зур кунак итте, сыйлады, аннары:

— Ә менә бу шакмаклы тактага сез ихтирамлымы? Едва-едва е четыре йөри беләсезме? — дип, өстәлгә фигуралары фил сөягеннән, тактасы затлы инкрустацияләнгән шахмат тактасы чыгарып куйды.

Генерал чын шахматист икән. Шахматны без дә еш уйныйбыз. Хәрәмләшә-хәрәмләшә, генералга ничек тә оттырмаска тырышып, күп партияләр уйнадык без бу кичтә. Генералга тыныч йокы теләп, аның номерыннан төн уртасында гына киттек. Урамга чыккач, Вадим сигарет кабызды.

— Слушай, дружище, — дип сүзне турыдан башладым. — Клара сине Казанга кайтып китәргә җыена дип сөйләде. Шул сүз дөресме? Башыңа тай типмәгәндер ич? Мондый матур, күңелле, ижади эшне син бит Казанда шәм яндырып эзләсәң дә таба алмыйсың! Нигә кыланасың? Әллә арт ягыңны май баса башладымы?

Вадим тирән итеп сигаретын суырды. «Дустым, йонлы колагым, бу кадәресенә тыгылмасаң да яраган булырые» дигән сымак төбәлеп карап алды.

— Телевидение... минем өлкәм түгел, — диде ул, сүзләрен теш арасыннан кысып чыгаргандай итеп. — Баш өстендә үз түбәм, үз куышым. Дөрес әйтәсең, хезмәт хакын да яхшы алабыз. Болары бәхәссез, зур плюслар. Әмма тагын ике-өч елдан мин художник буларак бетәчәкмен. Бөтенләй юкка чыгачакмын. Телевидение — кешелек акылының искиткеч казанышы. Әнә минем Клара аның очсыз-кырыйсыз диңгезендә үз корабын уйнатып кына йөртә. Ул бит беренче класслы каллиграфистка. Титрларыңны ничек матур яза. Андый каллиграфисткалар борынгы заманнарда хәтта хан сарайларында да зур хөрмәткә лаек булганнар. Искитмәле матур хәрефләр белән хан указларын бизәгәннәр, шәмаилләр, ярлыклар язганнар. Клара бер штрих төшердеме, бер сызык сызып куйдымы

— барысы да экранда. Ә минем стихиям — төсләр. Мин төсләр, ярым, чирек төсләр алдында табынам. Алар белән бизисем килә дөньяны. Кичен кояш батар алдыннан син офыкта нинди төсләр күрәсең?

— Кеше күргәнне инде. Дөресрәге, тавыклар, казлар күргәнне, — дип шаяртмак булдым. — Ал, кызыл, сары, яшел, кара, ак, куе зәңгәр, шәмәхә төсләрне. Аларны кем санап торган.

— Барысы сигез-тугыз төс инде, — диде Вадим. — Ә мин егермеләп төсне танып күрәм. Ләкин телевидение экраны аша мин аларның берсен дә бирә алмыйм... Телевидение бүгенге хәлендә бары тик ак белән караны гына таный. Бәлкем, кайчан да булса, төсле телевидение пәйда булгач, минем дә кирәгем чыгар. Ләкин ул кайчан туа әле? Ә бүген мин монда киряксез. Минем иң мажор төсләр белән тулы пейзажлар ясыйсым, үзем иҗат иткән киң полотнолар белән зур театрларның сәхнәләрен бизисем килә. Ә бит биредә андый мөмкинлекләр юк.

— Клара?..

— Клара китәргә теләми... Калам, ди. Үз ихтыярында, теләсә нишләсен. Ә мин рәссам буларак йөземне югалтудан, юкка чыгудан куркам. Бер тамак туклыгы белән генә үлчәп булмый бит дөньяны. Мине чорнаган мохитне, чынбарлыкны иң нечкә төсләрдә сиземләвемне жуйсам, минем алда бер генә перспектива, бер айнымыйча эчү, алкоголизмга бирелү рәхәте генә кала. Күрәләтә упкынга барасы килми. Ә вакыт поезды коточкыч тизлек белән алга чаба. Элемтә бүлегенә хат салырга төшкән җиреңнән генә вагоныңнан төшеп калсаң да, аны куып җитәрмен димә...

* * *

Икенче көнне студиягә килгәч тә, Клара белән сүзебез Вадим турында гына булды.

— Китә икән, ялынып тормыйм, дүрт ягы кыйбла. Мин аны бәйләп тота алмыйм. Киребеткән Вятка мужигы бит ул. Яхшы сүз, акыллы киңәш әйтеп телеңне дә ардырма, алар аңа барыбер керми. Хәер, әгәр эшем үземә ошамасамы?! Мин үзем дә монда бер көн дә тормас идем. Иҗади эшләвем өстенә минем монда һөнәри осталыгым да көннән-көн камилләшә бара. Иҗади чишелешләре буенча берсе икенчесен кабатлаган бер генә заставка да куйганым юк бит алдыңа.

— Анысы шулай-й, — дип килештем. — Аларны искитмәле нечкә зәвык белән ясыйсың. Миңа сокланырга гына кала. Әй, Клара, матуркаем, Вадим — законлы ирең! Ир — баш, хатын — муен! Ире кая, хатыны шунда! Син шул кысадан чыкма әле, зинһар! Ир — энә, хатын — тегәрҗеп.

— Старое, патриархально-феодальное мышление! Ты сам так думаешь? Или чьи-то слова повторяешь? Я сама думаю совсем иначе, дорогой!

— Вадим кебек ирләр аяк астында ятмыйлар. Бер югалтсаң...

— Ә мин югалсам? Ул мине югалтса? Ник ул кайгырмый?

— Урыслар мондый чакта, с жиру бесятся, диләр. Сезне дә маегыз чәнчә. Юктан гына ситуация тудырасыз.

— Вадимга эше ошамый. Ә миңа үз һөнәрем бик ошый. Экранны матур шрифтлар, яңадан-яңа күзалланышлы хәрефләр белән язылган титрлар, заставкалар белән бизәүдән ләззәт табам. Күрәсең бит, минем бер титрым да икенчесенә охшамаган. Ә заставкалар? Мин аларның һәркайсына иҗат көчемне, талантымны салам. Бар булган иҗат көчемне җәелдерергә синең менә шушы өстәлендә минем өчен бернинди чикләүләр юк. Килешәсеңдер дип уйлыйм, хөрмәтле Ленар әфәндем. Әйе, мин бик кырыс дилемма алдында: йә ирем, йә яраткан эшем. Мин эшемне сайлыйм. Бәлки, ник ялгышамдыр. Әмма минем башка чарам юк. Аннары, Ленар, мин тормыш чатаклыкларына фәлсәфирәк карарга күнегеп киләм. Вадим безнең һич тә юл ярып алдан баручылардан түгел. Ул хис, эмоция колы. Казанга кайтып та... Египет пирамидасы төзергә алынырмы икән әле? Гәрчә, бер дигән егет булса да, мин аны яратсам да...

* * *

Үгет-нәсихәтләребезне әйтеп, күңелле генә озату да оештыра алмый калдык. Шалт кына җыенып Вадим китеп тә барды.

Ул китүгә, безнең телецентр тирәсендә ниндидер хәрбиләр кайнаша башладылар. Стройбатта хезмәт итүче, бер сынык ипи сорарлык та русча белмәгән төрекмән егетләре, баштанаяк кызыл балчыкка батып, ниндидер траншеялар казырга керештеләр, беләк юанлыгы кабельләр салдылар. Көннәрдән бер көнне шәһәребез чип-чиста, ап-ачык итеп Мәскәү тапшыруларын тота башлады. Һәм... шалт, Мөхәммәтҗан! Ап-аяз көнне яшен сугу шушы буладыр инде. Безнең кирәгебез калмады. Техник хезмәткәрләргә тимәделәр. Инженерлар, техниклар кирәк. Ә менә студияне яптылар да куйдылар.

А-ах, ялгышканбыз бит. Җирле студияне калдырырга булган икән бит, дип, соңыннан бик үкенгәннәр өстәге чал чәчле агайлар. Чөнки җиде-сигез еллап эшләп алу дәверебездә, анда бик көчле иҗади коллектив тупланган иде.

Палубасына ургылып су кергән, батарга торган корабтагы паниканы күз алдына китерү кыен түгел. Андый чакта һәркем үзе турында кайгырта. Тиктомалдан гына эшсез, иртәгәсе көнгә бер сынык иписез

калу фаҗигасе теләсә кайсыңны салкын тиргә төшерә. Алай да кулдан килгәнне эшләргә тырыштык инде. Уфадан килгән белгечләрне — Уфага, Оренбургтан килгәннәрне — үзләренә, Казан режиссерларын, телеоператорларын, бар булган мал-төяген машиналарга төяп, Казанга озатып куйдык.

Клара да, җыйнак кына юл сумкасы тотып, Казанга әнисе янына кайтып китте. Хәер, тагын кая барсын? Авырлы килеш. Булган барча җиһазларны, өстәл-урындыкларны, шкафларны, хәтта телефон аппаратларын да бер исемлеккә теркәп дәүләткә тапшыру мәшәкатьләре белән йөргәндә, бүлмәгә Клара керде.

— Ленар, саубуллашырга керүем, — диде.

Мин тиз генә чәй өлгерттем.

— Шушы бүлмәдә, бер һаваны сулап, бер эш өстәле артында узган көннәр, Ленар, күңел түремдә иң матур, иң истәлекле көннәр булып сакланыр, — диде ул. — Ә менә монысы миннән истәлек. Синең тапшыруларыңа иң матур титрларны менә шуның белән яздым бит инде, — дип, миңа бер пумала сузды. — Минем төсем итеп сакла!

Безнең ир-ат халкы мәгънәсез бит ул. Аңгыралык та баштан ашкан. Шунда бит инде!.. Бүлмәдә генә түгел, бөтен студиядә беркем юк. Кысып алып бер туйганчы кочасы, сусыл иреннәреннән суырып-суырып үбәсе булган миңа аны. Дөрес, соңыннан бик үкендем. Ләкин көмәне авызына җитеп килгән ханымга, кая, кочаклыйм әле бер үзеңне, дип ничек үреләсең? Булмаганны.

* * *

Сулар ага, гомерләр уза тора икән.

Шушы хәлләрдән соң, егетләр, ун-унбиш еллар гына үткәндер. Һәрхәлдә, тормыш сулары, кайчакта бер дә юктан гына буылып торып та, ә кайчакларны ургылып-ургылып та, бик күп акты.

Шушы еллар эчендә башкалабызга анысы аз йөрелмәде. Ашыгып барасың, ашыгып эшләреңне хәл итәсең, ашыгып кире кайту ягын карыйсың. Эзләгән, сораштырган булсам, Кларалары тапкан да булыр идем. Казанда берәр ышык кына чәйханәгә кереп, бергәләп тәмләп кенә чәйләп чыгарга да булыр иде. Эш дибез бит. Гомер буена аның көен көйлибез. Ә менә бу юлы башкалабызга бик четерекле йомыш белән барып чыгарга туры килде.

Бу юлы бәйнә-бәйнә сөйләми булмас. Сүземне менә шуннан ук башлыйм әле. Без Казанда күкрәк киереп студент булып укып йөргән чакларда, 5 нче трамвай маршрутында чакматаштай чая бер татар кызы кондуктор булып эшләде. Әтнә-Арчаданмы, әллә Питрәчтән булдымы икән? Гомер эчендә бер авыз җылы сүз ишетмичә, берүзенә егерме биш-утыз сыер савудан тәмам гарык булып, ферманы ташлап шәһәргә килеп урнашкан кызый булуы аның кырыс карашлы йөзенә чыккан. Аны гаепкә санаган кеше юк, әмма кондуктор кызыбызның русчасы бик чамалы. Соң, русчаны фермадагы сыерларыннан өйрәнсенмени? Әмма шушы чая телле, ачык күңелле кызыкайның үз пассажирлары белән теттереп сөйләшеп җибәрәсе килә. Әмма ул елларда җәмәгать урыннарында татарча сөйләшү, Әлгаязе билла (берүк Алла үзе саклый күрсен!), тыела иде бит. Телеңне тыймасаң, алып китүләре дә мөмкин иде. Әйе, татарча сөйләшкән өчен. Чөнки син бу мәкерле гамәлең белән илдә корыч ныклык белән урнашкан халыклар дуслыгы нигезенә балта чабасың.

Без лекцияләрдән соң үзебезнең тулай тораккa кайтканда гел шушы чая кыз вагонына эләгергә тырышабыз.

«Культура паркы» дигән тукталыш бар иде ул елларда. Менә шул тукталышка җиткәч, шунда төшүчеләрне:

— Настоящий парка культура! Смотри, тут ходи культурно! Один не гуляй! Гуляй падручком! — дип озатып кала. Киңәшләре изгедән аның. Иң кызыгы — «Ветеринария институты» тукталышына җиткәч: — Астануфка витириннарный! Кому надо в сумашушный дум, тут выходи! Эслизай смело! Там место всем хватает! Если там есть еще ыслабудное место, и меня занимай!

Без кешнәп көлеп җибәрәбез. Кондуктор безгә күз кысып ала. Пассажирлар да көлеп җибәрәләр. Стипендия алыр көннәр алдыннан кесәңдә өч тиен акчаң да булмаган чаклар еш була бит ул. Шунлыктан, билетсыз йөргәнлектән, кондуктор кыз безнең барыбызны да таный. Билет сорап та бәйләнми. Шунда берәребез алдында туктап:

— Иптәш студент! Кесәңдә өч тиен дә акчаң юк, ни дип укып йөрисең, балакай, ә укыгач кем буласың соң син? Бальшуй начальник будешь? Меня женкам возьмешь? Я тебя крепко буду любить, каждый день токмач будешь кушать. В восскресенье әбәзәтельни бәлешом булу угащчать, — дип сүз ката.

Казан халкы арасында «желтый дом» дип йөртелгән диваналар йорты да нәкъ шушы тукталышта бит. Шушы тукталышта төшүче барча пассажирларны да диваналар йортына баручылар дип аңлый инде, күрәсең. Аңламаса, шаянлыгы да җитәрлек аның. Шаян, чая булмаса, колхоз фермасындагы утыз баш сөтлебикәсен ташлап шәһәргә килеп урнаша алыр идеме?

* * *

Кай кичләрне мин Бауман урамындагы «Татарстан» кинотеатрына каршы гына яшәгән апаларыма төшәм. Хәлләрен белеп меним, ни хәлләрдә яталар икән дип инде. Берочтан апаның томат пастасын күп итеп салып көнбагыш маенда кыздырган макаронын да бөкләп чыгам. Стипендиягә хәтле ун сум акча да сорап торам. Апам үзе дә әллә ни бай тормый, әмма биш ел укуым дәверендә бер генә тапкыр да макарон белән сыйламыйча, чәй эчермичә чыгармады. Тулай торакка алардан соң гына чыгып кайтам. 5 нче трамвайга утырсам, тагын Гөлхәбирә вагонына эләгәм. Бу кичтә ул икенче сменага чыккан. Вагонда кеше юк диярлек. Гөлхәбирә алдагы буш урындыкка киерелеп утырган да лач-лоч нарат сагызы чәйни. Кулында алсуга манган йон йомгагы, үзенә калфак бәйлиме. Авыл кызлары кул эшсез тора алмый инде алар. Мине күрүгә, яныма килеп утырды.

— Төн күзен ертып, тушы чакка хәтле кая йөрдең, малай? Кызлар озатыптыр инде? Синең урыныңда үзем булсаммы?! Мендәремне кочаклап, гыр-гыр килеп рәхәтләнеп йокларыем мин.

— Кызлар кайгысымы соң әле монда. Имтиханнар җитте, конспектлар ятлаудан баш чыкмый. Бер ара табып, башны да бераз ял иттереп алыйм дип, апаларга төшкәнием. Хәлләрен белеп чыгыйм дип.

— Укып-укып та кем буласың инде син? Шәт, бер-бер урындагы кеше булырсың инде? Персидәтел-мазармы йә милиция нәчәлниге. Участковый булсаң да начар түгел. Әнә безнең авылның участковые кылый Ибрай абый бөтен Мәңгәрнең котын алып тора. Алдына китереп куйсаң, чалгыны кайсы баштан тотарга икәнен белми. Ул кылый шайтанга чалгы гупчи бирергә ярамый. Үләп чабам дип кешегә селтәнүе бар. Үзе бер сәнәк чапмаса да, ишегалдында елның елында биш кибән печән кышлый. Менә кем булырга укырга кирәк, матурым!

— Кем буласын кем белгән инде, — дим Гөлхәбирәгә. — Бер кергәч йөрибез инде шунда, гомер уздырып, аяк савыты туздырып.

— Мин сиңа туп-турысын әйтәм, егетем, — ди Гөлхәбирә, бу юлы бармагы белән күкрәккә үк төртеп. — Син үпкәли күрмә, синдә өмет юк. Бу килештән, әгәр әниең генә колагыңнан тотып, борының белән китереп төртмәсә, кырыкка хәтле өйләнә алмый йөриячәксең. Беләсеңме, миңа синең иптәш егетең ошый. Теге, сул ботинкасының үкчәсенә басып, бераз чатанлап йөри торган имгәгең. Менә анда өмет бар. Бераз чатанласа да, чурт с ним, күзләре уйнап тора. Таныштыр мине шул чатаның белән. Бал-май эчендә яшәр. Җәннәт рәхәтен җирдә татыр. Мин аңа бер итәк малайлар-кызлар табып бирермен. Бәхет дигән пәрәвез ишле балалы нигезгә ешрак сарыла икән, диләр бит. Таныштыр әле мине шул мут күзең белән.

— Иртәнге якта лекцияләргә көн дә сиңа утырып төшәбез бит. Кил дә таныш. Билетын тикшергән бул. Гомер эчендә бер трамвай билеты алып өч тиенсез калса да, бүсере төшмәс. Синең билет сорамасыңны белеп, укырга төшкәндә дә, менгәндә дә, башка трамвайга утырмый да ул.

— Юк. Син безне менә үзең таныштыр. Башта мине үтереп макта. Нәселләрен беләм, диген. Байлар, диген. Атасын бүгенме-иртәгәме министр итеп куярга торалар икән, диген. Миңа шундый изгелек эшләсәң, савабы үзеңә булыр.

— Авылда аның бик яратып йөргән кызы бар бугай. Хатлар алышып торалар.

— Булмагае! Әллә минем юкмы? «Беломор» папиросы тартмасындагы шоп-шома папиросларны төсле тезелешеп торалар. Егетләргә кытлыгым юк анысы, Аллага шөкер. Үземә ошаганы кирәк!

* * *

...Бер елны мине, предприятиеләрдә көзге политик укулар башланыр алдыннан, пропагандистлар курсына укырга җибәрделәр. Казанга килеп 5 нче трамвайга утыруга, шылт итеп Гөлхәбирә искә төште. Кайларда икән, исән генә микән үзе? Трампарклар Казанда егерме түгел. Берсендә белмәсәләр, икенчесендә хәтерлиләрдер. Тоттым да беренче трампаркка киттем. Күңелле, гажәп, сәер бер халәт. Гөлхәбирәне күреп сөйләшәсем килде. Аны табуы да кыен булмады.

Трампарк идарәсенең ишегеннән атлап керүгә:

— Ә-ә, «астануфка «Витиринарный институт». Кому надо в сумашушный дум, эздись выхади»мы? — дип көлешеп тә алдылар.

Әле без укып йөргән заманнарда муенына арзанлы мәрҗәннәр, җиз алкалар гына такса да, Гөлхәбирә төскә-биткә бик чибәр иде. Уңганлыгы, булганлыгы, тормышны сөеп яшәве йөзенә чыккан. «Мин бу дөньяны үземнең барлыгым белән тагын да бизәргә туган җан!» аның яшәү максаты иде бугай. Һәрхәлдә, аның белән кыска вакытка гына аралашып алу да күңелдә шундый уйлар тудыра иде.

Шул хисләр рас килде бит, әй. Гөлхәбирәбез матур калфаклар бәйләп кенә юатмаган икән күңелен. Читтән торып, гел бишләргә генә укып, финанс институтын тәмамлаган. Хәзер трампаркның производство-экономика бүлеге башлыгы икән. Үзен дә күреп чыкмакчы идем. Ире, балалары белән пароходта Идел буйлап сәяхәткә киткән. Ирен Казанның бик зур түрәсе диделәр. «Тырышкан табар, ташка кадак кагар» шушы буладыр инде. Үзе теләгәнчә «ба-альшуй начальникка» чыккан бит тәки.

Бәхетле генә булсыннар. Бу кадәресе күпләр өчен гыйбрәт булсын, бәхетең өчен көрәшергә дә кирәк икән. Юкса ул назлы кош бик сирәкләрнең генә канатына үзе эзләп килеп куна...

* * *

...Казанга бу килүебездә юлдашым Әхәт белән без нәкъ менә «Ветеринария институты» тукталышында төшәргә тиешбез. Гөлхәбирә әйткәнчә, «сумашушный дум»га барышыбыз. Юлыбыз шул якларга төште. Психдиспансерга. Гомерлек ахири дустым Әхәт тик торган җирдән кисәк-кисәк кенә тузга язмаган сүзләр сөйли башлый, акылы читкә тайпылып киткәли. Бер карасаң, үзендә дәүләт эшлеклеләре акылы бар. Икенче карасаң, «Мин Маршал Рокоссовский!» дип күкрәгенә суга башлый. Аның Советлар Союзы Маршалы К.К.Рокоссовский булуына кем каршы? Болар өстенә ул, миңа Галәм киңлекләреннән хәбәрләр килә, тегене эшләргә, менә моны һич кичекмичә башкарырга куштылар, дип аптырата. Кушалар, пычагым.

— Галәм киңлекләренә син генә кирәгиең, Әхәт, — дип тә карыйм мин аңа.

Аларны ул колагына да элми. Ә кайчакларны бөтенләй кызып китеп, әйләнә-тирәдәге әйберләрне кырып салырга, телевизорны тибеп очырырга да күп алмый. Үзебезнең белгән табиблар аңа «тихое помешательство» дигән диагноз куйдылар. Бер дулап китсәме, булыр тихий. Беркөн шулай, өянәге кузгалып, өеннән балаларын куып чыгарган, бар булган савыт-сабаны кырып чыккан. Дустым югыйсә университетның биология факультетын бик яхшы билгеләренә генә тәмамлаган үтә дә укымышлы егет. Эрудит, белмәгән нәрсәсе юк. Җир, туфрак, агрономия фәне турында сөйли башласа, авызына карата да шундук сине әсире итә дә куя. Дустым зур урында эшли. Әгәр инде аның кулын-аягын бәйләп больницага машинада илтсәң, зурга китәчәк. Дөнья булгач, дус-иш тә җитәрлек, дошман-хәшәрәт тә баштан ашкан. Берәүләр, ah, бичаракай, дип хәленә керсәләр, икенчеләре бот чабып сөенерләр. Күрче, ишеттеңме әле бу яңалыкны, Әхәт Борһанов нинди дәрәҗәле урында эшләгән җиреннән акылдан шашкан бит, дип, бөтен дөньяга шар ярырлар. «Тихое помешательство» дип кенә калмаслар. Кеше хәтле кешене үтереп, егерме ел зинданда утырып кайтучыны ярлыкау бар. Җәмәгатьчелек хәтта бер атнадан аның кем икәнен оныта, үзе белән бер өстәл артына утырта. Бик сәер психология бу. Ә менә әлеге «желтый дом»да ялгыш кына берәр кич кунып кара. Сиңа гомерең буена ярлыкау юк. «Ул бит, беләсеңме, «сары йорт»та ятып чыкты!» дигән кләймә, кара сакалың төсле, кая барсаң, шунда ияреп барачак.

Көтмәгәндә-уйламаганда башка төшкән бу хәсрәтне кешегә-карага чыгармыйча, Казанга поезд белән чыгып киттек. Гомер буе дус булганлыктан, Әхәт минем сүздән чыкмаска тиеш. Шулай дигән булды инде. «Суга сикер, дисәң, Ленар, суга сикерәм, утка кер, дисәң, утка ташланам», — дигән булды әле. Акылы саф чакларны шаян сүз аның тел очында гына тора. Алай да алдагысын Алла гына белә, акылы бер урында таптана башласа, аннан теләсә нәрсә көтәргә була. Анысын да искә алдык. Юлда барганда өянәге уйнаклый, пристубы койрык чәнчә башласа дип, контрчараларны да мулдан кулландык. «Тәмам бетерәсез бит сез мине, урындыкка утырыр җиремне калдырмыйсыз, шайтаннар!» дип зарланса да, табиб дусларыбыз аның арт ягына уколларны берсе өстенә берсен чәпәделәр генә. Төймә-төймә тынычландыргыч, шундук йоклатып җибәрә торган даруларны да бер кесә тутырып алдым. Мондый юлдаш белән ерак юлга ныклы хәзерлек белән чыксаң да таманча гына әле. Анысын күңел тукып кына тора.

Казанга әйбәт кенә килеп җиттек. Нурлат җирләрен узганда гына, Әхәт, вагон тәрәзәсеннән карап: «Язгы чәчүгә чыгарга вакыт, бик вакыт!» — дип сөйләнеп алды. Мин дә: «Әйе, әйе, бик дөрес сөйлисең», — дип, аның һәр сүзен хуплап бардым. Югыйсә тәрәзә аша башагы тулган бодай кырын байтактан күреп киләбез. Халык печәнгә төшкән. Яңа гына бастырган печән кибәннәре очрап тора. Алай гына ялгыш сөйләүдән кемгә зыян, тик котырып кына китә күрмәсен дип котым чыгып килдем инде.

5 нче маршрутка утырып, әлеге «Ветеринария институты» тукталышына кадәр мендек. Әхәтем күзгә күренеп гасабилана башлады. Барасы килми. Югыйсә, читтән безгә кып-кырыс тәнкыйть күзлеге белән караганда да, Казан елга портына туктаган круиз теплоходыннан төшеп шәһәр күргәнә чыккан чит ил туристларыннан бер ягыбыз белән дә ким түгел. Икебезнең дә өс-башларыбыз да кырт иткән. Авызларда алтын тешләр, аякларда фасонлы штиблетлар. Анысын тагын ни дип алганмындыр инде, минем муенда хәтта «Кодак» фотокамерасы да бар әле. Трамвайдан төштек. «Сары йорт» әнә генә. Әмма ул якка таба Әхәтнең аягы атламый.

— Аяк атламый бит, Ленар. Әйдә кире борылыйк, — ди бичаракаем. Як-ягына карана, гасабилана.

— Нәрсә инде, Әхәт дустым? Минем сиңа гомердә хыянәт итмәсемне үземнән болайрак беләсең бит, — дим, тынычландырмак булам.

— Инде, дустым, монда кадәр килгәч, кереп күренми булмас. Чирне аны беребез дә сорап алмыйбыз. Берәүнең үтереп теше сызлый, икенченең бүсере төшкән.

— Ә минем вакыт-вакыт сельсовет сбой бирәме? — дип бүлдерә Әхәт, бармагы белән бораулап башына күрсәтә. Үз-үзенә юмор хисе белән кararга да булдыра. Акылдан тайпылган булып әллә бераз кылана гынамы?

— Алай дип әйтмәс идем мин. Синдәге баш, Әхәт! Синдәге акыл! Беркадәрсен Госдума депутатларына биреп торырлык, — дим, чөнки салпы якка салам кыстырганны Әхәт дустым чирләп киткәнгә кадәр дә килештерә иде.

Бу юлы да:

— Баш анысы ба-ар. Дөрес әйтәсең. Тик бит ара-тирә кырау төшкәли башлады түгелме? — дип килеште.

— Менә шул шул, Әхәт дустым. Шул «ара-тирә кырау төшүдән» котылу өчен дә килдек бит инде монда. Син табибка, профессорга күренерсең. Ә мин бакчада утырып торырмын. Аннары үзебез укып, илгә кирәкле егетләр булып чыккан университетка төшеп китәрбез. Монда кадәр килгәч, «Альма матер»га кереп, сәлам биреп чыкмый килешмәс. Үпкәләр. Шулай бит? Ничек уйлыйсың?

Әхәт килешкәндәй башын селкегән була. Миңа да сынаулы карашлар ташлый. Ә менә аның бераз томау төшкән миендә нинди уйлар йөзгәнен кем белә? Усал уйлар гына туа күрмәсен.

Берәү үзен тары бөртеге итеп саный икән.

— Әһә, менә тары бөртеге таптым! — дип йотып җибәрмәгәе дип, әтәчтән курка икән.

Моны «желтый дом»га салалар. Байтак кына вакыт дәвалыйлар.

— Йә, ничек, терелдегезме инде? — дип сорый врачы. — Үзегезнең тары бөртеге түгел икәнлегегезгә тәмам ышандыгызмы?

— Мин ышануын ышандым. Ә менә әтәч ышанды микән шуңа? Мин урамга чыгу белән, ул мине кабып йотмасмы? — дигән.

Әхәтнең дә башында нинди уйлар хөкем сөргәнен кем белә?

Әхәт миңа, сөзеп-сөзеп карап алгаласа да, килешкәндәй башын селки.

— Ә менә син профессордан чыккач, башкалабызның иң затлы ресторанына кереп, Казан байларыча мулдан расхутланып, утырып чыгарбыз, — дип тынычландырмак булам үзен. — Өлгерсәк, кичке поезд белән үк өйгә әллүрт. Өлгермәсәк тә не беда, Тукай мәйданындагы «Татарстан» кунакханәсенең иң яхшы номерларына төшәрбез. Менә бит акча бездә бер букча. И-и, Әхәт дустым, без икәү бергә булганда, диңгез безгә тубыктан.

Тал бөдрәсе, тал бөдрәсе, тал бөдрәсе усакта.
Дошман сигез, без икебез бирешмәбез булсак та, —

икебезнең дә яраткан җырыбыз бит.

Гадәттә бик ачык, шаян сүзне дә борчак урынына сибәргә яраткан Әхәт дустым, ни турында гына сөйли башласам да, дәшми. Зомбиланган кеше кебек, башын гына як-якка тибрәтә.

— Бу кыяфәтең белән бөтен йөзен вак чебен сарган карт алашага охшыйсың. Ичмасам, селекмә әле шушы башыңны, — дип тә алам, — сүзгә кушыл, каршы төш миңа!

Сүзләренә карап башындагы ниятен төшенер, сизәр идем. Әллә уколларны артыграк кадаганнармы, шуның тәэсиреме? Мин аны кочып-кочып алам, аркасыннан дөп-дөп сөям, биллəреннән сыпырам. Без икәү булганда «менә сезгә!» дип, кемнәргәдер йодрыгымны яныйм. Әхәт, шуны килештереп, авыз чите белән генә елмаеп та куя. Шулай итә-итә килеп җиттек «желтый дом» каршына. Карап торырга бер дә куркыныч түгел. Революциягә хәтле үк салынган төзек кенә йорт. Халык телендә «желтый дом» дип йөртсәләр дә, сарысы шактый тоныкланган. Яңабаштан тагын бер акшарлап чыксалар, тагын да ямь кереп китәр иде. Сарыга түгел, бәлкем, аны алсу-кызгылт яисә сыек зәңгәр төскә буяргадыр. «Желтый дом» дигән исеме югалудан куркырга түгел. Халык телендә инде ул шушы исем белән мәңге йөриячәк.

Капка төбендәге эскәмиягә утырып, муен тирләрен кирәк була-нитә калса дип үзебез белән алган тастымалларыбыз белән сөрткәләп, бераз хәл җыеп алгандай булдык. Бер тора торгач, Әхәткә янә карап алам да, әллә бу кара мыеклы шайтан, башын юләргә салып, юри кылынамы, дип тә уйлап куям. Чөнки кайчак, син көтмәгәндә генә, сине аяктан егарлык, һуштан яздырырлык акыллы сүзләр әйтеп куя. Менә хәзер дә тиктомалдан гына:

— Син Габдулла Тукайның яңүд шагыйре Семен Липкин русчага искитмәле матур тәрҗемә кылган «Шүрәле»сен яттан беләсеңме? — дип сорап куйды.

— Каян белим ди инде. Татарчасын да баштан ахыргача хәтерләмим.

— Ә мин беләм! Сөйләп чыгыйммы соң?

— Тукта, чак кына сабыр ит. Бер кат баш-күз алыйк инде.

Әлеге өч катлы бинага кемнәрдер бик эшлекле кыяфәттә кереп-чыгып йөриләр. Яныбыздан, шарык-шырык көлә-көлә, бик чибәр ике кыз узып китте. Сагая калырлык, шикләнерлек берни дә күрмәдек. Заманында, безнең яшьлек чорында, бик популяр бер җырдан өзек китереп:

— Мы рождены, чтоб сказку сделать былью! — дип куйды Әхәт.

— Вот именно! — дип куәтләдем аны.

Без бар булган кыюлыгыбызны бер учка җыеп эчкә атладык.

Акылдан тайпылганнарны кабул итү бүлмәсендә безне Ходайның бирмеш көнендә якты йөз, җылы сүз белән каршы алдылар. Әйтерсең без аларның күптәнге танышлары, юллама кәгазьләребезне сузуга, Әхәт дустымны шундук өске катка алып менеп киттеләр. Мин тәрәз төпләрен зур чүлмәкләрдә гөлләр бизәгән фойеда калдым. Күпме көтәргә икәнен әйтмәделәр. Күпме көтәргә булса да көтәм инде. Җилкәмдә тегермән ташы утырмый, түзәрмен. Юлда укырга алган китабымны ачтым.

Иртәнге уннар-унберләр тирәсе инде бу. Өсләренә ап-ак халатлар кигән студентлар яшендәге ярау гәүдәле егетләр, биек үкчәле туфлидән чибәр-чибәр кызлар да кереп-чыгып йөриләр. Аларның араларында шушы хастаханәдә эшләүче табиблар, шәфкать туташлары, санитарлар да бардыр инде. Моңарчы мондый җирләргә эшең төшмәгәч, берсен дә танымыйм шул, бар үткән-барганга җиңелчә генә баш иеп, сәлам биреп утырып торам инде шунда.

Мин утырып торган бераз караңгырак фойега, үлчәүгә салсаң, кимендә йөз-йөз егерме килолар тартышлы, мәһабәт гәүдәле, сөйкемле, йөзен бераз чал кергән бөдрә сакал бизәгән бер ир уртасы чыкты. Башта тәмләп киерелде. «Ау-ау-ау!» — дип авызын чәбәкләп, иснәп алды. Өстендә моның шоп-шома итеп үтүкләгән ап-ак ефәк халат. Мин дә бит аз-маз булса да дөнья күргән егет. Бер карау белән чамаладым. Биредәге баш врачның үзе булырга тиеш бу. Ярады, нәкъ үзенә тап булдым. Мондый мәгъдән вә мәгърур гәүдәле ир баш табиб булмый тагын кем булсын? Гипноз, пациентларына психологик ысуллар белән тәэсир итү көче дә бардыр бу кешедә. Чөнки бер күрүдә үзенә ихтирам хисе уята, буйсынырга мәҗбүр итә. Башта тәмләп киерелеп, аннары ике күзен уып торганнан соң, мине күреп алды. Шундук миңа таба атлап, ачык йөз белән:

— Кай яклардан килмеш? Нинди гозер-йомышлар белән йөрмеш, туганкай? — диде. Тавышы да ягымлы. Йөзендә — кешенең хәленә керү, кирәксә, ярдәмгә әзер булу чаткысы.

— Бер бик якын дустым бераз гына чирләп киткәние. Менә шуны озата килгәнием. Хәзер генә өске катка алып менеп киттеләр. Алып калырлармы, әллә кире борырлармы? Шуның врачтан чыкканын көтеп утырам әле.

Әлеге сөйкемле ирнең йөзе тагын да ачыла төште.

— Нәрсә дип әле сез бу караңгы почмакта утырасыз? Әйдәгез, түрдән узып, менә бу палатага рәхим итегез. Биредә яктырак та, иркенрәк тә. Әйдәгез, әйдә, шикләнмәгез. Бездә берәүне дә тотып ашамыйлар.

«Ай, рәхмәт төшкере, менә бит нинди ягымлы, ипле кешеләр бар дөньяда!»

Әлеге ап-ак халатлы, матур сакаллы, кунакчыл ир артыннан чиста итеп җыештырылган палатага кердем. Тартынып, аяк очларыма басып кына. Керүгә палатада сигез карават санадым. Дүртесе буш. Аларына урын-җир дә җәелмәгән. Түрдәге ике караватта, буй-буй зәңгәр сызыклар төшкән яшел одеялларын башларыннан ук бөркәнеп, ике кеше йоклый. Авырулар микән соң инде? Палатаның дүрт як стенасында картонга, ватманга язып ябыштырылган бихисап күп рәсемнәр, сурәтләр, пейзажлар. Араларында бик зур осталык һәм зәвык белән ясалганнары да бар. Шәрә хатын-кызлар сурәтләрен аеруча җиренә җиткереп ясаганнар. Сокланып туймаслык. Монда соң әллә шәһәрнең танылган рәссамнарының күчмә күргәзмәсеме икән дип тә уйлап куярлык. Русның бик танылган рәссамы Кустодиевның картиналарындагы кебек мул күкрәкле, калын бәдәнле, авыр эштән дә чирканмый торган кыяфәтле шәрә хатын-кыз сурәтләреннән күзеңне алышлы түгел.

— Игътибарыгызны бүләм, әйе, әйе, безнең монда чын мәгънәсендә Кече Третьяковка! Анда булганыгыз бардыр бит? — Әлеге баш табиб дигәнем диварлардагы рәсемнәргә ымлады. — Гаҗәпләнмәгез, әнә теге буаз бурсык, шакмаклы одеял астында яткан йокы чүлмәге ясый аларны. Ул республикада бик танылган рәссам. Ничек, ошыймы картиналары? Әлбәттә, шундый шедеврлар ижат итәргә акыллы киңәшләрем белән үзем дә нык булышам. Шунсыз булмый...

— Ошамыйча! Мондый сурәтләрне төшерергә ай-яй зур талант кирәк. Әнә теге ат башы ничек матур чыккан. Авызыннан ялкын бөркеп, прәме ажгырып тора бит. Чын оста, профессионал икән!

Ишек катындагы ук карават астында кемдер берәү нидер шалтыр-шолтыр китерә. Караватының бушаган пружинасын тарттырамы соң? Янында үзеннән гайре беркем дә күренмәсә дә, вакыт-вакыт:

— Дайте семнадцатый ключ! Тринадцатый дайте! Отвертку суньте! — дип сорап куя, тозлап-борычлап унбиш катлы итеп сүгенеп ала.

Мине бу палатага дәшкән әлеге ап-ак ефәк халатлы ир калын-калын китаплар өелгән кечерәк кенә өстәл артына килеп утырды. Терсәккә кадәр кап-кара йон баскан юан беләкләрен як-якка җәеп тагын бер тапкыр тәмләп киерелде, тирән иснәп авызын чәбәкләп алды. Карават астында шыгыр-шыгыр яткан егеткә ымлап:

— Аңа игътибар итмәгез. Ул бит «болай»! — дип, бармагы белән чигәсенә бораулап күрсәтте. — Шизофреник! Аның да иң кискен формасы. Колхозда шофер булган. Акылдан шашуының да сәбәбе һич аңлашылмый: то ли на почве глубокого алкоголизма, то ли травмы головного мозга. Үзен һаман да машина ремонтлыйм дип тоя, күрәсең. Караваты астыннан көннәр буе чыкмый. Тик сүгенеп ята. Бар белгәне — «дайте семнадцатый ключ»! Хәер, чирле кешедән какой спрос? Жәлләп тә куям үзен. Күрше

Питрәч егете ул. Ике баласын ияртеп, ара-тирә хатыны да килеп киткәли. Аларны да танымый. Алардан да «семнадцатый ключ»не генә таптыра.

Шулай байтак кына сөйләшеп утырганнан соң, ак халатлы, күркәм йөзле әлеге ир уртасы нәкъ Карл Марксныкыдай чем-кара куе бөдрә чәчләрен артка сыпырды, «о-хо-хо-хо!» дип иснәп алды.

— Ә сез, иптәш, мине таныйсыздыр бит? — дип сорады ул кинәттән генә.

Маңгайга терәп биргән сорауга җавап бирми дә кала алмыйсың бит.

— Бераз төсмерләгәндәй булам, әлбәттә. Ялгышмасам, сез баш табибның үзе түгелме соң? Шулай бит?

— Буламмы соң! Алла сакласын! Ничек танымыйсыз инде? Мин бит Карл Маркс! Минем «Капитал» белән әллә бер дә таныш түгелме? Менә бу томнарны кем язды дисез? Мин яздым бит инде! Укымыйсыз шул. Менә шул томаналык, наданлык хур итә дә инде барчагызны.

Йә Ходай! Тәннәрем чымырдап китмәсенме? Мин баш табибтыр бу дип уйлаган әлеге чибәр ир уртасы кулларыма битләре тәмам саргаеп, тышлары таушалып беткән ике-өч калын китап тоттырды. Чытаеп калдым. Тәннәремә каз тәне чыкты. Каушап төшүдән иреннәрем дер-дер килә. Бу хөрмәтле Карл Маркс әфәнде бер-бер хәтәр нәрсә эшләп куймасын тагын. Аныcыннан сак булырга кирәк.

Ә ул, тавышын чак кына күтәрә төшеп:

— Бу чәчләрне әллә сез бер дә юкка гына агара дисезме? Шалишь, туганкай! Сыйнфый көрәш көннән-көн оборотларын арттыра. Ә чәчләрне шушы томнар өстендә төн йокыларымны калдырып утырып агарттым. Тәнемдәге каным да элеккегечә саф, чиста түгел инде. Мировой буржуазиянең мәкерлекләренә кем генә түзсен. Менә алар бозды канымны. Ә «Манифест»ны укыганың бармы? Аны да мин яздым бит. Төп тексттагы ижекләрнең ныклыгын күр син! Сандалга салып чүкеч белән чыныктырган ныклык белән яңгыйлар бит. «Европа буйлап Коммунизм шәүләсе йөри!» Шәп әйтелгәнме? Көчле әйтелгән! Шуны инкарь итеп кара син, әгәр дә кулыңнан килсә! Ул шәүләләр бүген бөтен Җир шарын сырып алырга тиешләр. Ә властьлар?! Шушы «Капитал»ым өчен мине рәхимсез эзәрлеклиләр. Тотып Шлиссельбург крепостена ябарга да күп сорамаслар. Андагы салкын, юеш казематларда минем өчен генә бер урын табарлар. Ләкин тотмый гына торсыннар әле. Шуңа күрә дә, башымны тилегә салып, шушы диваналар арасында ятам бит инде. Ләкин бу турыда син беркемгә дә сөйли күрмә, яме. Безнең сафларда строгая партийная дисциплина! Тсс! Конспирация!

— Сөйлимме соң, иптәш кем, ни... Карл Маркс, булмаганны! Үлгәндә дә беркемгә бер сүз ычкындырасым юк. Тыныч булыгыз. Мин серне тота беләм.

Күзем ишектә генә. Ул-бу хәл килеп чыкканчы, исән-имин чагымда миңа моннан, үз аягым, үз кулым белән дигәндәй, чыгып ычкынасы иде. Карават астында яткан егет тә, «семнадцатый ключ»не, таләпләрне бик катгый куеп сорый башлады. Үзем дә бер пешмәгән нәрсә инде мин. Ни дип кенә кердем соң мин бу бүлмәгә? Утырып торган җирем ипле генә иде бит. Иң тиле, тавык мие эчкән, өстәвенә дыңгычлап буш кибәк тутырган баш биредә мин үзем бугай. Әйе, кайчакларны үз-үземә шулай катгый каты бәрелсәм дә, бик кирәк чакларымда минем бу тубалым искитмәле тәвәккәллек, зирәклек тә күрсәтеп куя. Менә хәзер дә кылт итеп кенә акыллы фикер тудырды. Мин шундук, чыраемны әрем бәлеше капкандай чытып, эчемне уа башладым.

— Иптәш Карл Маркс... ни бит, туалет дигән нәрсә сезнең монда бардыр бит? Бик ерак түгелме? Кһм, кһм! Мин бик ямьсез кыстала башладым бит әле, әй. Кәһәр генә икән!

— Ничек булмасын инде?! Пожалысты, фойега чыгасыз да коридор буйлап теге башка атлыйсыз. Кыю рәвештә. Ишеге уңда булыр. Җылы су уң як кранда.

Үзен хөрмәтле Карл Маркс дип таныткан әфәндем (аның чып-чын Маркс булуына минем шигем дә калмый башлады, чөнки ул аңа бик охшаш) куе кара йон баскан юан беләген күзләренә якын китерде. Швейцария маркалы кыйммәтле сәгатенә бакты.

— О-о, пардон, пардон, хөрмәтлем! Сезнең белән мавыгып мин халыкара күләм дәрәҗәгә ия чарабыз турында онытып җибәрә язганмын. Биш минуттан безнең Конгресс башлана. Ә мин анда төп докладчы. Гафу, гафу! — дип, миннән дә алдарак каядыр ашыкты. — Ә сез бер дә борчылмагыз, әнә теге буш караватларның берсенә җәймә җәегез дә бераз ятып торыгыз. Ә шофер егеткә игътибар итмәгез, санитарлар кереп күтәреп салмасалар, караваты астыннан ул хәтта төнлә дә чыкмый.

Туалеттан да исән-сау әйләнеп килсәм, бу палатага янә керәмме соң инде мин, җүләр! Әхәт дустымны өскә алып менеп киткәннәренә инде байтак. Тагын күпме тотарлар икән? Тотып кына сорар, белешердәй бер кеше күренми. Ак халатлы, күзлекле, кара мыеклы кешеләр янымнан тыз да быз узып-узып киткәлиләр. Болары да Карл Маркс йә Энгельс, йә Штирлиц булып куймагайлары. Белмәгән, танымаган кешегә сүз катарга да шикләнәм. Нишләргә дә аптыраш. Әллә шәһәргә чыгып бераз йөреп керергәме? Алай итсәң, Әхәт белән аймылыш булырбыз дип куркам. Монда, ишек катында утыру да шикләндерә башлады.

Поезддан килгәндә гел Әхәткә күз-колак булып, черем дә итмичә килеп, мондагы әсәрләнүләрдән дә тәмам арып, мәлҗерәп утырганда, өске каттан, үз-үзенә ышанычлы җитез адымнар белән атлап,

төсле күзлеген кулына тоткан ак халатлы бер ир төште. Туп-туры миңа таба атлап, каршыма ук килеп басты.

— Борһановны бирегә озата килүче сезме? — диде.

— Әйе, бергә килдек. Без бик күптәнге дуслар. Университетта да бер елларны укыганыек. Хәзер бер шәһәрдә яшибез. Күрешеп, аралашып торабыз. Дөнья бәясе ипле, әдәпле егет ул. Хәле ничек соң? Тоттык та менә сезгә килдек инде. Соңармаганбыздыр бит?

— Әлегә тирән хафага төшәр җир юк. Дустыгызда җиңелчә генә акылдан тайпылу галәмәте. Җирле табибларыгыз диагнозны дөрес куйганнар. Акыл хезмәте белән көн итүчеләр арасында була торган хәл.

— И-и, доктор әфәнде, Әхәт дустым нинди егет иде бит! Компьютер хәтерләре бар иде үзендә. Менә шул артык хәтерле булу да харап итте бугай инде аны. Дәвалап була торгандыр бит? — дип, әлеге докторның сүзен бүлдердем. Хәтта үземә дә уңайсыз булып китте.

— Нигә булмасын? Медицина елдан-ел алга атлый, берсеннән-берсе көчлерәк препаратлар чыгып тора. Әмма Борһановны берәр айга алып калырга булдык. Күп дигәндә ике ай эчендә янәдән аякка бастырырбыз. Авыруның хатыны, балалары бармы?

— Бар, бар. Гаиләсе бик тату. Хатыны — шәфкать туташы. Бер улы, бер кызы бар. Әйтәм бит, дустым феноменаль хәтерле иде. Шахматны синең белән күрше бүлмәдән торып уйный. Ә Советлар Союзы Маршалы Г.К.Жуковның «Мемуарлар» китабын битен-биткә яттан белә. Кайсы битләрдә кайсы сугыш операцияләре язылуын уйлап та тормыйча әйтә дә бирә. Китапның шул битен ачып карыйсың, нәкъ Әхәт әйткәнчә була. Нәрсә генә булды инде аңа? Болай эшендә дә тәртип. Берәрсе белән бер дә юктан гына конфликтка кереп китә торган гадәте дә юк. Хатыны белән дә бик тату яшиләр.

— Нәкъ менә шундый феноменаль хәтерләләр еш кына саташып киткәлиләр дә. Һәрхәлдә, ми системасын артык көчәнеш белән эшләтүдән түгел моның сәбәпләре. Чөнки кеше миенең мөмкинлекләре чиксез. Көтмәгәндә генә шулай акылдан тайпылып китүләрнең нигезендә, бәлкем, экологик сәбәпләр ятадыр. Без — җир балалары — җир йөзендә артык шапшак, пычрак яши башладык. Җиңел формадагы шизофрения, һәрхәлдә, шыр тилегә калып, акылдан тәмам язу түгел. Дәвалана торган очрак. Методикасы да сыналган, әйтәм бит, даруларыбыз да көчле. Борһановыгызны тиз көндә аякка бастырырбыз.

Әлеге доктор, миңа төбәлеп карап торганнан соң, авыз чите белән генә елмаеп алды:

— Беләсегез килсә, без барыбыз да беркадәр шизиклар. Берәүдә чак кына, икенче берәүдә көчлерәк. Артык нәфеслек, кирәкмәгән көнчелек сыйфатлары һәркайсыбызда чагылып-чагылып куя. Берәүләрнең сандык төбендә ул шым гына гомер буе ята. Икенчеләрдә тышавын салган айгыр кебек уйнаклап ала. Стресслар белән тулы заман, кыйбласыз яшәү рәвешебез, экологик пычраклык һәркайсыбызның сандыгында яткан шизофрения чүпрәсенең вулкан булып уянып куюына сәбәпче була да куя. Гаиләсенә дә әйтегез, артык борчылып тормасыннар. Ике ай дигәндә иптәшегезне кеше итәрбез. Үзе дә болай күндәм, тәртипле егеткә охшый. Андыйларны дәвалау да җиңел. Ә сез кайтып китсәгез дә була.

— Бик рәхмәт инде, доктор әфәнде. Бу җылы сүзләрегез өчен мең рәхмәт! Карагыз әле, доктор әфәнде... Менә ни бит... Фамилиягезне әйтмәдегез. Сез... Юлий Цезарь яисә Бонапарт Наполеон түгелме? Мин монда сездән алда гына Карл Марксның үзе белән таныштым. Байтак кына вакыт матур гәп корып тордык.

— Мин медицина фәннәре кандидаты Дамир Динмөхәммәтов, шушы матур учреждениенең шизофреник авыруларны дәвалау бүлеге мөдире булам, — диде дә көлеп тә җибәрде. — Әйе, авыруларыбыз арасында Наполеоннарыбыз да, Чыңгызханыбыз да, хәтта Фидель Кастробыз да бар. Ярый, хәзергә хуш иттек!

— Абау, доктор әфәнде, бу сүзләрем белән сезне рәнҗетмәдемме соң? Тәмам башым каткан хәлдә утырам бит. Бер минутка гына туктагыз әле, Дамир әфәнде... Сезгә берәр бүләк, яхшы кул сәгатеме, япон зонтигымны алып керим. Ул кадәресе генә безнең өчен бер проблема түгел... Сметага кертелгән расхут, кыскасы...

— Анысы нигә тагын? — Доктор әфәнде кире борылды, каршыма басты. Бу юлы миңа да профессионаллар карашы белән төбәлде. Янәсе, мин дә өлгереп җиткән шизик түгелме, Әхәт белән бергә мине дә алып каласы түгелме? Текәлгән карашыннан шуны сиздем. Күзлеген киде, ике кулы халаты кесәсендә. Бик чибәр кеше бу. Ияк очында аның йөзен бизәп, баетып торган уймак хәтле генә чокыр бар.

— Дөресен әйтәм, кырык биш яшемә җитеп, Дамир әфәнде, моңа чаклы хастаханәгә юлым төшмәде. Әмма хәзер бар халык, табиблар авыруларыннан кыйммәтле бүләкләр өмет итәләр икән, дип сөйлиләр. Без дә бу юлга кесәбездә сукыр бер тиен акчасыз чыкмадык. Әхәт дустымны дәвалый гына күрегез. Бүләгеннән тормабыз. Эшләгән җиреннән дә җитәкчеләре мине шулай дип кисәтеп җибәрделәр. Бүләкнең бәясеннән торма, диделәр. Терелтә генә күрегез.

Сизәм, сизәм, күз карашыннан аңлашыла, доктор миңа да бу кешедә шизофрениянең әле башлангыч стадиясе генәме, әллә инде бүген үк дәвалый башларга вакытмы дип карый. Шул ук

вакытта аннан кешеләрне ялгышлары өчен кичерү, гафу итә белү сымак ниндидер бер җылы энергия килә. Ирен читләрен уйнатып алды.

— Чынбарлык күзлегеннән караганда, бүләк начар нәрсә түгел. Әмма аның бер уңайсыз ягы бар...

— Юк, юк, доктор әфәнде. Минем өчен бернинди дә уңайсызлыгы юк. Мин ихлас күңелдән. Унбиш минуттан әйләнәм дә керәм. Тик күңелегезгә ошаган әйберне генә әйтегез. Кирәксә, япун фотоаппараты алып керәм... Андый гына расхутларны юлга чыкканчы ук керттек, әйе. Сметасы расланган...

— Уңайсызлык менә нәрсәдә, хөрмәтлем. Бөек Гиппократ хәзрәтләренә мин антымны «авыруларны кулымнан килгәнчә дөрес дәвалармын, рәнҗетмәмен, җәберләмәм, шәфкать вә мәрхәмәтле булырмын» дип бирдем. Мине беркем дә мәҗбүр итмәде. Антны үзем бирдем. Ант текстында сез тәкъдим итәргә җыенган япон фотоаппараты турында бер сүз дә юк. Әлеге вәгъдә җилкәгә шулхәтле авыр йөк сала. Йөк чыннан да авыр. Аны ташларга да булыр иде. Аннары нинди йөз белән яшибез? Кешеләр күзенә ничек карыйбыз? Ә мин таныш-белешләремә, әңгәмәдәшләремә менә шулай төбәп карарга өйрәнгән. Яшәү рәвешем, һөнәрем шундый. Антны-вәгъдәне, әгәр кулыңнан килмәслек булса, бирмәскә генә. Бирдеңме, авыз-борыныңнан кан тамсын, тугры кал. Башкача чишелеш юк, хөрмәтлем, — диде дә, кинәттән генә нәрсәнедер исенә төшергәндәй сискәнеп, маңгаен уа-уа өске катка таба атлады.

Мин дә:

— Ah, kahәр, ничек тактсыз кыландым бит, доктор әфәндене рәнҗеттем, яшь арткан саен акыл чыга гына бара! — дип, үземне орышып алдым. Үземә соң шундый тәкъдим ясасалар, рәнҗеməс идемме? Эш дәверендә ришвәт төртергә маташучылар миңа да булгалады. Булды, булды... Намусыма тап төшермәдем шикелле...

Ришвәт алучыларны җенем сөйми дип кенә калмадым. Миңа ришвәт төртергә маташучыларның кайберләренең колак төпләренә дә үрелгәләдем. Барысының да түгел, бер әйтү белән аңламаганнарының. Чөнки җирәнгеч күренеш бит!

Шулчакмы?! Күрәселәр алда булган икән әле. Каршы яктагы бүлмәнең ике канатлы ишеге, чак кына шыгырдап, ике якка ачылып китте. Дәүләт Думасы депутатларың бер читтә торсын, әлеге бүлмәдән бик тә эшлекле кыяфәтле, кайсы ияк астында гына калдырган кыска сакаллы, кайсы шопшома пеләш башлы, кайсы күзлекле, кайсы таякка таянган, ә кайсы коеп куйгандай киң күкрәкле, спортчылардай төз гәүдәле егерме-утызлап ир-егет, һәркайсы Фәннәр академиясенең президиумында гына утырырлык мәгърур килеш-килбәтле агайлар чыкты.

Чын әгәр, бу агайларның ниндидер бик җитди киңәшмәдән чыгулары булса кирәк. Боларның берсе дә акылдан тайпылганнарга, тиле башларга охшамаган. Килеш-килбәтләре дә президентларныкыннан мыскал ким түгел. Аяк атлаулары да шик-мазар тудырмый. Кулларын да кирәксезгә бутамыйлар. Кемнәр генә булсалар да, бик эшлекле, җитди кешеләр болар. Кем белә, бәлкем, бүген биредә медицина мәсьәләләренә кагылышлы Рәсәйкүләм симпозиум-мазардыр. Бу халыкның шуның утырышыннан чыгуларыдыр. Тукта, тилеләр мөгезле булмый, дип бер дә юкка гына әйтмәгәннәрдер...

Абау! Чү! Әллә миндә галлюцинация, күз алмашу, күз буылу галәмәтләре башландымы? Бүлмә эченнән ап-ак халатлы, тулы гына гәүдәле бер чибәр ханымны җиңелчә генә, әмма үзенә бер дәрәҗә белән култыклап, баягы танышым Карл Маркс әфәнде — «Капитал»ның авторы чыкты. Юк, юк! Тагын бер кат юк! Миндә галлюцинация башланды. Кап-кара чәчле, ап-ак халатлы ханым Клара бит! Моның булуы мөмкин түгел. Әмма нәкъ үзе. «Ышанма күргән күзеңә, ышан минем сүземә!» — нәкъ менә шушы очрактыр инде. Әмма бу ханым мин моннан унбиш еллар элек белгән коры сөякле леди Кларадан чак кына калынрак. Аны тагын да чибәрләтү хисабына. Башын горур тотуы, сөйкемле күз карашы шул ук. Тавышы да шул ук. Чак кына тыңкышлыгы сизелә. Карл Маркс белән ипле генә гәп корып торалар. Иллюзия түгелме бу?! Ни-нәрсә турында баш ватсыннар инде тагын, барча илләрнең пролетарийларын берләштерү проблемалары турындадыр инде. Берләшеп җитә алмыйбыз бит һаман. Кларaның аягында очлы борынлы, биек үкчәле кап-кара туфли. Теге чакларда киноoператор егет Лева Симонов массаж ясаган төз, матур балтырлар. Леди Кларaны аны йөз ханым арасыннан да шундук танып алырга булыр иде. Шул төз, станокта махсус кырып ясаган балтырларыннан.

Галлюцинация кичерәмме дисәм дә, юк, чынбарлык кочагында мин. Алдымда — Клара нәкъ үзе. Булса соң! Бәлкем, ул да, матурым, чирләп киткәндер. Рәссамнар — бик җитди һөнәр ияләре. Ижади тормышларында чәчәк аткан чорлары була. Кризис та кичерәләр. Ул зәхмәтне кем ничек кичерә. Берләре эчәргә керешәләр. Бу кризистан бүтән чыга алмам, мин инде беткән, югалган зат дип, үз-үзләренә кул салучылар да була. Әдәбият, сәнгать, музыка өлкәсендә моңа мисаллар санап чыккысыз. Әнә Эрнест Хэмингуэй күпме романнар язганнан соң нинди тирән психологик кризис кичерә. Җиңә алмый, барьерның теге ягына атлыйсы гына да бит. Юк, үзендә көч тапмый, үзенә кул сала. Берәүләр кризис кичерә башлагач җиңелчә генә акылдан тайпылалар. Бер дә гаеп түгел. Клара да бирегә шулай эләксә инде.

Кинәт ул үзе дә, кулын каш өстенә куеп, мин утырып торган колонналы почмакка текәлебрәк карап алды. Бу караштан мин урындыгыма сеңәргә, боз булып эрергә, эфир булып һавага очарга әзер идем.

Ә ул:

— Мама мия! Убейте меня, я не верю своим глазам! Первейший ас советской журналистики, Ленар, дорогой мой Ленар! Бу чынлап синме соң? — диде дә яшен угы тизлеге белән каршыма ук килеп басты. Бәрхеттән йомшак бармаклары белән битемнән сыпырды. — Ленар, син бит бу! Син, син бу! Минем сине бик күрәсем килгән иде. Нинди җилләр ташлады сине монда? Ни генә булса да, күрешүебезгә мин бик шат. Безнең хастаханәгә күренергә генә, әллә ятарга ук килдеңме? Нинди генә йомыш белән килсәң дә, решим самым лучшим образом.

Клара ике кулымнан тоткан хәлдә яныма утырды. Бераз салкынча, әмма ташны эретә торган җылылык белән яңагын яңагыма куйды.

— Это я беру на себя! Ле-на-ар! Сколько лет, сколько зим! Мондый ситуациядә, ты прости меня, дорогой, мин үземне ничек тотарга белмим. Но я очень соскучилась по тебе, старик. Батюшки! Радость-то какая. Счастье какое!

Клара әле бер хәл. Менә мин үземне ничек тотарга белмим. Кочып кына аласы да иде үзен... Стоп! Авызың пешмәсен... Бер-бер хата эшләп ташламагаем дип, үземне башлап сүз катарга авыз ачудан тыеп утырам. Тыймаска соң. Әлеге кап-кара бөдрә чәчле, баш табиб кыяфәтле ир уртасы «Капитал» авторы булгач, Клара монда кем икән? Иран шаһинәсеме, әллә Маргарет Тэтчермы? Ялгыш адымнар ясаудан Ходай берүк мине үзе саклый күрсен.

Ни генә булса да, бу гөнаһсыз сөйкемле җан шулхәтле сагынылган. Бу очрашуга мин дә чиксез шат. Кларадан да сагыну хисе бәрелә. Мин аны бөтен тәнем, җаным белән тоям.

Клара, күзләремә туры карап:

— Ленар, кадерлем, син бирегә ничек килеп чыктың? Әллә минем монда икәнне берәрсеннән ишетеп, белеп, эзләп килдеңме? — Ул янәдән яңагын минем яңагыма тидерде. Битеннән бик затлы пудра исе килә. — Әле студиядә эшләгән чакта ук шушы курнос борын очыңны учларыма алып уасым килә торган иде. Ул чакта ничектер батырлыгым җитми иде. Менә хәзер рәхәтләнеп уам. Чөнки мин сине бик-бик сагындым. — Аннары ул, кинәттән генә туктап, йөземә төбәлеп: — Син биредә бер-бер диагноз белән түгелдер ич? — дип сорады. — Алай булса да, борчылма, үзебезгә ипле, уңай якка хәл итәрбез.

«Үзең соң, җанашым, биредә нинди диагноз белән? Шуны әйтсәңче?» — дип бик сорыйсым килә дә, тел әйләнми.

— Төрле факультетларда булса да, заманында университетта бергә укыган бик якын дустым бераз чирләп китте. Шуны озата килдем.

— О-о, алаймыни? Ул дустың кая соң әле? Фамилиясе ничек? Сезне кем кабул итте? Безнең монда дөньякүләм танылган психотерапевт, медицина фәннәре кандидаты Динмөхәммәтов эшли. Дамир Харисовичны лекцияләр укырга Берлин, Лондон, Хельсинки клиникаларына чакыралар. Без аның белән бик тату, дуслар.

— Дустым Әхәтне нәкъ менә шул доктор кабул итте бугай инде.

— Ул чакта сөенергә генә кала. Башы акыллы, күңеле киң, куллары җиңел, дустыгызны тиз арада сафка бастырыр. — Клара хуш ис бөркеп торган йомшак куллары белән ике битемнән чәбәкләп алды. — Ленар, дорогой мой человек, бу чынлап та синме соң? О-о, Ходай, рәхмәт сиңа бу шатлыклы көнең өчен! Ә син шатмы соң, керпе чәч? Казанга кайткач мин сине бик еш искә төшердем. «Шушы минутларда янымда Ленар булса, миңа ничек җиңел булыр иде!» дип сыкранган чакларым күп булды. Кая, карт сөякләрең шатыр-шотыр килгәнче кочыйм әле бер үзеңне. Мөмкиндер ич? — дип, тәмле иннек-кершән яккан битен кат-кат минем битемә тидерде.

Үземә дә кочып кына аласы бит... Кирәк иде югыйсә...

— Башкалабызга да бер дә килми-китми тормагансыңдыр инде. Шунда ник бер шалтыратсаң? Әллә синең монда миннән башка да «татар маржаларың» бармы? Ярар, үпкәләмим. Үткән эшкә салават, диләрме әле?

Минем үземә дә күзле бүкән булып күпме утырырга була? Кларaны исән-имин күрүемә чиксез шат булуымны раслап, бер-бер адым ясау бик кирәк. Шулай икәнне дә бик аңлыйм. Һаман да теп-тере Карл Маркс әфәнде белән очрашудан алган тәэсирләремнән айнып бетә алмыйм. Ә Клара ханым Жанна д'Арк булып чыксa? Мин — Индира Ганди, дия башласа?..

Тирәбездән гаять эшлекле кыяфәттә әрле-бирле узып йөрүчеләр (әлбәттә, аларның күбесе биредә дәвалануучылар) безгә игътибар итә башладылар. Ике-өче, Дон елгасы далаларында скиф кабиләләреннән үк калган таш балбаллар төсле, кулларын күкрәк өсләренә куеп, каршыбызга ук килеп бастылар.

— Менә озак еллар күрешмәгән бертуган абыем көтмәгәндә генә Ташкент якларыннан килеп чыкты. Узып барышлый гына минем янга да сугылган. Мәскәүгә үтеп барышы, — диде аларга Клара.

Аның бу сүзләреннән мин тагын да көчлерәк шикләнә калдым. Клара үзе дә авыру икән бит. Биредә дәвалана торгандыр. Мине ни өчен Ташкент якларыннан диде? Минем анда гомердә булганым юк. Мәскәүгә дә җыенмыйм.

— Син минем бу сүзләремнән гаҗәпкә калгансыңдыр инде. Безнең биредә шундыйрак реалияләр. Бу нарасыйлар — барысы да минем авыруларым. Аларның барысы да патологик рәвештә миңа гашыйклар. Барысы да коточкыч көнчеләр. Җиңелчә акылдан язган бичараларның барысына уртак сыйфат, ягъни диагноз бу. Алар барысы да телевидение, радио дикторларына гашыйклар. Хат арты хат яудырып аларны тәмам аптыратып бетерәләр. Мондый хат авторлары белән бик сак булырга кирәк. Соңыннан алар үч алырга да күп сорамыйлар. Минем группамдагы авыруларның «һәркайсы Клара ханым тик аңа гына гашыйк, тик аны гына ярата» дип уйлый. Миңа исә менә шул юнәлешне бик төгәл тотарга туры килә. Үзеңне шулай тотмасаң, бу гениялар арасында эшләп тә булмый. Әгәр инде көнләштерә-нитә калсаң, күп сорап тормыйлар, тоталар да буып үтерәләр. Аларның бит һәркайсы үзенә бер Мавр, ә мин һәркайсы өчен Дездемона. Әлегә, Аллага шөкер, андый конфликтка барып җиткән юк. Чөнки күрәләр, мин аларның барысына да тигез игътибарлы, барысын бер дәрәҗәдә ихтирам итәм. Яшермим, һәркайсына беркадәр гашыйк та әле. Минем группамда үзен Карл Маркс дип йөрткән бер авыруым бар. Ох, какой красавец-мужчина! Интеллигент, умница!

— Биредә дәвалангач, умница буламы инде? — димичә кала алмадым.

Клара, матуркаем, белсәң икән син минем хәлемне. Мин бит берсе өстенә берсе бик рәхимсез төстә очлы-агулы уклар яудырып торган уйлар-хисләр дөньясында мәлҗерәп утырам. Кайтарып кына сорарга да кыюлыгым җитми.

— Үзең әйткәнчә, бу «генийларың»... ничек синең авыруларың була инде? Син соң кем монда? Академик Виноградов яисә академик Амосов түгелсеңдер ич!

— Ленар! Тел үтергеч синдә. Төрттереп кенә калмыйсың, прәме касыкны уеп аласың, — дип, Клара көлеп җибәрде. — Әлегә Жанна д'Арк та түгел. Мин монда, Ленар, кадерлем, ун ел инде психолог булып эшлим. Игътибар ит, психиатр түгел. Ә психолог. Алар мандарин белән апельсин дәрәҗәсендә генә түгел, бу һөнәрләр бер-берсеннән бәрәңге белән помидор дәрәҗәсендә аерылалар. Понимаешь менә, дружище? Мин авыруларымны таблеткалар, уколлар белән түгел, ә җылы сүз, ихтирамлы мөгамәлә, аларга ошаган комплиментлар яудырып дәвалыйм. Кыскасы, безнең үз методикабыз.

— Психолог? Син бит бик талантлы рәссам идең. Матур язу, каллиграфия королевасы! Медицина институтын да тәмамлап алдыңмыни? Булдыргансың.

— Юк, юк. Институт тәмамламадым. Психоневрология диспансеры игълан иткән конкурсларда катнашып, өч турда иң күп балл җыйдым. Монда аның бер сүз белән генә һич аңлатып бирә алмаслык нюанслары күп. Баштарак бик кыен булды. Биредәге контингентны үзең күрәсең. Авыруларым барысы да укыган кешеләр, интеллигентлар, бер сүздән үпкәләргә торалар. Берни булса, чәчләрен йолкып елый башларга да күп сорамыйлар. Араларында зур түрәләр булганнары, үзләре табиблар, рәссамнар, шагыйрьләр, композиторлар, сәхнә йолдызлары бар.

— Барысында да «тихое помешательство»мы? Вәйт сиңа замана!

— Әйе шул, — дип елмайды Клара. — Анысын каян беләсең?

— Минем дустыма да шундый диагноз куйдылар.

— Безнең Карл Маркс әфәндебез — атаклы физик-математик. Космик цивилизацияләрне өйрәнү институтында бүлек мөдире. Фәннәр кандидаты. Моңа кадәр берәүнең дә теше үтмәгән бер тигезләмәне чишеп биргән. Чишкән дә тайпылган. Бәлкем, миенә көч килгәндер. Елына ике-өч тапкыр дәваланып чыга ул бездә. Әнә тегесе — тәрәзә алдында басып уйга калганы — мәшһүр композитор. Бик эрудицияле шәхес. Кызы белән хатыны авиакатастрофада һәлак булганнар. Популяр рапсодияләр, сюиталар, бик җылы яңгырашлы симфонияләр авторы, нечкә күңелле шәхес бу кайгыны ничек күтәрсен? Аның миенә көч килүгә шул вакыйга сәбәпче булгандыр. Ул да елына бер-ике мәртәбә җиңелчә генә ычкынып куя.

— Клара ханым...

— Матурым диген әле, Ленар, — дип бүлдерде мине Клара. — Студиядә эшләгәндә син миңа гел шулай дәшә идең. «Татар марҗасы» дип дәшүең дә ошый иде.

— Син бу авыруларыңны ничек дәвалыйсың? Мин аны күз алдыма да китерә алмыйм. Карл Маркс әфәнде белән бая аз гына танышырга өлгердем. Тәнем хәзер дә чымырдап тора...

— Дипломсыз табиб башың белән дисеңме? — дип елмаеп алды Клара. — Аның махсус методикасы бар. Ул Психиатрларның халыкара ассоциациясе тарафыннан кат-кат расланган. Аларга ел саен яңа рекомендацияләр өстәп торалар. Медикоментоз ысуллар, таблеткалар, порошоклар, уколлар белән дәвалауга мин катнашмыйм. Аларын психотерапевтлар эшли. Минем алда һәр авыру белән иң җылы мөнәсәбәтләр урнаштыру бурычы тора. Аның белән уртак тел табу. Ул үзен икенче сортлы зат, вагоннан төшереп калдырган пассажир итеп, ягъни акылдан тайпылган зат итеп хис итмәсен. Аның мие, беренче чиратта күңел түре, төрле шик-шөбһәләрдән азат булсын. Минем пациентларым мактауга, җылы сүзгә бик мохтаҗлар. Бигрәк тә кризис кичергән чорларында. Дүрт-биш яшьлек балалар акылы аларда: юктан үпкәлиләр, ярсып елыйлар, кәҗәләнәләр, андый чакларында муеннарына элмәк кияргә дә күп сорамыйлар. Нәкъ менә шушы вакытта җылы сүз, ихтирам, эчкерсез дуслык хисләре белән авыруның хәленә керү иң нәтиҗәле дәва. Шул ысуллар белән кризисны бергәләп уздырып җибәреп,

нормаль акылларына кайтырга ярдәм итәргә кирәк. Монысы нәкъ менә минем бурыч. Алар барысы онытылып рәсемнәр ясарга яраталар. Ә бит аларның күбесе бирегә эләккәнче кулларына пумала да тотып карамаганнар. Ә без хәзер бер дигән пейзажлар, искитмәле натюрмортлар, коеп куйгандай автопортретлар ясыйбыз. Араларында профессиональ күргәзмәләргә куярдайлары бар.

Үз группамдагы егетләремне кул эшенә, калфаклар, шарфлар, перчаткалар бәйләргә өйрәттем. Безнеңчә ул хезмәт терапиясе белән дәвалау дип атала. Ни гаҗәп, кул эшен барча авырулар да яратып эшлиләр. Бу чакта бүлмәдә тын гына матур көй агыла. Авыруларым, бу минутларда үзләренең кайда булуларын бөтенләй онытып, бәйләү бәйлиләр, чигү чигәләр. Өйдәге якыннарына бүләкләр әзерлиләр. Бәйләгән калфаклары йә шарфлары күршесенекеннән кайтышрак чыкса, бу балакайлар тәмам хафага төшәләр. Андый чакларда әлеге шарфларны, перчаткаларны бергәләп тиешле кондициягә җиткерәбез. Шундый чакта аларны мактап та җибәрергә кирәк. Әлеге дәвалау сеанслары вакытларында мин аларга дөнья корифейлары, кешелек цивилизациясенең үсешенә, бүгенге үрләрне яулауга керткән өлешләре, аларның сикәлтәле тормыш юллары турында сөйлим. Бөек композиторлар, рәссамнар, танылган артисткалар, математиклар, компьютерщиклар. Нобель премиясе лауреатлары турында кызыклы лекцияләр укыйм. Мондый лекцияләрне алар аеруча яраталар. Чөнки аларның һәркайсы үзен даһи саный. «Даһилык» диагнозы — күпчелек авыруларыбызның төп чире. Котдус Шәрипов әфәндедә шул диагноз. Үзен сезгә Карл Маркс дип таныткан бит инде. Даһилар — даһилар, үзләренә тиңнәр турында сөйләгәнне яраталар. Ә минем максатым ачык — пациентларымның психик авырулар булуларын оныттыру. Чөнки аларның күпчелеге бирегә эләгүләрен, биредә дәваланулары бик авыр кичерәләр. Кризистан чыгу чоры, терелү процессы башлангач хәл кыенлаша.

— Мин бик аңлыйм аларның хәлен, — дидем. — Дураку все по колено, дибез дә. Акылына кайткач нишләргә? Менә үзебезнең Әхәт тә нишләр? Бик аңлаешлы ситуация. Гаиләң, балаларың, якыннарың бар бит әле...

— Терелгәч, аякка баскач, аларны өйләрендә, эш урыннарында ничек каршы алырлар? Нинди бюллетень бирерләр? «Тихое помешательство» яисә шизофрения дипме? Почмакка җыйналышып пышын-пышын килмәсләрме? Аңа бармак белән төртеп күрсәтеп, авызларын томалап кына көлмәсләрме? Алар өчен чын проблемалар терелә башлагач туа. Моннан иң җиңел юл белән котылу өчен нәкъ менә шушы чорларда муеннарын элмәккә тыгарга тырышучылар булып тора. Минем методикам бу бичараларга нәкъ менә шушы этапта ныклы ярдәм итә инде. Контингентымның күңелләрен күтәрү, кирәкмәгән фикерләрен башларыннан чыгару өчен лекцияләремне конгресс, съезд, пленум, форум, симпозиумнар дип атыйм. Минем группа егетләренең дә күбесе, авырып киткәнче, шундый дәрәҗәле форумнарда, симпозиумнарда катнашканнар, чыгышлар ясаганнар. Дәрәҗәле конференцияләрнең президиумнарында утырганнар. Шуңадыр минем бу методикамны алар аңлыйлар, килештерәләр, чыгышлар ясыйлар, әлеге симпозиумнарда теләп катнашалар. Ленар! Ленар, дим. Яратып, үз итеп текәлебрәк кара әле миңа. Миндә андый-мондый шиклерәк үзгәреш сизелмиме? Сөйләгәндә, ялгышып кына булса да, мин үзем дә Казан ханбикәсе Сөембикә булам бит дип ычкындырмадыммы, әй? — Клара, ике бит уртасындагы, мине үзенә гашыйк иттергән чокырларын тагын да тирәнәйтә төшеп, тигез, ап-ак тешләрен күрсәтеп елмаеп алды.

Каһәр, чак кына олыгая төшү аны тагын да чибәрләткән. Конфетка ул бүген! Аның да иң татлысы, иң затлысы! Үзе белә микән шуны?!

— Туберкулез белән авыручыларны дәвалаган табибларның кох таякчыкларын үзләренә йоктыру очраклары сирәк. Тиешле саклык чараларын да төгәл үтиләр булыр. Ә менә психик авыруларны, шизикларны дәвалаучылар гомерләренең ахырына үзләре дә беркадәр тайпылып, шизикка әйләнеп өлгерәләр, дип үзара шаярып сөйләшәләр безнең өлкән профессор агаларыбыз. Ленар, мин дә бу соравымны вполне серьезно бирәм. Миндә бераз серлерәк отклонениеләр күрмисеңме? Күрсәң, яшермә, по-дружески, по-братски, по-тугански, дөресен әйт, будь откровенен, друг.

— Беләсеңме, яшермим, сине Карл Маркс белән күргәч, Казан ханбикәсе Сөембикә бит бу, нәкъ үзе бит дип шикләнгәнием. Дөресен генә әйткәндә менә хәзер дә әле ни теге, ни бу якка төпле генә карар чыгарганым юк... Әмма сине күрүемә бик шат, бик шат, матуркаем. Казан ханбикәсе булсаң, мин Сәхибгәрәй булырга әзер...

Клара шунда, кырт кисеп:

— Кара, нәрсә соң әле мин һаман үзем турында гына сөйлим? Ленар, очень дорогой мой человек, син ничә көнгә килдең? Кайда тукталдың? — диде.

— Килүен бүген генә килдек. Әхәтне күрсәтермен дә, алып калсалар, калдырырмын, кире борсалар, аны иртәп кичке поездга утырырбыз дип тора идем.

— Алып калдылар булды инде алайса. Доктор Динмөхәммәтов — бик көчле белгеч. Консультацияләр ясарга аны Берлин, Лондон клиникаларына дәшәләр. Бу докторның иң көчле ягы — авыруларын ихтирам итә! Җылы сүзе, кешеләрчә мөнәсәбәте, чиксез шәфкате белән дәвалый. Борчылма, сөен генә, дустың да тиз терелер. Аны, мөгаен, минем группама бирерләр. Кем дидең әле син аны?

— Фамилиясе Борһанов. Гыйлеме буенча — туфрак белгече, биолог. Районның баш агрономы. Эрудит, гаять укымышлы егет. Аспирантура да тәмамлаган иде. Кандидатлык дәрәҗәсен яклап тормады. Эшенә артык бирелгән җан. Аның белән аралашу үзенә бер ләззәт. Җирне, туфракны, табигатьне аныңча сөеп, болын-тугайларыбызда үскән барча үләннәрнең, чәчәкләрнең татарча, русча, латинча исемнәрен белүчеләр әйләнә-тирәдә юк! Андагы хәтер, зирәк зиһен беренче класслы компьютерда юк. Күз тигәндер аңа. Поезд тәрәзәсеннән карап килдек. Кайбер җирләрдә инде уракка төшкәннәр. Ә ул, минем җиңемнән тарта-тарта: «Бу карлар ике-өч көннән эреп бетәчәк, тизрәк язгы чәчүгә чыгарга инде», — дип, тәмам башымны катырып килде. Нәкъ әле син әйткәнчә, кризис вакытында аларның күзенә ак-кара күренми икән. Минем аңа акыл сатуым стенага борчак ату белән бер. Ул гел үз сүзен сөйли. Кызып китмәсен тагын дип, ул ни сөйләсә, мин шуны хуплап килдем. Якын дустым бит...

— Алайса, Ленар, бүген син минем иң кадерле кунагым. Мин сине беркая да җибәрмим. Хәзер безгә кайтабыз.

— Клара... Матурым... Килешерме соң? Мин бит...

— Килешмәсә, үзебез килештерербез. Кемнәргәдер килештерү гамәлләре башкарудан безнең яшьләребез күптән узган. Шулай ич? Шулай, диген!

— Шулаен шулай. Аллага тапшырып дигәндәй кайтырга да була. Әхәт өчен дә җаным тыныч. Кем әйтмешли... син моннан ничә болытлар арырак торасың соң? Минем машинам юк. Такси дисәң, хәзер дәшәбез.

— Борчылма бер дә. Моннан ике адымнарда гына. Шушы хастаханәнең ишегалдында ук.

Клара ханым мине култыклап алды. Без урамга чыктык. Карт каеннар бизәгән хастаханә ишегалдының теге башында ук штукатурлары коелган, каравылчы алачыгыннан әз генә зур, шыксыз таш бина алдына килеп бастык. Бу бина элек тәгаен трансформатор будкасы йә кечкенә генә склад-мазар булгандыр. Клара ханым сумкасыннан орчыктай озын ачкыч чыгарды, ишектә эленеп торган ат бәкәле зурлыгындагы йозакны шалтыратып ачып та җибәрде.

— Милости просим, түрдән уз, кадерле кунак!

Чаршау белән генә аерган ике бүлмә. Тар гына кухнясы да бар.

— Бар уңайлыклар да урамда. Хәтта чәйгә суны да төп бинадан чиләк белән ташыйбыз. Кер юганда су ташып тәмам хәлдән таябыз. Ике ара ике-өч йөз адымнар гына бардыр. Әмма, Ленар кадерлем, бу безнең үз куышыбыз, аңлыйсыңмы шуны, үз куышыбыз. Халкы миллионнан өстә булган бу калада үз куышың булуның нинди зур бәхет икәнен, Ленар, ни за что аңламыйсың. Ә мин аны татыдым. Теге чакта мин Казанга сигез айлык корсак белән кайтып төштем. Җитмеш яшьлек сукыр әнием, хатыны, ике баласы белән абыем Радик егерме квадрат метрлы коммуналкада интегәләр. Бүгенме, иртәгәме бәбәйләргә торган хатынга аларда карават кую түгел, арт ягымны төртергә дә урын юк. Фатирдан фатирга күчә-күчә җаным чыкты. Бу эшкә үз проектларымны яклап мин өч иҗади конкурста җиңеп чыгып, беренче чиратта шушы алачыкка кызыгып, нинди генә булса да үз куышыбыз булыр дип алындым. Югыйсә мин кайту белән Фәннәр академиясенә, аның Борынгы китаплар фондына, реставрация цехына урнашканыем. Бик кызыклы иҗади эш. Нәкъ минем профиль. Гарәп графикасы, иҗади колачыңны, фантазияңне көчең җиткәнчә җәелдер, каллиграфия горизонтлары чиксез. Рәхәтләнә! Кыска гына вакыт эчендә бик борынгы китапларны бизәргә, кулга алып укыр хәлгә китерергә өлгердем.

— Ә Казанда сине Вадим каршы алмадымыни?

— Вадим мин кайтканчы ук Ленинградка киткәние. Ул кадәресен мин соңыннан гына белдем. Эш аклы-каралы, ягъни төссез телевидениедә генә булмаган икән. Күңеле Казанга кайткач та тынычланмаган. Социалистик реализм кысалары минем иҗатымны чикли дип зарланган. Сюрреализм белән мавыга башлаган. Көнбатышка ычкынырга ният тоткан. Ул вакытларда сине кем чыгарсын? Күп шыңшып йөрсәң, ябып куярлар. Психушкаларда да урын җитәрлек. Күрдең ич, Карл Марксларпалатасында да өч урын буш...

Клара тар гына кухнясында кайнашкан арада, мин, тиз генә кибеткә чыгып, карбыз, виноград, конфет-печенье, ике-өч төрле затлы шәраб, бәйләме белән клиндерләр алып кердем. Мин кайтышка хуҗабикә ханым күкәйгә суган турап күп итеп борыч салып тәбә өлгерткән. Әйбәт кабымлык ул! Казан байлары сые инде! Хуш ис бөркеп, чыжлап торган табаны:

— Башка сыем юк, Ленар кадерлем, гаеп итештән булмасын... Әмма булганы — чын йөрәктән! — дип, алдыма китереп куйды. — Бу кичтә Казан байлары кебек утырыйк әле. «Казан байлары» синең яраткан сүзең иде бит.

— Утырмаска, Клара! Күкәй тәбәсе — ханнар сые! — дидем. — Ә син кыздырганы ханнарга да эләкмәгән.

— Ленар, чын әгәр, минем сине бик тә, бик тә күрәсем килгәние. Студиядә бик тату эшләгәниек бит.

— Алай гынамы?! Мин сиңа гашыйк идем. Гыйшык утлары дөр-дөр дөрләттең син минем эчемдә. Сиздермәскә генә тырыштым.

— И-и, Ленар, ничек сизмим ди инде мин? Мин бит үзем дә сиңа гашыйк идем. «Татар маржасы» дип тә син куштың бит. Ике арага табу салып: «Клара, знай, я тебя люблю, но я женат!» — дип куя идең. Ә миңа: «К сожалению, я замужем!» — дияргә генә кала иде. Хәтерлисеңдер, эшкә ничек бизәнеп килә идем. Сиңа ошар өчен! Синнән берәр комплимент яулау өчен! Минем дә күңел кылларымны тик синнән генә чиерттерәсем килгән чаклар күп булды... дускай!

— Ул гадәтең белән бөтен нервымны ашап бетердең бит. Син киенеп-ясанып, матуррак киенеп килгән саен, минем ачуым көчлерәк кузгала, оператор егетләрдән көнләшәм. Ул теге синең балтырларыңа массаж ясарга беренче булып әзер торган яһүд егете Лева Симоновны бәреп үтерердәй булам. Нахалның нахалы бит!

Клара, мин өстәлгә кайтарып тараткан ризыкларга карап:

— Болай зурдан кубып расхутланмасаң да яраган булыр иде. Син бит юл кешесе. Ә минем өчен син болай да иң зур кунак, иң кадерле кунак, — диде. — Аскы яктарак безнең клиниканың җиләк-җимеш бакчасы бар. Аның уңышын миннән башка берәү дә җыймый. Профессорларның, докторларның үз дачалары. Шул бакчада елның елында крыжовник бер дә галәмәт күп була. Узган ел уңышыннан, «Йорт эшләре» дигән китапта язылган күрсәтмәсен бик төгәл саклап, настойка куйганыем. Уңгандырмы, юкмы, хәзер татып карыйбыз. Узган атнаны бер санитарыбызны пенсиягә озаттык. Тетя Маша дип йөртәбез. Шуны озату мәҗлесенә алып кергәнием, болай бик мактаганнарые, — дип, өстәлгә тулы графин белән алсу-кызгылт төстәге сыекча куйды.

— Белмим, сиңа ошармы, юкмы? Төсе матур, тартып тора. Нигә әле начар булыр икән? — О-о! Чыннан да Казан байларыча сыйлану була инде бу, Клара. Башка кергән хыялмы бу минем өчен?

— Ленар, кадерлем, әйт дөресен, син дә шулай шатмы безнең бу көтмәгәндә очрашуыбызга? — дип, Клара мине арттан кочып алды. — Үзең соң ничек яшисең? Кызың Айгөл зурдыр инде. Тагын кемнәрең бар? Журналистиканың азау тешен чыгарган карт бүресенә әверелгәнсеңдер инде. Теге чакта ук студиянең иң көчле журналистларыннан берсе син идең. Юк кына хәбәрләрне дә кешене тетрәндерерлек, тыңлаучының күңеленә үтеп керерлек итеп бик оста яза идең.

— Ә син аларны бик матур зәвык белән язылган титрлар, заставкалар белән тагын да көчәйтә идең. Экранга ничек ямь кереп китә иде. Настойкаң бик әйбәт чыккан бит! Үзе тәмле, үзе кодрәтле! Эчкән саен тагын берәр рюмка тотасы килеп тора. Мин артык тәкатьсезләнмимме, әй? Гөрләп эшләп яткан студиябезне япкач, бу һөнәрдән гайрәтем чикте. Журналистикага бүтән кайтмадым. Промыселга оператор булып кердем. Хезмәт хакы әйбәт. Эшләгән кешене зурлыйлар, күтәрәләр. Баштагы чорларда миннән көлүчеләр дә, шаяртучылар да күп булды. Ә мин тоттым да нефть институтын тәмамлап куйдым. Өч ел эчендә. Хәзер бораулау установкаларын монтажлау белән шөгыльләнә торган бер җыйнак кына идарәдә җитәкче инженер. Эшем үземә ошый. Ике ел Алжирда эшләдем. Шушы арада гына бер төркем инженерлар белән Һиндстанда өч айлык командировкада булып кайттым. Эшкә бик күндәм һинд егетләрен безнең буровойларда эшләргә өйрәттек. Әле менә Гыйрак белән кызыклы килешүләр төзеп ятабыз. Анда да нефть скважиналары бораулларга җыенабыз. Үзебезнең егетләр анда вахта ысулы белән берәр айга очып йөриячәкләр. Ә журналистика алай да тынгылык бирми, шайтан нәрсә икән ул. Күңелне нидер кытыклый. Бәлкем, Татарстан «кара алтын» табучыларының чит илләрдәге героик хезмәте турында турыдан-туры Нобель премиясенә лаек булырлык берәр роман да язып куярмын әле. Материал байтак тупланды. Яз менә бу турыда, халыкка җиткер дип, күңелне туктаусыз кытыклап торалар.

Ә Вадим исәндер бит? Хәзер кайда ул? Казанга киткән шәпкә «Чаян» журналында мин аның ике-өч рәсемен күрдем. Сөендем. Рәсемнәре болай тәэсирле, талантлы кул белән ясалган төсле тоелды. Аннары суга чумгандай юк булды. Ул-бу булмагандыр ич?

— Казанда озак тормаган ул. Ленинградка китеп барган. Анда аның кемедер, бертуган апасымы, абыйсымы бар иде. Анда укыган чагыбызда ук аларга барып йөри иде. Ленинградта пропискага кереп бераз гына эшләп алган да сәүдә флотына матрос булып ялланган. Бу план аның башында студиядә эшләгән чагында ук булган, ахры. Сәүдә корабында озак йөзмәгән. Италиянең бер портында туктагач, ярга чыккан да корабына кире кайтмаган.

— Диссидент, сәяси түбә сораган мәллә? Андый, черегән фәлсәфәле егеткә бер дә охшамаган иде.

— Ю-ук. Сәяси түбә аңа ниемә хаҗәт? Каян килеп диссидент булсын? Бер атнадан илчелеккә барган да әйткән. Мин рәссам, дигән. Пароходымнан махсус төшеп калдым. Ишегалды себерүче яисә мич торбалары чистартучы булып эшләп булса да, Рим сәнгать академиясен тәмамларга телим. Биредәге сәнгать шедеврларын үз күзем белән килеп күрергә башкача матди мөмкинлегем юк. Үз һөнәремдә камиллеккә Рим осталарыннан өйрәнеп ирешәсем килә, дигән. Илчегә берничә эшен күрсәткән. Бәхетенәдер инде, илче агай шәфкатьле кеше булган. Вадимны аңлаган. Аның ике картинасын шундук үзе сатып алган. Аларны илчелекнең фойесына элгән.

Вадимның үзен илчелектә үк каравылчы һәм машина юучы итеп калдырган. Егетебез хәзер илчелек хезмәткәре, любите и жалуйте! Ак күлмәктән, кара галстуктан гына йөри булыр. Фырт килеп кыланырга булса, аңа гына бир.

— Ул яктан караганда, — дип куйдым үзем дә, — сез икегез дә берегез өстенә икенчегез суйган да каплаган. Фасон белән киенә идегез.

— Безнең Вадимны аны не поймешь, — дип көрсенеп әйтеп куйды Клара. — Бер карасаң, кызганыч та. Икенче карасаң, ни җитми торгандыр үзенә? Хатларын болай бик жылы яза, һәр бите сагыну, өзелеп юксыну кичерешләре белән тулы. Елап укыйм. Что еще остается! Әмма сирәк яза, ара-тирә, исенә төшкәндә генәме? Узган елны Римның иң атаклы картиналар галереясы уздырган Халыкара күргәзмәдә катнашкан. Аның рәсемнәренә Италиянең иң күренекле академиклары бик югары бәя биргәннәр. «Значит, я не зря здесь небо копчу!» — дип бик сөенгән. «Клара, земная богиня моя, ты, пожалуйста, прости меня. Что ж делать мне, если судьба моя такая? Поистине так, судьба играет человеком, а человек лишь на трубе. Хотя ледоруб в моих руках отточен как положено, но путь к вершинам Олимпа немыслимо тернист и коварен. А я по-прежнему, богиня моя, очень и очень тебя люблю. Слов нет описать, как я скучаю по тебе. Скучаю! Караул, скучаю! Скучаю, моя родная! Если нам судьбою не суждено снова увидеться, то знай, богиня моя, я умру только с твоим именем на устах», — дип яза шайтан малае хатларын. Аларны еламыйча ничек укыйсың? Ә кызыбызны үстергәндә юк-бар алиментлары белән дә ярдәм итә алмады. Хәзер шуңа да бик борчыла булса кирәк. Элеонораны аякка бастыру берүземә ух! — авыр булды. Бер тиен акчага аптыраган чакларым, Ленар, күп булды. Ты поверишь, менә бу эшкә күчкәннән соң гына туйганчы ашап яши башладык. Җитмәсә, кызым да кече яшеннән үк этисе кебек үҗәт бернәрсә булды. Бу эшем — миңа язмыш бүләге. Лотерея отышы! Хезмәт хакым әйбәт. Нинди контингент белән эш итүемне исәпкә алып, ай саен егерме биш процент өстәмә түлиләр. Тиеннәрне санамый яшәргә өйрәнеп киләбез.

Өзелеп сагына торгандыр дисең Вадимны. Ничек инде сагынмасын. Кошлар да үзләре канат ныгыткан ояларын сагыналар. Миндәй «татар маржасын» дисеңме? — Карлыгач канатларыдай ике якка канат җәйгән кара кашларын чак уйнатып, Клара шаяртып алды.

— Вадимны бик аңлыйм мин. Сагыну галәмәте — бүгенге көнгә хәтле аңлаешсыз бик тирән хис ул. Ничек түзә диген әле. Кешеләр генә түгел, барча җан ияләре дә кичерә бит бу халәтне. Бу хис күңелеңне бер биләп алсамы, үземнән үк чыгып әйтәм, сине тәмам үзенең әсире итә. Тезләндерә! Утлардан алып, ташкыннарга сала. Кеше ышанмастай гамәлләр эшләтә. Бер күренекле шагыйребез дә бер дә юктан гына:

Ялгыз йөргән юлларымда
Моңнарым сибелә һаман,
Сагыну кемдә дә була ул,
Сагыну кемдә дә була ул,
Ә миндә бигрәк яман, —

дип язган бит. Шушы изге һәм серле халәт адәм баласының кайсы әгъзасында туа икән? Башындамы, әллә йөрәк түрендәме, дип уйлап куям мин кайчакларны. Минемчә, әлбәттә, йөрәк түрендә туа булыр. Әле узган гасыр башында ук Фатих Кәрими атлы безнең бик күренекле, үзе журналист, үзе прозаик, үзе педагог, бик тә уңган җәмәгать эшлеклебез булган. Аның әтисе Гыйльман ага ул елларда Бөгелмә өязенә кергән, ә бүген Әлмәт районында исәптә торган Миңлебай исемле зур гына авылда имамлык иткән. Шул рәвешле әлеге авылда утыз еллар чамасы имамлык иткәч, Гыйльман агай улы янына Оренбургка күченеп китә. Хуҗалар башка мал-төякләре белән, йомшак шәлгә төреп, камыштан үргән кәрҗингә песиләрен дә алалар.

— Алмыйча! — дип куәтләде Клара. — Аны ничек алмыйсың инде? Ул да бит тулы хокуклы гаилә әгъзасы. Безнең дә Солтан кушаматлы ата мәчебез бар. Бу арада күренми әле, мөгаен, мутлыкта йөри булыр. Ә мулла абзый песие бик иркәләрдән дә булгандыр әле.

— Менә шул песикәй Оренбург каласына берничек тә күнегә алмаган, ахры. Үзе туып үскән нигезне, мартның юеш буранлы кичләрендә бер ду килеп түбәләрдә, өй кыекларында мәхәббәт уены уйнаган күрше мияубикәләрен түзә алмастай сагынганмы, песи юкка чыга. Үзләре калдырып киткән нигезгә өч елдан соң кайтып керә. Оренбург белән Миңлебай арасы алты йөз чакрымнар гына бар да бар. Песикәй адымнары белән генә аны ике-өч атнада да, хәтта бер ел эчендә дә һич үтешле түгел. Бичара җан бу араны өч ел кайткан. Имамыбызның бик яраткан мәчесе иде, аның төсе, якты истәлеге булып калсын дип, аны соңыннан бөтен авыл караган, сыйдырган, иркәләгән. Хәтта ашка йөрткәннәр.

— Монысы чыннан да искитәрлек хәл! Башка берәү сөйләсә, Ленар, ышанмаган да булыр идем. — Клара бот чабып куйды. — Өч ел гел юлда булып, ул песи кайларда гына кунмагандыр, ниләр генә күрмәгәндер. Салкын кышы бар, яңгырлы җәе... Ә ул һаман кайта бирде микән, җанашым? Теле булса, юлда берәрсен туктатып, Миңлебай кайсы якларда соң, мин дөрес барам микән, дип сораган булырые. Юлын нинди билгеләр буенча тәгаенләп, нинди ориентирлар аша кайтты икән? Чын әгәр, искитмәле хәл бит.

— Әллә киткәндә үк, минем бер дә китәсем килми бит, мин барыбер Миңлебаебызга кайтам, дип, юлны хәтерләп барды микән? — дидем мин.

— Бу очракта аңлатма бер: бичара песикәй туган-үскән җирен бик сагынган. Үзен-үзе белмәс хәлгә килгән. Үзенә кирәкле юнәлешне ул, бәлкем, йолдызларга карап тапкандыр. Ул — гениаль штурман. Йолдызларга карап исәп-хисап йөртә белгән песикәй штурман булмыйча... Высшая математиканы, синус-косинусларны да белә булгандыр. Үзебезне чорнаган мохитне бик начар беләбез бит. Үзебезгә шаккатып яшәү көчле бездә. Яныбызда ук бездән акыллы җан ияләре яшәгәнен белмибез дә, белергә дә теләмибез.

— Минемчә дә, — дип килештем Клара белән. — Җирлеген без мыскал да аңлап бетерә алмаган сагыну хисе йөрткән. Шул хис акыл биргән, хәл-көч биргән. Шушы очракка бик тәңгәл килешле бер хәл безнең үзебезнең гаиләбездә дә булды бит.

Өстәл әзерләп маташкан Клара:

— Ленар, я тебя слушаю с предельным вниманием, — диде.

— Балачак бу минем. Без бер кечерәк кенә барак бүлмәсендә яшәп ятабыз. Сугыш кырларыннан исән-сау кайткан әтиебез, кайтып бераз баш-күз алу белән:

— Болай булмый, балалар, болай булмый, үз куышыбызны булдырырга кирәк, — дип сөйли башлады. — Күргәнегез бардыр, хәтта карлыгачлар да, балчыгын авызлары белән ташып, үз ояларын коралар.

Бүрәнәләр юнәттек тә йорт салырга керештек.

«Чынлап торып алынсак, балалар, көзгә үз куышыбызны өлгертеп тә куярбыз», — дип, әти барыбызны дәртләндереп тора. Осталар дәшеп бура бурата башладык. Ә бура бураучыларга түләргә әтинең чамасы юк. Нишләргә? Ул елларда авыл кешесенең бердәнбер, иң кадерле, бөтен гаиләң, өеңдәге бар тере җан белән табына торган малы — сөтлебикәсе инде. Әни, бичара, күз яшьләрен алъяпкыч итәге лычык булганчы сыкса да, бер хәлең юк, бураучыларга бурычны түләргә кирәк. Сөтлебану дип йөрткән алты имчәкле сыерыбызны күрше Шыпшыйк авылы Гаптери агайларга сатып җибәрдек. Хуҗабикә ул үзенең сөтлебикәсенең бозавын, анысы тана бозау да булса, ул бозауны иреннән, балаларыннан болай көчле ярату белән ярата, сөя, иркәли, авызыннан өзеп каптыра. Башта итәгендә, аннары кочагында үстерә. Хакыйкать бик гади югыйсә. Хуҗабикәнең сөтлебикәсе исән-сау булса, гаиләсе дә тук була. Безнең әни дә Сөтлебануыбызны бозау чагыннан ук үз балаларыннан болай сөеп, иркәләп үстергәние. Малкай үзе дә бик игелекле булды шул. Сөткә тәмам кинәндергәние инде безне. Сөте дә бер дә галәмәт куе һәм тәмле иде.

— Сезнең Сөтлебануыгызныкы төсле үзе куе, үзе тәмле сөт күрше-тирәдә юк, күз генә тия күрмәсен малкаегызга, — дип, иртәнге чәйлек сөт сорап безнең оч урам карчыклары керәләрие.

Менә шул, әле биш кенә бозау китергән, алты имчәкле, көненә өч саусаң, мөлдерәмә өч чиләк сөт бирешле Сөтлебануыбыз Шыпшыйк көтүеннән качып көн саен безгә кайта. Мөгезе белән йомшак кына капкага төртүгә:

— Һай, балакаем! Һай, күз алмам, тагын кайттыңмы? Ничек кайтмасын, кеше акыллары бар бит аның башында! Безне оныта алмый! Өзелеп безне сагына бит! — дип такмаклап, әни елап ук җибәрә. Тирән эчле галушының берсен элəктерә, икенче сыңарын юк. Куенындагы ипи катысын капшый-капшый, капка ачарга йөгерә. Әти безнең кырысрак кеше. Бер дә килештерми бу хәлне.

— Ипи катылары тотып каршылагач... нигә кайтмасын! Иртәгә дә кайтачак, — дип мыгырдый. — Чыбыркы белән ку үзен! Йөрмәсен бүтән. Безнең мал түгел ул хәзер. Ничу йөрәк бозып йөрергә. Юкса... хәзер мин аны үзем...

Андый чактамы?! Безнең әнигә каршы сүз таба алмыйсың.

— Баскан җиремдә егылып үлсәм үләм! Туган-үскән нигезен сагынып, безне юксынып кайткан малкаема чыбыркы белән кизәнү түгел, наный, авыр сүз дә әйттерәсем юк! — дип кенә җибәрә. Ялгышлык белән генә юлына аркылы төшмә, чәчелдереп кенә җибәрер. Әни безнең шундый.

Шыпшыйк безгә биш чакрымнардыр. Кечерәк кенә авыл ул. Көтүе дә зур түгел. Ул көтүдән качу үзе могҗиза. Гаризасына көтүче агайдан кул куйдырып, аннан рөхсәт алып китми бит инде ул, ә качып китә. Кичкә чаклы малкайның алты имчәкле җилене сөт белән тулып, кочакка сыймаслык булып киерелгән була. Таш җәйгән шоссе юлдан төшә бит әле. Очлы ташларга басып, тоягының күп җирләре кителеп канап чыга. Әнигә еларга гына бир.

— Балакаем, бу тикле җиленеңне ничекләр күтәреп төштең? Безне, менә үземне өзелеп сагынмасаң, дүрт аягыңның берсен дә атламасыең, бәбкәм, — дип сыга гына күз яшен.

Әни елаганда без дә карап тормыйбыз бит инде. Өстәлдә күнегелгән каймак-сөт, салкын катык булмавы да сиздерә. Мондый чакта безнең әнигә сүз әйтеп кара... жүләр! Иңбашында йомшак тастымалы, комганда җылы суы күптән әзер аның.

— Хәлеңне хәзер җиңеләйтәм, бәбкәм, — дип, малкайны әвеслек астына җитәкли, шундук саварга керешә.

Маһруй апайлар төшкәнче, әни сауган сөтен сепараттан аертып ук куя. Мөлдерәмә бер чиләк сөтне кем инде Шыпшыйкка кадәр күтәреп менсен. Биш чакрымнар араны. Башка беркая да түгел, малкайның бездә икәнен белеп, Гаптери агай белән Маһруй апай безгә өч көпчәкле шалтыр-шылтыр матайлары белән төшәләр. Гаптери агай аннан үз эше белән китеп бара. Маһруй апай Сөтлебануны бау белән җитәкләп, үз җайларына менеп китәләр. Малкайны орышмый. Аның да күзләрендә яшь. Ул инде ни дип елагандыр?

— Игелекле малкаем, хуҗаларыңны борчуга салып төшмә инде бүтән безгә. Яхшы кешеләргә бирдек бит үзеңне... Махруй апаең да сине минем кебек үк ярата, иркәли бит, балакаем! Шул нигезгә күнек инде, бәбкәм. Алдагы язларда үзеңдәй матур бер тана бозау китер, Шыпшыйкка үзем менеп алырмын. Төсең итеп, — дип кат-кат үгетли торгач, малкай да аңлады төсле. Безгә алай еш төшми башлады. Әни аннары үзе бер тастымалга ипи катылары җыя да:

— Сөтлебануымны юксынам, кичә төшемә дә кергәние, мин Маһруйларга менеп киттем әле. Бик кыстасалар, мунчалар да кереп, куна калырмын. Сөтлебануны иртән үзем савармын, — дип, еш кына Шыпшыйкка үзе менеп йөри башлады. Икенче җәйне Сөтлебануның нәкъ үзе төсле, маңгаенда кашкалы, алты имчәкле тана бозавын алып төште.

— Ленар, хәзер мин дә елап җибәрәм. Синең бу истәлегең мулла абзый песие язмышыннан да тәэсирле, понимаешь! Сине тыңлаганда үз күзләремә дә яшь килде. Сөтлебануыгызның бөтен килеш-килбәте күз алдымда. Талантлы рәссам кулына эләксә, җанны тетрәткеч бер сюжет, тәэсирле полотно ясарга булыр иде. Ничек уйлыйсың, әгәр алынса, безнең Вадим җиңеп чыга алыр идеме? Малкайның кыяр-кыймас кына, мөгезе белән йомшак кына итеп капка төртүе менә хәзер дә күз алдымда тора. Бер яктан үзе аңлый да булса кирәк. Бу капканы шакырга аның хакы юк. Аның хуҗалары башка. Ә йөрәктә әйтеп бирә алмаслык сагыну, юксыну, яңа җиргә ничек тә күнегә алмау. Ә бу капка артында аны тәмле ипи катылары белән сыйлаган, яңакларыннан сөеп иркәләгән хуҗабикәсе. Бичара малкай, мөгезе белән капканы төрткәндә: «Зинһар, мине аңлый күрегез, барчагызны бик сагындым, бер күреп чыгыйм дип кенә шакуым. Мин качкалакны берүк орышмагыз инде. Зинһар, кичерә күрегез», — дип теле белән генә әйтми. Булдыра алса, теле булса, ничек кенә тезеп әйтер дә иде. Беләсеңме, Ленар, әгәр чынлап торып алынсамы?! Бу картинаны ясый алыр иде. Монысын мин өздереп әйтәм. Ленинградта укыган чагыбызда ук укытучы профессорларыбыз Вадимны «яшь Левитан» дип йөртәләр иде.

Вадим бик үҗәт җан бит. Тешләсә, өзми калдырмый. Читтән караганда гына, итәгенә ут капса да исе китмәүчән бер җан булып күренә.

— Ты понимаешь, Ленар, — дип дәвам итте Клара, үзен-үзе куәтләп. — На этот счет я так думаю, сагыну, халыкчарак әйтсәк, саргаю хисе, җирдә тереклек иткән барча тере җаннарның яшәү рәвешен аклый торган, алда да яшәргә көч, дәрт, энергия бирүче бердәнбер этәргеч, локомотив, минемчә. Һәркайсыбыз җирдә сагыну хисе белән яши. Кичтән йокларга ятканда иртән туачак көнне, кояшны, якыннарыбызны сагынып уянабыз. Җәен — кышны, көзен язны сагынабыз. Сагыну хисе күңелне матур хатирәләр белән баета. Көткән көн, көткән сәгатьләрнең киләчәгенә өмет уята. Өмет исә шулай ук драгоценность очень высокой пробы! О-о, мин килешәм синең белән, Ленар, кешеләрнең талпынып, үз-үзләрен аямыйча башкарган барча изге гамәлләренең төбендә өзелеп сагыну хисе ята. Сагыну хисе — серле сандык. Шуны шалт итеп кенә ачып салырга философларның һаман да кулы җитешми. Ә философия, минемчә, чыннан да уйланырлык. Әле генә кылт итеп башыма килде. Ә нигә бу турыда миңа үз пациентларым белән киң дискуссия уздырмаска? Алар барысы гаиләләрен, эш урыннарын, бергә эшләгән коллегаларын сагынып яшиләр. Көчле, матур дискуссия чыгар төсле. Алар еш кына моңарчы берәүнең дә башына килмәгән йомры-йомры акыл төргәкләре әйтеп куялар.

— Алайсамы?! — дип дәртләнеп киттем үзем дә. — Синең сүзләреңне куәтләп, рәхим ит, тагын бер искитмәле гыйбарә. Сагыну хисенә килгәндә, мине иң-иң тетрәткәне үткән гасырда яшәп иҗат иткән, дөньякүләм танылган инглиз язучысы Джеймс Олдриджның романы булды. Бәлкем, синең дә күзеңә чалынып киткәндер бу әсәр. Башта ул роман-газетада басылды. Аннары күп тапкырлар аерым китап булып та чыкты. Романда вакыйга бер монгол айгыры турында бара. Туган илеңне, үскән җиреңне, җан сөйгән ярыңны өзелеп-өзелеп сагыну менә ни төсле була ул! Бер инглиз бае, миллионеры диик инде, Монголия буйлап сәяхәт иткәндә, аны далага да алып чыкканнардыр. Исәбе-хисабы чама белән генә билгеле ат көтүләрен дә күргәндер. Шунда ун меңнәрчә баш бахбайлар арасыннан бер айгырны ошата. Сатып та ала. Әлеге айгыр кай ягы белән инглиз баеның игътибарын җәлеп иткәндер? Анысы билгесез. Поездларга да менгереп, пароходларга да төяп, айгырны дөньяның икенче почмагына — Шотландиягә алып кайтып китә. Шуннан ни булган диген? Айгырны әйләнә-тирәсе биек коймалар белән әйләндереп алынган көтүлеккә җибәрәләр. Ашаган азыгы, яшәгән җире гөлбакча булса да, әлеге айгырны үз илен, үз даласын, үз көтүлеген, шул көтүдә калган бердәнбер нечкә билле биясен өзелеп сагыну хисе баса. Хет баскан җиреңдә егылып үл, аның күңелен сарган сагышка һич түзәрлек түгел. Качарга карар кыла айгыр. Җаен китереп тәвәккәлли.

Тәвәккәлләү белән генәмени? Шотландиядән Монголиягә чаклы ун меңнәрчә чакрымнар гына микән? Араларны зур диңгезләр, текә таулар, дистәләрчә илләр-дәүләтләр аера. Өзелеп сагынганда ул

киртәләр дә киртә түгел, ул чакрымнар да ара түгел икән. Әлеге айгырыбыз Шотландия белән Англияне аркылы үтеп диңгез ярына чыга. Диңгезгә ташланып, Ла-Манш бугазын кичә. Шултикле араны йөзеп, ничек хәле бетмәгән, ничек су төбенә китмәгән? Суга батмаска, юлында очраган барча киртәләрне җиңә барырга өзелеп сагыну хисе көч биргәндер.

Кайчак айгыр Германия Федератив Республикасы җиренә килеп керә. Анда тыгызлык, кая карама авыллар, торак пунктлар йә шәһәрчекләр. Кеше күзенә бик чалынып йөрсәң, нинди адашкан җан бу дип, муеныңа элмәк салырга, эләктереп алырга да күп сорамаслар. Ниндидер ориентирлар аша үзенә тынычрак маршрутлар сайлый-сайлый, хәрби полигонга килеп керә. Монда тынычрак булмагае дип исәп йөрткәндер инде. Полигонда тыныч буламы соң?! Анда корал сыныйлар. Бомбежкага эләгә, яралана. Чак исән кала. Белоруссия урманнары аша узганда, аңа бүреләр көтүе ташлана. Бүреләрнең әле берсен, әле икенчесен тибеп кенә очырып, тешләшә-тешләшә, алардан да котыла. Янә хәрби полигонга эләгә. Аннан чыкканда тимерчыбыкларга буталып, бөтен сыртын ерттыра, канга бата. Бу бичарага язмыш үзе теләктәш булгандыр инде. Бу батыр йөрәк иленә кайтып җитсен, даласына аяк бассын, кардәшләрен күрсен, бер киерелеп кешнәп җибәрсен дигәндер. Бөтен СССР территориясен исән-сау узып, ниһаять, Монголиясенә — туган даласына кайтып керә. Анда аны өзелеп сагыну хисе тулы сагышлы кешнәү белән айгырның сөйгән биясе каршы ала.

— Ә бит мин сине барыбер көттем, егетем! — диде микән соң аңа биясе.

— Мин дә бит сине бер генә минутка да күңелемнән чыгармадым. Ун меңнәрчә чакрым араларны кичеп барыбер кайттым, матурым! — диде микән бәхетле айгыр. Әсәренең бу җирләрен талантлы язучы аеруча тетрәткеч итеп бирә.

— Безнең мөгезле шайтан, Вадимны әйтәм, сагына беләме икән, как ты думаешь? — Клара бу соравын көтмәгәндә генә бик көчле интонация белән бирде төсле. Сагынычлы хатлар язып, минем колагыма ложками лапшу, наверное, не вешает? Песиләр, сыерлар, бахбайлар шулай сагына белгәч, кеше дигәнең нишләргә тиеш?

Клара каршы стенада эленеп торган майлы буяулар белән ясалган Вадимның автопортретына ишарәләде.

— Я хорошо думаю, — дидем. — Слушай, татар маржасы, синең белән ярым русча, ярым татарча сөйләшеп утыра торгач, үз телебезне онытып киләм бит инде.

Клара рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

— Мадам Клара, син аңа алай каты бәрелмә. Аңларга тырыш. Вадим Олимп башына менмәкче бит.

— Аңларга тырыш, имеш. Ә мин нишлим? Мин егерме бер яшемнән никахлы хатын. Толмы мин, әллә ирлеме? Иртән йокыдан уянуына йомырка тәбәсе пешереп, алдына чыжлап торган кайнар таба куярга ирем юк. Дөресрәге, ачуымны бик китергәндә маңгаена тукмак белән берәрне чүкеп алырга. Ah, Вадим! Ничек тирәннән аңлыйм мин сине, дип, дипломатик каналлар аша рәхмәт хисләре белдерергә түгелме тагын? Ә гаилә? Гаиләсе алдындагы бурычы? Алайса, ни пычагыма дип өйләнгән? Ленинградта чакта үземә тиң гомерлек ярлар сайларга мөмкинлекләрем муеннан иде. Ә мин, тавык баш, аны сайладым. «Ah, Клара, богиня моя земная», имеш! Ah, Вадим, Вадим, земной ишак ты мой!

— Ир-атлар үзләре алдына тормышта аеруча бөек максатлар куйганда, җиңеп чыгачакларына инанганда, тарихта Вадимга чаклы да мондый адымнар ясаучылар байтак.

— Кемнәр, например?

— Норвегияле Фритьоф Нансен турында ишеткәнең бармы?

— Йә, шуннан?

— Алдында мин баш иеп, тез чүккән бөек затларның берсе ул.

— Яле, яле? Кем алдында баш иеп, тез чүгәсең икән?

— 1861 елда туган Фритьоф Нансен, танылган сәяхәтче, океанограф, күренекле җәмәгать эшлеклесе. 1882 елда Норвегиядә Кристиания университетын тәмамлый. 1897 елдан зоология профессоры. 1888 елда чаңгыда берьялгызы Гренландия атавын аркылыга кичә. 1890 елда, корабка утырып, дрейфовать иткән бозлар белән Төньяк котыпка бару проектын раслый. 1893 елның сентябрендә шушы максатлар өчен махсус төзелгән «Фрам» корабында әлеге хәтәр сәяхәткә чыгып китә. Бөтен хикмәт шунда, утыз яше белән барган Нансен моннан өч атналар элек кенә Норвегиянең бик чибәр баронессасы белән никахлаша. Корабка да Нансенның хатыны — унсигез яше белән генә барган баронесса исем куша. Аның исеме безнеңчә — «Алга!». Төньяк полюсны өйрәнүдә күпме кыюлар анда каберләрен таптылар. Нансен да исән-имин әйләнеп кайтырмы-юкмы. Әмма хатыны, баронесса Ева Нансен, иренә ихлас күңелдән хәер-фатихасын бирә. Фрить- оф Нансенны котыпта көтеп кенә торганнар икән. Баренцево диңгезен узып, Карск диңгезенә килеп керү белән, корабны бозлар кысып ала. «Фрам» Яңа Җир, Төньяк җире, Кече Таймыр, Новосибирск утраулары аша узып өч ел дрейфта була. Экспедициянең икенче бер әгъзасы Ф.Я.Иогансен белән берлектә Нансен «Фрам»ны калдырырга мәҗбүр була. Төньяк полюсның үзәгенә чана өстерәп менеп китәләр. 1895 елда 86 градус 14 минутка кадәр күтәреләләр. Моңарчы әле берәү дә аяк басмаган биеклеккә! Ашарларына беткәч, кире борылалар. «Фрам» да аларны көтеп тормаган. Бозларга кысылган хәлдә дрейфовать итүен

белгән. Ә Нансен иптәше белән, чаналарын өстерәп, Франц-Иосиф атауларына кадәр төшәләр. 1896 елда, Англия сәяхәтчесе Ф.Джексон оештырган экспедициягә юлыгып, аның корабында Норвегиягә кайталар. Ева Нансен аны, әлбәттә, көтә. Кочагын җәеп каршы ала. Менә бит тормышта нинди мисаллар да бар.

Фритьоф Нансен гомумән бик эшлекле кеше була. I Бөтендөнья сугышы тәмамлангач, 1914–1918 елларда Милләтләр Лигасының хәрби әсирләр эше буенча Верховный комиссары вазифаларын өстенә ала. Аны Европа таный башлый. Әсирлектә иза чиккән миллионнарча солдатларны үлемнән коткарып кала, туган илләренә кайтырга булыша.

1921 елларда үзебезнең Идел буенда коточкыч ачлык була. Өлгер һәм гаять эшлекле Фритьоф Нансен Идел буе халыкларын ачлыктан кырылудан саклап калу өчен гаять зур эшчәнлек күрсәтә, Ярдәм фонды оештыра. Туп-турысын гына әйткәндә, бу бөек зат алдында без — Идел буе татарлары да бурычлы. Мәктәпләребездә, музейларыбызда, сәнгатебездә аның исемен һәрчак тирән ихтирам вә рәхмәт хисләре белән искә алырга кирәк. Шундый тормышта матур эз калдырган шундый бөек затларның биографияләре белән танышкач, беләсеңме, мин үземә хәтта беркадәр җирәнү хисе белән карап куям: без дә яшибез инде дөньяда!

— Һава пыскытып, ипи черетеп, — дип җөпләде мине Клара. — Сокланып искә алырлык эзләр калдырган затлар күп бит.

— Ирле-хатынлы Кюрилар, әйтик. Уранның тере тукымаларны үтерә, юк итә торган радиациягә ия булуын алар бит ача. Шуны белә торып та, бу өлкәдә эзләнүләрен туктатмыйлар. Үзләрен түгел, кешелекне коткару турында уйланалар.

— Ленар, дустым, кайчакларны син үзеңә карата артык кырыс. Барыбызга да Нансен булырга, котыпны ачарга чыгып китәргә димәгән. Син дә мулла, мин дә мулла, атка печән кем сала, дия иде әнием, — дип, Клара тыныч кына әйтеп куйды. — Ә менә Вадимны Фритьоф Нансенга тиңләргә тырышуың, ышан, күңелгә барыбер якын.

— «Кайчакларны миндә үземә карата хәтта җирәнү хисе дә туа» дип, планканы чыннан да артык югары күтәреп әйттем бугай. Нигә дип җирәнү хисе туарга тиеш әле? Дөрес, әгәр Нансен алдында туган дилемма минем алда туса, икеләнми әйтәм, юк. Бер уйласаң, акылга сыешлы түгел бит. Никах срогы нибарысы өч атнадан узмаган, ирләрчәрәк әйтсәк, туйганчы бер кочакларга да өлгермәгән унсигез яшьлек кәләшемне ташлап китә алмас идем мин ул экспедициягә.

— Котып котыптан да ары олакмас әле? — дияр идеңме.

Клара ярыйсы ук кабаланып табын әзерли. Минем белән күбрәк яны белән басып сөйләшә. Шушы хәлендә дә бик чибәр ул. Өлгергән җимеш, тулып пешкән алма! Миңа хәтта бераз уңайсыз. Шушында ук тотып ашардай, кабып җибәрердәй булып каравымны сизә булыр. Карамаска, ир уртасы ла мин. Хатын-кыз затының тәмен самый белгән чорлар бит бу.

— Юк, миннән булмас иде, — дип дәвам иттем. — Җан сөйгәнемне ташлап, әллә кая, күп смельчаклар китеп кире кайтмаган мәңгелек бозлар иленә китмәс идем. Ул котыпны барыбер буйсындырам, очына әләм кадыйм, дип йөргәннәрнең күпмесе кире кайтмадылар, шунда мәңгегә югалып калдылар.

— Монда, Ленар, уйлар, теләкләр берлеге төп этәргеч булгандыр. Евага нибары унсигез. Фритьофка егерме тугыз, утыз белән бара. Алар бер-берләрен якыннан белеп никахлашканнар бит. Фритьоф — бөтен Гренландияне берьялгызы чаңгыда аркылыга кичкән атаклы сәяхәтче.

— Клара, кара, әй, синең бу крыжовник согың чын тел ачкычы булган бит. Әйбәт чыккан ул! Торган саен телне ача гына бара. Чын винодел икәнсең син. Мин артык күп сөйләмимме соң? Карт үрдәк кенә күп сөйләшә...

Шулай дидем дә тын калдым. Берара байтак кына тып-тын утырганнан соң тел тагын да ачыла төште.

— Юк, юк, Клара. Мин үземне болай пешкән шалкан, төшкән калганга санамыйм. Партия һәм профсоюз взносларын вакытында түләп барам. Властьлар белән конфликтка кермим.

Минем беркадәр юмор белән сөйләүгә күчүемне хуплап:

— Совет властеның үз гражданнарына биргән иң зур бәяләрнең берсе инде бу! Властьлар белән конфликтка кермәү, — дип бүлдерде Клара.

— Әгәр инде бурычка керсәм, берәрсеннән әҗәткә алган акчамны бер ел узса да түлим. Аның каравы процентлар белән. Так ышту пессимизмга бирелергә сәбәп күрмим әле. Эх, нәкъ үзең кебек, настойкаң әйбәт синең, кызый.

— Бер-беребезне, Ленар, байтактан беләбез бит. Беләсеңме, синдә күп ир-атларда мыскалы да булмаган бик яхшы сыйфатлар күп. Шуның, минемчә, иң затлысы, кадерлесе, көчлесе — кешелекле егет син, һәркемгә ярдәмчел. Кешеләрне кигән киемнәренә, биләгән кәнәфиләренә карап аермыйсың. Шуңа күрәдер сине студиядә дә яраталар иде. Берәр җәмәгать оешмасына-мазар кандидат күрсәтергә булса, һәрчак сине күрсәтәләр иде бит. Басымчак итеп түгел, эшләячәгеңә, намус белән башкарачагыңа ышанып.

— Абау, абау! Мактый башлама! Мактама, зинһар, мине! Тәмен дә татырга өлгермәгән сырым хәзер үк авызымнан төшеп китә бит. Миңа мактау гомумән килешми, ашказанымда шундук хронический изжога, ачы кикерек килү башлана. Бу настойкаң прәме галәмәт синең, Клара. Ә бу матур графиның да мине үз итте. «Тагын бер рюмка кап, кыю бул!» дип күз кысып утыра. Чын винодел икәнсең, Клара. Моннан соң Казанга юлым төшсә, шушы настойкаңны тату өчен үк атылып килеп чыкмагаем. Мин таптасам, гел бер сукмакны таптаучылардан...

* * *

— Ты понимаешь, Ленар, другой раз Вадим мне кажется совсем чужим. Как будто он мне никто. Это страшно. А ведь я любила его безумно...

— Син борчылма, дускаем. Бер-берләренә бик якын рухи мөнәсәбәтләрдә булган җаннар арасында да бозлык чоры, ягъни ледниковый период булып алуы табигый. Марксистик-ленинчыл тәгълимат та моны инкарь итми, таный. Чөнки күңелдә туган хисләр суынырга, бөтенләй сүнәргә дә мөмкин. Безнең Гөлчирәм белән андый вполне закономерный күренешләр атнасына өч булып ала торгандыр. Аңа карап юынтык су белән анда коендырырга салган нарасыйны чүплеккә түккән юк.

— О-о, ледниковый периодмы? Ул бит, хәтерем ялгышмаса, Европада унике мең елларга сузылган түгелме соң? Ленинградта укыган чорыбызда бер егетебез үзенең курс эшен «Ледниковый период» дигән абстракт картина язып яклаган иде. Берәүләр аны үтереп мактадылар. «Пустяк!» дип тетмәсен тетүчеләр дә булды. Миңа тел төбең аңлашылып җитми, кадерлем. Вадимны унике мең ел көтәргә киңәш итүең түгелдер ич? Не выйдет, дорогой!

Клара авызына бер телем лимон кисәге капты да, чыраен сытып, берара миңа төбәлеп карап торды. Аннары кинәттән генә:

— Ленар, минем синнән яшерер серем юк. Өлкән яшьтәгерәк бер симпатичный агай, академик «Х» булсын, кулымны сорап аптырата.

— Академик булгач, табигый, кайнар канлы гусар яисә бөдрә мыеклы корнет, йә кадет булмас инде, чибәркәем.

— Фәннәр академиясендә эшләгән чагымда ук танышкан идек. Сирәк кулъязмалар бүлеге мөдире ул. Хатыны үлгән. Ике улы бар. Алары үз гаиләләре белән аерым торалар. Болай беренче карашка бик порядочный кеше сымак. Кеше карбыз түгел, ярып карый алмыйсың.

— Бергә булсак, кызым, кефир шешәсе дә күтәртмәмен, — ди.

Әйе, «кызым» дип дәшә шул.

— Кызыңны да бергәләп аякка бастырырбыз. Бөтен байлыгымны сезнең исемгә күчерермен. Клара ханым, бар ягыгыз белән күңелемә бик хуш киләсез бит, — дип, диферамбалар җырлый академик «Х» әфәнде.

Йә, нәрсә диярсең. Әйт дөресен, җәннәткә керерсең. Минем кайчакларны әллә тәвәккәлләргәме дигән чакларым да була. Китап бит, унга чык, уңганчы чык, дигән. Сирәк кулъязмалар фондында эшләгәндә байтак укыштырдым мин аларны.

— Минем күрше егетемнең яраткан сүзе бар, берәр гамәлне инкарь итәргә теләсә: «Не в какоем случае!» — дип әйтергә ярата. Әйе, не в какоем случае! Мин каршы.

— Академик «Х» еш кына эш урыныма килгәли. Приятный агай. Килмәгез дип әйтергә кыюлыгым җитми, рәнҗетермен төсле тоела. Авыруларым арасында шик-мазар тудырмас өчен, миндә дәваланып чыккан пациент итеп танытам.

— Ул камытны кияргә уйлый да күрмә. Беренчедән, бик гыйбрәтле төрек мәкале белән кисәтәм. Аларда «моңа чаклы гел кара бәхетем карбыз алгач кына ак булды» дигән мәкаль бар. Әнә академик «Х» әче ак карбыз булмагае. Икенчедән, болары аргументларның иң көчлесе, син бит тулаем Вадим өчен һәм тырнак очы хәтле генә булса да минем өчен дә яралган җан. Мин фәкыйрең шуңа да баш түбәмнән риза.

— Мин дә риза, Ленар. Кая, шушы матур сүзләрең өчен баш түбәңнән үбим әле бер.

— Үпкәч-үпкәч инде аны...

— Ярар, син дигәнчә булсын!.. Мин сине чыплап бик сагынганмын икән...

Вакыт дигән нәрсә аккан су кебек ай-һай тиз уза. Сәгатемә күз салсам, кичке сигезләрдән авышып бара. Кузгалсам да бик вакыт икән. Клара да, син китә беләсеңме егет, дип әйтмәс бит инде.

Хуҗабикә исә, минем тынычсызлануымны күреп, гадәтенчә бераз тынкышрак калын тавыш белән:

— Хөрмәтле вә кадерле Ленар, мең төрле сәбәпләр тапсаң да, бүген мин сине беркая да җибәрмим. Политбюроның махсус карары шундый, бүген миндә кунасың, — дип өзеп куйгандай итеп әйтте.

Төнгә каршы кунар урын эзләп чыгып китәргә мин үзем дә атлыгып тормыйм, дөресен әйтим. Этикет, әдәп саклап кына кымшанганмындыр инде. Башкалар өчен ничектер, әмма минем өчен җаныңны һәрчак тартып тора торган чибәр хатын ул. Аның яныннан, куып чыгармаганда, кемнең китәсе килсен, җүләр. Тагын бер мәртәбә тәмләп чәй эчтек. Безнең сүз бер күрешүдә генә бетешлеме?

Янәдән күргән-белгәннәрен искә төшердек. Ваклап-ваклап кына булса да затлы шәрабларны тоткалап утыра торгач, тора-бара мин дә кыюланып киттем бит, әй.

Хуҗабикә өстәл яныннан торып урын җәяргә керешкәч, уенын-чынын бергә кушып:

— Клара, сөеклем, беткән баш беткән, калган көтү калган, урынны икебезгә җәй алайса... Башкайларыбызның икесен бер мендәргә салып, сине бер туйганчы кочып куну — минем һич тормышка ашмастай мәңгелек хыялым. Бу көтелмәгән очрак үзе үк шуңа ишарәли бугай... — дидем. — Тәкъдимемне артык фамильяр күрсәң инде, алай да өеңнән үк кумассың әле... Кешеләр хокукы дигән нәрсә дә бар бит әле. Шулай ич?

— Урынны... әлбәттә, икебезгә җәям, — диде ул, мине янәдән кочып алып. — Синең бу акыллы теләгең — минем дә күптәнге хыялым, Ленар әфәнде. Минем дә сине сөякләрең шытыр-шытыр килгәнче үз кочагымда кочып карыйсым килә... Нәрсә соң? Без соң әле кем алдында тирән бурычлы? Вадим ерак, академик агай не причем!

Төнге унберләр тирәсендә, тышта җылы су белән юынып кереп, хуҗабикә җәйгән йомшак урынга чумарга гына торганда, бер егет тә ияртеп, бүлмәгә кыштыр-кыштыр бер кыз кайтып керде.

— Нефтьчеләрнең данлыклы каласыннан Казанга сигез айлык хәлендә карынымда алып кайткан кызым шушы була инде — Элеонора, — диде Клара. — Икесе дә сәнгать училищесында укыйлар. Эляның кулы талантлыга охшый. Әмма холкы тач әтисенеке. Артыннан тере шәүләсе булып йөргән егеткә дә, картлык көнемдә миңа да игелек күрсәтмәс, ахры. Үҗәт бернәрсә булып үсеп килә. Каян туа диген шушындый игелексез балалар?

— Мамулечка, родная моя, что ты говоришь? При людях-то? При моем Рустике? Я тебя безумно люблю и никому в обиду не дам! Это у меня на всю долгую жизнь. Об этом по Интернету я сообщила на всю планету. Слышь, голубка моя, на всю планету! Ответственность я взяла перед всей планетой... Если вокруг меня полная эмансипация женщин, почему я должна в стороне стоять? А Рустик все это понимает.

Студентларның күзе өстәлдә. Аларның тук чагы бармы икән? Андагы ризыкларны алар күз ачып йомган арада чистартып куйдылар. Аннары, чаршау гына аерып торган «үз бүлмәләренә» чыгып, магнитофон кабыздылар. Яшьләр алдында, ике араны чаршау гына аерганда нинди инде ул кочаклашу? Килешмәгәнне! Ни теләсәк тә... Күзләрне күзгә төбәшеп, тезләрне тезгә терәшеп, ул төндә без керфек тә какмадык. Алай да үзенең матур бизәкләре белән күңел түреңне мәңгегә бизәрлек бу гажәеп матур кичтә синең тарафыңнан әлеге гамәлне үзе көтеп торган гүзәлне ничек инде суырып-суырып үбеп алмыйсың?

Җитмәсә, Элеонора, безнең янга чыгып:

— А я ведь вас заочно знаю. Мама мне про вас частенько рассказывала. Притом с чувством внутренней симпатии! Поверьте, вы очень милый человек. Я вас именно таким и представляла. А почему вы не целуетесь? Не бойтесь, характер у меня кремень, об этом я никому ни слова! Даже под пыткой! — дип сөйләнеп кереп китте.

Керфек какмасак та, төннең узганын сизмәдек тә. Ah, Клара, сөйкемлем, бу җиһанга син сөяр, иркәләр өчен генә туган җандыр. Вадимны да әйтер идем. Сөйгәнеңне кочагыңда эретүдән дә татлы мизгел бармы соң бу дөньяда? Ир- егетләрнең кайберләре әллә бөтенләй белмиләр бу турыда, әллә белеп тә, көндәлек тормыштагыча инертныйлар, ягъни карт алашадай ваемсызлар.

* * *

Кичә кичтән бирле мине бернәрсә борчыды. Чын күңелдән сагынган, юксынган кешеңне барыбер бер күрәсең икән. Менә бит күрештек. Язмыш үзе шулай теләгәндер. Иртәгә аерылышабыз. Язмышның бу бүләгеннән тагын нәрсә өмет итәргә? Бу изге җанга, читтән торып, ягъни заочно гына булса да, күп еллардан бирле гашыйк фәрештәмә, нинди генә изгелек кылырга соң? Мин аңларга тиеш, язмыш үзе бүләк иткән бу күрешүебез мәңге онытылмаслык бер матур хатирә булырга тиеш!

Иртән бер кат юынып, кырынып алганнан соң, Клараның чәе өлгергәнче, янәдән кибеткә чыктым. Карасам, якында гына бер «Белорусь» тракторы бар көченә көчәнеп ниндидер канау казый. Канау башына өч егет басканнар. Бер-берләренә ниндидер күрсәтмәләр бирә-бирә, сигарет көйрәтәләр. Бәхәсләшәләр. Андый чакта, башымда берәр фикер кылт иттеме, күп уйлап тормыйм, прямой наводкой бәрдерәм. Яннарына килеп бастым да:

— Егетләр, күп булса ярты сәгать эчендә шалт итеп кенә биш йөз доллар эшләп алырга дәртегез юкмы? — дидем.

Күрәм, тәкъдимем боларда әллә ни энтузиазм хисе уятмады төсле. Әллә мине аңлап бетермәделәрме? Әллә инде шаярта дип уйладылармы?

— Болай да баш чатнаган чак... Ачуны чыгарып, сару кайнатып йөрмәсәңче, агайне, — диде егетләрнең киң җилкәлесе, болай да чытык чырайларын тагын да сыта төшеп.

Хәер, моңарчы аларга мондый эшлекле тәкъдим ясаучы булдымы икән әле?

— Йөрмәче буталып, йә үзеңне берочтан бераз гына чәбәкләп җибәрербез, — дип тә өстәп куйдылар.

— Сезнең белән килде-китте сүз куертып торырга, егетләр, минем дә мыскал вакытым юк. Алайса, берәр сәгатькә генә тракторыгызны биреп торыгыз миңа. Әмма гонорары ике йөз доллар гына булыр. Арагызда сезнең кайсыгыз баш, кайсыгыз койрык?

Егетләрнең буйга озынрагы, чандыр гәүдәлесе, төпчеген ташлап, миңа йөзе белән борылды.

— Шаяртмасаң, агайне, йә, әйтеп кара, гозерең нидән гыйбарәт?

— Менә шушы ишегалдындагы әнә теге ялгыз йортка су кертергә кирәк. Әнә ул йорттан ун-унбиш метрлар гына читтә су колонкасы. Суны шуннан сузарга була. Әмма бу эшне Маршалыбыз Георгий Константинович Жуков Берлинны алгандай шалт кына эшләргә кирәк. Күп куйганда утыз-кырык минут эчендә. Чөнки минем дә вакытым бик чикле.

— Ай-яй горячий адәм күренәсең син, кем дип әйтик соң, чибәр абый кеше. Кулыңны маңгаеңа куеп кара әле, температураң юкмы икән? Белая горячка-мазар түгелме синдә? — диештеләр егетләр. Алай да бераз ачыла төштеләр сыман.

— Тәкъдимең, әгәр шаяртмасаң, күңелне генә түгел, табан асларына кадәр кытыклый кытыклавын. Чиертеп карарга була җимеңә. Биш йөз доллар? Без күргән-ишеткән нәрсәме? Дүрткуллап алынырга була бу эшкә... Анысы гына безнең кулдан килә, агайне, — кояш астында эшләп ярыйсы гына уңарга өлгергән буй-буй тельняшка кигән әлеге киң җилкәле егет алгарак чыкты. — Кәнишне, моннан торып кына берни әйтеп булмый. Барырга, күрергә кирәк. Безнең кулдан килерлек, без башкарып чыгарырдай мәшәкатьме? Без дә бит малай-шалайлар гына түгел.

— Миңа соң нәкъ шушы сүзегез кирәк. Менә монысы эшлекле сөйләшү. Барыйк та карыйк.

Тельняшкалы егет иптәшләренә карап алды да тамагын кырып куйды.

— Абый кеше, бу юлы чынлап торып соравым: шаяртмыйсыңдыр бит, шәт? Андый болтуннарга охшамыйсың охшавын. Алай да... Башта долларларыңны күрсәт. Монда, җиде юл чатында, аферистларның, жуликларның любой категориясе адым саен. Күзеңә карап, башыңа капчык киертеп китәргә дә күп сорамыйлар.

— Кара, әй, бүген иртән чәйне эчеп чәшкене каплагач, чынаяк астыннан пылт-пылт килеп күбекләр чыгып торды, — диде егетләрнең буйга озынрагы, озын чәчле, кыяфәте, килеш-килбәте белән Һади Такташка тач охшаганы. — Минем Әнисә шундук: «Рәфкать, күрәсеңме, бүген синең кесәңә көтмәгән җирдән умырылып шабашка керергә тора бит. Күбекләр акча керергә пылт-пылт итә. Ишетсен колагың, акчаңны тулысы белән өйгә алып кайт. Айрат әнә кайчаннан бирле биләсәфит сорый. Чыгарбыз да алып керербез», — дип юраган иде. Әнисә чынлап юраган, ахры. Бу эшкә алынырга кирәктер.

— Хатыннар юрый инде алар, — диде егетләрнең трактор кабинасында кымшанганы. — Юрауларының тик рас килгәне генә сирәк була.

— Рас килсен дисәгез, кыймылдагыз. Ә сез, авызыгызга калҗа капмаган килеш, һаман теш казып маташасыз.

Егетләрнең кып-кызыл майкасы өстеннән кыска җиңле сары камзул кигәне, лап-лоп атлап, өй белән колонка арасын үлчәп килде.

— Әй, агайне — ак мыек, чабата башы кыек. Абый кеше, ике ара син әйткәнчә ун-унбиш метрлар гына булыр, бар. Тот капчыгың! Минем бер метрдан озын адымнар белән дә утыз адымнар чамасы чыкты. Ышанмасаң, үзең үлчәп кара. Землемер таягыбыз юк, адымлап сана.

— Чыкса соң! Мин дә долларны артыграк чыгарырга мәҗбүр булырмын. Казан хәтле Казанда эт эчәгесе юанлыгындагы утыз-кырык метр торба табу сезнең кебек егетләр өчен проблема түгелдер инде?

— Түгелен түгел лә. Табуын да табарбыз... Ул да бит мани-мани, ягъни акча тора. Хәзер бушка черки дә тешләми. Барысы мани-мани сорыйлар, ягъни валюта.

— Биш йөз доллар да җирдә ятмый. Мин дә аларны маңгай тиремне сыпырып эшләп табам, егетләр.

— Анысын да беләбез, абый, җаныкаем, — дип, моңарчы сүзгә кушылмыйча трактор кабинасында утырып торган, авызы тулы көмеш тешле егет лып итеп җиргә сикерде. Монысы араларында иң тәвәккәле, ахры. — Долларлар алар, абый, җаныкаем, торналар канатында бит. Алар әнә ничек биектә очалар. Безнең тарафларга бик төшмиләр. Юкса мин долларларны үзем дә бик уважайт итәм. Егетләр, нәрсә карап каттыгыз, барыгыз, сварка артыннан йөгерегез. Мондый клиентларның безгә дә көн саен юлыгып тормауларын киртләгез колагыгызга. Аякларыгызны күтәребрәк атлагыз. Сваркасыз булмас монда. Ә мин траншеясын казый торам. Ходайның рәхмәтле сәгатендә «мәгез, кулыгызга биш йөз доллар тоттырам» дип торган кешегәме?! Табанын үбегез! Ул «эт эчәгеләрен» дә Казанны ике кат урарлык үзем табам. Базарга чыгып эзлисе юк. Аның запасы — завсклад Мөнирәдә. Казаннан Мәскәүгә җитәрлек! Бу торбаларны Ильяс конкрет үзенә сорады, диегез. Аның гозере миңа төшкәндә, мин ашыйсы ашымны читкә куеп чыгып йөгерәм. Ык-мык итеп тора күрмәсен. Андый гадәте дә бар аның... Ильяс үз кирәгенә сорады, диегез. — Ильяс, миңа карап: — Мөнирә — безнең авыл кызы ул. Миңа

беркайчан отказ бирми. Быел, язын авылга кайткач, берьялгызы яшәп яткан әнисе Сәрбиҗамал абыстайның арт бакчасын мендәр түшәгәндәй йомшак итеп сөреп-тырмалап бирдем. Әле менә киләсе ялда өй түбәләрен ябышырга өмәгә дәшеп тора, — диде. Ильяс, иптәшләрен дә ашыктырып: — Җәлт йөрегез. Бот арагызга ике потлы гер аскандай кыймылдамагыз. Күрәсез, клиент нинди горячий, сез дә очкын булыгыз. Абый кеше, син үзең дә берәр идарәдәме-контордамы йә прораб, йә баш инженердыр әле. Күрсәтмәләреңне бөтереңә таянып бирәсең, — дип өстәде. — Дөрес әйттемме? Кемнең кайсы авыл көтүен көтүен мин бер карау белән чамалыйм.

— Егетләр, эш беткәч алай да миңа бер ярты куярсыз бит? — дип күз кыстым. Араларны тагын да якынайту максатыннан инде.

— Берне түгел, икене, агайне. Түлке срокны бик кыска куйдың бит. Өлгерербезме? Ракета тизлеге белән ме?

— Сез ашыкмагыз. Җиренә җиткереп эшләгез. Мин, канәгать калып: «Менә бу эш! Долларлар җәл түгел!» — диярлек булсын. Әгәр мин сезгә ике көн срок бирсәм, сез аны биш көнгә сузачаксыз. Шулай бит? Элен-сәлен йөреп, аз эшләп, күп акча сорап йөрү рабочий классның үзенчәлекле сыйфатларыннан берсе.

— Анысы да дөрес, — дип хуплады Ильяс. — Башны дуракка салырга булса, безгә генә бир. Бая дөрес әйткәнмен бит. Абый кеше, менә безнең ише рабочий халкына йөгәнне момент кидерә беләсез. Муеныңа камыт, сыртыңа ыңгырчак салганны сизми дә каласың. Берүк, үзебез дә, күреп торасың бит, ике бозауга кибәк аера белми йөрүчеләрдән түгел. Барын да син кушканча, кырт итеп эшлибез аны.

...Клараның шатлыгы түбәсеннән ашты. Башка чакны авызымны киң ерып көлсәм, битемә җыерчыклар чыгар дип чамалап кына елмаерга күнеккән ханым иреннәрен җыя алмый. Чөнки төшке ашка суны җиз краннан агызды.

— Ленар, ты не представляешь, как нам теперь жить легче стало?! Не представляешь...

Ә монтажчы егетләр, монтаж эшләре тәмамлангач, миңа тиешле бер яртыдан баш тартуымны аеруча югары балл белән бәяләделәр.

Ильяс алай да:

— Абый кеше, бу чибәр апа кемең соң? Туганыңмы, бер-бер белгәнеңме? — дип төпченеп маташты. — Ай-һай тиз тоттың бит!

— Әйе, чибәр апам, чибәр апам...

Ильяс, сүзләренә күп мәгънә салып:

— Ул чакта, абый кеше, мин сиңа турысын әйтәм. Мондый чибәр апа өчен мең долларың да не жаль. Ник, шулай бит, егетләр?

* * *

Шушы гамәлләрдән соң Клара җибәрәме инде? Бик кыстагач, тагын бер кичкә калырга туры килде. Моннан бер еллар элек Вадим аңа Италиядән «Миланода тегелгән» дигән мөһер сугылган озын итәкле, кап-кара йон күлмәк салган булган. Шул күлмәген киеп, көзге алдында байтак боргаланганнан соң:

— Ленар, я уже сто лет не была в обществе, — дип куймасынмы. — Я хочу побыть в обществе.

— Соң, әйдә берәр затлырак, разрядлырак ресторанга төшик. Мин үзем дә шундый инициатива белән чыгарга тора идем.

— Бик затлы күлмәк бу. Аны илче хатыннары гына кия булыр. Алар мондый күлмәкләр киеп ресторанга йөрмиләр. Операларга йөри булырлар. Я тоже хочу в оперу. Безнең Казанда бер атна инде Свердловск Опера театры гастрольләре бара. Бүген алар Дж.Пуччининың «Мадам Баттерфляй» операсын куялар бугай. Ленар, голубчик, минем Чио-Чио-сан ариясен тыңлыйсым килә.

— Әй Алла икән, таптың проблема! Киттек операга.

Удача дигән шома койрык бер килсә, гел каршыңа гына чыгып тора икән ул. Лотерея билетларының да гел отышлылары гына эләгеп тора. Билетларны партерга ук алып кереп утырдык. О-о, егетләр, Кларадай чибәр белән опера карау — үзе бер театраль сәхифә ул. Алай гынамы? Эпопея! Моңа кадәр дә: «Эзләмә миннән, Ленар, матурлыкны. Чибәрлек өләшкәндә мин комда уйнап калганмын. Юк миндә матурлык, бары театраль бутафория генә», — дип сөйләнсә дә, бу кичтә Клара бер кашык су белән кабып йотышлы. Киенә-ясана белә инде ул. Шушы күзеңнең явын алырдай үзенә килешле йон күлмәге өстеннән бик затлы ап-ак мәрҗәннәр, түшәмнәргә аскан меңәр шәмле люстраларга сәлам биреп, «зайчиклар» уйнатырга сәләтле бижутерияләр аскан.

Минем гаҗәпләнүемне күреп:

— Вадим 8 Мартка салганые. Боларны тагып дөньяга беренче чыгуым. Сиңа ошыймы, миңа килешәләрме? Яшь күркә булып күренергә тырышкан карт гусыня түгелме мин? — дип тезеп китте. — Хатын-кызның чәче озын, акылы кыска, дия иде әнием. Мин не исключение.

— Клара, бүген син Көнчыгыш шаһинәсе генә түгел, Көнбатыш королевасы! Карале, үзең һаман Вадимнан зарланасың. Бу зөбәрҗәт мәрҗәннәр бик кыйбат торадыр әле...

— Бик кыйбат торалар бугай. Бәяләрен белү өчен генә комиссионкага алып барганыем, чүт кулымнан талап алып калмадылар.

Клара — бүгенге кичтә тамаша залын бизәүче чын королева. Шулай уйлап мин, бәлкем, ялгышамдыр дисәм, юк икән бит. Алтын-көмешкә, затлы мехларга төренгән җан бәгырьләре турында кайчак бөтенләй онытып, җәмгыятьнең иң куе каймаклары колонизацияләгән ложалардан да озак вакытларга бинокльләрен гел безгә төбәп утыручыларны да тоеп, сизеп, күреп торам.

Клара миңа еш кына күп мәгънәле итеп елмаеп ала. Башын иңбашыма салып:

— Ленар, әле дә син бар әле дөньяда, — дип куя.

Әллә безнең өчен генә бу кичтә солист һәм солисткалар да үз арияләрен ниндидер күңел күтәренкелеге белән, киерелеп җырлап башкардылар төсле. Чио-чио-сан ариясен башкаручы яшь кенә колоратур сопрано яңгыратты гына бөтен сәхнәне. Тавышы да киң диапазонлы, драматизмны да табигый бирә. Тамашачылар аның һәр ариясен алкышлар белән каршылап, сәхнәдән озак вакытлар кертми тордылар.

Ниндидер серен без аңлап бетермәгән бер көч, бер рух дәшмәде микән безне операга бу кичтә, дип уйламас җиреңнән уйлап куешлы. Тәнәфескә чыккач, фойеда тамашачылар барлап, үзебезне күрсәтеп йөргәндә, мин сиңа әйтим, дүрт-биш кешелек группадан аерылып, болай чибәр генә килеш-килбәтле бер агай каршыбызга килеп басмасынмы? Клара ханым да сискәнеп киткәндәй булды. «Академик «Х», — дип пышылдады.

— Сезне күрүемә бик шат, Клара ханым, — диде ул. Карашы аталарның балаларга сөеп, яратып карашыдай сымаграк. Бармагы белән миңа төртеп: — Бу кемегез? — булды аның икенче соравы.

Мин янәдән Ташкентта ук яшәгән, Мәскәүгә эш белән үтеп барышлый гына Казанга сугылган, Клара ханымның туганнан туган, әмма бик якын абыйсы булдым.

— Ә сез ничек монда, нинди җилләр белән?

— Мисыр кунаклары белән. Каһирә университеты галимнәре. Алар да безнең фондлардагы борынгы кулъязмалар белән кызыксыналар, үзләре дә безнең өчен яңа күп кулъязмаларның факсимилеләрен алып килгәннәр. Аларны бизәргә янәдән сезгә ялынырга ниятләп торабыз, Клара ханым. Ял көннәре үзебезнең фондка килепме, кайберләрен өегезгә дә алыпмы аларны тиешле зәвык белән бизәп бирсәгез, сезгә янәдән кабат һәм кабат рәхмәтле булыр идек.

— Мин бит алай ялындырып торучылардан түгел, Нияз Гариповић, — дип елмайды Клара. — Сезнең фондтагы китапларны бизәргә мин һәрвакыт әзер. Кызым Элеонораны да алып килермен. Шушы араларда сезгә үзем шалтыратырмын.

Академик «Х», ике кулын күкрәге өстендә кушырып, әйтәсе сүзен әйтергә кыймыйчаракмы таптаныбрак торды.

— Клара ханым, акыллым, минем иң төп гозерем дә көчендә кала... Әйе, көчендә кала... Сез гафу итегез, мине кунакларым көтә...

Чибәр ханымны култыклап театрга бару үзенә бер галәмәт могҗиза икән бит ул. Бу кичтә опера тыңларга килгән тамашачылар арасында Кларадан башка да чибәркәйләр булгандыр инде. Ничек булмасын ди?! Шулхәтле халык арасында? Әмма алар ничектер күзгә чалынмадылар шикелле. Чөнки без фойены аркылыга-буйга узып танылган опера җырчыларының стеналарга эленгән фотоларын карап йөргәндә, эчендә җаны булган барча ир-атның күзләре бездә генә булды бугай.

* * *

Су керттерүем турында сөйләп тормасам да яраган булыр иде. Сөйләнелде инде. Гаеп итеп тормассыз әле, шәт. Әгәр инде коттедж төзеп биргән яисә «Мерседес» бүләк иткән булсам, сөйләсәң дә булырые. Сүз иярә сүз чыга инде ул. Әхәт дустым ике айлар дигәндә тәмам терелеп, үз аягы белән кайтып төште. Ут чыгарып эшләп йөри. Ә менә күптән түгел генә телевизордан, Казанда узган Бөтендөнья татарларының III конгрессы уңае белән, Татарстан рәссамнарының зур күргәзмәсен күрсәттеләр. Бөтен диварны иңләп эленгән зур полотно янында... Чү! Ялгышмыймммы?.. Вадим картлачны күрдем. Казанга кайткан, күрәсең. Кайчандыр өч бөртек кенә булган җирән сакалы, хәзер учка йомарлык. Аның янында — бик кырыс, әмма бик затлы, үзенә бик килешле костюмнан Клара. Урталарында — кызлары Элеонора. Бу күренешкә ничек сөенмәскә инде? Чиксез сөендем, ихлас күңелдән. Бәхет дигән назлы кошның үземнән бигрәк дусларым кыегына ешрак кунуын, чүт-чүт килеп сайравын, оя корып балалар чыгаруын, алай гынамы, шунда даими яшәргә калуын теләдем мин. Дус-ишләремнең бәхетле яшәүләрен күрү минем өчен зур бәхет. Чын бәхет!

Чатан

Газинур, берсеннән-берсе чибәр, берсеннән-берсе уңган ике кызын — Гөлшат белән Айгөлне дә иярtеп, кеше-кара гына түгел, хәтта кыр тавыгы да уза алмастай куе урман-чытырманлыкны кичеп,

кәләпүштәй җыйнак, бар почмакларын җылы кояш нурлары иркәләгән-назлаган, бик тә аулак бер аланга килеп чыктылар. Абау! Бер якта башың әйләнердәй хәтәр, менә-менә убырылып-ишелеп төшәргә әзер текә яр. Аста, тирән чокыр төбендә, сазлыктан чыпчыкка да тездән инеш саркый. Кыл урталыкта, кәкре-бөкре озын тамырларын күккә ямьсез чөеп, биредә байтак еллардан бирле ятып тәмам сөяк булып кипкән, тораташ булып каткан карт имән ята. Аны кайчандыр әллә шаярып кына яшен сугып киткән, әллә дуамал давыл аударганмы? Иртәнге чыкка чыланып, билдән чат су булып шушы аланга килеп керсәләр, тамаша! Әлеге имән тирәли бер өер эт-маэмай балалары мәш килеп әүмәкләшәләр. Дөнья матур, дөнья киң боларга. Шушы сүзнең иң-иң киң мәгънәсендә. Әнкәләре дә тапкан бит оя корырга шундый аулак почмак! Бик акыллы җан иясе булса кирәк.

Көчекләр онытылып, нәкъ балаларча әүмәкләшүләрен беләләр. Бернидә гамьнәре юк. Соңыннан, еллар узгач, һәркем сагынып искә алган бер хәсрәтсез, бер кайгысыз бәхетле балачак шушы буладыр инде ул. Газинур һәм аның апалы-сеңелле кызлары кичләрен, үз аланнарыннан торып, шушы шыптыйларның чәң-чәң килүләрен иштеткәннәр икән. Имәндә булып чыкты бит чикләвек!

Көтмәгәндә, уйламаганда гына берәрсе килеп чыгып аяк басышлы түгел шул бу аулак алан. Ай-яй! Шуңа күрәдер көчекләрнең дә бернидә гамьнәре юк. Җаннары тыныч. Әүмәкләшеп-әүмәкләшеп, рәхәтләнеп уйнауларын беләләр. Газинурның кызлары бермәлне аларга хәтта бераз кызыгып та карап тордылар әле: бер кайгы-хәсрәтсез бәхетле балачак нәкъ менә шушы мизгелләрдер инде ул. Көчекләр, ара-тирә бөтенләй кызышып китеп, бер-берсенең колагын йә тәпиен тешләп алалар. Колагын йә тәпиен тешләткәне шундук бөтен урманга шар ярып чинап җибәрә. И-и, син! Елакның елагы икәнсең! Чебен тимәс чер итәр кеше җан икәнеңне белмәдек бит. Белгән булсак, уенга да катнаштырмаган булыр идек, дип, башкалары аңа тәпи янап та алалар. Чинарлык булгач, кермә безнең арага! Бер читтә генә утырып тор!

Ә тегесе, сезгә шул тешләшергә генә булсын. Әйем, уйнамыйм мин сезнең белән, дип үпкәләп, читкә үк китеп утыра. Аннары, үпкәсен шунда ук онытып, янәдән иптәшләре арасына килеп кушыла.

Көчекләр арасында берсе, иң матуры, кара, әй, күзгә күренеп кәегрәк. Җитмәсә, бераз чатанрак та бугай әле. Анысы уенга да юньләп катыша алмый: атлый да абына, атлый да егыла. Монысы әнкәләренең иң сөйгәне, иң яратканы, төпчеге бугай. Төпчекләр һәрчак шулай бераз кәегрәк була бугай алар.

Көчекләрнең гамьсез уйнауларын килештереп карап торганнан соң, кара, әй, бик ишле түгелме соң болар, дип куйды үзенә-үзе Газинур. Бармакларын бөкте, саный башлады. Берәү, икәү, өчәү... Абау! Җиде үк түгелме соң? Бу тикле тиктормасларны әнкәләре ничек туендырып өлгерә икән? Бичара ана ул кадәрен үзе генә белә булыр. Хәер, балалары күплегеннән кайсы ана зарлана инде? Шатлана, сөенә генә булыр. Ана өчен балаларының кайсы да саф энҗе бөртеге бит! Балалар менә шул хакыйкатьне беркайчан исләреннән чыгармасалар икән алар...

Алар ерып чыккан куелыктан алан бик яхшы күренә. Маэмай балаларының өннәре кайчандыр җилдавыл аударып ташлаган әлеге карт имән куышында икән. Җылы, бик ышык җирдә. Өн алдында, икеөч җирдә, чүмәлә-чүмәлә булып сөяк өемнәре ята. Әнкәләре өстерәп кайтканда, алар арасында симез итле, майлы-сеңерле, татлы желеклеләре дә булгандыр. Бу шайтан чыбыкларына аларны ташып кына өлгер. Сөякләрне бик оста кимереп, тәмам ялтыратып, шомартып бетергәннәр. Яңаларын ташый тор. Аягың талса да, табаныңа ут капса да зарланма. Монысы ананың изге бурычы.

Көчекләрнең, әйе, анда-монда эшләре юк, әүмәкләшеп уйнауларын беләләр. Ара-тирә, әйе, үпкәләшеп тә алалар. Барыннан күбрәк әлеге чатан тәпигә эләгә. Абыйлары күбрәк аны кыерсыталар. Кайда да, хәтта кешеләр арасында да шулай бит ул. Өлкән абый-агайлары төпчек туганнарын, үзенә аерым бер ярату белән яратсалар да, үзләре дә сизмәстән кыерсытып та куйгалыйлар. Күп чакта, син әле кечкенә, бездән дә акыллырак булып кыланма, дип. Кылансаң, кирәгеңне дә хәзер аласың. Үзеңнән өлкәнрәкләрне кечкенәдән үк ихтирам итәргә өйрәнеп үс! Тормышның нигезе шундый хакыйкатькә корылган.

Боларга хәзер дүрт-биш атналар гына бардыр, артыгырак булмаса. Көчекләр туганда дөм сукыр булып туалар бит. Аларның күзләре ике атналардан соң гына ачыла. Ә бу шыптыйларның күзләре кесә фонарьлары уты кебек уйнап торалар.

Бу нарасыйларның гамьсез уйнауларын тын да алмый күзәтеп торганнан соң, Газинур «кхым! кхым!» дип тамак кырды. Шул җитте. Көчекләр башта шып булдылар. Аннары, уеннарын ташлап, өннәренә йөгерделәр. Әлегә болай хафага төшәрлек нәрсә күренми. Аларга берни дә янамый. Бераздан, өннәреннән башларын тыгып: «Әй, сез кемнәр буласыз? Без сезне белмибез, танымыйбыз. Безнең аланыбызга ни дип килеп чыктыгыз? Йөрмәгез монда безне шикләндереп, куркуга салып», — дип, кисәтүле-янаулы тавыш белән чәң-чәң килделәр. Үзләренә күрә генә түгел болар. Әнә ничек ризасызлык белдерәләр. Янәсе, ни пычагым калган сезгә монда? Менә әниебез кайтып кермәсме әле? Ул кайтса, күрсәтәчәк әле сезгә күрмәгәнегезне. Безнең аланыбыздан үкчәгезне күтәрегез тизрәк!

Көчекләрнең әлеге абына-сөртенә атлаганы, чатаны, арада иң кечерәге генә аларны күреп әллә ни өрекмәде. Уйнаган җирендә утырып калды. Аннары, бөтенләй кыюланып китеп, күптәнге танышларын

очраткандай, Гөлшат белән Айгөл апалары каршына килеп утырды. Башын бер яккарак янтайтып, аларга төбәлде. Янәсе, берегездән-берегез матур апалар, сез кемнәр буласыз соң? Безнең аланыбызга каян килеп чыктыгыз? Мин үзем сезне күрүемә чиксез шат. Сезнең белән танышырга буламы?

— Син, бәләкәч, ай-яй кыю малай күренәсең, — дип, Айгөл иелеп аны кулына алды.

— Әтием, менә монысы бигрәк матур, — дип, көчекне башыннан сыйпап, аны күкрәгенә кочты.

Тегесе дә тартынып-нитеп, тыпырчынып тормады. Айгөл апасының куенына йомшак курчак булып сыенды.

— Ә тәпиләре менә ничек йомшак! Күзләре ничек матур итеп карыйлар. Абау, ә менә борыны боз кебек салкын. Әтием, бу бәләкәч авырмыймы, аның температурасы юкмы икән? — дип сорады Айгөл.

Шунда Газинурның йөрәге жу-у-у итеп китмәсенме. Болар бит! Болар бит көчекләр түгел! Болар теп-тере бүре балалары! Менә сиңа мә! Газинур һәм кызлар, үзләре дә сизмәстән, бүре оясы өстенә килеп чыкканнар. Айгөл кочагында да маэмай — эт көчеге түгел, теп-тере бүре баласы, чү, саграк була күрсен. Өннәре авызыннан башларын тыгып, хор белән чәң-чәң килүчеләр дә безнең як урман-далаларының иң дәһшәтле, иң кансыз ерткычларының берсе — Соры бүре балалары! Ай-яй-яй! Газинур моны хәзер генә төшенде. Нишләргә хәзер?

— Борыннары салкын булганда, алар киресенчә тап-таза буладыр, кызым, — диде Газинур. — Паникага бирелергә ярамый. Синең кочагыңдагы бәләкәч тә тап-таза. Ләкин кочма, хәзер үк җиргә җибәр үзен.

— Әтием, бу бәләкәчне әллә үзебез белән аска, үзебезнең аланга алыйкмы? Бигрәк матур бит. Безне дә ошатты...

— Ярамый! — диде Газинур. — Хәзер үк җиргә төшер үзен... Ирегенә җибәр!

— Әтием! Үтенеп сорыйбыз.

— Ярамый булгач ярамый! Җибәр! Үзебез дә тизрәк китик бу аланнан... Киттек, киттек! Үзебезнең аланга төшәбез.

Газинур мәктәптә укыган елларында, үзләренең Кара Чишмәләрендә җиденче сыйныфны тәмамлаганнан соң, алардан биш чакрымнар ераклыктагы Түбән Чыршылы авылына барып укып йөрде. Мәктәпләрендә көнаралаш үткәрелгән төрле чараларда актив катнашып, концертларда җырлап, спектакльләрдә уйнап, кайчакларны авылларына кичке чорларда берүзе генә кайткан кичләре күп булды. Ике авыл арасында калын гына урман бар. Халык әвәл-әвәлтеннән «Бояр урманы» дип йөртә бу урманны. Менә шул урманда бүреләр күп үрчегән, дип сөйли халык. Барын да бар инде. Бер тора торгач, шул урманнан өерләре белән төшеп, колхозның сарык фермасына бәреп кереп, сарыкларны буып чыкканнары булды. Ә һөҗүмнәре уңышлы чыкмаганда, авыл урамында очраган этләрне дә урлап киткәлиләр. Менә шул бүреләрдән саклану чарасы итеп Газинур букчасында өч ел рәттән бер бәйләм коры чыра йөртте.

Ул чорларда бер бөртек шырпының баш бәясе торган чагы. Алыйм дисәң, кибетләрдә дә юк. Китап-дәфтәрләр йөрткән букчасында, нәни генә киндер янчыкта, игәү кисәге, чакматаш, өстендәге куфайкадан гына йолкыган коры мамык кисәге дә йөртте. Ул кайтасы юл өстенә бүре-мазар чыгып утырса, Газинур тиз генә шул чакматашны алып, мамык кисәгенә ут төртеп, чыраны кабызырга тиеш. Әнисе чыраларны, бәйләү энәседәй юка итеп, тик кара чыршылардан гына телә. Чөнки кара чыршыдан телгән чыралар бенгаль утлары төсле бер дә галәмәт, як-якка чытыр-чытыр очкыннар чәчрәтеп яналар. Әй-й-й, шушылай чытыр-чытыр очкыннар чәчрәтеп янган чыраны күрсәме?! Күңелендә иң усал ният булган бүре дә, шундук коты алынып, качу ягын караячак. Бенгаль утлары тагын да күбрәк очкыннар таратып яна да януын. Бүреләрнең котын шундук алган булыр иде дә. Ул чакларда бенгаль утлары да юк иде шул. Букчасында гел бер бәйләм чаралар йөрткәнгә классташлары ничек кенә шаярмыйлар, ә Газинурның үзен «Чыңгызхан гаскәре укчысы» дип тә йөрттеләр.

Бу чыра бәйләменнән ул үзе дә бик туя иде. Алып чүплеккә ташлаган чаклары да булды. Әмма әнисе Бибинур апай улының букчасына аларны сиздерми генә салып куя иде. Алай да кара чыршыдан телгән чыраларның бер кирәге чыгып куйды бит. Ул язны аларның мәктәбендә бөек шагыйребез Габдулла Тукайның туган көненә багышланган кичә булды. Шул кичәдән аның белән бер сыйныфта укыган күрше кызы Кадрия белән соң гына кайтырга чыктылар. Март ахыры, апрель башлары. Аяк астын чак кына чираткан. Бик матур айлы кич. Бояр урманын чыгып җитешле генә җирдә күрәләр: юл өстенә өч бүре чыгып утырганнар. Газинурлар ерактан ук сөйләшеп килсәләр дә, бүреләрнең кузгалырга, юл бирергә исәпләре юк. Кадрия бөтенләй куркып калды. Курыкмассың, бар. Үтәсе юл өстендә өч бүре утырып торсын әле.

Кадрия:

— Беттек без, беттек! Әнкәйләребез, бичараларыбыз, иртәгә безнең коры сөякләребезне генә күрерләр инде. Әҗәлебез шушы икән, — дип шыңшый ук башлады. — Борылыйк, кире авылга йөгерик, — ди.

Газинур шунда, тиз генә чыраларын алып, берьюлы өчне яндырып җибәрмәсенме! Чыралары, әлеге бенгаль утларыннан да болайрак очкыннар чәчрәтеп, чытыр-чытыр янып китмәсеннәрме?

Газинур, бөтенләй батыраеп китеп:

— Хәзер, чак кына көтегез! Өчегезне берьюлы өтәлим мин сезнең! Өчегезнең дә койрык астына янган чыра кыстырам, — дип, тегеләр өстенә китмәсенме!

Тегеләр дә аның тарафыннан мондый батырлыкны көтмәгәннәрдер. Чытыр-чытыр очкыннар чәчкән утлы чыраларны күреп алуга, койрыкларын бот араларына кыстырып, каршы як үргә таба шылдылар. Карт бүреләр булса, бәлкем, алай куркып та төшмәсләр иде. Ә болар әле бер кыш кына кышлаган яшь бүреләр иде бугай.

Берни булса, «Кешеләр! Кешеләр!» дип аһ итәләр. Әниләребез безне, алардан бик сак булырга кирәк, дип кисәтәләр. Кемнәр икән алар Кешеләр. Шуларны үз күзләребез белән күрик әле, дип, юл өстенә бернинди усал ниятсез чыккан яшь бүреләр булганнардыр алар. Ул чакта Газинур чыннан да аларны утлы чыралары белән чак тотып өтәләмәде, йоннарын көйдермәде.

Менә бу аланда әүмәкләшүчеләр дә теп-тере бүре балалары. Башлары зур, тәпиләре озын, танаулары очлы. Койрыклары да артык озын, шөкатьсез. Колаклары тырпайган. Кем белә, бәлкем, әнкәләре дә шушы тирәләрдә генә йөри булыр. Хәзер, менә шушы минутта атылып кайтып керсә?.. Кайтып керсәме, җүләр!

— Ә-ә, кунаклар бар икән бездә! Хуш килдегезме? Әйдүк, әйдүк, кадерле кунаклар! Түрдән узыгыз! — дип колач җәеп каршы алмас. Арыслан булып ажгырып өстеңә ташланыр.

Газинурның бөтен тәне буйлап югары көчәнешле электр тогы узгандай булды. Тәненә салкын тир бәреп чыкты. Чыкмас, бар. Бала дигән зат кемгә дә бик кадерле. Бала дигәндә ана утка да керә, суга да сикерә. Чебешләренә куркыныч янганда, хәтта чуар тавык та, үзен-үзе белми, тилгән-карчыга, хәтта бөркет өстенә ташлана. Ә бу шукларның әнкәләре — Соры бүре! Ерткычның ерткычы. Аннан теләсә нинди явызлык көтәргә була. Яхшы, исән-имин чакта бу аланнан тизрәк ычкынырга, үкчәңне ялтыратырга кирәк.

Газинур сәгатенә күз салды. Көндезге унберләр тирәсе. Шушы минутларда, бәлкем, аларның әнкәләре, сыртына берәр үр куянымы, үрдәк-казмы йә божыр-байбак түшкәсеме салып, һәркайсы ач бүредәй ач балалары янына ашыгадыр. Тизрәк, һич кичекмичә китәргә кирәк аларга бу аланнан.

— Кызым, ике әйттермә, хәзер үк төшер көчегеңне кочагыңнан, иптәшләре янына җибәр! — диде Газинур, кырыс тавыш белән.

— Нигә, әтием? Кочагымда тәмам эреп ята бит. Әйдә, монысын үзебез белән аска алыйк. Без аны куе сөт белән сыйларбыз. Бу көчек миңа бигрәк ошады.

— Төшер, дидем! Җибәр хәзер үк! Ярамый аларны хәтта кулга алырга! — диде әтиләре, бу юлы нык кискен итеп. — Киттек бу аланнан! Киттек! Үз аланыбызга төшик! Әниләре кайтып керүе бар... Ул чакта...

Газинур, кызларын куркытмас өчен, аланда уйнаган көчекләрнең эт-маэмай балалары түгеллеген, ә кансыз, ерткыч Соры бүре балалары булуын әйтмәде. Бу юлы аның кулында күп итеп теленгән кара чыршы чыралары да юк. Шалашлары каршындагы юкә ботагына элеп куйган, түтәсе ярык берданкасын да алмаган иде. Дөрес, билендә үткен хәнҗәре бар. Урманда хәнҗәрсез дә йөрми инде ул. Кулында чукмар башлы чикләвек таягы. Ана бүре кайтып кереп, алар өстенә ташланса, күз күрер. Бирешмәс.

...Әйе, аңар гына бирешмәс. Ике кызын да артына бастырыр. Хәнҗәре белән кизәнер, кулында чукмар башлы таягын уйнатыр. Һәрхәлдә, буш кул гына түгел бит. Аннары, нигә әле тавыш куптарырга? Әлеге аланга басып керүчеләр алар. Алан — бүреләрнеке. Һәр ананың үз оясын, үз балаларын сакларга хакы бар. Бу йөкне аларга Табигать үзе йөкләгән. Аланына кайткач, аңа бүре ни кылса да хаклы. Ул үз биләмәсендә, үз өнендә. Әйе, исән-имин чакта, тавыш-гауга куптармый, аларга моннан тизрәк китәргә кирәк.

Айгөл кочагына алган, борын очыннан гына ике-өч тапкыр пәп итеп өлгергән чатан тәпи генә «нигә инде алай тиз китәсез? Үзегезне күргән төсле дә булмадым. Алайса, үзегез белән мине дә алыгыз, пожалуйста» дигән төсле, аларны алан чигенә хәтле килеп, күңелсез генә озатып калды.

Айгөл апасы, кат-кат артына борылып, аңа кул изәде.

— Хәзергә сау булып тор, Чатан! Көт мине. Синең яныңа мин әле тагын менәрмен. Без синең белән чын дуслар булып китәрбез. Мин сине әле яңа гына ачкан бик тәмле сөт консервасы белән сыйлармын. Беләсеңме нинди тәмле ул! Телеңне йотышлы. Көт, яме! — дип ышандырды. — Хәзергә сау булып тор, матурым. Чатан аяк, бик ошадың син миңа.

Инде алан читенә җиткәч, Чатанны тагын үз янына дәшеп:

— Кил алайса, юеш борыныңны шушы кулъяулыгым белән корытыйм. Юкса чебеннәр кунып борчырлар үзеңне. Чиста йөр, иртән торгач битеңне юарга онытма, — дип, аны янәдән кулына алып, танавын сөртте. Чатанның борын очыннан гына тагын бер тапкыр пәп итеп алды.

Әтиләре, кече кызының бу гамәлләрен килештермичә:

— Җитте инде, җитте! Кхым! Кхым! Киттек бу аланнан! — дип кат-кат тамагын кырды.

* * *

Матур җәйләр җитеп, чәчәкләргә ишелеп бал төшәр алдыннан Газинур ел да шулай итә: умарталарын машинага төяп урманга чыгара. Шулай эшләмичә соң! Аның берсеннән-берсе уңган-булган кызлары ишегалларында утырган ак мунчаларына суны авылның теге башындагы ук буаданмы, әллә ишегалдындагы коеданмы күбрәк ташырлар? Әлбәттә, коедан. Умарта кортлары да шулай. Алар да балны ояларына авылдан җиде-сигез чакрымдагы болыннанмы, әллә оялары артында ук утырган йөзәр еллык юкәләрдән күбрәк ташырлармы? Әлбәттә, баш очларындагы юкәдән!

Быел Газинур умарталарын, бер-берләрен күп еллардан бирле белгән җиде умартачы агай белән бергәләп, Коногоровка урманына чыгарырга сөйләшкәние. Булса, бал шушында булачак инде. Коногоровка урманында гел юкәлек. Кочакласаң, кочагың җитмәстәй юаннары, йөзәр еллыклары бар. Барысы шашып чәчәк атарга җыеналар. Һәр елны алай булмый. Йә кыш артык салкын була, йә җәе коры килә. Юкәләр дә ел саен шашып чәчәк атмыйлар. Быел менә ышандыралар балны. Дөресрәге, нектарны. Ә бал дисәң, бер кими, кашык тыксаң, биш кими торган үзе татлы, үзе искитмәле ризыкны нектардан ясыйлар. Кич утырып, төн йокламыйча. Алар көндез җыйган нектарны балга әйләндергәндә, умарта оялары төннәрен дә кайнап утырган самавырдай гөжләп торалар.

Башта, беренче эшләре итеп, урманга чыгып, күңелләренә хуш килердәй аланлык сайлап, аның печәнен чабып өйделәр. Умарталарны машиналардан бушатканда ук, ипләп кенә утырта барырга казыклар кагып чыктылар. Бу ышык аланда аларга кимендә берәр айлар чамасы яшәргә туры киләчәк. Чәй кайнатырга, бит-кул юарга урыннар билгеләделәр. Барысы да сыярлык иркен, биш көн рәттән яңгыр койса да су үтмәслек итеп шалаш корып куйдылар. Янәшә генә көмештәй саф сулы чишмә агып ята. Монысы иң кирәклесе. Чөнки җәйнең бу чорында умарта кортлары суны ат урынына күп эчәләр. Оялары алларындагы агач тагаракларга суны аларга салып кына өлгер. Эчәр сулары алларында булмаса, кортлар аны эзләп ерак араларга очалар. Бал җыясы урында, үзләренә һәм оядагы ун меңнәрчә балаларына су ташып, вакытны бушка уздыралар. Чәчәкләргә җәен бал төшү чоры болай да кыска. Аның һәр минуты алтын бәясенә тиң.

Кортларны чыгарырга урманда урын әзер. Бик матур аланны сайладылар. Тачокка* кем кайчан чыга, кайчан күченә, анысы һәркемнең үз эше. Үз җаена карый.

Газинур, эшне озакка сузмыйча, шул кичне үк күченергә булды. Мондый чакны бик тәвәккәл булу кирәк. Юкса поезднының китеп баруы да мөмкин. Елның елында Газинурның кортларын күршесе Ильяс күчерешә. Шәһәрне яшелләндерү, төзекләндерү конторасында кортлар төяп йөрергә бик ипле, әрҗәсе бик киң йөк машинасын йөртә ул. Ильяс бу кичне Газинурлар капка төбенә сәгать кичке сигезләр тирәсендә үк килеп туктады. Әмма җәйнең бу чорында кортлар бик соңгача очалар, ояларына да тәмам караңгы төшкәч кенә кайтып утыралар. Аларның кырдан кайтып беткәннәрен кичке уннарга кадәр көтәргә туры килде. Көндез төялсәң, бар кортың очышта, басуда калачак. Кортларның утырып беткәннәрен көтеп, оя авызларын юеш чүпрәкләр белән томалап чыкканчы төнге унберләр дә җиткәндер.

Машина кабинасына, дәшкәнне-чакырганны да көтмичә, Газинурның ике кызы — Гөлшат белән Айгөл дә кереп утырдылар. Алар шулай һәр елны әтиләре белән тачокка чыгалар. Сезгә, кызларым, малайлар гына булып туарга булган, дип, бер дә юкка гына әйтми булыр әтиләре. Тачокка чыккач, алар ниләр генә кыланмыйлар. Моңарчы тып-тын утырган урман аланнарын аякка бастыралар. Карамадан җәяләр бөгәләр. Уклар ясыйлар. Иң хәтәр ботакларга арканнар бәйләп таган атыналар. Кайчакта әтиләре орышып та куя үзләрен. Чөнки нидән дә булса бераз шүрләп, куркып калу аларга бөтенләй ят нәрсә. Кызлары урманның аяк басмаган почмагын, барып актармаган аланын калдырмыйлар. Әтиләренә ярдәмнәре дә җитәрлек. Аңа нык булышалар. Рамнарга яңа кәрәзләр тарталар, умарта күче чыга-нитә калса, аны җыешалар. Әтиләре, аларны орышкан чакны да, бик кадерләрен белеп, яратып кына орыша.

Алар күченәсе көнне, төшкә чаклы, утка бастырып кыздырды. Тын алышлы булмады. Ә кичке якта ишеп яңгыр явып китте. Ә төнгә, ертып үтә алмаслык стена булып, бар җиһанга куе томан төште. Коногоровка урманы болай үзе йөз тапкыр йөрелгән, белгән җир. Әмма көндезен казыклар кагып кайткан аланга Ильяс әллә барып җитмәде, әллә узып китте. Менә хәзер көч-хәл белән томан пәрдәсен ертып барган юллары бөтенләй таныш түгел. Бара торгач, бөтенләй таныш булмаган кварталга барып керделәр. Юлны чынлап торып ялгыштылар, ахры.

— Кире борылудан файда юк. Киттек шушы урман юлы буйлап, — диде Газинур. — Себер тайгасы түгел, бер читенә чыгарбыз әле, шәт. Бу юлның да бер очы булыр. Иплерәк кенә алан да бетмәгәндер. Әйдә, Ильяс, алга, газуй!

Белмәгән, бер кат узмаган урман юлы башваткычларның да иң мәкерлесе бит ул. Монысы да чокыр да чакыр булып чыкты. Чокырлар барысы да су белән тулы. Шул чокырларга кереп чума-чума, ни алга, ни артка китә алмыйча, бер урында таптанып торып, байтак чакрымнар уздылар бугай. Көндезен сайлаган аланга тәки чыга алмадылар. Җәйге төн терсәк буе гына. Әнә яктырып та килә инде. Машина әрҗәсендә егерме биш баш умарта! Һәр оя эчендә җитмеш-сиксән мең баш җан иясе. Аларга анда гаять тынчудыр.

Газинур бер араны машина әрҗәсенә менеп карап төште. Һәр оя корыч торбасына нарат-чыршы күркәләре салып кайнаткан самавыр кебек гөжли. Аларга туктарга, кичекмичә йөкләрен бушатырга кирәк. Юкса машинадагы кортлар пешәчәкләр. Оя эчендә тынчуга хәзер түзешле түгелдер. Чөнки аларның авызы ябык, саф һава керми. Яңа урынга күченгәндә бер елны шундый хәлгә тарыды инде ул. Юлда озаграк юанып, вакытында бушатырга соңарып, ул чакта Газинурның бер оя кортлары пештеләр. Ике су чиләге үлгән, дөресрәге, һәлак булган кортларын бушатты ул җиргә. Яннарына утырып еламады гына. Әгәр шул ике чиләк кортларын исән-имин килеш урман яланына чыгарып утырткан булсамы?! Алар Газинурга кимендә өч-дүрт чиләк бер дигән юкә балы җыеп биргән булырларые.

Әйе, менә хәзер дә кортларны бер минут кичекмичә бушатырга кирәк. Юкса харап булачаклар. Туктап, иплерәк урын сайлап йөрер ара калмады. Ни булса, шул булыр дип, юл өстендәге беренче аланга бәреп керделәр.

Газинурның күршесе Олыяз Ильясы бик булган егет ул. Берәр эшкә алынса, кулыннан гөлләр тама. Кортларны да тиз бушаттылар. Җиргә төшергән бер ояның авызын ача бардылар. Газинурның кортлары да нәкъ аның үзе кебек уңганнар, булганнар. Әлеге аланда әйтерсең алар инде мең еллар яшәгәннәр. Чит итеп, ят итеп тормадылар. Оя авызларын ачу белән баш очларындагы юкәләргә ашыктылар. Мондый тамашаның шаһиты үзең булу кирәк. Шунсыз аны төшенү кыен. Дөньялыкта шундый могҗизалар барын моңарчы белмәгән, ишетмәгән, күрмәгән ярым кыргый урман яланы, иртәнге чык, куе томан төсле, Бөек Бетховенның атаклы 9 нчы симфониясенә тиң симфония белән тулып килә. Бу бөек музыка, аһәң алдында йөз еллык юкәләр дә тез чүгәргә әзер. Башкасын әйткән юк, әле йокыдан гына уянып, үз эшләре белән ашыгырга җыенган күбәләкләр дә, юл өстендә очраган беренче чәчәкләр керфегенә кунып, бер мәлгә тын калдылар. Җиһанда яшәү, тереклек итүнең төп мәгънәсе менә шундый булырга тиешлеген раслап, аланны били башлаган симфонияне тик беренче класслы маэстролар гына башкара булыр. Увертюрага керешне беренче булып башлап, әлбәттә, прима-скрипка суза. Чылтыр-чылтыр аккан чишмә авазларын чыгарып аңа арфа кушыла. Кошлар булып кларнет сайрап ала. Тромбон, күпсанлы быргылар туып килгән иртәне сәламлиләр. Җир йөзен барлыклары белән бизәргә дип, кешеләрдән кырык миллион еллар алда туган умарта кортлары, дөньялыкта бүтән тиңдәше булмаган иң затлы, иң баллы, иң шифалы Бал галиҗәнапларын җыярга керешкән мизгелләр бу. Моңарчы ялгызы утырып торган аланда бәйрәм бүген. Уңыш җыюга керешү бәйрәме! Шушы процессның гади бер шаһиты булу да сатып алырга да таба алмаслык бәхет ләбаса! Газинур моны бөтен тәне-җаны белән сиземли. Җирдә яшәвенә сөенә. Ә кайчакларны, бөтенләйгә хыял дөньясына чумып, үзен-үзе аңлап бетермәстәй мизгелләр кичерә. Авызым, иреннәрем кабартма булып шешмәгәе дип тормый. Булмаса, бераз хәл җыеп, ял итеп алыйм дип, аның иңнәренә, җиңнәренә кунган кортларның әле берсен, әле икенчесен кадер белән генә алып, үбеп-үбеп очыра. Аларның уңганлыкларына, булганлыкларына, зирәк акылларына сокланып, баш иеп, бил бөгеп, тез чүгеп. Хәер, аларны шулай яратмаган кеше умартачы да була алмый торгандыр. Монысы бәхәссез хак! Җир йөзендәге барча кешеләр исеменнән бу тырыш җан ияләренә рәхмәтен дә шул рәвештә җиткерә булыр. Чөнки җир йөзендә өч йөз меңнән артык җан иясе яши. Гажәеп коточкыч зур сан бу! Филләр, арысланнар, крокодиллар, очар кошлар. Бер эләктереп алса, арысланыңны буардай көчле анакондалар, еланнар, күбәләкләр. Ә менә шул өч йөз меңнән артык җан ияләре арасында бал дисәң, бер кими, кашык тыксаң, биш кими торган гаять шифалы ризыкны тик Бал кортлары гына җыялар. Җыя беләләр. Саклый да беләләр. Татар да бер дә юктан гына әйтмәгәндер: «Бал бозылмый, кыз картаймый!» Дөрес сүзгә җавап юкның нәкъ менә конкрет очрагы бу. Борынгы Мисырның дөньяны тетрәткән фиргавеннәре дә зур бер бит кәгазьгә сыешлы озын исемнәре, дәрәҗәләре соңында һәрчак «Бал корты углы» дип тә өстәп куя булганнар. Шул сүзләрне дә өстәмәсәң, дәрәҗәң тулы дәрәҗәле саналмаган.

Инде яктыргач, бераз күз-баш алгач карасалар, чын әгәр, үкенер җирләре юк. Ат дагасыдай ярым түгәрәк, үзе ышык, үзе җыйнак кына бик матур аланлыкка килеп утырганнар бит алар. Кортлары гына түгел, аланлыкны кызлары да ошаттылар. Төне буе килеп, аннары кортлар бушатып, кызларының күзенә бүген йокы эләкмәде.

Гөлшат, әтисе каршына килеп, дәррәү булып эшкә керешкән кортларга ымлап:

— Безнекеләр сыгачак бу аланнан балны! — диде. Әтисенә шаян күз дә кысып алды.

— Изге сәгатьтә әйтелгән сүз булсын, кызым. Бирегә чыгып утыруыбызның да төп максаты шул бит инде, — дип елмайды Газинур. — Сыксыннар! Безгә генә түгел, илгә, табигатькә шифа. Кортларыбыз канаты тиеп киткән һәр үлән, һәр чәчәк сафлана, яшәрә, серкәләнеп, яшәреп кала. Табигать бер дә белми, ахырын уйламый гына яратмагандыр Бал кортларын. Җир йөзендә Кешеләр дигән затлар барлыкка килгәнче 40–45 миллион еллар элек. Җир катламнарын казып-казып өйрәнүче геолог агайлар моны шулай дип раслыйлар!

* * *

Уң якта, тау астында чишмә чылтырый. Үзләренә дә чәй кайнатырга, кортларга ташырга да су эзләп йөрисе юк. Аланның әйләнә-тирәсен йөзәр еллык юкәләр бизи. Барысы да менә-менә шау чәчәккә

күмелергә торалар. Юкә чәчәк атканда тараткан хуш исне тагын нинди генә тәмле исләр белән чагыштырып була икән? Аны сулыйсың, сулыйсың, ә тын юлларың киңәйгәннән-киңәя, иркенәйгәннән-иркенәя төсле. Юк, Парижның үзендә чыккан иң затлы хушбуйларның исен дә чәчәк атканда юкәләребез тараткан искитмәле тәмле ис белән рәттән куеп булмас төсле. Ә соң балы! Юкә балы белән тагын нинди ризыкны тиңләргә була?! Мичтә уңып, мамык мендәр булып күпереп пешкән ап-ак күмәчебезне генә бер рәткә куя алабыз.

Бал булачак быел бу аланда! Коногоровка урманына шуның артыннан чыктылар да бит инде. Гомумән алганда, чәчәк аткан чорларында нектарны бик күп үләннәр һәм чәчәкләр бирәләр. Аларның кадерен белеп җыючы умарта кортлары булмау, җитешмәү сәбәпле, табигатьтә елның елында миллионлаган тонналар бал җыйналмый кала. «Җыйналмый кала» дигән сүз дөньяда көндәше булмаган иң затлы ризыкларның берсе өстәлләребезгә эләкми дигән сүз. Һәм бик кызганыч! Илебездә умартачылыкны җәелдерергә кирәк. Халкыбыз да сау-сәламәт, шат күңеллерәк, озын гомерлерәк булыр.

Алдан белми-күрми, шулай очраклы гына килеп кергән аланны Газинурның «малайлар гына булып туасы» кызлары да ошаттылар. Әтиләреннән болай уздырып, аны үзләштерергә керештеләр. Йөгереп кенә чишмәгә төшеп су алып менделәр. Бит-кул юарга урын билгеләп, кышын үзләре чиккән матур тастымал-сөлге элделәр. Учак тергезеп, чәй куеп җибәрделәр. Умартачылар арасында чәйне казанда кайнату юк. Үзләре сыйган машинага җиз самавыр да сыя. Умартачылар умарталыкта җәйне җиз самавырда кайнатып эчәләр. Кортлар карый-карый тәмам тамагың кипкән чакта җиз самавырдан кайнар чәй агызып эчүләре, и-и-и, бер дә галәмәт үзенә бер ләззәт ул! Бал кабып түгел. Бал шапыртма тиргә төшерә, тирләтә. Шалашың ышыгында кайнап чыккан чәйне керт-керт итеп шакмаклы шикәр кабып эчәләр. Шикәрнең дә нинди татлы ризык икәнен чынлап торып менә шунда сизәсең. Аның һәр шакмагына аерым бер ихтирам хисе белән үреләсең.

Чәй өстәле булачак җиргә Газинур кызлары радиоалгыч элделәр. Иртәнге якларда һәм кичен яңгырый торган татарча концерт та монда, урман яланында, аеруча моңлы, адәм баласы өчен бик кирәк икәнлекләрен сиздереп яңгырыйлар. Газинур үзе җыр остасы түгел. Кичен, кортлар утырып беткәч, бер мәлгә урман тып-тын кала. Кош-кортлар да кыштырдашмыйлар. Ярканатлар да әле ауга чыкмаганнар. Баш очыннан гына очып-очып киткәләмиләр. Шундый сихри тынлыкта, радиодан татарча җыр-моң агылганда, Газинур да концертка кушылмый кала алмый. Тамагын кырып тора да, «Керим әле урманнарга, урманның карасына» дип җырлап җибәрә. Урман килештерә аның бу халәтен. Тып-тын калган урманда аның «Керим әле урманнарга»сы бик ераклларга тарала, аннары кайтаваз булып кире аланга кайта. Галәмәт халәт инде!

Аларны китергән Ильяс абыйларына иртәнгә эшкә кайтып өлгерергә кирәк. Бер чынаяк кына чәй эчте дә эшенә ашыкты. Ара чыкса, хәлегезне белергә кичке якларда тагын бер әйләнермен әле, дип ышандырды.

Әлеге аланны, Газинурның үзеннән, «малайлар гына булып туасы» кызларыннан бигрәк, аның кортлары ошаттылар. Картрак юкәләрнең очлары инде чәчәккә күмелеп килә. Ояларының авызларын ачу белән кортлар шул юкәләр очына омтылдылар. Хәзер аларны берни белән мавыктыра да, берничек тә туктата да алмыйсың. Физиклар-атомчылар телендә бу процесс «необратимая цепная реакция», ягъни «һичбер нәрсә белән туктата алмаслык чылбыр реакциясе» дип атала. Газинурлар туктаган әлеге аланлык бик зур аэропортны, берсе артыннан берсе очарга торган уннарча реактив самолетны хәтерләтеп жу-у-у килеп тора. Тормаска! Бер оядан гына да утыз-кырык меңләп корт очып чыгып, нектар төяп, кире кайтып тора.

Газинурның кызлары да аланда уздырган көннәрен, әтиләре янында шалашта кунган кичләрен үз тормышларындагы иң бәхетле минутлары итеп саныйлар бугай. Кортлар да чагып бетерә үзләрен. Күзләре бөтенләй кысылып, йодрык хәтле борын белән йөргән чаклары да була. Әмма зарланмыйлар. Коеп яуган яңгыр астына эләгеп туңганнары, өшегәннәре дә бар. Бер елны алар тачокка чыгып утыргач, дүрт көн рәттән яңгыр койды. Алар янына машина белән керешле булмады. Ашарларына бары каткан ипи генә иде. Зарланмадылар. Тачокка чыгабыз, дип кенә торалар. Гөлшат инде җиденче сыйныфны тәмамлады. Айгөл дүртенчегә күчте. Умартачы Газинурның иң үткен кызы Айгөл бугай. Былтыр, алдына ап-ак алъяпкычлар ябып, Әлмәт базарында әтисенә бал да сатышты. Базардагы балның иң хуш ислесе, иң татлысы алар тәпәнендә булды, ахрысы. Халык мактый-мактый алар балын алды. Алмаска! Урманның уртасына чыгып җыйган бал ничек инде татлы, ничек инде хуш исле булмасын? Хикмәт балда гына микән? Ә сатучысы да курчак кебек матур кыз бит: ике бит уртасында берәр кашык су салырлык чокырлары бар. Күзләре чиста күк йөзедәй зәп-зәңгәр. Үзе бик ягымлы тагын. Алардан бал алучыларның һәркайсына рәхмәт әйтеп, барысына исәнлек-саулык теләп кала.

Тәпәннәре балдан бушагач, әтиләре дә кызларының күптән сораган үтенечләрен исенә төшерде:

— Кулың җиңел булды бит, кызым. Син дә булышкач, балыбызны тиз арада сатып бетердек. Болай булгач, теге сез сорап йөргән компьютерны алып бирми булмас, — дип, Газинур машинасын базардан туп-туры компьютерлар сата торган кибеткә тотты.

* * *

Газинурлар аланнан чыгып китүгә, сыртына бер сарык бәрәне салып, тәмам арып, әлсерәп, Ана бүре үзе кайтып керде. Ah! итте ул, алан читенә аяк басу белән. «Ah! Беткәнбез! У-у-у!» дип бөтен урманга ямьсез улап җибәрде. Аланда йөгерешкән уллары куркышып өннәренә качтылар. Шулай ямьсез улап кайтып керде шул Ана бүре аланына. Чөнки биредә бүреләрнең иң хәтәр, иң куркыныч дошманы Кешеләр булганнар бит! Моны ул аланга аяк басканчы ук, йөз адымнар алдан сизде. Балалары, кадерлеләре, күз нурлары исәннәрме икән? Юктыр! Бирегә Кешеләр бер дә юкка гына килмәгәннәрдер. Ходайның рәхмәтеме, балалары исәннәр түгелме соң? Өннән берәм-берәм чыга башладылар. Әниләрен күреп алуга, сарык бәрәненә ташландылар, аны ботарларга керештеләр. Ваемсызлар! Гамьсезләр! Ана бүре алай да әниләргә генә хас сөю-ярату хисе белән аларның барын да янәдән бер күздән кичерде. Балакайлары әнә ничек тәгәрәшеп үсеп киләләр бит. Көзләргә инде үз көннәрен үзләре күрә башларлар.

Ана бүре, балаларын имчәктән аергач, бер араны аларны үзе ашаган ризыкны ашказанынан кикереп чыгарып ашатты. Хәзер бу шайтаннарны алай гына туйдырырсың, бар. Әнә бит ничек күзгә күренеп, тәгәрәшеп үсеп киләләр. Бәрән түшкәсен дә әнә ничек белеп ботарлыйлар. Баштарак, нәниләре туган шәпкә, аларны карашырга әтиләре дә булышканые. Хәзер күренми. Үзенә башка бер яшьрәк, чибәррәк кәләш тапканмы? Тапса инде. Ана бүре әлегә тормышыннан зарланмый. Урман иркен, бай. Иренмә, йөгер генә. Кирәгеңне табарга була. Балаларына бурсык, сусар, кама да тотып кайткалый. Кыр кәҗәсе, поши балаларына да юлыкканы булды. Урман сукмакларында үз үлемнәре белән үлгән кош-корт, җанварларның үле гәүдәләренә юлыкса да, борынын җыерып узмый. Оясына барын өстери. Җидәүләр бит! Шуларны бер башың белән асрап кара. Булсалар соң! Ана бүренең үз әнисе аларны унөч баш итеп тапканые әле. Берсен дә өненнән кумады. Ашатты, имезде, иркәләде. Аларның нәселе шундый игелекле, уңдырышлы, үрчемле. Өннәрендә унөч ач күз булсалар да, Ана бүре үз әнисенең зарланганын хәтерләми. Ашатты, үстерде. Берсен дә имчәгеннән өзмәде, үзеннән читкә кумады. Хәзер менә ничәсе исәннәрдер, соңгы вакытларда күрешә алганнары юк. Исәннәренең һәркайсы үз көннәрен үзләре күрә булырлар.

Ана бүре, сыртына салып кайткан түшкәне балалары алдына салганда ук:

— Балакайларым, татлыларым, сезгә тамак ялгап алырга нибары биш минут ара бирәм. Соңарганчы, харап булганчы, безгә бу аланнан һич кичекмичә качарга кирәк. Белеп калыгыз, балакайларым, Кешеләр безнең иң мәрхәмәтсез дошманнарыбыз. Алар булган җирдә безгә көн юк. Кешеләр безнең аланда да булганнар бит. Ничек әле сезне җыеп алып китмәгәннәр? Җайлары килмәдеме икән? Юксамы?! Бер булгач, алар монда янәдән киләчәкләр, — дип кисәтте. — Килерләр дә барыгызны җыеп арыш капчыгына тутырырлар. Аларның кулларында мылтык дигән, авызыннан көлтәсе белән ут, үлем чәчә торган дәһшәтле кораллары бар. Шул коралларын да тотып менсәләр, нарасыйларым, сезне мин дә коткарып кала алмам. Моннан хәзер үк качу ягын карыйк. Соңармагаек, балакайларым!

Бүреләр арасында беркая язылмаган, әмма буыннан буынга бик төгәл тапшырылып һәм үтәлеп килә торган Закон яши. Бүреләр барысы да үз өннәреннән, ояларыннан кимендә утыз-кырык чакрымнар читкә китеп аучылык итәләр, ризык табалар. Бүреләр, ерткычлар дигәч тә, алар өчен ашар ризыкны беркем дә алдан әзерләп куймаган, урман аланына китереп аудармыйлар. Берәр әрләнме-йомранмы, әллә үр куянымы эләктерү өчен аларга озын телләрен асылындырып күпме чакрымнар чабып узарга туры килгәнен үзләре генә белә булырлар. Көне буе чабып та, берни таба, эләктерә алмасаң, сарык-кәҗә көтүләренә дә һөҗүм итми хәлең юк. Төннәрен урманга якынрак берәр авылга төшеп, берәр этне буып, йә каз-үрдәк түшкәсе, кызыл кикрикле әтәч чәлдереп кайткан чаклары да булды. Әгәр инде оя-өн корган, анда балаларың калган урманга бик якын торган авылларга төшеп, аларның сарык бәрәннәрен еш ташый башласаң, ул авылларның агайлары да түзәләр-түзәләр дә, беркөнне сәнәкләр, күсәкләр белән коралланып, авыл өстендәге урманга облава, тентү ясыйлар. Урманның иң куе, һичкем эзләп таба алмаслык җиренә яшергән өнеңне үзләре күрмәсәләр, бүреләрнең мәңгелек дошманнары — этләре-бурзайлары табып күрсәтәләр. Ә инде сарык түшкәләрен кырык чакрымнар читтәнрәк урласаң, авыл агайлары, шулкадәр арадан килеп, синең ояңны эзләп йөрмиләр. Әлеге Законның нигезендә шушы хакыйкать! Шушы хәйлә!

Ана бүре яшерми, үз гомерендә куян да, төлке дә тотты. Поши-болан, тана, хәтта колын буган чаклары да булды. Әмма ул үзен мыскал да юлбасарга һәм җинаятьчегә санамый. Менә аның балалары, кәҗә йә сарыклар төсле, печән ашасалар икән. Аларга ул печән генә ашатыр иде. Печәнне кышка да күп итеп җыеп, киптереп куяр иде. Ә балалары печән ашамыйлар шул, ит-сөяк таптыралар. Ана бүре үзе дә ит, майлы-җелекле сөякләр кимерергә ярата. Аларны кибеткә кереп кенә, үзеңә кирәгенчә генә үлчәтеп алышлы түгел. Ашыйсы ризыгыңны уннарча километрлар әлсерәп чабып табарга кирәк. Әмма ул үзенең җир йөзендә булуы, җир йөзен барлыгы белән бизәп яшәвенә чиксез горурлана. Табигать аны сөеп, яратып яраткан. Аңа җете күз, сизгер колак, бер дигән тешләр биргән. Кыю холкы, батыр йөрәге, көненә йөз чакрымнар чабып үтеп тә аруны белмәгән аяклары белән горурлана. Табигать-анабыз

бүреләрне җир йөзенә тудырган чакта ук, аларга гаять җаваплы һәм зур бурычлар да йөкләгән. Хәтта аларга: «Улларым, сез бу Җиһанның профессиональ санитарлары!» — дигәндер әле. Бу исем белән тик горурланырга гына мөмкин.

Чыннан да шулай бит. Әгәр дә мәгәр бүреләр булмаса, җир йөзен күптән үләксәләр басар иде. Үләксәләр тараткан авырулардан, йогышлы чирләрдән җирдәге барча тереклек кырылыр иде. Хәтта кулын-битен юып, тешләрен чистартып, атна саен мунча кереп йөргән кешеләр дә. Җирдәге тереклек әлегәчә исән-имин яшәүләре өчен беренче чиратта бүреләргә бурычлы. Чыны шул!

Алай гынамы?! Бүреләр Табигать-анабызның бер дигән селекционерлары! Урман-кырларыбыздагы кош-корт, кыргый җәнлекләрнең елдан-ел нәселләрен яхшырту да алар өстендә бит. Булсын ат-сыер көтүе, поши-боланнарныкы, аларга ялгыз башың белән генә һөҗүм итешле түгел. Алтын яллы ажгырып торган айгырлар, теләсә, үсеп утырган имәнне аударып китәрлек көчкә ия үгезләр көтүләрен ай-яй оста саклыйлар. Батыраеп араларына керсәң, ахырын уйла. Билсез калма. Ә пошилар үгезенең күп япьле мөгезенә эләксәң, йолдызларга ук очуың да мөмкин.

Көтүләргә уңышлы һөҗүм оештыру өчен аларга җиде-сигез бүредән торган артельгә берләшергә туры килә. Мондый чакта атаман бүре һәркайсы алдына конкрет бурыч куя. Андый чакта беренче эшләре итеп көтүне һәрьяклап чорнап алалар. Әле теге, әле бу яктан һөҗүм иткән булып, көтүдә паника тудыралар. Балыкны бит болганчык суда тоту җиңел. Максат — көтүдәгеләрне алар өчен ипсезрәк җиргә, аланга кысрыклау. Мондый чакта көчеңне кызганма. Ажгырып-ажгырып көтү өстенә кил дә кире чиген. И-и, сөйләп кенә бирешле тамашамы соң бу мизгелләр! Бөтен тәнеңне, барлыгыңны, моңарчы синдә тыелып торган дәрт, ашкыну баса. Күзләрең ут булып яна. Йөрәк ярылырдай булып тибә. Һөҗүм дәрте белән үз-үзеңне, ни кылганыңны белештермәс хәлгә киләсең. Бияләр дә, ап-ак тешләрен ыржайтып, арт аякларына басканнар. Мондый чакта айгырларның арт аякларына юлыкма.

Сыерлар көтүендәге күзләрен кан баскан үгезләрнең мөгрәвеннән агачлар чайкала. Чөнки аларның әлеге һөҗүме үлем белән яшәү арасындагы көрәш бит. Биредә кем акыллырак, шул гына исән кала. Әмма дөньяны күргән бүреләрнең күбесе шушы мизгелләр тәмен бер генә тапкыр тату өчен дә җаның жәл түгел дип исәплиләр. Әйе, мондый һөҗүмнәр корбансыз да булмый. Җанын фида кылучылар да булып тора. Әмма мондый һөҗүмнәр — җирдә Бүре заты булып яшәүнең иң бөек ноктасы. Аннан бер бүре дә беркайчан да баш тартмас!

Әйе, кайчакларны алар пошилар, боланнар, ат-сыер көтүләренә җиде-сигез бүре бер артельгә берләшеп, күмәкләшеп һөҗүм итәләр.

Ләкин хәтта үр куянының да үткене, җитезрәге, хәйләкәре бүре тырнагыннан качып котыла ала. Пошиларның, атларның-бияләрнең дә җитезләре, көчлеләре, зирәк акыллылары. Бүреләр бит беренче чиратта көтүдәге гарибрәк, аңгырарак, чирләшкәрәк затларны буалар, аяктан егалар. Дошманнарыннан тибешеп, тешләшеп, сөзеп котыла алучыларның балалары да зирәк акыллырак, зиһенлерәк, үткенрәк булалар. Алар арасында табигать шартларына тагын да җайлашу, камилләшү, нәселне саклау һәм тагын да яхшырту селекциясе әнә шундый конвейерга куелган система белән бара. Бу изге эштә, әлбәттә, бүреләр төп рольне уйныйлар. Ә Кешеләр менә шул турыда хәбәрдар микән? Беләләрме икән? Белсәләр, нигә соң алар бүреләргә карата шулай үчләр? Ана бүре менә хәзер дә балаларына нибары биш минут вакыт бирде. Аларга бу аланнан хәзер үк китәргә, качарга кирәк.

Ана бүренең төпчеге, чатаны, иң яратканы, имчәк өмет итеп әнисенә якынлашты. Бүтән чакны әнисе аны башкаларыннан аерып иркәли иде. Төпчек бит шулай тәмлерәк, татлырак була инде. Аның бу юлы да бераз иркәләнәсе килгәндер. Чөнки абыйлары да гел кыерсытып кына торалар бит үзен.

— Абай, балам! Төпчегем! Беткәнсең бит! Бу минуттан син минем балам түгел! — диде Ана бүре. — Син бит Кешеләр кулында булгансың. Синнән ургылып Кешеләр исе килә. Сине яныма якын китерешле түгел. Якын киләсе булма, балам. Кешеләр исен миңа да йоктырырсың, мине дә харап итәрсең, күз алмам.

Ана бүре төпчеген алгы тәпие белән төртеп тә җибәрде әле. Чатан тәпи, бичаракай, тәгәрәп үк китте. Хәтта чинап җибәрде.

Ана бүренең моннан егерме чакрымнар гына җирдә запас өне бар. Кайда икәнен бары үзе генә белә. Кайчакларны кереп бераз ял да итеп чыга. Дөнья эшен белеп булмый, запас өнсез дә яшәргә ярамый. Бу сыйфатны да алар бер-берләренә буыннан буынга кайчандыр Тәңренең үзе биргән буенча түкми-чәчми тапшырып киләләр. Запас өннең кирәге менә хәзер чыгып куйды бит. Ана бүре балаларын шунда күчерергә карар итте. Шушы кичтә, төн эчендә үк. Чөнки аларны монда калдырырга ярамый. Кешеләр бирегә янәдән киләчәкләр. Ана бүре шунысын да ишетеп белә: район Хәзерләүләр конторына бер бүре баласы тотып китерүчегә бер капчык он, бер капчык шикәр бирәләр икән. Әгәр инде Ана бүренең үзен үк тотып китерсәң, өч көпчәкле мотоцикл белән бүләклиләр, ди. Ана бүре үз тормыш тәжрибәсеннән шуны да сиземли: Кеше дигән зат дөнья малы дигәндә җанын кызганмый, бер карында яралган туганының бугазын чәйнәргә әзер. Бу очракта да аптырап калмаслар. Әлегә берни аңламаган, бернидән шикләнмәгән җиде бүре баласы уйнап йөргән аланга, капчык авызларын киң ачып, иртәгә үк менеп җитәрләр. Ана бүре янәдән «Кешеләр соң безне ни дип шулкадәр сөймиләр икән?» дип уйлап алды.

Җир өстен сафлыкта, пакьлектә тоту өчен Табигать-анабыз тарафыннан махсус расланган санитарлары булуыбызны белмиләр микәнни?

Бу кадәре шулай. Аланнан мөмкин кадәр тизрәк ычкынырга кирәк. Ана бүре балалары янына тәмам арып, талып кайтса да, кичләрен аларга алдагы көннәрендә хәвеф-хәтәрсез көн итү буенча иң кирәкле сабакларны бирергә дә өлгерә иде. Болары да аңа Тәңре йөкләгән бурыч. Менә бүген дә, шушы кымкырыс арада да: «Балакайларым, алдыгызда кызыл флажокларга юлыксагыз югалып калмагыз!» дип кисәтте. Ни-нәрсә ул кызыл флажок? Нигә аның алдында югалып калмаска? Аларын аңлатып торырга ара калмады. Алай да янә бер тапкыр: «Юлыгызда кызыл флажокка юлыксагыз югалып калмагыз, тотып ашамас» дип кабатлауны кирәк тапты. Шунда ук срочный эвакуация эшләренә дә кереште. Балаларын муеннарыннан кабып, ут капкан ашыгычлык белән берәм-берәмләп запастагы өненә күчерә башлады.

* * *

Газинурның кызлары каядыр якында гына эт-маэмай балаларының чәң-чәң килүләрен әлеге аланга умарталарын китереп бушаткан кичтә үк ишетә башладылар. Ишетеп алалар да әтиләре янына йөгерәләр.

— Әти, син әллә чынлап чукракланып барасыңмы? Әнә бит якында гына ничек ап-ачык итеп өрәләр. Барып карыйк әле үзләрен. Нинди көчекләр икән алар? Урман куелыгына аларны кем китереп ташлаган? Әллә намуссыз хуҗалары өйләреннән куып чыгарган берәр әнкә эт бирегә килеп балалаганмы?

Кырык эше кырылып ятканда да, Газинур кызларының үтенечен үтәми калмый ул. Менделәр. Урман куелыгыннан чәң-чәң килеп яткан көчекләрне эзләп таптылар. Әмма алар көчекләр түгел, тептере бүре балалары иделәр. Әниләре — юлыңда очрамасын — канечкеч ерткыч! Аның да ниндие әле! Иң миһербансызы! Ирек куйсаңмы? Бөтен көтүеңне, бөтен авылыңны кырып чыгарга да күп сорамаслар. Шул кансызлыклары өчен Кешеләр, бер тора торгач, аларның тамырларын ук корытмак булалар. Шиклерәк күренгән урман-чытырманлыкларга облавалар, тентүләр ясыйлар. Ояларын, өннәрен туздыралар. Ләкин аларның тамырларын алай җиңел генә корытырмын димә. Сизгерләр, бик хәйләкәрләр алар. Кайчакларны аучыларның исләрен китерердәй акыллы карарлар кабул итәләр, адымнар ясыйлар. «Ай-яй-яй! Хуҗа Насретдин зирәклеге бар үзләрендә» дип баш чайкарга гына кала. Хәер, хакыйкать бәхәссез. Иң көч-кодрәтле дошманнары Кешеләрдән дә акыллырак булмасалар, алар нәселләрен дә саклый алмаган булырларые. Күптән юкка чыккан булырлар иде.

Газинур кичә аланда гамьсез уйнаган көчекләрнең бүре балалары булуларын кызларына әйтмәде. Куркырлар, дип уйлады. Аларны кулга алырга ярамаганын да әйтмәде. Бу аланнан тизрәк төшеп китү ягын гына ашыктырды.

Төнлә бөтен Коногоровка урманын каплап, дөбер-шатыр күк күкрәп, күзләрне чагылдырып яшен яшьнәп, бик көчле яңгыр ишеп китте. Юкәләр чәчәк атарга җыенганда мондый яңгырның бик үк кирәге дә юк. Яңгыр чәчәкләрдәге нектарны юа. Әмма әйләнә-тирәдәге юкәләр төрлесе төрле яшьтә. Берләре инде чәчәк атарга керешсәләр, икенчеләре әле җыеналар гына. Яңгырның зыяны зур булмады. Киресенчә, шифасы күп булгандыр әле. Ничә көннәр торган эсселектән соң урман бөтенләй сафланып китте. Ә бал булачак. Анысы шиксез!

Умарталыкта эш һәрчак муеннан. Әнә бер оя күч аерырга ниятли. Ирек куйсаң, очып чыгарлар да буең җитмәс биеклеккә кунарлар. Ул агач башына озын баскычлар куеп менәргә калса, кыен була инде. Яхшысы — күчне очып чыкканчы ук җыеп алу. Ә кызлары, әтиләре янына килеп, янәдән теге көчекләр янына меник әле, дип сорый башладылар. Аларның усал, кансыз бүре балалары икәнен белмиләр бит. Газинур да кызларының бәләкәй генә үтенечләрен үтәми калучымы соң?!

— Алар барысы да нинди арыклар. Әнкәләренең сөте җитеп бетмидер. Ә Чатансыйрак арада иң арыгы. Монда кичтән калган ярты чуен тәмле ашыбыз бар. Әниләре дә кайтмаган булса, барысы да нык ачыкканнардыр, — дип, аерым савытка салып, кызлары шул калган ашны да алдылар.

Бу юлы Газинур, күп еллар рәттән үзе белән умарталыкка алып йөри торган, ярык түтәле булса да, берданкасын да алды. Алар аланга килеп кергәндә әниләре шунда булса, Алла сакласын! Газинурларны, хуш килдегез, әйдүк, түрдән узыгыз, дип каршы алмас.

Бүреләр алар, мылтыкның үзеннән бигрәк, дары исеннән куркалар. Дәһшәт бит дарыда. Утны ул чәчә. Курыксалар, шул инде. Профилактик максатларда дигәндәй, Газинур, мылтыгын һавага төбәп, бөтен урманны яңгыратып берне гөрселдәтте әле. Мылтык тавышын Коногоровка урманының бер почмагында да ишетми калмаганнардыр. Хәзер алар менәчәк аланда да.

Менсәләр... Кичә котырынып-әүмәкләшеп бүре балалары уйнаган алан буп-буш, тып-тын. Аланнан дошман явы узганмы диярсең. Шушы кыска төн эчендә, коеп яңгыр яуганда, Ана бүре балаларын запастагы өненә күчереп тә өлгергән. Ни арада? Җидәү иделәр бит. Үзендә дә чыдамлык бар икән. Запас өне моннан егерме чакрымнарда гына булса да, ике якка кырык чакрым. Җидесен ташып өлгерткәнче өч йөз чакрымнарга басамы? Кып-кыска җәйге төн эчендә бит. Коры чыдамлык кына

түгел, Тәңренең үзе тарафыннан йөкләтелгән ыру-нәселен саклау бурычы, аңардан да бигрәк балаларын өзелеп сөю, ярату көче әрле-бирле чаптыргандыр инде бичара Ананы. Хәер, бала дигән татлы җан өйрәтә, ут йоттыра аналарга.

Әлеге аланнан әз генә өстәрәк, чыршы, нарат үсентеләре утырту өченме, урманчылар трактор белән сызган киң генә ызан бар. Яңгыр алдыннан гына аны тырма белән тырмалап та чыкканнар. Ана бүре балаларын яңа өненә ташыганда, муеныннан каптырган көчекләрен шул ызан өстенә салып, еш кына ял иткән. Аның аяк эзләре дә җир өстендә ярылып яталар. Шул эзләргә карап, тирән хисләргә чумып, Газинур байтак вакыт уйланып торды. Бала дигән зат хәтта бүрегә, кансыз ерткычка да ничек татлы, кадерле икән. Тормышны аны яшәгән саен тирәнрәк аңлый барасың шул...

— Әтием, кичә монда калган көчекләр кая киткәннәр соң? — диде Айгөл, гаҗәпкә калып.

— Кызым, алар эт балалары түгелләр иде бит. Алар җидесе дә канечкеч ерткыч бүре балалары иделәр. Сезне куркытмас өчен бу турыда мин сезгә әйтмәдем генә.

— Бүре балалары?! — диделәр кызлары, икесе дә бер-авыздан.

— Теге мин кулга алган иң матуры, чатан тәпилесе дәме?

— Барысы да, барысы да, кызым.

— Абау! — диде Гөлшат. — Ничек инде алар бүре балалары булсыннар? Үзләре нинди матурлар. Шаяннар. Ышанасы да килми.

— Ә башка кош-корт, җәнлекләрнең балалары матур түгелләрмени? Тавык чебешләре, үрдәк бәбкәләре? Кәҗә, сарык бәрәннәре нинди матурлар. Бозаулар, колыннар соклангычлар. Тумыштан ук тешләре ыржаеп торсалар да, хәтта крокодил балалары да матурлар. Табигать аларны шулай матур итеп тудыра.

— Әниләре аларны сөйсен, яратсын өчен! — дип куәтләде әтисе сүзен Айгөл.

— Әйе, нәкъ шулай, кызым, — дип килеште Газинур.

— Чатан аякны мин кочагыма алып сөйдем. Башыннан сыйпадым. Иркәләдем. Борын очыннан гына хәтта ике-өч тапкыр пәп итеп тә алдым. Аннан бернинди дә бүре исе килмәде. Бик сәер, — дип сузды Айгөл.

— Күп булса, ай ярымлык баладан нинди бүре исе килсен, кызым? — диде Газинур.

Шул чакны менә мә! Моңарчы каядыр качып яткан җиреннән чыгып, озын койрыгын болгый-болгый, алар алдына Чатансыйрак килеп басты.

— Чүгез әле, чүгез! Бу кем була соң әле? — дип куйды хәтта Газинур да, тәмам аптырашка калган хәлдә.

— Бу безнең Чатансыйрак бит! — дип, Айгөл аны шундук кочагына алды.

— Алай-й-й! — дип сузды Газинур. — Аңлашыла-а, димәк, Ана бүре төпчеген үзләре белән алмаган. Әллә монысы артыннан әле кайтып өлгермәдеме икән? Алай түгелдер. Өлгерер иде. Сәбәп бөтенләй башкада. Сәбәп бездә булырга тиеш. Ана бүре төпчегенә: «Балам, үпкәләмә дә, чинама да. Үзәгемнең ничек өзелгәнен, мең-мең кисәкләргә телгәләнгәнен үзем генә беләм. Әмма сине, нәнием, үзебез белән ала алмыйм. Син Кешеләр кулында булгансың. Синнән, бар урманга сибелеп, Кешеләр исе килә. Ә Кешеләр — безнең иң хәтәр дошманнарыбыз. Йөрәгем ни сыкраса да, ни телгәләнсә дә, сине абыйларың янына, запас өнебезгә ала алмыйм, җаным. Абыйларыңның иминлеге хакына. Гәрчә арагызда иң яраткан, сөеп-иркәләп туймаган балам син булсаң да. Үпкәләмә, шыңшыма, кичерә күр мине, наныем. Урманыбыз киң, иркен. Үз кочагына сине генә сыйдырыр әле. Бүгеннән үз көнеңне үзең күрә башла, балам. Хәзергә сау бул, үскәнем. Кем белә, бәлкем, урман сукмакларында очрашырга да язгандыр. Ә бүген сине шушы аланда калдырырга мәҗбүрмен», — дигәндер.

Каршына койрык болгап килеп баскан Чатанны Айгөл апасы янәдән кулына алып сөя, иркәли башлады. Тегесе дә, кыргый бүре баласы димәссең, гөнаһсыз бер сабый булып, апасының җылы кочагына сеңеп үк кереп ятты.

— Тамагы ачтыр аның, кызым. Башта ашатыгыз әле үзен, — диде әтиләре.

Шуны гына көткән Чатан алдына куйган тәлинкәдән, шупыр-шупыр китереп, токмач шулпасы чөмерә башлады.

— Әнисе дә ташлаган. Абыйлары да юк. Шушы аланда берьялгызы нишләр инде ул? Нәрсә ашар? Ачка үлмәсме? Әйдәгез, аны үзебез белән аска, безнең аланга алыйк, — дип сорый башладылар Газинурның кызлары.

— Ярамый аны моннан алырга! — дип кырт кисте әтиләре. — Бәлкем, әниләре кире уйлар. Төпчеген берьялгызы калдырып китү аңа да җиңел булмагандыр. Килер дә алыр. Бала дигәндә ана кеше күп киртәләрне җимереп уза. Ярамаганнарын да хәтта. Туйганчы ашатыгыз үзен. Калган ашын тәлинкә белән алдына куеп калдырыгыз. Уйлар-уйлар да әнисе, бәлкем, бер-ике көннән килеп алыр. Өзелеп сагыну хисе Кеше исен генә түгел, әллә нинди тирән үпкәләрне, шикләнүләрне дә оныттыра ул. Калдырыгыз үзен. Иртәгә тагын менәрсез, ашатып төшәрсез. Ул урман иясе, булачак кансыз ерткыч. Кешеләр арасында аңа барыбер урын юк...

Ашап туйгач, бер кикереп тә куйгач, Чатан йөгереп кенә аланны әйләнеп килде. Апалары белән куышлы уйнарга да исәбе бар. Күзләрендә әнисе ташлап китү кайгысы да, апалары белән күрешү шатлыгы да чагыла. Нишләргә? Чатанны кая куярга? «Кешеләр арасында аңа урын юк» дип кистереп әйтте әтиләре. Апалары Чатанны өн авызына илттеләр.

— Утыр шушында гына. Беркая да чыкма. Юкса үзеңне бүреләр тотып ашарлар, — дип кисәттеләр. «Бүре баласын бүреләр тотып ашамаслар инде» дип елмаештылар.

— Алай да, Чатан, безне тыңла. Бу аланнан беркая да читкә китмә. Юкса адашырсың, — дип бармак янап кисәттеләр. — Көт безне. Хәлеңне белергә иртәгә дә менәрбез. Тәмле аш пешереп алып менәрбез. Ярар, хәзергә сау булып тор, — дип, — кат-кат пәп итеп, үз аланнарына төшеп киттеләр.

* * *

Бал чорында умарталыкта умартачыга ял да юк, йокы да юк. Бал сезоны! Ләкин ул бик кыска. Шулай булгач, синең бөтен эш-гамәлләрең шушы сезонның бөтен мөмкинлекләреннән киң файдаланып калуга корылган булырга тиеш. Быел шалашымны урманның иң матур аланына корып куйдым, дип һаваланып йөри алмыйсың. Башта Газинурның кортлары күч аерып аптыраттылар. Кирәк нәрсә, матур күренеш. Кәек гаиләләр күч аера алмыйлар. Ләкин вакыты түгел. Күч чыгарган умарта гаиләсе кәегеп кала. Бал җыярга аның көче кими. Утыз сутый бәрәңге бакчасын бер өй бала-чагасы булган ишле гаилә тизрәк утап чыгармы, әллә ике-өч карт пенсионерлар яшәгән гаиләме? Әлбәттә, ишле гаилә! Бал кортлары да шулай. Нектарны ишләре зур, көчле булган корт гаиләсе күбрәк җыя. Бал чорында һәр корт гаиләсенең өстен ачып, көненә ике-өч тапкыр күз салып торсаң да, бер дә артык түгел. Рамнарын алыштырасың, яңаларын куясың. Яңа кәрәзләрне дә тартып кына өлгер.

Газинур кортларыннан зарланмый. Бу көннәрдә алар ару-талуны белми нектарны ташып кына торалар. Гектар ярымнар җирне биләгән ышык аланны ояларда өлгереп килә торган хуш исле бал исе басты. Бу ис борын тишекләрен кытыклый, тәмле генә итеп төчкереп җибәрәсе килә. Казыкларда утырган ояларны да урыннарыннан кузгатышлы түгел. Бал белән тулып киләләр. Елы да бик ипле килде шул. Елы килгәч, кортлар да балны нык ташыдылар. Газинур әле теге, әле бу оя янына килә дә, аларны кузгатып карап, үзенә бер татлы канәгатьләнү хисе белән: «Бар болар эчендә хәзинә, бар!» — дип, кызларына күз кыса. Шәһәргә кайтыр чаклар да җитеп килә. Ояларны җиңеләйтеп, балларын аертып кайтсаң да әйбәт булыр иде. Аларны төяп-бушатып йөрүләре бермә-бер җиңеләячәк. Ләкин биредә, урман шартларында ипсезрәк. Кортлар үзара йә талаша башлар. Алар анысын да булдыралар. Кызлары аерту ягында. Әниләре каршына яңа аерткан бал белән, тулы флягалар белән кайтасылары килә.

— Оядагы бал беркая да качмый. Шәһәргә кайткач, ипләп, ашыкмый гына аертырбыз әле, — ди әтиләре.

Корт карау мәшәкатьләре белән Газинур һәм кызларының ике-өч көн рәттән хәтта ярты сәгать кенә дә буш вакытлары булмады. Алардан өстәге аланда калган Чатансыйрак турында гел исләренә төшереп торсалар да. Күп итеп ашарына да алып, менә иртәгә менәргә торалар инде. Ачтыр, тәмам ачыккандыр, бичара балакай.

Иртән Газинур шалашларыннан торып чыксa, ни күрсен, Чатан — үзе төшкән. Койрык чәнчеп, алан буйлап чабып йөри. Әйтерсең ул биредә моңарчы да күп тапкырлар булган. «Монда керергә ярыймы?» дип, Газинурның күзенә карады да кыю рәвештә шалаш эченә дә кереп китте. Битләреннән генә пәп итеп, апаларын да уятты. Чатанның бирегә үзе белеп төшүенә алар бик шатландылар инде. Сохари да ашаттылар, сөтле чәй, кофе да эчерттеләр. Кочакларына да алдылар, чиратлашып сөйделәр, яраттылар да.

Чатанның алар янына төшүен әтиләре генә хупламады. Чатан — теп-тере бүре баласы. Әлегә күп нәрсәне аңлап бетерми. Кызлары да кочакларыннан төшермиләр. Ләкин аларның бу дуслыгы ни белән тәмамланыр? Бүре баласын алар үзләре белән шәһәргә ала алмыйлар. Ике-өч көннәрдән алар кайтып китәргә җыеналар. Аерылышыр сәгать җиткәч, Чатан монда калырмы соң? Болай тәмам күнегеп беткәч, аны аерып калдыру бик кыен булачак бит. Үзләре белән алу турында... уйлыйсы да юк!

Юкәләр күп итеп нектар биреп, чәчәк атып бетерделәр. Кортлар аларга утырмый башладылар. Әмма урман хәтле урманда кортларның күзе төшәрлек чәчәкләр адым саен. Әнә иван-чәй чәчәк атарга җыена. Кортлар аңа бик теләп куналар. Алардан аз гына астарак үзәнлектә ак клевер ап-ак булып утыра. Ак клеверның да балы гажәп хуш исле, үзенә бер татлы ароматлы. Кортлар шул тарафларга да очалар. Биредә тагын атна-ун көннәр утырырга булыр иде әле. Ләкин көтмәгәндә генә аланга Ильяс килеп чыкты.

— Безне күрше районга урып-җыю эшләрендә катнашырга җибәрәләр. Аннан ике-өч айсыз кайтып булмас. Шәһәргә кайтырга җыенсагыз, менә бүген генә буш арам бар, — диде.

— Алай да хуп, Ильяс туган! — диде Газинур. — Бу урманга, бу ышык аланга бик рәхмәтле без. Чыгуыбыз бушка булмады. Шәһәргә ояларыбыз тулы бал белән кайтабыз. Рәхмәт ара табып килеп чыгуыңа. Кайтабыз, кайтабыз. Җыена да башлыйбыз.

Ильяс абыйлары булган җирдә нигә тотынсаң, шул эш гөрләп тора. Һәр оя әбиләр сандыгыдай авыр булсалар да, аларны төяү дә озакка бармады. Тик менә һаман аяк астында чуалган Чатанны гына нишләтергә? Апалары аны, ашатыпэчертеп, хәтта битләрен юдыртып, һәр кичне үз аланына менгерәләр. Иртәнгә ул янә төшеп җитә. Кулга килә. Апалары белән уйный. Кая куярга хәзер бу бүре малаен? Әнисе килеп алмый калмас дип көткәние Газинур. Тәки килмәде бит.

— Шыңшымагыз да, тәмам нервамны да бозмагыз! — дип бармак янады Газинур кызларына. Үзе исә Чатанны култык астына кыстырды да янә өскә, бүре аланына менеп китте. Кесәсендә кыска гына шнур кисәге бар иде. Шул шнурдан муенчак ясап, аны Чатанга кидертте. Бер очын имән ботагына бәйләде. Өн авызына ике-өч көн ашарга җитәрлек итеп ипи, ит, сыр-колбаса кисәкләре салды. Су куйды.

— Алдыңа салган ризыкларыңны ашап бетереп ачыга башласаң, юеш борын, шнурны чәйнә дә өз. Менә бит ул нечкә генә. Чәйнәп өзәрлек булсын дип махсус сайладым, — диде, Чатанны башыннан сыпырды. — Сине монда калдыру минем үземә дә җиңел түгел. Әмма безгә рәнҗеп кала күрмә берүк. Шуны аңла, дускай, син бүре баласы, сиңа шәһәрдә урын юк. Анда климат синеке түгел. Ә урман сине ят итмәс. Башың, акылың бар. Тиз арада үз көнеңне үзең күрергә өйрәнеп китәрсең. Ярар, хәзергә сау бул!

Газинур аска, кортлары төялгән машинага ашыкты. Чатан калырга теләмәде. Үзен имән ботагына бәйләгән шнурны өзәргә теләп, ярсып-ярсып чәң-чәң килгәне бөтен урманга ишетелеп торды бугай. Төшсә, кызлары лычык-лычык килеп елап утыралар. Әтиләре аларны:

— Китегезче, матурларым! Тапкансыз еларлык кайгы. Тормыш эчендә мондый гына аерылышуларны күп кичерергә туры килер әле. Юктан-бардан гына сугылып төшүчеләр булып үсмәгез. Үзегездә ныкихтыяр көче тәрбияләгез, — дип юатмак булды.

— Юктан да, бардан буласы, имеш. Әле имчәктән дә аерылып бетмәгән көчекне берьялгызы урманда калдырабыз. Шуннан соң үзебез кемнәр булабыз соң инде без? Миһербансызлар! Шәфкатьсезләр! — дип, Айгөл елавын белде.

Әтиләре дә нишләсен соң? Бүре баласы аның үзенә дә жәл. Бик кызганыч. Жәл, кызганыч дип, аны шәһәргә дә алып кайтып булмый лабаса. Товары андыйлардан түгел. Әлегә ул песи баласыдай юаш, ягымлы. Әмма үсә төшкән саен аңарда бүреләргә генә хас инстинктлар туа барачак. Шәһәргә кайту белән аңа битлек тә кидертә, яңа күлмәк тә тегеп бирә алмыйсың.

Ильяс абыйлары телгә бик шаян егет. Ул еш кына:

— Кызкайлар, доллар ул Африкада да доллар! — диярга ярата.

Шуның төсле, урманда туган бүре баласы шәһәргә кайткач та бүре баласы инде. Битлек тә киемәс, холкын да үзгәртмәс.

Газинур көтмәгәндә генә килеп туган бу җитди проблеманың теге ягын да, бу ягын да кат-кат уйлап карады. Иң яхшысы Чатанны урманда калдыру дип хәл итте. Үз көнен үзе күрсен, балакай...

Аланнан кузгалуны тиз тоттылар. Газинурлар урманга егерме биш баш умарта белән чыкканнарые. Машинага утыз ике баш оя төяделәр. Кызларына рәхмәт инде. Алар бик булганнар. Оядан чыгарга җыенган бер күчне дә читкә җибәрмәделәр. Чыккан берсен тубалларга җыя бардылар. Һәр яңа күч үзе бер байлык! Вакытында ояга гына утырт. Көзгә чаклы алар көчле умарта гаиләсе булып өлгерәләр. Әйе, мондый уңган кызларың булганда, ата башына да байлык ишелеп кенә тора. Менә хәзер генә һаман да лычык-лычык киләләр.

Газинур, үзен дә, кызларын да тынычландыру өчен:

— Арабыз әллә ни ерак түгел бит. Бу алан белән дә мәңгегә хушлашмыйбыз. Ике-өч көннәрдән килербез дә хәлен белеп китәрбез. Ул арада гына, Чатанығызны әйтәм, боз түгел, эремәс, — дигән булды.

* * *

СССР Министрлар Советының кайчандыр, һәрхәлдә, моннан күп еллар элек, «Умартачылык белән шөгыльләнүче һәвәскәрләргә кайларда, нинди генә жаваплы урыннарда эшләсәләр дә, чираттагы ялларын, кайчан сорасалар, шул чакта, әмма унбиш көнгә озынайтып бирергә» дигән Указы нәкъ менә Газинур кебек һәвәскәрләр өчен чыгарылган. Ул да елның елында чираттагы ялын чәчәкләргә ишелеп бал төшәр алдыннан, урман яланына, карабодай басуына, эспарцет, чебен үләне чәчелгән болыннар уртасына кортлары белән чыгып утырыр көннәр җиткәч ала. Чыгып утыру белән генә түгел бит. Басуга чыгарып утырткач, кортларына күз-колак булып, аларны саклыйсы да бар. Кыюлык хисе җитмәүдән зарланучылар бик аз алар хәзер. Корал тотып сакламасаң, төнлә килеп умарталарыңны машинага төяп алып китәргә дә күп сорамаслар.

Урманнан кайткач, ике-өч көннәр ял да итеп, Газинур эшенә үткән атнаны гына чыкты. Карабаш поселогы янындагы нефть промыселында диспетчер булып эшли ул. Өлкән инженер-технолог иде. Кортларны кararга буш вакыт кирәк булганлыктан, үзе сорап, гариза язып, диспетчер булып күчте.

Диспетчерлар бер тәүлек эштә, ике тәүлек өйдә. Буш вакыт күп. Кадерен бел, рәхәтлән. Иркенләп кортларыңны кара.

Беренче көнне, бер кәнди сыек бал күтәреп барып, эштәге иптәшләрен сыйлады. Промыселга, елдагыча, җәйге каникуллар чорында практикага Мәскәү нефть институтыннан бер төркем студентлар килгәннәр. Аларның диспетчерлык пунктына икесе дә сап-сары чәчле, бик чибәр ике украин кызын һәм антрацит күмер төсле дөм кара негр егетен билгеләгәннәр. Битенә корым яккан төсле чем-кара булса да, негр егете бик ачык, шырык авызлы, шаян егет. Океан артындагы ерак Кубадан ук килгәнме? Ике сүзенең берендә, күкрәк сугып, юлбашчылары Фидель Кастроны мактый. Студентлардан да хәйләкәррәк затлар бармы икән ул ошбу җиһанда? Газинурның әле утырырга өлгермәгән хуш исле сыек балын, татарча да, русча да, украинча да, хәтта кубача да мактый-мактый, бер утыруда бер кәнди балны ялап та куйдылар.

Газинур үзе дә, мәктәпкә хәзерләнә башлаган кызлары да урман яланында калдырып кайткан бүре малае турында онытып та киләләр иде бугай. Беркөн иртән шулай, төнгелеккә ишегалдында гына калдырган бер оя казларның, ишегалдында үзен аеруча дәрәҗәле, һавалы тотарга яраткан ата казның дөнья ярып каңгылдавына, чү, нәрсә булган, әллә безнең ишегалдына чит планетадан килүчеләрнең корабы төшкәнме дип чыкса, Газинур ни күрсен! Койрыгын сыртына салып, ишегалдын аркылыга-буйга Чатансыйрак айкый. Ата казның разбуй салуы бик аңлашыла. Ишегалды буйлап бүре баласының чатыр чабуы булган, ишетелгән хәлме?

Карт ата казның:

— Бүре бит бу! Җәмәгать, бу хәлгә ничек түзеп торасыз? Ишегалдыбыз буйлап бүре чабып йөри, ә сезнең исегездә дә юк! — дип гауга куптаруы, каравыл кычкыруы бик урынлы. Бу куркыныч хәл турында хуҗага беренче булып ул хәбәр салмаса, тагын кем салыр?

Кош-корт, җәнлекләр арасында бер-берләре белән аралашу өчен алар арасында күп тапкырлар сыналган Морзе аппараты булса кирәк. Беренче булып ата каз салган разбуйдан Газинур хуҗалыгында булган барча кош-корт, тере җаннар шиккә төшеп, сагаеп калганнар. Песиләре, быел миңа бәбәйләү өчен шушыннан да ипле, җылы урын юк дипме, мунча кыегына менеп бәбәйләгән иде. Күзләре ачылгач, шуннан бик матур дүрт песи баласы чыгып йөри башладылар. Аларның да тыны да юк. Чатанны күрү белән мунча кыегы астына кереп посканнар. Гамьсезнең гамьсезе, ваемсызның ваемсызы, иркәнең иркәсе, хуҗабикәнең иң кадерлесе өч айлык тана бозау Шәмсеруй да, ишегалдын айкаган бүре малаен күреп, әчтерхан чикләвегедәй зур күзләрен тагын да шарландырган. Телсез калган.

Чатан гына бернигә карамый ишегалдын айкавын белә. Газинурны күреп алуга, аның каршына килеп басты. Азау тешләре чыгып килгән авызын ерган. Сорау юк, ни юк, аны кул аркасыннан үбеп тә алды. Сагынган, янәсе. Үрелеп, муеныннан кочып алмак әле.

— Ах, шайтан син, Чатансыйрак! Ни дип кайттың? — булды аның беренче сүзе. — Ни дип кайттың? Кем сине чакырды? Кем көтә? Бездәге климат сиңа ярамый бит, дивана баш!

— И Газинур абыем! Шулхәтле каты бәрелмә әле, зинһар. Ни дип кайттың, имеш. Олылар сүземе шушы, валлаһи! — диде дә, янәдән сикереп, Чатан аны битеннән пәп итеп алды.

— Кит, шайтан! — дип, Газинур кул аркасы белән битен сөртте.

— Ничек инде кайтмыйм ди! Шул урман яланында берьялгызым ятыймммы? Гөлшат, Айгөл апаларымны, менә сине бик сагындым. Яттым-яттым да, булмаса, үзләрен бер күреп кайтыйм дидем.

— Кайткансың да бит... Ләкин син бездә «персона нон грата». Беләсеңме соң бу сүзләрнең мәгънәсен? Безнеңчә, кирәкмәс, артык җан дигән сүз була ул. Безнең тарафлар өчен син артык, кирәкмәс җан.

— Ник кайттың да, ник кайттың, дисең. Ә мин урманда берәрсенә хажәтме? Әнием: «Синнән Кеше исе килә!» — дип ташлап китте. Сез дә ташладыгыз. Теге чакта сез муенга бәйләп калдырган шнур кисәген сезнең арттан ук чәйнәп өздем. Сезне шулхәтле өзелеп, эчкерсез яратып та, хыянәт итүегезгә үпкәләп, яныгызга юри төшмәдем. Үземчә яшәп китмәк булдым. Тегендә чаптым, монда йөгердем. Бернинди тормыш тәҗрибәң булмаган башың белән берьялгызың урман аланында калып кара әле. Син нишләриең, Газинур агам? Ачыга башладым. Аланда аунап яткан сөякләрне тагын бер кат кимереп чыктым. Аларны кимереп кенә тамак тую түгел, өзелеп ашыйсы килү бераз басылса икән. Үләнарасында кыштыр-кыштыр килгән бер түмгәкне күреп, әһә, таптым ашарга дип, аның өстенә сикергәнием, очлы энәләрен як-якка тырпайткан керпе булып чыкты ул. Аның ите бик тәмле. Әниебезнең алып кайтканы бар иде. Ләкин аны тотып ашау өчен, башта су буена тәгәрәтергә кирәк. Керпе йөзен суга тәгәрәтеп керткәч кенә ача. Ә безнең аланда керпене кертеп батырырлык су кайда анда? Бик сусаган чакта үзеңә шупырдатырга да юк әле.

Шулай бик ачыгып, ашарыма берәр нәрсә тапмаммы дип әрле-бирле чапкан чагында юл кырыенда утырып торган куяннар төркеменә юлыктым. Берәр кош кунганнан, кинәттән тирбәнеп, сыгылып киткән агач ботагыннан да шыр җибәрүчеләр бит инде. Ә мине санга да сукмыйлар. Кыланышларын күрсәң икән.

— Кара-кара, бу бүре малае әллә тилергәнме? Әллә эче бушаганмы, әллә тәрәтен тота алмыймы? Ни дип чабып йөри ул биредә? — дип, эчләрен тотып, чырык-чырык көлделәр әле миннән.

Дөньяның ачы конфетларын, Газинур агам, мин күп татырга өлгердем инде. Берсендә, менә-менә ачка үләм дигәндә, яфрак астыннан ике кыр тычканы тотып хәл алдым. Чак үлми калдым...

Чатан Газинур агасы алдында ипләп кенә утырган хәлдә сүзен дәвам итте:

— Бер күзеңне бераз кыса төшеп каравыңнан сизәм, агам. Бу бәхетсез бүре малае, бичаракай, тәмам ачка интегүдән, бүре булып ачыгудан минем ишегалдыма аяк баскандыр, дип уйлый күрмә тагын. Ул чорны мин күптән кичердем, ул чор минем өчен артта калды. Урман зур, һәм ул минеке! Бер тамагымны гына тук тотарлык ризыкны мин аннан күпме кирәк табам. Ул чакта ни пычагыма дип килеп чыктың, диярсең инде син. Мәсьәлә биредә бөтенләй башкада, Газинур агам. Бәлкем, син ышанмассың да. Хәер, анысы синең эш. Иң башта үзеңне, берсеннән-берсе чибәр, ягымлы кызларың Гөлшат апа белән Айгөл апаларны өзелеп сагындым. Сез белмисез дә, аңламыйсыз да. Бүреләр кемне дә булса сагынсалар, үзенә бер көч-сыкрау белән сагыналар. Чөнки сездә, ягъни кешеләрдә, мондый сыкрау хисе юк. Ул яктан бәхетсезләр сез. Чөнки атлаган саен аерылышып, бер-берегезне ташлап, онытып яшисез. Сыгылып төшеп сыкрап сагына да белмисез. Яшисез инде шунда... Шулай түгел, диген Газинур агам? Айгөл апамның мине җирдән күтәреп алып, кочагында кочып, борын очымнан гына пәп итеп алуларын онытырга мөмкинме соң? Минем бит үз әнием дә мине алай иркәләмәде. Абыйларым, шаярабыз гына дигән булып, гел кыерсыттылар. «Замана көчленеке!» дигән кыргый принципны дөньяга беренчеләрдән булып безнең бүре пиратлары тараткандыр. Әниемнең сөтле имчәген беренче булып алар эләктерәләр. Миңа имчәк алар суырып туйгач, сөте тәмам беткәч кенә эләгә иде. Сөтсез имчәген каезлаганны әниебез дә яратмый. Түзеп ята-ята да калын табаны белән пәч берне минем башка кундыра. Ул ач күзләрне имчәк сөте белән генә туйдырырсың, бар. Бераз үсә төшкәч, әниебез аланга йә көртлек, йә куян түшкәсе күтәреп кайта. Абыйларым аны шунда ук ботарлап ташлыйлар. Шунда ук янәдән ашарга таптыра башлыйлар. Биреп куйганнары бармы диярсең. Әниебезгә рәхмәт, ул безне ач итмәскә тырышты. Кайчакларны үләксә базыннан йә дуңгыз түшкәсе, ат-сыер боты күтәреп кайта. Ул чакта безнең аланда бәйрәм. Берәр калҗа кисәге миңа да эләгә. Ю-ук, боларны зарланып түгел, ә шул чакларны сагынып сөйләвем. Әниебез бер дә юктан гына әйтмәгәндер. Аның бу сүзләрендә чын хакыйкать ятадыр. «Балакайларым, без бүреләрнең иң бәхетле чагы тамаклары ач булган минутларда» дияргә ярата иде ул. Су уйсу җиргә җыела, ә тере җан җылылык күргән җиргә тартыла.

— Күпме генә арада син танымаслык булып үскәнсең, — диде Газинур. — Үсә төшкәнсең. Сүзләрнең дә, нәкъ мулла абзый кебек, акыллыларын гына сөйлисең. Гаҗәпләнеп тыңлап торам үзеңне. Чын егет булып киләсең син. Ләкин... Белмим... Айсбергларның да язмышын берүзең хәл итешле түгел. Ә син, Чатан, минем алга айсбергка тиң мәсьәлә куйдың бит. Теләсәң ничек хәл ит, имеш. Белмим...

— Тормыш йөге, Газинур абый, чиксез авыр йөк икән ул. Аны берьялгызың гына өстери башласаң, үсмәс җиреңнән бик тиз үсәсең икән, — диде Чатан, бер күзен кысып, колагын уйнатып куйды.

— Алай дисе-е-ең, — дип сузды Газинур. Аның башында үз исәп-хисаплары. — Бер яктан, безгә килеп син дөрес иткәнсең. Сине еш кына үзебез дә искә төшерәбез. Ул бүре малае нинди ачы язмышларга дучар булды икән, дип борчылган чаклар да күп. Без үзебез дә сине яратырга өлгергән идек. Син инде бездән... кусак та китмәссең.

— Нигә? Калдырсагыз?.. Калмаска! Бик теләп! Әнә мал-туарың да ишле генә күренә. Ишегалдына бер ышанычлы сакчы кирәк синең. Калдырсагыз, барсына күз-колак булып торырмын.

— Син булдырырсы-ы-ың! Сиңа ышанса-а-аң! Кәҗәне кәбестә бакчасына кертсәң, урып чыгасын көт тә тор, — дип елмаеп бармак янады аңа Газинур.

— Китче инде, Газинур абый! Ул хәтле син мине кемгә саныйсың?

— Анда, гараж ышыгында, бер буш оя бар. Калдырган тәкъдирдә, сине урамда кундырып булмый бит инде. Хәзергә шул ояда яшәп торырсың. Актырнак оясы иде ул. Бик игелекле маэмаебыз бар иде. Ишегалдыбызга чит тавыкларны да кертмәде.

— Кайда соң әле үзе? Ник күренми? Танышыйк булмаса.

— Кайнар мәхәббәт колы булды, ахры. Бик сорагач, этләр туена җибәргән идем үзен. Менә шуннан инде ике-өч атналар кайтканы юк. Без ир-ат затын, харап итсә, шул кайнар мәхәббәт харап итә инде. Бу өлкәдә сиңа да сак булырга туры килер.

— Бәлкем, кайтып та килер әле. Бер казанга ике кәҗә башы сыймый, диләр бездә. Без бит кәҗәләр түгел. Сыярбыз. Чынлыкта исә этләр-маэмайлар, сез кешеләрдән кала, иң сөймәгән дошманнарыбыз безнең.

— Нилектән ул кадәр? — диде Газинур.

— Кышкы үтә салкыннарда, ачлыктан тәмам интеккән чакларда, булмаса, берәр сарык эләктерик дип, авылга бүреләр төшкәндә, беренче булып шау-шуны кемнәр куптара? Алар бит сезнең маэмайларыгыз. Алар артыннан сәнәкләр, чукмарлар тотып хуҗалары чыгып җитә. Авылга ничек ач

төшсәң, урманыңа да шулай кайтып китәсең. Минем үзем әлегә андый хәлләргә калганым юк. Мондый гыйбрәтләрне безгә һәр кичне әниебез сөйли иде.

— Ә без, эт буранда котыра, дип сөйләргә яратабыз. Март башларындамы, апрель ахырындамы, бик буранлы ямьсез бер көндә безнең курмышта булды ул эт туе. Актырнакны әнә шул туйга җибәргәнием. Гел чылбырда утыру аңа да кызык түгел бит. Ял итеп, гүләйт итеп кайтсын дигәнием. Шул китүдән кайтмады ул. Этләр туенда катнашучыларны шәһәрне төзекләндерү, яшелләндерү конторасы егетләре барысын берьюлы мушкага алганнар икән, дип сөйләделәр. Югыйсә бик акыллы маэмаебыз иде.

— Бик шәп булган! — диде Чатан.

— Ни дип шулай кансыз син?!

— Ә бүреләрнең кайчан канлы, миһербанлы булганын күргәнең бар, агаем?

— Алайсамы-ы-ы? — дип уйланып торды бераз Газинур. — Калырга булсаң, менә шул ояга япсам инде сине. Ишегалды буйлап, бар мал-туарның котын алып, шалтай-балтай йөрүләрне өмет итмә. Муеныңда муенчак, бер очын казыкка каккан тимер чылбыр. Не согласен, иди урман гуляй, егетем.

— Мондый перспектива әллә ни шатландырмаса да, котны алып куркытмый да, дөресен генә әйткәндә. Әнием безгә «балакайларым, язмыштан узмыш юк» дия торганые. Нәкъ менә шушы очракны күздә тотып әйтә булгандыр. Бик акыллы җан иясе иде бит ул.

— Алай да, Чатан, бер авыз гына булса да мактау сүзләре дә әйтим әле үзеңә, — дип елмайды Газинур. — Үзең дә булган егет бит. Безнең урманнан кайтканга инде айдан артык. Ара да ерак. Коногоровка урманы безгә егерме-утыз чакрымнар гына бар да бар. Шултикле арадан безне ничек таптың, шайтан?

— Сезне табу миңа абсолютно проблема булмады. Менә мин шуңа аптырыйм: бу лычык та лычык борыннарыгыз безгә ниемә генә хаҗәт? Бер ис сизмисез бит сез. Урманда сез калдырып киткән, минем өчен бик кадерле исне мин менә хәзер дә сизәм. Башка мең төрле исләр арасыннан. Менә шул ис эзеннән тоттым да килдем. Пойдетмы?

— Пойдет! — дип елмайды Газинур. — Кил, хет башыңнан сыйпыйм бер. Тукта, урманнан килгән шәпкә син бераз тамак ялгап ал әле. Өйгә кереп токмач ашы алып чыгыйм әле.

— Менә монысы чын егетләрчә! — дип тыпырдап алды Чатан. — Токмач ашымы?! Газинур абый, теге чакта сез миңа урманда ашаткан токмач шулпасының тәме бүген дә авызымда.

Газинур бер зур кәнди белән аш алып чыкты. Аны бүре малае алдына куйды.

— Аша! Ялап куй!

— Есть! Ашарга! Нәкъ сез дигәнчә булыр. — Чатан күз кысып алды.

Аннары, гаражга төшеп, Газинур муенчак, чылбыр алып менде. Бүре малаен бәйгә утыртты. Туйганчы бер ашап алгач, тегесе карышып тормады.

— Калдыруын сине өйдә калдырам инде, — дип бармак янады булачак хуҗасы. — Соңрак син миңа һич көтелмәгән кордебалетлар күрсәтмәссең микән? Карап торам, күзеңдә мыскал да миһербан әсәре юк бит син шайтанның...

— Миһербан дигән нәрсә минем күзгә каян килсен инде ул? Бер тора торгач үзең дә сөйләп куясың инде, Газинур абый. Укымаган-нитмәгән, бер хәреф танымаган, наданның наданы, кыргыйның кыргые бүре баласына андый югары хисләр каян иңсен? — Чатан сул күзен янәдән хәйләкәрләрчә кысып-кысып алды.

— Телгә ай-һай оста күренәсең, матри у меня! Менә бу йодрыкны күрдеңме? Кордебалетлар-мазар чыгара калсаң, үпкәләштән түгел, ике каш араңа берне генә бирермен. Күзеңнән утлар чәчрәр. Матри у меня! — дип, Чатанның борын төбендә янә бармак янады. — Бүгеннән мин синең хуҗаң. Аңлыйсыңмы? Монысын аеруча нык белеп тор! Тамагың тук булыр. Үз куышым бар дип сөенергә ояң. Тугры хезмәт ит. Итмәсәң, ике каш араңа менә шушы йодрык. Матри, егет! Эт котырса, хуҗасына ябыша, диләр. Синнән дә әллә ни игелекләр көтмим. Котырсаң... Матри у меня!

Чатанның аларны эзләп табуына, аларда калуына Газинурның кызлары — Гөлшат белән Айгөл бик сөенделәр. Үзләре ни ашасалар, бүре малаен да шуның белән сыйладылар. Чатанның сые ит тә сөяк.

Алар яшәгән урамның теге башында гына әрмәннәр ресторан ачтылар. Кызлар Чатанга шуннан тавык тәпиләре яздырып ташый башладылар. Бер пакет тутырып алып кайталар да Чатанның аларны ничек шатыр-шотыр китереп ашаганын карап торалар. Әтиләренә чиратлашып урман егетен мактарга керешәләр: «Чатан матур, Чатан акыллы. Аның күз карашлары да нинди сөйкемле».

Мондый хасият, мондый тәрбия булгач, Чатансыйрак, ай үсәсен көн үсеп, көзгә Себер овчаркасы хәтле булып җитеште. Матурлыкка да матур. Муен өлешләре кара йон. Шул кара тасма сырты буйлап койрык очына кадәр сузыла. Колаклары постта торган солдатныкы кебек. Черт иткән тавышны да ишетеп, анализлап, эшкәртеп торалар. Хуҗасы Газинур гына кайчакларны, аның оясы алдына килеп, башыннан кырыс кына сыйпаган чакта: «Күзеңдә миһербан әсәре юк. Абау, абау! Ничек шулай салкын, йөрәкләрне өшетерлек итеп карый беләсең? Матри у меня!» — дип бармак та яный торды.

Чатан аңа һаман да шул бер җавабын бирә килде. Ә чынлыкта ул үзенең бик сизгер бүре акылы белән, бүре йөрәге белән (ә чын ярату хисе, саф мәхәббәт тик йөрәктә генә туа) бу дөньяда Гөлшат

апасы белән Айгөл апаларын гына ярата иде бугай. Нинди хис бу, нинди ярату? Чатан аны аңлап та бетерми. Өшән-бүшән үсмәсен, буыннары да нык булсын дип, хуҗасы аны кай кичләрне бәйдән ычкындыра. Андый чакта Чатан кая басканын белми. Ишегалдын ду китерә. Шулай чабып уйнап, буыннарын язгач, апалары аяк астына килеп ята. Айгөл апасы аны нишләтеп кенә бетерми. Су белән битен юа, күзләрен сөртә. Муенына кара бантик тагып, башына бейсбол кепкалары киертә.

— Кая бу локаторларың тагын да яхшы ишетсеннәр, бераз чистартыйм, — дип, нечкә бармаклары белән аның колагы эченә керә.

Кытыгы килгәнгә Чатанның түзәр хәле калмый. Алай да түзә.

Чатанның тәмам үсеп, өлгереп җиткәнлеген раслый торган азау тешләре дә чыкты. Ике якка икәү. Корбанына, дошманына һөҗүм иткәндә бу тешләре аның төп, ышанычлы коралы. Керпенең — энәләре, сыерның — мөгезләре, ат-бахбайларның — арткы аяклары. Ә бүреләрнең — азау тешләре.

— Бу тешләрең синең, Чатан, ай-яй нык күренәләр. Ләкин син аларны көн саен чистартып торырга онытма. Мин сиңа паста һәм теш чистарта торган щетка чыгарып куярмын, — дип, Айгөл апасы аның азау тешләрен дә капшый, сыпыра.

— Кызым, саграк бул әле. Алдыңда кыш чыккан бозау хәтле бүре, безнең якларның иң кансыз ерткычы ята, — дип куя кайчак Газинур. — Тешләп алмасын үзеңне. Бу шайтанның күзендә мыскал миһербан әсәре юк. Карашында котып салкыны. Кыяфәте — яуга җыенган юлбасарныкы.

— Ничек тешләсен инде ул мине? Ул бит мине ярата. Шулай бит, Чатан?! Яраткан кешеңә ничек инде усаллык эшләп булсын? — Айгөл апасы аны муеныннан алып коча, иркәләп башыннан сыйпый. Апасының сүзен раслап, Чатан үзе дә алгы тәпиләре белән топ-топ килеп ала, койрыгын болгый. Ә күзләрендә чыннан да галәм түрләрендәге иң ерак планеталардан килгән яктылык төсле җан өшеткеч нур. Нишләсен соң? Ул бит бүре! Ялгыш кына тешләп алса да, ни әйтерсең? Ләкин ул моны гомердә эшләмәс. Ниндидер көч аны тыеп, кисәтеп тора. Айгөл апасын бүреләрчә тугрылык, бирелгәнлек белән ярату, сөю хисе тыеп торадыр аны төрле усаллыклар кылудан. Ләкин бүре бит ул! Чып-чын, теп-тере бүре! Тәңре аңа бөтенләй башка вазифалар йөкләгән...

* * *

Җиргә ашыкмыйча гына, тирбәлә-тирбәлә ап-ак карлар төшкән чаклар. Җиләнен бөркәнеп, итәк чабуларын җыеп, көз китеп барды. Үрәчәле чанасына кырын ятып, безнең якларга кыш килергә җыена. Чатанны хәзер танырлык түгел. Ай үсәсен көн үсеп, тагын да зурайды, матурайды. Оясы түбәсенә менә дә кочакка сыймаслык түшкә булып ята. Бераз холкын, кайсы ырудан булуын күрсәтеп алырга да исәбе юк түгел. Кайчак үҗәтләнә, карыша. Сез мине, юаш, күндәм дигәч тә, диваныгызда гына йоклаткан песи баласына тиңли күрмәгез, диюеме? Бу дивана баш, бүре малае, гел чылбырда утырып, чеп-чи томана, бөтенләй надан кала күрмәсен тагын дип, Газинур аңа аз-маз гына булса да төрле командаларны аңларга, шуларны үтәргә өйрәтмәк була. Өрә белми. Берни булса, улый гына. Сирена урынына улап куя. Улама, аңгыра баш, калын тамак белән ваклап-ваклап кына өр. Оясы алдына басып, хуҗасы аңа hау! hау! дип өреп-өреп тә күрсәтте инде. Үз өйләре, каралты-куралары белән яшәгән шәхси секторда эт-маэмай заты һәр йортта. Уң күршеләре Бакировларда колакчынлы бүрек хәтле генә әнкә эт. Өч ай дигәндә бәбәйли дә тора. Күрше-тирә малайлары рәхәтләнәләр. Көчекләренең күзләре ачылганчы ук ташып та бетерәләр. Тухтаман атлы чуаш агае арык гәүдәле, озын сыйраклы ау эте тота. Каршыдагы бер генә подъездлы биш катлы йортка каяндыр читтән отставкага чыккан бер хәрби кайтып урнашты. Ул хәрби агай кичләрен прогулкага бик гайрәтле килеш-килбәтле Кавказ овчаркасы алып чыга. Ул овчарка кешеләргә өстерү, талату өчен махсус өйрәтелгән маэмай, ахры. Ят кеше күрү белән ямьсез ырылдый башлый, тешләмәк-таламак булып аның өстенә ыргыла.

Бу кешенең бирегә килеп урнашуына биш-алты айлар да юктыр әле. Әмма барча күрше-күләннәре белән сүзгә килеп, кычкырышып-талашып бетте бугай инде. Урамга чыгу белән, тискәре, киребеткән җан түгел диген син аны, этен бәйдән ычкындыра. Ул тыкрыкта бала-чага уйный, балалар мәйданчыгы бар. Карт-корылар чишмә суына йөриләр. Тана хәтле овчарка көтмәгәндә генә каршыңа килеп басса, кайсы бала чыр кычкырмас та, кайсы тәһарәтле әби тәһарәтен бозмас? Этеңне кулыңнан җибәрмә, дип әйтеп карыйлар аңа.

Әмма әлеге үҗәт хәрби беркемнең сүзенә колак салмый. Берни булса:

— Я этого заслужил! Понимаете, заслужил! — дип күкрәк суга.

«Я этого заслужил»ы белән тәмам аптыратты инде ул барча күрше-тирәне. «Күрше-коланың белән тату тор, дус яшә!» — мөселман әхлакларының иң төп таләпләренең берсе бит. Ләкин ул бу турыда гомерендә бер ишеткән кеше түгел, ахры. «Заслужил» дип ни пычагым коргандыр, кемнәрне кыйнап, җәберләп, атып йөргәндер? Анысы безгә караңгы. Анысын белгән дә, белергә теләүче дә юк. Овчаркасына да тапкан бит исем. Аңа «Черчилль» дип дәшә. Черчилльнең кем икәнен белә микән соң? Ул бит Англиянең элекке премьер-министры, заманында зур дан, шөһрәт казанган кеше. Әле дә ярый үзе исән түгел. Мәгәр исән булса, шулай күрәләтеп мыскыллаганы, эткә тиңләгәне өчен шартлатып Гаага Халыкара судына биреп, бу сәер майорны төрмәгә утыртып куяр иде. Эткә, овчаркага кушарга

матуррак исем беткәнме? Бертуктамый «Я этого заслужил!» дип күкрәгенә суккач, белгән-күргәннәр аның турында «бу бичараның әллә мие бераз сыекланды микән?» дип уйлыйлар.

* * *

Кәҗәнең маллыгы, бажаның туганлыгы, имеш. Бер тора торгач, югыйсә үзен бик зирәк акыллыга санарга яраткан безнең халык та әллә нинди мәгънәсез мәкальләр чыгарып куя. Чөнки чынбарлыкка мыскал да туры килми бу мәкаль. Аның никадәр ялгыш булуын Газинурның күп тапкырлар сынаганы булды. Мәкаль чыгарырга оста тел бистәләре моның белән генә дә калмаганнар. Имеш, «Москвич» — машина, кәҗә — мал, маргарин — май, тавык — кош, бажа туган түгел. «Москвич» ничек инде машина булмасын? Иң арзан чагында да аның бәясе биш мең тәңкә торды. Бажа да шулай. Газинурның терекөмеш кебек тере бажасы аңа ничек туган булмасын? Беренчедән, аларның апалы-сеңелле хатыннары бер карында яралган җаннар. Икенчедән, алар менә ничә еллардан бирле дөнья йөген бергәләп тарталар. Андый уңган егетләрне табарга кирәк әле. Тапсаң, кадерен бел. Газинурның аннан дүрт-биш яшькә генә кечерәк бажасы Әбелнәгыйм ишле бала-чагасы белән Карабашта яши. Аны анда белмәгән кеше юктыр. Чөнки ян-тирә күршеләр дә, әйләнә-тирәдәге белгән-күргәннәр дә, берәр якын бәйрәм-мазар якынлашса, мае тамып торган симез каз түшкәләрен аларга килеп алалар.

Әбелнәгыймнең хатыны да, ягъни Газинурның балдызы Нажия дә, иренә тиң уңганнарның, булганнарның берсе. Аларның өй артларында гына киң болынлык. Ә кырык-илле адымнар гына эчтәрәк Карабаш «диңгезе» чайкала. Диңгез дигәч, диңгез үк түгел ул. Буа гына. Әмма иң киң җирләрендә бер ярыннан икенчесе күренми. Бажаларының башка мал-туарлары да җитәрлек. Әмма алар күп итеп Голландиядән кайтарткан нәселле казлар асрыйлар. Асрыйм дигән кешегә казлар бик игелекле маллар бит алар. Көтүгә куып торасы юк. Артта гына Карабаш чайкала. Каз бәбкәләренә беренче чорларда пи-пи килеп йолкырга яшел чирәм булсын аларга. Өй артларындагы болынлык ямьяшел чирәм. Ә хуҗабикәләре ишегалдына җәйгелеккә көйләгән тимер мичтә пешергән кукурузны, бодай-солыны, көзләргә кергәч, казлар көтүләре белән су буеннан кайткач, аларны симертә башлагач кына алларыннан өзми.

Менә шушы бажасы, көзлеккә кергәч, беренче кар күренгәч, Газинурны бөтен гаиләсе белән каз өмәсенә чакыра. Кунакка! Андый-мондый, көтмәгәндә генә килеп чыккан сылтауларны табып, бармый кала торган бәйрәм түгел бу. Бавырын-бөерен, башларын-тәпиләрен салып кайнар мичкә тыккан өмә бәлешенә тиң тәмле, хуш исле ризыкны син Париж ресторанларына барып та таба алмыйсың. Юк ул бу дөньяда тәме, хуш исе белән аңа тиң мәҗлес сые! Өмәгә дәшкән күрше кызлары-киленнәре, көянтәләренең һәр очына дүртәр түшкә асып, аларны аргы очтагы чишмәдә тагын бер кат юып кайтканчы, бажасының чуеныңны эретерлек итеп яккан мунчасы өлгерә. Башыңа бүрек, кулларыңа солдат шинеле итәгеннән кисеп теккән киез бияләйләрне киеп чабынып чыгышыңа өстәлдә өмә бәлеше! «Дөнья матур, дөнья киң» дигән җырны киерелеп торып бер җырлап җибәрәсе килү теләгә күңелдә нәкъ менә шушы минутларда туа торгандыр инде ул.

Менә быел да, кечерәк кенә бер тәпән бал да алып, Газинурлар шушы бажаларына каз өмәсенә барганнарые. Тамак кибүне салкын әйрән белән баса-баса мунча да керделәр. Өмә бәлешен котлап, «Дөнья матур, дөнья киң»не дә җырладылар.

Икенче көнне күтәренке күңел белән капка төпләренә кайтып туктасалармы?! Аларның өй тирәсен күршеләре, үткән-барган халык сарган. Кулларына сәнәк-тырма, күсәк тотканнары да бар. Машинадан чыгу белән очраган беренче күршесеннән:

— Мөгамбәр, нәрсә булды? Карак-угры без югында өебезне басып чыкмагандыр бит? Алай-болай ут-күз дә чыкмагандыр, шәт? — дип сорады.

— Эш монда ут-күз чыкканнан да хәтәррәк, — диде күршесе.

— Алай да, нәрсә булды соң?

— Нәрсә булсын?! Бер сүз белән генә...

Ул арада авызын колак төбенә хәтле ерган Чатан йөгереп килеп утырды аның каршына.

Исән-сау гына кайттыгызмы, янәсе. Кайтканыгызны сагынып көттем. Бер китсәгез, бигрәк озак йөрисез. Онытыласызмы шунда...

— Шушы эзвирең, ата ерткычың, Әндри дәдәйнең кетәклегенә кереп, кырык баш тавыгын кырып чыккан. Буган да ташлаган, буган да ыргыткан. Ышанмасаң, әнә үзең кереп кара, — дип, аның алдына озак еллар төрмәдә өлкән надзиратель булып эшләгән күрше хатыны Назирә килеп басты. — Протокол төзим, участковыйны чакыртыйк, дип, Әндри дәдәйгә кергәнием, кирәкми, башта үзе кайтсын, аннары аңлашырбыз, дип борып чыгарды. Үшән бит ул.

— И-и, Газинур туган, үзең болай дурак егет тә түгел. Умарта тотуыңны да хуплыйбыз. Кышкылыкка балны, базарга чыгып алуга караганда, синнән алуны яхшырак күрәбез. Чөнки синең балың баллырак та, хуш ислерәк тә була. Ләкин ни дип асрыйсың шушы эзвирне? Күр әнә, күзендә мыскал иман әсәре юк. Бүген тавыклар буган. Иртәгә үзеңне буып ташламас дип кем әйтә алыр? — дип, сүзләрне башка күршеләре дә күп тезделәр.

Газинур аптырашта, ни генә әйтсен соң?!

Ә Чатан әйтерсең зур батырлык кылган. Дошман амбразурасын каплап, иптәшләрен коткарганмы диярсең. Хуҗасы каршында утыра бирә. Башыннан сыйпап иркәләгәнне көтә әле. Авызы шатлыклы ерык, койрыгын уйната.

— Бәйдән кем ычкындырды соң сине, шайтан? Салып җибәрермен берне яңагыңа? Әллә колак төбеңә ялтыратасы микән?

— Үзем ычкындым... Ул хәтле инде... ычкынам дигән кешегә ычкына алмаслык бәй юктыр ул. Үзең дә бит ычкына алмаслык итеп бәйләмәгәниең. Сезне дә бик сагынып көттем...

— Булдыргансың инде. Мин сиңа нәрсә дигәнием? Андый-мондый кордебалетлар чыгара калсаң, кара аны, ике каш араңны сугып ярам, дигәниемме? Әйттемме шулай дип? Хайван син! Дуңгызның дуңгызы! Кит, ичмасам, күземә күренмә!

— Газинур күрше, менә без әйткәние диярсең, бераз үсә генә төшсен. Әнә бит нинди азау тешләр чыгарган. Синең үзеңне йә кызларыңны буып ташларга да күп алмас бу. Ишетсен колагың. Эзвир бит бу! Аның да ниндие! Иң хәтәре! — дип, күршеләре тезә тордылар. — Бер-бер чара күр үзең исән чакта!

Газинур беренче эше итеп Чатанны бәйгә утыртты. Үгез көчләре бардыр үзендә. Каккан җиреннән нинди казыкны каерып чыгарган бит. Кулына кувалда алып, имән казыкны җиргә тагын да тирәнгәрәк иңдерде. Казык какканны Чатан да карап торды. Хуҗасы аңа янә бармак янады: тагын да берәр кордебалет чыгарсаң, матри у меня! Бу юлга инде… түзәргә булдым.

Әндри дәдәйнең тавыклары кырык баш ук түгел иде бугай. Курыкканга куш, койрыгы белән биш. Булган трагедияне үз күзе белән күреп чыгарга Әндри дәдәйләргә керде. Ачык ишектән кетәклеккә атлады Газинур. Кетәклекнең иң өске куначасында үз күз алдында булган коточкыч хәлләрдән, тирән стресс кичерүдән әле хәзер дә айный алмаган бичара әтәч һаман да кытак та кытак килә.

— Көпә көндез бит, көпә көндез! Үз күз алдымда ничә бичәмне буып ташладылар. Беспредел бу! Беспредел! Прокурорның үзенә жәвит итәргә кирәк. Бу хәлне болай гына калдырырга ярамый! — Кыт-кытак та кыт-кытак килә. Тирән стресс кичергән зур кикрикле, матур каурыйлы, шпоралы әтәч һаман да тынычлана алмый.

Ә Газинурның бандиты тавыкларның буган берсен ботарламый-нитми койма буена чыгарып сала барган. Унөчен дә бер рәткә тезгән. Хәтта каннарын да чыгармаган.

Ишегалдында Газинур йөрүен күреп, баскыч төбенә Әндри дәдәй чыкты. Соңгы вакытларда бераз авырып тора әле ул. Култык таягына таянган. Күпне күргән, авыр тормыш юлы узган агай. Газинурның күршеләре арасында иң әйбәте, иң иплесе, йомыш белән керә торганы. Әмма бу юлы… Әндри дәдәй нинди җәзага тартыр инде аны. Һәрхәлдә, башыннан сыйпамас. Газинур әзер… Әндри дәдәй ни дисә дә…

Әндри дәдәй исә, ипләп кенә:

— Күршеләр иң якын туганыңнан якын затлар. Туганың — ераката, ә күршең күршедә генә. Ни йомышың төшсә дә, аңа керәсең. Хәзер генә артык баеп, әллә кем булып киттек. Бер-беребезгә сәлам бирергә дә онытабыз… — дип сөйләп китте ул. — Минем малай чагымда мичебездәге салам көлтәсенә ут кабызырга күршеләребезгә бер бөртек шырпы сорап кергән чакларым исемдә. Күршеләребезгә чуенда пешкән кабыклы бәрәңгене манып ашарга бер чеметем тоз сорап кергән чаклары бызда булды. Үзебез дә шундый идек. Ишегебез бусагасын атлап, нәни генә гозер белән кергән кешене дә буш чыгармадык.

Әндри дәдәй бер араны тын калып торды. Газинур аңа текәлде.

— Күрше хакы бик зур, Газинур туган. Килгән зыянны түләр булсаң, участковыйларга барып талашып йөрисем бер дә килми, — диде ул. — Ашыкма, үз җаең белән. Үз җаең белән ризалатырсың. Мин ашыктырмыйм.

— Әндри дәдәй! Мең яшә! Түләмимме соң! Үзем белән эшләгән бер әйбәт егетнең хатыны кошчылык фабрикасында ветеринария табибы. Аның аркылы яздырып алып, иртәгә үк унбиш тавык төшереп бастырырмын. Рәхмәт сиңа җылы сүзең өчен! Мең яшә, Әндри дәдәй!

Күршеләреннән чыккач, Газинур Чатанның оясы алдына килде. Ә ул юлбасарның авызы һаман да ерык, оясы алдында зур батырлык кылган кыяфәттә утыра. Күкрәгенә медаль такканны көтә.

Газинурның кулында урам себеркесе. Шул себерке сабы белән Чатанның сырты буйлап бер-ике «медаль» кундырырга бик исәбе бар. Ата гайрәтле булса, бала гыйбрәтле була дигән алтын принципны алга сөреп.

— Ни дип күршеләр кетәгенә барып кердең, хайван? Корткыч син! Тамагың ачмы? Ашарыңа җитмиме?

— Абау! Нәрсә булган инде ул хәтле? Карап чыгыйм, кемнәр яшәп ята икән монда дип кенә кергәнием. Керсәм, тавыклар! Бүре күргәннәре юкмы диярсең. Тотындылар кытак та кытак! Пыр да пыр киләләр. Шунда башыма хуҗаларның кунактан кайтышларына мин дә бүләк ясыйм әле дигән бер уй килеп куймасынмы! Газинур абый, миндә дә нәкъ синең холык бит. Башыма килгән уйның очына чыкмый калмыйм. Мал иясенә охшамаса, хәрам була, дияләр түгелме соң сездә?

— Син дә мал булдыңмы? Корткыч син! — дип кизәнде себеркесе белән Газинур.

— Берәм-берәм будым да барысын да койма буена чыгарып тездем. Бер тамчы каннарын да чыгармадым. Мин аларны сиңа бүләк өчен будым бит, Газинур абый.

— Булдыргансың! Кем синнән бүләк сораган? Игелексез син! Ярый әле Әндри дәдәй яхшы кеше. Эшне зурга җибәрмәде. Бирермен берне шушы себерке сабы белән сыртың буйлап. Кисәтмәдем түгел, кисәттем. Кордебалетлар чыгара калсаң, ике каш араңны сугып ярачакмын, дип. Бар, ояңа кереп кит, күземнән югал, ичмасам! Корткыч син!

Чатан хуҗасының аны аңламаганына тәмам кәефе кырылып, койрыгын бот арасына кыстырып, оясына кереп ятты. Газинур да күзгә карап узына барган бүре малаен бераз акылга утыртып алырга кирәк дигән уеннан кире кайтты. Бәйдә, чылбырда утырган әлеге шайтан белән булышмас бит инде. Себеркесен читкә томырып, өенә кереп китте.

* * *

Башыңа төшсә, башмакчы буласыңны көт тә тор. Булмыйча хәлең юк. Әлеге бүре малаена аз гына булса да гыйлем бирергә кирәк бит. Газинур кинолог, ягъни эт өйрәтүче вазифаларын да үз өстенә алды. Чатанны тормышта бик кирәкле командаларны үтәргә, тыңларга өйрәтми ярамый. Бер кирәге чыкмаса, бер чыгар. Әлегә исә ул бит чеп-чи надан. Күзеңә карап иркәләнергә, ялагайланырга гына булдыра. Апалары аны «бир бишне!» командасын үтәргә өйрәттеләр бугай инде. «Бишне» бик теләп бирә. Сорасаң да, сорамасаң да алгы тәпиен суза. Чөнки «бишне» биргән саен, апалары аны тәмле конфетлар белән сыйлыйлар. Болай үзе сәләтле егет күренә ул. Тырышканда күп нәрсәгә өйрәтеп булыр төсле. Апалары Чатанга «ят!», «утыр!», «бире кил!» командаларын да өйрәтеп киләләр.

Чатан белергә тиешле иң әһәмиятле командаларның берсе — «фу!». Ягъни «кагылма!», «тимә!», «ярамый!». Икенчесе — «фац!». Ягъни «тот!», «каптыр!», «ботарла!». Тормышта шундый ситуацияләрнең дә килеп чыгуы мөмкин, шушы ике команданы ул бер әйтү белән үтәргә тиеш.

Әлеге шушы халыкара ике команданы Чатанга өйрәтергә Газинур үзе алынды. Каяндыр укып-нитеп түгел, үз акылы белән. Дөресрәге, әнисе Нәфисә апай бала чакта аның үзен имчәктән биздергән ысул белән. Ашау-эчүдән калып, сыны катып елап имчәк таләп иткән иркә улына тәмам аптыраган Нәфисә апай имчәк очына кызыл борыч сөртеп каптырганые. Әй яндырды, әй өтәләде ул чакта кызыл борыч Газинурның тел очын. Йөткерде, төчкерде, буылды малай. Борыныннан куыклар чыгарды. Әмма сабак тәэсирле булды. Шуннан бирле иркә малай имчәкне ник бер сорасын.

Газинур зур гына ит кисәгенә күп итеп кызыл борыч сибеп, горчица ягып Чатанга ыргытты. Ач күз бүре малае аны җиргә төшкәнче үк элэктереп алды. Кабып та йотты. Аннары гына үрле-кырлы сикерә башлады. Хуҗасы башта «фу!», «фу!», «фу!» — «кагылма!», «ярамый!» дип өч тапкыр кисәткәние. Чатан аны колагына да элмәде. Элмәсәң, менә шул инде. Ит кисәгенең яндыруына түзә алмасаң, күккә сикер.

Утлы күмер кисәгедәй калҗа каптыруны Чатан башта Газинур абыйсы тарафыннан эшләнгән башка сыймаслык хыянәт итеп кабул итте. Күрәләтә торып ничек инде мондый этлекне-усаллыкны эшләргә мөмкин? Ә хуҗасы баягы серле сүзләрне тагын өч тапкыр кабатлады. Ярар, моның артыннан ни булыр? Хуҗасы янә бик хуш исле калҗа ыргытты. Чатан аны да кабып йотты. Бу юлы ул чүт кенә: «Абау-у-у! Үләм бит!» — дип улап җибәрмәде. Калҗаның монысы тегесеннән дә утлырак булды. Эчендә янган утка түзә алмыйча, Чатан үрле-кырлы сикерә.

Хуҗасы, нәрсәдер сибеп, кашык белән нәрсәдер ягып, оя алдындагы тәлинкәгә чат сеңер бот сөяге куйды. Андый сеңерле сөяк күрсә, Чатан тәкатен җуя. Әмма хуҗасы, аның алдына ук чүгеп, янәдән әлеге серле сүзләрне кабатлады: «Фу!» Чатан сөяккә бик кызыкса да ашыкмаска булды. Дөрес эшләде. Сөяккә тел очын гына тидереп караганые, теле утлы тимергә тидергәндәй пеште. Аннары апалары да аның белән шундый ук «дәресләр» үткәрделәр.

Чатан сәләтле егет бит ул. Үзеннән нәрсә таләп иткәннәрен тиз төшенә. Дөрес, башта хуҗасына да, апаларына да бик нык үпкәләгәние. Аралашмаска, уйнамаска, барларын да белмәскә, оясыннан да чыкмаска иде исәбе. Аннары кайтты тагын. Холкы белән ул ачу да, үпкә дә саклый белми иде. «Фу!» икән «фу!» инде. Монда төшенмәслек бернәрсә дә юк. Шуны үземә тел белән генә әйтсәгез дә аңлаган булыр идем әле. Ә сез проблемага әйләндерәсез. Бераздан ул, берни булмагандай, оясы түбәсенә менеп ятты. «Фу!» дигән команданы ишетү белән бернигә кагылмас булды. Димәк, «табу!», димәк, «ярамый!». Бүреләрнең үз араларында да мондый «табулар» байтак. Мондый «тыюлар»ны алар бер-берләренә буыннар аша бирепкиләләр.

«Фас!» командасын өйрәтү шулай ук кыен булмады. Хуҗасы сеңерле, майлы ит кисәген ераккаук ыргыта да «фас!» ди. Алып килергә куша. Чатан шундук алып килеп бирә. Апалары да читкә прәннек-печенье ыргыталар. «Чатан, фас!» диләр. Алар кушкан команданы Чатан аеруча теләк белән үти. Чөнки бик ярата аларны. Өйрәтсеннәр генә. Шулай өйрәтеп торсалар, Чатан гыйлемен тагын да тирәнәйтергә әзер. Ул бит аңгыра баш түгел. Менингит белән дә чирләмәде. Чатанның сәләтле баш булуына

хуҗалары да, ул үзе дә сөенә. Әле «бир бишне!», «фу!», «фас!» белән генә калмаслар. Шулай өйрәтеп торганда, гыйлемне нигә арттырмаска? Өйрәтсеннәр генә. Чатан бик теләп әзер.

Ул көнне Газинур эштә иде. Апалары Чатанны өй тирәли прогулкага алып чыкканнар. Бәхетсезлеккә каршы, Чечнядан кайткан офицерлар яшәгән биш катлы йорттан әлеге теге холыксыз, бәйләнчек хәрби дә чыккан. Овчаркасы Черчилль белән инде. Чыккан да, кулыннан да ычкындырган. Тегесе, Чатанны күреп алу белән, аның өстенә ташланган. Әүмәкләшеп киткәннәр. Чатанны күрәләтеп талаганны, буганны апалары карап тормаслар ич инде. Аны да ирегенә җибәргәннәр. Озак әүмәкләшмәгәннәр. Чатан теге овчарканы буып, хәлсез калдырып, юл читенә салган. Бугазыннан кан саркый. Шау-шу, чыр-чу зур булгандыр инде. Тыкрык чаты бит. Моннан халык өзелми.

Вахта автобусы белән Газинур промыселдан кайтып төште. Автобустан төшсә, сабан туе диярсең, халык җыйналган. Уртада әлеге майор.

— Я этого заслужил! Понимаете, заслужил! Я этого так не оставлю! — дип, баш өстендә зур йодрыгын уйната. Кулында кәрәзле телефоны. Кемнәрнедер срочно үз янына дәшә. «Ашыгыч ярдәм» машинасын дәшәргә дә өлгергәнме? Шул арада алар килеп җитте.

— «Фу! Чатан! Фу!» дип ни тыярга тырыштык. Овчарка безгә үзе килеп бәйләнде. Чатан аны буды да салды, — дип, кызлары елап торалар.

«Мин барып ябышмадым. Үзе бәйләнде бит! Үзе бәйләнде! Ул минем бугазны буганда мин карап торыйммы?» дигән кыяфәт белән апалары янында исе дә китми Чатан утырып тора. «Ашыгыч ярдәм» машинасыннан төшкән кап-кара сакаллы, колгадай озын буйлы хирург егет һәм сап-сары чәчле шәфкать туташы Черчиллгә беренче ярдәмне күрсәттеләр. Ап-ак марля белән муенын, тәпиләрен бәйләделәр. Уколлар да кададылар. Овчарканы үзләре белән алмадылар. Яшь кенә ике санитар егет аны, носилкага салып, әлеге хәрбинең фатирына керттеләр. Ә хәрбинең үзен: «Безне анда йөрәк авырулы кешеләр көтә. Моннан соң безгә мондый вызовлар ясамагыз!» — дип орышып та алдылар. Бу холыксыз хәрбинең: «Я этого заслужил!» — дип сукрануы «ашыгыч ярдәм» каретасы киткәч тә ишетелеп торды әле. «Я этого так не оставлю!» дип тә кычкырган икән әлеге хәрби.

Бу яңа йортта алар байтактан торалар. Башкаларының тыннары да юк. Шул ук подъезддан хәтта полковник дәрәҗәле бер офицер да чыгып йөри. Бик ачык, әдәпле кеше. Күрше-күлән белән беренче булып үзе исәнләшә, хәл-әхвәл белешә. Ә бусы исә хезмәт иткән җирендә контузия-мазар алганмы, әллә нервылары бөтенләй какшаганмы? Кем туры килсә, шуның белән бәйләнешергә генә тора.

Бер атналардан Газинурны участковый чакыртты. Барса, бүлмәдә әлеге хәрби утыра. Гариза язган. Овчаркасын талаткан өчен Газинурны судка бирмәкче икән.

— Гражданин Исмәгыйлев, күршеләрегезнең сезнең өстән язган жалобалары миндә бер кочак. Нигә сез беркем белән тату яшәмисез? Күршеләрегез әйтеп торалар, овчаркагызны урамга битлексез алып чыккансыз. Чыгу белән үз ирегенә җибәргәнсез. Һәркем белән алай әчелешле булып, бәйләнешеп йөрсәгез, мин сезгә үзем зур итеп штраф салам, — дип, аның үзен орышты участок инспекторы.

— Күрәләтә торып башбаштаклык бу, иптәш инспектор? Мин моны болай гына калдырмыйм. Үзегезне соңгы инстанция санасагыз, нык ялгышасыз. Мин Мәскәүгә язачакмын. Мин — Кавказ сугышы ветераны! Мин анда кан койдым! — дип, капитан Исмәгыйлев өстәл сукты.

Участок инспекторы, зәңгәр күзле, кара мыеклы яшь кенә егет:

— Ә сез, Газинур агай, кайтып китсәгез дә була, вопрос исчерпан, — дип, ишеккә күрсәтте. — Әй, әйе, агайлар, мондый чакны бөек Маяковский агаебыз да: «Вопрос на этом исчерпан!» — дип әйтергә яраткан. Мин бит заочник. Педагогия институты студенты. Тиздән сессиягә барырга. Укыйсы әдәбиятның чиге юк. Ә сез күпме вакытымны алдыгыз. Соңгы күрешүебез булсын, карагыз аны. Дөнья матур, дөнья киң. Шушы матур дөньяны һәркайсыбыз үз кулыннан килгәнчә бизәп, тату гына яшик әле, егетләр, — диде дә, әлеге төскә-биткә дә бик чибәр инспектор егет аларның икесенә дә күз кысып алды. Аның бу сүзләреннән жалу белән килгән бәйләнчек хәрби дә хәтта сискәнеп киткәндәй булды.

* * *

Үз өең, үз йорт-җирең, каралтыларың, мунча-гаражларың белән ун-унбиш сутыйлар җир биләсәң дә, ишегалдында бүре кадәр бүре асрауның кыенлыкларын сөйләп кенә бирешлеме соң? Аны үз җилкәңдә татып карарга кирәк. Әмма Газинур әлегә зарланмый. Холкы андый түгел.

— Кара аны, малай актыгы! Матри у меня! — дип, Чатанның борын төбендә зур йодрыгын уйнатып ала да эшенә китә.

Андый чакта Чатанның түбәсе күккә тия. Оясы алдында тыпыр-тыпыр биеп алып, хуҗасы алдында ялагайлана, кулын ялап ала, үз яныннан җибәрмәскә тырыша. Ә күз карашы! Чын ерткычныкы бит. Ул көннән-көн шиклегә, кырыс карашлыга, усал ниятлегә, нәфрәтлегә әйләнә бара төсле. Менә-менә тышка бәреп чыгарга торган ерткычлык инстинктларын гаять зирәк акыллы җан булуы аркасында гына тыеп, басып килә бугай. Алай да үз-үзеңне күпме тыеп торырга була? Бер тора торгач, тәмам чыгырдан чыгып, тимер чылбырын зәһәрләнеп чәйнәп, психланып ала. Уңга-сулга ыргыла, үзен-үзе имгәтеп булса да бәйдән ычкынмак була. Андый чакта апалары чыгып кына, башыннан сыйпап, иркәләп, матур

сүзләр әйтеп кенә тынычландыралар аны. Ычкынуын беркая да ычкына алмый ул хәзер. Газинур да тиешле чараларны күрә тора. Үзләренең промыселындагы тимерчедән муенчакны да күгәрми торган тимердән эшләтеп кайтты. Чылбыры да үгезләр арканлый торган.

Кичләрен, йокы алдыннан, ишегалдына саф һава суларга чыккач, Газинур беренче эше итеп бүре малае янына килә.

— Ни хәлләр, картлач? — дип, аның башыннан сыйпый.

Чатан өчен дөньяның иң татлы, иң матур минутлары шушы мизгелләр. Хуҗасының аны яратуын сизә ул. Шул ук вакытта әлеге минутларда аның күңелендә әллә нинди каршылыклы уйлар туа...

— Түзәрлек, — ди ул, моңсу гына. — Түзми нишлисең? Муенда корыч богау... Алда... билгесезлек...

— Түзәрлек, имеш. Сөйләшүен генә күр. Инде син дә тормышыңнан зарлансаң... Әнә тоташтан май басып килә бит үзеңне. Өйдә өстәлдә булган бар затлы ризыкны, башта үзләре кабып караганчы, апаларың сиңа чыгаралар. Кара бу түшкәңне, бер кыш чыккан тана хәтле булып киләсең бит.

— Симермәскә, ашау — байдан, үлем — Ходайдан. Баш өстемдә түбәм бар, артык кырыс булса да, хуҗам бар. Муенымда тимер галстук булса да, түзми хәлең юк, дип уздырам инде көннәрне. Юкса күңелемне бик тирән вәсвәсәләр баскан минутларым да булып куя куюын. Андый чакларны үз-үземне белешмим. Ә син, хуҗам, ник шулай ямьсез улыйсың, дип чыгып мине орышасың. Уламассың! Тимер галстугыңны көнен дә, төнен дә салмый үзең менә бер генә тәүлек утырып кара әле.

— Чакырып кайтармадым. Башта алдыңа бер чуен итле аш куйдык. Тамагың туйгач, дүрт ягың кыйбла, дидем. Калсаң, чылбырга утыртачакмын, дидем. Калдың, риза булдың. Мин бит сине, баш бармагы бүрәнә ярыгына кысылган Шүрәле төсле сузып улама, этләр кебек ваклап өр, дип орышам. Улавың бик ямьсез чыга бит.

— Бүре башым белән эт аламасы, маэмай булып өрергәме?! Кит инде, хөрмәтле хуҗам! Акыллы агай бит син! Эт булып өрсәм, миннән тавыклар көләчәкләр бит. Никогда в жизни!

— Ярар, телеңә остарма. Кара аны, моңарчы күрсәткән комедияләреңә дә тәмам гарык. Кордебалетларның яңаларын күрсәтә күрмә. Минем дә бит түземлек чиксез түгел. Ачуымны чыгарсаң, түзәрмен-түзәрмен дә, бер кичне кых итәрмен дә куярмын үзеңне. Сизми дә калырсың. Умарталыкка алып йөри торган кинжалым әнә чөйдә генә тора. Чиста итеп тунап алып, иләтеп тә җибәрсәң, бер дигән бүре толыбы чыга хәзер синнән. Андый киңәшне миңа эштә дә әйткәлиләр. Кара аны...

— Абау, абау! Тәннәрне чытайткыч сүзләр сөйлисең бит, хуҗам. Мин сине бик ихтирам итәм, чын әгәр, бик акыллы кешегә саныйм. Ә бер тора торгач әллә нинди, бернинди калыпка сыймас ахмак сүзләр дә сөйләп куясың. Кем инде хәзер бүре толып кия?

— Кимәсәм, чөйдә эленеп торыр. Малы түгел, даны ни тора! Матри у меня! Артыгын узынма! Булганына канәгать калып яшәргә өйрән. Ак сакаллы карт булырсың.

Хуҗасының «матри у меня»сына Чатанның бик исе китә инде. Ишегалдындагы мал-туарның котын алып дулап та ала, ямьсез итеп улап та куя. Хәзер аларга күрше-күләннәре кермиләр. Туган-тумачалары да сирәк киләләр.

Барчасы:

— Капкагызны ачып керергә кот чыгып тора. Китегез инде, прәме! Ул эзвирегез ычкынып китсә... Беттем, әҗәлем шушы икән, дисең инде, — диләр.

— Таптың инде асрар мал! Мал булса икән, теп-тере бүре бит! Бу ерткычны симерткәнче, берәр тана симертсәң, авызың-борының май булыр иде, Газинур туган, әгәренки дивана баш булмасаң! — дип, шул рәвешчә үпкә белдереп, акыл өйрәтүчеләр дә җитәрлек.

Хәсрәт хәсрәткә охшамый, баш хәсрәттән бушамый дигәндәй, Газинурның үз башына үз теләге белән алган хәсрәт бу. Үз бөкреңүзеңә авыр булмый, әлегә түзә әле. Кеше хәлен кеше белми, үз башына төшмәсә, диләр. Газинурның кызлары гына түгел, аның күзләренә котып салкынлыгы белән караган шушы хәйләкәр бүре малаен ул үзе дә ярата. Нилектән икәнен дә белми. Ярата, еш кына кочагына алып та сөя. Күңелендә төрле каршылыклы, вәсвәсә уйлар уйнаклаган чагында: «Нишләтәсең инде аны? Дөньяга бүре булып туган җанны көчек йә песи баласы итә алмыйсың. Кирәге дә юк. Үзе булып яши бирсен», — дип юата ул үзен-үзе.

Узган атнаны, сишәмбе көн, вахтадан кайтышлый, төрле кош-корт, ерткыч җанварлар сурәтләре төшерелгән афишалар күреп алды Газинур. Шәһәргә күчмә зверинец килеп чыккан. Нәниләр, балалар өчен зур бәйрәм ясап, алар ел да бер килеп чыгалар. Барыннан бигрәк мәктәп балалары рәхәтләнәләр. Юкса Африка филен, озын жирафны, Уссури юлбарысын, зебр атларын, ун метрлы анаконда еланын, ак аюны үз күзләре белән кайчан күрерләрие иде әле. Класслары белән дә, үзе генә аерым кереп тә, зверинецта Айгөл дә булып кайткан.

— Ерткыч хайваннарны быел аеруча күп алып килгәннәр. Юлбарыслар хәтта өчәү. Ак аю әле бәбиләгән генә. Балаларын берәүгә дә күрсәтми, кочагында гына тота, — дип, бик әсәрләнеп сөйләп утырды ул чәй өстәле артында. — Ә менә «Степной волк» дигән читлек буш. Нигә икән? Бүресе әллә чыгып качканмы?.. Зверинец миңа бик ошады. Мин тагын керәм әле.

Кече кызының «Степной волк» дип язылган читлек буш» дигән сүзләре Газинур колагына аеруча кереп калды. Күңеленә кылт итеп бер уй килде. Зверинецка ул шул көнне үк төшеп китте. Әйе, «Степной волк» читлеге буш икән шул.

Читлек эчендәге ерткыч хайваннарга күз-колак булып, шушы тирәләрдә йөренеп торган кара күзлекле, кыршылган джинсалы егеттән:

— Болай карап торырга ипле генә торак, бу читлек нигә буш? — дип сорады.

Әлеге егет, шушы сорауны гына көткәндәй, ачылып:

— «Степной» бер дигән мировой бүре иде. Циркач! Озак еллар циркта эшләгән. Безгә аны бераз начар күрә башлагач биргәннәрие. Цирк сәхнәсе! Прожекторлар! Ничек сукыраймыйсың? Болай үзе бик ныk күренә иде әле. Тамагына да яхшы ашады. Гастрольләргә чыккач кына безне бик уңайсыз хәлгә куеп үлде дә куйды, — дип сөйләп китте. Егет, кара күзлеген салып, өскә, һавага күрсәтте. — Аның җаны хәзер тегендә, күкләрдә инде. Кызганыч, әйтәм бит, Рюрик мировой бүре иде... Хәзер читлеге буш тора.

— Әлбәттә, кызганыч, — дип куәтләде аны Газинур. — Үзегез монда кем буласыз? Администратор-мазардыр инде?

— Минме?! — диде егет, ике кулын ике якка җәеп, елмая төшеп. — Мин Мәскәү ветеринария академиясенең дүртенче курс студенты.

— Булачак ат духтыры, алайса, — дип елмайды Газинур. — Үпкәли күрмәгез, бездә ветеринария врачларын, иң изге ихтирам хисләре дә өстәп, «ат духтыры» дип йөртәләр.

— Беренче ишетәм, әмма приятно слышать. Нәкъ үзе, нәкъ үзе, — дип күтәреп алды студент егет. — Бу гастрольләр минем җәйге практикам. Күбебез практикага академиянең үзендә калдылар. Ипподромнарга, манежларга, бөтенсоюз күргәзмәләренә урнаштылар. Мин дә бу гастрольләргә бер дә теләмичә, акчасына алданып кына чыкканыем. Ә бик кирәкле әфәнде булып чыктым. Көн дә кирәгем чыгып тора. Бер атна гына элек ак аюыбыз Флора бәбәйләде. Башыңа төшкәч, башмакчы булмый хәлең юк. Флорага кендек әбисе булдым. Әнә хәзер ике улын да ничек кочагына кочкан. Кулыннан төшерми. Әйтерсең аның ярым сукыр уллары кемгәдер хаҗәт. Хәтта мине дә якын җибәрми. Әнә теге гыр-гыр йоклап яткан арыслан Кинганы гына күр. Өч көн рәттән теше сызлады. Акырды инде, читлегендә урын тапмады. Ул улаганда парктагы барча кош-корт, җанвар халкы дер калтырап тора. Нәрсә эшләргә? Биш кубик укол ясадым да йоклаттым үзен. Авызын каерып ачтым да черек тешен умырып аттым. Бернинди ассистентсыз бит! Әнә хәзер колак төбендә пушкадан атсаң да уянырга исәбе юк. Йокласын инде бер рәхәтләнеп. Әнә нигәдер филебез Солтанның кәефе юк әле. Эче каткан. Чөнки гастрольдә теләсә нәрсә ашатырга да туры килгәли. Кайчакларны аның ашказанына ярап бетмәгән ашамлыклар да эләгә, күрәсең. Менә хәзер аңа бераз касторка бирәм. Рәтләнер. Солтан безнең шулай ук озак еллар циркта эшләгән. Күп командаларны аңлый. Ә мине беренче көннәрдән үк үз итте. Хәтта шаярмак та була әле. Читлегенә керсәм, алгы аякларына төшә. Башымнан кепкамны салдырып читкә бәрә.

Беләсезме, чынлап торып ярата башладым үзләрен. Булачак профессиямне дөрес сайлаганмын бит. Шуңа сөенәм. Күзеңә карап, синнән ярдәм көткән бу телсезләргә кирәк чакта ярдәм итә алуым миндә патриотик хисләр уята. Үземне, сез әйткәнчә, ат духтыры итеп кенә түгел, чын Айболит итеп хис итәм. Ә бит башта аяк атлыйсым да килмәгәние. Мондый гастрольләрдә тройной оклад түлиләр, дигәч, акчасына гына кызыгып күнгәнием. Студент кешегә аңа һәрчак акча җитешми бит.

— Килешәм. Үзем дә заманында студент булган кеше, — дип килеште Газинур. — Үзегез болай ачык күңелле, чибәр егет икәнсез... Ә башлыгыгыз кем?

— Шефыгыз кем димәкче буласызмы?

— Әйе. Менә аны да күрергә буламы?

— О-о, Ашот Саркисьянович кирәкме сезгә? Нигә булмасын. Әнә теге, башын калай белән япкан алачыкта утыра ул. Ит сорап шәһәр башлыкларына барырга җыена иде. Боларга ашатырга көненә беләсезме күпме сыер кабыргасы, ат боты кирәк? Санап күрсәтсәм, исегез китәр. Ашыгыгыз, китеп өлгермәсен.

Ашот Саркисьянович урта яшьләрдәге озын буйлы, спортчыларга хас җыйнак гәүдәле, кара мыеклы, башына бейсболчылар кепкасы кигән Кавказ кешесе булып чыкты.

— Нинди йомышлар белән йөрмеш, дорогой? — дип, Газинурны ачык йөз белән каршы алды. Йон баскан беләгенә таккан сәгатенә карап: — Бик ашыгам, дорогой, — диде.

— «Степной волк» дип язган читлегегез буш икән, — диде Газинур.

Сүзне аңа, бәлкем, икенче почмагыннанрак башларга кирәк булгандыр. Шулай диде дә бераз уңайсызланып калды. Башлык ашыктыра бит.

— Буш шул, дорогой, буш. Килгән берсе шул читлеккә игътибар итә. Хуҗасын гастрольгә чыккач югалттык. Рюрик озак еллар циркта хезмәт иткән почетлы ветераныбыз иде. Дәүләт Думасына делегат итеп сайларлык акыл, зиһен һәм тормыш тәжрибәсе бар иде аның, понимаете! Бик үкенеч. Рюрик читлеге инде бер ай буш...

— Менә ни...

— Тыңлыйм сезне, дорогой.

— Минем өемдә яшь ярымнар тирәсе бик акыллы бүре егете бар.

— Тыңлыйм... Ачыграк булыгыз.

— Алсагыз... тәкъдим итмәк идем. Болай үз гаиләбездә дә артык кашык, артык җан түгел. Хатыным да, балаларым да яраталар. Әмма иң кансыз ерткычлар нәселеннән бит...

— Бүре башын бүреккә салсаң да, урманга карый, диләрме әле? — дип куәтләде Ашот Саркисьянович Газинур сүзләрен.

— Алай ук түгел, — дип куйды Газинур. — Үзебезнеке ул...

— Бик теләп алабыз, дорогой. Почему же алмаска?! Бик яшь тә булгач кыйбат сорыйсыз булыр инде. Күпмерәк сорамак буласыз?

— Китегезче! Сату, алыш-бireш турында сүзнең булуы да мөмкин түгел. Ул безгә улыбыз кебек якын. Сезгә әнә күпме бала-чага килә. Безнең Чатанны зверинецка бүләк итеп алыгыз. Әйтәм бит үзебезгә дә бик кадерле ул. Яратабыз. Ләкин аңлый булырсыз. Ерткыч ерткыч инде ул. Нинди хәл булмас... Башка чарабыз юк.

— Аңлыйм, дорогой, бик аңлыйм. Аңламаска соң! — дип хуплады Ашот Саркисьянович. — Шулар арасында гомер кичерәм бит. Ерткычның да ниндие әле! Үзсүзлеләр. Дрессировкага да бик кыенлык белән биреләләр... Ул чакта киттек сезгә. Безнең Кавказ халкы тимерне кызган чагында суга.

Ерткыч җанварлар йөртергә махсус көйләнгән «Газель» белән менеп тә киттеләр.

— О-о! Какой красавец! Экземпляр! Мондый егетне алмаска соң! Бишкуллап алабыз. Берәр дрессировщик күреп алса, миннән аны аягыма егылып сорар әле, — дип бот чапты зверинец башлыгы.

— Мин Чатаныбызны беркемгә дә бирмим! — дип, Айгөл нык карышмакчы иде.

— Кызым, карышма! Бу турыда мин күп уйландым. Уйламый-нитми генә хәл ителгән нәрсә түгел. Чатаныбызның алдагы язмышы өчен бу иң-иң кулай вариант, — дип әтисе кырт кисте.

— Безнең бәхеткә дә, аның бәхетенә дә көтмәгәндә генә чыгып куйган иң уңай лотерея отышына вариант бу. Муенына тимер галстук таккан хәлдә гел бәйдә, чылбырда утыру түгел. Гастрольләрдә йөрер, илләр гизәр, дөнья күрер. Кереп карап чыктым. Читлеге иркен, бәлкем, иптәшкә янына тагын берәр бүре ябарлар. Кәләшле дә булыр. Гел чылбырда-бәйдә утыру түгел.

Әмма Чатан белән хушлашу-саубуллашу алай җиңел генә булмады. Беренчедән, башта ук шикле күренгән бу машинага Чатан һич кенә дә утырырга теләмәде. Киреләнде. Аяк терәп карышты. Тешләшмәкче булды. Башына калын арыш капчыгы киерткәч кенә, анда да көч-хәл белән читлеккә кертә алдылар.

— Рай-вай-вай! Какой экземпляр! Авырлыгы да центнер булыр! — дип, маңгаен, муенын сөртте Ашот Саркисьянович.

Кызларның яшь сыгуын сөйләп бетерешле булмады.

Чатан исә читлеккә кертеп япкач та:

— Хуҗам, матур апаларым, нишлисез сез? Мондый хыянәтне сезнең тарафтан гомердә көтмәгәнием. Мине ни дип бер белмәгән чит-ят кешеләр кулына биреп җибәрәсез? Мин аларда нишләрмен? Сезне өзелеп сагынуга түзә алырмынмы? Урманнан да сезне бик сагынуга түзә алмаганга кайттым. Без бит, бүреләр, сагынсак, сез, кешеләр төсле, өстән-өстән, бер атнадан онытырлык итеп сагынмыйбыз. Без сагынсак, сыгылып төшеп, тамактан-аяктан калып, тәмам хәлдән таеп, егылып китеп сагынабыз. Чөнки шулай сагынырлык итеп, мәңгегә тугрылык саклап ярата да беләбез, — дип, читлек эчендә аркылыга-буйга бәрелде. Гөрс-гөрс килеп читлеккә бәрелде. Үзен-үзе бетермәк булды.

— Ярар, ярар! Барыгыз берьюлы сыгылып төшмәгез әле! — дип сөйләнде Газинур барыннан бигрәк үзенә-үзе. — Башны ташка орырлык трагедия булмады бит әле. Зверинецка эләгү каторгага хөкем ителү түгел. Киресенчә, сөенергә генә кирәк. Анда, кая карама, Чатанның үз ишләре булачак. Вакытында ашаталар, вакытында су бирәләр. Авырып китсәләр, табиблары бер дигән егет. Директорлары, әнә күреп торасыз, нинди ипле кеше. Чатанны әйтәм, беренче шәпкә әнә шулай кәҗәләнсә дә, бераздан күнегер. Күнегер генә түгел, безгә рәхмәтләр укыр әле.

Кызлары алдында Газинурга чыннан да бераз уңайсыз иде. Алай гынамы?! Ничә еллар бергә гомер иткән, ике кызын буйга җиткереп килгән хатыны Сәрияне генә күр әле. Моңарчы Чатан янына килгән, ашарына чыгарган булса икән. «Сезнең шул канечкеч юлбасарыгызны күземә күрсәтмәгез, теләсәгез кая куегыз!» — дип сукрана гына иде. Хәзер исә зур чәчәкләр төшкән алъяпкычы итәгенә казан кабартмалары тутырып чыккан да:

— Мә, балакаем, үз кулымнан ашап кал! Берүк, сабыем, безгә рәнҗеп китә күрмә! Миңа мишәйт итми идең, хуҗаң бит шулай хәл иткән. Кем белә, бәлкем, чыннан да шулай кирәктер. Үз кулымнан аша, сабыем, — дип, тимер рәшәткә аша Чатанга кабартма артыннан кабартма каптыра. Алъяпкычы очына әледән-әле күз яшьләрен сөртә. Аннары, капка төбендәге урындыкка утырып, сыгылып еларга кереште.

— Сәер дә соң сез хатын-кыз заты. Сезне һич аңламассың, — дип, Газинур аны юатмак була. — Чатан әле кайчан гына синең өчен урман пәрие, кылый юлбасар, канечкеч эзвир иде. Теләсә кая куегыз

үзен, дип, тәмам миемне череттең бит, әнисе. Ә хәзер инде «балакай»га, «сабый»га әйләнгән. Прәме аптыраш!

* * *

Чатанны зверинецка бирүләренә бер еллап ара узды бугай. Әмма Газинур гаиләсендә аны искә алмаган бер кич тә юктыр. Һәрчак сагынып, юксынып.

Беренче булып хатыны Сәрия җиңгәй искә төшерә:

— Ул чын эзвирләр арасына юкка гына бирдек без аны. Яшәгән көе үзебездә дә яши бирер иде әле. Ул эзвериниста уң күршең дә эзвир, сулың да чын эзвир булгач, эзвир булмаган җиреңнән кан эчүчегә әйләнерсең. Чатаныбыз да чын ерткычка әйләнер инде, — дип тезеп китә. Яулык читенә яшен дә сөртеп ала.

Күрше Бакировларның игелекле, уңган әнкә этләре янә балалады. Шулар арасыннан иң тересен, иң матурын сайлап, Айгөл бер көчек алып чыкты. Аңа Сарбай дип исем куштылар. Әнә бөтен ишегалдын аркылыга-буйга буйлап койрык чәнчеп уйнап йөри. Бик усал, кырыс холыклы маэмай булырга ниятли. Коймага кунган саесканнарга да чәң-чәң килә. Йөрмәгез монда, китегез, дип кумак була.

Газинур бу җәйне кортларын Чияле тау ягына, очсыз-кырыйсыз ап-ак җәймә булып, алты йөз гектарлар җирне биләгән карабодай кырына чыгарды. Урыны матур. Яссы гына тау бите. Карабодай килештерә мондый җирләрне. Яңгырлар да вакытында булып китсә, бал булачак монда. Ә карабодай балы — табигатьнең бүгенгәчә ачылып җитмәгән сере, бер могҗизасы. Аның янында иң яхшы сортлы балларың да бер читтә торсын. Беренчедән, хуш исе генә ни тора! Аш өстәленә бер касә кертеп куйсаң, бөтен өй эченне әле мичтән генә алган ак күмәч исе баса. Калак очына гына алып, тел өстеңә салсаңмы?! Дөрес, капкан шәпкә башта җиңелчә генә кхм, кхм йөткереп аласың. Чөнки карабодай балы синең тамак төбеңне кытыклый. Аның шундый сәер хикмәте бар. Әмма бик шифалы хикмәт!

Юкә балыдай сары булмый ул. Чәчәкләр балы төсле дә көрән булмый. Карабодай балының төсе үзенчә. Тук булып тулган карабодайның үзе төслерәк кызгылт-көрән ул. Ә шифасы! Карабодай балы, табибларның раславынча, аз канлылыктан интегүчеләргә иң шифалы дәва инде!

Елы килгән еллардамы?! Карабодай балны бирәп тә карый инде. Шул ягы да уңай. Боткасы да тәмле, бик туклыклы, шифалы булганлыктан, дәүләт бу культураны хуҗалыклардан югары бәя белән ала. Карабодай — зур табыш китерә торган культура. Шунлыктан колхозлар-совхозлар аны зур мәйданнарда игәләр. Ә бал кортлары өчен карабодай кыры, алтын эзләүчеләр тарафыннан әлегә бер шурф та салынмаган чын клондайк*! Саф алтын ятмасы!

Әмма ләкин карабодай үзенә карата бик таләпчән культура. Ул чәчәккә утырган чорларда температура 24–26 градуслардан өстә булмасын. Җылылык төннәрен дә 14–16 градустан төшмәсен. Җилләр тынып торсын. Иссәләр дә, тик көньяктан, көнчыгыштан гына иссеннәр. Төннәрен, кичтән үк башлап, җылы яңгырлар явып торсыннар. Ә көндезен һава өстендәге күлмәгең тәнеңә ябышырдай, сыгып-сыгып алырдай тынчу булсын. Менә шул шартлары да килсә, карабодай бирәп тә күрсәтә инде балны. Андый елны умарта ояларына яңа кәрәзләрне куеп, бал белән тулганнарын аертып кына өлгер. Мондый елларны бал кортлары тотучылар, умартачылар гына баеп калмый. Бал дигән җиһанда башка көндәше булмаган затлы, шифалы ризык бөтен ил-халык өстәлен дә мулдан бизи.

Балчыларның, умарта кортларының бәхетеннән менә быел да ике атналар чамасы нәкъ менә шундый көннәр торды. Чияле тау ягыннан Газинур да бал тәпәннәрен мөлдерәмә тутырып кайтты. Хәзер сентябрь ахырлары, октябрь башлары. Ни эшкә алынсалар, шуңа җитез кызлары ярдәме белән Газинур умарталарын кышка әзерләп куйды. Чөнки тиздән салкын яңгырлар башлануы бар. Кортларны кышка да, оядагы артык рамнарны алып, тишек-тошык җирләрен ник томалап, җылытып хәзерләп куярга кирәк.

Ә бүген исә алтын көзнең җилсез, кояшлы, матур бер көне. Газинурныкылар, бөтен өй эчләре белән чыгып, алгы як бакча бәрәңгесен алалар. Әтиләренең кулында агач көрәк. Җире мамык түшәгәндәй йомшак. Газинур бәрәңгене агач көрәк белән алырга ярата. Агач көрәк аларны имгәтми, яраламый. Һәр төпне ачкан саен, һәркайсы куш йодрык хәтле сигез-тугыз сап-сары бәрәңгеләр як-якка тәгәрәшеп китәләр. Әле генә җылы ваннада коендырып бишегенә салган нарасыйдай киерелешеп яталар алар җир өстендә. Сөйләп тә торасы юк, эре бәрәңгеләрне казу үзе бер ләззәт бит ул. Һәр ачкан бер төбең үзенә бер хәзинә! Җылы кояш нурлары астында шундук җилли барганнарын Сәрия җиңгәй талчыбыктан матур итеп Газинур үзе үргән кәрҗиннәргә җыя бара. Кызлары аларын капчыкларга тутырып торалар. Нәни Сарбай да, бу ишегалдында үзенең бик кирәкле зат икәнен танып, апалары янында бутала. Апаларына булышырга, бәрәңге җыешырга да исәбе бар. Ләкин аңа ук әлегә башы җитеп бетми. Бүген аның да дөньясы күккә тигән. Ишегалды буйлап кая басканын белми чаба. Чапмаска! Аның ничек җитез чапканын апалары карап торалар бит.

Шулчак урам яктан койма аша ишегалдына кемдер гөрс итеп сикермәсенме? Карасалар, чү! Кем соң бу? Чатан түгелме? Чатан бит, шайтан димәсәң! Ә Чатан, койма аша сикергән хутка ук атылып килеп, Газинур абыйсына сарылды, аннары апаларын кочып чыкты. Урманда туып, мыскал педагогик

тәрбия алган кыргый бүре димәссең. Апаларын да кочып, аларның чыр килүләренә дә карамастан, борын очларыннан гына пәп итеп чыкканнан соң:

— Әйе! Бу мин игелексезегез әле! Гаҗәпләнмәгез! Кайттым да килдем! — дип, бәрәңгесе казылган йомшак җир өстенә сузылды. Ике алгы тәпие өстенә башын салып, хуҗаларын күзәтте. Алар ничек кабул итәрләр? Зур койрыгы белән шап-шоп итеп әледән-әле җиргә сугып ала. Бик җаваплы момент бит. Монысы күрешү шатлыгыннандыр инде. Хуҗаларының исән-сау булуларын күрептер, үзенең дә шушы нигезгә исән-имин кайтып керүенә сөенептер.

Аның янына апалары килеп иелделәр. Башыннан сыйпап иркәләргә керештеләр. Агач көрәге сабына таянып бер-ара торганнан соң, Чатан өстенә Газинур да килеп иелде. Башыннан сыйпады.

— Чын шайтан икәнсең! Үзләре җибәрмәгәннәрдер. Сизәм... Качкансыңдыр. Дезертир... Качтыңмыни? — диде, тавышында беркадәр кырыслык саклап. — Качакмы син?

— Качтым, качтым, Газинур абый. Яшермим, тоттым да качтым.

— Булдыргансың инде... Шундый күңелле җирдән, кая карама үз ишең, ни дип качтың инде?

— Ни дип качмыйм ди. Бер минут түзәр хәлем калмаганга. Ике колагым да ишеткәндә, ике күзем дә күргәндә, тәпиләрем йөгереп торганда, бөтен яшь гомеремне шул тимер читлектә уздырыйммы? Кешеләр әнә кыл диңгез уртасында утырган крепостьлардан качалар. «Индийская гробница» романын укыганың бардыр ич, агам? Аның герое диңгез уртасында утырган крепостьтан, ташкапчыктан кача. Роман анысы бер читтә торсын. Укымаган булсаң укырсың. Сез миннән җиңел котылдыгыз. Машина эчендәге тимер читлеккә утырттыгыз да куйдыгыз. Шуның белән оныткансыздыр да. Ә мин сезне сагынып, төннәр буе уйлап чыгам. Прәме өзелеп-өзелеп сезне сагына башладым. Әлеге ветеринар егет: «Акылдан шашмагансыңдыр бит, ни дип шулай улыйсың? Парктагы бар кош-кортның котын алып бетерәсең бит!» — дип, яныма кереп, камчы белән дә ярып чыкты.

Мин кичергән сагыну хисе сез — кешеләр аңлый торган халәт түгел ул. Мондый тирән хисләрне кичерергә сәләтле нечкә күңелне табигать безгә генә биргән бугай. Кирәк чакта рәхәтләнеп бер сөйләшергә, аңлашырга, хәтта талашырга сезнекедәй телләребез булмау бәрабәренәдер, бәлки.

Хөрмәтле Газинур агам, сездә яшәгән көннәрем минем тормышымдагы иң матур, иң бәхетле чорлар булган икән. Бу турыда мин читлеккә эләгү белән уйлана башладым. Сезнең белән аралашу миңа күп акыл бирде. Анда эләккәч, тирән үпкәм аша мин сезне бик-бик сагындым.

— Чү әле, чү! Син ни дип әле крута гына алып мине мактый башладың? Салпы якка салам кыстыруыңмы? Мине ишегалдыннан кумасын дипме? Яңадан мине кайткан җиремә озатмасын дипме? Кайткансың икән, молодец! Үзебез дә бик юксындык. Зверинецка тапшыруыбызга да үкенеп беттек. Үз ишләре арасында булыр, илләр гизәр, дөнья күрер дигәнием бит. Бер дә ошатмадыңмыни?

— Ошатмадым. Качтым. Качмаска! Ошатырдай, нигез корыр урынмы соң ул? Дөрес, ач та түгел, тук та түгел, бер күнеккәч, юк та түгел, дип, бераз яшәргә була анда. Башыңны дуракка салып. Дөньяны үз күзең белән танып белү өчен. Тормыш университетларының тулы программасын узу максаты белән. Башкаларның холкын өйрәнү, үзеңне дә таныту өчен.

Ләкин бу периодның иң озын периоды ике ай! Аннары яшәү рәвешендә кискен борылыш ясау кирәк. Юкса бетәсең. Әйтик, анда ни дип әле мин чиләнергә тиеш? Минем алдымда бер тамагымны ничек туйдыру проблемасы тормый. Мин бит цирктан списайт ителгән ветеран, теше төшкән, күзе сукырайган, йоны коелган, мөгезе сынган инвалид түгел. Гомерем буе шул тимер читлек эчендә кагаерга туган илен дошманга саткан, һәркем аңа җирәнеп караган җинаятьче дә түгел. «Качам!» дип хәл иттем. Һәм качтым.

— Качкансың. Яхшы булган. Монысын мин дә хуплыйм, Чатан.

— Качтым! Төкереп куйдым зверинецларына. Исемә төшсә, менә хәзер дә косасыларым килә.

— Ул чакта нишләргә булдың соң инде? Бездә калырга булсаң, шул... ни инде... Муеныңа тимер галстукны салмый булмас, — дип,Газинур Чатанны түшеннән сыйпавын белде.

— Күрмәгән, татымаган нәрсә түгел. Ул тимер галстук чәнчелеп китсенсәнә. Мин сезне ничек өзелеп сагынуымны тагын бер аңлатмак булам. Инглизләрнең бик танылган бер язучысы Джеймс Олдриджның бер чорда бик популяр булган романын укыганыгыз булгандыр бит?

— Әллә инде, — диде Газинур. — Син генә безнең бик укымышлылардан!

— Белмим. Ни арада барып укып өлгерәсеңдер?

— Укыдык. Без укыдык, — диештеләр кызлары.

Йөзенә кызыксыну билгесе чыгарып, Газинур да:

— Шуннан, шуннан? — дип куйды. — Ни-нәрсә дип язган Джеймс әфәнде?

— Шуннан, шуннан, — дип кабатлады Чатан. — Урыс Митрие артында чуаш авылы Шуман. Арт ягына утырган да рәхәтләнеп тау шуган.

— Ай-яй! Читлектә утыруың бушка китмәгән. Тәмам тел бистәсенә әйләнгәнсең бит. Владимир Жириновскийның үзен уздырасың.

— Әйләнмәссең, бар. Анда утыруның бер тәүлеге бер елга тиң. Читлекнең бер ягында макаки маймыллары. Әле уйныйлар, әле чыр-чу килеп талашалар. Аннары берсе өстеннән берсе миңа

зарланырга тотыналар. Тәмам колагымны тондырып бетерәләр. Икенче ягымда тәвә кошы. Үз-үзенә шаккаткан, бер дә галәмәт эре кыяфәтле бер җан. Җитмәсә, әләкче. Үзе очлы, үзе озын томшыгын минем читлеккә тыга да тотына барысы өстеннән зарланырга, әләкләргә, түз генә. Янәсе, бу паркта бер генә дә юньле зат юк, барысы да үз-үзләрен генә сөйгән чын хайваннар. Ишегалдына прогулкага чыккан җиреннән ике бөкреле карт дөя аның йөзенә төкергән. Бу хурлыкка тәвә кошы башы белән аңа ничек түзәргә? Ак аю аңа йодрык янаган. Биле катудан аякларына да баса алмаган карт арыслан, аны күргәч, «эх, сине тотып ботарласаң икән бер» дип янаган.

Шушы мохиттә, хуҗам, булмас җиреңнән тел бистәсенә әвереләсең. Мин бит сезгә өзелеп сагынуымның ни рәвешле булуын аңлатмакчы идем. Әлеге шул инглиз язучысы Д.Олдридж романында Англиянең бик бай бер кешесе алардан ун меңнәрчә чакрымнар ерактагы Монголиягә барып чыга. Менә шушы сәяхәтче агайны монгол хуҗалар меңнәрчә баш бахбайлар койрык чәнчеп көтүләп йөргән далага алып чыгалар. Кунакның күзе көтүдәге бер айгырга төшә. Шул айгырны аңа сатуларын сорый. Зур кунакның теләгән үтәү хуҗалар өчен дәрәҗә генә. Әлеге агай шушы айгырны, пароходка утыртып, Англиягә алып кайта. Айгырның исә көтүдә өзелеп сөйгән биясе кала. Ә кешеләр соң шуның белән хисаплашып торалармы? Аералар да алып китәләр. Англия җиренә аяк басу белән әлеге айгырның күңелен сагыш баса. Өзелеп биясен сагына башлый. Ашаудан, эчүдән кала. Ахыр чиктә бичара тота да кача. Монголиясенә, сөйгәне янына кайтырга чыга. Кулында картасы да, компасы да юк. Атлаган саен зур-зур шәһәрләр, шахталар, заводлар булган Англияне кичеп, диңгез ярына килеп чыга. Алда Ла-Манш бугазы. Аны кичәргә кирәк. Айгырны Европа җиренә күчерү өчен берәү дә алдан ук паром әзерләп куймаган. Туган илен, үзе үскән далаларын сагыну хисе аңарда шулхәтле көчле, ул, ике дә уйлап тормый, берсе өстенә берсе мәкерле дулкыннар сикерешкән диңгезгә кереп китә. Исән-имин калып, Европа җиренә чыгып баса. Германия биләмәләренә килеп керә. Анда да атлаган саен хәрби полигоннар. Берсендә яңа танкларны сыныйлар, икенчесендә — реактив снарядлар белән ата торган яңа тупларны. Берсендә нәкъ менә туплар сынаган вакытка туры килеп, ут астында кала, ныклык яралана. Ә сагыну хисе барыннан көчле. Унбиш көннәр чамасы бер чокыр төбендә ятып, бичара айгыр үзен-үзе дәвалый... Сагыну хисен басардай көч бармы соң ул җирдә? — дип сорап куйды Чатан. Үзе үк җавабын да бирде: — Айгырыбыз, чикне бозып, элеккеге СССР җирләренә килеп керә. Җир шарындагы 147 миллион дүрткел чакрым коры җирнең 22 миллион дүрткел чакрымы СССРныкы. Бернинди транспортсыз, җәяүләп кенә шушы араны узып кара син! Туган иленә ашыгучы әлеге кыю җан, Совет-Монголия чиген дә тупас бозып, үз даласына кайтып керә. Көтүен эзләп таба. Ике ел буена аны күңеленнән бер минутка да чыгармаган биясен коча. Өзелеп сагынганда ара ераклыгы да берни тормый. Мин үзем дә сезгә бик күп җирләр кичеп кайттым. Кешеләр: «Менә без кемнәр! Без — Кешеләр! Безнең кулыбыздан килмәгән бер эш юк!» — дип борыннарын күтәреп йөри торгач, тормыш итү өчен бик кирәкле сыйфатларын, бөтенләй таныш булмаган җирдә дә дөрес ориентация ясау сизгерлеген җуйганнар, югалтканнар. Ә без аларны сакладык. Туган иленә кайтырга карта да, компас та кирәкми. Кирәкле юнәлешен дә чамалыйсың, юлын-сукмагын да табасың.

— Карап, сүзләреңә колак салып тыңлап торам. Белмәгән нәрсәң юк синең. Бу бүре егете әллә читтән торып кына булса да Франциянең Сорбонна, Англиянең Оксфорд университетларын тәмамлаганмы, бакалавр гыйльми дәрәҗәсе алганмы диярсең, — дип бүлдерде аны Газинур. — Сөйләгәннәреңнең бу кадәресен кайдан белдең, кемнән ишеттең?

— Ничек белмим инде? Кешеләрнең кайберләре безне бөтенләй томана санамакчылар. Янәсе, без, урман халкы, берни белмибез. Урман үзе безгә университет! Агач төбе саен китапханә бит безнең анда! Иренмә генә. Укы, гыйлем ал, башыңа сеңдер, башкаларны да өйрәт. Шунсыз ярамый урманда. Балыклар булып алар да, дөньяга вак кына уылдыклар булып туган сәгатьләреннән үк, үзләренең башлангыч мәктәпләренә йөри башлыйлар. Өйрәнергә, мәктәпкә йөрергә теләмәгәне озак яшәми, кемгәдер татлы калҗа булу язмышы көтә аны.

— Сүзегез озаккарак сузылды түгелме соң? — дип, Сәрия апа килеп җитте. — И-и, балакаем! И-и, җанашым! Туган-үскән җиреңә кайттыңмы, күгәрченкәем! Дөрес иткәнсең бик! Илдә чыпчык үлми.

Сәрия апасы, бар эшен ташлап, өйгә кереп китте. Аннан бер табак аш күтәреп чыкты. Тирән эчле тәлинкәгә салып, аны Чатан алдына куйды:

— Аша, балам!

Чатан этикет-мазар саклап тормады. Ул чыннан да ач бүредәй ач иде бугай. Койрыгын болгый-болгый рәхмәтен әйтеп, Сәрия апасының токмач шулпасын шупырырга кереште.

— Безнең ишегалдына кайтып басканчы нинди генә нужалар күреп бетермәгәндер инде бу балакай, җанашым! Эзверинис дидек тә ah иттек. Бер белмәгән, күрмәгән ятлар кулына бирдек тә җибәрдек. Анда тәлинкәнең читенә генә салып ашаталар, күрәсең. Әнә бит, тере җаны гына калган. Кабыргаларын бармак белән санап чыгарлык, — дип, бот чабып гажәпкә калды Сәрия апа. — Яшәгән көе үзебездә дә яшәр иде әле, юкка читкә озаттык, дип, төннәр буе уйланып, борчылып яттым. Елап алган чакларым да булды. Кайтыр! Кайтыр! Түзмәс! Бүре баласы бит ул! Берәр җаен табар да качар дип көттем. Менә бит,

мин уйлаган рас килде. Үзебезгә кайтып бик дөрес эшләгәнсең, Чатан балакай, — дип, Сәрия апа янә елап җибәрде.

— Ярар инде, әнисе. Күзләрең юеш урындамы соң синең? Берни булса, шыңшырга гына торасың, — дип, Газинур аны юатмак булды. — Кайткан. Исән-сау. Тагын ни кирәк? Әнә нинди тәмле аш чыгардың.

Әле генә ишегалдында койрык чәнчеп уйнап йөргән Сарбай Чатанны күреп алу белән актан астына кереп посты. Аннан аны өстерәп чыгарыр хәл юк.

Чатан лаеш шулпасын да байтак шупырган, ахры. Бер колагы шәлперәйгән. Аны тешләп алып, өзеп үк ташламакчы булганнармы? Арт аягына да бераз аксый төшә. Сыртында кан саркып торган ярасы бар.

— Беләм, беләм, балакаем! Ирек ул берәүгә дә җиңел бирелми. Аны ташаяк тәлинкәгә салып алдыңа китереп куймыйлар. Качып, азатлык яулап бик дөрес эшләгәнсең. Төче коймак бик ярата идең бит. Хәзер керәм дә туглыйм. Төче коймак белән сыйлармын үзеңне. Без хыянәтчеләрне гафу иткәнең, янәдән үзебезгә кайтканың өчен, җанашым! — дип, Сәрия апа бер көйгә елавын белде.

— Әниебез, хәзер үк туктамасаң, без дә кушылабыз. Чатан исән-сау. Кайтты. Тукта елавыңнан, — дип, кызлары юатмак булалар. Ә бераз елап алырга үзләре дә каршы түгел.

— «Өенә кайтканның ояты юк» дигән китап. Зверинецтагы коллыктан котылып та дөрес эшләгәнсең. Туры безгә кайтып керүеңә дә кул куям, — дип тамагын кырды Газинур абыйсы. — Әмма, дустым, мин сиңа алтын таулары ышандырмыйм. Муенымда гел тимер галстук, дип, соңыннан зарланма. Сине янәдән чылбырга утыртмый булмый. Түзәрсең. Чакыртып кайтармадым... Тыңлаучан булсаң, алдыңнан җылы аш өзелмәс.

Кызлары:

— Төче коймак, Чатан, төче коймак! — дип куәтләделәр әтиләренең сүзен.

Ашап, тәлинкәсен ялап куйганнан соң, Газинур аны буш торган оясы алдына җитәкләде. Чатанда бүреләр затына гына хас наянлык, юмор хисе дә җитәрлек. Муенына «тимер галстук» таккан чакта, «менә шушы җиреннән генә капсам, өзәм дә алам бит инде» дигән сымак, хуҗасының кул аркасын шаярып-шаярып кына ялап-ялап та алгалады.

Газинур да, аның шаяруын күреп:

— Менә күрдеңме моны! Шаярып кына кара! Ике каш араңа менә шушы йодрык белән берәрне бирсәм, ике күзеңнән утлар күренер, — дип, йодрык янап ала. — Ә Сарбайны кыерсытасы булма! Матри у меня!

— Сезнең бәрәңге төя торган тукмак хәтле генә әнчегегез белән булышасым гына калганые бүре егете башым белән! — дип, Чатан оясы эченә үк кереп китте. — Мине ул хәтле кемгә саныйсыз?

Сәрия апасының чат токмач ашларын иртәсен дә, кичен дә берәр чуен шупырып, апаларының прәннек-печеньеләре белән генә сыйланып, Чатан берәр айдан танымаслык булып матурайды. Бу ишегалдына күтәрәмгә калган хәлендә кайтып керүен онытты. Аннары аңарда бу ишегалдына күз-колак булу гына түгел, ә чын хуҗа булу хисе уянды шикелле. Бүреләр хәтта урман тикле урманны да үз территорияләренә, үз көтүлекләренә бүләләр. Аны бик сизгер рәвештә саклыйлар. Чит бүре көтүлегенә аяк басасың икән, үзеңә үпкәлә. Газинур абыйсы утары Чатан көтүлеге. Кемнең кем булуына карамастан, кергән-чыкканга усал ырылдый башлады. Йөрмәгез, янәсе. Бәйдән ычкынмак булып әрле-бирле бәрелә. Мәгәр ычкына калсам, миһербан көтмәгез, дип, ап-ачык текст белән яный. Кичләрен танавын айга төбәп, ямьсез итеп улап-улап та ала.

Тормыш дигәнең тын гына аккан су белән бер. Газинурның олы кызы Гөлшат, сигезенче классны гел бишле билгеләренә генә тәмамлап, Бөгелмәгә барып, фельдшер-акушерлар чыгара торган колледжга кереп кайтты. Бу көздән шунда торып укый. Өйләренә ял көнне генә кайта. Гөлшат апасы кайткан көнне Чатанга да бәйрәм. Чөнки апалары аны өйләре артындагы болынлыкка прогулкага алып чыгалар. Андый чакта Чатан болындагы үләннәр, чәчәкләр арасыннан тик торганда гына котырып китүдән, ашказаны-эчәк юлларын төрле хәшәрәт суалчан-кортлар басудан саклый торган үләннәр табып чемченә. Бу үләннәрне танырга аны кем өйрәткәндер, монысын ул үзе дә әйтә алмый. Әмма кайсы үләннең йә чәчәкнең нинди авырудан шифалы икәнен белә. Шулай үзеңне-үзең дәваламасаң, айлар буе бәйдә утырып, көтмәгәндә генә акылдан шашып куюың да бар. Эчәк юлларына да төрле хәшәрәтләр ояларга гына торалар бит алар.

Айгөл апасы сәнгать мәктәбенә йөри. Төрле кошлар, чыпчыклар, кыргый җанварлар сурәтләре ясарга бик оста ул. Чатанның әллә ничә рәсемен ясап, аның үзенә дә күрсәткәне бар. Яраткан кешеләренә карата Чатан комплиментлар әйтергә дә булдыра. Айгөл апасының рәсемнәрен:

— Нәкъ үземне ясагансың, коеп куйгансың бит! — дип мактый.

Айгөл ясаган кош-корт сурәтләрен укытучылары да килештерәләр. Зур үскәч бу бала бик танылган рәссам булыр әле, диләр. Ә үзе Айгөл, мин зур үскәч ветеринария табибы булам, ди. Барча кош-корт, җәнлекләрнең, хәтта ерткыч җанварларның да доктор Айболитлары булам, ә Чатан минем ассистентым булачак, ди.

— Урман аланында аларны дәвалый торган поликлиника ачарбыз. Әгәр дә урман ияләрен бүгеннән үк дәваларга керешмәсәк, берәр куркыныч инфекциядән аларның бөтенләй кырылып бетүләре мөмкин. Чөнки экологик шартлар урман-кырларыбызда көннән-көн начарлана бара, — дип, үз-үзенә нык ышанып сөйли ул. — Берләре каурый канатлы, икенчеләре дүрт тәпиле дусларыбыз кырылып бетсә, безгә, кешеләргә, җирдә бик күңелсез булачак. Безгә иксез-чиксез галәмдә япа-ялгыз калу катастрофасы янаячак. Мин артка чигенмәслек итеп хәл иттем, доктор Айболит булачакмын. Ә Чатан — минем ассистентым. Шулаймы, Чатан?

Айгөл апасы авызыннан чыккан бар сүзне аңлап тора Чатан. Апасының сүзләрен хуплап, оясы түбәсендә тыпыр-тыпыр биеп тә алды.

* * *

Газинурларның өе шәһәр читендә үк, кечерәк кенә, чыпчыкка да тездән, әмма бик ямьле инеш буенда. Инешнең теге як ярын бөдрә таллар, елак өянкеләр, зелпе, карамалар бизи. Шомырт, кара карлыган күп була. Халык теленә «Пошилар усаклыгы» дип кергән урман да шушы тирәләрдән үк башлана. Бу урман бик ераклarга ук сузылып, чалгыңны сызгыртып печән чабарлык, очлары күккә ашкан кибәннәр куярлык киң аланнары, акланнары, чуртан-сазаннарга, беләк буе бәртәс-кызылканатларга бай, кыштыр-кыштыр камышлы тын күлләре белән мул сулы Кама ярларына ук барып тоташа. Кош-корт, төрле җәнлекләр, кама, сусар, куян-төлке, кабан дуңгызлары, кыр кәҗәсе, поши, бүре кебек җанварлар да җитәрлек аның киң, иркен куенында.

Бер итәге белән шәһәргә терәлеп үк торган Пошилар усаклыгында җәен җир җиләге, көзләрен ак гөмбә күп була. Менә шул урманлыкта бик сәер хәлләр була башлады бит әле. Җиләк җыярга менүчеләрне, гөмбәчеләрне, бер төркемгә берләшкән егермеләп-утызлап эт-маэмай өере, көтмәгәндә генә өсләренә килеп чыгып, котларын алып өркетә башладылар. Үзләре генә белгән иң җиләкле аланга менгән ике карчыкны чүт үтереп таламаганнар. Җырлый-җырлый гөмбә җыеп йөргән биш кызчыкны, көтмәгәндә генә чорнап алып, өсләренә ыргыла-ыргыла өреп, бик нык куркытканнар. Ике малай урманга өч көн көтүдән кайтмаган бозауларын эзләп менгән булганнар. Качкалак бозауларын каенлыкта ботарланган килеш тапканнар. Әлеге азгын этләр бу малайларның үзләрен дә чак кына ботарлап ташламаганнар. Ярый әле букчаларында үзләре белән алган ипи-тозлары, колбасалары булган. Шуларны бирeп кенә котылганнар, исән калганнар бугай.

Халык телендә хәзер бар сүз, базарда да, теш врачына чиратта да, урманда оешкан җинаятьчел этләр төркеме турында гына. Алар урманда гына ятып калмыйлар, төннәрен өерләре белән шәһәргә дә төшәләр икән. Күп катлы йортларның ишегалларындагы чүп контейнерлары тирәсендә бер сынык каткан ипи кисәге өчен бер-берсенең бугазларын чәйнәп, сугышып та китәләр икән. Шундый чакта чүп чыгаручы туры килсә, аның өстенә дә ыргылалар икән. Урманнан төшкән азгын этләр талау аркасында инде ничә кеше шифаханәгә эләккән, ди. Коточкыч хәл бит бу.

Халык вәкилләре шәһәр башлыкларына барганнар. Бу юлбасарларга карата кискен, нәтиҗәле чаралар күрүне сораганнар. Шәһәр сунарчылар җәмгыятенең чын профессиональ ун әгъзасы, ике көпшәле мылтыкларын бүреләргә генә ата торган эре ядрәләр белән корып, усаклыкларны да, гел имән, гел юкә генә үскән кварталларны да айкап чыкканнар. Ник бер маэмайны очратсыннар.

Ничек инде алай җиңел генә очратсыннар? Хәзер азгын, кансыз ерткычларга әверелгән, әмма әле кайчан гына иң матур, иң кадерле көчекләр булып, иркә-наз тоеп, кешеләрнең кулында гына түгел, җылы куеннарында үскән җаннар бит алар. Кешеләрнең башларындагы уй-ниятләрен аларның үзләреннән алда беләләр. Авызларыннан утлы көлтә бөркегән ике көпшәле мылтыкларны да иң эре ядрәләр белән нинди максатларда коруларын бик ерактан торып ук чамалыйлар.

Шундый бер җинаятьчел, кешеләргә бик үчле этләр шайкасының башлыгы Полкан кушаматлы бер дигән немец овчаркасы. Философия факультетын тәмамлаган диярсең. Бик башлы, бик зиһенле. Бик сизгер, үзеннән башка беркемгә ышанмый, кырыс характерлы, гаять көчле эт егете. Бу нәсел маэмайлары берәрсен үз итсәләр, яратсалар, мәңгегә яраталар. Хыянәтне, аерылышуны бик авыр кичерәләр. Нинди дә булса сәбәпләр аркасында аерылышырга туры килсә, яраткан хуҗаларын оныта алмый интегәләр, авыруга сабышалар. Әгәр инде хуҗалары үлеп китсә, алар да аның каберенә барып үләләр. Кабер өстенә барып яталар да шуннан кайтмыйлар. Шундый очраклар чутсыз күп. Әдәбиятта да, тарихта да. Бу нәсел егетләре дрессировкага җиңел бирелеләр, хуҗасының теләген күз карашыннан аңлый башлыйлар. Тәртип яраталар. Армиядә, милициягә бик теләп хезмәт итәләр. Андый овчаркаларның күкрәкләре көмеш медальләр белән тулы була. Ә менә Полканның кешеләргә карата шәхсән тирән үпкәсе, үче, хәтта нәфрәте бар. Чөнки алар аңа беркайчан кичерә алмаслык итеп хыянәт иттеләр.

Полканны хуҗасы хәрби хезмәт өчен махсус үстерә торган питомниктан алып кайтты. Ике яшьлек улы Русланга туган көненә тере бүләк итеп. Хуҗаның фатиры бер генә бүлмәле булса да, аңа да җылы урын таптылар. Полкан коридорда, йомшак палас өстендә генә йоклап үсте. Ике яшьлек матур малай

Руслан аны кулыннан да төшермәде. Әүмәкләшеп туйганчы уйныйлар да, шунда коридорда ук кочаклашып йоклап та китәләр.

Өч ел яшәде Полкан хуҗаларында. Русланга биш яшь булды. Полкан — Русланны, ә Руслан аны бик яратты. Аңа ашларны да фарфор тәлинкәләргә генә салып бирәләр иде. Өч ел эчендә Полкан үзе дә бер дигән маэмай егете булып үсеп җитте. Хуҗасы, офицер кеше, аны төрле командалар үтәргә өйрәтте. Аларны үзләштерә бару Полканга кыен булмады.

Әмма көннәрдән бер көнне хуҗасы белән хуҗабикәсе, берәүләрдән кунактан кайткач, бик нык талашып киттеләр. Аннары һәр кичне бер дә юктан гына тавышлана башладылар. Бер-берләре өстенә тәлинкәләр җибәреп сугышкан, елашкан кичләре күбәйде. Хуҗалары тыныша алмадылар. Русланны, Полканның җан дустын, каяндыр кайтып, бик ерakka дәү этисе алып китте. Шунда «әйдә» дисә, Полкан да киткән булыр иде. Әйтмәде шул. Әлеге матур, ягымлы малай Руслан да Полканны бик сагына булыр.

Ә хуҗасы фатирына бөтенләй кайтмый башлады. Хуҗабикәсе дә Полкан турында онытты. Прогулкаларга да алып чыкмый, юньләп ашатмый да. Ә беркөнне аны урамга ук куып чыгарды. Мондый хәлне һич көтмәгәние ул. Полкан бөтенләй югалып калды. Хуҗабикәсенең ишеген тырный-тырный, шыңшып кире кертүен сорады. «Мин бит беркемне дә белмим, кая барыйм, кемгә сыеныйм, кайда куныйм?!» дип ялварды. Әле дә ярый ишегалларында чүп контейнерлары бар иде. Беренче кичне подъездда кунгач, Полкан тамагын шунда чыгып ялгады. Әмма тормыш законнары монда да кырыс икән. Чүплеккә күптән инде сыңар күзле бик усал бер маэмай хуҗа. Бирегә ул ят этләрне, хәтта күрше урамнарның ач бурзайларын да якын китерми. Хәтта шушы чүплектә дә кешеләр арасында яшәгән кебек җинаятьче мафия структурасы. Биредә дә рэкетирлык галәмәте. Әлеге циклоп, беренче чыккан шәпкә, Полканны да контейнерлар тирәсенә җибәрмәскә маташты. Намус саклап кыяр-кыймас торсаң ач каласың. Монда джунгли законнары өстенлек итә. Көчле, гайрәтле генә хаклы. Контейнерларның хуҗасын, тәмам шомарып, этләшеп беткән маэмайны, сыртыннан кабып, бер читкә чөеп җибәрми булмады Полканга. Аны шунда ук шул тирәдәге барча карендәшләре ихтирам итә башладылар. Әйе, Пошилар усаклыгындагы төркемгә баш булганчы, аңа ай-һай күпне күрергә, күп сынаулар узарга туры килде.

Өердәге һәр эт-маэмайның язмышын тыңласаң кычкырып еларлык. Төркемдәге Полканның ышанычлы дусты сенбернарлар нәселеннән, Казбек атлы эт егетенең дә биографиясе шундый ук. Бу игелекле, мактаулы нәселне Швейцариянең Альп таулары итәгенә урнашкан Сен-Бернар монастыре монахлары чыгарганнар. Тауларда йөрергә, кыя башларына менәргә яраткан сәяхәтчеләргә ышанычлы юлдаш, ярдәмчеләр итеп. Сенбернарлар эреләр, физик яктан бик көчеләр. Искитмәле акыллылар, үткер зиһенлеләр. Карап торырга да бик матурлар. Халыкара күргәзмәләрдә еш кына призлы урыннарны алып киләләр.

Казбек та бик бай, респектабельле гаиләдә үсә. Хуҗасы белән иномаркаларда гына йөри. Урман яланнарына, түгәрәк күл буйларына пикникка, шашлыкка чыккан чакларын сагынып исенә төшерә ул. Шашлыкның иң тәмле калҗалары белән хуҗасы иң башта аны сыйлый иде. Әллә ул артык урлашкан, әллә бурычка баткан. Шундый пикникларның берсендә хуҗасы тотты да атылды. О-ой, мондый коточкыч күренешне бүтән күрергә язмасын. Икенче көнне үк ниндидер хәрби киемле кешеләр килеп, аларны особняклариннан куып чыгардылар. Үзләренә сыеныр урыннары калмаган улларында Казбек кайгысымы соң? Алай да мине урамда калдырмаслар, үзләре барып баш төрткән җирләренә мине дә сыйдырырлар, дип көткәние Казбек. Чөнки хуҗасының ике улы Рубис белән Рубинны бик ярата иде ул. Алар исә Казбек турында уйлап та карамадылар. Ул урамда калды. Чүплектә тамак туйдыручы урам этләре арасына барып кушылды. Кешеләргә карата үпкәсе чиксез аның.

Эт-маэмайлар арасында дворяннар дәрәҗәсендә саналган, дөньяга атаклы һәм мәшһүр пекинслар нәселеннән булган Шурочка кушаматлы кыска аяклы, колакчын бүрек хәтле генә, матур шома йонлы әнкә этне өердә яратмаган җан юктыр. Ул һәрчак шат күңелле. Һәркем белән тиз дуслаша. Аңа ашарга да күпме генә кирәк. Шырпы тартмасы хәтле ак ипи эләксә, шуның белән көне буе тук йөри. Менә аның биографиясе дә утырып еларлык бер трагедия. Шурочканың хуҗабикәсе бик танылган артистка булган, аны кулыннан төшермәгән, куенында гына йөрткән. Алар киенеп-бизәнеп театрларга, чакырулы банкетларга йөргәннәр. Хуҗабикәсе үзенә бүләк иткән иң кыйммәтле француз хушбуйларын башта Шурочкага сипкән.

— Шурочка! Син минем бәхет талисманым! Сәхнәдә ирешкән уңышларымда синең дә өлешең зур, җаным! Син шуны үзең беләсеңме, гүзәлем? — дип, аны иркәли, сөя торган булган.

Көннәрдән бер көнне аны кинәттән генә «ашыгыч ярдәм» машинасында больницага алып китәләр. Шул китүдән ул кайтмады. Ничә көннәр ач торып, хуҗабикәсен сагынып елап утырган Шурочканы, артистлар тулай торагының комендантты, авызыннан гел аракы исе килеп торган юан маржа, швабра белән бәргәләп, урамга куып чыгарды. Үз тырнакларын кискәндә, чистартканда, хуҗабикәсе Шурочканың тырнакларын да кисә, төзәтә иде. Моңарчы җылы куенда гына йоклап, иң тәмле шоколадлар белән генә тукланып яшәгән Шурочка япа-ялгызы урамда кала. Кая барсын, кемгә

сыенсын? Ул кемгә хаҗәт? Әле дә ярады, алар торагы ишегалдындагы чүплек хуҗасы Рекска юлыкты. Рекс аны үз канаты астына алды, урманга да ул алып килде.

Кыска йонлы, таксалар нәселеннән булган Майонез кушаматлы эт егетедәй батыр йөрәкле маэмайлар гомумән бик сирәк очрыйлар. Хуҗасы ярдан торып аткан каз-үрдәк артыннан ул, кирәксә, Кара диңгез уртасына йөзеп керә. Суы салкын дип тормый, төпсез тирәлектән дә курыкмый. Өннәрендә качып яткан әрлән-йомраннарны, бурсыкларны да бик оста казып чыгара.

Ә менә рус алмачуар чабыш этләре нәселеннән булган озын сыйраклы Динго үр куяны куарга бик оста. Озын колакның эзенә бер басса, тегесе аннан җәядән аткан ук булып качарга тырышса да, Динго аны тотмый калмый. Майонез, Динго да бер дигән ау этләре. Питомникларда аларның бәяләре дә бик кыйбаттан йөри. Майонезның хуҗасы бик давыллы бер кичтә, аткан үрдәге артыннан кереп, көймәсе белән суга капланды. Майонез аны коткарырга бик тырышып карады, булдыра алмады. Хуҗасы нык исерек иде шул. Дингоның хуҗасы, куян атып кайтканда, юл һәлакәтенә очрап һәлак булды. Ул да исерек иде шул. Урман юлын калдырып, тип-тигез асфальтка чыккач, каршы килгән машина белән маңгайга-маңгай бәрелештеләр.

Чио-Чио-сан кушаматлы ак пудель — Полкан төркемендәге әнкә этләрнең иң яше, иң матуры. Иң-иң дәрәҗәле дворяннар нәселеннән булган бер дигән эт егетләренең дә күзләрен яндырырлык итеп үзен тота белә. Аның игътибарын яулау өчен, көтүдә һәр кичне диярлек үзара талашулар, хәтта кан чыгарып сугышулар да булып ала. Ә Чио-Чио-сан үзен тормыш юлында ул юлыккан бүтән мәңге кабатланмас чын мәхәббәт корбаны дип саный. Алар бу якларга күчмә цирк белән килеп чыгалар. Чио-Чио-сан циркта иң оригиналь номерлар белән чыгыш ясаучы артистка санала. Аның чыгышларын аеруча балалар бик яраталар. Чио-Чио-санны цирк башлыклары да бик ихтирам итәләр. Бер шәһәрдән икенче җиргә күченгән чакта да аны аерым, төбенә йомшак мендәрләр салган бик ипле кәрҗиннәргә салып кына йөртәләр. Шулай дан, дәрәҗә белән яшәп ятканда кирәк бит шундый бәхетсезлеккә абынырга. Май айлары, табигатьнең шау чәчәккә күмелгән чорлары. Дрессировщицалары мадам Наталья аларны бераз саф һава суларга прогулкага алып чыккан җирдән Чио-Чио-санның күзе бер урам этенә төште. Төште дә ah итте. Тегесе аны үзе белән китәргә дәште, монысы иярде дә китте. Дрессировщицасы артыннан ни йөгереп чакырса да, Чио-Чио-сан борылып та карамады. Күрәчәге булгандыр инде.

Мәхәббәт шундый нәрсә ул, каһәр. Аңа бер юлыксаң, тиз генә айнырмын, котылырмын димә. Күз яшьләрен сөртеп искә ала хәзер Чио-Чио-сан ул көннәрен. Атна-ун көннәр узгач, чын мәхәббәт сөременнән бераз айнып алар чыгыш ясаган культура сарае төбенә килсә, цирклары бу тарафлардан инде күптән киткән. Ак пудель Чио-Чио-санның бер күрүдә башын җуеп гашыйк булган әлеге эт егете дә яшәр почмагы да булмаган бер җилбәзәк булып чыкты. Иң оригиналь номерлар башкаручы цирк артисткасына карата булган кайнар мәхәббәте дә тиз суынды. Чио-Чио-сан тормышына ничек дуамал килеп керсә, шулай дуамал юкка да чыкты.

Моңарчы сәхнә алкышлары белән куанып яшәгән ак пудельгә хәзер нишләргә? Кая барырга? Зинһар, бер сынык ипи кисәге бирә күрегез, дип, кем алдына барып тез чүгәргә, ятарга? Җитмәсә, авырлы. Бәбәйләргә җыена. Ул көннәрдә төнен дә, көнен дә кергән-чыкканны этләрчә койрык болгап сәламләп ресторан төбендә чуалды. Киерелеп кикерерлек тук булмаса да, ач та булмады. Урамның теге ягындагы биш катлы йортның подвалына төшеп бәбәйләде. Аның берсеннән-берсе матур, түп-түгәрәк балаларын шул ишегалды малайлары күзләре ачылганчы ук алып та бетерделәр. Полкан төркеменә Чио-Чио-сан менә шулай килеп кушылды.

Әлеге төркемдә һәр кардәшенә тирән ихтирамлы, бик сабыр һәм тыныч холыклы, коллилар нәселеннән булган Беркут кушаматлы эт егете дә бар иде. Бу нәселне безнең яклардан бик ераста, Шотландия дигән илдә сарык көтүләрен көтү өчен көтүчеләргә ышанычлы ярдәмчеләр итеп чыгарганнар. Кирәксә, бүре дигән юлбасар белән бугазга-бугаз килергә дә куркып тормыйлар алар. Әмма бик йомшак холыклылар. Коллилар гаиләдә яшәргә, бәбәй бишеге тирбәтергә, балалар белән бакчада уйнарга, аларны паркларда озата йөрергә яраталар. Балаңны коллига ышанып чыгарсаң, бер дә борчылма: ул аны машина юлына да чыгармас, төртеп тә екмас, чит-ят кеше кулына да бирмәс.

Бу нәсел вәкилләре Россиягә моннан күп еллар элек китерелгән булсалар да, яссы тау битләрендә иркенләп сарык көтүләре көтү инстинкты аларда бүген дә сакланган. Әлеге, беренче карашка ук беркатлы Беркут та «әгәр берәр яхшырак хуҗа кулына юлыксам, аның сарыкларын гына көтәрием. И-и, сарык көтүнең рәхәтлекләре аның. Тауларда һәрчак саф һава. Сарыкларны аларны кигәвен-мазар борчымый. Хуҗаң үзе ни ашаса, сиңа да шуны бирә. Авызың майлы сөяктән өзелми. Булган хуҗа кулына эләксәм, аның сарыкларын гына көтәрием» дигән өмет белән яши. Колли — бик әдәпле зат. Тере кошкортка беренче булып барып ябышмый. Күбрәк аяк астында тапканы, башкалардан калган белән ризыклана. Кыерсытылганнарны яклый, үз канаты астына ала. Төркемдәгеләрнең һәркайсына матур, җылы сүз таба, юата.

Полканның полкы ишәйгәннән-ишәя. Урманда ятып кына тамак туймый. Җәен ярый әле, бер чыкмаса, бер җае чыга. Үләксәләр дә очрап тора. Колхозлар тиреслекләренә үле туган бозау, дуңгыз балаларын түгеп торалар. Ә менә кышын бер тамагыңны туйдыру гаять кыенлаша. Авыл агайларының

абзарларына, колхозларның сыер-сарык фермаларына да һөҗүм иткән чаклар була. Полканның үз җилкәсендә татыганы булды: ачлык коточкыч халәт ул. Өзелеп-өзелеп ашыйсың килү бар оятыңны качыра. Андый чакны үзеңне бернинди җинаять алдында тыеп тора алмыйсың. Ул шунысын да сизә. Ишәйделәр бит бик. Кешеләр аларга һаман да түзеп тормаслар. Берәр көнне, көтмәгәндә генә килеп чыгып, бөтен урманны чорнап алып, облава ясарлар. Шарт та шорт мылтык атканнан бөтен урман эче дары исенә күмелер. Аның төркемендәге күп эт егетләренә дөнья белән саубуллашырга туры килмәгәе.

Полканның ишеткәне бар: Урал дигән якларда, имеш, тормыш иркенрәк икән. Ул якларда урманнар кош-корт, җәнлекләр белән тулы икән. Үз төркемен шул якларга алып китмәкче иде. Әмма берсе дә аңа иярергә теләмәде. Берсенең дә туган-үскән җирләреннән күз күрмәгән, колак ишетмәгән якларга китәсе килмәде. Төркемдәге маэмайларның күңелендә «кем белгән, минем язмышым, бәлкем, үзебезнең шушы җирдә үк җайланып, көйләнеп китәр әле» дигән өмет яши иде.

Төркемдәге әнкә этләр арасында чибәркәйнең чибәре Чио-чио-санның да сүзе үтемле. Бу яклардан китүгә ул аеруча дүрт аягы белән каршы булды.

— Мин үзебезнең цирк труппасының иң күренекле артистларыннан идем бит. Мине хуҗам бик сагынадыр. Түзмәс, мине эзләп, алар бу якларга янә килеп чыгарлар. Мин циркка кайтырмын. Тамашачыларыбызны яңадан-яңа оригиналь номерлар белән шатландырырмын. Мине цирк сәхнәсе көтә! Менә күрерсез, мин анда янәдән чыгышлар ясаячакмын, — дип сөйләп җибәрә. Төркемдәгеләрнең барысы да Чио-Чио-сан чибәркәйнең якты хыялларының тормышка ашуын телиләр.

Ачлык дигән коточкыч халәтне бу төркемдәге барча маэмайларның да татыганы бар. Үз-үзеңне, нинәрсә кылганыңны белмәслек хәлгә китерә бит ул бу халәт. Менә кичә дә, усаллыктан түгел, ачлыкка түзә алмаганнан, Полкан егетләре бер авыл көтүеннән бер сарык бәрәнен алып киткәннәр. Көтүчеләре күз алдында. Кым-кырыч кыр эшләреннән кешеләр бераз бушый гына төшсеннәр. Усаклыкны бар яктан камап алып тентү ясарлар. Алар кулында авызларыннан ут көлтәләре бөрки торган кораллар бар бит. Алардан йөгереп кенә котылырмын димә. Полкан төркемендә ау этләре дә бар. Бу коралның нинди көч-кодрәткә ия булуын алар аеруча нык беләләр.

Өйләреннән куылган бәхетсез кардәшләрен үз җитәкчелеге үз канаты астына алган Полкан бу турыда тегеләй дә, болай да уйланып карый. Нишләргә дә белгән юк. Әллә бөтен төркемне ияртеп Каманың теге ягына алып китеп караргамы? Аларны анда да берәү дә көтеп тормыйдыр. Ләкин шулай да...

* * *

Беркөнне үз төркемендәге булган барча маэмайларны корылтай-киңәшмәгә җыйды Полкан. Төркем алдында торган проблемаларны уртага салып сөйләшергә.

Беренче булып атаклы пекинслар нәселеннән булган Стелла атлы әнкә маэмай сүз алды. Буе-сыны белән бер кирпеч хәтле генә булса да, баш, зиһен, хәтер үзендә! Сүз алса, сөйли башласа да, бу Стелла, кәтүк җан, Франциянең Сорбонна, Финляндиянең Хельсинки университетларында фәннәр бакалавры булырга диссертация яклаганмы диярсең. Кыскасы, көндәлек тормышта ул ныклап белмәгән, әйтер сүзе булмаган өлкәсе юк бугай аның. Өердә аны барысы ихтирам итәләр, аның белән киңәшәләр. Бу юлы исә җир йөзендә көннән-көн арта, ишәя барган гаделсезлеккә каршы үзенең кискен сүзен әйтмичә калырга түземлеге калмаганга шулай чәчрәп чыккандыр.

— Без, маэмайлар, кардәшләрем, бер хәл әле. Хуҗаларыбыз бездән туйсалар, куалар да чыгаралар. Менә без барыбыз да урам этләре — бомжлар. Алай да яшибез бит әле. Ә бит бездән кыенрак хәлгә калучылар да күп. Карап торырга акыллы гына кайбер кешеләр кып-кысан фатирларында юлбарыс, арыслан, бишәр метр озынлыктагы питон-еланнар, хәтта крокодиллар асрыйлар. Ниемә дип? Алар арасында нинди рухи якынлык булсын? Ул биш метрлы шланг-питон белән нәрсә турында сөйләшергә, серләшергә мөмкин? Абау! Абау! Аңламыйм мин кешеләрне. Ә менә ул кардәшләребезне безне куган кебек урамга кудың да котылдың түгел бит. Урамга куылган юлбарыс йә крокодил анда ниләр эшләмәс?

— Шушы трагедияне менә үз күзем белән күрдем, — дип кушылды сүзгә коллилар нәселеннән булган Керамит атлы бик тыйнак кына эт егете. — Хуҗалары аларны куып чыгарып тормыйлар. Ике көпшәле мылтыктан бах-бах! итәләр дә, бетте-китте! Аннары чүплеккә чыгарып аталар.

— Булмас ла! Не может быть! — дип кабатлады бөдрә йонлы болонка Җәмилә. — Ничек куллары бара икән? Кечкенәдән алып, кулга ияләндереп иркәләп үстер дә, аннары тот та бах та бах! Бу чын вәхшилек! Ул минем башыма сыймый! — Минем хуҗабикәм тимер читлектә какаду попугае да тотты, — дип дәвам итте Җәмилә. Барыгызның да күргәне бармы икән? Бик акыллы кош иде. Хуҗаларыбыз эштә чакта өйдә икәү генә калабыз. Ул — үз телендә, мин үзебезчә көннәр буе гәп кора идек. Бу попугай нәкъ кешеләрчә сиптерергә дә булдыра иде. Хуҗа абзый безнең бик акчалы эштә эшләде бугай. Әмма һәр кичне бераз салып кайта. Какаду попугае аны хуҗабикәдән алда: «Алкаш син! Алкаш!» — дип орыша иде. Хуҗамның улы Фәрхат, укудан яисә хоккей уйнаудан буш чагында, әллә нигә бер булса да мине урамга, саф һава суларга алып чыга. Ә попугай гел өйдә, гел читлек эчендә.

Кайчакларны гына аны да атына торган даганасы белән чәй бүлмәсенә чыгарып эләләр. Бер телен тыймыйча, бик күп сөйләшә торган кош иде ул. Хуҗалар белән дә сүз көрәштерергә, әрепләшергә яратты, — дип дәвам итте Җәмилә. — Беркөнне чәй бүлмәсенең форточкасы ачык иде. Читлектә утырып ул тәмам туйган булгандыр. Ачык форточка аша тотты да урамга очты. Анда гыйнвар суыгы. Мин бик хөрмәт иткән какаду белән ни булганын сөйләп тормыйм, үзегез дә аңлый булырсыз.

— Әйе, — дип куйды Полкан. — Җирдәге цивилизациянең йөрәк, бавыр, бөер кебек органнарны имплантацияләү дәрәҗәсенә ирешкән чорда, космик сәяхәтләр эпохасында Кеше дигән олуг затларның кайберләре әллә бөтенләй шизанутыйларга әйләнеп баралармы дип уйлыйм мин еш кына.

— Ә бит аларга космосны яуларга да беренчеләрдән булып без булыштык, — дип сүз кыстырды җирән йонлы урам эте Шарик.

— Беренче космик корабларда башта безнең братлар очтылар бит!

— Ишебез көннән-көн ишәя, ризык табу кыенлаша, нишләргә соң безгә? — дигән соравын куйды Полкан.

Урман яланына җыелган барча эт-маэмайлар да беравыздан шул ук сорауны кабатладылар.

— Безне шушы хәлгә төшереп, бер кирәксез җаннарга чыгарганнары өчен кешеләргә карата үпкәбез чиксез, — диде Полкан. — Ләкин ишетсен колагыгыз! Урман юлында юлыккан кешеләргә, аеруча балаларга, «hау» дип тә әйтәсе булмагыз. Юкса... — диде ул, күп мәгънәле итеп.

— Юкса-а... — диделәр маэмайларның кайберләре, башлыкларыннан конкрет җавап көтеп.

— Юкса андыйларга хөкемне үзем чыгарырмын. Бу хөкем моңарчы сез ишеткән хөкемнәрнең иң кырысы булачак. Андыйларны хурлык белән төркемнән куачакбыз.

* * *

Вакыт арбасы үз көенә тәгәри бирә. Кайчакларны, хет беразга гына туктатып, көпчәкләрен, күчәрләрен майлап алырга бик кирәк. Туктамый шул, бер көйгә шыгырдый бирә. Хәзер менә галәмдә, зур көзге алдына басып, озын чәч толымнарын Яңа гасыр тарый, Яңа гасыр үрә. Бу килешенә караганда, бик көйсез килен булыр, ахры, ул. Көннән-көн узынып, намуссызлык, әдәпсезлек, комсызлык баткагына бата барган кешелеккә ниләр бирер дә ниләр күрсәтер?

Тагын бер ямьле җәй узды. Көз җитте. Сулар туңды, җиргә юка гына җәймә булып ап-ак кар төште. Янәдән каз өмәләре чоры якынлашты.

Чатанның тамагы тук, өсте бөтен дигәндәй, үз язмышына буйсынып, бер көйгә яши бирә. Хәзер ул зур гәүдәле, гайрәтле, ат көчле чын бүре егетенә әйләнде. Шушы хәлдә гел бәйдә, чылбырда утыруына гарьләнеп, бер тора торгач, ямьсез дулап, котырынып алгалый. Газинурныкылар аңа гына күнектеләр инде.

Андый чакларны хуҗасы, аның янына килеп:

— Йә, әйт турысын гына, нәрсә җитми сиңа? Бәйдән ычкындырыйммы? Җибәрсәммe?! Үзеңне-үзең күрмисең генә, чын-чын эзвир бит! Бер күрүдә котың алынышлы ерткыч! Җибәрсәм, бөтен әйләнә-тирәне кырып чыгачаксың. Аннары нишләргә? Миңа төрмәдә утырыргамы? Шаярма, малай! Матри у меня! — дип бармак яный.

Ни гажәп, хуҗасы килеп шулай башыннан сыпыргач, бармак та янап алгач, Чатан әле генә ду килеп котырынган җиреннән шып тынып кала. Оясы түбәсенә менеп, зур башын алгы аяклары өстенә сала. Уйга кала...

Көзге төн икенче яртысына авышып килә булгандыр. Газинур Чатанның ничектер бик сәер, хәтта беркадәр шатлык белән өргәненә, кемнәрдер белән уйнарга тырышып ыр-ыр килгәненә уянып китте. Әллә умарталыкны басарга килгәннәрме? Анысы да ерак йөрмәс. Шәһәрдә яшьләргә эш юк, урлар нәрсә дә калмады. Вакыт тәгәрмәче, бәлкем, шуңа ямьсез шыгырдый булыр. Караклар әллә гараж ишеген каералармы? Диңгездәге кораб-баржаларны тарттырырдай нык чылбырда утырган бүредән генә түгел, Уссури тайгасы юлбарысы булса да курыкмыйлар бит алар.

Газинурны былтыр да ике кулсыз иткәннәрие. Гараж капкасын урам яктан каерып кереп, шунда утырган өр-яңа «Жигули»ның биш көпчәген сүтеп алганнарые. Хәзер бит басурманнар да хәтәр һөнәрләренең виртуоз осталарына әверелделәр. Милицияләр тиз тоттылар үзләрен. Гараж төбенә дә алып килделәр. Беркая да эшләмәгән, эшләрлә рие, эш юк, дүрт яшь кенә малай-шалай.

— Минем машина көпчәкләре өчен генә утыртып куя күрмәгез. Берәрне җилкә тамырларына кундырыйк та җибәрик үзләрен, — дип сораган иде Газинур милиция егетләреннән.

— Нигә әле алай? — дип сорады гажәпсенеп тикшерүче егетләрнең өлкәнрәге.

— Бары көпчәкләрне генә салдырганнары өчен мин бик рәхмәтле бу карак егетләргә. Ә шунда гаражга шырпы сызып ташлаган булсалар, машинам да янган булыр иде. Ә көпчәкләрнең яңаларын алырга да була. Машина исән булганда...

— Сезнең сүзгә колак салып, Газинур абый, бәлкем, җибәргән дә булырыек, — дип елмайды тикшерүче егетләрнең башлыгы. — Сезгә чаклы бу өлгер караклар тагын җиде кешенең гаражларын басарга өлгергәннәр. Аларның фикерләре бөтенләй башкачарак.

Бу юлы да гаражны басарга килмәгәйләре. Газинур почмак як стенада гына эленеп торган түтәсе ярык берданкасын алды. Шунсыз чыксаң, караклар алдында кыен хәлгә калуың бар. Чыксамы?! Ни күрсен! Чатан оясыннан ике генә адым читтә, үзен түр кунагыдай тотып, Соры бүре үзе утырып тора. Ә Чатан дөньясын оныткан. Шатлыгы тышка ташый, оясы алдындагы ике бүре егете белән уйный. Дусларча йомшак кына ыр-ыр килүе шуннан икән. Туганлык хисе аларда да шулай көчле, күрәсең.

Газинур башта бөтенләй каушап калды. Аннары гына, исен җыеп:

— Ah сезне! Майт якагызны! — дип кычкырып җибәрде. Шунда ук берне һавага гөрселдәтте.

Гаубицадан аттылармы диярсең. Бер генә көпшәле булса да, аның берданкасы бер дә галәмәт каты гөрселди. Атканнан чыккан тавыш әйләнеп килергә өлгергәнче, ишегалдындагы бүреләр, аткан ук булып, койма аша сикерделәр, юк та булдылар.

Газинур, сигаретын кабызып, Чатан янына килде.

— Кунакларың бар идемени? Әллә әниең дә килгәнме? Улап, үзең чакырдыңмы? Әллә үзе тапканмы?

— Килгәние шул. Үзе тапкан. Әни бит! Аналар балаларын ерак Африкадан, Әфганстаннан да эзләп табалар. Куркыттың бит, юньләп сөйләшергә дә ирек бирмәдең. Өеңне күтәреп китмәсләрие әле! — Чатан, кәефе кырылып, хуҗасы белән сөйләшәсе килмичә, оясы түбәсенә менеп ятты.

Газинурның үзенә дә уңайсыз булып китте. Һавага гөрселдәтмәсә дә ярыйсы булган икән. Баласын сагынып, эзләп табып килгән Ана бүре аның хуҗалыгына зыян итмәс иде әле, өеннән чыга-чыгышка шушы хәлне күреп каушап китте шул. Атмаса да ярыйсы буласы икән.

— Эзләп килгәч, әйбәт булган инде. Әниең нәрсә ди соң? — диде Газинур. — Сагындым, диме? Урманга чакырамы?

— Нәрсә дисен. Улым, теге чакта ташлап киткәнем өчен, зинһар, гафу ит, ди. Мин бит сиңа карата ул хыянәтне абыйларыңны саклап калу өчен эшләдем. Хәзер менә үкенәм. Сине юксынып, сине өзелеп сагынып, төннәр буена улап чыккан чакларым күп булды, балам, ди.

— Балам, имеш. Тотып сукага җигәрлек егет бит инде син хәзер. Еламагандыр да әле, әниеңне әйтәм. Тамагы ач чагында, бик ашыйсы килгән чагында улап-улап куя булгандыр.

— Безнең бүреләр ыруы турында шулай дорфа, грубияннарча сөйләвеңне гомумән килештермим, хуҗам. Тешкә тия. Үземнең улыйсым килә башлый.

— Әйтәм җирле аны... Бер тотынсаң, кулыма чыбык алмый туктамыйсың улаудан. Абыйларың да килгәннәрмени?

— Килгәннәрие шул. Алар да, бик сагындык, диләр. Болай җае чыккач, хуҗам, әйтсәм әйтим инде, сез бит, кешеләр, безнең кебек өзелеп сагына белмисез. Сездә бер-берегезгә карата үч тоту, грубиянлык, көнчелек, бер-берегезне күрә алмау инстинктлары көчле. Юкса тыштан караганда башларыгызга бик затлы эшләпәләр, затлы җиләннәр киеп, борыннарыгызны бик югары чөеп йөрсәгез дә, барыгыз да кара эчеләр. Әгәр рентген алдына бастырып карасаң, һәркайсының куены, кесәсе таш белән тулы. Ташны ташка бәреп, кирәк чакта ут-очкын чыгару өчен түгел, ә берәр сөймәгәнегезнең башына тондыру өчен йөртәсез куеннарыгызда бу ташларны. Дөресен әйтәмме?

— Миңа карата да шушы фикердәме син, оятсыз? — дип куйды Газинур. — Мин телгә оста дигәч тә, бераз чамалабрак сөйләш. Юкса телеңне кыскартып куймагаем.

— Минем телне кыскарту белән генә кешеләр холыкларын уңайга үзгәртсә икән...

— Җитте, җитте. Күп лыгырдый башладың. Чаманы белеп кенә сөйләргә өйрән. Миннән бер дә шүрләми башладың. Бер кызсаммы?! Өйрәтермен мин сине шәүләмне күрү белән дер калтырый башларга.

— Нигә шүрләмим ди инде? Күрәсең бит, дер-дер калтырап та куям.

— Остар әле, остар теленә күп. Камчы алмагаем. — Урманда чакта абыйларың алтау иде бит. Мин икесен генә күреп өлгердем.

— Абыйларымның ике генә калуларын әнием, улым, җае чыккан саен мин сезне, юлыгызда очраган кызыл флажоклардан курыкмагыз, дип кисәтә килдем, алар куркуларын җиңә алмадылар, дип аңлатты. Кызыл флажоклардан курыкмаска булган да бит...

— Әниең тагын ниләр сөйләде? — дип кызыксынуын дәвам итте Газинур. — Котырткандыр инде... Карт Ана бүре тагын нәрсә әйтсен.

— Улым, яшәгән җирең коры, тамагың тук икән, диде. Монысы сөенечле. Әмма муеныңда тимер галстук. Балам, шуны бел. Синең шушы тук тормышта яшәвеңне берәр авылга төшеп, сыртыңа сарык түшкәсе салуга йә, бөтен көченә ажгырып, урман яланында утлап йөргән пошилар, болындагы атлар көтүенә гомердә бер генә һөҗүм итүгә дә алыштырмас идем. Без бит, балам, бәндә йә читлек эчендә утыру өчен яралган җаннар түгел. Без — һавадагы кошлар кебек ирекле җаннар. Без бертуктаусыз санитарлык итәргә тиеш. Тәңребез безгә шундый бурыч йөкләгән. Менә шул турыда беләсеңме, онытмадыңмы? Юкса куенымда үстергән кичләремдә дә бу турыда сезгә байтак кына сөйләргә өлгердем төсле.

— Кансыз ерткыч синең әниең! Кара син аны, монда килеп, сине дә аның кебек кансыз, юлбасар булырга котырта. Бәхете инде, берданкамнан берәрне дөпелдәтергә өлгермәдем.

Чатанның да Газинур абыйсын бераз үчектерәсе килде:

— Шушы берданкаң беләнме? — диде ирония белән. — Син аңамы? Гомердә тидерә алмыйсың. Бу пушкаң белән, Газинур абый, колхоз басуына яшел борчак урларга менгән малайларны гына куркыта аласың.

Чатан әнисе белән туйганчы гәпләшә алмады бит. Шунда инде хуҗасы чак кына чыкмыйча торса.

— Тидермәм! — дип янады Газинур, берданкасын баш өсте күтәреп. — Йөрмәсен бүтән. Әйт үзенә, эзе булмасын. Берданкамны жакан белән корып, маңгай сөяген чәлпәрәмә китерермен.

Ана бүре алар ишегалдына бүтән килүен килмәде. Әмма Газинурларның арт ягындагы текә тауга һәр кичне килеп, шуннан торып ямьсез улап, улын үз янына чакыра башлады. Һәр төнне шулай. Газинур, берданкасын тауга таба төзәп, бер-бер артлы атып та карады. Бик исе китте Ана бүренең. Һәр кичне, ай калыгу белән, килеп улавын гына белде. Әнисе чакыруына җавап итеп Чатан да төннәр буе җан өшеткеч ямьсез тавыш белән улап чыга. Түзешле дә, узышлы да булмады бу хәл.

Газинурның:

— Ташла бу дурак гадәтеңне, юкса тунап тиреңне салдырам бит, — дип, берәр тапкыр тал чыбыгы белән Чатанга сырты буйлап сыптыруының да файдасы тимәде.

— Чукын! Чәнчелеп кит алайса! — дип, Газинур бер кичне Чатан муенындагы тимер муенчакны сүтте. — Ләкин алдан ук кисәтәм син киребеткән зимагурны, ул-бу хәтәр хәлләргә тарысаң, безгә үпкәләмә.

Чатан, тәмам акылын жуйгандай, абына-сөртенә, мәтәлеп-мәтәлеп китеп, урманга чапты. Шунда ук әнисен эзләп тапты. Бер-берләренә карата берсе ана булып, икенчесе бала булып якынлык, туганлык хисләрен шулай озак сакласалар да, бергә булгач, аларның уртак ашлары пешмәде. Әнисе аны бергәләп дөнья көтәргә, бер табыннан ризыкланырга түгел, ә шушы зирәк акылы-зиһене белән бәйдә саргаймаска, шушы киң дөньяда ирекле булып яшәргә чакырган икән. Җитмәсә, әнисе авырлы да иде. Ярыйсы гына олыгаеп барган көннәрендә хәвеф-хәтәрсез генә бәбиләргә, һәр почмагын яхшы белгән урманның бер аулак, ышык җирендә үзенә ипле генә ятак эзләү белән мәшгуль иде.

Чатан урман сукмагына басуының икенче-өченче көнендә үк башлыклары беренче класслы немец овчаркасы булган, инде ярым кыргыйланып барган этләр өеренә барып кушылмакчы булды. Тагын кая барсын? Ялгызы гына көн итәргә өйрәнмәгән. Полкан өерен тиз эзләп тапты. Көтүгә бер күз йөртү белән исе китте. Әлеге юлбасарлар шайкасында эт-маэмайлар затының нинди генә данлы, атказанган нәсел вәкилләре юк: озынча танаулы, озын сыйраклы сенбернарлар, үз көчләренә ышанган зур гәүдәле лайкалар, аскы иреннәре салынган куркыныч кыяфәтле бульдоглар, нечкә билле эрдель-терьерлар, һәрчак чибәррәк эт егетләре тирәсендә чуалучы бөдрә йонлы, кыска аяклы болонкалар, кыланчык ак пудельләр, солдафон кыяфәтле доглар. Кыскасы, аларны күреп бот чабышлы. Эт-маэмайларның интернациональ дуслыгы! Кешеләр арасындагы категорияләргә күчерсәң, аларны лордлар, маркизлар, бароннар, кнәзләр, графлар итеп санарга булыр иде. Ишләре дә утыз-кырыктан артык.

Шунысы сәер: Чатанны күрүгә барысы да койрыкларын бот араларына кыстылар. Аңа Полканның гына исе китмәде. Көтмәгәндә-уйламаганда гына аның өеренә килеп кушылган бу очлы колак, ялт-йолт күз бүреләр нәселеннән бугай. Булмагае! Бетмәсләр алар төрле килде-китте килмешәкләр. Бер белмәгән, кырыс тормыш шартларында сыналмаган затны ни дип әле төркемгә алырга? Көтүгә аннан бер-бер файда булырмы? Полкан — үз өерендә танылган авторитет. Көтүдә Бөркет, Казбек, Байкал, Рекс кебек, физик яктан Полканга караганда күпкә көчлерәк Себер овчаркалары, сенбернарлар, коллилар бар. Әмма алар барысы да Полканның күзенә генә карап торалар. Аның күңелендә туган нинди дә булса теләген күз карашыннан аңлыйлар, ым гына каксын, шундук үтәргә әзер торалар. Ә бу килмешәк кем? Урманда әллә башка төркемнәр беткәнме? Ни дип әле аның өеренә килеп кушылды? Кешеләр арасында «халыклар дуслыгы» дигән изге төшенчә бар. Ә Полкан баш булган өердә шушы сүзнең тулы мәгънәсендә эт-маэмайлар дуслыгы. Югы — бергә, бары — уртак! Өердәгеләр бер-берсен ихтирам итеп үзара тату, дус яшиләр. Мондый тәртипне төркем оешкан беренче көннәрне үк Полкан оештырды.

Әлеге бүре егетенең рөхсәт тә сорап тормыйча аның өеренә килеп кушылуына да күз йомар идең. Килеп кушылу белән, ул үзен бик иркен тота башлады. Башлык булырга да нияте бармы? Полкан, усал ырылдап, әлеге килмешәккә көтүдә үз урынын күрсәтмәк, кисәтмәк булды. Килмешәкнең, беркемгә буйсынмыйча, үзен бик иркен тотуына да түзәр идең. Көтүгә килеп кушылу белән бу затсыз җан Полканның инде күптәннән күзе төшеп йөргән әлеге чибәркәй Чио-Чио-сан тирәсендә бөтерелә башлады.

Мондый чакта икенең берсе инде: йә син, йә дошманың. Уртак яр сөю мөмкин түгел. Полкан да шулай дип хәл итте. Кырык-илле парлап бик җете күзләр аларга төбәлгән аланда Полкан беренче булып үзе һөҗүм итте. Җиргә салып бераз әвәләп тә алып, Чатанны акылга утырту гына иде Полканның исәбе. Чакматашка чакматаш белән суксаң, очкын чыга. Очкыннан — ут, уттан ялкын

кабына, янгын чыга. Чатан да, Полкан килеп кагылу белән, «берсүзсез буйсынам!» дип җиргә сузылмады. Алар якалашып киттеләр, аннары бугазга-бугаз ябыштылар. Бүре егете Полканны оста гына буып алды, ипле генә итеп җиргә салды. Шушының белән «аңлаштык» дип уйлаганые Чатан. Төркем белән җитәкчелекне дә үзенә тапшырыр дип көткәние. Кая ул! Бөтен төркем алдында Чио-Чио-сан да әллә кем булып шушы тирәләрдә генә йөреп тора. Ике көндәшнең бил алышулары ни белән беткәнен көтә бугай. Полкан алай тез чүгүчеләрдән түгел иде шул.

Бугазын бушатуга, сикереп торып, тагын да ярсып, ямьсез ажгырып, Чатан өстенә ташланды. Мондый чакта мәми авыз булып торсаң, үзеңә үпкәлә. Чатанның да айлар буе тыеп торган каны гөлт итеп кызды. Бөтенләй кызып китеп, көндәшен бөтәрләп, умырып-умарып ташлады. Кызды шул. Артыгын кызды...

Шунсыз булмый иде. Шунсыз аның үзен ботарлап ташлаячаклар. Полканны авыр хәлдә күреп, төркемдәге иң якын кардәшләре аңа ярдәмгә ташланмакчылар иде. Бер рәттән Чатан аларны да буып-буып ыргытты. Төркемдәгеләрнең калганнары шундук җиргә яттылар, дүрт аякларын өскә күтәрделәр. «Безгә тия күрмә! Без сиңа буйсынабыз! Шушы минуттан башлыгыбыз итеп сине таныйбыз!» дигән сүзләре иде бу аларның.

Чатан шулай Пошилар усаклыгы урман массивында юлбасарлык иткән эт-маэмайлар бандасының башлыклары булып куйды. Әлеге төркемдәге әнкәләр арасыннан чибәркәйләрнең чибәре, гүзәлләрнең гүзәле ак пудель Чио-Чио-санны шундук үзенең кәләше итте. Тормыш юлында үзенә бер ышанычлы кәләш табу аның күптәнге хыялы иде. Хыялы, ниһаять, чынга ашты. Бәхетле парлар була күрсеннәр инде.

Өзелеп ярату, ихлас күңел белән сөю хисе Чатанда зур, гаять биек плотина белән буылган буа төсле торган, ахры. Хәзер менә шул плотинаның шлюзлары ачылды, күрәсең. Төркемдә йөрткәндә дә Чио-Чио-санны үзеннән бер адым калдырмый. Ял иткәндә дә кочагында гына йоклата.

Чио-Чио-сан үзе дә Чатанга бер күрүдә гашыйк булды. Хәзер ул, нинди генә кыен сынаулар алдында калса да, барыбер үз циркына кайтырга җыенуы, иң оригиналь номерлар белән тамашачыларның исләрен китерәчәге турында бөтенләй сөйләми башлады. Чатан белән алар арасында туган саф мәхәббәткә төркемдәге инде бераз дөнья күргән өлгергән әнкә маэмайлар да, әле кызлар кулы тотарга да өлгермәгән эт егетләре дә ихлас күңелләре белән сокланып карыйлар, аларның бәхетле булуларын телиләр.

* * *

Табигать урман ияләренең берләрен җим чүпләп көн күрә торган итеп яраткан. Болары кош-кортлар, каурый канатлылар, очлы, үткен томшыклылар. Аларның ашаган ризыклары да җиләк-җимеш, шомырт-миләш, карлыган-балан, чикләвек-орлык. Каурый канатлы булуларына зарланмыйлар алар. «Тырышкан табар, ташка кадак кагар» дигән принцип белән яшәп, бер тамакларын туйдырырлык ризыкны җәен дә, кышын да җиңел табып көн күрәләр. Үзләренең барлыклары белән Табигатьне бизәп яшәүләрен белеп, сөенеп, горурлык белән яшиләр.

Пошиларга, боланнарга, кыр кәҗәләренә, кабан дуңгызларына исә чыршы-нарат ылыслары, усак-юкә ботаклары, кыяклы үләннәр, сусыл тамырлар булсын. Русак, ягъни үр куяны, озын колак, кылый күз куяннар кыш чыгарлык майны үзенә көзге уҗым ашап җыя. Аларны күрәсең килсә, көзлектә, җирләр туңдыргач, уҗым басуларына гына чык. Җир өстенә килеп керсәң, әллә каян күренәләр. Чөнки соры-көрән җәйге җиләннәрен кышкы ап-ак туннарына алыштырып өлгермәгәннәр. Өстенә чак кына ак кар төшкән уҗым басуы өстендә ерактан ук күренәләр. Шунда көн-төн яталар. Шунда ук туйларын да уздыралар. Үр куяны алмагач кайрысына да тәкать тота алмый. Кыш буена алар булмаган алма бакчасы, алар кимереп карамаган агач калмый.

Ә менә барысы бергә ерткычлар, ягъни ерткыч җанварлар исеме астында йөргән урман ияләреннән төлкегә, бүрегә, аюга җан асрау өчен ит кирәк бит. Ит кирәк дип кенә аларга дигән симез түшкәләрне урман аланнарындагы агач ботакларына берәү дә чыгарып элеп куймаган. Биредә инде башка принцип хөкем сөрә. Суга батучыны коткару батучының шәхсән үз эше. Төнне ач кунасың килмәсә, аягыңны кызганма. Чатан төркеме әгъзалары, вак-вак төркемнәргә бүленеп, һәр кичне шәһәрләр, поселоклар тирәсендәге чүплек базларына, күп катлы йортлар ишегалларындагы чүп-ташландык җыю контейнерларына төшәләр. Шунда актарыналар, чүпләнәләр. Анда, бәхетеңнән инде, кем нәрсәгә юлыга, шуның белән сыйлана. Кыюраклары, тәвәккәлләре теге йә бу якынрак авылның сыер-сарык, дуңгыз-кәҗә абзарларына да бәреп керәләр. Берәр кәҗә бәтиенме йә шираулатып кычкыртып берәр дуңгыз баласынмы сыртларына салып урлап чыгалар. Чаган сизә: мондый тормыш озакка бармас. Ишләре дә күп бит. Әлегедәй җинаятьләр көн саен булып тора. Кешеләрнең түземлеге бер көн бетеп куйса? Һич югында, беразга булса да китәргә иде аларга бу тарафлардан. Чатан ужулана, үз төркемен җәлт кенә итеп алып китә алмый бу яклардан... Шуңа пошына...

Менә сиңа мә, беркөнне һич көтмәгәндә Пошилар усаклыгы өстендә вертолетлар күренде. Шулхәтле түбәннән очалар. Болытсыз, аяз көн иде. Чатанның каушап калудан бернинди карарга килә

алмаган, Броун хәрәкәтен хәтерләтеп, кайсы кай якка чабышкан егетләрен чүпләделәр генә вертолеттан. Гөрс тә гөрс аткан тавышлар ул көнне урманда яңгырап кына торды. Ап-ак карлы урман аланы төш алларына кып-кызыл канга батты. Һәр ачыклыкта җиңел яраланган маэмайның кызганыч чинавы, авыр яралысының көчкә-көчкә ыңгырашуы ишетелә. Чатан үзе дә өстән, вертолеттан күренмәслек куе чытырманлыкка кереп кенә исән калды. Күңелен шуның белән юатты: кәләше, өзелеп сөйгәне ак пудель Чио-Чио-сан аның белән. Ул аны вертолеттан атучылар утыннан ике-өч тапкыр үз гәүдәсе белән каплап саклады.

* * *

Аучыларның Пошилар усаклыгына облава ясаулары турында Газинур да ишетте. Аучылар урманда кулга төшергән трофейларын «Беларусь» тракторы чанасына төяп төштеләр. Чананы Шәһәрне төзекләндерү, яшелләндерү, бизәү конторасы ишегалдына куйдылар. «Трофейлар»ны карарга ярты шәһәр килде. Кайберәүләр көчектән алып үстереп, соңыннан урамга куган коллиларын, сенбернарларын, болонкаларын, пудельләрен таныдылар. Ah та вах килделәр. Икейөзле булу өчен күп кирәкме? Арада йөрәген тотып, валидол төймәләре кабып, күз яшьләрен сөртеп алучылар да булды. Эш узгач...

Газинур, трактор арбасына менеп, инде таш булып катарга өлгергән эт-маэмай, бүре түшкәләрен үз кулы белән барлап, тикшереп чыкты. Кичен чәй янында, хатыны Сәрия җиңгәйгә, кызлары Гөлшат белән Айгөлгә төбәлеп һәм нык сөенеп:

— Урманнан төяп төшкән «трофейлар» арасында безнең Чатан юк! — диде.

— Ура! Ура! — Кызлары лепер-лепер генә кул чаптылар.

Ә Сәрия җиңгәй, авызына китергән кашыгын кире куеп:

— Безнең Чатан ул, балакаем, нарасыем, ятимлектә үсте. Көтелмәгән хәвеф-хәтәрдән Ходай аны үзе саклый. Яши генә бирсен, җанашым! Чын бүрегә әйләнгән иде бит инде. Ә менә шулай да сагынам үзен. Төче коймак бик ярата иде. Бер килеп чыкса, күбенгәнче сыйлыйм әле үзен, — дип, авыз эченнән генә бер кыска дога укып битен сыйпады. — Минем бу догам тылсымлы кодрәткә ия. Әнием шулай дия торганые. Алла боерса, урманнарыбызны биләп яшәр әле безнең Чатаныбыз. Яшәр! Яшәр! Яши күрсен! Уллар үстерергә язсын үзенә!

* * *

Аучылар инде, бер керешкәч, Пошилар усаклыгын дүрт аяклы, азау тешле ерткычлардан, корткычлардан чип-чистага чистартып чыгарга булганнар, күрәсең. Бәлкем, шәһәр башлыклары да шулай кушканнардыр. Атна-ун көннәрдән соң алар урман аланнарына снегоход дигән дәһшәтле машиналарында килеп керделәр. Дәһшәтле димәскә, аннан котылу юк. Карга батмый, тизлеге зур. Син тирән карны ерып качарга маташканда, алар шундук өстеңә килеп җитәләр. Аннан котылырга да җаен табар идең. Алар барлык аланнарга кызыл флажоклар куеп чыкканнар. Алларында шундый флажоклар күрүгә, бүреләр дә, маэмайлар да коелып куркып калалар. Мондый флажокларны аларның сукмакларына бары кешеләр генә куялар. Мәкер белән! Әлбәттә, хәйлә белән! Флажок артында капкын буласын көт тә тор. Шулай булгач, яныннан ерак тор! Янына якын килмә!

Артыннан бар хутларына куа килүче ике снегоходтан качып, Чатан да кызыл флажоклар тезгән зур аланга килеп чыкты. Нишләргә? Капты бит. Аучылар да куып җиттеләр. Атмыйлар. Чатан өстенә ятьмә ташламакчылар. Тере килеш эләктермәкчеләр. Шунда аның исенә әнисенең «балам, кызыл флажоклардан курыкма! Абыйларың да шул флажоклардан курку аркасында харап булдылар!» дигән сүзләре килде. Күп уйланып торыр ара калмаганые инде. Алдагы снегоходта утырган аучы кулына тимер көпшәсен алды. Башта Чатанны җиңелчә генә яраларга булды, ахры. Көпшә авызыннан ут бөркелде. Чатанның сыртын нәрсәдер җиңелчә генә чеметеп алды. Ятып яраны ялап алсаң да ярар иде. Кая ул! Ике сунарчы, чаналарыннан төшеп, ятьмә җәяләр, Чатан өстенә ыргытмакчылар. Аның белән кар ерып чапкан Чио-Чио-санга: «Сикер, матурым, минем арттан!» — диде. Үзе беренче булып кан саркыган гәүдәсен флажокларның теге ягына атты.

— Киттеләр бит, киттеләр. Флажоклардан да курыкмадылар! Борын төбеннән генә ычкындылар! Бик хәйләкәр бүре булды бу! Вожаклары булгандыр әле. И-их, эләктерә алмадык бит!

— Булмыйча! Үзе белән сөяркәсен дә алып качты бит! — дип, аучыларның сүгенгәнен ишетте Чатан.

Ярасы алай тирән, зыянлы түгел иде аның. Кәләше — ак пудель Чио-Чио-сан — аның ярасын теле белән ялап чистартты, ярадан тары бөртеге хәтле генә кургаш кисәген дә тартып чыгарды.

Кичен, урманда шау-шу басылгач, Чатан, җиңелчә улап, кардәшләрен үз янына дәште. Озын-озын итеп уласа да, аланга күп булса ун-унбиш карендәше килгәндер. Кайберләре кыенлык белән арт аякларын өстериләр. Алгы аякларына баса алмаучылар да бар.

Ә башлыклары Чатан аларны:

— Болай булгач, безнең ыру яши әле! Яралар алар... төзәлә торган хәсрәт. Рус агайлар «рана у него заживают как на собаке!» дип бер дә юктан әйтмиләрдер. Безнекеләр дә төзәлер, — дип каршы алды, барысының күңелен күтәрде. — Моннан соң, кардәшләрем, вертолетлар һөҗүм итә калганда, урманның югары вольтлы электр линияләре узган өлешенә качыгыз. Ул линияләргә вертолетлар, электр сугудан куркып, бер чакрым арага якын килергә шүрлиләр. Снегоходлар килеп чыкканда, иң куе, беркем керә алмаслык урман-чытырманлыкка йөгерегез. Анда керә алмый алар. Кызыл флажоклар тезеп чыккан аланга килеп чыксагыз да каушап калмагыз. Сикерегез дә чыгыгыз! — дип, Чатан облавадан исән калган иптәшләренә киңәшләрен бирде.

Чибәркәйләрнең чибәре ак пудель Чио-Чио-сан тагын да матураеп, түгәрәкләнеп китте. Ул авырлы. Чатан аңа бәбәйләр урынны Пошилар усаклыгыннан шактый ераста, шәрә кыр уртасында, әмма кешекара күзенә чалынмастай тирән чокырда тапты.

Чио-Чио-сан «без яшибез, ай үсәсен көн үсәбез» дип торган берсеннән-берсе матур, берсеннән-берсе татлы дүрт кыз һәм төпчеге итеп бер малай көчек тапты. Анысы әтисенең кыл күчермәсе, кыл бала чагы инде. Хәтта бераз гына чатанлыгы да бар. Зирәк акыллы, сизгер холыклы буласы әллә каян сизелеп тора. Күп тә узмас, әлеге чатан көчек тә, әтисе кебек, шушы урманның усал, кансыз хуҗасы булыр. Бер улап җибәрсә дә, күпләрнең күңеленә шом салыр. Кансыз булса соң! Тәңре аны шулай итеп яраткан. Яраткан гына түгел, ярата да әле. Урманнарыбызны бүреләр бизәргә тиеш, ди ул. Санитарларсыз яшәп булмый. Профилактиканы бертуктаусыз ясап торырга кирәк. Санитарларсыз җирдә тереклек яши алмас!

Матур көчекнең әтисе Чатанның сөенече күктән ашкан. Ул бәхетле ата. Аның дүрт кызы һәм нәкъ аның үзе төсле улы бар. Чатан еш кына Газинур агаларында торган вакытларын, аның матур кызлары Гөлшат белән Айгөл апаларын искә төшерә. Аларны сагынып, бер күрәсе килеп, кай кичләрне сыкрау белән улап-улап җибәрә. Апаларына аның үзе кебек бераз чатан, әмма бик тере улын алып төшеп күрсәтәсе килә. Әмма урман ияләре арасында буыннан буынга үзгәрешсез бирелеп килә торган «табу!», ягъни «ярамый!» дигән кырыс инстинкт яшәп килә. Ярамый! икән ярамый! Аны бозарга беркемнең хакы юк. Ул чакта аның улыннан да Кеше исе килергә мөмкин. Аның үзе белән дә нинди зур трагедия була язды. Югыйсә өзелеп яраткан бердәнбер улын, үзе кебек бераз гына чатанны, сыртыннан гына каптырып, Газинур абыйсына, Сәрия җиңгәсенә, аларның кызларына алып төшеп күрсәткән булыр иде. «Табу!» «Ярамый!»

Әмма кышкы озын кичләрдә, улын җылы кочагына алып, Чатан аңа акыллы киңәшләрен күп бирә:

— Табигать-анабыз безне, улым, җиргә бик кирәкле җаннар итеп яраткан. Әгәр без булмасак, җирне төрле үләксәләр, берсеннән-берсе хәтәррәк йогышлы авырулар басар иде. Кош-корт, җанварлардан бигрәк Кешеләр үзләре кырылырлар иде. Без, улым, җирнең санитарлары! Җир йөзендәге саулыкның, иминлекнең, чисталыкның сагында торучылар! Йорт хайваннары арасында да, урмандагы җәнлекләр арасында да без нәселләрне яңартучылар. Прогресска хезмәт итүчеләр. Көтүләргә һөҗүм итсәк тә, абзарларга төшеп сарык бәрәне йә кәҗә бәтие урласак та, без алар арасыннан иң кәекләрен, иң чирләшкәләрен, булмаганнарын, пешмәгәннәрен, болай да үлемгә дучарларын гына эләктерәбез. Аларның уңганнары, булганнары, үткерләре безгә тоттырып та тормыйлар. Качып котылырга җитез тәпиләре бар. Хәйлә корырга зирәк акыллы башлары иңбашларында.

Кайчакларны, улым, тормышта бик кыен чаклар да була. Хәтта менә шундый чакларда да, балам, безнең Табигать-анабызга, Кешеләргә бик кирәкле затлар, алар тарафыннан тирән ихтирам ителгән җаннар икәнебезне белеп, горурланып яшәргә тырыш.

Чатан мондый сүзләрен улына үзләренең бүреләр телендә төннәр буе сөйләп чыга.

Биш балалы ана булу бәхете болытларга ашкан Чио-Чио-сан да тормыш иптәшенең һәр сүзен хуплап тора:

— Балакайларым, атагыз сезгә хак сүз сөйли. Берсен дә җилгә очыра күрмәгез. Тормыш диңгезен кичкәндә аның һәр сүзенең бик кирәге чыгуы мөмкин, — дип, үзе әйтергә тиеш сүзләрен өсти. Урман кочагына кадерле балаларын тиешле хәзерлек белән чыгарасы килә.

— Әлегә, кадерлеләрем, мин сезгә гыйбрәтләр генә сөйлим. Авызлары пешмәсен, бернәрсәне дә өрми капмасыннар дип. Бераз гына үсә төшегез дә, аннары ауга да алып йөри башлармын, — дип, бәхетле ата биш баласының әле берсен, әле икенчесен кочагына алып сөя...

Кай кичләрне, ертык болытларны аралап, ай күренә. Йокы алдыннан бераз йөреп керергә ишегалдына Газинур чыга. Аның янына шундук Сарбай килеп җитә. Хуҗасының кулында ике-өч төче коймак буласын белә ул. Чөнки Сарбай да төче коймак ярата. Газинур өйләре артындагы урманга төбәлә. Кулын колагына куя. Кай кичләрне шунда таныш бер тембр белән бүре улагандай була. Әллә шулай тоела гынамы?

Әмма Газинур үз-үзенә:

— Безнең Чатан тавышы бит бу! Шайтан, шушы тирәләрдә генә йөри, күрәсең! Шунда төшеп күренсә соң? Бәйләп куймас идек әле. Төче коймак белән сыйларыек та җибәрериек. Шулаймы, Сарбай? — дип сөйләнеп ала.

— Һay, һay! Шулай, шулай! — дип хуплый аны карсак Сарбай.

Хикәяләр

Булырлар сиңа аңгыра!

Июль урталары бу. Тын ала алмастай бөркү көн. Төш аллары. Боргаланып-сыргаланып аккан, быелгы яңгырлы елда аеруча күп сулы Ык елгасы буендагы тигез болында ишле генә сыер көтүе йөри. Саескандай аклы-каралы түшле бер бик матур гына тана үзен сарып алган кигәвеннәрдән тәмам туйды, ахры. Туймассың! Борын-танау тирәләрен үтереп, тәмам канга батырып талыйлар бит. Тана коенып чыгарга булды. Башкача котылыр чара юк. Суга җай гына кереп китмәкче иде дә, ярның бик текә җиренә туры килде. Ишелгән җир белән бергә бух итеп суга чумды. Йөзә белүен белә икән. Шундук пылт итеп өскә калыкты. Әмма нык каушавы йөзенә чыккан, күзләре шар. Мөгрәве дә шөбһәле. Кире ярга чыкмакчы. Чөнки елганың бик тирән җире бу, агым да көчле. Тананы бөтереп кенә алмакчы. Юк, чыгышлы түгел. Яр бик текә. Елга аны уртагарак өстерәмәкче. Мондый хәлдә батып китүең дә бар. Тана ярга чыгарга азаплана, шөбһәле мөгри. Аның шулай бушка азапланууын болында утлап йөргән башка, өлкәнрәк сыерлар да күреп алдылар. Менә әкәмәт, ваемсыз гына утлап йөрүләрен ташлап, барысы да яр буена җыелыштылар. Кыен хәлгә калган тананы кулларын сузып кына тартып чыгарган булырларые да, куллары булса. Алай да үзләренә генә аңлаешлы ишарәләр, ымнар, мөгерәү белән тананы тиз тынычландырдылар.

— Кабаланма, каударланма! Яле үзеңне кулга ал. Бу турыдан син ярга чыга алмассың. Әнә бит ничек текә. Син чак кына өскә табарак йөз. Анда яр сөзәк, — диделәр, ахры.

Барысы да башларын түбән игәннәр, теләктәшлек белдерәләр. Бәлагә тарыган иптәшләренә ашыкмый, кабаланмый гына акыллы киңәшләрен бирделәр. Әлегедәй хәтәр хәлләргә тарыганда, бер-берләрен бик җиңел аңлый торган үз телләре бар икән бит боларның. Бу күренешне үзем дә исем китеп карап торам.

Танабыз, өлкән иптәшләренең сүзен тыңлап, кыю рәвештә өскә таба йөзеп китте. Тиз арада елганың саерак җиренә җитеп, төпкә басты. Сөенеченнән уф! дип пошкырып куйды. Аннары шупыр-шупыр суны сөзеп ярга ук чыкты. Бу юлы инде җиңүче буларак шатлыклы мөгрәп алды.

Аның янына шундук берничә тана, сыерлар килделәр. Аны котылуы белән котладылар, ахры. Һәрхәлдә, әлеге тананы чорнап алып, озын гына вәгазь дә сөйләделәр төсле. Моннан соң күргән бер җирдә алай кинәттән генә суга шупырдап кереп китмәскә, саграк булырга киңәш иткәннәрдер инде. Үзара бик җитди сөйләштеләр төсле алар.

Сыерларны без гадәттә бик ваемсыз, хәтта бераз аңгыра җан ияләренә санап йөртәбез бит. Булырлар аңгыра! Кардәшләре бәла-казага тарыганда әнә ничек оеша, берләшә, бер тын белән сулый, конкрет ярдәм кулы сузалар. Барысы бер булып, бар эшләрен ташлап! Гаҗәпләнмәслек тә түгел шул.

Әлеге матур тана исә: «Уйламаган-көтмәгән җирдән кара нинди хәлгә тарыдым. Ярый әле иптәшләрем ярдәм итте. Юкса Ык төбенә китә идем бит», — дигән төсле, бер урында басып, байтак вакыт уйланып торды әле.

Вә Аллаһе әгъләм биссаваб!

Кым-кырыс кына эшем төшеп, үзебезнең Лениногорскидан нефтьчеләр башкаласы Әлмәткә барып кайтыйм дип чыкканыем мин бу хәвефле сәфәргә. Тик үземнең пешмәгәнлегем, каударлыгым аркасында гына инде бик күпне күргән, гаражга кергән чакта, капкага сыймыйча, ике алгы ишеген, аннан чыкканда, абайлап өлгермичә, ике арткы ишеген каерткан «Жигули-4» машинам белән инде. Ун еллар гомере эчендә әнә шундыйрак күп сынаулар аша узса да, болай нык әле ул. Кирәк чакта һәркайсына дүртәр чиләк бәрәңге салынган сигез капчыкны эһ тә итмичә тарта. Дуылдата гына! Бездә машиналарның көч-куәтен, кодрәтен, үзе көзге төн кебек озын, үзе Каф тавыдай текә Зәй-Каратай тавын менгәндә сыныйлар. Минем «четверка»мда төптәнрәк куып та килсәңме?! Салоныңда киерелеп утырган, «башкирская красавица» сортлы алмалар төсле кып-кызыл йөзле өч пассажирың белән бергә, хәтта дүртенче тизлектә, шушы тауның иң очына менгерә дә куя. Бу машинаңның игелеген күп күрдең бит инде, алыштыр, яңарагын ал, диючеләр дә бар. Алыштыраммы соң, жүләр! Ул бит күпме утны-суны бергә кичкән ышанычлы дустым. Бер-беребезнең халәтен, эчке кичерешен без бер-беребезнең күзенә бер карау белән аңлашабыз. Кулым белән иркәләп сыпыра-сыпыра, мин аңа бик күп мактау сүзләре дә сөйлим. Ә ул тын гына тыңлый...

Хәзер бит юлга иң изге ниятләр белән чыгарга да куркыныч. Машина, машина!.. Җитә егетләр башына, димәссеңме. Тыз да быз гына чабалар. Кая чапканнарын, кая шулай ашыкканнарын да белмиләр бугай. Олы юлга чыгуыма ук, төрле ал да гөл төстәге иномаркалар мине дә яшен угы тизлеге белән уза башладылар. Узсалар соң инде! Барыр җирем ерак түгел. Миңа, пенсионерга, кая ашыгырга, диген. Трассага чыгып басу белән, аяк терәп, юлның иң-иң уң ягын билим дә үз көемә илле-алтмыш чакрымны тотам. Гәрчә кайчакларны минем «Жигули» да дилбегәне бушата төшүне, аны үз иркенә

куюны сораса да. Дилбегәне бушата төшсәң, сәгатенә йөз егерме-йөз утызлар белән уйнаклап алуны бик килештерә ул. Әмма күрәм: мине космик тизлекләре белән узып киткән иномаркалар, Әлмәт юлының катлаулы бер чатына җитәрәк, кинәттән тизлекләрен чаж киметеп, хәтта табан асларыннан очкыннар чыгарып тормоз салып, бер төшне кискен рәвештә әйләнеп узалар.

Әллә ни ашыкмасам да, ул җиргә мин дә якынайдым. Күрәм: юлның нәкъ уртасында, авыл абыстайларының чажлатып сыер сава торган, ун-унике литрлап сөт керешле эче ап-ак эмаль чиләкләре кадәр бер түмгәк күренә. Машиналар, очып килгән хутларына кинәттән тормоз салып, шул түмгәкне әйләнеп узалар икән. Якынрак килеп туктасам, ни дип әйтергә дә аптыраш. Юлның иң хәтәр җирендә, нәкъ уртасында, үзенең кызгылт көрән тунын ябынып, безнең төбәк халкының горурлыгы, намус сафлыгы суыр, ягъни байбак галиҗәнаплары утыра. Чү! Чүгез әле! Китапларда кыргый җанварлар исәбендә йөрсәләр дә, беркемгә мыскал зыян-зарар итмичә, киресенчә, туган як табигатен аерым бер матур төсмер белән бизәп, баетып яшәгән әлеге җан ияләренең берсе — байбак хәзрәтләре — әлеге хәтәр юл чатына ни дип чыгып утырган?

Аз гына саксызлык күрсәтсә дә, машиналарның аны шундук бәреп китүләре мөмкин. Кузгалырга да җыенмый бугай. Бик ипсез рәвештә арт аякларына чүккән. Башта мин аны бик дәрәҗәле шахмат турнирларында катнашучы, үтә хәтәр йөреш алдыннан тирән уй, исәп-хисапка, анализга чумган гроссмейстерга охшаттым, әй. Ниндидер отышлы йөреш алдыннан берәр сәгатьләргә тирән уйларга чумып утырган шахмат осталарын күп тапкырлар күргәнем булды. Бу затлы уенны үзем дә бик яратам, күп еллар рәттән шахмат клубына йөрим. Әлеге суыр да нәкъ менә аларча, нәкъ гроссмейстерларча, ике алгы тәпие белән башын, битен, күзләрен каплаган. Бүгенге реаль чынбарлык аның өчен әллә бар, әллә төпсез бушлык. Мин аптырашта.

Тукта, исән-имин тере җанмы соң бу? Әллә берәрсе шаярып ташлап калдырган плюш курчак, манекен-мазармы? Тересен тере икән. Әмма бик тирән кайгы кичерә бугай ул, бичаракай. Машинамны бер читтәрәк туктатып, якынрак килмәк булдым. Килсәм, абау, абау! Ни күрәм! Асфальтта, әнисе каршында, йомшак, матур тәпиләрен як-якка ташлап, аның нарасые ята. Гәүдәгә өч-дүрт атналык песи баласы кадәр генә булыр. Курчак та курчак, суыр баласы да курчак. Күтәреп кулыңа ал да куеныңа тык, сыйпа, иркәлә. Борын очыннан гына пәп итеп ал.

Байбак баласын берәр машина бәреп киткән, ахры. Карап торырга болай чәчрәп каны чыккан җире дә, изелгән-тапталган төше дә күренми. Хәер, реактив самолетлар тизлеге белән чапкан машиналарның җиле генә тисә дә, бу нарасыйны бәреп ташларга күпме кирәк соң? Ә юлга чыккан халык кууын белә шул. Элдертә генә. Халык үзе дә чебен кебек кырылып тора бит. Кырыла тора, котыра тора. Юл фаҗигаләренең чутын алып бетерешле түгел бит.

Ана суыр, бичаракаем, тирән кайгыда. Тәмам башын җуйган дәрәҗәдә.

— Йә Ходай! Күр инде бу хәлне! — дип ыңгырашып куйдым үзем дә. — Бик аңлыйм, хөрмәтлем, хәлеңне. Башыңа килгән бу олы кайгыңны ихлас уртаклашам, җанашым, — дип, кул сузар ара якынлаштым.

Әлеге трассаның бу өлеше аеруча катлаулы. Мөгезсез сыер төсле, уңнан да, сулдан да көтмәгәндә генә аңа тагын ике авыл юлы килеп кушыла. Җитмәсә, юлның ике ягында кыр ышыклау каеннары җилферди. Аларсыз да булмый. Кышын бу тирәләргә, үч иткәндәй, бөтен котып патшалыгының карын китереп өя. Ике бульдозер, моторларын тәүлек буена сүндермичә, юлны көнен-төнен чистартып торсалар да, таман гына була. Шушыларның барын искә алып, юлны караучылар трассаның ике ягына да «Бу юлны еш кына пошилар, боланнар, кыр кәҗәләре, кабан дуңгызлары, бүреләр, төлкеләр, хәтта куркак куяннар да кисеп чыга. Машина руле артында утыручылар! Берүк игътибарлы булыгыз!» дигән кисәтүләр язып элгәннәр.

— Бу кисәтүне әллә без, кешеләр өчен дип кенә белдегезме? Сез, байбаклар өчен дә бит ул. Бу трассаны кичкәндә әнә шул щитларга күз салган булсаң соң, — дип, авыз эчемнән сөйләнеп, тирән кайгы-хәсрәт эчендә утырган байбак алдына килеп чүкмәк булдым.

Бәхәссез, биредә икенең берсе булгандыр. Әлеге ана суырның бик иркә, кечедән үк үзсүзле улы юлның теге ягына үзе генә чыкмак булгандыр. Шунда үзен яшен угы тизлеге белән чапкан берәр машина бәреп киткәндер.

Кем белә, әллә байбак үзе: «Балакаем, без яшәгән дөнья бик зур, чиксез киң бит ул! Менә мин сиңа, нәнием, торган-яшәгән җирләребезнең әнә теге ягындагы өлешен дә күрсәтим әле. Андагы хозурлыкка күрсәң исең китәр», — дип, улын кулыннан җитәкләп, теге якка алып чыкмак булганмы? Шунда өсләренә машина килеп чыккан да, болар юлны чыгып өлгермәгәннәрме?

Ике арабыз ана байбакны үрелеп башыннан сыйпарлык кына калгач, ул, кисәктән генә исенә килеп, юл читенәрәк йөгерде. Ә баласы аның алдында теп-тередәй курчак булып ята. Чын шулай, кулыңа ал да күкрәгеңә кыс. Йомшак кына йон чыгарга өлгергән нәни тәпиләре дә бик матур. Дөресе шул: аңа әле күп булса ай ярымнар гына булгандыр. Чөнки бу әле табигатьнең җәй капкасын каерып ачып кергән чаклары гына. Ә байбаклар салкын кышны татлы йокыда, туң-суыклар төшеп җитмәстәй итеп бик тирән казыган өн-ояларында, кайчакларны күбәүләп, ә кайчакларны җан сөйгән ярлары белән икәүдән-

икәү генә дә уздыралар. Кышкы йокыга алар сентябрь ахырларында ук яталар. Ә яңадан өскә, җир өстенә, озын кыш узгач, җирләр кардан арынгач, апрель башларында гына чыгалар. Йокы бик яратучыларга карата русларда хәтта «спит как сурок!» дигән әйтем дә бар. Алар бу әйтемне бер дә юктан гына чыгармаганнар. Суырлар йокының тәмен чыннан да бик беләләр. Өннәренә бер кереп яткач, уянмыйча җиде-сигез айлар йокларга тик алар гына булдыралар. Йоклаган чакта ачка үлеп китмәс өчен, җәй эчендә кышкылыкка май запасын да бик мулдан туплыйлар.

Әнкә байбаклар еш кына өннәреннән үк авырлы булып чыгалар. Бәбәйләрен карыннарында алты атналар, төгәлрәге, нәкъ кырык ике көн йөртеп, елына бер генә балалыйлар. Бер тапканда гадәттә өч-дүрт, ә кайчакларны хәтта җиде бәби дә китереп куялар. Әнә асфальтта яткан нарасыйга да, әйе, нәкъ ай ярымнар гына тирәсе. Чалт иткән кояш астында теп-тередәй ята ул. Кызганыч! Бик кызганыч! Ләкин башны ташка орасыңмыни? Ташка орып та ни файда?..

Үзем дә, баскан җиремдә чүгә төшеп, тирән уйга калдым. Башы-аягы белән бер су чиләгенә сыеп бетешле җан иясе, байбак кына димәссең. Күр әнә, нинди тирән кайгыга төшкән. Ничек сыгылып сыкрана. Аны күреп, аның кичерешләрен үз йөрәгем аша уздырып, мин дә үземне кая куярга белмим.

Әлеге бала байбакны да шушы килеш, юл уртасында калдырып булмый бит инде. Йә бөтенләй сытып ук китәрләр. Юл читендәрәк куе үлән өстенә целлофан пакет җәйдем. Балакайны шунда күчердем. Әнисе дә ерак китмәгән. Шунда, үлән арасында гына кыштырдый. Аннары кыю рәвештә баласы яткан пакет янына килеп утырды.

— Хәлеңне бик аңлыйм, хөрмәтлем. Ләкин шушыннан да гайре сиңа тагын ни генә эшли алам? Кулымнан килсәме? Балакаеңны да терелтеп биргән булырыем... Үлгән артыннан үлеп булмый. Түзәргә туры килә... Үзеңне кулга ал... Бу килештән үзең дә харап булып куйма, — дип сөйләнәм.

Ана байбак үзе:

— Бигрәк яраткан балам иде... Аның урынына үзем үлгән булсамчы, — дип өзми-куймый сыкрана төсле.

Суырлар алар туган як табигатебезне, аның кыргый җәнлек-җәнварлар дөньясын үзләренең барлыклары белән бизәүчеләр. Кешеләр белән дә янәшә бик тату һәм тыныч яшиләр. Күрер күзгә дә матур, сөйкемле, гөнаһсыз җан ияләре.

Узган җәйне шулай күп балыкчылар аның дөньяда барын да белмәгән бик матур бер түгәрәк күлгә барып чыктык. Советлар Союзы Герое Газинур ага Гафиятуллинның туган авылы Сугышлыдан күп булса ун-унике чакрымнар читтәрәк, үзебезнең Татарстан биләмәләре бетеп, күрше Самара өлкәсе башланган төбәктәрәк. Табигатьнең гажәеп бер матур, тын бер почмагы бу. Барып чыксаң, кире китәсең килмәс. Янымда төбәгебезнең танылган рәссамы Яскәр Зиннәтуллин да бар. Әлеге искитмәле матур күренешләрдән илһамы кабынып, ул шунда ук этюднигын, мольбертын алды. Ә мин, кармаклар салып, әллә ни арада гына ярты чиләк чамасы алтын-көмеш тәңкәле симез чабаклар чүпләргә өлгердем.

Бу гүзәл тарафтан безгә көнозын елмайган кояш каршы яктагы тау артына тәгәри башларга җыенгач кына чыктык. Яссы гына тау бите буйлап кайтабыз. Шунда һич көтмәгән җирдән байбаклар колониясенә юлыктык. Ындыр табагы хәтле генә мәйданда илле-алтмышлап байбак көн күреп, нәселыру үрчетеп ятмышлар. Араларында әллә моңарчы Кеше дигән олуг затны күрмәгәннәре дә бар? Булыр да. Олы юл өсләреннән шактый читтәге бик аулак почмак бу. Әлеге байбакларның күбесенә кешедән курку хисе дә ят сыман. Прәме машина көпчәге астына керәләр. «Биип! Биип!» кычкыртуыңа да әллә ни исләре китми. «Жигули»ны туктатып, ике ян як ишекләрен дә ачтык. Бармак яныйм. Исләре китә бик. Бу очракта без, кешеләр, алар өчен кызык объектлар.

— Кая, килегез әле монда. Булмаса, берәрегезне алдыма алып сөйим, яратыйм, — дим. — Ягез, кыюрак булыгыз!

Байбаклар, күзгә карап:

— Акылың алтын икән, агай! Эләктереп алырыең да, машинаңа салып, әллә кайларга алып китәриең. Тотмый гына тор әле, яме! — дип елмаешалар.

Өсләренә килә башласаң, тәмам май баскан арт якларын көчкә генә өстерәп, читкәрәк күчеп утыралар. Күзләрендә, йөзләрендә безне күрүдән исләре китеп гажәпкә калу хисе. Машинага кереп утырсак, аны янәдән сорып алалар.

Без, янәдән ишекләрне ачып:

— Айть! Айть! Шунда берәрсен арт тәпиеннән генә эләктереп алам бит. Айть! — дип шаяртабыз, кул шапылдатабыз.

Шаярганны күрәләр. Бездән мыскал да шикләнмиләр.

Шушы сөйкемле җан ияләре, фәнчә атасак, кимерүчеләр отрядына керешле Мармота Муллер. Тиеннәр гаиләсен тулыландыручы саналган Скиридае Статус, ягъни Европа байбагы, үзебезчә атасак, Суыр галижәнаплары, унсигезенче гасырга кадәр Рәсәй биләмәләрендә күп булган. Танылган галим-зоолог Э.А.Эверсман «байбаклар Идел елгасы буйларында, Буа уезды каласыннан алып Саратовка хәтле бик еш очрый» дип язган.

Әмма шунысы бар: суырларның ите тәмле, шифалы гына түгел, аның тиресе дә затлылардан йөри. Шунлыктан аларны браконьерлар һәркайда рәхимсез кырганнар. Әүвәлге СССР биләмәләрендә ул хәзер бөтенләй диярлек юк. Гәрчә дәүләт аны бик ныk сак астына алса да. Әлбәттә, зур сөенечкә, суырлар безнең Татарстаныбызның көньяк-көнчыгыш районнарында гына сакланып калган. Бу юлларны мин дә зур горурлану хисе белән язам.

Суырлар ыру-нәселләргә берләшеп, колонияләр корып яшиләр. 1991 елда махсус тикшерү-барлау нәтиҗәсендә безнең Татарстаныбыз биләмәләрендә суырларның илле өч колониясе барлыгы ачыкланган! Шуларның утыз бере Азнакай районында! Җирле халык бик әдәпле, динле булганлыктан, байбаклар Лениногорск районы Сугышлы, Юлтимер, Чыршылы, Урмышлы авыллары тирәләрендә дә бик рәхәтләнеп үрчиләр, яңадан-яңа колонияләр төзиләр.

Әледән-әле үрчеп торган суыр колонияләре — Азнакай төбәгенең, шушы тарафларда әвәл-әвәлтеннән гомер итеп, мул уңыш үстереп, күп итеп аяклы мал асрап яшәп яткан тырыш халыкның киерелеп бер мактана алырлык горурлыгы! Шушы райондагы, диңгез өстe тигезлегеннән 380 метр биеклеккә ашып утырган мәһабәт Чатыр-тау битләрендә генә дә суырларның сигез колониясе бар. Һәр колониядә аларның баш саны дүрт йөзләрдән ким булмый. Биредә чын мәгънәсендә — Тыюлык! Яссы тау битләрендә чәчелешеп көн иткән, уйнаган, әрле-бирле чабышкан суырларны беркем дә борчымый, тыймый, аларга янамый.

Дәүләт тарафыннан да ныклы саклау чаралары күрелгәнлектән, суырлар бөтен республика буенча да ныk үрчи башладылар. Бүгенге көндә Татарстаныбызда аларның баш саны егерме биш меңнәрдән өстә исәпләнә. Үзем исә тагын да күбрәктер дип исәплим. Узган елны җир җиләгенә йөргәндә, аларның яңадан-яңа, моңарчы исәптә тормаган колонияләренә юлыктым. Көтмәгәндә генә өсләренә барып чыгам да үзем дә аптырап калам. Оялары алдына тезләнеп, кулларымны бутап-бутап сөйләп гафу үтенәм. Тынычлыгыгызны бозган булсам, бер юлга кичерегез инде, дим. Туган як табигатебезнең фаунасын үзенә бер матур төс белән бизәүче, баетучы бу изге җаннарны бүгенге егерме беренче гасыр шартларында үрчетү, саклау шушы сүзнең иң тулы мәгънәсендә зур культура, милли горурлык! Икенчедән, төбәк халкының милли йөзен, аның шәфкатен, мәрхәмәтен, уңганлыгын, булганлыгын, үз җирендә иман белән яшәвен кызыл сүзләрсез дә раслый торган искитмәле матур бер төсмер! «Менә ичмасам минем халкым!» дигән горурлык хисе күңелдә үзеннән-үзе туа!

Шулай димәскә соң! 1920–1921 елларда бөтен Идел буен сарган коточкыч ачлык елларында ите тәмле, тиресе затлы байбакларны бар җирләрдә тәмам нәселе юкка чыгышлы дәрәҗәдә кырып, ашап бетерәләр. Ачлык — һәр тере җан өчен коточкыч халәт. Аны кичергән зат хәтта акылын җуя. Баласын тотып ашый. Бу халәтне беребезгә дә татырга, кичерергә язмасын.

Әмма шунысы бар: шул авыр елларда да, берән-сәрән генә булсалар да, суырлар тик татар авыллары тирәләрендә генә сакланып калганнар. Ә сере бик тирәндә. Суырлар, әйтәм бит, күрер күзгә дә бик сөйкемле, беренче күрүдә үк күңелдә иң матур, иң җылы хисләр уятырга сәләтле җан ияләре. Аларны шунда ук алдыңа алып, йомшак йоннарыннан сыйпап сөясе, иркәлисе килә. Алар чисталыкны бик яраталар. Һәр көн иртән, бик тирән итеп казыган өннәреннән өскә чыгып, оя авызына утырып, кояшка карап, алгы тәпиләре белән битләрен, колакларын сыпыра-сыпыра бик озаклап чистарыналар. Битләрен юалар. Әгәр инде читтән карап торсаң, кара, күр әле, Ходайның бу җан ияләре бик динлеләр икән, иртән торып өннәреннән чыгу белән озаклап иртәнге намазларын укыйлар лабаса, диярсең. Нәкъ шулай инде. Шунлыктан татарлар суырларны мөэмин-мөселман өммәтеннән булган динле, иманлы һәм изге затлардан санаган. Җирле халык ачлыкка интексә дә, коточкыч һәлакәтләр кичерсә дә түзгән. Суырга кагылмаган. Ярамый! Табу! Изге затларга кагылсаң, кулың гына түгел, нәсел-нәсәбең, ыруың корыр! Андый кыргыйлыкларны кылудан Хак Тәгалә үзе саклый күрсен, йа Раббым! Татарлар яшәгән авыллар тирәсендә әвәл-әвәлтеннән суырларга кул күтәрмәгәннәр, аларны рәнҗетмәгәннәр.

Байбаклар чыннан да мыскал гөнаһсыз, мәһлук бер җан ияләре.

Галим агайлар аларны кимерүчеләр отрядларына кертсәләр дә, нәрсәне дә булса ялгыш кына кимереп, бозып, һичберәүгә, һичкемгә мыскал да зыян китергәннәре юк. Чәчкән игеннәргә дә, ашлык-мазарга да якын да килмиләр. Бөртеклеләрне гомумән ашамыйлар. Алар нәрсә ашап, ни белән генә туенып торалар соң? Үләннәр белән! Галим-зоологлар аларның ашказанында утыз җиде төрле үлән тапканнар. Алар барысы да болын, тау бите үләннәре. Әмма аларның ашказаннарында ник бер бөртек солы, тары, бодай, борчак булсын.

Аннары алар бик өй җанлылар. Суырларның берсе дә өннәре тирәсеннән ике йөз метрлардан да ары читкә китмиләр. Шул оялары-өннәре тирәсендәге үләннәр белән тукланып көн итәләр. Алай гынамы?! Шул үләннәр белән тукланып бер дә галәмәт симерәләр әле. Җиде-сигез ай буена бер кузгалмый йоклап чыгарга җитәрлек май запасы туплыйлар.

Аларга карата соклану, мактау сүзләрен күп сөйләргә була. Суырлар ояларын-өннәрен сөрергә, ни дә булса чәчәргә яраксыз уңдырышсыз, хәтта көтү йөртергә дә уңайсыз, ташландык җирләргә, таулы-ташлы яссы тау битләренә казыйлар. Колонияләре өчен дә шундый җирләрне сайлыйлар. Өлкән туганнары, без, кешеләр тарафыннан, бу килмешәкләр үзләренә оя-нигез кору өчен нинди уңдырышлы

чәчүлекләребезне биләгәннәр, бу тарафларга сезне шайтаным чакырып китердеме, әллә кул болгап дәштеме, дип әйтергә алар беркайчан да җирлек бирмиләр, урын калдырмыйлар. Бер уйласаң, искитмәле хәл бит! Кыскасы, игелеклеләр!

Колониянең һәр метр җире төгәл учетта. Аның һәр чигендә үткер күзле, үткер колаклы суыр егетләре сакта, кизүдә торалар. Алай-болай колония биләмәләренә көтмәгәндә генә кем-мазар килеп чыкса да, дозорда торган суырлар шундук ачы итеп сызгырып җибәрәләр. «Тревога, җәмәгать! Безгә куркыныч яный! Сак булыгыз! Кардәшләр, барыгыз да өннәрегезгә кереп яшеренегез!» дип кисәтү була бу. Шушы сызгыру яңгырау белән колония биләмәләрендә һәркайсы үз эшләре белән мәшгуль өлкән байбаклар да, татлы уеннарын уйнап, кояшта кызынучы яшь җилкенчәкләр дә шундук бар эшләрен ташлап өннәренә йөгерәләр.

Сакта торган суыр егетләре сине нык күзәтәләр. Өйрәнәләр. Колония биләмәләренә килеп керүченең кыланышында усал ниятләр күрмәсәләр, бераздан «отбой» сызгыралар, суырлар ояларыннан чыга башлыйлар. Кайчакларны хәтта сиңа җиде-сигез адымнар гына калдырып якынаялар, кызыксынып сине күзәтәләр. Алар да безне, кешеләрне, ниндидер бер кызык һәм сәер җан ияләре итеп саныйлар төсле. Безнең ниндидер гамәлләребезне алар күзлегеннән караганда ахмаклыкка санап, кайчакларны бездән тәгәри-тәгәри көләләр дә төсле. Әйтик, без, кешеләр, арт аякларыбызга басып йөрибез. Озын аяклылар. Алар өчен бик сәер бу. Шуннан соң безгә ни файда? Ә байбакларның аяклары әнә ничек кыска. Әмма без аларның бер генә малаен да куып тота алмыйбыз. Алар өчен чыннан да чын көлке бит бу! Тәгәрәшеп көлмәскә соң!

Бер матур җәйне, «Ватаным Татарстан» газетасының үз хәбәрчесе булып эшләгән чагымда, мине бик кызу урак өстендә Тымытыктан унбиш чакрымнар читтәге кыр станына төшке ашка алып бардылар. Тирә-якта хәрби аэродромнар төзүчеләр бер күрүдә кызыгырлык очсыз-кырыйсыз тигезлек. Иген кыры, бодай басуы! Әлегә аяз торган көннәрнең кадерен белеп, берьюлы сигезләп комбайн уракка төшкән. Алар суктырган ашлыкны унлап «КамАЗ» тыз да быз ындыр табагына ташып торалар. Биш-алтылап трактор басуның урылган өлешен шунда ук туңга да сөреп киләләр. Алдынгы хуҗалык бу! «Авангард» исемен йөрткән бу хуҗалыкта кыр эшләренең һәркайсын үз вакытында башкарып киләләр.

Әле пилорамнан гына чыккан, гаять тәмле хуш исле такталардан ясаган озын өстәл артына төш вакытында ким дигәндә егерме-утызлап механизатор утыра. Алар башта бер-берсенең җилкәсенә чүмеч белән салкын су коеп, пошкыра-шаярыша юынып алалар. Белепме, әллә күреп өлгермичәме, кыр станын бу юлы ишле генә байбаклар колониясе өстенә корганнар. Әйе, зур гына колония бу. Аның хуҗалары баштарак механизатор егетләрдән курыккан булганнардыр. Аннары күнеккәннәр, ахры. Механизаторлар гөр килеп шаярышып төшке ашка утырышкач, байбаклар да өстәлдән күп булса ун адымнар гына читтәрәк бер түмгәкле төшкә җыйналышалар. Стадионда футбол матчын карарга килгәннәрме диярсең. Комбайнчыларны, «КамАЗ» йөртүчеләрне күзәтәләр. Бер карасаң, үзләрен тотышлары белән авыл малайларын да хәтерләтәләр. Авылга цирк-мазар йә Казан артистлары килсә, алар да шулай җыйналышып, бераз сәерсенеп, бераз шикләнебрәк тә кунакларны күзәтәләр бит.

Карыннары нык ачкан, бу минутта ашау белән мәшгуль егетләрнең берәрсе аларга йә күмәч сыныгы, йә берәр телем кыяр ыргыталар. Ипи телеменә суырларның берсе дә якын килми.

— Без бирегә сездән ризык өмет итеп җыйналышмадык бит, агайлар. Сезне якыннанрак күрергә, башкарган, кылган гамәлләрегезне аңларга тырышып килдек. Күреп торабыз, арыгансыз. Ашыгыз тәмле булсын! — дигән төс чыгарып, тын гына утыра бирәләр. Үз сүзләреннән үзләре ямь табып, юмор чыгарып, мөгер-мөгер киләләр, бераз көлешеп тә алалар бугай.

Механизатор егетләрнең берәрсе алар өстенә берәр чүмеч салкын су бөркесә, сәер авазлар чыгарып чукыр-чукыр килешәләр, шаяруны килештерәләр. Егетләр ашап-туеп эш урыннарына таралу белән, байбакларның да «чираттан тыш корылтайлары» ябыла, алар да таралалар.

Кыр станы болай бик матур төштә. Бер читтәрәк дүрт-биш төп карт өянке утыра. Аның төбендә һәрчак ике самавыр кайнап тора. Теләсәң, чәеңне шул өянкеләр төбенә җәйгән паласка кырын ятып эчә аласың. Өянке төбендә кайнаган чәйне аеруча өлкәнрәк механизатор агайлар тәмләп эчәләр. Станның аргы башында матур гына чишмә саркый. Аш пешерүче кызлар чәйгә суны шул чишмәдән алалар. Ә көрәк очы белән генә буып куйган җиренә барып, савыт-саба юалар. Шунда барган чакны да куе үлән арасыннан байбаклар күренеп-күренеп китәләр. Кайберләре хәтта аяк арасыннан чабып узалар. Бер уйласаң, бу изге җаннарны күптән инде кулга ияләштерергә дә булыр иде. Кәҗә-сарыкны ияләштергән кебек, аларны да нигә ияләштермәскә? Тамакларын үзләре туйдыралар. Кышка да азык әзерлисе юк. Сентябрь башларында ук йокларга яталар да, җир өстенә апрель башларында гына торып чыгалар.

Юк шул, булмый икән. Беренчедән, алар тик нәсел-ыру белән берләшеп яшиләр. Кулга ияләштерсәң, дүрт-биш йөз башны кайда, ничек асрыйсың? Яшәү, тереклек итүләре бөтенләй башкача бит. Аларга тереклек итү, нәсел-нәсәбен үрчетү өчен таулы-ташлы яссы тау битләре, тирән итеп өннәр казырлык тын урыннар кирәк. Хәер, үзем дә аларның беркем кубызына да биимичә, үзләренчә, иректә, азат булып яшәүләрен хуплыйм. Азатлыкта, иминлектә яшәүгә ни җитә!!!

* * *

Әлмәткә барып әйләнгәнче, йомышларымны юллаганчы өч-дүрт сәгатьләр генә узгандыр. Килгән юлым белән үк кайтырга да чыктым. Машинамны янәдән бая байбакны калдырган җиргә үк китереп туктаттым. Килсәм, исләрем китте. Ана суырым, башын-битен, бөтен йөзен алгы тәпиләре белән кочкан килеш, иң соңгы йөреш алдыннан тирән уйга чумган гроссмейстер кыяфәтендә, һаман да баласы каршында утыра. Инде көнозын кояш астында яткан «курчагы» өстенә кырмыскалар үрмәләгән, чебен-черки, башка бөҗәкләр кунган. Әнисе шуларны берәмтекләп-берәмтекләп кенә чүпләп читкә бәрә.

Бу юлы ул мине әллә таныдымы, мине күрү белән читкә йөгермәде. Бәхетсез ананың йөзен шулхәтле тирән кайгы, борчу баскан, аны сөйләп бирешле түгел. Кулга алдырса, иркәләп, башыннан сыйпап, хәленә керер идем.

Бер араны ул бөтенләй тын калып, икенчесендә бик тирән итеп сулыш ала.

— Синең урыныңда, балам, күз нурым, үзем генә үлгән булсамчы! Бигрәк ярата идем бит үзеңне! — дип сыкрап-сыкрап ыңгыраша иде бугай ул.

— И-и, суыркаем, сиңа нинди генә җылы сүзләр әйтеп, нинди генә тылсымлы гамәлләр кылып юатыйм икән соң? Үлгән артыннан үлеп булмый бит. Башыбызга мондый кайгы-хәсрәтләр килгәндә безгә, бәхетсез ата-аналарга, тешебезне кысып булса да түзәргә, түзәргә генә кала инде, җанашым. Үзең турында да уйла. Әнә теге куелыктан төлке-мәлгунь килеп чыкмасын. Синең итеңне бик ярата булыр ул. Тәмам башыңны җуйган, бик кайгылы чагың дип тормас, тотар да ботарлар. Тилгән-карчыга да, бер каныгып алса, чукымаган бер җиреңне калдырмас. Соңгы вакытларда алар да нахалның нахалына әйләнеп баралар.

Бу суырда кешеләр акылы гына түгел, академиклар зиһене дә бармы диярсең. Ул сул күзе белән генә миңа бик мәгънәле итеп карап алды.

— Рәхмәт, бик рәхмәт инде, агаем, хәлемә кергәнең өчен! Син әйткәннәрне дә бик аңлыйм. Нишлим соң? Шушы кызымның, бердәнберемнең, мәрхүмә булуына, күз алдымда җансыз ятуына һич ышана алмыйм. Ташлап та китә алмыйм. Менә торыр да йөгереп китәр дип көтәм. Бик чая бала иде. Үлеп ярата идем үзен...

— Син, хөрмәтлем, алай тәмам бирешмә инде. Торган-яшәгән җирең бар. Җылы ояң-өнең. Дус-иш, кардәшләреңбардыр. Бу кайгыңны алар да күтәрешерләр. Әнә күктә назлы кояш елмая. Бирешмә берүк, — дип, кулдан килгәнчә юатырга тырышып, машинама таба атладым.

Юк, болай гына китеп булмый икән. Багажнигымнан көрәк алдым. Шунда, юл читендә, бер яшь кенә чыршы төбендә көрәк очым белән генә кабер ачтым. Ана суырның һаман да курчак булып яткан нәниен, целлофанга төреп, әлеге кабергә иңдердем. Нишлисең? Болай калдырып китеп тә булмый бит. Икебез өчен дә иң авыр минутлар булды бу.

Инде кайтырга чыккач та күңелне биләп алган борчулы уйлардан арыну җиңел булмады. Безнең бүгенге буын тереклек иткән замана көннән-көн кырыслана бара. Табигатьнең кануннары буенча аналарны балалары җирләргә тиеш бит. Ә хәзер еш кына киресенчә була. Кешеләр арасында да шулай бит. Цинк табутларны кочып, чәчләрен йолкый-йолкый елаган аналар азмы хәзер? Көндәлек тормышта ямьсез, әдәпсез яшәү рәвешләребез белән без кемнең ачуын куптардык? Кемне рәнҗеттек? Кем каргышларын күрәбез? Бездән кем шулай рәхимсез үч ала? Бу сорауларга тиз генә җавап табышлы да түгел. Андый чакларны гарәп туганнарыбыз, авыр сулап: «Вә Аллаһе әгъләм биссавәб!» — дип куялар. «Бу турыда чын хакыйкатьне Хак Тәгалә үзе генә белә булыр» дигән мәгънәне белдерә бу сүзләр безнеңчә. Әйе, нәкъ шулай шул.

Тормыш мәктәбе

Ул үзе сыңар биялә хәтле генә. Барыбыз да бик яраткан, бик иркәләгән шушы көчегебез Муйнак курчак өедәй матур оясы алдына чыгып яткан да бар дөньясын онытып сөяк кимерә. Сөяге сеңерле, чат җелек кенә. Каршыдагы алма ботагына кунган дүрт саескан шуны бик кызыгып һәм дә көнләшеп карап тора. Чат сеңер, эче тәмле җелек белән тулы сөякне, йә әйтегез, кем генә яратмый инде аны! Беләсез микән, хәйлә-мәкерлек коруга килгәндә саесканнар төлкедән бер дә калышмыйлар. Күреп торам, менә бу юлы да көчекне ничектер алдау, тәмле сөякне кулга төшерү турында исәп корып утыралар. «Муйнак, сак бул, болар сине кызык итәргә җыеналар», — дип әйтергә дә уйлыйм, араларына керүне дә килештермим. Ул арада саесканнар, сүз куешкандай итеп, серле генә каркылдашып алдылар.

— Тәвәккәлләдекме, җәмәгать? — диде, ахрысы, арадан берсе, өлкәнрәк күренгәне.

— Килештек! — дип куәтләде аны калганнары да.

Боларда әйткән сүз — аткан ук икән. Саесканнар бик тәвәккәл кыяфәттә дүртесе дә шунда ук җиргә сикерделәр. Терт-терт килеп, дүртесе дүрт яктан көчеккә таба якынлаша башлады. Дөнья күрмәгән,

тормыш тәҗрибәсе булмаган, моңарчы алданып авызы пешмәгән Муйнакка бу бик кызык тоелды. Әһә, аның белән әнә кемнәр уйнарга тели! Көчек, сөяген онытып, боларны күзәтә башлады. Ә саесканнар вак-вак адымнар белән сикергәли-сикергәли якынлаша бирделәр. Муйнакның күзендә шаян чаткылар ялтырый. Эчендә хисләр ташкыны. «Ау! Ау!» Әмма саесканнар көчек аларны бер сикерүдә эләктерер арада туктап калдылар. «Боларның соң башта кайсысын эләктерергә?» Муйнак, шашып типкән йөрәген тыеп, як-ягына карап алды.

— Ау! Әһә, менә монысы иң якыны! Башта шунысын эләктерим!

Бу сәер җан ияләренең берәрсен эләктерәчәгенә, аның белән рәхәтләнеп уйнаячагына көчекнең аз гына да шиге юк иде. Боларны тоту аңа берни тормый. Муйнак үзенә якын торган саесканнарның берсе өстенә сикерде. Күреп торам, алар моңа күптән әзер. Хәйләне дә нәкъ менә шуңа исәп тотып корганнар. Саескан шунда ук ярты адым гына читкә күчеп утырды. Көчек тагын сикерде. Саескан аны тагын да читкәрәк алып китте. Ә ул арада калган өчесе, бик әйбәтләп кенә сөякне эләктереп, агач башына кунды. Үзен ничек оста алдауларын Муйнак шунда гына төшенде. Кызганыч шыңшып, минем янга йөгереп килде. Күзләре белән алма ботагына, анда утырган саесканнарга ымлап, ярсып-ярсып өрергә кереште. Янәсе, әнә алар, оятсыз караклар, минем сөякне урлаучылар!

— Инде эш узгач, тавыш куптарудан файда юк, — дим мин аңа.— Аннары, беләсеңме, дөнья, тормыш дигәнең шундый катлаулы нәрсә ул, Муйнак туганкай. Авызың бер пешми торып, аны аңларга һич өйрәнә алмыйсың. Ачы тормыш мәктәбе менә шул була торгандыр инде ул.

Муйнак шундук өрүдән туктады. Йонлач башын аз гына кыйшайтып, очлы борынын тагын да суза төшеп, миңа төбәлде. Дошманга нәфрәтле, ә дусларына чиксез мәхәббәтле нәни йөрәгенә мин сөйләгәннәрнең барын да чәчми-түкми сыйдырырга, һәммәсен дә аңларга, төшенергә тырышып утыруы иде бу аның.

Үтерә күрмәгез!

Урамга гына күз салыгыз әле. Бүген анда нинди матур, нинди җылы, кояшлы көн! Бакчаларда, паркларда пионнарның, гладиолусларның, розаларның һәм башка бик күп гөлләрнең шау чәчәктә чагы. Әнә түп-түгәрәк, сип-симез төклетураларны гына күр син. Тамак төпләреннән чыгарган тавышлары үзләреннән зур. Әллә каян ук ишетелә. Жу да жу килеп әле бер чәчәккә куналар, әле икенчесенә күчеп утыралар. Чәчәк түтәлләре өстендә төрле төстәге күбәләкләр тирбәлә. Без яшәгән, ягъни тереклек иткән табигатьнең гүзәллегенә сокланып туймассың. Менә ачык тәрәзә аша сезнең бүлмәгезгә бер бал корты очып керде. Ә сез зур гауга куптардыгыз: өегезне су баса башлаган яисә янгын чыккан диярсең.

— Тотыгыз үзен, тизрәк тотыгыз! Үтерегез! — дип кычкырыша башлыйлар бүлмәдәгеләр барысы беравыздан. — Үтерегез үзен тизрәк! Югыйсә ул безнең барыбызны да чагып чыгар!

Нәни дусларым! Ашыкмагыз! Үтерә күрмәгез ул бал кортын. Зинһар, эшли күрмәгез бу вәхшилекне. Югыйсә сез Табигать-анабыз каршында зур җинаять кыласыз.

Сезнең бүлмәгезгә ялгыш кына килеп керүенә бу бичара корт, бәлкем, үзе дә нык үкенә торгандыр. Аның безләве шундый шау-шу кубарыр дип башына да китермәгәндер. Сезнең бүлмәдән килгән үзләре сәер, үзләре серле тоелган исләргә алданып кергәндер ул. Ә бәлкем, иң изге ниятләр белән кергәндер. Тәрәзә төбегездә утырган гөлләрне күргәндер дә кызгангандыр, аларны серкәләндереп чыгарга булгандыр. Ә кем белә, бәлкем, ул кортларны бүлмәгә әлеге гөлләр үзләре кунакка дәшәдер? Анысы да бик мөмкин. Кызганыч, аларның телен аңламыйбыз. Югыйсә күп нәрсәләргә төшенер идек.

Сезнең бүлмәдә купкан әлеге шау-шудан бал корты үзе дә каушап калган. «Бу бүлмәдән ничек кенә исән качып котылыйм икән? Мин кергән ачык тәрәзә кайда соң ул?» — дип без-без килә.

Ачык тәрәзәм аша алар минем бүлмәмә дә еш очып кергәлиләр. Керүен-керәләр, ә чыгар юл тапмыйлар. Эчкә кергәч әллә башлары әйләнеп китәме? Шөбһәле аваз белән безелдәп, кабаланып, чыгар юлны эзли башлыйлар. Андый чакта мин буш шырпы тартмасын алам. Бал корты тәрәзә пыяласында чәбәләнгән чакта, саклык белән генә аның өстенә буш тартманы каплыйм. Кортны ипләп кенә шул тартмага кертәм. Аннары, тартманы балконга алып чыгып, кортны үз иркенә җибәрәм. Рәхмәтле җан тартманың капкачын ачкач та очып китәргә ашыкмый әле. Алгы тәпиләрен бер-берсенә ышкып, ике нәни мөгезен як-якка йөртеп нидер сөйли, без дә без килә. Әлбәттә, рәхмәтен белдерә. Үзең дә исән бул, сау-сәламәт яшә, ди төсле.

Әйтик, менә сез дә бүлмәгезгә очып кергән бер бал кортын шулай коткардыгыз ди. Белегез, бик тә изге эш эшләдегез. Чөнки шушы нәни генә бал корты да тере җан иясе. Ул да, безнең кебек үк, тормышны ярата, чыккан кояшка сөенә. Бәләкәй генә бал корты да — Тереклек! Ә Тереклеккә һич-кайчан кизәнергә ярамый. Сез аны нинди генә рәвешләрдә, килбәтләрдә, сурәтләрдә очратсагыз да, Тереклекне яшәүдән мәхрүм итәргә ярамый. Моңа берәүнең дә хакы юк.

Менә шул күренешне күз алдына китерик әле. Бакчабызда, урман аланында йә болын түрендә барыбызга яхшы таныш гап-гади тузганак үсеп утыра. Утыра гынамы?! Үзенең барлыгына, шушы дөньяда яшәвенә сөенеп туя алмый. Сап-сары төсе, көләч йөзе белән әллә каян ук күренеп, елмаеп,

безне ерактан ук сәламләп каршылый. Ә бер әдәпсезе шуны тотты да йолыкты ди. Өзде дә алды. Ни дип? Ни дип ул аның гомерен өзде? Ярты сәгатьтән үк янәдән ташлау өченме?

Кайчакларны урман-болыннардан кочак-кочак шомырт чәчәкләре күтәреп кайткан балаларны күрәм. Шул чакларны йөрәкнең ничек сыкраганын белсәгез икән. Чәчәкләрен өзгәндә, ботакларын сындырганда агачларның да гәүдәләре авырта, сызлый бит. Алар да нык рәнҗиләр. Менә шуны балаларыбыз ник аңламыйлар икән? Ата-аналар балаларына шуны ник аңлатмыйлар икән? И-и, алар гынамы! Кайбер малайлар — әлбәттә, усаллары, тискәреләре — урам этләренә җәяләрдән очлы уклар аталар, песиләрне тотып җәберлиләр. Алар әлегә белмиләр генә, соңыннан үзләре дә зур михнәтләр, кайгы-хәсрәтләр күрәчәкләр. Бәхетсез булачаклар. Шуңа күрә, нәни дусларым, кечкенәдән үк үз-үзеңә хуҗа булып, бар эшеңне үлчәп, бу гамәлем белән берәрсен кыерсытмыймме, рәнҗетмимме икән, дип, үз-үзеңнән сорап яшәргә гадәтләнү кирәк. Моның файдасы беренче чиратта үзеңә булачак. Кайгы-хәсрәтсез бәхетле тормыш кичерерсең. Әйе, нәкъ шулай...

Мунча яратучы мәче

Башына чиертсәң җаны чыгарга торган бу мескен песи баласын безгә ике нәни кызчык китерде. Җәйге ял чорында алар, әниләренә ияреп, төзелешкә барганнар. Өйдә ялгызына гына күңелсез булыр дип, үзләре белән песикәйләрен дә алганнар. Аны гел кулда гына тотып булмый бит инде. Йөгереп-йөгереп уйнасын дип, идәнгә төшергәннәр. Ә тегесе йөгереп балконга чыккан да дүртенче каттан аска очкан. Нык кына имгәнгән. Зур песиләрне Америкада унынчы каттан да ташлап караганнар. Алар һәрчакны аякларына төшкәннәр, имгәнмәгәннәр дә. Берни булмаган. Ә бу песикәй әле бик яшь, берничә атналык кына шул. Бичараның борыны канга каткан, ирене ярык, бер тәпиенә баса алмый. Кызганыч инде, күрсәң елап җибәрерлек. Бичараны менә шул хәлдә калдырдылар бездә.

Ә безнең мунча яккан көн. Авыл җирендә шул бит инде ул, врачка йөрү юк. Борыныңа томау төшсә дә, йөткереп торсаң да, билең кузгалса да — мунча ләүкәсе. Ләүкә, каен себеркесе барын да дәвалый. Җиңгәгез дә күп уйлап тормады, песикәйне үзебез белән «чәп-чәп»кә алып керде. Битен, колак артларын да хуш исле сабын белән юдык, ләүкәгә салып чәп-чәп тә иттердек.

Ни гажәп, башка чакны тәпие белән юешкә басарга кыймаган песиебез «чәп-чәп»не ошатты бит, әй! Яшь каен себеркесе белән аркасын чапканда дөньясын онытып ята. Ник бер тавыш-тыны чыксын.

Хәзер, мунча яга башлау белән: «Мияу, мияу!» — дип, аяк арасында бөтерелә башлый. Мунча ягасыз түгелме, янәсе, «чәпчәп»тән мине дә калдыра күрмәгез.

Кая инде ул калдыру! Мунча өлгерү белән, башта аны ләүкәгә менгерәбез.

Гомумән, бик игелекле песикәй булды ул. Соңгы вакытта ишәеп киткән «идән асты халкы», ягъни тычкан-елтыр күзләрне өйдән тәмам биздерде.

Әле менә урманнан каен кисеп кайттым да кышка себеркеләр бәйлим. Песикәй минем янда. Себерке бәйләгәнемне бик зур дикъкать белән карап утыра. Әллә каян гына шунда кигәвеннәр килеп чыга. Тешләмәкче булалар. Эш белән утырган кешегә комачау ясамагыз әле, дип, песикәй, нәни тәпиләре белән кизәнеп, минем яннан кигәвеннәрне куа.

Тол сыерчык

Бала чактан ук килгән гадәт инде бу минем. Ерак океан-диңгезләр аша күпме җирләр кичеп, туган якларына очып кайтучы сыерчыкларга елның елында кимендә бер-ике яңа оя бәргәләп куям. Әлегә, кем әйтмешли, шөкер, балта-пычкы тота алмастай корышкан куллардан саналмыйбыз. Әмма шунысы кызганыч, безнең якларга бу кадерле кунакларыбыз елдан-ел әзрәк килә. Ишегалдындагы тугызлап ояның тик дүртесенә-бишесенә генә хуҗа табыла. Башкаларына, килештерсәләр, чыпчык-песнәк кереп оялый, ошатмасалар — бөтенләй буш торалар. Һи, элеккерәк елларны болай идеме соң!

Сугыштан соңгы авыр, хәерче еллар бик хәтеремдә әле. Әмма без, малай-шалай, барыбер җаен табабыз. Аннан каерып, моннан суырып булса да тактасын да юнәтәбез, сыерчыклар килешкә түбә кыегына бер-ике яңа оя менгереп кадакламый калмыйбыз. Менә шул үтмәс пычкылар белән кисеп, тешләнеп беткән балталар белән юнып, кәкре, кыйшык такталардан бәреп-сугып ясаган ояларыбызны язларын безнең авылга кара болыттай ишле булып килгән сыерчык гаиләләре үзара бүлешеп туя алмаслар иде.

Ә менә безнең көннәрдә шундыйрак хәлләр шул: яз хәбәрчеләре — көтеп алган кунакларыбыз — туган якларына елдан-ел азрак әйләнеп кайта. Дөрес, әйләнә-тирәне, үзебез яшәгән мохитне саклау, табигать гармониясен бозмау буенча хәзер бөтен дөнья күләмендә зур эшләр башкарыла. Әмма, күрәсез, бу эшләр әлегә һич кенә дә җитәрлек дәрәҗәдә түгел. Шушы уңайдан күз алдыбызда булган йөрәк өзгеч драма турында сөйләргә телим.

Бала чактан килгән гадәт буенча, сыерчыклар килешкә кимендә бер-ике яңа оя ясап куям, дигән идем инде. Ә бу юлы исә, агач комбинатына барып, эче куыш юкә алып кайттым. Аны станокта

кырдырып, балалар белән бергәләп курчак өедәй матур оя ясап куйдык. Менә шушы оябызга, моңарчы гомердә күрелмәгән хәл, бер япа-ялгыз сыерчык оялады. Бу мескенкәй үзенең тормыш иптәшен кайда югалткандыр, юлда килгәндә нинди һәлакәтләргә очрап беткәндер, теле булмагач сөйли алмый шул. Югыйсә сыерчыклар да пар күгәрченнәрдәй парлашып яши бит алар. Ни генә булмасын, шунысы хак: безнең матур оябызны сайлаган кадерле кунагыбыз ялгыз, тол иде.

Тормыш шулай көйләнгән бит ул. Вакытлар үтү белән иң тирән яралар да җәйләнә, күңелдән мәңге китмәстәй тоелган кайгы-хәсрәтләр дә онытылгандай була. Әлеге сыерчыгыбыз да, ничәмә мең чакрым араларны узып, ниһаять, туган якларына килеп җитүенә, шундый матур ояга юлыгуына сөенеп бетә алмыйча, берәр атна тирәсе шашынып-шашынып сайрады. Бу матур ояны ясап куючыларны үземнең матур җырларым белән кинәндерим әле дигәндер. Ләкин шулхәтле ерак яклардан безгә алар нибары бер максат белән — ул да булса тизрәк балалар чыгару, аларны очарга өйрәтү нияте белән киләләр. Бу кошкайларның һәр сәгате санаулы. Башка парлы-парлы сыерчыклар белән бергә безнең бу ялгызыбыз да ашыга-ашыга оясына салам-печән кисәкләре ташырга кереште. Бер караганда бары да яхшы, бары да тәртипле төсле. Әмма аны алда зур фаҗига көтәсен, бичара кошкаем, үзе генә белми. Каян белсен, аның белән инстинкт идарә итә. Аны шул ашыктыра. Ләкин бу очракта хәтта инстинкт та ялгыша.

Әлегә тол сыерчыгыбызның анда-монда эше юк. Тизрәк балалар чыгарып, аларны очарга өйрәтеп, ныгытып, ерак юлга хәстәрләргә вакыт. Җылы, һәр иртәсе кояшлы җәйнең дә чиге бар.

Сыерчыгыбыз хәзер бик сирәк күренә. Йомыркаларын басарга утырды, күрәсең. Бу чорда ана сыерчыкларны, җимне ояга ташып, ата сыерчыклар ашата. Әгәр инде тегеләре кыска вакытка гына һава суларга йә канатларын язып керергә тышка чыкса, йомыркалар өстендә аталары утырып тора. Инкубация чорында аларны аз гына вакытка да суытырга ярамый. Ә безнең тол сыерчыгыбызның алай иркәләр иптәше юк. Бу мескен йомыркалары өстендә түзә алган чаклы утыра-утыра да оядан уктан аткан шикелле атылып чыга. Беренче туры килгән бөҗәкне йә суалчанны эләктерә дә кире оясына ашыга. Йомыркаларымны суытмагаем, чәберчекләндермәгәем дип курка.

Ул арада, күп тә узмады, күрше ояларда ыгы-зыгы башланды. Үз вакытында чәчрәшеп чыгып җиткән балаларына ата-аналары җимне ташып өлгертә алмый. Беренче көннәрдә генә эчтә чыр-чу килгән бу ачкүзләр аналарының җим алып кайтканнарын оядан башларын чыгарып ук көтә башладылар. Әлегә ялгыз, тол анабыз утырган ояда гына шомлы тынлык. Берничә көн инде мин аның оядан чыгып йөргәнен дә күрмим. Бу хәл миңа шикле тоелды. Ояны колга башыннан алып карарга булдым. Ни күрәсемне, нинди күренеш белән очрашачагымны алдан ук сизенсәм дә, бу минутта күзләремә яшьләр килде. Оя эчендә йөрәк тетрәткеч фаҗига. Тагын чүт кенә түзим, менә тиздән балаларым да чыгып җитәрләр, дип, көн-төн кузгалмый утыра торгач, сыерчыгыбыз ачлыктан, ялгызлыктан чәберчек йомыркалары өстендә җан биргән...

Эт белән мәче төсле...

Наполеон кушаматлы песиебез бар безнең. Ярты гомерен диванда, ярты гомерен түбә кыегында үткәрә. Карап торырга бик интеллигент кыяфәтле. Үз кадерен үзе белеп, аяк очларына гына басып йөри. Чисталыкны бик ярата. Өсте һәрчак ялык-йолык килеп тора. Битен көненә өч тапкыр юа. Мыеклары да галәмәт аның. Аларны гел сыпырып, майлап, кадерләп кенә тота. Үз-үзенә сокланып һәм тәмам мөкиббән китеп көзге каршында сәгатьләр буе утырырга ярата торган песи бу. Драма театры артисты диярсең, валлаһи! Инде эрелеккә, тәкәбберлеккә килсәк, аңа тиңнәрне бүтән табарсыңмы әле! Үзенә тиңнәр белән дә тик ике метр ярым биеклектәге койма башыннан торып аралаша. Түбәнрәк төшсә, авторитеты төшүдән курка, күрәсең. Кыскасы, үзен тота белә, кыланчык нәрсә.

Безнең әле Сарбай исемле бик акыллы маэмаебыз да бар. Дөньяда бер тырыш, намуслы җан иясе инде. Көнен генә түгел, кышкы озын төннәрне дә керфек тә какмыйча саклый ул безнең йорт-җирне, мал-мөлкәтебезне. Күрше тавыгы түгел, алмагачка ят чыпчыклар килеп кунса да, шундук тавыш куптара. Шунысын да өстәп әйтим әле: һәрчак шат күңелле, юктан да үрле-кырлы сикереп сөенүчән безнең Сарбай. Һәр елны мин аның туган көненә яңа муенчак бүләк итәм. Бу көннәрне сөенеченнән Сарбайның түбәсе күккә тия.

Менә әлеге Наполеон белән тырыш җан Сарбай бер-берсен, кем әйтмешли, йөзгә-йөз танып беләләр. Белмәскә соң, икесе дә бер оешмада хезмәт итәләр, ягъни безнең мал-мөлкәт сагында торалар. Әмма шушы ике җанның бер-берсенә бер генә мыскал да ихтирам хисе юк. Сөймиләр берсен-берсе. Югыйсә конкурентлар, көндәшләр дә түгел.

Кайчакны шулай Наполеон, диванда аунаудан туеп яки эшсезлектән интегепме, лапас түбәсенә чыгып ята. Анда һәрчак ышык, һәрчак кояш кыздыра. Сарбайның оясы да каршыда гына.

Наполеон түбә башында тын гына кызынып ятса бер хәл, анда чыгу белән Сарбайны иреш терә башлый:

— Әй, картлач, синең тормышны да әйтер идем инде, чын эт көнендә яшисең бит. Ничә карама муеныңда чылбыр галстук. Нүжәли бер дә туймыйсың? Салып ташла да шуны, минем янга мен. Дөнья дигәнең ул бит әнә ничек киң, әнә ничек чиксез.

— Кит моннан, оятсыз җан, ата ялкау! Минем муенымда нинди галстук булуда синең ни эшең бар?! Мин хуҗама намуслы хезмәт итәм. Шуның белән үземне бәхетле саныйм, — дип, ярсып-ярсып Сарбай аны орышырга керешә. — Синең урыныңда булсам, оялыр идем мин мондый сүзләр сөйләргә. Өй кыегында төне буе мәхәббәт уены уйныйсың. Көне буе йоклыйсың. Гомер эчендә бер идән астына төшеп караганың юк. Анда тычканнар, тәмам котырынышып, сабан туе ясап яталар. Әрәмтамак! Белмим, аңламыйм хуҗабызны. Син әрәмтамакны ни дип кенә асрый торгандыр? Әй, таптым тагын кем белән нервыларымны бозарга, — дип, оясына ук кереп китә.

Менә шулай яши бу ике җан иясе, нәкъ эт белән мәче кебек. Әмма күптән түгел искитмәле бер хәл булып куйды. Печәнгә төшәргә атна-ун көннәр кала урманчы Сәлимҗан килеп чыкты. Атын капка баганасына бәйләде. Арбасында бозау тикле йонлач маэмай ята. Хуҗасы кая атласа, монысы шунда сикерергә күнеккән. Сәлимҗан артыннан маэмае да ишегалдына килеп керде.

— Кая, кая керәсең? Кем дәште әле сине монда? Һау, һау! — дип, Сарбай бу йонлачны бик коры каршылады.— Тәртәләреңне кире бор. Юкса мин күп сорап тормам, һау, һау!

Әмма урманчының маэмае да хуҗасы кебек әрсез җан икән, кире чигенергә җыенмады. Болар шул арада, бер-берләренә ташланып, аяк астыбызда бөтерелә дә башладылар, һич аерыр хәл юк үзләрен. Наполеоны да шушында ук казык башына чыгып кунаклаган. Андый чакны мәзәк кәрарга аңа бир инде. Күрше әтәчләренең сугышканын, күрше малайларының чәкәләшкәннәрен дә ул, тәм табып, казык башында күзәтеп утырырга ярата.

Ике маэмай, бер түгәрәк йомгак булып, ишегалды буйлап тәгәриләр. Кычкырып та, таяк белән дә кизәнеп карадык. Колакларына да элмиләр. Әй, чәнчелеп китсеннәр лә шунда! Безнең үз мәшәкатьләребез муеннан. Печәнгә төшәбез дип кенә торганда яңгырлар китте. Кояшлы көннәр тиз генә кайтмаса, белмим, ничек кенә чабып алырбыз быел ул билдән печәнне.

Ике маэмай җан-фәрманга кызып сугыша. Әмма Сәлимҗанның йонлачы хәйләкәррәк, әмәл белән сугыша. Бер араны оста әмәл кулланып, безнең Сарбайны сыртына салды. Сарбай — аста, йонлач — өстә. Урманчы этенә хәзер Сарбайны ничек җәзаласа да була. Әлеге көтелмәгән хәл менә шушы мизгелдә булып куймасынмы, валлаһи! Әлеге ызгышны күзәтеп торган Наполеон нечкә тавыш белән ямьсез мыраулап җибәрмәсенме?!

— Җәмәгать, нәрсә карап торасыз! Безнекеләрне тукмыйлар бит! — диде, ахрысы, һәм әлеге казык башыннан таш булып урманчы эте өстенә атылды. Дүрт тәпие белән берьюлы тегенең йонлач башыннан каптырды.

Урманчы эте шундук чинап җибәрде. Кемнең, каян һөҗүм итүен дә аңламыйча урамга йөгерде. Ә Наполеон мыекларын төзәтеп алды да янәдән җәһәт кенә багана башына үрмәләде.

Сарбай да торып басты. Чак кына кан саркыган иренен ялап алды.

— Безнең маэмайлар арасында андый гына конфликтлар булып ала инде ул. Катышмасаң да була иде. Мин ул нахалны үзем дә акылга утырта идем, һау! — дип куйды.

Әмма Наполеонның ярдәме бик вакытлы булды. Сарбай да бу «һау-һау!»ны чын күңеленнән рәхмәтен белдереп әйтте төсле.

— Безнең дә кем икәнне белеп торсыннар. Җыен килмешәктән бер-беребезне кыерсыттыра башласак, нәрсә була ул, мияу?! — дип куйды Наполеон үзе утырган багана башыннан.

Менә шулай яшиләр инде алар. Эт белән мәче төсле. Бер-берләренә мыскал да симпатияләре юк...

Хәйләкәрнең хәйләкәре!..

Узган җәй ничектер мәшәкатьлерәк килеп чыкты. Байтак кына вакыт командировкада йөреп кайттым. Ә минем дуслар умарталарын күптән инде басуга чыгарганнар. Шалашлар, палаткалар корып, үзләре дә бал кортлары тирәсенә урнашканнар. Урман яланының тын бер почмагында миңа да урын калдырганнар. Чык та утыр. Умарталарны утырту өчен казыклар кагасы гына калган.

Әмма бүген-иртәгә кунаклар килеп төшәргә тора. Өең тулы кадерле кунаклар булганда урманда югалып, кунып яту шулай ук килешми. Бу җәйне кортларымны урманга чыгарып тормаска булдым. Тик, карап торам, умарта семьяларым көчле. Җәйнең бу чорында, һәр чәчәк керфегеннән нектар кашыклап тамган чагында, аларны шәһәрдә тоту гөнаһ. Балны асфальт өстеннән җыймаслар бит инде! Бу тырыш җаннарны кая да булса чыгармый ярамас.

Күп тормыш сынаулары узган, әмма һичкайчан хыянәт итмәс мотоциклым бар. Өч кенә көпчәкле булса да, менмәгән тавы, ерып чыкмаган сазы юк. Шуны кабыздым да кортларымны чыгарып утырту өчен уңай урын эзләргә чыгып киттем. Шәһәрдән күп булса унике-унбиш чакрымнар гына җирдә бик матур карабодай кырына юлыктым. Аннан аз гына астарак, Карабаш тавы итәге буйлап уннарча

чакрымга әрәмәлек, сазлык сузыла. Ә сазлыкның өстен ак клевер — тукранбаш сарган. Тукранбашмы?! Бал бирү буенча аңа тиң чәчәкне табарга кирәк әле!

Тагын шунысы да бар: карабодайга гына бик үк ышанып та бетәргә ярамый. Бик «кәҗәле», бик нәзберек культура ул. Аның өчен җәй җылы да булсын, яңгырлы да. Көндезләрен температура 24–26 дан артмасын, төнлә 16–17 градустан төшмәсен. Карабодай нектарны тик менә шундый шартлар үтәлгәндә генә бирә. Ә мондый уңайлы шартлар безнең Татарстанда ел саен булып тормый шул. Карабодай чәчәк атар алдыннан гына йә артык кыздыра, йә суытып куя. Чак кына төньяк җиле исеп куйдымы, карабодайның кәефе шундук китә. Ап-ак эскәтер булып чәчәк ата үзе, әмма хуш исе юк. Хуш исе белән үзенә чакырып тормагач, аңа кортлар да кунмый.

Кортларымны чыгарып утырту өчен нефтьчеләрнең ташландык товар паркын сайладым. Биредә хәзер беркем дә юк, тыныч. Үзләренә кирәк җиһазларын алар биредән күптән сүтеп алганнар. Заманында бик матур һәм төзек булган алма бакчасы гына калган. Чаллы — Бөгелмә трассасыннан бирегә тар гына асфальт юл керә. Минем өчен монысы да уңай. Юкса аз гына яңгыр сибәләп үтсә, умарталар утырган аланга керешле булмый. Андый чакларны, их, вертолетым булса икән, дип уфтанган минутларым да күп булды.

Умарталарны кояш чыгышка каратып, карт алмагачлар күләгәсенә утырттым. Чөнки җәйнең иң кызу, иң эссе өлеше — арыш урагына төшәсе чаклар алда әле. Алмагач күләгәсендә аларга әйбәт булачак. Юкса көндезләрен оялары артык кызып китсә, алар, бар эшләрен ташлап, ояны суытырга керешәләр. Чөнки оя эчендәге серкәләрнең, личинкаларның, әле очарга да өйрәнмәгән бала кортларның пешүе бар. Мондый чакларны алар оя авызына бүрек, тубал хәтле булып чыгып утыралар да, канатларын җилпеп, ояга салкын һава өрә башлыйлар. Уттай кызу эш өстендә, җәйге озын көннең һәр минутын бал җыюга файдаланасы, сарыф итәсе урында, диген.

Сүз дә юк, әлеге ташландык алма бакчасы алар өчен бер дигән урын инде. Үзем өчен исә каравылчы будкасын тәртипкә китердем. Рамнары алынган тәрәзә бушлыгына целлофан пленка кактым. Ишеккә палатка элдем. Алачык эчендәге өч аяклы өстәлне һәм шыгыр-шагыр тапчанны элеккеге хуҗалар калдырган. Хәзер монда рәхәтләнеп яшәргә, көн итәргә була.

Кешегә барып ябышырдай усаллыклары булмаса да, аз булса да күз-колак булып торырлар, төннәрен һау-һау килеп карак-угрыны куркытырлар дип, бирегә ике ата ялкау — Бим белән Сарбайны да чыгардым. Бу маэмайларның Бим исемлесенә сүз әйтешле түгел. Бик акыллы җан. Мин ишегалдында нидер эшләргә карар итсәм, ул уйларымны күземә карап аңлый. Әгәр бу фикерләремне хупласа, шатлана, сикеренә, аяк арамда бөтерелә. Ошатмаса, оясына кереп китә, үпкәли.

Ә менә Сарбай дөньяда тиңдәше булмаган аңгырабаш. Һәр аңгырабаш шикелле коточкыч ялагай үзе. Бирегә чыгуыбызның беренче көнендә үк ташландык нефть коесына егылды. Ваемсыз нефтьче коеның өстен ябарга оныткан. Ә моңа шул гына кирәк, барып чумган. Мин аны ул коедан чак өстерәп чыгардым. Икебез дә баш-аяк кара нефтькә, мазутка баттык. Аннары ул шушы зинданнан котылу шатлыгыннан, болай да куркак саз бакаларының котын алып, көне буе болын буйлап чапты.

Сарбай коега күп белергә теләүдән түгел, ә ахмаклыгы аркасында чумган. Ю-ук, бу аның беренче генә мәҗарасы түгел. Өйдә чакта да шулай кисәктән генә ишеп куя торган иде ул ишәк чумарларын. Ә бу юлы мазутка баткан кием-салымымны ацетон белән юа-юа көчкә чистарттым.

Шушы ташландык парк ишегалдына чыгарып утырткан кортларымны көне-төне сакларга вакытым да, мөмкинлегем дә юк. Аларны саклауны шушы ике ялкауга тапшырдым. Парк территориясеннән бер адым читкә китәсе булмагыз, дип кисәттем. Ашарыгызга ташып торырмын, дидем. Аңгырабаш булса да, Сарбай тәмлетамак ул. Табада кыздырган минтай балыгы күрсә, тәкатен җуя. Минтай булачак, дип, бармак янадым аңарга. Икесе дә каршыма килеп басып, күзләрен әлҗе-мөлҗе йомгалап, «саклыйбыз, хуҗа, саклыйбыз кортларыңны, сакламаган кая, без дә сакламасак, аларны кем саклар» дигән төсле калганнар иде кичтән. Иртән торып ишегалдына чыксам, кайтып та җиткәннәр. Алмагач күләгәсенә сузылганнар. Арыганнар, әлсерәгәннәр, янәсе. Унбиш чакрым җир кайтканнар бит. Аңгырабаш Сарбай зур батырлык эшләгән каһармандай карый. Мактаганны, минтай калҗасы чыгарганны көтә. Бим гына, бераз оялган төсле, башын йонлач тәпиләре арасына яшерә.

Шулай итеп, умарталарым саксыз калды. Әмма кайгырмыйм. Алар янына хәзер битлексез якын килешле түгел. Үтерәчәкләр чагып. Умарта оясы янына сузып салулары бар. Кырга чыгарып бастыргач, ояларында бал запасы арткач, шулай усаллана алар, тәмам ерткычка әвереләләр. Бик яхшы аңлыйм мин аларны. Үзем дә шулай усалланыр идем. Мыскаллап, нинди зур көч куеп җыйган балымны берәүгә дә бирәсем килмәс иде.

Каравылчылары юк дип борчылмыйм. Чөнки һәр көн кич хәлләрен барып беләм. Көннәр әлегә матур тора. Болынлыкка һәр көн кичтән мул итеп чык төшә. Кичтән чык булса, иртән нектар бит инде ул.

Шул бик тә тыгыз көннәрдә миңа янәдән берәр атнага командировкага барып кайтырга туры килде. Бер хәлең юк, кушкач, барасың.

Командировкадан кайтып төшү белән умарталыкка ашыктым. Чәчәкләргә нәкъ бал төшкән чаклар бит. Һәр семьяны барлап чыктым. Кортларым мин юкта да тик утырмаганнар, канәгать калдым үзләреннән.

Бар ояларны да бер кат барлап чыктым да бер таш өстенә барып чүктем. Кортларның кай якка таба очуларын, балны кайсы як басудан ташуларын күзәтәм. Шунда колагыма ниндидер ялварулы тавыш, кемнеңдер шыңшыганы ишетелде. Сагаебрак калдым. Әйе, кемдер авыр ыңгыраша, ярдәм сорый.

Әлеге тавыш котырып үскән акация куаклары арасыннан килә. Алар парк читен урман төсле әйләндереп алганнар. Куаклар арасына ниндидер маэмай актыгы кереп кысылган түгелме соң? Ул шулай ыңгыраша, ахры. Кереп карадым. Әйе, куак төбендә ниндидер аңгыра маэмай ята. Башыннан алып койрыгына тикле чәнечкеле тимерчыбыкка уралган. Әйтерсең урап салганнар. Нефтьчеләр әлеге паркны сүткән чакта аларга койма булып хезмәт иткән бу тимерчыбыкны тураклаганнар да, кая туры килсә, шунда ташлап киткәннәр. Аларга абынып мин үзем дә күп азапландым. Чалбарымны ертып, ботинка табаннарымны тишеп бетердем.

Әйе, куак төбендә бер маэмай ята, кызганыч шыңшый, ярдәм сорый. Ләкин янына керешле түгел. Мин куштыммы? Кергәнсең икән, ят шунда, дим. Юк, керми дә булмый. Ул биредә берничә көн ята булса кирәк, тәмам хәлсезләнгән. Башын да тота алмый. Ничек ярдәм итмисең? Күрә торып үтермәссең бит инде?!

Алачыгыма барып кискеч-келәшчә алып килдем. Аның ярдәменнән башка биредә берни кылышлы түгел. Ах-ух килеп, билемне тотып, кадерле радикулитымны каргап, акация куагы астына үрмәләдем.

Чү! Бу нәрсә соң? Әллә күзләрем ялгыш күрәме? Маэмай дигәнем маэмай түгел бит! Бу соң төлкебикә түгелме? Шул! Үзе бит! Ничек килеп капкан соң ул монда? Әсирлеккә ничек төшкән? Аңлады-ы-ым! Ул бит кыр тычканы ярата. Алар дигәндә тәкатен җуя. Ә бер-ике елга тып-тыныч калган парк аларның мыж килгән җирләре. Минем дә тәмам үзәгемә үттеләр. Портфелемне алачыктагы өстәлгә куярга өлгермим, өерләре белән актара да башлыйлар. Янәсе, мин аларга өйдән нинди тәмле нәрсә алып килдем икән. Курыкмыйлар да, каһәрләр. Берләрен сыпырып төшерәм, икенчеләре менә өстәлгә.

Төлкебикә менә шуларны тотам дип кергән булгандыр инде куак төбенә. Кергән дә чыбыкка буталган. Котылам дип чәбәләнеп, тагын да ныграк уралган. Хәзер, мескен, селкенә дә алмый.

Эсседән, сусаудан, ничәмә көннәр ач торудан, ничек тә котылам, дип тыпырчынудан ул тәмам хәлсезләнгән. Хәтта башына тикле чыбыкка уралган. Бичара! Хәзер ул тирән итеп сулыш та ала алмый. Сулыш алырга тырышкан саен, тимерчыбыкның очлы тешләре аның тәненә тагын да тирәнрәк кадала бара.

Беренче күрүдә алай да бераз шикләнеп, куркып калдым. Ни дисәң дә, ерткыч җанвар бит. Тешләп алса шунда! Әмма ярдәм итми дә ярамый. Кызганыч бит.

— Кара аны, берүк шаярма! Мин андый нәрсәне яратмыйм, — дип, башта бармак янап кисәттем үзен. Аннары кискеч белән шарт-шырт итеп аның тәнен урап алган чәнечкеле тимерчыбыкны кисә башладым. Койрык өлешеннән тотындым, әлбәттә. Тимерчыбыкны тәненнән аерып алышлы түгел. Куба башлаган йомшак мамыгы белән тәмам укмашкан. Бармак буе-бармак буе гына кисәм, һәр кисәкне кискән саен, әсирем авыр ыңгырашып куя. Авырта торгандыр инде. Түз, чыда, дим. Йомшак кына сыпырып алам. Әллә мин куып кертемме, дим. Моннан соң акыл булыр, дим.

Әнә нинди зур, озын, матур икән төлкенең койрыгы. Үзе йомшак, үзе шома. Шунда нәфесем дә уянып куйды. Синең бу койрыгыңнан хатыныма бер дигән якалык чыгачак йә бүрек. Юк, үземә йомшак күкрәкчә тектермермен. Бу, каһәр төшкән радикулит, тәмам иза чиктерә, дип сөйләнәм. Үзем кырт та кырт чыбык турыйм. Ярар, әлегә тын гына ята бир. Башта сине бу әсирлектән коткарыйм әле. Синең белән ни эшләргә икәнне соңыннан хәл итәрмен, дим.

Тын гына ята хәйләкәрбикә. Вакыт-вакыт күзләрен җемелт-җемелт итеп ачып япкалый. Чәбәләнми-нитми. Тешләшми. Әйтерсең гомер буе кулда үскән. Ара-тирә тирән итеп тын гына алып куя. Ярый әле, бәхетең бар икән, мин туры килдем, дим. Мин күреп алмасам, шушында кәкрәйгән булыр идең. Син артларыннан кергән тычканнар үзеңне кимерә башлаган булырлар иде, дим.

Әсирне әлеге үткен очлы чыбыклардан бер кат арындырдым төсле. Ярар, хәзергә шушында ятып тор, хәл җыя тор, дидем. Хәзер мин сиңа су алып киләм. Авызың кипкәндер, дим. Төлкебикәм ятып калды. Мин алачыгыма су алырга киттем. Ачыккандыр да, дим, бер телем колбаса кисәге дә алдым. Килсәм, менә сиңа мә, төлкемнең исе дә юк. Күз алдымда үләргә яткан хәйләкәр җаннан җилләр искән. Сыздырткан. Әйләнә-тирәдә чәнечкеле тимерчыбык кисәкләре, аларга укмашкан мамыклар гына калган. Менә шулардан соң төлкеләрне хәйләкәрләрнең хәйләкәре димичә нәрсә дисең?!

Акыл иясе

Иртә таңнан аякта булып, кортларыбызны баш күтәрми карап, тәмам арып-алҗып, авызларыбыз кибеп, алан уртасындагы учак янына җыйналыштык. Битлекләребезне салып, җиргә сузылыштык.

Учакта кайнаган чәйне генә әйт син! Мондый тәмле, мондый шифалы чәйне тик биредә генә татырга мөмкин! Чөнки чәйнек эчендә нинди генә хуш исле, нинди генә шифалы үләннәр юк!

Шулчак якында гына чырт-чырт итеп коры куак чыбыклары сынган тавыш ишетелде. Кем булыр икән бу уттай кызу эш өстендә?

— Кем булсын? Гөмбәче-мазардыр. Адашып килеп чыккандыр, — дип куйды арабыздан берсе. — Әйдә килсен. Кунакларга бездә һәрчак якты йөз. Менә тәмле чәй белән сыйларбыз үзен.

Кем, дисезме?! Шулчак аланга, артына ут капкандай атылып, Озын Колак-Кылый Күз Куян хәзрәтләре килеп чыкмасынмы?! Килбәтсез озын сыйраклы үр куяны. Чыбыкларны шатыр-шытыр сындырып куаклыктан ул чапкан икән. Күзләре шар. Йөрәгенең ярылырдай булып дөп-дөп типкәне безгә дә ишетелә. Әллә соң бу бичара акылыннан язганмы? Акта-карада эше юк моның, әллә безне дә күрми инде? Ракета тизлеге белән аланны әйләнеп чыкты да, инде нишли бу дип торсак, кыл уртабызга керде дә ятты. Колакларын шиңдереп, үләнгә үк сеңде. Аптырап карап торабыз. Мондый хәлне күрү түгел, ишеткән дә юк. Берни аңламыйбыз. Әйе, керде дә ятты уртабызга, җиргә сеңде. Күлмәк сәдәфедәй зәңгәрсу, нәни, кылый күзләрен безгә төбәгән. Нидер ялвара, сорый төсле. Зинһар, коткара күрегез, дия сыман. Ләкин, телен белмәгәч, нәрсә эшлик, ничек ярдәм итик? Аптырашып тора бирәбез.

— Нәрсә, Кылый Күз, әллә бал татып карыйсың килдеме? Юк бит әле. Бал төшкәнне үзебез дә көтәбез генә. Ә менә тәмле чәйдән авыз ит. Шикәрне сиңа ничә кашык салырга?

Нәкъ шул чакны аланга, туптан аткандай атылып, икенче бер кунак, төлке-хәйләкәр килеп чыкмасынмы! Акны-караны күрми, күзләрен тәмам кан баскан. Әлсерәгән. Телен асылындырган, гыж-гыж сулый.

Атылып килеп чыкты да бер мәлгә аптырап калды. Янәсе, кая, кемнәр янына килеп чыктым мин?! Безнең арада җиргә сеңеп яткан куянны шушы комсыз куып килгән булырга тиеш. Тәмле куян ите татып карыйсы килгәндер инде.

Кем утырып, кем ятып торган җиребездән сикерешеп торып, төлкегә таба йөгерештек. Хәйләкәр җан — Озын Койрык бик тиз зиһененә килде. Кырт кире борылып, куе куаклык эченә сикерде. Койрыгын гына күреп калдык. Алай да сызгырып, артыннан шаян сүзләр кычкырып, бармак янап озаттык үзен.

Инде кире борылып, янәдән алан уртасына, учагыбыз янына килсәк, Озын Колак-Кылый Күздән дә җилләр искән. Менә син, ә?!

Куркак җан куянга безнең уртага кереп яту өчен никадәр тәвәккәллек, никадәр батырлык, акыл һәм зиһен кирәк булгандыр. Ул бит кыргый җәнлек. Әмма шушы авыр чакта, менә куып җитәм, менә тотып ботарлыйм, дип артыннан мәрхәмәтсез ерткыч куганда, бик дөрес карар кабул иткән ул. Юкса мәкерле җан төлке аны һичшиксез куып җиткән, тотып ботарлаган булыр иде. Җитмәсә, без аның буаз куян икәнен, менә-менә бәбәйләргә торуын күрдек. Бу килештән ул ерак китә алмаган булыр иде. Үзенә үлем куркынычы янаганда куян әнә нинди зирәк карарга килгән, башка чакны үзе дә коты алынып курыккан кешеләр янына чыккан, безгә сыенган.

Без, гадәттә, куянны иң куркак җанга саныйбыз. Ләкин ул әле зирәк акыл иясе дә икән. Бу табигатьнең серләрен белеп кенә бетерешлеме соң?!

Көзге урман аланында

Төбәгебезгә сап-сары, ал-кызыл яфраклары белән алтын көз килде. Елның һәр фасылы үзенчә матур. Ә көзләребез — аеруча. Кортларыбызны кышка инде күптән әзерләп куйсак та, өй ягына алып кайтырга ашыкмадык әле. Һаман да урман аланында тотабыз. Бирегә иртә яз башында чыгып утырган идек. Ни дисәң дә, урман һавасы урман һавасы инде: тын, ышык, тузан юк, тавыш юк. Аз гына кояш караса, алан шундук җылынып китә, кортлар оча башлый. Канатларын язып, һава сулап керәләр.

Умарталыкны чиратлашып саклыйбыз. Бүген — минем чират. Килү белән учак ягып җибәрдем, су салып казан астым, көлгә бәрәңгеләр тәгәрәттем. Кесәгә генә сыешлы радиоалгычны каршыдагы имән ботагына элеп куйдым. Аннан, күңелгә рәхәтлек өстәп, җиңел көй агыла.

Моңа тикле бер атна тоташ яңгыр койды. Көн бүген генә ачылып китте. Аланда җылы, ышык. Кичке дүртләр тирәсе булыр. Шулчак, ишетәм, күрше аланда поши мөгри. Бу урманда байтак алар. Моңа кадәр дә еш күренгәләп китәләр иде. Тавышы бик гайрәтле ишетелә. Барып карасам, мин сиңа әйтим, аланның нәкъ уртасына чыгып баскан. Тау артына күчәргә җыенган кояш нурларында аның сыртты, кызгылт төскә чумып, елык-елык килә. Кызыл мәрмәрдән коеп куйган сын диярсең. Поши үгезе бу! Янәсе, бу урманга мин хуҗа! Мөгри, мин сиңа әйтим, үзенә бер гайрәт белән! «Кем дә кем минем белән килешми, бирегә, ошбу аланга, көч сынашырга чыксын! Ягез, кемнең йөрәге җитә?!» — ди төсле. Әйтәм ич, бөтен урманны тетрәтеп мөгри. Күзләрен тәмам кан баскан.

Миңа бик кызык булып китте. Үземә дә кирәк бит шундый малайлыкны эшләргә: поши егетен үртәмәкче булдым. Инде чәчем агарып бара, акыл керергә дә вакыт югыйсә, ә шуклыкларны эшләргә генә торам. Каеш белән тотып ярасы нәрсә, дип орыштым үземне соңыннан. Әйе, соңыннан. Ә хәзер

исә үз аланыма кайттым да, ике кулымны авызыма куеп, пошича мөгри башладым. Бик килештереп мөгрәгәнмен, күрәсең. Әлеге пошием юлында очраган усак үсентеләрен, чикләвек куакларын шатыр-шотыр сындырып килеп чыкмасынмы каршыга?! Ажгырып минем өскә килә. Йөзендә миһербан әсәре күренми. Инде нишләргә? Ярый әле каршыда гына карт имән бар иде. Уйлап-нитеп торырлык ара юк, космик кораб тизлеге белән шуның башына үрмәләдем. Үртәвемне, үзенең алдануын поши шундук сизде. Әй ачуы чыкты да соң моның. Мине изеп ташларга әзер. Хурлыгыннан тагын да ярсый төште. Имән төбенә килеп басты. Төкереген чәчә-чәчә уңга да сулга башын чайкый, усал пошкыра. Топ та топ тибенә. Имән нык, йөз еллык, юкса аны да сөзеп аударган булыр иде. «Төш монда, куркак җан! Күрсәтәм хәзер күрмәгәнеңне!» — ди бугай поши.

Әйтәм ич, әле ярый башына менеп кунаклаган имәнем нык. Нечкә генә усак яисә юкә булса, шундук сөзеп аударган булыр иде. Аудармас, бар! Җен көчләре бардыр үзендә.

Имән тирәсендә таптангалап берни майтара алмагач, пошием учакка таба юнәлде. Учак өстенә каккан казыкларны, аркылы агачларны сөзеп аударды. Болар гына аз тоелды, ахры, үзенә. Казыклар өстендә утырган умарталар арасына барып керде. Берәм-берәм аларны аударырга кереште. Агач башыннан гына: «Пиф-паф! Атам бит!» — дип әтәчләнгән булам. Колагына да элми, хулиган. Соңгы умартаны мәтәлдергәннән соң гына ачуы бераз басыла төште әзмәвернең. Радиоалгычта яңгыраган «Җиңүчеләр маршы» көенә аланны янәдән бер әйләнде дә каршы як чыршылыкка таба атлады.

Бераздан мин дә агач башыннан төштем. Сукрана-сукрана умарталарны янәдән казыкларга утыртып чыктым. Урынсыз шаяртуым өчен хәтта үземә дә оят булып китте. Колак очларыма кадәр кызарды. Аларны күрергә янымда иптәшем генә юк. Ә поши үгезенең гайрәтле мөгрәве урманның аргы башындагы аланлыкта ишетелә. Ул әле дә үзенең көндәшләрен — поши егетләрен — аның белән көч сынашып кararга чакыра. Аларның хәзер нәкъ менә көч сынаша, бил алыша торган вакытлары шул.

Башкаларга кое казысаң...

Әле иртә кыш башында ук карт алма ботагына фанер кисәге элеп куйдым. Шунда һәр көн җим сибәм. Бер көтү чыпчык, сарытүш, карабүрек, соры песнәкләр шуннан җим чүпләп кинәнәләр. Шатлыклары түбәләреннән аша, бөтен ишегалдына чыр-чу килешәләр. Ә нигә шатланмаска, сөенмәскә. Җан биргәнгә җүн бирә тора. Тау артыннан февраль кояшы карый инде, җылы язлар җитәргә дә күп калмый. Әлегә исә җим тактасында җылы тары боткасы, ипи валчыклары. Ә җаны теләгәннәргә әнә ботакта бер кисәк дуңгыз мае да бар. Теләсәң, анысыннан авыз ит.

Беләм, бик аңлыйм мин аларның хәлләрен. Әгәр кышның шушы авыр чорында ярдәм кулыңны сузмасаң, эшләре мөшкел. Былтыр шулай үтә салкын төннәрдән соң, иртән эшкә барганда, туңып үлгән кошчыкларны юлда күп очраткаладым. Салкыннан түгел, ачлыктан үлгәннәр алар, бичаракайлар. Тамаклары тук булса, берни булмый, туннары калын, җылы. Ә менә кешеләр ярдәм итмәсә, кышын җимне каян табып бетерәсең? Кош-корт, бөҗәкләр кар астында. Шуңа күрә кышка керү белән үзебезнең кошчыкларны мин җимнән өзмим. «Үзебезнекеләр» дим шуның өчен. Чөнки алар чыннан да безнекеләр. Безнең өй, мунча, лапас шиферлары астында, гараж кәрнизләрендә бик күбәү яшиләр алар. Чыпчыкларның кайберләре, хуҗалары җылы якларга китү белән, кышкылыкка сыерчык ояларына да күчәләр. Чөнки анда җылырак, ышыграк.

Ә бер тапкырбаш чыпчык гаиләсен генә күр син. Искитмәле бит. Ике-өч ел саен череп-авып аптыраткан кайбер койма баганаларын тимер торбалар белән алыштырган идем. Әлеге чыпчык гаиләсе, мин сиңа әйтим, шул торба эченә оя корган. Башлары җиткән. Үзләренә аннан очып чыгу күп кенә. Ә менә песи-разбойникка йә башка ерткычка анда якын килешле дә түгел. Әйтәм ич, профессор башы бар икән үзләрендә. Икенче елларын инде шунда кайгы-хәсрәт, хәвеф-хәтәрсез дөнья көтеп яталар.

Бүген исә җим сибүем генә булды, фанер такта өстен үзебезнең һәм күрше-тирә чыпчыклары, сарытүшләре, песнәкләре сырып алдылар. Ачыкканнар. Әмма әдәплеләр. Бер йотып куялар да, нәни томшыкларын югары күтәреп, җылы ботканы мактарга керешәләр. Миңа да рәхмәт әйтәләрдер инде. Елмаям үзләренә.

— Чәчмәгез, түкмәгез, сак кына ашагыз! — дип бармак яныйм.

Шулчак, каян килеп чыккандыр диген, каршыдагы агач ботагына карчыга-юлбасар килеп кунды. Кошчыклар сизгерләр, шундук як-якка сибелештеләр. Карчыга, качсагыз, исем китә бик, миңа сез генә кирәк инде, дип, ялкау гына очып узды да янәшәдәге миләш ботагына барып утырды. Дөресрәге, яшеренде, посты. Сизәм, изге уй-ният белән йөрүе түгел моның. Кышын, бигрәк тә шушы чорларда, бу бичаракайның да хәле мөшкел. Аның да тамагы гел ач. Каз яисә үрдәк бәбкәләре чәлдерергә бик мәчтыр да бит, ләкин әле иртәрәк. Алары инде, боерган булса, яз җиткәч, болын тутырып бәбкәләр чыккач. Әлегә исә өзелеп ашыйсы килгәнне басарга шунда берәр аңгырарак чыпчык яисә песнәк түшкәсе эләксә дә би-ик ярап куяр иде.

Ярар, карап карыйк, нинди хәйлә корыр икән бу юлбасар?

Карчыганы күздән жуйган, инде аның турында онытып өлгергән чыпчык-песнәк халкы янәдән җим тактасын сырып алды. Тактаны барабан урынына тукылдаталар. Авызыңны ачып торсаң, ботканың бетеп куюы да бар. Ач карын белән ояңда дер калтырап куну язмасын инде.

Бу беркатлылар артыннан яшерен генә күзәткән карчыга: «Вакыт! Тәвәккәллим!» — дип хәл итте, күрәсең. Җәядән аткан ук тизлеге белән кошчыклар өстенә ташланды. Әмма тегеләр дә сизгер. Сакта торучылары да булган икән. Алар: «Караул! Юлбасар!» — диешкә, чыпчык-песнәкләр як-якка борчак булып сибелештеләр. Ә карчыга сунарчылар дәрте белән мавыкты, ахры. Атылып килә. Көчле канатларының аэродинамика куәтен тыя алыр микән ул? Бу бит коточкыч көч, һавага ничәмә тонналы самолетларны күтәрә. Икесенең берсе: йә хәзер ул җим тактасына бәрелеп коймак була, йә туптан аткан снаряд тизлеге белән тирән кар эченә чума. Бичара!

Әмма ул зур кыенлык белән булса да очу юнәлешен чүт кенә читкә юнәлтә алды. Ләкин бик аз. Тизлеген баса алмады, бар хутына очып, вак ботаклар баскан алмагач арасына килеп керде. Шарт-шорт итеп коры ботаклар сынды. Канатларын нык имгәтте, ахры, башын түбән игән хәлдә ботакта асылынып калды. Ул да булмады, шап иттереп кар өстенә килеп төште. Ята. Селкенми. Мин инде килмәкче, аны кардан күтәрмәкче, кулдан килгән ярдәмемне күрсәтмәкче идем. Әмма соңардым.

Шушыларның барысы артыннан тагын бер пар нәфесле күз бик игътибар белән күзәтеп торган икән. Монысы күршеләрнең тәмлетамак ата песие — Наполеон. Мин ике адым ясаганчы, ул койма башыннан гына кар өстендә һушсыз яткан карчыга өстенә сикерде. «Прэс, шайтан!» — дип тә өлгерә алмадым. Карчыганы элэктереп, күршеләрнең утынлыгына сызды. Аннан аны, ачкүзне, кран белән дә өстерәп чыгара алмыйсың.

Ни генә әйтсәң дә, тере җан. Бик кызганыч булып китте миңа бу бичара карчыга. Мескенем. Ләкин бу очракта: «Башкаларга кое казыма, үзең чумып куймагаең», — дип әйтергә генә калды шул...

Төп мәсьәләгә кагылмый да...

Шушы юеш борыннар, ягъни маэмай халкы белән күптәннән әшнәлек йөртүемне дус-ишләрем яхшы беләләр. Шулай инде, башымны иеп сәлам бирмичә, кочагыма алып сөймичә, алар яныннан битараф кына узып китә алмыйм. Бу, минемчә, мөмкин дә түгел. Яфрак колакларын салындырып, ниндидер сөйләп бетергесез сагыш тулы акыллы күзләрен төбәп сиңа карап торалар бит алар. Авызыңнан чыккан бар сүзеңне аңлап, төшенеп, отып баралар. Кайтарып җавап бирергә, моң-зарларын сөйләргә телләре генә юк бичаракайларның. Тузанга-пычракка батканнарын да, баштанаяк тигәнәк сарганнарын да, барып сыеныр почмак таба алмыйча, вокзал-пристань тирәсендә көн итәргә тырышып йөргәннәрен дә ишегалдыма күп күтәреп кайттым инде. Аларның миндә өчкә-дүрткә, хәтта бишкә-алтыга җиткән чаклары да булды. Ләкин болары аның вак нәрсә һәм төп мәсьәләгә кагылмый да...

Ә-ә, сез Джекны сорыйсыз инде. Әйе, мин аны шактый сәер шартларда сатып алган идем шул. Җәйге бер матур көндә Казаннан кайтып килешем иде. Кама ярында байтак вакыт паром көтәргә туры килде. Гадәттә ике як арасында әрле-бирле йөреп торган дүрт паромның бүген сыңары гына күренә. Андый чакта, билгеле, халык гасабилана. Катлы-катлы итеп пристань хуҗаларын сүгүчеләр дә бар, эч пошканнан, кан оешканнан берәрсе белән якалашып алырга якадаш, кулдаш, билдәш эзләп йөрүчеләр дә юк түгел. Ләкин болары аның вак нәрсә һәм төп мәсьәләгә кагылмый да...

Шунда күрәм, пионер галстугыдай кып-кызыл күлмәк, кыршылган джинсы кигән студент яшьләрендәге озын сыйраклы чибәр генә бер егет дебаркадер янында тана хәтле овчаркасын сатарга ниятләп тора. Халыкта аның кайгысымы соң! Һәркем якты чакта тизрәк өенә кайтып җитәргә дип дүрт күз белән теге яктан паром чыкканны көтә. Ә мин бу егет яныннан алай борын чөереп кенә узып китә алмадым, янына килеп сигарет суздым, берәрне көйрәтеп җибәрдек. Карыйм, овчаркасы шәп моның, парин. Бер дигән европейский, овчарка, каһәр! «Утыр!» — дисәң, шып итеп утыра. «Ят!» — дигәч, шундук җиргә сузыла. Кыскасы, ни боерсаң, шуны үтәргә әзер тора. Әмма шунысы сәеррәк, бу егет нишләптер бик арзан, нибары егерме биш сум гына сорый. Чынында исә мондый өйрәтелгән овчаркалар түгел, алардан туган нәселле көчекләр дә йөз сумнан өстә йөриләр. Аларны әле шул бәягә дә таба алмыйсың. Хәер, монысы аның үз эше. Бәлкем, аның квартирасы кысынкылангандыр, кинәттән генә гаиләсе ишәеп киткәндер. Яисә хатыны, бу ачкүз ерткычыңны теләсәң кая куй, югыйсә үзеңне дә кертмим, дип кисәтеп чыгаргандыр. Дөнья булгач, хатыннарның андыйлары да очрый... Ә бәлки, аңа тиз генә җыйналып ерак юлга, ашыгыч сәфәргә чыгаргадыр. Хәер, болары аның вак нәрсә һәм төп мәсьәләгә кагылмый да...

Ә минем шатлыгым эчемә сыймый. Шундый овчарканы кулга төшерү турында күптәннән хыялланып йөри идем. Шыгырдап торган егерме бишлекне әлеге егеткә бер дә кызганмый, күпсенми суздым. Игелеген күрсен. Муенчакны үз кулыма алдым. Кире уйлап куймасын тагын, дим. Дипломлы маэмайлар белән эш итүе җан рәхәте бит ул. Муенчак кем кулында булса, хуҗасы итеп алар шул кешене таныйлар, аңа берсүзсез буйсыналар. Джек та, мине хуҗасы итеп тануын күрсәтеп, шунда ук кулымны ялап алды. Әйтәм ич, шатлыгым эчемә сыймый.

— Менә, картлач, һич көтмәгәндә генә миңа юлдаш булып куйдың бит әле. Син шатмы шуңа? Мин үзем бик шат, — дип, башыннан сыйпыйм. — Кайгырма бер дә, менә күрерсең, без синең белән бик якын дуслар булырбыз әле. Яратам мин сезнең братны...

Ә егетем исә овчаркасы белән саубуллашып та тормады. Үз нәүбәтендә ул да, бу беркатлы агай кире уйлап, маэмаемны кайтармасын, дип шүрләде, ахрысы. Арт ягына ут капкан төсле кабаланып китеп тә барды. Ярар ла саубуллашмаса, анысы аның үз эше.

Без кайтасы якка ул көнне машиналар агылып тормады. Караңгыга калынды. Чистайда кунып чыгарга туры килде. Кунак йортына эт белән урнашу шулай ук җиңел булмады. Әмма болары аның вак нәрсә һәм төп мәсьәләгә кагылмый да...

Бездә тәртибе шул инде аның, кайту белән Джекны чылбырга утырттым. Күрәм, кулдан килгән бар осталыгымны салып үз кулым белән ясап куйган ояны ул да ошатты. Эченә дә кереп чыкты. Менеп ятарга яссы түбәсен дә килештерде. Юк әле, башта, юлдан кайткан шәпкә, беренче эшебез итеп күлгә төшеп коенып мендек. Маэмаем күземә генә карап тора. Син аңа әмер генә бир, теләсә нинди боерыгыңны шундук үтәргә әзер. «Саклан!» — диюемә, шып итеп киемнәр янына килеп утырды. «Суга кер!» — дип боергач, шупыр-шупыр килеп коенып чыкты. Аның акылына, зирәклегенә хәйран калмалы. Җитмәсә, үзе шат күңелле, койрык чәнчеп уйнарга, шаярырга ярата торган эт егете икән. Йөгереп килә дә аңышмастан гына кулыңнан каптырып ала. Әгәр шунда куркып, сискәнеп китсәң, йөзендә шаян көлү, елмаю чаткылары чагыла. «Менә, хуҗам, күрдеңме, үзеңне ничек сискәндердем», — дигәндәй, койрык чәнчеп читкә сикерә.

Джекны өйдәгеләр дә яратты. Күрер күзгә дә бик матур маэмай ул. Барыбызга да бик тиз ияләште. Йортыбыз да шәһәр читендә. Карак булмаса, угры бар дигәндәй, каралтыңа кем кермәс тә, кем чыкмас. Ишегалдында мондый овчаркаң булганда, йокыңны тыныч йоклыйсың инде аны, егетләр.

Ләкин күрәселәребез алда булган икән әле. Шулай сокланырлык итеп ул бездә ике-өч атналар гына торгандыр. Аннары холкын күрсәтә башлады, мин сиңа әйтим, түз генә. Очлы борынын күккә төби дә тотына уларга, хет өеңнән чыгып кач. Төне буе шулай ямьсез итеп улап чыга. Каршына басып орышып, бармак янап кисәтеп тә карадым. Алай да аңламагач, ишегалды себеркесе белән дә берәрне сыптыргаладым. Барыбер файдасы юк, улавын белә. Ниләр генә булды моңа, дибез. Төрлечә уйлап карыйбыз. Чү әле, мин әйтәм, бу бит бер дигән эт егете, күрше-тирәбездәге берәр чибәр генә эт кызына күзе төшкәнме, гыйшык утларында шулай саргаямы икән әллә? Әнә күрше урамда гына эт туе бугай, әллә шунда башкода булып катнашасы киләме? Була торган хәл, заманында барыбызның да башыннан узды. Әйдә алайса, мин әйтәм, бераз җилләнеп кайт. Берүк дөньяңны онытма, вакытында кайткан бул, артыңнан эзләп чыгарлык итмә, ишетсен колагың! Чылбырдан ычкындыруым булды, Джегым, капканы ачканны да көтмичә, ике метрлы койма аша урам якка сикерде дә юк та булды. Хәер, болары аның вак нәрсә һәм төп мәсьәләгә кагылмый да...

Шул китүеннән ул ун көннәр чамасы югалып торды. Мин эзләмим, ул кайтмый. Артыннан эзләп чыгарга калгач, ни була инде ул? Андый эттән игелек көтмә инде син. Тәмам югалды, элеккеге хуҗасына качуы булды, күрәсең, дип тора идек инде. Әмма беркөнне кайткан бит бу. Оясы алдында, тавыклар казынып туздырган туфракта гамьсез генә йоклап ята. Ике тавык чебеше моның сыртына менеп кунаклаган, тәмләп черем итеп утыралар. Чү, ни булган соң моңа? Әллә агу биргәннәрме, үлгәнме әллә? Ныклабрак карасам, күзләремә ышанмый торам: овчаркам лаякыл исерек.

Җитмәсә, күрше хатыны кереп җиткән, шап та шоп бот чаба:

— Бу хәлендә ничек кайтып ауган диген! Ничек әле милициягә, айныткычка эләкмәгән!

Джек рәткә керә алмыйча өч көннәр газапланды. Тәгам ризык капмады. Алдыннан суны өзмәдек. Шул суны гына әледән-әле шупырдата бичара. «Ни булды, ничек бу хәлгә төштең, балакай?» — дим. Кызганыч бит. Башыннан сыйпыйм. Әллә берәрсе, юри шаяртып, аракыга-сырага манып, колбаса, ит кисәге каптырдымы? Кем ул хайваннан туган нәрсә? Күрсәт син аны миңа, үз күз алдыңда муенын борып ташлармын, дим. Маэмаем дәшми. Зур гөнаһ кылган кешедәй башын аска игән. Оятыннан керер җир тапмаган төсле. Ни дияргә дә аптыраш. Кызганып башыннан сыйпаудан гайре мин дә берни эшли алмадым.

Ул арада печән өсләре җитте. Урманчылар белән сөйләшеп, үзем дә бер түгәрәк алан алдым. Өмә ясап шуны чабарга кирештек. Печән чабу мәшәкатьләре белән Джекның «салып» кайтканы да онытылды. Урманда шалаш корып, төн кунып, ике атналар чамасы шул печәнне сакладык. Бу көннәрдә Джек үзен ышанычлы иптәш, уңган булышчы итеп танытты. Иртәнге якта бер, кичке якта икенче тапкыр авызына зур сумка каптырам да авылга озатам. Ике якка унбиш-уналты чакрымнар җирне арага да санамый. Пешкән ит, кайнар коймак, салкын әйрән салган сумканы кабып килеп тә җитә. Куе сөт өстенә, салкын кваска кинәндерде генә. Ә караңгы төшсә, ник бер керфек каксын. Түгәрәк аланга читят кешене аяк та бастырмый, печән саклый. Төштән соң, көннең үтә эссе чагында, шалаш күләгәсе астына кереп, без дә бераз черем итеп алабыз. Джек та безнең янга килеп ята. Ике алгы тәпие өстенә башын салып, тирән уйларга чума, вакыт-вакыт авыр итеп сулап куя. Андый чакларны борчымыйм.

Уйлансын әйдә. Уйлану, алда яшисе көннәргә матур планнар корып кую кемгә дә комачауламый. Аңа исәп-хисап йөртү бигрәк тә кирәк...

Урманнан кайткач, мин аны тагын чылбырга утырттым. Күп тә узмады, бу тагын дөнья бетереп уларга тотынды. Себерке белән генә түгел, чыбыркы белән сыптыруның да файдасы юк. Башка чара калмагач, янәдән иреккә җибәрдем. Берәр атна чамасы югалып торганнан соң тагын шулай ләх булып кайтты бу. Анысы әле аның бер хәл. Таныш-белешләр аны пивнушка тирәсендә күргәннәр. Ул анда теге «профессиональ кызыл борынлылар» белән дуслашып алган. Тегеләр команда бирәләр, бу үти: утыра, ята, шуыша; алкашлар исә моңа, аракыга манып, ипи сыныклары, сыр-колбаса каптыралар икән. Хәтта бер танышыбыз Джекның пивнушкада, арт аякларына басып, өстәл артында бер алкаш белән бер кружкадан сыра эчеп торганын да күргән.

Кем әйтмешли, юкәдә икән чикләвек. Ниһаять, төшендем мин. Теге чакта хуҗасы аны миңа менә ни өчен шулай арзанга биреп киткән икән. Джек, бичара, алкоголик. Хронический әле җитмәсә. Ничек бу хәлгә төшкән соң ул? Фән, галимнәр аңлатканча, бу коточкыч чирне аңа эчкече атасы белән эчкече анасы мирас итеп калдырганнармы? Әллә элекке хуҗалары, уйнап-шаярып, аңа аракыга-спиртка манылган калҗалар каптыргалап, көчек чагыннан ук бозганнармы? Хәтеремдә әле, малайлыктан чыгып, егет булып җитешә алмый алҗыган чакларны андый шуклыкларны үзебез дә эшләп куя идек. Аракыга манган ипи кисәкләре ыргытып, күрше әтәчләрен исертә торган идек. Безгә, башка юаныч тапмаган авыл шукларына, бу бик кызык тоела иде. Әмма аларның берсе дә алкоголикка әйләнмәгәндер. Әтәчләр озак яшәми, хуҗалары аларны бик тиз казанга озата бара...

Әгәр дә Джекны хуҗалары шулай бозган булса, бу җирбитләр бичара маэмай каршында гына түгел, ә Табигать-анабыз каршында да һич гафу итмәслек җинаять кылганнар. Бу күңелсез нәрсә хәзер дөньякүләм проблемага әверелеп бара... Әмма аякка басарга теләгән адәм, дәваланып, кеше рәтенә керә ала. Ә менә Джекны, Табигать-анабызның дүрт аяклы нарасыен, кайда, ничек дәваларга? Мөмкинме соң бу?

Джек шулай бер көйгә яши бирде. Хәер, яшәми нишләсен? Хәзер аны кая куясың? Тәмәке төпчеге генә түгел, чүплек башына ташлап китә алмыйсың. Ике-өч атна күзен дә йоммый ишегалдын саклый. Айнык чагындамы? Аннан сизгер, аннан тырыш этне таба алмыйсың. Ишегалдыбызга хәтта чит тавыкны да кертми. Аннары инде берәр атна югалып тора. Андый чакта, үзең ычкындырмасаң, муенчагын чәйнәп, чылбырын өзеп кача. Качуына да, кем әйтмешли, исереп кайтуына да түзәр идең. Кешедән, таныш-белештән уңайсыз. Очраша-нитә калсаң (әйтерсең бу дөньяның бар кызыгы шул!), барысы Джекны сораша башлый. Имеш, алкашыгыз ни хәлдә? Айныткычка эләккәне юкмы? Штраф түләтеп теңкәгезне корытмыйлармы? Әлегә шөкер генә, андый җирләргә эләккәне юк, дим. Эзләп алырга калдырмый, дим. Шушы хәл күпләр өчен коточкыч фаҗига түгел, ә көлке генә. Әйе, өебезгә кайтып егыла. Эзләп алырга калдырмый. Ике-өч көн аунап ята да аяклана. Аннары инде:

— Монысы соңгы тапкыр, хуҗам, кичер. Ул агуны бүтән гомеремдә авызыма аласым юк, — дип ялварып шыңшый, аягыңа ятып гафу үтенә. Аннары инде үзен кая куярга, башын кайсы ташка орырга белми.

Бичара җан, ничек шулай үкенә беләдер? Аңлыйбыз без аны, орышмыйбыз да, оялтмыйбыз да. Тәмам бозганнар аны, кешелектән, түгел лә, этлектән чыгарганнар. Хәзер инде берни дә эшләп булмый.

Ул шулай яшәгән дә булыр иде, бәлки. Яшәми нишләсен? Куып чыгарсаң, барыбер кайтачак. Капкаңны бикләсәң, койма өстеннән сикереп төшәчәк. Аннары, бичараны кызганабыз да, ни дисәң дә, тере җан бит. Табигатькә үпкәләр урын юк. Ул аны камил акыллы, талантлы итеп яраткан. Аның күкрәгендә дөп-дөп килеп батыр йөрәк тибә. Ләкин Джек пивнушкалар тирәсендә соңгы тапкыр югалып йөргәндә, ниндидер малайлар ишегалдында торган бишекле мотоциклымны тәмам «чишендереп» чыкканнар. Карап торган бер транспортым иде. Ансыз мин ике кулсыз. Бу юлы инде ачуым чиктән ашты. Ишегалдында тана хәтле овчарка асра, ә матаеңның рулендәге көзгесенә хәтле салдырып алсыннар, имеш! Бу хәтле басымчак итүгә, белмим, кем генә түзәр икән?! Джекка да ышанычым тәмам бетте, күңелем суынды, өметемне өздем. Ахырда мин аннан котылырга карар иттем. Башка чара юк, ба-бах иттерергә туры киләчәк. Ләкин моны да бик яшерен эшләргә кала. Чөнки җиңгәгез дә, балаларым да Джекка тел дә тидертмиләр, мин орыша башласам да, аны якларга гына торалар.

Беркөнне капка төбенә өсте бөркәүле машина белән кайтып туктадым. Чираттагы запойдан соң инде өч көн аяклана алмый яткан ярты центнердан авыррак Джекны шофер егет белән икәүләп көчкә күтәреп кузовка салдык та шәһәрне төзекләндерү, яшелләндерү конторына төшеп киттек. Анда минем таныш каравылчым бар. «Салуын ташламаса, син аны минем янга алып төш. Уналты калибрлы пушкам баш очымда гына тора, мин аны сиңа маминт афармит итеп бирермен», — дип сөйләнгән иде. Шуның янына юл тоттык. Хәер, болары аның вак нәрсә һәм төп мәсьәләгә кагылмый да...

Джекны әйтәм, картлач, кая алып баруыбызны сизенде, ахры. Сизмәс, бар! Бик тә зирәк акыллы җан бит ул. Кинәттән генә айный төште, күзләре җанланды. Алай да карышмый тагын үзе, ике күзеннән мөлдерәп яшьләр генә ага. Хәер, үз хәленнән үзе дә туйган булгандыр инде, бичара. Башкача чара юклыгы белән үзе дә килешкәндер.

Тормышта бит ул син дигәнчә генә булып тормый. Төшсәк, әлеге агай үзе ләх, аякларын як-якка ташлап, гараж күләгәсендә мәрткә киткәндәй йоклап ята. Барып уяттым, әлбәттә. Баш ими дә хәлең юк. Җәллад вазифаларын башкару күпләрнең кулыннан килми. Ярады тагын, ничек изрәп йокласа, шулай әсәрләнеп уянды да. Йөгереп барып, Джекны карап килде.

— Бер кыш чыккан тана хәтле бар, валлаһи! Моннанмы?! Мин моннан ун бүрек тегәм, беләсеңме, ун бүрек! — дип ары бәрелде, бире сугылды. Әмма «баш очында гына тоткан пушкасы»н бу юлы тапмады. Әллә инде каядыр куеп оныткан, әллә инде сатып эчкән. Озак баш ватып тормады, гараждан зур пычак тотып чыкты. Бармагы белән капшап карады, үтмәсрәк тоелды, ахры. Электромоторны тоташтырып, аны наждакта кайрый башлады. — Чак кына көтегез. Хәзер була...

— Юк, пычак белән кых иттермим. Без алай сөйләшмәгән идек, — дидем. — Мылтык белән булса әле бер хәл, бах иттең, эше бетте. Әмма пычак белән кагылдыртмыйм.

Шофер егет тә миңа ярдәмгә килде:

— Ул бит әле нәселле овчарка. Пычак белән өстенә килсәгез, үзегезне буып ташлар,— диде.

— Алайса, сез аны калдырыгыз. Әнә теге почмакка төшереп бәйләгез. Үземнекен тапмасам, иртәгә күрше мылтыгын алып төшәрмен. Бер дә шикләнмәгез, маминт афармит итеп куярмын.

— Ә ул үзен афармит иткәнне көтеп иртәгегә кадәр шушында утырырмы? — дидем мин, бу сорауны беренче чиратта үз-үземә биргәндәй. — Калдырмыйм. Без алай сөйләшмәдек.

Әлеге агай, минем халәтемне аңлагандай булып:

— Кызык та кеше инде син, дустым,— дип, башын кашып алды. — Ул чагында син болай ит. Инде машина яллагансың икән, көнеңне бушка уздырма. Туп-туры заготконторага менеп кит. Андагы егетләр мин түгел. Тиресен салдырып ничек казыкка элгәннәрен маэмаең сизми дә калыр. Үзеңә бер яртылык акча да тоттырырлар әле. Ah, каһәр, пушкамны кая гына куйдым икән, нинди керем кулдан ычкына бит!

Анысы шулай... Тиресен салдыруны булдырырлар. Күңелне биләгән авыр хисләрне сүз белән әйтеп бетererлек түгел. Мин тирән хәсрәткә чумдым. Тегеләй дә, болай да уйлап карыйм. Минем өчен зур кайгы, ә берәүләр шуны гади бер бүрек үлчәме белән генә үлчәмәкче. Йа Хода, бу дөньяда кемнәрең генә юк! Шунда ук үземне дә орышып ташладым. Тәти агай булып кыланырга сиңа гына бир. Атарга, юк итәргә дигән Джекны салган машина белән бирегә төшеп туктаучы үзең бит. Алай дисәң, бу исерек җаннан кайчан да булса барыбер бер котылырга кирәк бит инде. Шулай булгач, икеләнеп торасы түгел. Тәвәккәлләргә икән тәвәккәлләргә! Ә машина инде заготконторага җитеп килә. Эчемдә һаман да каршылыклы уйлар уйнаклый. Тукта, агай, ашыкмыйсыңмы, дим. Соңыннан үкенерлек булмасын, дим. Әллә киregә борылыргамы?

Ул арада заготконтораның мөгезләрен тырпайткан поши, тешләрен ыржайткан кабан дуңгызы, йөгереп баручы кыр кәҗәсе сурәтләре төшерелгән буяулы биек капкасы күренде. Кулымны рульгә салып, кире борылырга ишарәләдем. Җитмәсә, шофер да яхшы егет, синең хәлеңне берсүзсез аңлый торган зат булып чыкты. Карышмый да, сүз дә әйтми, кай якка ымласам, машинасын шунда бора. Тигез асфальт юллардан калын-калын урманнар аша кичеп тә, әле яңа гына сөрелгән иген кырлары өстенә килеп чыгып та, ул көнне байтак җирләрне айкадык без. Күп нәрсәләр турында уйлап бетердем. Аталарча тирән сыкрау белән, кара син бу алкоголь афәтен, дим. Шушы хәшәрәт нинди ир-егетләрне хур итеп ташламый. Башкайларын кылыч белән чапкандай гына тәгәрәтә. Инде хәзер Ходайның дүрт аяклы нарасыйларына керешмәкче була, агулы угын аларга төби башлаган. Джек шуның конкрет корбаны. Инде нишләргә соң? Кая барып карарга? Шунда кылт итеп исемә килеп төште: күрше районда бер таныш умартачым бар. Аның белән узган елны гына Казанда бергә киңәшмәдә булган идек. Кунакханәдә бер бүлмәдә тордык. «Умарталыгыбыз авылдан ерак, шуны сакларга бер яхшы гына маэмай табасы иде», — дип сөйләнгәне хәтеремдә. Арабыз да ерак түгел, күп булса туксан-йөз чакрымнар булыр.

Шул фикерем авызымнан чыгуга, шофер егетем башын гына какты:

— Киттек!

Умарталыкка кичке якта килеп җиттек. Хәер, болары инде аның вак нәрсә һәм төп мәсьәләгә кагылмый да...

Килеп туктавыбызга, каршыбызга чәң-чәң килеп бер әнчек йөгереп чыкты. Бәхеткә каршы, Тимерша агай үзе дә умарталыгында иде. Сәлам биреshtек, күреshtек. Пыскып яткан учагына чыбык-чабык өстәп, чәйнек асты. Алдыбызга табак белән кәрәзле бал китереп куйды. Хәл-әхвәл сорашып алдык.

Джекны да җиргә төшереп бастырдым. Көнозын кузовта җилләгәч, тәмам айнып өлгергән иде инде. Киерелеп-сузылып буыннарын язды. Урманны яңгыратып «hay-hay» дип тә куйды. Койрык чәнчеп чабып, әйләнә-тирәне барлап килергә дә исәбе юк түгел. Кая китерүләрен ул тиз төшенеп алды. Биредә аңа, һәрхәлдә, мылтык белән янамаячаклар. Картлачның кәефе бөтенләй башка. «Джек, тавышланма, кил минем янга, менә шунда гына утырып тор», — дим. Тимерша агайның күзе аңарда гына.

Бераздан, умартачыларча турыдан бәрдереп:

— Күпме сорасаң да сора, сат син моны миңа,— диде ул.

Без шофер егет белән күзгә-күз карашып алдык, икебез дә елмаеп куйдык.

— Бушлай бирәм, Тимерша агай, алып кала гына күр, — дидем. — Әмма соңыннан үкенмә берүк. Бу кара борынның бик начар гадәтләре дә бар... Ул аларны еш кына күрсәтеп тә ала...

Калганын инде яшерми-нитми генә сөйләп бирдем.

— Һәй, исең киткән икән! Уламагае, уласын! — дип, Тимерша агай сүземне ярты юлда ук бүлдерде. — Улый гына бирсен, умарталыкка карак-угры килмәс. Җаным тыныч булыр, татлы төшләр күреп йоклармын.

— И-и, Тимерша абзый, улап кына калса икән! Аның әле кача торган гадәтләре дә бар. Муенчакларын салып, чылбырларын өзеп...

— Миннән кача алма-ас! Боларны миңа авылга электр керткәндә монтажчы егетләр биреп калдырган иде, — дип, әвеслек астыннан ике колач озынлыгындагы, әле күгәрергә дә өлгермәгән чылбыр кисәге алып чыкты. — Бу чылбыр белән, энем, нәсел үгезен, арысланның үзен арканларга була.

Мәсьәләнең шулай уңай хәл ителүенә сөенеп бетә алмый, шат күңел белән кайтыр юлга чыктык.

Урыны яхшы Джекның, тик улап ятсын. Әмма ул бик үзсүзле җан иде шул. Умарталыктан да качкан, каһәр. Шул тирәдәге авыл кибетләре артында аның бер яртыны өчкә-дүрткә бүлеп торучылар янында буталып йөргәнен дә, ләх булып исереп тузанда аунап ятканын да күрүчеләр булган. Бу турыда ишетү белән, мин эзләп барып та карадым. Тапсам алып кайта идем. Бәлки, берәр ничек дәвалап караган булыр идек. Тапмадым шул. Кайларда михнәт чигә торгандыр инде, җанашым? Хәер, болары инде аның вак нәрсә һәм төп мәсьәләгә кагылмый да...

Әмма урманда аерылышу, саубуллашу вакытындагы бер күренеш әле дә хәтеремдә. Джек биредә, умарталыкта каласын тиз төшенде. Төшенмәс ул сизгер җан! Аңа бераз ямансу, шыңшып үзен кызгандырырга да исәбе бар. Шул ук вакытта аңлый да төсле, чөнки башка чара юк. Аның каршына басып, башыннан сыйпап, колак артын кашып торам. Саубуллашу миңа да җиңел түгел. Джек миңа төбәлгән, ә мин кичке саф җилдә салмак кына тирбәлгән усак очларына, баш очыннан аккан болытларга карыйм. Аның күзләренә карарга кыюлыгым җитми. Ни генә булмасын, үземне хыянәтче дип хис итәм, агач башларына төбәлгән килеш тора бирәм.

Бу зирәк җан шунда үзе ярдәмгә килде, ал тәпие белән шап иттереп миңа китереп сукты. «Син, хуҗам, бер дә юкка шулай борчылма әле. Ул хәтле тирән хафага төшәрлек бернәрсә дә юк. Бер-беребезгә үпкә-зар тотышмый гына аерылышыйк. Булмаса, бир бишне!» — диюе булгандыр инде.

Джекның дүрт бармак эзе минем плащта әле дә саклана. Аны кат-кат юып та бетереп булмады. Хәер, болары аның вак нәрсә һәм төп мәсьәләгә кагылмый да...

Баһбайлар ял йортында

Тиктормас, бер урында утырып тормас холкым белән берчакны мин Балтыйк диңгезе буендагы Клайпеда каласына ук барып чыктым. Бу шәһәрдән берничә чакрым гына читтә, шушы сүзнең тулы мәгънәсендә, атлар, баһбайлар санаториесы бар икән. Күп уйлап тормадым, такси ялладым да шунда киттем. Озак та бармадык, такси мине «Атлар санаториесы» каршына китереп төшерде.

Эш менә нәрсәдә. Французлар бездән елның елында шактый гына атлар сатып ала икән. Сәүдә, алыш-бireш эшләре Клайпеда аша башкарыла. Тезгенне белмәгән, иярнең нәрсә икәнен татымаган өч-дүрт яшьлек елкыларны Казакъстан далаларыннан Клайпедага хәтле үз көйләренә куалар икән. Малларны вагоннарга төяп йөртүгә караганда болай куу, әлбәттә, уңайрак. Аларны станция саен туктап ашатасы-эчертәсе, асларын чистартасы юк. Алай да күп чакны ике-өч айга сузылган бу сәфәр аларны өшәндерә, ялыктыра. Баһбайларны бу хәлләрендә сатып җибәрү аларны бушлай бирү белән бер булыр иде. Шуңа күрә, Клайпедага килеп җитү белән, аларны өч-дүрт атналык ял йортына урнаштыралар икән. Саулыгы какшап киткәнен дәвалыйлар, озын юл үтүдән кәегеп, арыгып, өшәнеп калганнарын симертүгә куялар.

Һәй, егетләр! Монда килеп кергәч, беркавымга зиһенең таралып китә. Әкият дөньясына эләккәндәй буласың. Баһбайларның торган җирен бер самавыр чәйне корытмый сөйләп тә бетергесез. Беренче класслы курорт бу! Зур, якты, чиста бараклар. Ат абзары түгел инде болар, ә дәвалану, ял итү палаталары. Стеналары, мин сиңа әйтим, ак кафельдән. Улаклардан чылтырап чишмә суы агып тора. Караучылар да йөзен сакал баскан кунних агайлар түгел, ак халатлы, галстуклы тәрбиячеләр. Их! Айгырларның үзләрен күрсәгез икән! Яратып, сөеп туйгысызлар. Көрләр, матурлар, чисталар. Ялларыннан сыпырсаң, кулың артыннан чытыр-чытыр килеп электр очкыннары ияреп бара.

Аз гына ятсынып һәм шул ук вакытта: «Бу ят кеше кем соң, биредә нишләп йөри?» — дигән сыманрак кызыксынып миңа төбәлгән айгырлар арасында наяннары бар. Якын килмә, ялыма кагыласы булма, тешлим, кара аны, беләгеңнән каптырам, дип, бик усал баш айкаучылары да юк түгел. Әмма минем өчен алар барысы да нарасыйлар. Ә тәмлегә, күчтәнәчкә, йә, әйтегез, нарасыйларның кайсы

алданмый? Атларның алданычы — шикәр-печенье, конфетны портфель тутырып алган идем. Шулар белән сыйлый башлагач, айгырларның иң усаллары, иң кыргыйлары белән дә уртак телне бик тиз таптым. Барысын бер туйганчы кочаклап-кочаклап, ялларыннан сөеп чыктым.

И-их, егетләр! Атларны яратмаган кеше буламыни! Ә мин үзем аларны гомер буена сүнмәс-сүрелмәс бер кайнар мәхәббәт белән яраттым. Бер уйласаң, гажәп инде, үзе ачы, үзе дегет сыман куе тир исе минем өчен иң тәмле, иң затлы хушбуй исләреннән дә татлырак. Яшь колыннарның әнкәсенә иркәләнеп, нечкә генә итеп ярым кыргый айгырларның топ-топ тибеп дөньяны яңгыратып кешнәвен, валлаһи, симфонияләргә тиңләп тыңлыйм. Үзегез дә тыңлап карагыз әле: тигез таш юл өстеннән дагалы атның чаптырып килүе симфония түгелмени?! Ә нигә таш юл гына? Кышын чатнама суыкта, терәкле чана җигеп, җиз кыңгыраулар тагып чапкан атлар начармыни?

Урап-урап карлар күмә
Кышның озын юлларын.
Чың-чың итә, җил тузгыта
Җиз кыңгырау моңнарын.

Кемне генә җилкендерми дә, кемне генә сискәндерми икән бу җыр! Ә миңа ул бала чагымның матур истәлекләрен хәтерләтә, күңелемне татлы уйлар, тәмле хыяллар диңгезенә сәяхәткә алып чыга.

Җиз кыңгырау, көмеш моңнар
Уйлата синең хакта.
Синең хактагы уйларым
Яшьлеккә алып кайта.
Уйлата синең хакта.

Җиз кыңгырау моңнарында
Үткәннең тавышлары,
Очрашулар, кавышулар,
Аерылу сагышлары.
Үткәннең тавышлары...

...Ул чакта без кечерәк кенә район үзәгендә тора идек. Кечерәк дип тик болай, чагыштыру өчен генә әйтүем. Югыйсә кырыклап зур-зур авылларга баш, аларга чын мәгънәсендә башкала вазифаларын башкарган үзенә күрә эшлекле генә бер үзәк иде ул. Гомерләре эчендә теге яки бу йомышлары чыгып, шушы үзәккә ерак авыллардан килгән җирән сакаллы агайлар исә:

— Ә-әй, парин! Күр әле син тушы Төпҗазның зурлыгын, чын кала бит, әй! — дип исләре, акыллары китеп йөриләр иде.

Зурлыкка әллә ни зур булмаса да, бик матурлап, авыл кешесенең күңелен кытыклардай итеп, тәрәзә капкачларын, түбә кыекларын төрлечә бизәкләп салган ике катлы райком бинасы каршына басып, шуның мәһабәтлегенә сокланудан зиһеннәрен җыя алмый торырлар иде алар. Ерак авыллардан килгән агайларның күбесе әтинең танышлары, дус-ишләре булып чыга. Йомышларын көнендә юллап бетерә алмасалар, безгә кунарга керәләр. Әни өстәлгә табада кыздырып суган салган, мул итеп бөтнек сипкән сөтле аш чыгарып утырта. Әти кунакны ничек кенә кыстаса да, авыл агае алай кинәттән генә кашыкка үрелми. Сүзне һаман да шул тормыш итү, көн күрү, дөнья хәлләре турында куерта. Безнең район үзәген җәннәткә тиңләп:

— Дөньяның урта бер җирендә яшәп ятасыз икән. Менә ичмасам тормыш! — дип куя. — Авырсаң-нитсәң, тау астында гына бүлнисегез, ысталаваегызда ничә сугылсаң да кайнар аш. Сарык-мазар суйсаң да, артык кишер-суганың булса да чыгарып сатарга атна саен базары булып тора. Болары булгач аның, гурыт җире — Казаның бер читтә торсын!

Авыл агаеның безнең район җирендәге тормышны бик ошатып, чын күңелдән сокланып сөйләп утыруын әти дә килештерә. Ул үзе дә ачылып китә. Әлеге бүлнис ул нәрсә, менә быелдан башлап яңасын салырга керешәбез, ди. Күз бүлнисе аерым, тешнеке аерым булачак. Такта яру, кирпеч сугу заводлары салдырырга җыенабыз, дип сөйләргә керешә. Аларның мондый тәмле гәпләре әни өстәлгә самавыр китереп куйгач та, инде утны сүндереп йокларга яткач та дәвам итә.

Авыл агайлары яшәү өчен уңайлыкларын шәһәр җиреннән болайрак күреп бәяләгән шушы район үзәгендә минем әти бик үк зур булмаса да, район масштабларыннан чыгып сөйләгәндә, бик кечкенә кеше дә түгел иде. Район җитәкчеләре арасында беренче дистәгә үк кермәде микән әле? Һәрхәлдә, аңа, үз вазифаларын башкарганда, җигеп йөрү өчен тарантаслы бер ат тотарга рөхсәт ителә иде. Елкың булгач, аны караучысы, ягъни куннихы да кирәк бит. Ул чакларда эшче куллар җитмәде микән, әллә башка сәбәпләре булгандырмы, әти үзенә кунних булып килердәй кеше таба алмый интекте.

Беркөн шулай кич чәй янында:

— Ат ябагасына батып, өс-башыма дегет, ат тире исен сеңдереп, миңа ат тугарып, арба майлап йөрү килешми. Ә куннихлыкка килүчеләр күренми, — дип сөйләп китте.

Әтинең алдына чәчрәп мин килеп бастым. Сүзен әйтеп бетерергә дә ирек бирми:

— Әти, үземне генә ал! Үкенмәссең! — дидем.

— Белмим инде, прәме аптырагански, — дип куйды әти. — Аны үзем дә шулайрак уйлаган идем, укуыңа зыян килмәгәе дип шикләнәм.

— Укумы? Гел «бишле» булачак, — дип, әтинең ул шикләрен дә юкка чыгарырга ашыктым. — Әти, хезмәт хакын түләрсең ич, шәт? Анысын җыеп барам, гармунга.

Әти дә тәвәккәл кеше.

— Алайса, яз гаризаңны, кул куярмын, — диде. — Башта бер айлык сынау узарсың.

Килешүнең гамәлгә керүен раслап, без әти белән кул сугыштык.

Ул чакларда әле алтынчы класста гына укып йөрсәм дә, ат җигеп-тугаруны гына булдырам. Моңа чаклы да, әтинең берәр җиргә барасы булса, алашабызны аңа мин җигеп бирәм, кайтып керсә дә, мин тугарып алам. Сүз монда мәсьәләнең юридик ягын хәл итү турында гына барды бугай. Менә шушы көннән мин әтигә ат караучы булып ялландым. Ат җигеп-тугаруга килгәндә, безнең ише малай-шалайның кулыннан килмәслек ике генә уңайсызлык бар. Йөгәнен дә киертәсең, ыңгырчагын да саласың, тәртәләр арасына да кертеп бастырасың. Дуга салуы кыен. Анысына буй җитми, ә камыт бавын тартып бәйләргә көч җитми. Әмма аптырап торды юк. Дуганы бүкән өстенә менеп салам, камыт бавын кысарга әтине чакырам. Мине үзенә ат караучы итеп алганына үкендермәдем инде мин аны.

Вакытында ашатмый-эчертми, өсте ялык-йолык килеп торырлык булганчы ябагадан чистартмый, алашабызны җәен тарантаска, кышын кошевой чанага җикмәдем. Бер атны карау, ашату-эчертү, астын чистарту минем өчен юаныч кына иде ул. Иртән сәгать биштән үк торып басам. Кайнар суда саламын тәмам пешереп, тоз сибеп, берәр кушуч кына арыш оны да сибеп, башак болгатам. Мондый чакта улактан, мин сиңа әйтим, башың әйләнердәй тәмле булып әрем, сукыр кычыткан, бөтнек, каен җиләге исләре килә. Алашам да тәмам тәкатен җуя. Ныклап бутап, саламны тәмам изеп бетергәнне дә көтми. Минем белән талаша-талаша, колагын усал шомартып, улакның бер башыннан башакны чәлдерә башлый. Кулымда ике япьле болгаткыч таягы. Шуның белән кизәнеп куркытмак булам. Кая ул! Таяк белән генә түгел, бастырык белән кизәнсәң дә аерыласы юк. Тәмле бит. Ахырда үзем читкә китеп басам. Алашабызның умырып-умырып башак ашаганын яратып, сөенеп карап торам. Улактан шулхәтле тәмле исләр күтәрелә, алашага кушылып үземнең дә башак ашыйсым килә башлый. Әмма аның тирәсендә алай озаклап юанырга вакытым бик чикле. Сәгать җиделәр якынлашып килә, мәктәпкә чыгып йөгерәсем бар. Аннан да, баласын имезергә ашыккан яшь анадай, йөгерә-йөгерә кайтып җитәм. Алашамны ишегалдына чыгарып, астын чистартам, атланып, бәкегә сугарырга төшеп китәм. Бер атланып алган юлы, ут уйнатып чабып, бөтен авылны әйләнеп кайтам. Кичтән тагын шулай, тәмле итеп башак болгатып бирәм. Төнгелеккә исә утлыгына күп итеп печән салам. Солыны кысынкырак бирәләр иде, аны кая да булса юлга, ерак авылларга чыкканда гына каптыра идек.

Шушы алашадан кала, семьяда олы бала буларак, минем карамакта тагын бик дуамал холыклы сыерыбыз, печкән үгезебез, җиде-сигез аңгыра баш сарык, үләселәрен дә белми гел ат-сыер аягы арасында тирес актарып, солы бөртекләре эзләүче гаң-гаң казлар-тавыклар бар иде. Алашаны аерым меню белән генә сыйлавымны күреп, көнләшүеннән тәмам шашынып, ат абзарына, бер тора торгач, сыерыбыз бәреп керә, улакка ташлана. Сөтлебикәбезнең дуамаллыгын күрегез инде! Алаша аңа бер типсә, аяктан егачак. Әмма алашабыз андый ваклыклардан өстен.

«Сыер сыер инде, аннан тагын ни көтәсең?» дигән төсле, бер читкәрәк китеп баса, аны болгаткыч таяк белән дөмбәсли-дөмбәсли абзардан куып чыгарганымны сабыр гына көтеп тора.

Ишегалдында мал-туар бер көтү булганлыктан, ял көннәре йөге-йөге белән тирес түгеп үтә. Боларын инде бөтен өй эчебез белән чыгып эшлибез. Үзем бит әле мәктәптә дә сынатмыйм. Анда да актив, йә шунда дружина члены, йә учком тирәсенә сайлап куялар. Җыелыш-мазар булса, йөземә бик җитди кыяфәт чыгарып, гел президиумда гына утырам. Шук малайларга бу гадәтләрен яхшы чакта ташларга чакырып еш кына кайнар сүзләр дә сөйләп алам.

Миннән дә бигрәк, атларны әти үзе ярата иде. Шуңа күрә безнең өйдә дә сүз гел атлар, айгырлар, алашалар, колынлы бияләр турында булыр иде. Әти, мәрхүм, бик сәер кеше иде ул. Аның гомер-гомергә өй байлыгы, өй җиһазы, матур кием-салым дип исе китмәде. Аңа ат булсын. Аның бар теләге үз кулына райондагы иң яхшы атны төшерү булды. Ә кем кулында нинди айгыр, нинди җитез аргамак булуын станса юлында сыныйлар. Бер тора торгач, район җитәкчеләрен Казанга киңәшмәләргә, җыелышларга дәшәләр. Ә бездән Казанга эләгү өчен бердәнбер мөмкинлек — башта тимер юл стансасына поездга чыгу. Район оешмаларының җитәкчеләрен ат белән стансага чыгаралар. Кемнең абзарында нинди аргамак булуын менә шунда сыныйлар инде.

Соңыннан бөтен район үзәгендә чамадан тыш бер хәл итеп:

— Егетләр, ишеттегезме әле? Райздрав мөдире стансага нибары фәлән сәгатьтә барып җиткән! — дип сөйлиләр иде.

— Ни мүжет бу! — дип, аңа шунда ук каршы төшәләр. — Арттырсагыз да, чамасын белеп арттырыгыз. Аның кулында да канатлы кош түгел. Ул вакыт эчендә стансага барып җитү практически мөмкин түгел ул!

— Һәй, сез аны әйтәсез! Ә мин зампредны илттем. Чыкканда авылдан барыбыз да бер сәгатьтә чыксак та, стансага беренче булып без барып кердек, икмәктер әгәр! — дип, өченче берәү күкрәк суга башлый.

Безнең район юлаучылары поездга чыга торган Биектау стансасы ярыйсы гына ерак. Райпотребсоюзга, сельпога товар ташучылар кышлыкта бу араны ике көн йөриләр иде. Районнан көн ачылгачрак кына чыгып китәләр дә юлда бер рус авылына кереп куналар. Ә җиңел чанага җигелгән рысакларда иртән караңгы белән чыгып китсәң, көндезге икеләр тирәсендә килүче Казан поездына барып кына өлгерәсең. Ул елны әти Моторны кулга төшергән иде. Менә шул кышны без юри барыннан да соңарып, ашыкмый гына иртәнге чәйләрне эчкәч чыктык юлга. Әмма авылдан егерме-егерме биш чакрымнар киттек дигәндә, бездән алда чыккан атларның соңгысын буран уйнатып узып киттек. Поезд килгәнче, станса ашханәсенә кереп иркенләп чәй эчәргә, атны суытырга өлгердек.

Сугыштан соңгы авыр, хәерче елларда авыл тирәләрендә яхшы, нәселле атлар, айгырлар бик аз иде. Безнең як халкы фронтка куркуны белмәс батыр улларын гына түгел, киерелеп бер кешнәп җибәрсә, фашистның котын ала, тәртәгә җиксәң, әллә нинди авыр пушкаларыңны, тягачларыңны да берүзе өстери торган айгырлар да, ломовой бияләр дә бирде. Алай да нәселле айгырлар анда-санда гына очрап куя. Фронтта югалган тузгак яллы айгырлар, бүрек кадәр бәкәлле бияләр урынына киң Ашыт, мул сулы Илләт буйларында яңалары үсә торды. Тик аларны кулга төшерү генә кыен. Начар, холыксыз, бер дә юктан гына чыгымлый торган баһбайларга юлыкканда, әти ашаудан кала, йокысы кача. Мондый көннәрне тирән хафага төшеп йөри-йөри дә, мине дә алып, мари ягына чыгып китә. Анда аның әле сугышка хәтле үк бергә кече политруклар курсында укыган, фронтта да бергә йөреп кайткан бер дусты бар. Колхоз председателе. Әти марича теттерә генә, теге агай синнән-миннән оста татарча сиптерә. Фронтны искә төшерәләр, русча җырлап алалар. Аннары боларның сүзләре атларга-баһбайларга күчә. Микола абзый безнең ни йомышлар белән йөрүебезне капкадан кергәнче үк сизә инде. Әтигә яхшы, бер дигән айгыр кирәк. Микола абый әтигә колхозы өчен кадак, шифер, түбә калае юклыктан зарланып ала. Әти, кайткач үк хәстәренә керәм, әлбәттә, булышырмын, дип ышандыра. Бик дуслар иде алар, шунда тагын сугыш кырларын, салкын окопларны искә төшереп алалар. Нинди ут өермәләре аша узып та исән калуларына, дөньяларның түгәрәкләнеп килүенә сөенешеп утыралар. Тагын «Огонек»ны җырлап алалар. Микола абыйда өч кыз, әтидә өч малай тәгәрәшеп үсеп киләләр. Нишлибез, өйләндерешәбез балаларны, кодалар булып куярбыз, диешәләр. Ахырда Микола абый бөтенләй юмартланып китә. «Ярар, үземә көтүдә бер дигәннәре үсеп килә», — дип, тезенә сугып куя. Безгә үзе җигеп йөри торган, янына килсәң котың очардай, су анасыныкыдай тузгыган ялык-йолык кара яллары тезеннән түбән алмачуар айгырын күрсәтә. Микола дәдәй миңа хәйләкәр күз кыса:

— Ошыймы?

Мин, бер мәлгә зиһенемне җуеп, телсез калам, башымны гына селкәм.

— Күп сөйләшеп торды юк, айгыр сезнеке, игелеген күрегез, — ди ул.

Безнең якларда «марида халык базык, урман калын» дигән мәкаль бар. Ул чакларда законнар да бик каты булмаган, күрәсең. Документ-фәләннәр белән баш катырды юк, җигеп килгән атыбызны башка-баш алышып, кайтыр юлга да чыгабыз. Кайтканда дилбегәне җил каккандай гына кагып, айгырны сынап карыйбыз. Авызлыкны йомшатып үз ирегенә куйсаңмы, жүләр, алмачуарның давыл уйнатырга исәбе бар! Чанаңнан төшеп калма да, алдагы берәр юлчыны бәрдермә, бәлале булма.

Алыш-бирештән бик канәгать калып, әти:

— Микола дәдәңме?! Микола дәдәң начар ат җикми инде ул! — дип куя.

Йомшак кына чөңгереп, дилбегәне кага. Алмачуар канатлы кош булып алга ыргыла. Әйтәм ич, ул чакларны без бөтен өй эчебез белән ат шөһрәтенә билдән баш иеп яшәдек. Без, малайлар, әтинең өч ташбашы, кулга эләккән һәр кәгазь битенә ат башы ясыйбыз. Алтын яллы аргамаклар турында әкиятләр чыгарып, шигырьләр яза идек. Шуларны кичләрен кычкырып сөйлибез, көйгә салып җырлап күрсәтәбез. Әти дә, без малайлар да пошкырып җибәргәндә танавыннан кайнар бу бәрелә, бер кешнәп куйса, тәрәзә пыялалары зыңгылдый торган айгырлар яратабыз. Әни белән сеңел колынлы бия дип егылып китәләр. Әни, укытучы булганлыктан, мәктәптән кайтып керми. Кышын алай иркенләп терәкле чаналарга утырып йөрергә вакыты да булмый. Ә җәен без бөтен өебез белән кубып әнинең туган авылына, әбигә кунакка кайтабыз. Ул көнгә дугаларны, тарантас-тәртәләрне һәйбәтләп, ялт иттереп кап-кара лакка буяп куябыз. Куябыз дигәч тә, мин инде, барын мин җимереп йөрим — әтинең өлкән улы. Ниһаять, ул көн килеп тә җитә. Тарантас башына без — малайлар менеп кунаклыйбыз. Тарантас түренә киерелеп кереп утырган әти белән әни араларына сеңелне дә алалар. Тарантас башында дырык та дырык барган килеш гармун тартуы кыен булса да, «Галиябану»нымы, «Алмагач»нымы ботарлавымны үзем дә аңламасам да, бак та бак бакасын бакылдатып, тальянымны сузып җибәрәм. Их, күңелле дә, матур да чаклар иде ул!

Менә шулай бер түгәрәк табын булып авылга кайткан чагында әни тарантас яныннан әнкәсенә иркәләнә-иркәләнә кешнәп яшь колын йөгерүен теләр иде. Әнинең күңелен күрми, теләген үтәми дә булмый. Әти, эш арасында бер җаен табып, тагын мари ягына чыгып китә. Микола дәдәйне хатыны

белән үзебезгә дәшеп, бик зурлап кунак итәбез. Әти йә колынлы бия, йә бүген-иртәгә тайларга торган буаз бия алып кайта.

Ә Моторны без зур кыенлыклар белән генә кулга төшердек. Шушы төбәктә туып үскән, районда да дәрәҗәле урында эшләгән әтинең дус-ишләре авыл саен иде. Бездән унике чакрымнар гына читтәрәк Зур Битаманда әти белән бергә педучилищеда укып, бергә армиягә алынган, хәзер мәктәп директоры булып эшләгән тагын бик якын һәм сердәш дусты Газиз абый бар. Елның елында сабан туйларында алар — безгә, без аларга кунакка йөрешәбез. Ә Зур Битаманда сабан туйлары районныкыннан зур булып, кунаклар да Донбасс, Прокопий шахталарыннан, Мәскәүдән, Ленинградтан кайтыр иде. Их, мондагы ат чабышлары! Аларны тагын кайда гына очратырсың икән! Моторны да менә шундагы ат чабышларында күреп алдык инде. Дөрес, ул өченче генә килде. Беренче урынны Битаманның үз айгыры алды. Икенче булып мари ягыннан катнашучы байтал килде. Әмма әтинең күзе җете. Чабышчы малайның аркасына танавын төртеп, мәйданның бер читендә кунак кызыдай оялчан гына торган бу кырыкмышны әллә каян күреп алды. Күреп тә алды, гашыйк та булды. Янына барып, очлы йодрыгы белән зыр иттереп аның кабыргаларыннан сыдырды. Әле чабыштан гына килгән, арыган, әлсерәгән булса да, кырыкмыш баскан урынында чак биеп җибәрмәде.

— Тагын ике елданмы? Тагын ике елдан без бик матур бия булачакбыз, абзыкаем! — дип, әти биянең үзе булып сөйләнә башлады. Кырыкмыш тирәли тагын бер әйләнеп чыкты. — Әле безнең бер карыш үсәсебез дә бар икән. Менә шуннан соңмы, абзыкаем... Аннары мине кара тарантаска җигеп куйсаңмы? Аннары инде сез мине танымыйсыз да!

Моторны марилар белән чиктәш бер зур гына авылдан алып килгәннәр. Без исә бу сабан туена ямьяшел тарантаска өсте ялык-йолык килеп торган, ал, кызыл тасмалар кушып үргән тузгак яллары кочагына сыймас кап-кара айгыр Чегәнне җигеп төшкән идек. Районыбызда дан бер айгыр иде ул. Һәр адымы, мин сиңа әйтим, бригадирның үлчәм таягы. Юлга чыксаң, аруын да, ануын да белми, канатлы кош булып оча. Әмма начар гадәтләре дә бар иде. Үз кәефенә килмәгән чагы булса, тезгенне авызын чимә-чи канга батырганчы каерсаң да баш бирми. Юлдан яхшы гына юыртып барган җирдән каядыр читтә, болында утлап йөргән берәр чибәррәк, яшьрәк бияне күреп алса, тарантасың-ниең белән шунда өстерәп төшеп китә. Көтүгә чыгарсаң да ут йотып торасың. Аннан да, айгырлар белән сугышып, чимәчи канга батып кайта. Әмма бүген Ашыт буенда ул күзеңне алгысыз. Башында кырыйлары чуклы ефәк калфак, муенында көмеш кыңгырау. Мәйдан кararга төшкән малай-шалайның башкада эшләре юк, күзләре безнең Чегәндә генә. Шуны сизә ул, кahәр. Малайларның күңелләрендә егетлек, тәвәккәллек хисләре уятып, әледән-әле гайрәт белән кешнәп ала. Ашыт буйлары әллә нишләп сискәнеп китә. Ә малайлар? Алар һушсыз кала.

Әти исә Моторны шушы үзебезнең Чегәнгә алыштырырга җыена. Өстәвенә тарантасны да кушып бирергә каршы түгел. Әмма Моторның хуҗасы безнең белән сөйләшергә дә теләми. Әтинең дә чигенер исәбе юк. Моторның йөгәнен кулына җыеп тоткан.

Ахырда теге агай да хәйләгә кереште:

— Кай җиренә кызыктыгыз шушы үләксәнең! Ул бит үпкә авырулы. Әнә кабыргалары бармак белән санарлык. Ашаганы тәненә йокмый. Төртсәң, аварга тора, — дип, кырыкмышны хурларга тотынды.

— Анысын син миңа сөйләмә инде, туган, — дип кырт кисте әти. — Беләм мин аның нидән кабыргалары төртеп торганын. Сез аны, ярышка әзерлибез дип, чи йомырка эчертеп кенә тоткансыз. Бер атна гына үз ирегенә куеп каптыру белән командармга бүләк итәрдәй байтал булачак бу.

Әмма Моторның хуҗасы ни теге якка, ни бу якка аумады. Әтинең исә дәрте кыза гына барды. Әлеге авыл безнең районга кермәсә дә, әтинең «агентура»сы анда да бар. Бу колхозда атларның баш саны пландагыдан аз булуын, шуның өчен райком бюросында әлеге председательне утлы табага бастыруларын да белеп тора. Ә безнең Чегәнне нәсел айгырына алырга икенче бер колхоз председателе бик кызыгып йөри иде. Әти күп уйлап тормады, Чегәнне шул колхозга илтеп, ике баш алашага, булырбулмас кына бер корчаңгы тайга алыштырып кайтты. Ул елны җәйләр бик матур, бик җылы һәм яңгырлы килеп, безнең якларда уңышлар бик мулдан булды. Сугыштан соңгы елларда беренче мул уңышлы көз иде бу. Шуңа күрә аның шатлыгы да бик зур булды. Көзен район җитәкчеләрен дә, шул исәптән безнең әтине дә зур-зур бүләкләр белән бүләкләделәр. Әтигә бүләк итеп чыныктырылган кара корычтан ике көпшәле бельгийский ау мылтыгы бирделәр. Мылтык түгел, курчак, уенчык иде бу! Әти аны кысан гына өебезнең иң түренә элеп куйды. Үзенең мылтык тоту, сунарчылык итү түгел, чебен үтергәне дә юк. Әмма бүләк аңа да ошады. Ә мылтыкны бездән кемнәр генә килеп сорамадылар да кемнәр генә зур бәяләргә сатып алырга теләмәделәр!

— Бүләк бит бу, иптәшләр! Нигә дип сатыйм мин аны? Аны сатып кына ертык җиремне томалый алмам, — дип, әти мылтыкны күпләргә тотып кararга да бирми.

Алай да озак саклый алмады ул бу бүләкне. Моторны кулга төшерми тынгы күрмәсен белеп торабыз. Кемгәдер шул мылтыкны биреп, мари ягыннан тагы ике кырыкмыш җитәкләп кайтты. Ишегалдында, мин сиңа әйтим, биш баш ат малы. Көтү булып йөриләр, ашатып-эчертеп өлгерер хәл

юк. Ә җигеп чыгыйм дисәң, тәртә арасына бастырырлык алаша юк. Ахырда, шуларның бишесен бирәп, әлеге колхоздан Моторны алып кайтты. Карарга матур, юлга җигеп чыксаң, талчыгуны, аруны белмәс чын мотор иде ул. Юлда үзеннән алда арба, тарантас күрсә, син аны тыярмын димә инде. Тегеләрне куып җитмичә, узып китмичә, янасын, үләсен дә белми чабачак. Ул көннәрне дөньяда бездән шат, бездән дә бәхетле кешеләр булмагандыр инде. Ял көннәрендә Моторны ишегалдына чыгарып бастырабыз, үткән-барган бары да безнең коймага ябырыла.

И-и-и, чыннан да, нинди бәхетле көннәр булган икән алар! Тәҗләрне скрипка кылыдай киереп, озын тәртә арасына урыс дуга салып җигеп куям. Түшлекне бушатам, аркалыкны тарттырып бәйлим. Кәгазьдә, рәсемдә дә шулай килеп чыкмый. Атның баскан җирдә биисе, алга ыргыласы, чабасы килә башлый. Ашаганда колагы селкенү белән генә түгел, бездә егетләрне ат җигүенә карап та сыныйлар иде.

Мотор ипподромнарда тәрбияләп үстергән метис түгел, туган як болыннары тудырган, шунда үскән чын рысак иде. Тиздән без аны үзебезчә Матур дип йөри башладык. Берәр азгын айгырның Матурыбызга күзе төшүдән, аңар кайнар мәхәббәт тотуыннан куркып, без аны кичләрен болынга да төшермибез. Төнгә ишегалдына гына җибәреп калдырабыз. Югыйсә биябезнең бер колынлау белән тупасланып, ямьсезгә калынаеп китүе бар. Әтинең аны, һич югы, өч-дүрт ел чамасы шушы зифа, сөлек кебек сыгылма хәлендә җигеп каласы килә. Алай да бер-ике ел чамасы аны шушы хәлендә саклап, җәйге сабан туйларына җигәргә өлгердек әле без. Әмма ат ул сиңа песи баласы түгел. Аны абзарга ябып кына да асрый алмыйсың. Әллә инде капкабызны җил ачкан, әллә берәрсе юри ачып киткән, төннәрнең берендә Матурыбыз, ишегалдыннан чыгып китеп, болындагы атлар көтүенә барып кушылган. Аңа шунда ук райисполкомның Борча кушаматлы алмачуар айгыры гашыйк булган. Районга дан холыксыз айгырларның берсе иде ул. Моңа кадәр дә безнең тирәләргә килеп: «Ул матур биягезне бик күрәсем килә, яхшылык белән аны минем янга чыгарыгыз, юкса капкагызны тибеп аударам, койма өстеннән сикереп керәм», — дип, бик каты дулап йөргәләгән иде. Без ул айгырны өй эчебез белән чыгып күп куаладык. Әмма аларның бу танышлыклары вакытлы шаяру гына булмаган икән. Борча безнең Матурыбызга чын мәхәббәт тоткан икән. Шулай алтын көзләргә кергәч карыйбыз: биябез авырлы. Инде җилен башлаган. Башта әти бик хафага төшкән иде, аннары сөенде генә.

— Колыны бия булса, аны сораучылар күп булыр әле бездән, кошевой чана алырбыз, — диде ул. — Әгәр инде айгыр була калса, үзебезгә үстерербез.

Шул көннән, кадерле кунак көткәндәй, татлы хыялларга бирелеп, колын көтә башладык. Буаз бияне яратмый, кочып сөйми мөмкин түгел. Ул шулкадәр матур, шулкадәр сөйкемле, шулкадәр газиз була, чынлап әгәр, үзенә карата күңелдә әллә нинди җылы хисләр уята. Ялгыш таеп китеп колынымны салмагаем дип, бик сак кына атлавын, ипләп кенә борылуларын аңлап, чын күңелдән хуплап торасың. Абзарга керсәң дә, сиңа тирән мәгънәле күзләре белән төбәлә. «Авырымнан исән-сау котылсам, хуҗам, сиңа бер матур колын бүләк итәргә җыенам» дип теле белән генә әйтми. Шундый чакта ничек аны килеп ялыннан сыпырмыйсың, кесәңнән ипи катысы чыгарып каптырмыйсың?!

Әле беренче баласына гына узган яшь килендәй, безнең Матурыбыз да декрет айларын борчылыбрак, хәвефлерәк уздыра. Янына керсәң, чыгарасы килми. Чыга башласаң, мине ялгыз калдырма дигән төсле, ишеккә аркылы баса.

Шундый көннәрнең берендә Матурны туйга җигеп, килен төшерергә сорап әтинең бер белгәне керде. Ул кешедән көзен бакча сукаларга алашасын алып торган идек. Кызу канлы, мал кыйнап яманаты чыккан Горячий Самат кушаматлы, әгәр әзрәк төшереп тә алса, бармакка чорнарлык та акылы калмый торган бер дуамал гына агай иде ул.

— Буаз бит ул, инде күп тә йөрисе калмагандыр, — дип тә караган иде әти.

Тегеләр:

— Без аны җиңел чанага гына җигәбез, килен төшергәнче генә, — дигән булдылар.

Горячий Самат, әгәренки үзегезгә ат-мазар кирәк булса, пужалыста, дип, ишегалдыбызга үз алашасын төшереп тугарды. Кызыл юрган, атлас мендәрләр салган кошевой чанасына Матурны җигеп менеп китте.

Бер кичкә, берничә сәгатькә генә дип алган җирдән бияне бишенче көнне генә төшерделәр. Аны ишегалдына Саматның үзе кебек кылый күзле малае җитәкләп килеп керде. Мине күрүгә, Матур ничектер моңсу кешнәп алды. Карыйм, болай үзенә берни дә булмаган төсле. Камытлыгы да суелмаган, ыңгырчаклыгы да таза. Абзарга да кертеп яптым. Биям шунда ук печәнгә ябышты. Инде бераздан карасам, эченнән кан килә. Ah, мин әйтәм, бетергәннәр икән биябезне! Эчем жу итеп китте. Иелеп җиленен капшыйм. Түп-түгәрәк булып тулып килгән җилен бөтенләй шиңеп, шәлперәеп калган. Өйгә йөгердем.

— Әти, Матурның таен салдырганнар!

Шул сәгатендә үк Саматларга менеп киттек. Исерекбаш ян сәкедә ята, телен әйләндереп тә сөйләшә алмый. Ни булганын хатыны гына сөйләде. Туй вакытында биягә ял булмаган. Ике кешелек кенә чанага алтау да, сигезәү дә менеп төялгәннәр. Тауга каршы бер җирдә шушы исерекләрне тарта алмау

хурлыгыннан Матур чыгымлый башлаган. Атлардагы бу хис бик яхшы таныш миңа. Андый чакта тизрәк йөгеңнән төш тә атыңны иркәлә, матур сүзләр әйт, ялыннан сыпыр. Тынычландыр. Үзеңә дигән соңгы сынысыңны каптыр, һич булмаса, ялларыннан сыйпап иркәли-иркәли яңадан тугарып җик. Ун минуттан бияң трактор кузгата алмастай йөгеңне кубарып алып китәчәк. Ә бу исерекбашлар аны кыйнарга керешкәннәр. Моңа кадәрле Матурның кыен-кайәр түгел, тупас сүз дә ишеткәне булмады. Авырлы, колынга йөкле биябез, бу мыскыллауны күтәрә алмыйча, тагын да чыгымлап, карга яткан. Ә теге күзен кан баскан ерткыч чана башыннан чылбыр суырып чыгара, бияне шуның белән кыйнарга керешә. Эченә дә типкәндер инде. Безнең Матурыбыз колынын салган. Аны шулай озак төшерми торуның сере шунда икән. Биянең колын салуын яшереп калдырмак булганнар.

Исерек белән нәрсә аңлашасың да аңа нәрсә исбат итәсең?

Әти кулындагы камчысын бөтерә-бөтерә таптанды да:

— Әмма, Самат, исеңдә тот, гомер эчендә ялгызың урман юлында очрама! Шушы камчы белән тиреңне тунамасам!.. — дип, ишекләрен тибеп чыгып китте.

Шул хәлдән соң, ничек кенә сакласак та, нәсел өчен берәр колын алырга ничек кенә тырышып карасак та, Матур колынын сала торган булып китте. Әти хәвефләнгәнчә, юанайды, тупасланды. Сбруйларына, камыт шлеяләренә сыймас булды. Алары әле безнең өчен бишенче хәсрәт. Сбруйларны яңаны юнәттек. Иң яманы — аның тизлеге бетте. Хәзер инде ул элеккеге мотор түгел, ә көчкә-көчкә генә әйләнә торган тегермән чарыгы. Аның каравы йөк тарту дигәндә аңа тиңнәр юк. Биектау стансасына берәрсен илтә барсам, аннан буш кайтты юк. Сельпога товар төйим. Башка атларга җидесигез прәннек әрҗәсе салалар. Ә мин йөгемне мунча биеклеге итәм. Өскә үзем менеп кунаклыйм. Кайту юлына без ун-унике олау булып чыгабыз. Кара мыеклы, кысык күзле, битләре суыкка чыныккан кып-кызыл йөзле ямщик агайлар берсеннән-берсе хәйләкәр. Алдан беренче булып юл салып бару йөгеңне икеләтә авырайта. Әмма алар һәрчак алдан мине җибәрмәк булалар. Мин йөгемне юри мөмкин хәтле озаграк, әледән-әле ял итә-итә төйим. Төяп бетергәч тә теге сылтауны, бу хәйләне табып, һаман биям тирәсендә юанам. Тегеләрнең түземлекләре бетә. «Кара, егет, соңыннан үкенмә, кышкы юлда ялгызың каласың бит», — дип, кайтыр якка кузгалалар. Әмма күп булса биш чакрымнардан без аларның барысын куып җитәбез, табаннарына басып бара башлыйбыз.

Алар көенә бераз гына атлыйбыз да:

— Һәй, сезнең көйгә кайтсаң, иртәгә дә кайтып җитәсең юк, — дип, атымны алга чыгарам.

Алга чыккач та әле, теге агайлар, атыңны артык кума, безне ташлап китмә, дип аптыратып бетерәләр. Ташлап китмәскә тырышам инде. Һәр авылга керер алдыннан туктап көтеп алам. Чөнки арабыз ике-өч йөз метрдан ерагайса да, җирдән себергән кышкы җил без салган чана эзен күмеп өлгерә. Арттан килгән олауларга тагын көрт ерырга туры килә.

Безнең Биектау ягы ямщикларын мин әле дә сагынып искә алам. Их, нинди егетләр иде алар! Базык гәүдәле, келәт ишегедәй киң җилкәле, хәленә карап кыска тун, сырган бишмәтме кигән, нәрсә кисә, шуның билен ал, кызыл, зәңгәрсу билбаулар белән килештереп буган, кешенекенә тимәс, үзенекен үлсә дә бирмәс киң холыклы, җор телле агайлар иде алар. Матур гомерләре эш белән, гел авыр күтәреп үткәнлектән, алар арасында көч-куәтне бизмәнгә салып үлчәү юк. Ул елларны авылга прәннек кенә ташымадык без. Район үзәгенә тегермән ташыдай авыр электронасослар, моторлар, двигательләр ташыган чаклар хәтердә. Әмма шул авыр тимер-томыр арасында безнең Дөбъяз агайлары кузгата, күтәреп чанага сала алмаган мотордыр, насостыр, поршеньдыр кебек нәрсәләрне хәтерлим.

Тагын бер яклары белән нык истә калганнар алар: үзара бераз чәкәләшеп алырга яраталар иде. Әллә инде каннары кайнап тынгылык бирмәгән? Бер дә юктан гына кызышып китәләр дә бер-берсенең якасыннан эләктереп тә алалар. Әмма алар бәргәләшүнең тәмен, ләззәтен белеп, бер-берсен артык имгәтми, җан җирләргә сукмый, алай да гөрс-гөрс бәрешерләр иде. Сабан туйларында бил алышыр чаклар әле ерак, ә сау-сәламәт тәндә кан кайный, күрәсең. Шушы бәргәләшүдән соң кемнең дә булса үпкә тотканын, тукмаклашуны начар итеп искә алучыны күрмәссең. Әле генә тукмашкан агайлар икесе бер йөк өстенә менеп яталар да, толып якаларын күтәреп, берәрне көйрәтеп җибәрәләр.

— Кара, яшьти, һай, гәрәчи кеше үзең, бер дә юктан гына колак төбенә үрелдең бит.

— Үзең бит, үзең. Кызган чакта кешегә хут куясы җирдә аркылы төшеп торасың.

— Хут куярга икән! Тегеңә хут куй, монысына дәшмә. Дәшмәм! Бер каным кызса, мин бит үзем дә... Менә күрдеңме моны!

— Утырма, йә тагын әйләндереп җибәрермен!

— Син, яшьти, янама, әйләндереп күрсәт, — дип, бер-берсенең якасына тагын үрелешә башлыйлар...

Ә бераздан үзләре үк:

— Ир урталары бит инде үзебез. Ярамый, килешми безгә болай кул уйнатышу, — дип, бүтән беркайчан да сугышмаска, кул күтәрмәскә ант итешәләр. Юк кына сәбәптән янәдән кызышып китмәсәләр, юлда булган юлда кала. Авылга җырлашып кайтып керәбез.

Беренче карашка шулай тиз кызып китешле, дуамал холыклы булып күренсәләр дә, безнең як ямщик агайларның тагын бер ягы нык хәтердә калган: алар аяклы малны чын ирләрчә яраталар, аның кадерен беләләр иде. Минем бастырыктай юан тәртәләрне, биш тонна йөк салсаң да сыгылмаслык дугаларны капшап-капшап карыйлар.

— Синең бу бияң сыртына түшәк җәеп кунарга да була! — дип, Матурны мактыйлар, аны шап-шап итеп сөеп китәләр.

Авызын каерып тешләрен карыйлар да:

— Кара малкайны, яшь икән бит әле! Нәселгә алып үстерергә колыны юкмы? — диләр.

Юк шул. Булмас та инде. Алай да тегенең белән сөйләшә, моның белән киңәшә торгач, бер агай әтигә биябезне бер-ике елга кысыр калдырып карарга киңәш иткән. Шул агайның акыллы киңәшен тотып, Матурны ике-өч җәй бик сакладык. Көтүгә чыгару түгел, болынга төшереп тә арканламыйбыз. Шул чорларда бер язны район ветеринария участогына Биектаудан нәселле айгыр китерделәр. Көннәрдән бер көнне әти бияне шул айгыр белән куна калдырды. Шул көннән без аны авыр эшкә җикмәдек. Колынын ничек тә салдыртмаска, саклап калырга тырышып, парлаган мәтрүшкә, ромашка сулары гына эчереп тоттык. Икенче язга биябез нәкъ атасы төсле чем-кара яллы, борча-борча тимгелле колын бүләк итте. Ул көннәрдә сөенечебезнең чиге булмады. Аңа Дөлдел дип исем куштык. Хәзер бар курыкканыбыз — яман күз. Кат-кат өшкереп, әби бөти тегеп бирде. Ул бөтинең тылсымлы көч-куәтенә ышанычыбыз шулхәтле генә. Кеше күзенә шыксыз, ябага, корчаңгы булып күренсен дип, колынны һәрчак тизәккә, дегеткә, арба маена батырып йөртәбез.

Әмма бу иркә колын белән үзебез дә күрмәгәнне күрдек инде! Ишегалдында аның таптамаган бәбкәсе, тибеп очырмаган бәрәне калмады. Аның тояк эзләре энекәшнең маңгаенда, минем калак сөяге өстендә әле хәзер дә гомерлек тамга булып ярылып ята.

Ул арада мин үзем дә аттестатлы егет булып өлгердем. Илләт буеннан печәнлек алып, ике баш атка, сыер-бозауга кыш буена кайгы-хәсрәтсез күшәп чыгарлык печәнне чабып, киптереп кибәннәргә утырттым да институтка кереп карау нияте белән Казанга юл тоттым. Анда минем кебек хыялыйлар байтак булып чыкты. Ике атна дигәндә янәдән авылга кайтып җиттем. Әмма дүрт аяклы малны никадәр генә сөйсәм дә, урта белемле башым белән ат караучы, ягъни кунних булып калу авыл егетләре, бигрәк тә аның ерык авызлы кызлары алдында минем авторитетны нык кына какшата башлады. Чит кешедә булса, тагын бер хәер, үз атаңда ялланган хезмәтче бит! Көннәрдән бер көнне мин әтигә бик кискен төстә ультиматум белдердем. Әти мондый финалны көтеп йөргән, күрәсең.

— Улым, мин сине бүгенге көннән үземә завхоз итеп алам, берүк ташлама, ташлый гына күрмә, — диде. — Хакы шул ук булыр, чөнки миндә башка мөмкинлек юк, үзең беләсең. Ә бит исеме башка: завхоз! Тагын бер ел гына түз инде. Кышын басылыбрак утыр да киләсе елга тагын институтка барып карарсың. Анда инде армиягә алыныр срогың да җитә. Аннары инде тоткарламам.

Шул көннән үк миңа хезмәт кенәгәсе ачып, «Хезмәтен бик белеп һәм тырышып башкарган өчен гади ат караучыдан хуҗалык мөдире итеп күтәрергә» дигән приказ яздылар. Яшь кешенең күңелен күтәрү өчен күп кирәкмени! Хәзер инде мичкә белән су ташудан да, йөге-йөге белән тирес түгүдән дә оялмыйм. Бу эшләр, димәк, завхоз вазифалары!

...Ә-ә-әх! Баһбайларны сөймәгән кеше буламыни! Ә мин менә аерым бер моң, татлы сагыш белән сагынып искә төшерәм аларны. Шуңа күрәме, пытыр-пытыр килеп шәһәр урамнары буйлап чабышкан әлеге мотороллерларны аеруча женем сөйми. Шушы аңгыра металл кисәкләре бер селтәнү белән шәһәр тормышыннан минем ефәк яллы дусларымны кысыклап та чыгарды. Сүз дә юк, алар синең иң яхшы рысакларыңнан да җитезрәк чабалар. Алар өчен кышка печән әзерлисе дә юк, карау өчен куннихлар да кирәкми. Әмма алар җансыз, алар телсез. Алар белән эчеңне бушатып сөйләшә алмыйсың инде. Беләсезме, һәр адәм баласының күңеле саф сулы чишмә кебек. Үзеңнән кечене, нарасыйны, зәгыйфьне, мәхлукны кыерсытма, рәнҗетмә, кеше булсаң, олы була бел, киң күңелле бул, дип ага сыман ул чишмә. Адәм баласын чын мәгънәсендә олы итә, бөек итә торган хисләр болар. Әгәр көннеке көнгә сарыф ителеп бармаса, утырган-тутыккан кебек, бу хисләр дә бәгырьгә юшкын булып утыра башлый. Кеше дигәнең усаллана, аның күңеле итек табанындай тупаслана. Вөҗдансыз, шәфкатьсез бер җанга әверелә ул. Бу адәм инде тулы мәгънәсендә сәламәт адәм түгел. Бу чиргә дәва юк. Барыбызга да менә шуннан сак булырга кирәк.

Берләре яфрак колаклы, икенчеләре йонлач тояклы, өченчеләре каурый канатлы, ефәк яллы, уйчан карашлы кече кардәшләребез һәр сәгатьтә, һәр минутта безнең шәфкатебезгә, мәрхәмәтебезгә мохтаж булган кебек, без үзебез дә аларның һәр көн, һәр сәгать яныбызда иптәш, юлдаш, күрше, сердәш булып яшәүләренә мохтажбыз. Ялгызлык бит коточкыч нәрсә. Яфрак кыштырдавы, чишмә чылтыравы, бала елавы, бүре улавы ишетелмәгән, тик тынлык хөкем сөргән мәгарәләргә, тау куышларына үзләрен сынап карау өчен кергән кешеләр шушы тынлыкка берничә тәүлек кенә түзәләр...

Тагын шунысы да бар. Адәм баласы иксез-чиксез Галәм киңлекләрендә япа-ялгызы. Бу ялгызлык аны борчый, әлбәттә. Бик күптәннән борчый. Кеше дигәненең бу гаделсезлек белән һич кенә дә килешәсе килми. Аның фантазиясе кайчандыр Җиргә очып килгән марсианнар, ерак йолдызлардан

килгән могҗизалы затлар турында әкиятләр, ышанмас җиреңнән ышанып куярдай легендалар уйлап чыгара. Чыгарып кына да калмый, шуларның дөреслеген исбат итмәк була әле. Әмма әлегә уңышсызлыкка очрап тора. Галәмдә тынлык, бушлык. Анда без артык җаннарга чыгарып, һич кызганмый күпләп юк итә барган крокодиллар, еланнар, хәтта гөберле бакалар да юк...

Озын кыш артыннан гөрләвекләре, кыйгак-кыйгак казлары белән язлар килә. Агачлар яфракларга төренә, ботакларында кошлар серләшә. Саф сулы инешләребездә көмеш тәңкәле балыклар йөзә, маймычлар уйный. Болыннарда койрык чәнчеп яшь колыннар чабыша. Инеш-күлләребездә, берсеннән-берсе уздырып, сөйкемле бакаларыбыз бакылдаша. Менә бу тереклек ичмаса!

Кеше дигән ак сакаллы агаем! Шушының кадерен беләсеңме? Җирдәге тереклек ияләренең күбесен ашыгыбрак әрәмтамакка чыгармыйсыңмы? Соңыннан үкенмәссеңме? Галәмдә түгел, торган, яшәгән җиреңдә япа-ялгызың калмассыңмы? Аннары инде бу ялгызлыктан, чыннан да, акылдан шашарга гына кала...

Сүземне баһбайлардан башлаган идем бит әле.

Атларнымы?! Кем генә сөйми инде аларны! Ә мин аерым бер моң, тирән ярату белән яратам баһбайларны. Һәркайсына тагын бер кат шикәр, печенье өләшеп чыктым. Ялларыннан сөеп, иркәләп барам. Барысы да көрләр, симезләр. Синең белән шаярам, уйныйм дип кенә торалар. Тагын берәр ат-надан аларның барысын да, пароходларга төяп, ерак Франциягә озатачаклары исемә төшкәч, күңелсез булып китте. Йә, әйтегез, туган иленнән аерылу кемгә җиңел?!

Мин — Чыңгызхан ыруыннан

(Фәнни-публицистик трактат)

Ни үкенеч, миңа Чыңгызханга тигән бәхет тәтемәде.

Наполеон Бонапарт

Бу турыда җиң сызганып, акка кара белән язарга күптән кулым кыжрап йөри иде. Дөнья малы артыннан куып, һаман вакыт тапмый килдем. Әмма байтактан бирле күңелгә тупланып, кат-кат вак күзәнәкле иләктән өиләнгән фикернең ахырына бер симез генә нокта куярга бик вакыт. Күп еллар буе туплап килгән материалларны өстәлгә салып, Олуг вә Кодрәтле, Данлы вә Шөһрәтле, дөньяда бер зирәк акыл иясе Чыңгызхан бабабызның биографиясен, тормыш юлын, укучым белән бергә күздән кичерергә ниятләдем. Мәңге Зәңгәр Күк кодрәтләренә, ягъни Аллага тапшырып, диюем. Чөнки, берни булса, усал теллеләр, наданнар, бәлкем, көнчелекләрен тыя алмаудандыр: «Сез бит, у-у, Чыңгыз нәселеннән! Сездән тагын ни көтәргә була!» — дип куялар. Кимсетү, кыерсыту, мыскыллау нияте белән. Шалишь, брат! Булсак соң! Чыңгызхан бабабызны әйтәм, гомер буена алименттан качып йөреп, тәмам йончыган алкаш булып, әйләнә-тирәгә ямanaты чыккан бомж түгел ләбаса. Аның кебек бөек, чын мәгънәсендә ихтирамга лаек, яшәү рәвешенә сокланырлык Олуг вә Мөхтәрәм затны чал тарих битләреннән эзләп кара әле. Белмим, табарсыңмы? Чыңгызхан — акыллы реформатор, киң колачлы дәүләт эшлеклесе. Аның хәрби таланты алдында барча хәрбиләр тез чүгеп баш иярләр.

Олуг вә Кодрәтле Чыңгызханыбыз һәрчак тыныч лык сагында торган. Бу сүзләремне укып, бу мөхтәрәм шәхес турында моңарчы гел тискәре сүзләр генә ишетеп, миләре тәмам агуланып өлгергән укучыларым сагаеп кала күрмәсеннәр. Авызымнан чыккан һәр сүзгә җавап тотам. Чыңгызхан дөньяга аек карашлы, көр күңелле, шәфкатьле вә бик юмарт зат булган. Аның токымыннан, нәсел-нәсәбеннән булу хыялың җитмәстәй дәрәҗә саналган. Хәзер дә шулай. Чыңгызхан шагыйрь, җырчы, акын булган. Дәүләт эшлеклесе, аның башлыгы, талантлы полководец! Канатлы кошларга тиң тулпарларга атланып айлар буена чапсаң да, очына чыгышлы булмаган бөек Монгол дәүләтенә нигез салган, аны төзегән. Үзе исән чакта ук бу иксез-чиксез зур биләмәләре белән үзе үлгәч тә ничек оста идарә итү юлларын билгеләгән. Зур Законнар җыентыгы, ягъни фәнгә, укымышлыларга, галимнәргә яхшы таныш «Ясак»ны ул кичләрен черт-черт янган учак янында җырлар белән әйткән. Әйе, һәркемнең дә бер кире ягы була. Кирелек ул бездә юк, диегез. Ә Чыңгызда андый тискәрелек, үҗәтлек вагоны белән булган. Әгәр теләсәме? Хуп дисәме? Әгәр теләге булсамы, аны укырга-язарга бер атна эчендә өйрәткән булырларые. Әйе, укырга-язарга тәки өйрәнмәгән, тискәре! Гәрчә үзе укымышлылар, зыялылар алдында баш игән, тез чүккән. Галимнәрне, укымышлыларны үз тирәсендә батальоны, дивизиясе белән тоткан, алар белән киңәшкән, черт-черт янган учак яннарында бәхәсләргә кергән. Чын хакыйкатьне төшенергә тырышкан. Аның сараендагы галимнәр, станындагы укымышлылар Бөек Хан авызыннан чыккан һәр сүзне ак кәгазь битләренә, ә еш кына кызыл балчыктан койган махсус пластинкаларга теркәп барганнар. Бер сүзен калдырмыйча, бер фикерен үзгәртмичә!

Бер карасаң, Тарих агаебыз үзе дә бик шәфкатьле, мәрхәмәтле, игелекле зат бит ул. Гыйбрәт белән яшәсәләр, үзләренә күп өлеш җиңел булыр дипме, безгә, үзенең балаларына, бездән алда яшәгән буыннар тормышыннан бик кирәкле истәлекләрне саклап калган. Хәтта Чыңгыз үзе әйтеп торып «Ясак»ка яздырган балчык пластинкаларны да. Ни кызганыч, барысын да түгел. Аның өчен тарих агайга мыскал үпкә юк. Сакланганнары өчен рәхмәт!

Аллага шөкер, минем өч оныгым бар. Өч баш шыптый! Арыслан белән Искәндәр мәктәп яшендәгеләре. Биктаһир әлегә бишек таптый. Менә шушы компаниянең иң яратып уйнаган почмаклары минем эш бүлмәм. Прәме аптыраш, башка урын тапмыйлар. Аларның мондый «ихтирамыннан» мин бик еш кына зыян да күрәм. Бөтен кәгазьләремне буташтырып бетерәләр. Кайчакларны «бу бит полное нашествие войск Чиңгизхана» дип сукранам. Алар миннән Чыңгызхан турында риваятьләр сөйләтергә яраталар. Бик күпне сөйләгәнем бар. Әлеге трактатымны да үзем өчен түгел бит, алар өчен язам. Шуны язуымны хуплыйлар. Мышык-мышык борыннарын тартып минем янда чуалалар. Кулларына логарифмик линейка алып, үзебез тереклек иткән Җир шарының мәйданын исәпләп чыгардылар. Еш кына республика күләмендәге олимпиадаларда катнашкан, җиңеп кайткан бу ташбашлар өчен берни түгел ул. Момент исәпләп тә бирделәр. Якынча 521 млн. дүрткел километрлар чыкты. Иксез-чиксез галәм киңлекләрендәге Кояш системасына кергән иң матур, иң сөйкемле күк җисемнәренең берсе — Җир дигән планетаның төп-төгәл мәйданы менә шул чамалар, җәмәгать. Ә Чыңгыз бабабыз менә шушы дөньяның дүрттән бер өлешен үзенә буйсындыруга ирешкән. Унынчы сыйныфны укыган оныгым аны 130,5 млн. дүрткел чакрымнар чамасы дип исәпләп чыгарды. Бу кадәр

зурлыктагы илләрне, җирләрне Александр Македонский да (төрекчә исеме — Искәндәр Мәһдүди) һәм Бонапарт Наполеон да буйсындыра да, яулап та ала алмаган. «Ни кызганыч, миңа Чыңгызханга тигән бәхет тәтемәде», — дип бер дә юкка гына уфтанмый бит ул Бонапарт агай.

Шуны искәртеп куйыйм әле, яулау белән буйсындыру арасында зур аерма бар, егетләр. Александр Македонский да, Бонапарт Наполеон да илләрне талау, юк итү, халыкларын кол итү өчен басып алганнар. Ә Чыңгыз исә шул чактагы зирәк акылы белән халыкларны кабилә белән кабилә ызгышыннан, ыру белән ыру талашыннан, кан коеш сугышлардан коткару, төбәкләрдә, әйләнә-тирәләрдә тынычлык, иминлек урнаштыру өчен буйсындырган. Әйтә бу, диярсез инде хөрмәтле авторыгыз турында. Соң, егетләр, дөресе шул бит. Чыңгыз империясенә кергән, аның канаты астында булган халыклар бер-берләре белән үзара сугышмаганнар, җир бүлешмәгәннәр, еллык керемнәреннән, табышларыннан нибары ун өлеш кенә ясак, ягъни салым түләп, бер-берсе белән рәхәтләнеп сәүдә иткәннәр, тату яшәгәннәр. Бер-берләренә кунакка йөргәннәр. Чыңгыз канаты астында булганлыктан, нинди генә милләттән булсалар да, нинди генә телдә сөйләшсәләр дә, аларны берәү дә җәберләмәгән, кыерсытмаган, көтмәгәндә килеп чыгып нигезләрен туздырмаган, малларын талап, балаларын коллыкка кумаган. Күп төбәкләрнең халыклары, дәүләтләре Чыңгыз империясендә булуларын бәхеткә санаганнар. Тапкан малыңның уннан бер өлешен казнага биреп барудан гына берәүнең дә бүсере төшми. Аның каравы рәхәтләнеп сәүдә ит, мал тупла, аяклы мал үрчет. Чыңгыз галиҗәнапларын әйтәм әле, ул 1155–1227 елларда яшәгән.

* * *

Нигә соң әле мин һаман коры сүз сүлим, мишәр әйтмешли. Чыңгыз яшәгән чорның мохитен, көнкүреш шартларын күз алдына китерү өчен менә бу эпизодны кыстырып җибәрү дә кызык булыр. Бу теге, әлеге дә баягы паразит нәрсә, ачуым да бер килмәгәе, шайтан суын, аракы-хәмер дигән зәхмәтне әйтәм инде, Чыңгыз хәзрәтебез заманнарында ук булган, күрәсең, ул хәерсез. Хәер, егерменче гасырның ислам дөньясындагы иң күркәм шагыйрьләрнең берсе Әнгам Атнабаев та бер дә юктан гына язмаган бит инде түбәндәге юлларын:

И, аракым, җаным, синнән башка
Көнем кара, төнем күңелсез.
Шунысы җәлке: берчак мин үләрмен,
Син калырсың, шайтан! Син бит үлемсез!

Бу шайтанның үлемсез булуына шик юк. Чыңгызхан заманнарында да похмельдән, махмырдан интегүчеләр булганга охшый. Кая ул кара халык кына? Чыңгызның гаскәр башлыклары, ягъни нойоннары да яхшы гына чөмерә булганнар, ахры, хәмерне. Инде тәмам аптырагач, башка чарасы калмагач, дип укыгыз, һәрьяктан олылауга, зурлауга вә ихтирамга лаек бөек император әлеге «Ясаг»ында кызыл балчыктан койган пластинкаларга чокып яздырган: «Әгәр инде бу эчү зәхмәтеннән башкача котылу чарасы юк икән, кемнең кем булуына карамастан, аена өч тапкыр гына эчәргә рөхсәт итәм. Өчтән арттырса, кем булуына карамыйча, хөкем итәргә! Аена ике генә эчсә бик әйбәт! Әгәр бер генә эчсә — мактауга лаек! Әгәр бер дә эчми икән, империя өчен аннан кадерле зат юк! Әмма халыкларны эчүдән тыярдай нәрсәне каян табарга соң? Әгәр андый нәрсә табылса, аны һәрьяклап ихтирам итәргә!»

— У-у-у, бу аракы зәхмәте! Башына күсәк белән генә сугасы нәрсә, җен кебек озын гомерле икән, шайтан.

Бу олуг затны ихлас күңелдән ихтирам итсәм дә, аның ыруыннан булуым белән горурлансам да, аның тормыш юлын өйрәнә башлагач, «Ай бичара! Күргән икән газиз башкайлары!» дип тетрәнеп куйган чакларым күп була. Булмаска! Ул күргән михнәт-газапларны, кыерсыту-типкәләүләрне башка ата баласына күрергә язмасын. Бик яшьли ятим кала бит, балакаем. Атасыз, үксез балага кем кизәнми дә, кем җикеренми. Колак төбеңә ялтыратырга да, арт ягыңа тибәргә дә күп сорамыйлар. Канаты астына алырдай кешең, яклардай терәгең булмагач, түзми дә хәлең юк.

Чыңгызның әтисе Исүгәй бahадир (игътибар итегез, безнең төрек-мөселманда Рәхмәй, Әхмәй, Исмай, Шахмай һ.б.) Та-та-эр дигән бер кабиләгә каршы яу чыга. («Та-та-эр — кытайларча «татарлар» дигән сүз була» дип язалар галимнәр.) Исүгәй әлеге кабиләне тар-мар итеп, ыру башлыгы бик гайрәтле бahадир егет Те-му-чәнне әсир итә. Ә шушы көнне үк Исүгәй бahадирның хатыны булачак императорны таба. Көчле көндәшләрен тар-мар итү хөрмәтенә, әтисенең яудан кайтышына дөньяга килгән бәбигә, ягъни тупырдап торган малайга, Те-му-чән дип исем кушалар. Ә Чыңгыз, ягъни Тиңгиз, Диңгезгә тиң булырга аңа ай-һай бик ерак әле. Белмим, сукмагына аркылы төшкән, берсеннән-берсе биек киртәләрнең барысын да исән-имин уза алырмы егетебез?

Сүз уңаенда шуны да теркәргә кирәк. Дәүләтчелегебез таркалгач, культура, фән буларак тарихны өйрәнү дә тукталган. Инде хәзер тарихны төпләп өйрәнергә ниятләсәк, бигрәк тә Көнчыгыш тарихын белергә теләсәк, чит телләрне белмибез. Явыз Иван Казанны басып алганнан соң, миебезгә кырыктартмачылык фәлсәфәсе шултикле сеңгән, аннан хәтта бүген дә котыла алмыйбыз. Чит телләрне

урта мәктәпләрдә өйрәтергә тырышып карасалар да, үҗәтләнеп өйрәнмибез. Аларны, ягъни шприхеннарны чатнатып белмәгәнлектән, талантлы гына галимнәребезгә дә тик русча чыганаклар белән генә эш итәргә туры килә. Бөек рус телендә Көнчыгыш халыклары телендәге күп авазлар юк. Авазлары булмагач, аларны язарга хәрефләр дә юк. Шунлыктан, хакыйкатькә зур хилафлык итеп, төрекчә, татарча, гарәпчә, иранча, кытайча сүзләр бөтенләй башка транскрипциядә языла. Җирләрнең, биләмәләрнең, халыкларның исемнәре танымаслык үзгәрә. Мисал өчен ерак барасы юк. Чаллыдан Казанга барышлый, юл өстендә, Таулар Иле дигән авыл бар. Нинди матур исем! Ә юл өстендәге тукталышка русча «Тавларово» дип язылган. Тавлароводан табып кара инде син Таулар Илен. Үземнең булганым юк, анда Күн авылы да бар икән. Питрәч районына керә микән соң? Тукталышка исә «Село Конь. 3 км» дип язганнар. Ул сукмак белән китеп өч түгел, йөз чакрым төшсәң дә син аннан Конь авылын таба алмассың. Париж Париж бит инде ул. Берлин да Берлин. Нью-Йоркны да Новый Йорк дип язмыйбыз. Шунлыктан Чыңгызны да Чингиз дип, Тәмүҗинне дә Темүчин дип йөрибез.

Безнең татар яшьләрендә тагын бер начар гадәт бар. Университет бетерәләр дә, кайберләре хәтта аннан-моннан юллап Казанда калырга тырышалар. Бер елны мин «Литературная газета» юлламасы буенча Төмән якларында кырык көнлек командировкада булдым. Көнбатыш Себерне үзләштерүдә катнашучы фидакарь татар нефтьчеләре турында очерклар язарга җибәргәннәрие. Әйе, безнең Татарстан егетләре анда бик күп нефть ятмаларын ачтылар. Нижневартовск, Урай, Лангепас, Мегион калаларының халкы тач татар гына диярлек. Ялуторовск, Тобол калаларында да булдым. Андагы монастырьларның очырмаларына менеп йөрдем. И-и-и, егетләр! Көнчыгыш тарихы буенча әлегә берәүнең дә кулы тимәгән материаллар менә кайда! Нәрсә белән сәүдә итү, чикләрне билгеләү, кәрваннарны пиратлардан, юлбасарлардан ничек саклау, ике арада аңлашылмаучылык килеп чыкканда, үпкәләшмичә генә аларны ничек хәл итүгә кагылышлы килешүләр, илчеләр алышу, ярминкәләр уздыру буенча шартнамәләр менә кайда! Алар матур почерк, сыгылма тел белән язылганнар. Бәлкем, таләпләр дә шулай куелгандыр. Бар документлар исән. Һәр төргәккә тиешле номерларын сугып, пергамент кәгазьләргә төреп куйганнар. Тарих факультетын тәмамлаган унлап егет шул тарафларга барып чыксалар, дүрт-биш ел эчендә тарих фәннәре докторлары, академиклар булып кайтачаклар. Кайберләренә киңәш итеп әйтеп караганым да булды. Әмма барырга теләүчеләр юк. Хәер, академик В.В.Бартольд булып дөньяга бик сирәкләр генә туа шул. Бигрәк тә безнең татар арасында. Ярый әле Көнчыгыш тарихы буенча һәркайсы кирпеч калынлыгы унике томлык хезмәтләрен ул язып калдырган. Тирән акыл ияләренә, бөек галимнәргә хас объектив караш белән. Югыйсә тарихта тирән катлам биләгән Көнбатышның урта гасырлар тарихын аның хезмәтләреннән башка каян белер идек?

* * *

Әйе, төп сүзебез соңыннан бөек император булачак Тәмүҗин дигән егет турында. Аңа тугыз яшьләр тулгач, ул заманнарда монголларда яшәгән гореф-гадәт буенча, Исүгәй баһадир, улын да алып, аңа кәләш ярәшергә чыгып китәләр. Кан якынлыгының яхшы, нык, зирәк акыллы нәсел бирмәвен бабаларыбыз шул заманнарда ук сиземләгән булсалар кирәк. Кәләшләрне, киленлеккә бер дигән чибәркәйләрне ераграк ыру-нәселдән алырга тырышканнар. Ә бу юлы исә кем буласы бүгеннән үк күренеп торган үсмергә кәләшне бөтенләй ерак кабиләдән сайларга ниятлиләр. Юлда Дай кабиләсе юл-башчысы Сичәнне очраталар. Әйләнә-тирәдә дан тоткан Исүгәй баһадир һәм аның улы Тәмүҗиннең бу сәфәргә нинди изге теләк белән чыгуларын белгәч, Дай-Сичән мондый кадерле кунакларның аңа да сугылып, кайнар шулпадан авыз итеп, чәй-кумыслап чыгуларын үтенә. Аның да әлеге тарафларның чибәрдән чибәре, гүзәлләрнең гүзәле Борте атлы кызы бар икән. «Нечкә бил, сылуларның сылуы — бездән, туй бүләге сездән!» Дай-Сичән үзе дә бит дала киңлекләрендә үзен теләсә кемнән кыерсыттыручы, басымчак иттерүче кабилә башлыгы түгел.

Зурлап-олылап чакырып торган җиргә нигә кермәскә? Ризыктан өстә булуны берәү дә килештерми. Соңыннан артыңнан гайбәт итеп сөйләрләр. Далага бер яман атың гына чыксын, күзеңне ачырмаслар. Керсәләр, сылуның сылуы Бортега да тугыз яшь! Балалар да бер-берсен бер күрүдә килештерәләр. Далага чыгып ат өстендә уйнап керәләр. Булачак кодалар да бер утыруда кул сугышалар. Яшьләрнең тәмам балигъ булганнарын, ундүрт-унҗиде яшькә җиткәннәрен генә көтәсе кала.

Әлеге кунактан күтәренке күңел белән кайтышлый, Исүгәй баһадир тагын бер җиргә сугыла. Менә шунда аны агуламадылар микән? Бу сорауга тарих җавапсыз. Шуннан кайткач, күп тә узмый, Исүгәй баһадир үлеп куя. Тугыз гына тулып килгән Тәмүҗин үзеннән кече ике энесе белән әнисе Оелен-әкә кулында кала. Кабилә башлыклары, кара хыянәтчеләр түгел диген син аларны, Исүгәй баһадирның үлүен ишетү белән, боларны шыр далада ташлап, икенче җиргә күченеп китәләр. Боларны ияртмиләр. Тәмүҗиннең әнисе, Оелен-әкә, ягъни Болыт-ана вакытсыз мәрхүм иренең әләмен тотып, кабиләне куа чыга. Аларны куып җитеп, оялта, орыша. Моңарчы Исүгәй баһадир аркасында гына күбесенең җирдә кеше булып яшәүләрен исләренә төшерә. Бичара ана качкалакларның байтагын җәйләүгә кире бора. Әмма монголларда хатын-кыз кабилә башлыгы була алмый шул. Карендәшләренең кайтканнары да бераздан берәмләп-берәмләп кире качып бетәләр. Җир шарының биштән өч өлешен үзенә

буйсындырачак император гаиләсе әлегә ач шакаллар, комсыз караклар тулы шыр дала уртасында берьялгызы утырып кала. Хыянәтче караклар аларга тиешле малларны, елкыларны, сарыкларны да куып алып китәләр. Батыр йөрәкле булса да, Болыт-анага ничек көн итмәк, берсеннән-берсе яшь улларын ничек аякка бастырмак кирәк?.. Япа-ялгызы бит, бичара. Кем көче белән? Кемгә ышыкланып?

Чал тарих битен бизәгән бердәнбер мондый олуг зат турында язарга алынгач, үз башымда туган кайбер фикерләр белән дә уртаклашмакчы булам. Чыңгыз хан биографиясен ныклап өйрәнгән доктор Эренжен Хар-Даван, Л.Гумилев, В.Ермолаев, П.Савицкий, В.Иванов һәм башка галимнәрнең хезмәтләрен укымыйча бу турыда сүзнең булуы да мөмкин түгел. В.Бартольд, Б.Владимиров, М.Иванин, Н.Трубецкой, Г.Вернадский, Г.Грумм-Гржимайло, Х.Лэмб, Ф.Краузе, подполковник В.Котвич эзләнүләре Чыңгызханның тормыш юлы турында гаять бай мәгълүматлар бирәләр. Әмма шулай да минем язганнарымны зур лупалы тәнкыйть күзлеге аша карап укырга онытмагыз. Чөнки бу олуг затка мин ихлас күңелемнән мөкиббән, сокланып туя алмыйм. Башта император булачак егетнең төп-төгәл туган елын тәгаенлик. Әйткәнемчә, Тәмүджин 1155 елның февраль аенда Онон елгасы буендагы әтисе биләмәсе булган Делюгин-Болдак дигән аймакта туа. Чучка елы була ул. Исүгәй баһадир тирә-юньдә шөһрәт казанган, күренекле дала аристократы, Нирун ыруына буйсынган Киют-Борджигин кабиләсе башлыгы. Исүгәйнең әтисе Бартан баһадир. Анысы бу төбәкләрдә абруйлы Кабул ханның улы була. Чыңгызханның уникенче бабасы Гао-Маралга (Гүзәл маралга) өйләнгән Бүрте-Чоно (Соры бүре). Шул чорда ук унике буын бабасы билгеле булгач, Тәмүджиннең нинди нәселдән булуын чамалау әллә ни кыен түгел.

Доктор Эренжен Хар-Даван милләте белән калмык. «Чыңгызхан полководец һәм аның мирасы» дигән хезмәтен революциядән соң эмиграциягә китеп, Югославиядә язган. 1929 елда Белградта бастырган. Шулай да аның бу чиксез зур фәнни әһәмияткә ия хезмәтенә чак кына тәнкыйть белән карау зыян итмәс. Чыңгызга ул миннән дә болайрак мөкиббән, ирләрчә гашыйк. Калмыклар үзләрен монголлар нәселеннән таныйлар. Эренжен әфәнде дә Чыңгызны чеп-чи монгол дип раслый. Ә мин исә аның йөз чалымнарында, яшәү рәвешендә, холкында төркичә, мөселманнарга тартым сыйфатлар күрәм. Үзе ул бер динне дә тотмаган, безнең ише атеистрак шәхес булган. Әмма бер динне дә җәберләмәгән. Басып алган, үзенә буйсындырган җирләрендә будда динен тотучыларның пагаодаларын, христианнарның чиркәүләрен, яһүдләрнең синагогаларын, мөселманнарның мәчетләрен таламаган, аларга хәтта ясак та салмаган. Мин — атеист дип кенә, җирне бар иткән, вакытында таңын аттырган, вакытында кичен җиткергән, кояшын чыгарган, яңгырын яудырган ниндидер Олуг Кодрәтләргә, Югары Көчләргә ышанмый, табынмый мөмкин түгел. Эренжен Хар-Даван раслаганча, Чыңгызхан «Вечно Синее Небо»га табынган. Монголча әйтсәк, «Меңкә Кеке Тенгрин» була. Бу әле рус транскрипциясе белән шулай. Руста «ә», «ү», «ң» хәрефләре юк. Ә татарчасы бик тә гади чыга түгелме соң? «Мәңгелек Күктәге Тәңребез» була бит. Әйе, Тәңребез һәрчак күктә. Шушылардан чыгып шуны расламак булам, Чыңгызхан патшалыгы халкының төп аралашу теле төркичә, хәтта үзебезнең бүгенге татар теленә якын тел булгандыр. Дөрес, ул көннәрдән бирле кырыгы кырыкка төрләнеп беткәндер. Бер-берсе белән кушылып, күп ырулар, күп кабиләләр юкка чыкканнар. Әмма тел кала биргән. Телсез аралашып булмый бит. Һәрхәлдә, Чыңгыз һәм аның данлыклы полководецлары Сүбәдәй, Мүкәли, Тогучуар, Җәбә һәм башкалары бүгенге татар телебезгә якын, һәрхәлдә, тылмачсыз да аңлаешлы телдә сөйләшкәннәрдер төсле тоела.

«Баһадир» сүзе үзе үк төркиләр сүзе бугай. Тагын бер хикмәт бар. Әтисе үлеп киткәч, тугыз яшьлек Тәмүджин ике энесе белән һәм дә әнисе белән бернинди таянычсыз, яклаучысыз кала бит инде. Кабилә нигезеннән таркала, хыянәтче качаклар бу бичараларның аяклы малларын да үзләре белән алып китәләр. Тарихчылар үз хезмәтләрендә «Тәмүджин бу чорларда тормышның бар авырлыгын үз җилкәсенә салып, әнисен, энеләрен ни туры килсә — шуның белән, үләннәр җыеп, тирә-юньдәге күлләрдән балык тотып туендырып торган, үлемнән саклап калган» дип язалар.

Әйе, без еш кына сагынып искә алган СССР яшәгәндә, язучыларның Кырымда, Кавказда, Балтыйк буенда һәм тагын күп җирләрдә Иҗат йортлары бар иде бит. Ара-тирә мин дә шунда ялга бара идем. Исеме генә ял. Барып төшү белән, һәркем җиң сызганып эшкә тотына. Син дә беренче эшең итеп кулыңа каләм аласың. Язмый мөмкин түгел. Кемнең кем, ничә яшьтә, кайсы милләттән булуына карамыйча, барысы баш күтәрми язалар. Чөнки шартлар шундый, ошбу бетмәс-төкәнмәс мәшәкатьле дөньяны бер мәлгә онытып торып, иркенләп, җиң сызганып, бөтен талантыңны эшкә җигеп язуга көйләнгән. Илһам җилкәннәреңне бар хутка киереп, җәелеп язып китсәң, повестеңнымы, китабыңнымы төгәлли алмасаң, путевкаңны озайтырга да мөмкин. Әйбәт нәрсә иде инде. Әйбәт кенәмә! Хәзер күпләр авыз читләренә күбек чыкканчы чәйнәгән СССР чорында, язучыларның корылтайларында, әнә шундый Иҗат йортларында күрешеп, аралашып, җиде меңгә якын Язучылар берлеге әгъзалары кыргызлар, әрмәннәр, үзбәкләр, латышлар, эстоннарны күреп танып исәнләшә, бер-беребезне кунакка дәшешә идек. «Дружба народов» журналында үзең белгән берәр әрмән йә молдаван, украин дустыңның яңа әсәрен күрсәң, аның үзеннән болайрак сөенәсең. Уңышсызрак чыккан әсәргә юлыксаң, автор өчен борчылып куясың. Менә шулай яши идек инде, хөрмәтлеләрем.

Әмма төп әйтәсе фикеремнән читләшмәдем. Үткән заманга чын ностальгия, сагыну хисе белән берничә штрих кына бу. Иҗат йортларына барып чыккач, кан кардәшлеге, Тәңре кушуы беләнме, әллә чынлап та Чыңгызхан нәселеннән булгангамы, әллә ни арада гына монгол-бурятларны эзләп табам. Тиз арада дуслашабыз. Кичләрен үземә кунакка да дәшәм. Үзем яраткач, боларны да затлы нигъмәтләр белән сыйлыйм әле дип, шулчаклы тәмле, майлары тамып торган ысланган балык куям өстәлгә. Ни хикмәт, әй, минем кунакларым әлеге сый-нигъмәткә бармак очлары белән дә кагылмыйлар. Ике-өч тапкырлар шулай булды. Аннары гына белдем, аларга балыкка табу! икән. Ягъни балык ашау тыела. Ярамый! Хәрам! Табу!

Кунакларның шундый кадерлеләрен дәшкәч, бәяңне төшереп булмый, өстәлгә аракының да иң затлысын куясың. Ул чорларда шешәсе дүрт кырлы «Кристалл» дигән поляк аракысы иң затлылардан санала иде. Монголлар һәрчак өстәлгә артык бер рюмка куйдыралар. Аңа да сыекчаны мөлдерәмә салалар. Анысы Чыңгызхан өлеше була. Үз кулларындагы рюмкалар белән чәкештерәләр. Аннары бу рюмкадагысын кояш чыккан якка сибәләр. Берәр рюмка тотканнан соң телләр тагын да ачылып китә. Алда тагын ничә рюмка күтәрсәк тә, кунаклар Чыңгызхан өлешен дә онытмыйлар. Инде сигез гасырлар узып та, Чыңгызханны онытмауларына, аның белән горурлануларына исем китеп, кунакларымны тагын да ярата, ихлас күңелдән ихтирам итә төшәм.

* * *

Булачак императорның биографиясен кулыңа алып укый башласаңмы! Аның балалык елларда күргәннәрен күз алдыңа китереп, кычкырып елап җибәрердәй урыннары бар. Әле дә бәхетләре, малайларның әнкәләре Оелен-әкә (Болыт-ана) бик булган, кыю йөрәкле, батыр җанлы хатын була. Яшьли тол калса да, балаларын берәүдән дә җәберләтми. Усалларга, хыянәтчеләргә юлыкканда, йә шунда ук угын тартып чыгара, җәясен киерә, йә сөңгегә ябыша. Барлы-юклы малларын да далада көтми, кая көтәсең? Ә дала тулы карак-угры. Авыз ачып торсаң, көтүеңне күз алдыңда куып китәләр. Балигъ булуга, ерак өч малайга кышкы зәһәр салкыннарда, малларын саклап, хәтта казан да асмый кунарга туры килгән кичләр күп була. Учак яксаң:

— Әһә, монда көтүчеләр мал саклап төн куналар, — дип, шундук мародерлар, талаучылар өере килеп җитә.

«Монголның серле риваятьләре» китабында, Тәмүҗиннең әнисе Оелен-әкә, ягъни Болыт-ана, бик күп «серле, хикмәтле» сүзләр-такмаклар белгән, дип языла. Болыт-ана, ирем үлде, балаларым беләм ятим калдым, дип сыгылып төшми. Балаларымның киләчәгә, кем буласы миннән тора дип хәл итә. Аларга кышкы озын кичләрдә данлыклы монгол бahадирлары турында улларының күңелләрен җилкендергеч матур риваятьләр, дастаннар сөйли, чын егетлек, кыюлык, зирәклек турында матур җырлар көйли.

— Балакайларым! — дип эндәшә ул аларга еш кына. — Шуның белән горурланып яшәгез, сезнең унике бабагыз билгеле! Тирә-юньне тетрәтеп, буйсындырып торган зур, дәрәҗәле ыру-нәсел оныклары сез! Бүгенге кыенлыклардан сыгылып төшәргә, далада сарык көтүе көтеп яшәргә сезнең хакыгыз юк! Дала кубызына сез түгел, дала биергә тиеш! — дип тәрбияли ул балаларын.

— Беркайчан шуны онытмагыз! Исән чагында әтиегезгә кырык мең кибетка буйсына иде! Сезгә йөз мең буйсынырга тиеш! Тәңредән сорадым, ул шулай әйтергә кушты сезгә! — Ана улларына әнә шундый сүзләрне тукый. — Атагыз Исүгәй бahадир Тайчутлар ыруыннан иде. Тәңребез үзе Тайчутлар ыруының башлыгы янәдән сез булуын тели!

Исүгәй бahадир үлгәннән соң, Бәрҗигиннәр нәселеннән булган Торгултай тайчутларның юлбашчысы итеп үзен игълан итә.

Моңарчы Исүгәй бahадир биләгән Керуләнһәм Онон елгалары арасындагы иң бай көтүлекләрне дә үзенә тартып ала. Әтиседәй киң җилкәле пәһлеван булып үсеп килгән Тәмүҗинне дә күрәләтә торып кыерсыта, хәтта эзәрлекли башлый. Соры бүренең, ягъни Исүгәйнең олы улын, аякка-мазар басканчы ук, үз вакытында юк итмәкче була. Даламы?! Ачкүзләр, хыянәтчеләр, комсызлар оясы!

Торгултай һич көтмәгәндә генә Тәмүҗиннәр җәйләвенә һөҗүм итә. Ярый әле булачак император далага качып өлгерә. Шунда качмый кая барсын? Торгултай ялчылары алай да аны куып тоталар, әсир итәләр. Муенына, ике кулына богаулар салып, янган учак янында калдырып торалар. Малай гына бит. Кая китәр? Ятсын шушында. Аннары күз күрер. Иртәгесен коллыкка сатарбыз. Алучы булмаса, аягына таш бәйләп, күлгә тондырырбыз.

Шунысын ассызыклыйм әле, язмыш дигән нәрсәне юк диген син аны. Тәңре аны: «Улым, син монголларның императоры булырсың! Сине алда чиксез зур дан-шөһрәт көтә!» — дип яраткач, ничек үтертсен инде? Булмаганны!

Төнлектә Тәмүҗинне саклап утыручы сакчы изрәп йоклап китә. Шуны гына көткән егетебез моның башына богаулары белән суга. Сакчыны аңгырайта. Үзе Онон елгасы ярына йөгерә. Суга ташлана. Артыннан куа чыгучылар узып киткәнче, дер-дер калтырап муеннан суда, куе камышлар арасында тора.

Куа чыгучылар арасыннан Сарган-Шира исемле берәү камышлар арасында утырган Тәмүҗинне күреп ала. Әмма күрмәмешкә салыша. Соңыннан әйләнеп килеп, егетне коткара.

— Тайчутлар сине шулай үткен, кыю, курку белмәс егет булуың өчен дә сөймиләр шул. Үсеп җиткәч кем булыр дип, синнән куркалар, шикләнәләр. Әмма мин сине ул явызлар кулына бирмим, — ди аңа Сарган-Шира. Богауларын ватып, егетне ирегенә җибәрә.

— Бар, улым, бәхетле бул! Лачын булып далага оч!

Тормыш Чыңгызны бик яшьли кат-кат сыный, шул ук вакытта көннән-көн чыныктыра да бара. Берчакны караклар егетнең бар байлыгы булган сигез аргамакны урлап китәләр. Кирәк бит, чәнчелеп киткерләре! Тәмүҗин боларны артларыннан куа чыга. Белмим, юлдан язган караклар өеренә каршы берьялгызы гына нәрсә майтарыр иде? Мәңге Зәңгәр, Мәңгелек Күктәге Тәңре әмере булгандыр инде. Тәмүҗин бер егеткә юлыга. Каракларны икәүләп куа китәләр. Аргамакларны тәки кайтарып алалар. Тәмүҗин, кайтышлый әлеге егетнең әтисенә сугылып, аңа күп рәхмәтләрен әйтеп чыгарга тели.

Әлеге батыр егетнең әтисе Нагу-Баян:

— Сез икегез дә әле яшьләр. Дөньяны чын дуслар булып бер-берегезгә таянып көтегез! Ятлардан җәберләтеп тормагыз, — дип, икесенә дә үгет-нәсихәтләрен бирә. Гагу-Баянның кыю йөрәкле, тугры холыклы улы Богурча соңыннан Чыңгызханның иң ышанычлы дусты, иң талантлы полководецларының берсе була. Бирәм дисә бирә икән, юлыңа ук чыгарып куя икән. Тәңрене әйтәм...

Тәмүҗиннең кече-кечедән үзен яраттыра, ихтирам иттерә, үз тирәсенә сәләтле яшьләрне туплый торган сәләте була. Унсигез яшьләренә инде ул зур гәүдәле, киң җилкәле, күзләре утлы күмер кебек янып торган егет булып җитешә. Янында зәһәр укчы дусты Кәсар, юан беләкле пәһлеван Бәлгүтәй, ышанычлы һәм тәвәккәл Богурча бар. Боларга бәйләнеп кара хәзер. Ялгышлык белән генә юлларына аркылы төшмә! Дөрес, әлегә боларның оешкан отряды да, коллары да юк. Әмма алар хәзер дала аристократлары. Дала-җәйләүләрнең бик хәйләкәр, астыртын башлыклары бу егетләр белән сүзгә килмәүне яхшырак күрә башлыйлар. Монгол тарихын тәмам кызыл балчыгына төшеп өйрәнгән галим Гарольд Лэм: «Тәмүҗин һәм аның егетләре беренче чиратта киң күңелле, кыю йөрәкле егетләр булганнар. Чөнки Тәмүҗин үзе гаять киң күңелле, үзенә тугры хезмәт итүчеләргә мең-мең рәхмәтле зат булган. Бу кешелекле сыйфатлар егетләргә аларның булачак юлбашчыларыннан күчкәндер. «Бирдеңме сүз, ышандырдыңмы, җидегә ярылып үтә!» Әгәренки хаким әйткән сүзне үтәми икән, аннан да әшәке, аннан да чирканыч зат юк, дип әйтә торган булган» дип яза. Хәким! Чыңгыз өчен ул менә нинди шәхес булырга тиеш. Бу сүзләрне бүгенге заман хакимнәренә дә ишеттерәсе иде.

* * *

«Яшьли сөйгән ярлар барыбер ятка кала, яр сөйсәгез өзелеп сөймәгез» дип җырлый идеме әле безнең мәшһүр җырчыбыз Габдулла агай Рәхимкулов. Чыңгызның да тугыз яшендә ярәшкән кызы Борте бар. Аның да барып хәл-әхвәлен белеп кайтыр сәгатьләр җитте. Беркөнне Тәмүҗин кулдан килгәнчә киенеп-ясанып, баскан җирендә биеп торган аргамакка атланып, Борте чибәркәйне үзенә хатынлыкка сорарга китә. Иптәшкә бер энесен дә ияртә.

Дала баһадиры булып үсеп буй җиткән, төскә-биткә дә кырт иткән кияү егетен кәләше йортында якты йөз белән каршылыйлар. Бортеның әтисе Дай-Сичән никахлы кияве булган Тәмүҗингә, туй бүләге итеп, кара кош тиреләреннән генә теккән бик затлы тун бүләк итә. Күзеңнең явын алырдай тун!

Типкә күреп, ятим үскән егетнең зиһене үткер, акылы зирәк була бит аның. Тәмүҗин дә күп уйлангандыр. Әтисе ягыннан аларга кардәш, әмма баштарак аннан байтак җәбер күрсә дә, Тогрултайхан ыруы белән дуслашып җибәрергә ниятли Тәмүҗин. Ике энесен дә ияртеп, аның ыстанына килә. Башта ыру башлыгына әлеге кыйммәтле тунны бүләк итә. Мондый зирәк уй, дипломатларча адым аның башына ничек килгәндер. Тәңре үзе киңәш итсә инде...

Тогрул ханның да бер хәле юк, мондый зур бүләктән соң ничек йомшап төшмәсен. Тәмүҗин исә, аларның элекке туганлыкларын да искә алып, Олуг вә Кодрәтле хан аны углым дип игълан итсә, мин бик бәхетле булыр идем, дип куя. Тогрулханның да башына тай типмәгән, дала тулы дошманнарың булганда, җае килсә, шундук башыңны ашарга торган шакаллар арасында яшәгәндә, шундый баһадир егет синең улың, көрәштә уң кулың булып торганда, аны колачыңа алмау чын ахмаклык булыр иде. Җитмәсә, тун да бик ошый. Тиктомалдан гына сиңа шундый затлы тун бүләк итә алган бу юмарт егетнең арты да буш түгелдер. Ул зур байлыклар ияседер. Атасы Исүгәй дә кем иде соң! Дала күрке иде бит!

Тогрулхан бөтен далага, җәйләүләргә «Тәмүҗин — минем углым» дигән хәбәр сала. Ә син, углым, йомышың төшкәндә туры үземә кил, акыллы киңәшемнән, ярдәмемнән ташламам, дип ышандыра. Ә егеткә шушы гына кирәк. Булачак император, кулына камчы алып, теге чакта аны ачы язмыш кулына киткән хыянәтче канкардәшләрен, ыру-кабиләдәшләрен шираулатып камчы белән яра-яра, үз канаты астына җыярга керешә.

Дала гына димә, мишәр әйтмешли. Астына ут яккан казан төсле гөбер-гөбер кайнап яшәп ята ул. Һич көтелмәгән хәлләр дә монда көнаралаш булып тора. Матур гына гаилә корып, дус-иш туплап, үз

ыруын ныгытып ятканда, Тәмүджин ыстанына Себер меркуитларының өч ыруы берьюлы һөҗүм итәләр. Исүгәй баһадир нәсел-нәсәбенә алар инде бик күптәннән теш кайрап, тирән үч саклап йөргәннәр. Чөнки моннан нәкъ унсигез ел элек Тәмүджиннең әтисе Исүгәй баһадир булачак хатыны Оелен-әкә, ягъни Болыт-ананы меркуитлар юлбашчысы кулыннан үзе дә урлап качкан була.

Меркуитларның һөҗүме шулхәтле көтмәгән була, Тәмүджин үзе дә чак кына әсир төшми кала. Әмма хатыны Борте дошманнар кулына эләгә. Кирәк бит диген, Тәмүджин гомерлек йөрәк ярасы ала. «Тәмүджин минем законлы углым» дип, бөтен далага игълан иткән Тогрулхан ярдәмендә бераз вакыттан хатынын әсирлектән коткара ул. Соңыннан Чыңгызның хатыннары күп була. Әмма Бортены ул, ихлас күңел белән сөйгән, яраткан беренче ярын, беркайчан кыерсытмый, кимсетми. Ләкин аннан туган беренче баласы Җүчине барыбер үз итеп бетерми. Аның дөньяга килүенә меркуитларның да өлеше бар, дип, гомер буена шикләнә, кырынрак карый. Чыңгыз үзе үлгәннән соң, хәтта тәхеткә варислар сайлаганда да бу нәрсә ачык сизелә. Бер анадан булсалар да, энекәшләре Җүчине тәхеттән читкә этәрәләр. Аның каравы!.. Әйе! Ярар, бу турыда чак кына соңрак.

Инде башта ук әйткәнемчә, Тәмүджин аерым бер динне дә тотмаса да, ниндидер гадәттән тыш кодрәтле көчләрнең барлыгын таный, ышана. «Меңке-Күке-Теңри» — Мәңгелек Күктәге Тәңре хәзрәтләре кодрәтенә ышанган, инанган, табынган. Чөнки аңа карата шәфкатьле Тәңре аны ничә тапкырлар үлемнән алып калды. Аннары шул чорлардагы монгол эпосларында, дастаннарында, риваятьләрендә, Тәңре тиздән безгә менә шундый шәхес бирәчәк, ул үтә дә акыллы, гадел булып, бөтен монгол кабиләләрен үз канаты астына җыеп, көчле бер дәүләткә берләштерәчәк, дип, авыздан авызга сөйләгәннәр. Учак яннарында озын җырлар җырлаганнар. Монголлар көткәннәр мондый юлбашчыны. Тәмүджин дә аларны күп тыңлаган. Тәңре җиргә иңдерәчәк әлеге юлбашчы нигә әле нәкъ менә ул булмаска?! Үз-үзенә мондый сорауларны ул еш куйгандыр. Тәңре бит аңа барысын да биргән: буй-сын, чибәрлекне дә, баһадирларча көч-куәтне дә. Башында акыл-хәйлә дә уннарча кибиткага төярлек. Кайсына үзенә дә бик кадерле бүләкләрен биреп, кайсыларын өркетеп, өрекмәгәннәре өстенә яу белән барып, әйләнә-тирә ыру-кабиләләрне тиз арада үзенә буйсындырып бетерә. Әле малай чагында аны әсир төшереп, кулларына богаулар салып, аны чак кына коллыкка сатмаган тайчуитлардан үчне коточкыч рәхимсез алды. Алмыйча! Ояларын туздырды.

* * *

Ул чорга тайчуитлар далада иң көчле берләшмәләрнең берсе. Аларның һәркайсы бер мең атлыдан торган утыз дивизиясе була. Тәмүджин унөч дивизия генә туплый. Аерма 2,5 тапкыр чамасы. Булачак императорның гаскәр башлыгы таланты бу орышта аеруча чагыла. Рәхимсез кисеш, тураш иртә таңнан алып караңгы төшкәнче бара. Тәмүджин гаскәрләре тайчуитларны тар-мар итәләр. Бу орышта тайчуитларның зур түрәләре генә дә җитмеш сигез кеше әсир төшәләр. Тәмүджин аларның барысының да башларын чабарга боера. Башкаларга сабак булсын, аның исемен ишетүгә дошманнарының тез буыннары калтырый башласын өчен. Шунсыз, егетләр, далада үзеңне таныта, ихтирам иттерә алмыйсың.

Ә болай караганда кешенең хәленә керешле йомшак холыклы зат була ул. Тайчуитларны тәмам тар-мар иткәннән соң берара узгач, аның каршына бер егетне китерәләр. Нинди җәза бирергә дип.

— Узган орышта үзеңә төбәп аткан угым атыңа тиде. Әгәр мине үтерергә булсаң, каным белән уч төбе хәтле җирне пычратырсың инде. Әгәр исән калдырсаң, үзеңә тугры хезмәт итәрмен. Аккан суларны буармын, ташларны сугып ярырмын, — ди бу Җиргүәдәй исемле егет.

— Дошман гадәттә үз гаебен яшерә. Үч саклый. Ә син яшермәдең. Барысын ничек булса, шулай әйтеп бирдең. Минем юлдашым бул! — ди Тәмүджин, аңа кулын суза. Бу егеткә «Җәбә», ягъни «Ук» дигән кушамат алырга куша.

Җәбә хәрби түрә карьерасын Тәмүджин гаскәрендә десятник булудан башлый. Соңыннан аның иң сизгер, иң алдан күрүчән полководецы дәрәҗәсенә ирешә. 1223 елда Калка елгасында рус кенәзләре гаскәрен полководец Сүбәдәй белән бергә ул тар-мар итә.

Әйе, Сүбәдәй баһадир Тәмүджиннең иң талантлы полководецларыннан берсе. Җәбә яшьлеге белән бик кызу канлы, күбрәк кылыч уйнатырга яратса, Сүбәдәй баһадир ни-нәрсәне хәл иткәнче, өч бөртек сакалын бөтереп, байтак кына уйланып утырырга яраткан. Бу ике полководецлар бер-берсен тулыландырганнар. Шунлыктан күп орышларны җиңел генә ота килгәннәр.

Алай да сүз уңаенда гына шуны да әйтеп узыйм: сугыш-орыш кырларында Сүбәдәй дә гел иң пешкән, иң кызыл алмаларны гына өзмәгән. Болгар патшалыгына беренче походында безнең болгар бабаларыбыз аны акылга утыртканнар. Өсләренә рәхимсез яу белән килгән Сүбәдәйгә каршы зур гаскәр туплап чыкканнар. Бөек Биләр тирәсендәрәк иркенләп турашырга ипле урын сайлап, позициягә басканнар. Берәр сәгать канлы тураштан соң болгарлар позицияләрен, бай обозларын ташлап кача башлаганнар. Монголлар «ура!» кычкырып болар артыннан ташланганнар. Болгарлар боларны алдан ук чамалап куелган тау-ташлы, тирән чокырлар арасына алдалап кертеп, үзләрен урап алып, турый башлаганнар. Шушы орышта Сүбәдәй утыз меңлек гаскәрен бич туратып, болгарлардан чак кына

качып котылган. Монысы да тарихта теркәлгән факт. Алай гынамы?! Болгарлардан алган ачы сабакны соңыннан Сүбәдәй үзе дә күп орышларында куллана.

Чыңгызхан армиясе турында сөйләгәндә, кыргый атларга атланган ярым кыргый кысык күзле монголлар ордасы турында уйлый күрмәгез тагын. Тәмүджиннең ставкасында көн-төн баш күтәрми хәрби академия эшләп торган. Аларда бер дигән хәрби начальниклар, зур яуларда катнашкан гаскәр башлыклары укыткан. Һәр ике яктан алтмышар мең кеше катнашкан хәрби уеннар, учениеләр үткәрелгән. Бер төн эчендә елгалар аша күперләр салганнар, киң елгаларны кичкәннәр, кальга-крепостьларны алырга өйрәнгәннәр. Бу начальниклар климат, география фәннәрен яхшы белгәннәр. Көзен яу белән чыкканда Иделдә су кайчан катасын, кайчан боз белән капланасын алар сәгатенә кадәр белгәннәр. Идел катканчы аны тизрәк кичеп өлгермәсәң, кимендә ике атна көтәргә туры киләчәк. Атларыңа нәрсә ашатасың? Эшсезлектән армиядә дисциплина какшый. Әгәр инде Европадан яудан кайтканда Иделдә боз кузгалганчы чыгып өлгермәсәң, беттем диген. Суның ярларына төшкәнче кимендә ике-өч атна көтәргә туры киләчәк. Бу язгы чорда атларыңа, солдатларыңа нәрсә ашатасың? Иделдә һәм башка зур елгаларда кайчан боз кузгаласын алар шулай ук сәгатенә кадәр белеп торганнар.

Дөрес, монголлар яуга чыкканда тыл белән бик тыгыз бәйләнештә торганнар. Артларыннан көтүләре белән терлекләр, үгезләр, сарык-куйлар куганнар. Печән, фураж, җылы кием, уклар-кылычлар килеп торган.

Чыңгызхан армиясе үз заманы өчен иң алдынгы кораллар белән коралланган була. Хәрби тарихчы М.И.Иванин күрсәткәнчә, Сүбәдәй һәм Җәбә Нишапур каласын штурмлаганда өч мең зур уклардан ату җайланмасы, крепость стенасын җимертү өчен өч йөз катапульт, эченә нефть тутырып, ут төртеп шәһәр эченә ату өчен өч мең махсус чүлмәк, аларны ату өчен җиде йөз машина, штурм-һөҗүм вакытында куллану өчен дүрт мең баскыч, крепость алдындагы сулы чокырга тутыру өчен ике мең биш йөз капчык таш хәстәрлиләр. Мондый хәзерлек, мондый көч белән ябырылганда, белмим, нинди генә крепость-кальга, шәһәр бу һөҗүмгә түзәр, ак әләм күтәрми калыр икән? Шуңа күрәдер әлеге тарихчы генерал-лейтенант М.И.Иванинның 1875 елда чыккан «Монгол-татарларның һәм Урта Азия халыкларының басып алу походлары. Чыңгызхан һәм Тамерланның хәрби осталыклары, сугыш алып бару сәнгате» дигән китабы Россиянең иң дәрәҗәле хәрби уку йортларында — Император хәрби академиясендә махсус предмет итеп укытыла.

* * *

Сугыш-орыш, кан коешларның берсен дә тәбрикләмим. Бу кадәресен качакларның кайберәүләрнең: «Ы-ы, син Чыңгыз токымы!» дип җәберсетергә маташуларына җавап итеп кенә язам. Ә минем мышык-мышык борын ике оныгым, Чыңгызхан белән Батыйхан походларын картадан йөз кат өйрәнеп чыктылар инде. Әйтерсең башка эшләре юк. Әллә инде үзләре дә шундый полководецлар булырга җыеналармы? Һәрхәлдә, география фәне, географик карталар, бөек ачышлар белән күңелгә шик төшерерлек кызыксыналар алар. Малайларның күңеленә мондый коткыны үзем салдым бугай. Чөнки кичкә кердеңме, дәү әти, әкият сөйлә, диләр. Әкиятләр бик кискен сюжетлы булсын. Үзем дә бик теләп алынам. Рус балалар бакчасына йөргән, рус мәктәбендә укыган бу ташбашларга ана телебезне өйрәтер башка чара юк бит.

Әкиятләрне алай күп белмим. Мин белгәннәрне алар күптән яттан беләләр. Мин аларга үзем йөргән туристик походлар, андагы хәлләр, үзем менгән тау түбәләре турында сөйлим. Күбесен арттырам, әлбәттә. Ситуацияләр котыңны алырлык булмаса, тыңламый башлыйлар. Әмма шунысы хак: студент елларымда туризм-альпинизм спортын яратып, Алтайда, Уралда, Кырымда, Кавказда булдым. Аппатит түбәләрен таптадык, Карелия урманнарын гиздек. Сөйләрлек истәлекләр муеннан. Шул ук вакытта Чыңгызханның да нинди бөек шәхес, бик гадел, дөньяга киң карашлы кеше булуы турында күп тапкырлар сөйләгәнем булды. Чөнки Италиянең атаклы сәяхәтчесе, Чыңгыз ставкасында күп тапкырлар булган егет Марко Поло: «Чыңгызхан басып алган өлкәләрендә җирле халыкны җәберләмәгән, аларның милеккә хуҗа булу тәртипләрен бозмаган. Алар өстеннән үз наместникларын, үз чиновникларын куйган да яңа өлкәләр яуларга ашыккан. Ул буйсындырып киткән өлкәләрнең, илләрнең халыклары, аларга хәзер берәү дә һөҗүм итмәгәч, Чыңгызхан аларны сугыш, кан коеш афәтләреннән саклагач, аны җаннары, тәннәре белән ихтирам итә башлаганнар. Әле кичәге дошманнарыннан аның тугры хезмәтчеләренә, ялчыларына әйләнгәннәр. Чыңгызхан игосы, ягъни аның кул астында булу аларны күп афәтләрдән, көтмәгәндә дошман яулары килүдән саклаган», — дип яза.

Шул рәвешчә, бер дигән армия һәм талантлы гаскәр башлыклары белән күп халыкларны буйсындыргач, Чыңгызхан бөтен җир йөзен, бөтен дөньяны яулау турында уйлый башлый. Ә нигә уйламаска? Кулыңнан килә икән, нигә тырышып карамаска. Утыз яшьләренә ул Балхаш, Байкал күлләре, Иртыш буйлары, Уйгурстан, ярты Кытай биләмәләрендәге барча халыкны үзенә буйсындырып бетерә. (Байкалның төркичә исеме — Бай Күл.)

Укый да, яза да белмәүне инде әйткән дә юк, Чыңгызхан монголчадан башка бер тел дә белмәгән. Ә йомры башында гаять зирәк акыл. Аның запасы баш җитмәстәй хәйләләр корырга да, бик оста

дипломатик сөйләшүләр алып барырга да, акыллы, бик укымышлы затларны үз тирәсенә тупларга да җиткән. 1196 елда Ван ханны тар-мар иткәч, аның каршына бер әсир баһадир килә.

— Синең терсәктән канлы кулларыңа хуҗамны бирмәс өчен һәм үтертмәс өчен мин синең гаскәрең белән өч көн ял күрмичә кан коеп сугыштым. Аның ераккарак качып өлгерүен теләдем. Хәзер язмышым синең кулда. Телисең икән башымны чап. Калдырсаң, тугры хезмәт итәрмен, — ди әлеге баһадир.

— Үзенең хуҗасын саклап калу өчен минем белән өч көн сугышкан баһадирнымы?! Бу бит чын егет! Мин андыйларны ныкихтирам итәм. Бүгенге көннән син минем ышанычлы иптәшем, мә, тот! — дип кулын суза Чыңгызхан.

* * *

Моннан сигез йөз еллар, ягъни сигез гасырлар элек яшәгән бу олуг зат Чыңгыз әфәнде турында бар сокланулырымны, аның гениаль таланты турындагы уй-фикерләремне бер мәрҗәнгә тезеп, бер чеметем генә тәмәке салган кәгазьне төкерекләп төргәндәй, шалт кына көйрәтеп җибәреп булмый. Чәчелеп-чәчелеп язарга туры килә. Язмабызның героена, ниһаять, илле ике тула. Ир-егетнең самый өлгергән чагы. Алтайдан Аргунга һәм Себер тайгаларыннан алып Бөек Кытай стенасына кадәр булган гаять зур җирләрне биләгән мәйданда яшәүче барча халыклар аның кул астында. Юкса фикердәшләре, нойон-кенәзләре аны күптән Ха хан, ягъни «император» дип йөртәләр. Әмма тик законга буйсынырга яраткан һәм башкалардан да шуны таләп иткән Тәмүджин мондый исем кушуның рәсми төстә, законча эшләнгән булуын тели. Үзе туып үскән Онон елгасының өске буенда, Барс елы булган 1206 елда ул бик киң вәкаләтле Корылтай җыярга була Бу зур тантанага барча туган-тумачасын, фикердәшләрен, нойоннарын, кыскасы, Монгол биләмәләренең барча аристократиясен, аксөякләрен чакыра. Корылтай узачак җирнең калкурак төшенә Тәмүджиннең тугыз койрыклы байрагын кадыйлар. Бу символ үзе генә дә бирегә чакырылган кунакларның хуҗага карата ихтирамнарын бермә-бер кабартырга тиеш.

Шушы вакыйгаларны үз күзе белән күреп торган, Рим Папасының Тәмүджин ставкасындагы илчесе, дөресрәге, шымчысы Плано Карпини болай яза: «Чиксез зур мәйданга куе кызыл төстәге 2030 кеше сыешлы зур шалаш бастырганнар. Анда сыймаган кунаклар, атларына атланган хәлдә, шалаш тирәли басканнар. Барысының да атлары, сбруйлары егермешәр марка торышлы көмеш тәңкәләр белән бизәлгән. Почетлы кунаклар арасында Багдад хәлифе илчеләре, Грузия, Русь, Кыпчак, Мадьяр кенәзләре бар. Инагурация дигән церемониал, дускайларым, әнә шул заманнардан ук килә икән ул. Рим Папасы монголлар юлбашчысы Тәмүджин ставкасында үзенең шымчысын тотмаска соң? Җылы, бик бай, тәмле җимешләр үскән Италия ярларына да барып чыгарга Чыңгызханның күптән кулы кыжрый. Андый хәлләрдән Алла сакласын! Тәмүджин барып чыгам Италия ярларына дип хәл итсә, килеп тә чыгар. Аның сараенда илчеме, шымчымы тоту Рим Папасына бик файдалы. Болай ул сәүдәгәрләр аркылы да Тәмүджин ставкасындагы хәлләрне, хәтта аның күңел түрендәге уйларны ерактан белеп тора».

Корылтайны «үзенең искитмәле хикмәтләре белән күпләрне таң калдырган һәм зур дәрәҗәгә ия булган» Монголия төбәкләрендә бик атаклы шаман, идеолог, Мәңгелек Күктәге Тәңренең җирдәге гамәлләрен башкаручы Мунлик углы Күкчә ачып җибәрә:

— Аллаһ Тәгалә, ягъни Зәңгәр Күктәге Бөек Тәңре, синең, Тәмүджин, падишаһларның падишаһы, бар җирләрнең олуг патшасы булуыңны тели. Шушы бөек исемне кабул итеп ал. Шушы көннән син Суту-Богдо Чыңгызхан! Тәңребез кул астындагы барча җирләрдә әлегә син берүзең! Тәңре миңа һәм барча кунакларга менә шуны җиткерергә боерды. Тәңре әмеренә каршы килүчеләрне булган җирләрендә яшен сагалап торыр. Анысын да истән чыгармагыз. Монголларның җир йөзендә бердәнбер курыккан нәрсәләре яшен сугу булган. Хәтта бүген дә шулай.

Әйе, монголларның иң курыккан нәрсәләре яшен сугу. Чыңгыз үзенең «Билик», «Ясак» дигән законнар җыентыкларында да ватандашларын кат-кат нәкъ менә шушы турыда кисәтә. Ә шаман бу кадәр кисәтеп әйткәч, Тәмүджиннең Чыңгызхан булып сайлануына кем генә каршы килер икән?

Булачак тантананың, ягъни инагурациянең сценариен, барлык нюансларын Тәмүджиннең якыннары, алдан ук язып, өйрәнеп, кат-кат раслаганнардыр. Кем әйтмешли, шулай булмыйча, җүләр! Мунлик углы шаман Күкчәнең шушы сүзләреннән соң инагурациягә чакырылган бай сәүдәгәрләр, илче-шымчылар, кенәзләр, бароннар, синьорлар, идальголар — барысы берьюлы алтын тәхет тотып, Тәмүджин каршына баралар. Аны алтын тәхеткә утыртып баш өсте күтәрәләр. «Бөек Хан, синең шушы империя башында булуыңны телибез, үтенәбез, таләп итәбез!» — диләр.

Тәмүджиндә хәйлә бер капчык. Ул үз кадерен бик белеп, император булырга бик атылып та тормагандай:

— Инде бик теләсәгез, императорыгыз булырмын. Ләкин сезнең һәркайсыгыз мин кушканны үтәрме? Әнә шунда барыгыз, әнә шул дошманны үтерегез, дип кушсам, минем шул әмеремне бер карусыз үти алырсызмы? Минем ышанычлы һәм һичкайчан тутыкмас кылычым була алырсызмы?

Корылтайга дәшелгән, чакырылган кунаклар беравыздан:

— Булырбыз! Һич карусыз үтәрбез! — дип ант итәләр.

Чыңгыз утырган тәхетне кунаклар ак киез өстенә куялар.

— Хөрмәтлебез, башта башыңны күтәреп Күккә кара! Анда Тәңре! Аннары үзең утырган ак киезгә. Әгәр патшалыгың белән акыллы, зирәк идарә итсәң, шәфкатьле булсаң, тормыш ваклыкларыннан өстен булып, гадел булсаң, бароннарны, синьорларны дәрәҗәләренә карап ихтирам итсәң, бар җир йөзе синең кул астында булачак. Ә Тәңре сиңа ни телисең, шуны бирәчәк. Әгәр шуның киресе булса, көннәрнең берендә шулкадәр фәкыйрьлектә калырсың, астыңа салып утырырга кара киез кисәгең дә булмас, — дигән кисәтү сүзләрен дә тезәләр.

Шушы сүзләрдән соң Чыңгыз янына олы хатыны Бортены да бастырып, ап-ак йоннан язган затлы киезне баш өсте күтәрәләр. Чыңгызның үзен Монголның императоры, ә хатыны Бортены императрица итеп игълан итәләр. Дала күп чакрымнарга дер селкенә бу сәгатьләрдә. Мәңге Зәңгәр Күктән Тәңре елмая...

Уйлап-уйлап куям да, егетләр, Америка һәм Рәсәй президентларының тәхеткә утырулары, ягъни инагурацияләре Чыңгызныкы белән чагыштырганда пүчтәк кенә икән ул. Гәрчә үз империяләрендә алар да законлы императорлар лабаса.

Чыңгыз дигәннән, монгол телен яхшы белгән тарихчыларның әйтүенчә, монгол телендә «чыңгыз» дигән сүз юк. Галимнәр бу сүзне төрекчә «тингиз» сүзеннән алынгандыр диләр. Транскрипция законнарын алып ташласаң, безнеңчә «диңгез» була бит инде. Якыннары, нойоннары Тәмүҗингә бу исемне биреп, синең патшалыгың иксез-чиксез, диңгезгә тиң дигән мәгънәгә ишарә иткәннәрдер.

Ошбу язманың башында ук «Мин — Чыңгызхан ыруыннан» дип бер дә юкка гына әйтмәдем. Бөек Чыңгыз хәзрәтләре белән хәтта бүген йөзгә-йөз очрашсак та, арабызга арадашчы, ягъни тылмач кирәк булмас иде кебек. Аларның теле хәтта бүгенге татар теленә якын булган. Акчаны да тәңкәләр белән хисаплаганнар. Тәмүҗин ставкасыннан башлары кайтмаган рус кенәзләре дә Рәсәй җирлегенә аны «тенька», аннары «деньга» дип алып кайтканнар.

* * *

Ай-һай, үткен фикерле, алдан күрүчән башлы политик булган Тәмүҗин! Үзен шушы дәрәҗәгә күтәрү өчен шаман Күкчәне дә нык җиккән. «Искитмәле хикмәтләр, тамашалар тудыра белгән» тылсымчы сүзенә кара халык, әлбәттә, мыскал да шикләнми, икеләнми ышанган. Төрле юк-барларга ышанудан Тәмүҗин үзе бик ерак торган. Әмма аңа Күкчә, аның тылсымнары кирәк булган. Араларны тагын да якынайту, туганлашу өчен шаман Күкчәнең әтисе Мунликне тайчутлар агулап үтергәннән соң тол калган әнисе Оелен-әкәгә өйләндерә. Чыңгызхан үзенең шаманы белән кан кардәш дәрәҗәдә туганлаша. Ләкин вакытлыча гына. Тегесе артык узынып китеп дәүләт эшләренә дә тыгыла башлагач, аны юлдан алып ташлау ягын карый. Чөнки Күкчә кем икәнен оныта, артык масаеп китеп, чебен булып күзгә керә, авыр тузан булып тын юлына утыра башлый. Император янында итәгеңне җыеп, телеңне тыеп яшәргә кирәк икәнен оныта.

Кайсы яклап кына килеп уйлап карасаң да, һич аңлап булмый. Чыңгызханда ул нинди үҗәтлек, кирелек булгандыр инде. Укырга, язарга-сызарга тәки өйрәнми бит. Хәер, ул чакта монголларның алфавиты да булмаган әле. Хәреф танымагач, язу-сызуны белмәгәч, иге-чиге булмаган империя белән ничек идарә итмәк кирәк? Бу өлкәдә монголларның беренче мөгаллимнәре, император тирәсендәге аксөякләрнең балаларын борыннары белән алфавитка төртүче, аларга әсирлеккә юлыккан уйгур кешесе Тотатунга санала. Ул чорларда уйгур культурасы нык алга киткән була. Язу-сызуны да беләләр. Уйгурлар, бер яктан, күчмә тормышны да бөтенләй ташлап бетерməүләре белән монголларга да якын торалар. Яшәү, көнкүреш рәвешләрендә дә уртаклык күп. Шунлыктан монголның аксөяк аристократиясе уйгур культурасына тартыла, алардан укырга, язарга-сызарга өйрәнүне дә үзенә хурлык, түбәнчелек санамый. Алар арасыннан беренче булып уйгур язуын үзләштерүче аристократ аксөяк, Чыңгызның алып үстергән улы Шәһи-Котык була. Берчакны шулай аудан кайтышлый бер татар малаен очрата ул. Малайның бармакларында алтын балдаклар. Кеш тиресеннән тегелгән күкрәкчәсе дә алтын тәңкәләр белән бизәлгән. Малайның затлы сөяктән булуы әллә каян күренеп тора. Җитмәсә, үзе бик тере, тәмам эт борчасы. Чыңгыз малайны җәйләүгә алып кайта, аны тәрбиягә хатыны Борте кулына тапшыра.

— Ашат, эчерт, өстен кара, үз улың кебек үстер! — ди.

Шәһи-Котык атлы бу ягымлы малайны Тәмүҗиннең хатыны да ярата һәм аны үзенең алтынчы улы дип игълан итә.

Чөнки Борте ханымның үз балалары Җүси, Чагадай, Үгәдәй һәм Тулуйдан кала бишенче улы да була. Анысын, унбиш яшьлек Цаганны, Чыңгызхан тангутлар белән яудан кайтышлый таба. Малай җәяне дә бик төз тарта, ат өстендә дә уйнап кына утыра. Чыңгызхан бу малайны да тәрбиягә хатыны кулына бирә, үз улы итеп кабул итәргә куша. Әлеге малай соңыннан ханның мең баһадирдан торган шәхси гвардиясенең командиры Цаган-нойон булып җитешә. Чыңгыз үзе үлгәннән соң ике еллар

чамасы аның өченче улы Үгәдәй император булып тора. Үгәдәй хакимлеге чорында Цаган-нойон — Кытайдагы гаскәрләрнең башкомандующие һәм шунда губернатор.

Табылдык татар малае Шәһи-Котык та бик сәләтле булып чыга. Бик яшьли язу-сызуны үзләштерә, карталарны таный, берничә тел белә. Егетнең кемлеген күреп, зирәк акыллы, яхшы хәтерле булуына куанып, Чыңгызхан Шәһи-Котыкны империянең баш казые итеп куя. Мондый зур империядә баш судьясыз һич булмый. Ул зат талантлы, сәләтле һәм бик гадел шәхес булырга тиеш. Император Чыңгыз зур тырышлык белән төзегән империясенең нигез ташларына ярым-йорты, китек кирпечләр кертмәскә тырышкан!

— Үрелеп кулым җиткән барча халыкларны буйсындырырга ирештем. Хәзер алар белән бик оста һәм гадел идарә итәргә кирәк. Син, Шәһи-Котык, бөтен империядә минем очлы күзләрем, үткер колакларым бул. Алдашу күрдеңме, урлашу, караклык сиздеңме — барысын үзең хөкем ит. Тиеш икән, икеләнеп калма — үлем җәзасы бир. Әмма гадел булырга тырыш. Ә Монгол дәүләтен ныгытуга юнәлтелгән, илдә хокукый тәртип урнаштыруга хезмәт иткән гамәлләреңне кара тактага язып бар. Башкалар да күрсеннәр, гыйбрәт алсыннар. Шуны бел, империядә судсыз хөкем булмаска тиеш, — дип, Шәһи-Котык улына император чикләнмәгән власть бирә.

* * *

Бер башыннан икенче чикләренә кадәр кошлар очып җитмәслек араларны биләгән империя белән идарә итү мәсьәләсе Чыңгызхан алдына берзаманны бөтен кискенлеге, очлы кабыргалары белән килеп баса. 1215 елда, ул чакта Енкин исеме белән йөртелгән зур каланы (бүгенге Пекин) алгач, аның кулына шул заманның «иң акыллы заты» дип йөртелгән, даны киң таралган, үзе философ, үзе дипломат, үзе шагыйрь, җитмәсә, астролог та Элюй-Чуцай дигән кеше әсир төшә.

Әлеге Элюй-Чуцай тышкы кыяфәте, килеш-килбәте белән дә, императорга биргән җаваплары белән дә Чыңгызханның үзен әсир итә. Монголлар ханы укымышлыларның, зыялыларның кадерен ничек кенә белгән! Бу философны берсүзсез үзенә хезмәткә ала, аны һәрчак үз ставкасында тота, үз өстәлендә ашата. Чын мәгънәсендә бик галим кешедән император күп гыйлем-гыйбрәт ала. Элюй-Чуцай чорында Монголия империясенең Дәүләт архивы төзелә. Моның нинди фәнни әһәмияткә ия гамәл булуын кем генә аңламас вә бәяләмәс! Гасырлар, дәверләр уза тора. Әлеге акыл иясе Элюй-Чуцай нигезләрен салган Дәүләт архивы хәтта безнең көннәргә кадәр күп мәгълүматлар җиткергән.

«Җитез аргамакларга атланып бөтен дөньяны яуларга була. Әмма ат өстендә утырып кына бу дөнья белән идарә итү мөмкин түгел» дигән хакыйкатьне дә императорга Элюй-Чуцай әйтә. Империя белән уңышлы идарә итү өчен укымышлы, көчле администрация булырга тиешлеген күрсәтә. Әмма чиновниклар-казнокрадлар мөмкин кадәр аз булырга тиеш. Әгәр чиновниклар күп булсалар, алар ач күседән яман, империянең нигезен беренче булып үзләре кимерә башлаячаклар. Аларның эшен тугрылыклары императорга билгеле махсус ревизорлар даими күзәтеп торырга тиешләр. Чиновникларның күплеге эшлексез бюрократия армиясе тудыра, казнокрадлар, ришвәт алучылар күбәя. Боларын да императорга ипләп-ипләп кенә Элюй-Чуцай әйтә.

* * *

1206 елда узган Олуг Корылтай Тәмүджинне Диңгезгә тиң император итеп сайлауга, аның культын үстерүгә генә кайтып калмый. Төп максат — иксез-чиксез киңлекләрдә чәчелеп яшәгән татар, монгол, кара кытай, сары кытай ыруларын, кабиләләрен бер нык канат астына җыйган берләшмә булдыру, ягъни Мәңгелек Монгол дәүләте итеп ныгыту. Аның какшамас нигезләрен салу. Бу турыда Чыңгызхан еш кына ныклап торып баш вата. Үз тирәсен әледән-әле укымышлылар, зирәк акыллылар, дөнья күргән затлар белән тулыландырып кына тора. Укымышлы замандашларын аеруча тирән ихтирам итә. Кайсы халыкны яуласа да, аларга тими, берсен дә җәберләми. Үз тирәсенә туплый, аларны дәрәҗәле урыннарга билгели. Күтәрә, кулларына власть бирә. Бүгенге парламентлар дәрәҗәсендә үк булмагандыр. Әмма Корылтай утырышларында һәркем үз уй-фикерен шикләнми әйтә ала. Бу фикерләр Монгол дәүләтен ныгытырга ни дәрәҗәдә кирәкле, файдалы — анысын Чыңгыз һәм аның якыннары үзләре бәялиләр инде.

Әлеге Корылтайда, әлбәттә, беренче чиратта Монгол дәүләтен ныгытуны күздә тотып, император үзенең иң танылган туксан биш хәрби начальнигына Олуг хан ярлыклары, ягъни таныклыкларын өләшә. Тагын шунысы кызык: балачак дусты, малай чагында караклар Тәмүджиннең сигез аргамагын урлап киткәндә, аңа ярдәмгә килгән Нагу-Баян углы Богурчага гына тәтеми хан ярлыгы.

Бу хәлгә гаҗәпкә калучыларга Чыңгызхан:

— Олуг Хан ярлыгы аңа ниемә хаҗәт? Ул бит инде күптән Ханнарның Ханы! Кайсыгыз аны Олуг Хан итеп танымый? — дип сорый император.

Корылтай бертавыштан:

— Таныйбыз! — дип җавап бирә.

Чөнки Богурча — гади көтүче малае. Аксөякләр затыннан түгел. Үз заманында кырык мең кибиткага хуҗа, даланың иң танылган аристократы Исүгәй баһадир углы Чыңгызхан һаман да аристократларча фикерле булып кала.

Безнеңчә, ягъни бүгенгечә уйлаганда, «кызыл профессор» сымак була инде бу. Революциядән соң совет власте эшче-крестьян диктатурасын таныган кайбер интеллигенция вәкилләренә, диссертация-мазар яклап тормыйча да, «профессор» исемен биргән. Чөнки диктатураны кабул итмәгән профессорлар илне ташлап эмиграциягә киткәннәр. Яңа властьның югары уку йортларында фәнни эшләр алып барырга, студентларны укытырга укытучылары калмый. «Кызыл профессорлар» менә шул чакта туалар. Үземә дә менә шундый бер «кызыл профессор» кулында укырга туры килде. Бә-әк әйбәт карт иде ул «кызыл профессор» — Мөхәммәт ага Фазлуллин. Без студентлар аны бик ярата идек. Ул үзе дә безне яратты, «отл», «хор» билгеләрен кызганмады. Урыны җәннәтнең түрендә, иң почетлы гүр ияләре генә сайлана торган президиумында була күрсен мәрхүмнең! Богурчаны әйтәм, Чыңгызхан ставкасында ул да «кызыл профессор», ягъни «кызыл хан» булгандыр инде.

— Бүгенге Олы бәйрәмнәр көне җиткәнче мин бик дәһшәтле сынаулар аша уздым. Әмма Мәңгелек Күктәге Тәңре миңа һәрчак мәрхәмәтле булды, юл күрсәтте. Халкыма да рәхмәтлемен, һәрчак минем белән булды: шатлыкларга да тарыды, кайгы-хәсрәтләрне дә күп кичерде. Мине бүгенге дәрәҗәгә ул күтәрде. Моңа кадәр минем халкымны бидәләр дип йөрттеләр. Менә бүгенге көннән һәрьяклап ихтирамга, дан-шөһрәткә лаек бу халыкның йөзе-бите күк йөзе кебек һәрчак саф, ачык булып, аларның «күк монголлар» дип аталуын телим, һәм минем халкым җир йөзендә яшәгән халыкларның Иң беренчесе булсын! Бу тостны менә шуның өчен күтәрәм! — ди Корылтайда ясаган чыгышында император Чыңгызхан.

Аның максаты җирдәге барча халыкларны да үз канаты астына алу. Аның империясендә тынычлык хөкем сөрәчәк, сугышлар булмаячак. Очсыз-кырыйсызлыгы белән диңгезләргә тиң Чыңгызхан биләмәләренә кылыч тотып керергә, аның кул астында яшәгән халыкларга һөҗүм итәргә кемнең генә батырлыгы җитәр икән? Чыңгызхан кул астындагы барлык кабиләләр-ырулар да, бер-берләрен ихтирам итеп, үзара тату яшәячәкләр. Әнә киң колач белән сәүдә итсеннәр. Сәүдә — һәркем өчен бик дәртле, күңелне күтәрә торган шөгыль. Ә халыклар шул рәвешчә бер-берләрен үз культуралары, рухи байлыклары, яшәү рәвешләре, алга киткән яклары белән баетсыннар. Укучым, хөрмәтлем, үзең дә уйланып кара. Белмим, тагын кайсы дәүләт башлыкларының, императорларының башларына килде икән бу тикле акыллы, зирәк, изге фикерләр!

* * *

Генийларны аңлавы һәрчак кыен. Аларның да тәртәгә типкән, дилбегәләре көпчәккә чорналган мизгелләре буламы икән? Император Чыңгызханның ставкасында кемнәр генә чуалмый. Илчеләр-шымчылар дисеңме, сәүдәгәрләр, төрле сәяхәтчеләр, ханнар, аларның бичәләре, уллары, хәрби начальниклар-нойоннар. Аларга карата никадәр игътибарлы булырга тырышсаң да, киез шатерлар никадәр генә иркен булсалар да, манаралары алтынга манылган мәрмәр сарайларга җитми инде. Бер әйбәт башкала кирәк барыбер. Шунсыз булмый. Дәүләт белән идарә органнарын асрау өчен дә. Таштан, мәрмәрдән күзеңнең явын алырлык итеп салынган башкала! Чыңгызхан, менә шушы кала минем башкалам булыр дип, өч тапкыр уч төбенә төкереп, 1220 елда Каракырымга нигез сала. Чыңгызның өченче улы Үгәдәй аны 1224 елда төзеп тә бетерә. Алар белән күршедә генә Хара-Хото (Кара монгол) шәһәре була. Ни сәбәптәндер ачуы кубып, Чыңгызхан аны 1226 елда таш өстендә таш калдырмый юкка чыгара. Рус галиме П.К.Козлов 1908, 1909 һәм 1926 елларда биредә археологик казынулар алып бара. Хәрабәләр астыннан зур күләмдә кәгазь акчалар, алтын-көмеш савыт-сабалар, ике мең томнан артык китаплар, кулъязмалар, иконалар, скульптура-гравюралар казып чыгара. Шәһәрдәге кайбер сарайларның, храмнарның нигезе 440х360 метрлар. П.К.Козлов экспедициясе күп кеше сыешлы кунакханәләр, мунчалар, рәт-рәт булып тезелгән сәүдә лавкаларын казый. Монда табылган барлык нәрсәләр дә бүгенге көндә Санкт-Петербургта Эрмитажда саклана. Менә шулардан соң монголларны ярым кыргый халыклар дип санап кара инде!

Чыңгызханның башкаласы Каракырымда 1246 елда — сәяхәтче Плано Карпини, 1254 елда — Рубрук, 1275 елда янә Марко Поло була. Булмаска соң! Чыңгызхан белән Византия, Ватикан арасында курьерлар бер-берләрен алмаштырып кына торалар. Рим Папасы «җитез тояклы атларына атланып Чыңгызхан безнең якларга да килеп чыкмагае» дип коты алынып яши. Чыңгызханның Рим Папасына уйдырып-уйдырып язган хатлары Ватикан музеенда саклана. Аларны матбугатка тик 1956 елда гына чыгардылар. Алай да бер өлешен генә. Мажаралы вакыйгалар, шомлы теләкләр булмаса, ул хатларны шушы көннәргә чаклы «Совершенно секретно» грифы астында сакламаслар иде.

* * *

Күктәге Тәңрегә табынудан, тик аның чиксез кодрәтен танудан башка берәр динне тотмаса да, император аларның барысын да ихтирам итә. Яулап алган өлкәләрендә дин башлыкларына тими, җирләрен таламый, авыр ясаклар салып җәфаламый. Әмма шундый зур, күп халыклардан торган империя белән идарә итү өчен аңа якын таныш булган исламмы, буддамы, христиан диненме — шуларның берәрсен дәүләт дине итеп кабул итми булмастыр. Ләкин кайсысын? Аның сараенда берөзлексез итальян сәүдәгәрләре, синьорлары, идальголары, сәяхәтчеләре булып торганлыктан, аларның да турыдан-туры тәэсирләре тими калмагандыр. Берара христиан динен алырга ниятли ул. Бу турыда Ватиканга Рим Папасына ярлыклар да юллый. Әмма Рим Папасы нык шүрли аннан. «Динегезне кабул итәбез» дигән сылтау белән килеп чыгып басып алмагае, дип шүрли. Чыңгызханның күп ярлыкларын җавапсыз калдыра. Ә динсез яшәп булмый. Дәүләтнең төп бер дине булырга тиеш. Будда динен монголлар әле Чыңгызхан үлгәннән соң гына кабул итәләр.

Хөрмәтле укучыма шулкадәресе дә мәгълүм булсын. Дөньяда Каракырым дигән иң биек таулар системасы бар. Чогори очының биеклеге 8611 метр. Дөньядагы иң биек тау түбәсе Джомолунгма, ягъни барыбызга билгеле Эверестган чак кына калыша. Аның каравы Каракырым таулар системасына өчесе дә 8000 метрдан өстә өч тау түбәсе керә. Ә сигезе 7500 метрлардан югарырак. Хәтта перевалларның да иң түбән саналганнары 4500 метрлардан өстәрәк. Шуңа да карамастан Кытайга походларында Чыңгыз гаскәрләре бу перевалларны аша күп тапкырлар узганнар. Бер дә хәвеф-хәтәрсез түгелдер инде. Әмма шулай да узганнар. Бу перевалларны аша Кытайга хәтта Марко Поло да узган.

«Институтта укыган елларда бик теләп альпинизм спорты белән шөгыльләндем» дип яздым бит инде. Спортның бу төре буенча мастер дәрәҗәсе алу өчен уналты кыя башында булып, әләм кадап төшәргә кирәк. Мин уникесендә генә булырга өлгердем. Укуны тәмамлап эшкә киттем. Гаиләле булдым. Олы кызым Гөлнарабыз туды. Торырга фатирыбыз юк. Тагын дүрт кыя башында булып, «СССР спорт мастеры» дигән дәрәҗәле исем алырга берничек тә җай чыкмады. Әмма альпинизм белән шөгыльләнгән чакларда кышын да, күбрәк җәй айларында Кавказ, Кырым, Урал, Аппатит тау түбәләрендә булырга туры килде. Чыңгызхан гаскәрләренең 4000–5000 метрлар биеклектәге перевалларны кичү газапларын мин бик реаль күренешләр белән күз алдына китерәм. Хәтәр, хыянәт, фаҗига сине монда атлаган саен көтеп тора. Җир өстеннән нибары бер чакрым, чакрым ярымнар биеклектә йөзгән җәйге яңгыр болытларыннан күп өстә, текә кыя битенә басып, тауларда кар ишелгәнне бинокль аша исем китеп карап торганнарым булды. Коточкыч күренеш. Кар ишелү бездән егерме-утыз чакрымнар ераклыкта барса да, җир безнең аяк астында да «Әпипә»гә бии. Чыңгызхан да Каракырым перевалларын кичкәндә, аның сугышчыларының күрсәткән батырларын искә алып, башкаласына да Каракырым дигән исем биргәндер, кем белә... Ул перевалларны исән-имин үтү өчен кыюлык, батырлык, тәвәккәллек, корыч дисциплина ай-һай күп кирәк булгандыр.

Әйе, дөнья дигәнең без уйлаганга караганда күпкә киңрәк, баерак, тулырак бит ул. Менә бу информацияне мин Чыңгызхан үзен иксез-чиксез зур Монгол дәүләтенең императоры итеп игълан иткән 1206 елларга карата укучымның дөньяга карашын киңәйтү кирәк дип саныйм. Хәтер шүрлегенә теркәп куйса, бер дә зыян итмәс. Нәкъ менә шушы чорларга Мисырда Хеопс пирамидасы төзелеп беткәнгә 3580 ел! Күрче, дөнья дигәнең төзү, торгызу мәшәкате белән күптәннән яши икән! Уннарча мең бик сирәк кулъязмалар сакланган Ашшурбанипал китапханәсенең җир тетрәүдән һәлак булуына 1600 еллар. Олы мәдәният, цивилизация дигән төшенчәләр дә җир йөзендә күптән яши икән. Дөньялыкта бүтән тиңдәше булмаган мондый китапханәне 669–633 елларда хакимлек иткән Ассириянең дәһшәтле патшасы Ашшурбанипал җыйган, бер түбә астына туплаган булган. Шундый мәгълүматлар белән таныша башлагач, «менә ичмасам без!» дип бер дә күкрәк сугарлык җиребез юк икән, дип куясың.

Бөек Платонның шәкерте Аристотель хәзрәтләре б.э.к. 384–322 елларда яшәгән. «Платон минем дустым, әмма хакыйкать миңа кадерлерәк!» дигән канатлы афоризмны ул әйткән бит инде. Әдәп белән, намус саклап яшәргә ишарәләгән әлеге акыллы сүзләрне хәтта бүгенге сәясәтчеләребез дә бик еш кулланалар. Әйе, бүгенге дөнья без уйлаганга караганда күпкә, бик күпкә карт һәм бездән акыллырак.

* * *

Бөек полководец Чыңгызханга багышланган әлеге язмама, бер карасаң, турыдан-туры катнашы да булмаган әлеге мәгълүматларны, хөрмәтле укучыларым, дөньяга киңрәк диапазон белән карасыннар өчен кертәм, дидем бит. Монголларның императоры үлгәннән соң дүрт йөз еллар узгач, Рим инквизиция суды зур фикер иясе, философ, математик, астроном һәм шагыйрь Джордано Бруноны, сигез еллар төрмәдә интектергәннән соң, тереләй утта яндырырга хөкем итә. Без тырыша-тырмаша тереклек иткән чынбарлык һәрчак тирән катаклизмнар аша алга атлаган. Бу нәрсә хәтта бүген дә күзәтелә. Диалектик материализм дигән фәнне читкә куйдык. Аның «Борьба противоположностей», «Закон отрицания отрицания», «Переход количественных отношений в качественные и качественных в количественные» дигән өч биттән торган тәгълиматын оныттык. Юкса бит аларны коммунистлар уйлап чыгармаган. Аларны үз заманының иң алдынгы карашлы акыл ияләре раслаганнар, кешелек җәмгыяте

белән әнә шул законнарның идарә итүен күрсәткәннәр. Син бу законнарны таныйсыңмы, аларны беләсеңме, — аларның анда эшләре юк. Әлеге законнар җәмгыятьне барыбер үз калыпларында тоталар.

Кешелек җәмгыятенә вакыт-вакыт мракобесиегә, схоластикага, дөм томаналыкка әйләнеп кайту шулай ук хас нәрсә. Бозлык периоды төсле үк. Менә бит әле җиргә, аеруча Европага, янәдән бозлык чоры әйләнеп кайтуны көтә башладык. Бүген дә уй-фикер йөртү дәрәҗәбез Урта гасырларда аңнары схоластика, мистика белән сугарылган ватандашларыбызныкыннан әллә ни югары түгел. Үзләрен тотып утларда, учакларда яндырасы урында, янәдән урыннарны түрдән сихерчеләргә, багучыларга, экстрасенсларга, шарлатаннарга бирдек. Бер болганмый су да тынмый нәкъ менә шушы була торгандыр инде. Юкса үзебез күрше планеталарга сәяхәткә җыйналабыз. Ә табиблар, бер дә каушап калмыйча, бер кешенең йөрәген икенче затка күчереп куя башладылар. Бер уйласаң, акылга сыешлы гамәлме? Фантастика бит! Шул ук вакытта төрле шарлатаннар алдында баш иябез, соңгы тиеннәребезне түләп, аларның сеансларына йөрибез. Безгә океан артларыннан килгән, алларына бик шикле максатлар куйган секталарга язылабыз, йөрибез. Әйе, бер болганып алмый булмыйдыр шул инде.

* * *

Тәңре тарафыннан тумыштан ук гениаль зиһенле, зирәк акыл иясе итеп яратылган Чыңгызхан зыялыларның, укымышлы затларның кайсы диннән, кайсы милләттән, кысык күзлеме, ак тәнлеме икәнне тикшереп тормаган. Аларны үз тирәсенә туплавын белгән. Андыйларга тулы хокук, мул сыйризык биргән.

— Кайсы халыктан булуың түгел, минем өчен синең акыллы, сәләтле, укымышлы булуың әһәмиятле! — дип әйтә торган булган ул, үз тирәсенә зыялыларны туплаганда.

Әлбәттә, бу галимнәрнең, укымышлыларның да императорга уңай тәэсирләре зур булган. Алар аның дөньяга карашын тулыландырганнар, баетканнар. Кайчакларны артык кайнар булудан тыйганнар. Бәлкем, нәкъ менә аларның ярдәме, киңәше белән, Монгол дәүләте императорының бөтендөнья культурасын үстерүгә керткән өлеше чиксез зур. Кәгазь акчаларны, вексельләрне дөньяда беренче булып Чыңгызхан куллана башлый бит. Чөнки алтын-көмешне ишәкләргә, дөяләргә төяп йөртү эш түгел. Алыш-бирешләрне аяк өсте хәл итү өчен гаять ипсез. Куркыныч та. Алтын-көмеш төялгән ишәгеңне йә дөяңне урлап китәргә дә күп сорамаслар. Кәгазь акчаларны Италиягә Чыңгызхан станы сукмакларын ничә еллардан бирле таптаган Марко Поло алып кайта. Шуннан ул Европага да тарала.

Монголлар метеорология өлкәсендә дә бик алга киткәннәр. Яу белән чыгасын, төбәктә кайчак су катасын, кайчан җебетәсен алдан ук төгәл белмәсәң, бик уңайсыз хәлләргә калуың бар. Бу төркиләрнең ветеринария өлкәсендәге казанышлары гомумән искитмәле булган. Күп тарихчыларның язуынча, монголлар бахбайларның теләсә нинди суыкка яисә эссе-корылыкка чыдам, коры салам ашап та симерә торган нәселләрен чыгаруга ирешкәннәр. Бер уйласаң, гаҗәпләнеп туймаслык. Ул заманнарда микроскоп-мазар юк. Әмма алар ат-бахбайларын төрле чирләрдән гаҗәеп зур осталык белән саклый белгәннәр. Монгол атларымы?! Алар турында поэмалар артыннан поэмалар язарга була!

Вак елгалар аша җәлт кенә күперләр салу сәнгатен Европага монгол гаскәрләре алып килгән. Киң Иделләр, дәрьяларны паромнар белән кичү ысулларын рус кенәзлекләренә генә түгел, бөтен Европага Чыңгызхан гаскәрләре күрсәткәннәр. Күперләр салу Чыңгызхан генштабында махсус фән буларак өйрәнелгән. Чөнки яуга киткән гаскәрләргә берөзлексез азык-төлек, фураж, кораллар, җылы киемнәр җибәреп торырга кирәк. Монгол биләмәләрендә күперләр һәрчак төзек булганнар. Төзек, чыдам һәм нык! Нык, таза күперләр салу осталыгы — Азия һәм Европа халыклары культурасына монголлар керткән зур өлеш!

Болары әле бер хәл. Чыңгызхан һәм аның генералитеты разведка, яу барасы илнең экономик хәлен алдан белү мәсьәләсен моңарчы ирешелмәгән югарылыкка куйганнар. Мөгаен, озак еллар буена АКШ разведкасын җитәкләгән генерал Аллен Далес бу һөнәр серләренә Чыңгызхан разведкасының тәжрибәсен үзләштереп өйрәнгәндер әле. Карт бүре Сүбәдәй, хәйләкәр төлке Мүкәли, кулларына бик төгәл разведка мәгълүматлары тупламый торып, бер ил өстенә дә яу чыкмаганнар. Ул чакта радиотелефон да юк. Баш өстеннән шпион спутниклар да очмый. Генералитет кулында нинди разведка материаллары гына юк. Чыңгызхан үз сараенда мәш килеп торган чит ил сәүдәгәрләрен, сәяхәтче-шымчыларны, кенәзләрне, бароннарны, синьорларны нәрсәгә генә ашатып-эчертеп асрый соң? Хан штабына әле теге ил, әле бу халык турында иң кирәкле хәбәрләрне алар ташып, алар җиткереп торганнар. Әйе, зур политика шунсыз булмый, күрәсең.

Сүбәдәй башында да хәйлә, мәкерлек әллә ничә олау. Яу чыгасы илләренә башта, аларны сәүдәгәрләр итеп киендереп, үз шпионнарын җибәреп кайтара булган. Кирәк кешеләрне сатып алырга алтынны да кызганмаган. Соңыннан, уңышлы яудан соң, уны-йөзе белән кире кайта бит ул алтын!

* * *

Чыңгызхан һәм аның администрациясенең бөтендөнья культурасы алдында иң зур казанышы — дәүләтнең иң кирәкле органнары дәрәҗәсендә почта, хатлар йөртү-ташу хезмәтен оештыру! Чыңгыз ставкасыннан чыгып, дөньяның кайсы ягына гына сәфәр тотсаң да, почта станцияләре һәр илле-йөз чакрым саен булган. Марко Поло үзенең истәлекләрендә «Чыңгызхан империясе киңлекләрендә почта хезмәтен башкаручылар кулында өч йөз мең башлап атлар гына бар иде» дип яза. Почта биналары һәркайда юлаучының бөтен таләпләрен канәгатьләндерерлек итеп салынганнар. Зиннәтле итеп бизәлгәннәр. Почта бүлекләре бөтен империядә ун меңнәрдән өстә булгандыр.

Иң әһәмиятле юл чатларына салынган почта бүлекләренең һәркайсында кимендә дүрт йөз башлап юртаклар асраганнар. Мондый станцияләрнең иң вакларында да илле-алтмыш ат, юртак булган. Яу кыры белән ставка арасында срочный донесениеләр йөрткәндә, курьерларга кая ул төн кунып, чәй эчеп торулар. Хәбәр йөртүчеләр мондый станцияләрдә юртакларын гына алыштырганнар. Яңа аргамакка атланганнар да, юлларын дәвам иткәннәр, ставкага яисә яу кырына ашыкканнар. Махсус кенәгәдә аларның кайчан килеп җитүе, кайчан юлларын дәвам итүе сәгате белән билгеләнеп барган. Хөкүмәт-администрация, хакимият, суд, ревизия түрәләрен йөртү өчен җәен йомшак арбалы, кышын өсте ябулы ямьнәр йөреп торган. Аларны йөртүчеләрнең ямщиклар дип йөртелүен без дә беләбез.

Мондый уңайлыклардан файдаланучылар күп булган: илчеләр, сәяхәтчеләр, сәүдәгәрләр, чиновниклар, гади халык. Әмма император администрациясе үзенең иң кирәклеләренә махсус алтын пластинкалар биргән. Алар аны күкрәкләренә тагып йөрткәннәр. Почта станцияләренә килеп, шул пластинканы күрсәтү җиткән, мондый затка бернинди тоткарлык булмаган. Станция башлыгы, җидегә ярылып булса да, бу затлы затны тизрәк үз юлына озату ягын караган. Карамасаң, үзеңә үпкәлә, башыңны чабалар. Администрация үз вазифаларын начар башкаручыларга акыл өйрәтеп, нотацияләр укып тормаган. Шунсыз мондый зур дәүләтне тыңлатып, буйсындырып торырмын димә. Шушы сүзнең чын тулы мәгънәсендә Чыңгызхан империясендә почта-элемтә хезмәте тиешле югарылыкта булган. Юлчыларны, сәүдәгәрләрне, илчеләрне, курьерларны юлбасарлар һөҗүменнән саклау максатында ике станция арасында бик көчле сак отрядлары йөреп торган. Бүген дә шул хәлләргә калдык түгелме соң? Кайсы дәүләт учрежденисенә, кайсы гына офиска кермә, шунда автоматлы сакчы.

* * *

Үзем болай тарих факультетында укысам да, бу фәнне кызыксынып, яратып өйрәнсәм дә, Чыңгызхан төзегән Бөек Монгол империясе турында семинарны безгә өстән-өстән генә укып киттеләр төсле. Бу өлкәдә белемемне тирәнәйтим дип фундаменталь китапханәдә казынырга ниятләсәң, ул заманнарда аның кирәкле әдәбияты да юк шикелле иде. Алай гынамы?! Монголларга гомумән кыргый бер урда итеп, хәтта беркадәр җирәнеп карау идарәче даирәләр тарафыннан халыкта кечкенә чактан ук тәрбияләнә иде. Россиянең, СССР башлыкларының шовинистик позициягә басып, руслардан башка халыкларга кимсетеп карау политикасына бик туры килә иде бу караш. Менә хәзер дә әле, шушы трактатны язарга мин материаллар туплаган көннәрдә, НАТО авиациясе Югославияне бомбага тота. Рус шовинистлары югославлар, серблар, безнең «наши братья!» дип, ахмак башлыларның җаннарын җилсетәләр. Ил өстенә килгән бар афәтне руслар белән бер тәртәгә җигелеп тартучы без татарлар кемнәр соң? «Братьялар» түгелмени? Бүген Рәсәйдә егерме биш миллионнан өстә мөселман яши. Алар кемнәр? Шәт, кан дошманнар түгелдер ич? Хәер, күбесе үзебездән дә тора. Үзебезне тиешле дәрәҗәгә куя белмибез. Татар мәктәпләрен ябалар, дәшмибез. Телевидениедән татар тапшыруларын елдан-ел кыскарталар, тын да чыгармыйбыз. Татар телен дәүләт теле итеп кабул иттек итүен. Дәүләт Югары Советының бер генә сессиясен дә үз телебездә уздырганнары бармы? Эстоннарда — эстон телендә, латышларда латыш телендә уздырыла бит.

Узган көзне язучы Рәдиф Сәгъди белән «Казан утлары» журналын тарату буенча районнарга чыктык. Бөгелмә, Баулы, Ютазы, Лениногорск, Чирмешән, Әлмәт, Азнакай районнарында булдык. Әйтергә оят. Күп районнарның хакимият башлыклары шундый журналның хәтта барлыгы турында да белмиләр. Юкса бу басма Татарстан Язучылар берлеге органы! Анда язучыларыбыз тарафыннан язылган иң яхшы романнар, повестьлар, поэмалар, шигырьләр басыла. Укы, рәхәтлән. Үз мәдәниятең белән горурлан. Үз теле, үз мәдәнияте белән горурлана белмәгән халыкны әллә башка халыклар хөрмәт итәрләр дисезме? Шиш!

Сүзем бит бөек Чыңгызхан турында. Мисыр пирамидалары алдында кемнәр генә баш ими дә, кемнәр генә сокланмый. Алар дөньядагы җиде могҗизаның берсе булып торалар. Ә менә Бөек Кытай стенасы турында ни диярсез? Ул бит әле Иисус Христос хәзрәтләре дөньяга килгәнче үк, безнең эрага кадәр өч йөз гасырлар элек салына башлаган. Һәм аны төзүне 1260 елга кадәр дәвам иткәннәр. Әлеге стенаның озынлыгы ун мең километр! Биеклеге сигез, киңлеге дүрт метр. Аның өстендә пар ат җигелгән арбада чабарга була. Һәр йөз адым саен махсус башня. Бөек стена сусыз ком чүлләре, төпсез упкыннар, очлары болытларга ашкан тау түбәләре, ак күбек булып аккан елгалар, тирән тарлавыклар аша уза. Тимер юллар юк. Бүгенге экскаваторлар да. Ничек төзеделәр, нинди көчләр белән? Авырлыклары белән унар тонналы ташларны алар ничек күчерәләр икән? Стенаны төзүчеләр кемнәр

булдылар икән? Бөек Кытай стенасы белән чагыштырганда Мисыр пирамидалары нәрсә генә ул! Әлеге Бөек стенаны төзергә киткән 300 млн. кубометр ташлардан 120 Хеопс пирамидасы бастырырга булыр иде! Ә нинди максатны күздә тотып, кемнәр һөжүменнән котылыр өчен төзеделәр икән кытайлылар бу стенаны, дип сорагыз сез? Җавап бер һәм бәхәссез. Димәк, Бөек стенаның бу ягында әвәл-әвәлтеннән, безнең эрага кадәр үк, бик алга киткән цивилизациягә ия ниндидер бөек халыклар яшәгән. Алар борынгы Кытай дәүләтен дер селкетеп торганнар. Стенаны шул халыклар һөжүменнән котылу өчен салырга керешкәннәр. Кәгазьне, дарыны уйлап тапкан, гаскәрләрендә сугышчан филләре дә булган кытайлыларны куркытып торгач, Бөек стенаның бу ягында да зур көчкә, гайрәткә ия халык, ыру, кабилә яшәгәндер диясе килә.

Чыңгызханның үз гаскәрләре дә бу Бөек стенаның кай төшеннән күпме генә тапкырлар аркылы чыкмаганнар да, Кытайның күпме генә ханлыкларын пыр туздырмаганнар.

Кытай империясе башкаласы Енкинны (хәзерге Пекин) Чыңгызхан беренче тапкыр 1215 елда ала. Бу чакта императорга әле алтмыш кына яшь. Императорга: «Атлар өстендә ябырылып бөтен дөньяны яуларга була, әмма ат өстеннән төшми аның белән идарә итү турында уйлыйсы да юк!» — дигән сүзләрне әйткән, соңыннан аның иң акыллы, иң ышанычлы администраторына әверелгән акыл иясе Элюй-Чуцай да аңа нәкъ шул чакта әсир төшә.

Чыңгызханнан соң император булып торган аның оныгы Кубилайхан заманында Пекин Бөек Монгол дәүләтенең башкаласы да булып тора.

* * *

Аучылык, сунарчылык императорның иң яраткан шөгыльләреннән була. Һәртөрле яңалыкны бик тиз күреп, эләктереп алучан холыклы Чыңгыз, бәлкем, шахмат, нарда, кәрт уеннары да уйнагандыр. Аның тормыш юлын бик җентекләп өйрәнгән галимнәрнең язмаларында бу турыда бер сүз дә юк. Әмма аучылыкны, сунарчылыкны бөтен барлыгы белән яраткан. Берчакны шулай ауга чыккач, Чыңгыз астындагы ат, нидәндер өрлегеп, сөртенә. Чыңгыз, ат өстеннән егылып төшеп, аягын сындыра. Шунда моның өстенә ажгырып ата кабан дуңгызы килеп чыга. Аягы сынудан сыны каткан император шок хәлендә. Азау тешләренә кадәр ыржайткан кабан дуңгызы бичара Чыңгызны секунд эчендә өзгәләп ташлаячак. Әмма могҗиза! Юк дисәң дә, бар икән ул. Әллә Тәңренең әмереме? Кабан дуңгызы Чыңгызга җитәрәк берничә адым кала шып туктый. Аның өстенә ташланмый, нәрсәгәдер аптыраган хәлдә тора бирә.

Әлеге сәер очрак һәм шуңа охшашлары императорның зирәк акыллы миенә корт төшерә: дөнья киң, дөнья матур! Кызларның чибәрлеген күр. Берсеннән-берсе матурлар. Ә ниндиләре үсеп килә. Аңа гомере буе тугры калган, иренә дүрт баһадир ул табып биргән беренче хатыны Борте янына хатынлыкка чибәркәйләрнең чибәрләре, гүзәлләрнең гүзәлләре Есулин һәм Есукайларны кайтарып бастырды. Ә тангутлар патшасы хатыны Кюрбелдишин! Аның белән чагыштырырдай чибәркәй бөтен империядә бармы икән? Бу искитмәле гүзәл хатын Чыңгызхан кулына иренең патшалыгын туздыргач төшә. Бу турыда хәтта мондый легенда-риваять тә сакланган. Янәсе, Чыңгызхан шушы гүзәл хатынның тешләвеннән агуланып үлә. Дөрес, императорның үлеме бөтенләй башка сәбәптән. Әмма риваятьне дә тыңлыйк әле.

Чыңгыз чираттагы яуларының берсендә Тангут патшалыгын туздыра. Тангут патшасы Шидурхо-Хаган үзе чак качып котыла. Ә хатыны әсир төшә. Яуда җиңүченең тулы хокукы нигезендә ул Чыңгызханныкы булырга тиеш. Әмма Шидурхо-Хаган хатыны Кюрбелдишинга, Чыңгызны әгәр үпсәң дә, агулы тешләрең белән яралап үбәрсең, дип кисәтеп өлгерә. Императорның җан сакчылары гүзәлләрнең гүзәле, сылуларның сылуы Кюрбелдишин хатынны тырнак төпләренә чаклы бик җентекләп тикшерсәләр дә, авызын ачтырып карарга башларына да килми. Сөйгән, яраткан иренә тугры калып, Кюрбелдишин хатын Чыңгызханны беренче никах кичендә үк тешләп яралап, агулап үтерә. Иртәгесен исә үзе Хуанхэ елгасына ташлана. Чыңгызның ставкасы нәкъ шушы елга ярына җәйләүгә туктаган була. Шуннан соң монголлар бу елганы Хатун-мурен дип йөртә башлыйлар.

Риваять дөреслеккә никадәр якындыр, хәзер аны ачыклавы кыен. Әмма Чыңгызхан миенә чыннан да корт төшә. Шушы хәтле матур, ямьле дөньяны көннәрнең берендә нүжәли ташлап китәргә туры килер икән? Үлемнән ничек котылырга? Үлемсезлекнең, мәңгелекнең бер-бер дәвасы бармы икән? Бу дөньяда моңарчы аның ирешмәгән теләге калмады. Тәңре дә аңа һәрчак шәфкатьле булды. Бу каһәр үлем зәхмәтеннән дә котыласы иде бит. Аңа әле алтмыш алты яшь кенә. Чыңгызның бик яраткан кече улы Тулуй (безнеңчә — Көзге) Хорасәнне басып ала. Берочтан Мерв, Нишапур, Гератны буйсындыра. Чыңгыз үзе, әтисе Мөхәммәт вафат булганнан соң тәхеткә утырган Харәзм солтаны Җәләлетдинне тармар итеп, аны Һиндстанга ук куа. Шул чакта, аның чакыртуы буенча, почта атларында унике мең чакрымнар чамасы җирләр узып, шул заманның атаклы алхимигы, «үлемсезлек буенча фәлсәфи ташны эзләүче», «Тао» тәгълиматын таратучы данлыклы монах Чан-Чун килә. Әлбәттә, ялгызы гына түгел, күпләгән мөридләре, шәкертләре белән. Чөнки Чыңгызханның алдынгы карашлы император булуын, укымышлыларны ихтирам итүен ишеткән булгандыр. Философ Чан-Чун үз тәгълиматын Бөек

императорның иксез-чиксез биләмәләрендә тарату мөмкинлеген дә күздә тоткандыр. Күпсанлы шәкертләрен дә шул максат белән иртә.

Император аны колач җәеп, якты йөз белән каршы ала. Әмма үзен борчыган әлеге сорауларын бирергә ашыкмый. Таосс монахы Чан-Чунны үзе белән походларга алып йөри. Сыйлый, кунак итә. Кичен шулай черт-черт янган учак янында тылмач аша кинәттән сорап куя:

— Син менә күп нәрсәләрне беләсең, кадерле кунагым. Үлемнән котылып буламы? — ди.

Монах турыдан-туры: «Котылып булмый, — ди. — Ә гомерне озынайту, һәркемгә килә торган картлыкны чигендерү мөмкинлекләре бар», — ди.

Чыңгыз һич югында әнә шул мөмкинлекләрне, картлыкны дәвалау чараларын, әмәл-ысулларын секретарьларына бер сүзен калдырмый язып алырга, өйрәнергә боера. Чыннан да, каян чыккан бу үлем дигән ахмаклык? Шундый зур империя төзе дә үлеп кит, имеш! Патшалык кемнәргә калыр? Уллары үзара талашып аның артыннан ук империяне таратмаслармы? Хәер, җиденче дистәсен тутырып килгән патшалар патшасы башына мондый уйларның төшүе бер дә гаҗәп түгел.

Таосс монахы Чан-Чун белән алар күп кичләрне бергә уздыралар, күп нәрсәләр турында киңәшләшәләр. Сүз иярә сүз чыгып, Чыңгызның ауда аты абынуы, кабан дуңгызының аңа никтер һөҗүм итмәвенә дә барып җитәләр.

— Мәңге Зәңгәр Күкнең кисәтүе бу! — ди әлеге хәйләкәр монах. — Без хәзер олы яшьтә. Саграк булырга кирәк. Ауга йөрүне дә туктатырга вакыт. Ә кабан дуңгызының һөҗүм итмәве шулай ук Мәңге Зәңгәр Күкнең кушуы буенча. Ул безнең (Чыңгызханның) гомерен озайтырга тели. Мәңге Зәңгәр Күк безнең (Чыңгызханның) гомерен моннан соң да сакларга, озайтырга тырышачак, әмма үзебезгә дә сак булырга кирәк. Безгә хәзер унсигез яшь түгел. Мәңге Зәңгәр Күк өстән барын да күреп, күзәтеп тора.

— Киңәшләрең акыллы, әйбәт синең, — дип килешә Чыңгыз кунагы белән. — Әмма без, монголлар, ат өстендә туганбыз. Ук-җәяне бик иртә тарта башлыйбыз. Шул гадәтне кинәттән, тиктомалдан гына ташлау гаять кыен. Әмма синең кисәтүләреңә мин колак салырмын.

Таосс монахы Чан-Чун киңәшләрен ике айлар чамасы колагында да, хәтерендә дә тота ул. Аннары янәдән зур азарт белән ауга йөри башлый. Бер философ әйткән бит: «Без бу дөньяда туплаган холык-гадәтләребезне үзебез белән хәтта теге дөньяга да алабыз», — дигән. Хак сүз инде! Гадәтне ташлавы чыннан да бик кыен. Кая гына барсаң да, дегет чиләге булып ияреп йөри ул сиңа.

* * *

Чыңгызның моңа кадәр дә законлы-никахлы дүрт хатыны бар иде. Шул дүртесенең һәркайсы дүрткә торган дүрт хатын җитмәгәнме инде?! Бетмәс-төкәнмәс нәфес дигән нәрсә нинди генә ир-атларның башына җитмәгән. Чыңгыз чираттагы яуларының берсендә Найчун исемле тагын бер дөнья чибәрен кулга төшерә. Үз башына дигәндәй. Бу чибәркәй кочагында бер куну белән генә чикләнми картлач, аны бишенче хатынлыкка алып кайта. Әлеге яшь нәрсә Чыңгызның күңеленә бик хуш килгәндер инде, мин аны беркадәр аңларга тырышам. Әмма бу Найчун чын мәгънәсендә тайфун, ягъни бик әтчәянни нәрсә булып чыга. Чыңгызга, юлында нинди генә чибәрләргә юлыкса да, алты хатынлы булырга мыскал өмет калдырмый. Император кая барса, аннан бер адым калмый, аның белән яуга йөри башлый.

— Императорымны үзем ашатам, үзем эчертәм, кырыс поход шартларында үземнең кайнар кочагымда кочып йоклатам, — ди.

Ә бу хәйләкәр жанның усал мәкере бик түбәндә ята. Император җитмешләрдә. Әлегә болай нык күренсә дә, алда тагын күпме яшәр? Йөзгә хәтле яшәмәс бит. Хәер, анысы Мәңге Зәңгәр Күктәге Тәңре кулында. Алай да көтелмәгән хәлләргә әзер булып торырга кирәк. Андый-мондый әлеге кояшлы көннәрнең берендә Чыңгызхан үлә-нитә калса, аның өлкән хатыннары бу яшь килмешәкне шундук ашап ташлаячаклар. Анысы инде тавыкка да билгеле. Найчун шушы үткерлеге белән үзен әллә ни кыерсыттырмас. Хикмәт башкада. Найчунның унөч-ундүрт яшьләрендәге улы бар. Хикмәт менә кая! Император үлә-нитә калганда тәхеткә шул малайны утыртмыйча тагын кемне утыртасың? Яшь, чибәр, мәхәббәте ташып торган Найчун хатынның Чыңгызхан ставкасында да очрашканда күз кысышкан, каш сикерткән генераллары, полковниклары, нойоннары булгандыр. Тәхеткә Найчун хатынның улы утыра калганда әлеге нойон-генералларга да бәлешнең иң майлы калҗаларын ышандыруы да бик мөмкин.

Саулыгы ташып тормаса, Чыңгызхан җитмеш ике яшендә Кытайның аңа буйсынып бетмәгән өлкәләрен яуларга походка чыгып китмәс иде. Китә шул. Иренә сөлек булып ябышкан яшь хатыны да иярә. Чыңгызхан көтмәгәндә генә яуда үлеп куя. Аның шулай беркадәр серлерәк үлеме турында күп имеш-мимешләр бар. Ә мин аны яшь хатыны Найчун агуламады микән дип уйлыйм. Бер карасаң, үзеннән кырык яшьләргә өлкән Чыңгызхан аңа ниемә хаҗәт? Ставкада җәядә тарттырган уктай төз, күзеңне яндырырдай чибәр гаскәр башлыклары, ут кебек офицер егетләр бар.

Яшь хатыннарның чуар холыклырак булуларын беләбез инде аларның. Яу кырыннан җиңүчеләр булып, башкалага күкрәк киереп кайтып кереп, кирәксә, әлеге офицерлар белән бөтен сарайны туздырып, переворот ясарга да була. Әмма, хөрмәтле укучым, бу кадәре минем гипотезам гына, мин

аны фәнгә көчләп такмыйм. Ә менә Бөек Ханның җитмеш ике яшендә тангутларны буйсындырырга чыгып киткән җиреннән кинәттән вафат булуы тарихи факт.

Бу хәл Тангут дәүләтендәге Си-ся дигән төбәктә 1227 елның 25 августында була. Үлгән-беткән. Үлгәнне терелтеп булмый. Император агуланудан үлгәнме, әллә башка чирдәнме, ул чакта патологоанатомнар да, судмедэкспертлар да юк. Мәетне ярып карап, тикшереп тормаганнар. Алары тагын ниемә хаҗәт? Бөек полководецның янында соңгы минутларына кадәр иң сөйгән, иң яраткан хатыны булган бит.

Әйе, авырып, чирләбрәк торса, Чыңгыз бу яуга чыгып китмәс иде. Димәк, әле нык-таза булган. Бернидән зарланмаган. Ә менә поход чорында аны яшь хатыны агуламады микән дип шик белдерергә минем җирлегем бар. Һәр патша, һәр король, һәр солтан сараендагы кебек, Чыңгыз ставкасында да интрига, итәк астыннан эш йөртү, берсе өстеннән берсе донос язу, үч алу, әләкләшү, көнчелек муеннан ашкан була. Үләренә ярты еллар гына кала Чыңгыз гомере буена яратып бетермәгән олы улы Җүчине агулап үтертә. Монысы хак. Моңа бик оста корылган интрига сәбәп була. Чыңгызны улына каршы котырталар гына түгел, өстерәләр: улың сине картсына, переворот ясап, тәхетеңә үзе утырырга җыена, диләр.

Императорга шымчылар җиткергән хәбәрдә, бәлкем, дөреслек тә булгандыр. Җүчи һәрчак читләтүне, атасы тарафыннан үз баласы итеп танымауны гомере буена татып яшәде. Моңа күпме түзәргә була? Аның үз олысының чикләре «монгол аты тоягы баскан җирләргә» чикле. Монгол аты таптамаган җирләрне табып кара син. Җүчинең уллары Бату, Бәркә, Беркечар, Шәһбан, Тангкут, Бувал, Чиякүн, Шинкир, Чимгай, Мөхәммәд, Удур, Сингкум, Тукай-Тимур. Һәркайсы ут егетләр. Ат өстендә чабалар. Аткан укларын һавада очкан кошларга тидерәләр. Әтисе тарафыннан гел кыерсыту күреп торган Җүчигә нигә улларына таянмаска? Әйе, аңа бөтен империягә үзе хуҗа булырга күптән вакыт. Атасына мондый патшалыкны төзергә, кая җибәрсә, шунда баш очында кылыч уйнатып аз көч куйдымы? Аңа империя тәхетенә утырырга бик вакыт. Әмма Җүчи бу теләкләрен тормышка ашыра алмый кала шул. Аны агулап өлгерәләр.

Аз гына алгарак атлап, шуны да әйтеп китү урынлы булыр. 1236 елда половецларны, ягъни Дәшти Кыпчакларны пыр туздырган, 1237–1243 елларны бөтен Көнчыгыш Европаны үзенә кол иткән Батыйхан Җүчинең олы улы бит инде. Батый гаскәрләре атларын хәтта Адриатик диңгез ярларында коендыралар.

Шундый нык нигезе булгач, Җүчи үз биләмәләрендә үз тәртипләрен урнаштыра башлый. Гел әтисе кубызына гына биеп торырга теләми. «Олы углың Җүчи синең империяңнең составыннан аерылып чыгарга ниятли, сак бул!» — дип җиткерәләр коткы сүзләрен шымчылар Чыңгызханга. Бөек Хан моңа юл куячакмы соң? Инде олы яшьләрдә булуына карамастан, ул бит ару-талуны белмичә һаман да Бөек Монгол дәүләтен тагын да ныгыту турында кайгырта. Яуга йөри, аның чикләрен киңәйтә. Таосс монахы, философ Элюй-Чуцайның: «Ат өстендә утырып кына дәүләт белән идарә итеп булмый!» — дигән сүзләрен дә исеннән чыгармый. Зирәк акыллы җитәкчеләрдән торган идарә аппараты булдыру турында көндәлек кайгыртып тора. Реформалар артыннан реформалар уздыра, дәүләт белән идарә эшенә яңалыклар кертә.

* * *

Чыңгызхан — чал тарих битләрендә үзенең зирәк акылы, хәрби таланты, искитмәле реформалары белән иң тирән эз калдырган шәхесләрнең берсе.

Бу урында да конкрет сөйләми ярамас. Болай була ул. Чыңгызхан империясенең көннән-көн көчәеп, ныгып баруын күрше-тирәдәге мөселман дәүләтләре, аеруча Харәзм патшасы, Багдад хәлифе көнләшеп һәм котлары очып күзәтеп торалар. Башында Мөхәммәт солтан торган Харәзм патшалыгына ул чакта Төркестан, Әфганстан һәм Персия керә. Харәзм дә бик бай, күршеләренең котын алып торган патшалык.

Харәзм шахы Мөхәммәт, күп бүләкләр төяп, Чыңгызханга илчеләрен җибәрә. Әлбәттә, ныклы разведка максатларында. Әле яңа гына яудан кайткан Чыңгызхан аларны якты йөз белән каршы ала, зурлап кунак итә. Илчеләрне озатканда Мөхәммәт шаһ исеменә хат та җибәрә.

«Олуг вә Кодрәтле Мөхәммәт, син Көнбатышта хаким булсаң, мин — Көнчыгышта. Эчкерсез дуслык мөнәсәбәтләре урнаштырыйк, тату яшик. Үзара сәүдәгә киң юл ачык».

Бераздан Монголиягә килгән мөселман сәүдәгәрләре белән Харәзм шаһы Мөхәммәткә Чыңгыз үз илчеләрен җибәрә. Солтанга бик күп бүләкләр белән. Чыңгыз илчеләре ике зур дәүләтне дуслык җепләре белән тоташтырачак сәүдә-кәрваннар юлында саклык-куркынычсызлык чаралары булдыру турында вәкаләтле килешү төзеп кайтырга тиеш булалар. 1218 елны илчеләр Сыр-Дәрья буендагы Отрар шәһәренә килеп җитәләр. Солтанның Отрардагы наместнигы кунакларны һич көтмәгәнчә каршы ала. Сәүдәгәрләрне талый, ә Чыңгызхан илчеләрен үтертә. Шундый искитмәле хәл. Бәлкем, Мөхәммәт солтан Чыңгызханга ышанып җитмәгәндер. Аның илчеләрен дә үзенекеләр төсле разведчиклар, шпионнар санагандыр.

О-о, егетләр, Чыңгызханның бөек дипломат, акыл иясе булуына тагын бер ышанасың. Аның законнары буенча илчеләргә бармак белән чиертергә дә ярамый. Алар бит үз ирекләре белән йөрүчеләр түгел. Алар күрше патшалыкка, аның башлыкларына үз хакимнәренең уйларын-фикерләрен, киңәшләрен җиткерүчеләр. Илчеләрне кыерсытырга ярамый. Чыңгызхан үзенең «Ясак» тупламасында да бу турыда кат-кат әйтә. Ярар, әлеге очракта Чыңгызхан, бар ярсуын тыеп, Харәзм солтанына икенче илчелеген җибәрә. Мөхәммәт исә бу юлы да өлкән илчене үтертә, калганнарын эт итеп сүгеп, типкәләп куып чыгара. Чыңгызхан да тәмам ярсый. Бу хыянәтче җан белән сугышмый булмый икән. Ә Мөхәммәт патшаның бүгеннән сугышка әзер дүрт йөз меңлек атлы гаскәре бар икән. Ул шуңа таянган булгандыр. Чыңгыз да сугышка ныклы әзерлек чаралары күрә. Мондый хыянәтне, хурлыкны ул күтәрәме соң?! 1219 елның язына Иртыш елгасының башланган җирендәрәк ике йөз утыз меңлек гаскәр туплый. Император күпьеллык сугыш тәҗрибәләреннән шуны яхшы белә: эш санда гына түгел, беренче чиратта сыйфатта. Шушы ук вакытта олы улы Җүчинең Кыпчак далаларын дер селкеткән чагы. Чыңгыз егерме меңлек гаскәре белән аны чакыртып ала.

Харәзм шаһы Мөхәммәт гаскәрләре белән Чыңгызхан ике тапкыр орышып, аларны тәмам тар-мар итә. Мөхәммәт үзе, ставкасын ташлап, Сәмәрканд крепостена кереп бикләнә. Кальга эчендә йөз ун меңлек гаскәр, егерме сугыш филе. Крепость стеналары төбенә килеп баскан монголлардан аны саклаучылар берничә тапкырга күбрәк. Әмма Чыңгыз гаскәрләре Сәмәркандны биш көн эчендә алалар.

Монголлар Бохарадан һәм Сәмәркандтан да алда Отрар каласын алалар. Чыңгызхан илчеләренең башларын чаптырган Отрар каласы башлыгы, Мөхәммәт патшаның наместнигы Гаирханны император аягыннан дарга астыра.

Ә Мөхәммәтне тотарга Сүбәдәйне, Җәбә-Укны һәм кияве Тәгуҗарны җибәрә. «Мәңге Зәңгәр Күкнең ярдәме белән аны тотмый кайтмагыз», — дип озата. Әмма Мөхәммәт тә өлгер. Чыңгызхан кулына эләксә, үзен нәрсә көткәнен бик яхшы чамалый. Эзәрлекләүчеләр кулыннан чак котылып, Каспий диңгезе эчендәге бер утрауга кереп бикләнә. Аннан бүтән чыкмый инде. Шунда үз үлеме белән үлеп китә бугай.

Чыңгызханның нойоннары-генераллары, өч якtан кысрыклап, Харәзм шаһы Мөхәммәтне тотканнар да булыр иде. Әмма походка чыккач, Тәгуҗар үзбелдеклеләнеп Сүбәдәй һәм Җәбәдән аерыла. Император мондый башбаштаклыкларны беркайчан кичермәгән. Тәгуҗар — аның яраткан кияве, кызының ире, оныкларының аталары. Әмма бабасы аны үлем җәзасына хөкем итә. Бераздан кайтып төшә тагын. Гаскәр башлыгыннан гади сугышчы итеп калдыра. Тәгуҗар соңыннан Нишапур крепостен алган вакытта батырлык күрсәтеп һәлак була.

* * *

Шул вакытта дигәндәй...

Әтисе Мөхәммәт үлгәч, Харәзм тәхетенә аның улы Җәләлетдин утыра. Газни шәһәрендә (хәзерге Әфганстан) Җәләлетдин Чыңгызханга каршы бик зур гаскәр туплый. Тупламаска! Бу чорларда бөтен мөселман дөньясы: «Кылган гөнаһларыбыз өчен безнең өскә Хак Тәгаләбез тарафыннан җибәрелгән афәт», — дип, Чыңгызханнан дер калтырап, өркеп торалар. Аны берәр орышта тар-мар итеп, дар агачына асу өчен теләсә кем, хет шайтанның үзе белән берләшергә әзер булалар.

Чыңгыз Җәләлетдин белән орышка яшьлегендә далада үзе табып алган, хәзер танылган гаскәр башлыгы булып җиткән Шәһи-Котыкны җибәрә. Бамиан шәһәре янында Җәләлетдин солтан Шәһи-Котыкның йонын очырып тар-мар итә. Шәһи-Котык исән калган сугышчылары белән кая барсын? Бөек Хан каршына кайта. Бу очракта Чыңгыз нишләргә тиеш? Шәһи-Котыкны дар агачына асаргамы, әллә башын гына чабаргамы? Монгол гаскәрләренең яуда, нинди дә булса орышта җиңелгәне бармы?

Әмма Шәһи-Котыкның тар-мар ителүе турындагы хәбәрне Чыңгызхан елмаеп кабул итә. Аның катлаулы, кырыс холкына үзенә бер яңа чалым бу.

— Элэктеме үзеңә? Ярый әле башыңны алып котылгансың, — дип елмая Чыңгыз. — Моңарчы бит гел җиңеп, дошманнарыңны тар-мар итеп килдең. Күреп, сизеп тордым: эчеңнән генә «миннән дә акыллылар, хәйләкәрләр юк» дип масая башлаганыең. Ә бар икән бит. Ә хәзер җиңелүнең дә нәрсә икәнен белдең. Моннан соң дошманнарыңны җиңәргә икеләтә-өчләтә көч белән алыначаксың.

Дөрес, Җәләлетдиннең җитмеш меңлек атлыларына каршы Шәһи-Котык утыз меңлек гаскәре белән генә каршы чыга. Монгол полководецы орыш барышында хәйләгә дә керешеп карый. Үзләре белән арттан иярtеп йөри торган алашаларына да эчләренә салам тутырган карачкы-чучелолар атландырып карыйлар. Җәләлетдин солтанның командирлары аларны чыннан да чак кына чын атлылар дип алданмыйлар.

Чыңгызхан моңарчы гел җиңүче булып килгән полководецы Шәһи-Котыкны орыш узган кырга алып килә. Аркылыга-буйга йөреп чыгалар. Егетнең сугыш кырын дөрес сайламаганын күрсәтә. Анда түмгәк, монда түмгәк. Мондый кыр атлар белән һөжүм итәргә бөтенләй уңайсыз. «Булачак орыш кырын дөрес сайлау, ипле позициядә тору — ярты җиңү дигән сүз» дип кисәтә.

1220–1221 елларның кышын Чыңгызхан Сәмәркандтан чак кына читтәрәк, көньяктарак, кышлау өчен бик ипле урында уздыра. Шау чәчәккә күмелеп утырган Харәзм оазисын (хәзерге Хива өлкәсе) алу өчен өч улын һәм Богурча нойонны җибәрә. Байтак кына камап торганнан соң, Харәзм каласы Чыңгыз гаскәрләренә (бүгенге Үргәнеч) капкасын ача.

Харәзмне камап торганда, Чыңгызханның әлеге ике улы — Җүчи белән Чагадай арасында мөнәсәбәтләр пычакка пычак килерлек дәрәҗәгә җитә. Мондый чакта бердәм, бер йодрык булуның ничек мөһимлеге турында сөйләп тору кирәкме? Бу хәлне белеп алуга, аталары, тегеләрнең икесен дә гажәпкә калдырып, камау эшләренең башкомандующие итеп, өченче улы Үгәдәйне билгели. Җүчине үтертмәскә, ул инде шул чакта ук әтисе белән кискен конфликтка керә. Гаскәрен алып кайтып китмәкче була. Чөнки әтисе Чыңгыз аны гомере буена үз улы дип танымады.

Үгәдәй әтисе кебек бик зирәк акыллы, кешеләр белән тиз аралашып, аларның күңелләрен таба торган киң холыклы егет була. Тәмле сүзгә дә кесәгә керми. Бу юлы ул ике абыйсын да килештерә, татулаштыра. Ләкин озаккамы? Орыш кыры талашып ята торган җир түгел. Улларының татулашып куюларына Чыңгыз үзе дә сөенә. Үгәдәйне кочагына алып сөя.

Җәләлетдин белән хәлиткеч орыш 1221 елда Һинд елгасы буенда була. Бу орышта мөселманнар үз-үзләрен аямыйча, могҗизага тиң батырлыклар күрсәтсәләр дә, барыбер җиңеләләр. Бу җиңүләре белән монголлар үз императорларының искиткеч хәрби талантына бурычлылар. Орыш белән шәхсән үзе җитәкчелек иткән Чыңгызхан кырылышның иң җаваплы моментында сугыш кырына «мең баһадирдан» торган гвардиясен кертә. Тарихка кергән орышның язмышын алар хәл итә. Җәләлетдин исән калган батырлары белән Һинд елгасына ташлана. Теге якка таба йөзеп китәләр.

Шуны күреп торган улларын Чыңгыз үз янына дәшә. «Әтисенең тугры улы бу егет, Җәләлетдин. Мин аңа сокланам!» — ди.

Бу очракта ул нәрсәне күздә тоткандыр. Чыңгызхан, һәрхәлдә, бер дә юкка гына сокланмас...

Сугыш, яу мәсьәләләрендә бик сак эш итәргә күнеккән Чыңгызхан күреп тора. Җәләлетдин кереп качкан Һиндстанга яу чыгарга әле иртәрәк. Өрми капсаң, авызың пешмәгәе, ди ул улларына да.

1222 елның җәен Чыңгыз бөтен армиясе белән салкынча, әмма ризыкка-азыкка бай Гиндукуш тирәсендә, 1223 елның язын Ташкент янындагы Чирчик елгасы ярларында уздыра.

Чыңгызхан 1223 елның җәендә Сыр-Дәрья ярында тагын бер зур Корылтай уздыра. Аңа Бөек Монголиянең барча күренекле башлыклары чакырыла. Урыс кенәзлекләре җирләрендә киң колач алып барган орыш кырларын бер арага калдырып торып, Корылтайга башкомандующий Сүбәдәй дә кайта. Елъязмаларда язылганча, Чыңгызхан Сүбәдәйне күрү шатлыгын тыя алмый. Аны бүләкләр белән күмә, гел үз янында гына тота. Кичләрне икесе өчен дә татлы гәпләр эчендә уздыралар. Сүбәдәй императорга Европадагы кенәзлекләрнең таркау булуы, андагы байлыкларның чиксезлеге турында сөйләгәндер. Бөек Монголия дәүләте императорына Сәмәркандтан махсус кайтарылган, мәрхүм Мөхәммәт солтаннан калган алтын тәхетне бүләк итәләр. Ул шул тәхеттә утырып тора. Бүген ул Мәңге Зәңгәр Күк астында яшәгән биш төсле йөз-чырайлы —монгол, кытай, һинд, кыргыз-казах, урысларның һәм барлыгы җиде йөз егерме телдә сөйләшүче халыкларның патшасы! Ул бүген дан-шөһрәт дигән татлы нәрсәнең иң биек ноктасында!

* * *

Беркадәр Кытай архитектурасы стилендә төзелеп яткан башкаласы Каракырымга император 1225 елны гына кайта. Кайчандыр дошманнары тарафыннан таланган, типкәләп калдырган Тәмүджин бүген иксез-чиксез империя башында. Аның нинди көчле гаскәре, алар белән оста идарә итүче талантлы полководецлары, гаскәр башлыклары бар. Азия мөселманнарын тар-мар итү Көнбатыш белән Көнчыгыш арасында бөтенләй башкача бәйләнешләр булдырырга юллар ачачак. Ә Монголия шушы юлларның нәкъ уртасында! Итальяннар башкаласы Рим түгел, ә монголлар башкаласы Каракырым булачак дөньяның кендеге!

Хәзергә беренче чиратта сугыш максатларын хәл итү өчен хезмәт иткән почта-элемтә юллары тыныч вакытта милләтләр, халыклар арасында мәдәният-культура, үзара аралашу, сәүдә бәйләнешләрен чәчәк аттыруга этәргеч булачак.

Әмма Чыңгызханның әле тагын бер дошманы калган икән. Тангут патшасы. Моннан берничә еллар элек Харәзм шаһына каршы яу белән барган чагында Чыңгызхан аннан бераз гаскәр сорап торганые. Тангут патшасы бирмәде. Бирәме соң? Күршесенең тагын да көчәюен кайсы патша теләсен?! Чыңгызхан андый нәрсәләрнең берсен дә онытмый... Җае чыкканны гына көтә.

Чыңгыз беренче эше итеп башкаласы Каракырымга баш хатыны Борте янына, төп гаиләсенә кайтып бераз ял итә. Дәүләт эшләрен карый. 1225 елның ахырында Тангут патшасына каршы яу чыга. 1226 елның февралендә тангутларны, гомердә аякка баса алмаслык хәлгә төшереп, барысын ут һәм кылыч аша уздыра. Әле 1226–1227 елларның кышында далада кыргый атлар аулаганда, Чыңгызның үз аты нидәндер өркеп читкә сикерә. Чыңгыз, аттан очып төшеп, бик нык имгәнә. Аңа бит инде җитмеш икенче яшь бара! Кирәк бит, шундый яшьтә дә шундый азарт, дәрт белән яшәргә! Шушы егылудан соң

ул үзен байтак вакыт бик начар хис итә. Кем белә, аның үлеменә дә, бәлкем, шушы имгәнү сәбәпче булгандыр...

Инде походта, үлем түшәгенә яткач, Чыңгызхан янына уллары Үгәдәй белән Тулуйны дәштерә.

Васыятен әйтә:

— О-о, булдыклы, үзем кебек акыллы, булган-уңган улларым! Минем дә Мәңге Зәңгәр Күккә ашар сәгатьләрем килде бугай. Мин сезгә, оланнарым, кайсы якка карап китсәң дә, бертуктамый бер ел барырлык җирләр яулап калдырдым. Сезгә бердәнбер үтенечем шул: бер-берегезне ихтирам итеп, аңлашып, миннән соң да, зинһар, тату яши күрегез. Татулыкта булыр бар көчегез. Бу ни теләсәң — шуңа бай, очсыз-кырыйсыз империянең игелеген күрегез. Бер-берегезгә кунакка йөрешегез. Балаларыгыз, хатыннарыгыз белән. Арагызда аңлашылмаучылыклар, тарткалашулар килеп чыкканда кылычка ябышмагыз, андый мәсьәләләрне Корылтайга җыйналып хәл итәргә тырышыгыз. Минем урынга сезнең белән бер карында яралган өченче улым Үгәдәйханны сайлагыз. Үкенмәссез! Аннан уңарсыз.

Мәңгелек Бөек Монгол дәүләте төзү һәм аны какшамас итү буенча уй-фикерләремне «Ясак» законнар җыентыгында да дәлилләп, нигезләп әйттем. Аңа да еш күз салыгыз. Аңардан тайпылмагыз, үзгәртмәгез. Юкса империядә бер-береңә буйсынмау, бер-береңнең акыллы киңәшләрен тотмау китәр. Алайга китсә, эшләр харап. Империя җимереләчәк, тузанга әйләнеп юкка чыгачак.

Күктә — Тәңре, җирдә аның йомышчысы булган Чыңгызханны, үзе туган җиргә кайтарып, Бурхан-Калдан тау итәгенә җирлиләр. Ул туган Онон елгасы да башлангычын шул тау итәгеннән ала. Бүгенге мародерлар, зиратлар басып, каберләр актарып йөрүчеләр, ул заманнарда булган, күрәсең. Зиратны, каберлекне соңыннан юлбасарлар, мародерлар басмасын өчен, кабер өстенә бернинди дә билге куймыйлар. Соңыннан шушы җирдә үк Чыңгызханның улы Тулуйны (Көзгене), аның улы Мәңкеханны, аның балаларын, Күбилай ханны һәм аның балаларын җирлиләр.

* * *

Укучы сизгәндер, бу язмамны мин баштан ук Чыңгызханга симпатиямне яшерми сиздереп язам. Язмаска соң! Чөнки бу бөек шәхеснең алдына куйган максатлары, идеаллары да гадиләрдән генә түгел, бөекләрдән. Аның идеалы — Бөтен Кешелекне берләштергән патшалык төзү. Ул чагында сугышларның да кирәге калмас. Чыңгыз яулаган җирләрдә юк бит сугышлар! Һәр халык, һәр ханлык казнага тиешенчә ясагын түләп, тату гына яши бирәләр. Ә ясак түләми булмый. Аннан җыелган акча юллар төзүгә, почта-элемтә тотуга, чиновниклар асрауга тотыла. Барысы да бик аңлашыла. Бөтен Кешелекне берләштергән патшалык төзелсә, кешелек рухи һәм материаль культура өлкәсендә чәчәк атачак. Нинди матур сарайлар, шәһәрләр салырга, елгаларны буарга мөмкин булыр иде. Чыңгызханның уйлавынча, бер патшалык халкы бер-берләре белән эчкерсез аралашып, материаль һәм рухи байлыклары белән бер-берсен баетып, татулыкта, дуслыкта яшәрләрие.

Укый-яза белмәгән Монгол императоры Чыңгызның башына мондый тирән уй-фикерләрнең әле шул чорларда ук килүе үзе үк могҗиза, мине әсир итә. Аңа карата ихтирамым артканнан-арта. Кешелек дөньясының иң зыялылары бүген дә нәкъ менә шул турыда баш ваталар түгелме соң? Милләтләр Лигасы, Берләшкән Милләтләр Оешмасы шуларның ачык чагылышы түгелме? Европа илләренең бер-берсенә чикләре күптән ачык. Телисең икән, теләсә кайсы илгә визасыз-нисез бар да кер. Интеграция политикасы да шул юнәлештәге адымнарны раслый. Бер илләр корыч кына коя, икенчеләре машина гына ясый. Өченчеләре җиләк-җимеш, яшелчә үстерү буенча специальләшә. Хәзер менә Европа илләре өчен уртак валюта — евро керттеләр. Илләр арасында алыш-бireш, сәүдә эшләре бермә-бер җиңеләйде. Евроның курсы да, сатып алу кодрәте дә һәр ил өчен бер. Ә бит менә шушы фикерләрне, аеруча дус һәм тату яшәү кирәклеген, беренче башлап Чыңгызхан әйткән! Аны ничек ихтирам итмисең?! Бу фикерләрен кызыл балчыктан яндырып ясаган тәлинкәләргә чукып яздырып калдырган. Бу таш-ташыяк китапның кайбер фрагментлары Эрмитажда сакланалар. Казан дәүләт университетының тарих факультетын яңа гына тәмамлаган берәр егет шунда барып чыгып, шул ташыякларны күтәреп укып караса, исеме дөньяга танылган зур галим булыр иде. Ә Чыңгызханның гение алдында ничек баш имисең!

* * *

Бөек Ханның тормыш юлы, яшәү рәвеше, уй-фикерләре, ясаган реформалары, аның искитмәле хәрби таланты турында әлеге кыска язмада гына тулысы белән әйтеп бетерү һич мөмкин түгел. Моның өчен калын-калын томнар язу кирәктер. Беренче битләреннән үк шовинистик рухта язылган рус әдәбиятында да, аннан килә совет әдәбиятында да Чыңгызхан коточкыч шәхес, кыргый яу башлыгы, комсыз башкисәр буларак кына сурәтләнә. Шуңа нык ачуым килеп йөри иде. Чыңгыз бабабызның ямьсез сурәтен матур төсләр белән бизәп, баетып, тулыландырып берничә генә матур штрих өсти алсам, алдыма куйган бурычымның меңнән бер өлешен генә булса да үтәгән булачакмын.

Кем әйтмешли, кан тартмаса да, җан тартуыдыр инде. Ә менә моннан 779 еллар элек яшәп дөнья куйган Бөек Ханыбыз турында әлеге язмамны язуыма, әйтәм бит, мин бик канәгать. Югыйсә язучының үзе язганнан канәгать калу очраклары бик сирәк. Ә бу юлы мин канәгать, хәерлегә булсын! Әгәр инде мине кайчакларны «Син бит Чыңгызхан ыруыннан!» дип иреште рергә теләсәләр, ни дип ирешим, горурланам гына. Аяк терәп горурланам, хәтта рәхмәтлемен. Ул минем өчен зур дәрәҗә һәм мәртәбә!

Бу язмамны шушы җирдә төгәлләп, соңгы ноктасын куярга да булырые. Бөек Монгол дәүләтен төзегән көчле политик, акыллы администратор, тиңдәшсез полководец Чыңгызхан һәм аның тормыш юлына кагылышлы мәгълүматларның берсен дә һавадан гына алып яисә бармактан суырып язмадым. Бу трактатны язганда миңа институт буенча сабакташым, көндәлек тормышта эчкерсез дустым, үзе дә танылган язучы, тарих фәннәре докторы, профессор Равил Фәхретдинов бик нык ярдәм итте. Акыллы киңәшләре һәм сирәк очрый торган чыганаклары белән. Равил дустыма, аның тормыш иптәше Әлфия ханыма саулык, тигезлек, озын гомер телим.

Равил дустым миңа Георгий Вернадскийның (Мәскәү, 1997) «Монголы и Русь» дигән, фәнни яктан бик кыйммәтле китабын бирде. Әгәр аннан өзекләр китермәсәм, Бөек Ханыбызның образы берьяклырак кына язылган төсле тоелыр иде. Зур галим Г.Вернадский Монгол тарихын бик төпченеп өйрәнгән. Чыңгызханның фәнгә «Великие Ясы», ягъни «Ясак», дөресрәге — «Җасак» дип кереп калган законнар җыелмасыннан күп мисаллар китерә.

«Җасак»ның 156 нчы гамәлендә: «Әгәр ул кеше гадел, саф күңелле, зирәк акыллы икән, аның кайсы ырудан, кайсы нәселдән, кайсы катлаудан булуына карамыйча күтәрергә, ихтирам итәргә. Усалларны тыярга. Гаделлек сыйфаты җитмәүчеләр белән гомумән эш йөртмәскә!» — дип, балчык тактага мәңге сөртелмәслек итеп чукып язылган.

Илеңдә синең белән рәттән яшәгән милләтләргә ихтирам белән караш менә ничек була ул! Чын мәгънәсендә интернационализм шушылай, нәкъ Чыңгызхан әйткәнчә буладыр, шәт?

157 нче гамәл. Аның белән дә бик теләп таныштырам. «Беренче эшегез итеп бер-берегезне яратыгыз. Икенчесе — зина кылмагыз. Аннан ерак йөрегез. Урлашмагыз. Ялганчы шаһитлар була күрмәгез. Бер-берегезне чакмагыз, хыянәтчегә миһербан юк. Картларны һәм ярлы фәкыйрьләрне ихтирам итегез».

Күзләреңә ышанмыйча укырлык искиткеч мәгънәле, кешелекле сүзләр язылган бит әлеге гамәлләргә! Мондый тирән эчтәлекле, җылысы йөрәгеңә үтешле сүзләр, заманында без, коммунистлар, үз корылтайларыбызда дәррәү кул чабып кабул иткән «Коммунизм төзүчеләрнең мораль кодексы»нда да җитеп бетмиләр иде бугай. Моннан җиде йөз еллар элек язылган булуын искә алсак, бу язуларның әһәмияте ун тапкырларга арта.

Сан тәртибе билгесез икенче бер кызыл балчыктан койган пластинкага «...Ул барлык диннәрне дә бер дәрәҗәдә ихтирам итәргә, аларның берсенә дә аерым өстенлек күрсәтмәскә әмер бирә» дип язылган. «Ул»ның кем булуын, бөек император икәнен аңлау кыен түгел.

Чыңгызханның әлеге Законнар кодексы «Җасак»та халыкара хокук мәсьәләләре буенча ташка иңдергән фикерләргә шулай ук таң калырлык. «Фетнә, баш күтәрүчеләргә карата өндәмәләр, мөрәҗәгатьләр язарга туры килгәндә, аларны көч белән куркытмагыз, армиягезнең зур, кансыз булуы белән янамагыз. Минемчә, менә болай дип әйтү отышлырак булыр: «Әгәр сез ирекле рәвештә бирелсәгез, безнең тарафтан яхшы мөгамәлә тоярсыз. Җаныгыз тыныч булыр. Әгәр инде мөрәҗәгатебезне аяк астына салып таптап, каршылык күрсәтергә булсагыз, безнең тарафтан ни күрәсегезне кем белгән? Сезнең белән ниләр буласын, бәлкем, Мәңге Зәңгәр Күктәге Тәңре генә чамалый булыр. Әмма Тәңребез җирдә барган күп вакыйгаларга еш кына күз йома, колагын томалый, итәге белән битен яба. Димәк, һәркайсыбызга үз язмышыбызны үзебез хәл итү хәерле. Әмма алдан күрүчәнлек белән, аек, зирәк акыл белән».

«Җасак»ның сунарчылыкка кагылган өлешләре дә бик матур язылган. Алар әдәби әсәр итеп укырлык. «Монголлар, яуда йөрмәгән чакларында, һәр көн диярлек сунарчылык итәргә тиешләр. Бу һөнәр аларны чыныктыра, дөньяны танырга өйрәтә, миһербанлы итә. Урмандагы, таулардагы, даладагы кош-корт, кыргый җанварларга ихтирамлы булып калган хәлдә, һәр монгол үзенең улларын сунарчылыкка өйрәтсен, аның хәйләсен, алым-серләрен төшендерсен».

Монголларның Бөек Ханы үзе басып алган җирләрдә беренче эше итеп сәүдәне киң җәелдерергә тырышкан. Коммерция белән шөгыльләнү, төрле товарлар белән сәүдә итү сәүдәгәрләр өчен отышлы һәм куркынычсыз булырга тиеш. Халыкара сәүдә юлларында сәүдәгәрләрне тоткарлаучы, алыш-бирешне җәелдерүгә комачаулаучы бернинди пошлиналар алуны булдырмаска. Сиңа килгән сәүдәгәр алып килгән товарларын сатып бетерсен, синнән баеп китсен, бик теләп янәдән килсен. Сәүдәгәрләрне пиратлар, юлбасарлар таламасын өчен әһәмиятле сәүдә юлларында көнен-төнен махсус сак дружиналары, отрядлары йөреп торган.

Чыңгызхан биләмәләренә үз товарлары белән аяк баскан сәүдәгәрләр юлда талчыкмасыннар, ялыкмасыннар. Аларны олы юл чатларында кунакханәләрдә көткәннәр. Сәүдәне киң колач белән

җәелдерүне, — үзенең дәүләтен экономик яктан һәм культура өлкәсендә алга чыгаруда иң ышанычлы рычагларның берсе санаган Чыңгызхан.

Аның киңәшләрендә бүгенге заман күренекле икътисадчыларын да сискәндерердәй акыллы фикерләр бар. «Әгәр кем дә кем кредитка товар алып, бөлгенгә кала, ягъни банкротка чыга, шуннан янә кредит алып янә банкрот була, өченче тапкыр да кредит алып аякка баса алмаган бу ишәк үлем җәзасына хөкем ителергә тиеш». Бөек император моннан 777 еллар элек шулай уйлаган. Һәркемгә үзләрен сәүдә юлында сынап карарга ирек биргән. Безнең көннәрдә әллә Җир шары кызурак әйләнә башладымы, әллә үзебез ашыгыбрак яши башладыкмы, бүгенге кредиторлар банкротка чыгучыларны беренче уңышсызлыкларыннан соң ук үлем җәзасына тарта башладылар. Монысы инде бер дә хәерлегә түгел. Мәңге Зәңгәр Күктәге Тәңре дә бу хәлне бер дә килештермәс, хупламас, минемчә.

Ахирәт дустым Р.Фәхретдинов биргән китапларның иң кадерлесе — СССР Фәннәр академиясенең Көнчыгыш институты чыгарган елъязмалар җыентыгы (Мәскәү, 1952) — Рәшидеддиннең «Җамигъ әт-тәварих» булды. Урта гасырлар галиме Рәшидеддиннең башта үзебезнең татарларга карата әйткән сүзен китерим әле: «...Племя татар... Их имя издревле было известно в мире. В их природе преобладали ненависть, гнев и зависть. Если бы при наличии их многочисленности они имели единодушие друг с другом, а не вражду, то другие народы из китайцев и прочих, и вообще ни одна тварь не были бы в состоянии им противостоять». Менә белмәсәң бел, ишетмәсәң ишет, ике колагың тишек!

Афәрин бу Рәшидеддин! Холык-фигылебезне, яшәү рәвешебезне пәч иттереп өстенә бәреп әйтеп салган. Бер-беребезне күралмау, ямьсез көнчелек галәмәте безнең һәркайсыбызда бүген дә вагоны белән генә түгел, эшелоны белән. Без бу яман гадәтләребездән арынырга да бик омтылып тормыйбыз бугай. Шуңа күрә бер дигән дәүләтебезне жуйганбыз, шуңа күрә аны бүген дә аякка бастыра алмыйбыз. Мин кулланган китаплар рус телендә, исемнәр күрәләтә торып сәер яңгырыйлар. Мин аларны татар транскрипциясенә күчерергә мәҗбүрмен. Шул ук вакытта читкә дә артык тайпылып булмый.

Инде бер сүз кузгаткач, шунысын да әйтим. Чөнки җае чыкты. Юкса бу нәрсә мине бик күптәннән борчый, тәмам тынгылык бирми. Соңгы вакытта күп каләм осталарыбыз — язучылар, галимнәр, журналистлар — үткән тарихыбызга кагылышлы моңарчы архив киштәләрендә яткан кызыклы гына материалларны өстерәп чыгара башладылар. Кирәк нәрсә. Тарихың булмаса, андый халык та юк. Әмма бер нәрсәдә безгә бик сак булырга кирәк. Кем әйтмешли, авыз суыбызны корытып русларны ямьсез итеп күрсәтергә, үзебезне кызгандырырга тырышыпмы, Сөембикә ханбикәбезне Явыз Иванга коллыкка биреп җибәрүебез турында язарга яратабыз. Бу турыда әле күп халыклар белмиләрдер. Анысы безнең файдага. Берүк белә күрмәсеннәр. Әгәр белеп алсалармы?! Кайбер кайнар канлырак халыклар, әйтик, кавказлар, грузиннар, әрмәннәр, чеченнар йөзебезгә төкерүләре бар. Тарихта мондый хәлнең бүтән башка бер халыкта да булганы юк. Имеш, «Явыз Иван таләп итә» диген дә кулында нарасые булган ханбикәне тот та дошман кулына биреп җибәр. Башка сыешлы хәл түгел бу. Нүжәли шунда биленә кылыч таккан йөз-ике йөз татар егете булмады икән? Үлсәм үләм, җаным да, малым да жәл түгел, әмма кадерле ханбикәбезне ятлар кулына бирмим, дип, Дамаск корычыннан койган ут кылычларын кыннарыннан чыгарып, баш өстендә уйнатырдай егетләр? Ятларга түгел, иң якыныңа сөйләргә дә оят хәл бит бу! Әйтәм бит, бу турыда башка халыклар, Европа белеп алмасын. Аннары күзләребезне ачырмаслар. Үзебез һаман да суверен дәүләт төзибез дип йөрибез бит әле. Булганы булган инде. Барыбызга гыйбрәт булсын. Әмма бу турыда күкрәк сугып сөйләмик. Кулында нарасые булган ханбикәңне, ук та, җәя дә тартмый баскынчакларга биреп җибәрү безнең халыкны күтәрә торган «батырлык» түгел.

XIV гасырның танылган фарсы тарихчысы Рәшидеддин биргән мәгълүматлар Чыңгызхан империясе чорыннан иң сафлары, дөреслеккә якыннары, таушалмаганнары, телдән телгә күчеп йөрмәгәннәре.

Рәшидеддин Фазлуллаһ ибне Әбүл Хәйр әл-Хәмадани 645 (1247) елда Көнбатыш Иранның Хамадан каласында туа. Иран белән Монгол хөкемдарлары идарә иткән Хан сараеның баш табибы һәм вәзире була. «Елъязмалар тарихы»н, ягъни «Җамигъ әт-тәварих»не 1295–1304 елларда хакимлек иткән Бозан хан әмере белән язарга керешә. Аны 1304–1316 елларда Иран хакиме булган Улджейтү хан чорында да дәвам иткән.

Хан сарае кайда да интриганың, гайбәтчелекнең иң чәчәк аткан җире бит инде. Рәшидеддиннең дә көндәшләре, дошманнары җитәрлек булгандыр. Сарай тормышында булмыймы соң? Көннәрдән бер көнне Улджейтү хан кинәттән мәрхүм булып куя. Ә танылган галимебез — Хан сараеның баш табибы. Дошманнарына аннан канлы үч алырга җай чыга. Аны Улджейтү ханны агулап үтерүдә гаеплиләр. Хан сарайларында хөкем җәзалары да кырыс. Баш табибны үлем җәзасына хөкем итәләр, башын чабалар.

Шундый үкенечле үлем белән дөньядан киткән тарихчы- галим Әбүл Хәйр әл-Хәмадани Рәшидеддин үз заманының беренче укымышлыларыннан булгандыр. Бөек император Чыңгызхан мәрхүм булганнан соң, тәхеткә аның өченче улы Үгәдәйнең утырганын беләбез инде. Үгәдәй хан чорында да төп ставкадан, башкала Каракырымнан Иранга бер-бер артлы илчеләр, сәүдәгәрләр килеп-

китеп кенә торганнар. Хан сараеның иң затлы киштәләрендә генә сакланган «Алтан дептәр»гә ул Монгол дәүләтенә кагылышлы барча мәгълүматларны шул кешеләр авызыннан чәчми-түкми язып барган. Иран хакимияте башында Чыңгыз династиясе вәкилләре утырганлыктан, алар да «Алтан дептәр»гә вакыйгаларны эмоцияләрсез, арттыруларсыз, дөп-дөресләрен генә теркәп баруны таләп иткәннәр. Кыскасы, Рәшидеддин Фазлуллаһ ибне Әбүл Хәйр әл-Хәмадани хәзрәтләре безгә Көнчыгыш Урта гасырлар тарихы буенча кыйммәте белән үзенә тиңдәше булмаган китап язып калдырган. Бүгенге көндә бөтен дөнья тарих фәне, культурасы әлеге хезмәтләре өчен мәңге, мәңге бурычлы бу бөек шәхес алдында.

Язмамның башына ук «Мин — Чыңгыз ыруыннан» дип куйганыем. Ә кем ыруыннан булыйк соң? Чөнки ул үзе чеп-чи татар ыруыннан. Чыңгызның әтисе Исүгәй татар булмыйча кем булсын? Һәрхәлдә, төркиләрдән. Тарих үзе таныган «Великое переселение народов» чорында әллә нинди үзгәрешләр, исем-ат алмашлар булып торган. Кайбер ырулар, кабиләләр бөтенләй юкка чыккан, вакыт комы астында калган. Икенчеләре терерәк булып өскә калыкканнар. Телгә кергән «татар-монгол явы» дигән төшенчәгә дә каршы әле мин. Монголлар әле бүген дә чак-чак кына миллионнан артып киләләр. Монгол биләмәләре аша холера да узмады, алар өстенә хлорофос та сипмәделәр. Ул якларда зур сугышлар, кырылышлар да булганы юк. Ә Чыңгызхан, Батыйхан заманында бөтен дөньяны тетрәтерлек гаскәр каян килде икән соң? Бу сорау бик еш килә минем башыма.

Боларга өстәп тагын шуны әйтү дә урынлы булыр. Чыңгызның беренче хатыны Бортедан соң соңгы икесе Есулун белән Есукай саф татар кызлары булалар. Яһүдләр әйтмешли, еврейкадан тик еврейлар гына туалар. Татар кызларыннан да тик татарлар гына туа. Уңышлы узган яудан соң Чыңгыз тагын бер татар кызын әсир итә. Аның исеме тарихта билгесез. Әмма аннан Чыңгызханның иң төпчеге Чаган туа. Исеме үк саф татарча бит. Чаган! Чаганнан ясаган балта сабы сөяк кебек нык, мәңгелек була.

Сүземне очлап шуны әйтәсем килә Чыңгыз үзе дә төркиләр ыруыннан. Тәмүҗин монгол исеме түгел. Мин дә үземне Чыңгыз ыруыннан дип таныйм. Кайберәүләрнең моңа йоны күперсә, ачуы кабарса, исем китә бик! Әгәр инде берәрсе хуплый икән, сөенече-шатлыгы — уртак.

Күңелгә әледән-әле Франция императоры Бонапарт Наполеонның «ни кызганыч, миңа Чыңгызханга тигән бәхет тәтемәде» дигән сүзләре килә. Бәхет ул күп ботаклы татлы җимеш агачы сымаграк. Адәм баласына шуның кайсы ботагына утырып тирбәлү иплерәк, ышанычлырак икән соң? Әйе, бәхет дигән төшенчә бик җәенке. Кайсы чын бәхет, кайсысы ачы язмыш икәнен дә тиз генә аңламассың. Әмма Мәңге Зәңгәр Күктәге Тәңре үзенең яраткан улы Чыңгызханга «Бәхет» дигән зур, татлы бәлешнең иң зур кисәкләрен, хәтта иң тәмле җирен — төбен дә бер дә күпсенми каерып кисеп биргән. Инде бер сүз алгач, хөрмәтле укучыларыма менә шул турыда да, акка кара белән язып, кулдан килгәнчә эзлекле итеп сөйләп бирәсем килде. Чыңгызхан безнең үз бабабыз ул. Аның ыруыннан булуыбыз белән шатланып, горурланып яшәргә кирәк.

Әсәрне иң мажор ноталарда тәмамлыйсым килә. Тарих фәннәре докторы, танылган галим М.А.Водолагин безнең халык турында әнә нәрсә дигән бит. Алдарак Әбүл Хәйр әл-Хәмадани Рәшидеддин сүзләрен китергәнием. Бу юлы исә, аеруча рус телле кардәшләребезне искә алып, бу акыллы галим әйткән сүзләрнең эмоциональ көчен югалтмас өчен, мин аны татарчага тәрҗемә итми бирәм. «Татары?! О, это могучий народ, им только дай возможность, сразу активизируют свою деятельность — и весь мир в цепких объятиях, не приди Ульянов во время, опаздай хотя бы на 30 лет, вся власть уже перешла бы в руки трехсот непьющих миллионеров татарских. Ведь почти все — и золото, и уральские руды, и нефть, и камни — все было уже перешло в их руки. Тазиева и Азимовы, Рамиева и Шакуровы, Скуратовы и Строгановы... Урал, Кавказ, Сибирь... кони, хлеб и недра — все-все! Опасно это!!! Акчурины, Ишмуратовы, Морозовы, Дягилевы!!! Страшно это! А какая идеология?! Зеленая! Скромность, образовательность, кротость, величие... И в то же время храбрость, неустрашимость, мужество, достоинство, богатство, сила, могущество, верность и чистота!»

Хөрмәтлеләрем, кайсы халыкка карата мондый зурлау, ихтирам сүзләре ишеткәнегез бар? Рәсәйдә иҗтимагый тормыш бүген бөтенләй башка ерганак яра. Теге чакта бөтен эшне Ульянов бозып куйса, хәзергә андыйлар күренми төсле. Россия Президенты Владимир Путин да безне ихтирам итә. Шулай булмаса, Рәсәй патшасы башы белән, мәйдан уртасына чыгып, катыктан көмеш тәңкә эзләмәс иде. Татарчасын кыенлык белән генә әйтсә дә, Тукаебызны да татарча искә алды.

Яңа Рәмиевләр, Әҗемовлар, Шәкүровлар бармы соң арабызда? Нигә булмасын! Берән-сәрән генә күренә башладылар түгелме соң? Күренү белән генәмени. Дәүләтчелегебезне торгызуга салырга тиешләр алар бар көчләрен. Суверен дәүләт булып яшәсәк соң, кемгә зыяныбыз тияр? Җир өстенә кояш та көн саен чыгып тормый. Күптәнге хыялыбызны нәкъ менә тәвәккәлли торган чорлар түгелме дим мин?!

Март, 2002

Алланың — каһәре, халкымның ләгънәте төшсен...

Ни сәнгатьчә эшләнеше, ни тарихи яктан ике тиенлек тә кыйммәте булмаган бу әшәке фильм Үзәк телевидениедән күрсәтелә башлауга, редакциябезгә уннарча һәм уннарча рәнҗү хатлары килде. Байтагы газета битләрендә урын тапты. Бу хатларның авторлары белән никадәр генә теләктәш булсам да, үзем исә каләм алырга ашыкмадым. Гомердә кичерелмәслек бу явызлыкка, бу хыянәткә каршы, бәлкем, безнең белән бер һаваны сулап, бер коедан су эчеп, бер дигән кызларыбызны киленлеккә алып, бер дигән улларыбызны кияүләре иткән башка милләт вәкилләре чәчрәп чыгарлармы дип өмет иткән идем. «Зур кыенлыклар аша, түземлек белән мөстәкыйльлек өчен көрәшкән татар халкына нигә мондый нахак яла ягасыз? Нигә булышасыз? Шушы халык белән ничәмә буыннар дус һәм тату яшибез. Алардан мыскал да җәбер-золым күргәнебез юк. Һәрчакны кайгыбыз уртак, шатлыгыбыз бер булды. Син, Чигринов, үзең бик тар күңелле, пычрак җанлы адәм икәнсең» дип язып чыгарлармы дип бик көттем. Үкенеч, хет башыңны ташка ор, андыйлар булмады, ахры.

Үземне исә һаман тыя тордым. Әйтсәң, телең каты, бик зәһәр әйтәсең, ашыкма, дидем. Шул сәгатендә үк чыгып амбразурага ташланырдай ярсыган йөрәкнең бераз басыла төшүен көттем. Шунысы да бар: дошманнар, мөртәт-мәлгуньнәр яккан авыр ялаларны кайнарлык белән генә хәл итеп булса икән...

Әйтсәм әйтим, сүз җәйге айларда Үзәк телевидениедән күрсәтелгән Белоруссиядә яшәүче Иван Чигринов дигән бер мөртәтнең «Бүдәнә сыкравы» («Плач перепелки») дигән романы буенча әвәләнгән ун серияле фильм турында барачак. Әлеге фильмда Бөек Ватан сугышының беренче көннәрендә үк коралын ташлап дошман тылында калган бер егет образы бар. Исеме — Рәхим, янәсе. Автор аны турыдан-туры татар дип әйтми. Әмма туган җире Идел аръягында. Исеме дә Рәхим булгач, Идел аръягында тагын кем бар инде, без татарлар булмыйча?! Шушы Рәхимебез берничә йөз миллион тамашачысы булган Үзәк телевидение экранында, төнлә өенә бәреп кереп, идәнгә сузып салып, каравыл кычкырта-кычкырта бер белорус хатынын көчли. Күлмәкләрен шатырдатып ерта, күкрәкләрен ача. Шушы коточкыч хәлне, тарихта булмаган вәхшилекне әлеге бичара ананың дүрт нарасый баласы мич башыннан карап торалар.

Шушылардан соң без татарларга башка халыклар тарафыннан нинди мөгамәлә булыр дип көтәсез? Шушы вәхшилекне күреп торган нәни тамашачылар безгә ничек карар? Ябылып бетмәгән яраңа тагын тоз салсам, кичер халкым. Мин башлаган сүз түгел. Әмма турысын җавап бир. Син соң шундый вәхшиләр үстердеңмени? Ил өстенә кара болыт булып фашистлар ябырылганда, яу кырына әнә шундый вәхшиләр озаттыңмыни? Кайнар яшьләреңне түгеп. Юк, юк, һәм тагын бер кат юк. Синең исемеңнән, бер гөнаһсызга шундый кара яла ягылган халкым, мин моның нәкъ киресен расларга җыенам.

Әйе, халкыбыз, язмышыбыз шундый сынау алдында тора, ярсып кына эш чыкмый. Кулымда булган мәгълүматларны ашыкмый гына, салмак кына бер мәрҗәнгә тезмәк булам. Намусы качмаган, йөзендә иманы булган бәндәләр үз бәяләрен белсеннәр. Мин өзелеп сөйгән, шуның бер газиз баласы булган сөекле Татарстаным җиренә Бөек Ватан сугышы чорында бер бомба да төшмәде, бер снаряд та шартламады. Әмма аның ярсу йөрәкле, арыслардай гайрәтле уллары, сугыш башлану чаңы авыл башында яңгырауга, сөекле ярларын, газиз балаларын калдырып, дошманга каршы рәхимсез яуга чыгып киттеләр. Аларның күбесе яу кырыннан кире кайтмадылар. Чит җирләрдә мәңгегә ятып калдылар. Яу батырларының күбесе хәбәрсез югалды. Аларын исә хәтта бүген, сугыш беткәнгә 46 ел узгач та көтәләр.

Кызып эш чыкмас, салмак кына хикәяләргә тырышам. Бер җәйне миңа Мәскәүдән зур кунак килде. Берничә китабымны русчага тәрҗемә кылган дустым, яшьтәшем, рус язучысы Н.А.Ивановны дәшкән идем. Җәйнең чүт-чүт килеп кошлар сайраудан туймаган бик матур чагы иде. Урманнарга да чыктык, «безгә балык эләкми» булса да, кармаклар алып, күлгә дә төшеп утырдык.

Повестьларымны русчага тәрҗемә кылганда, Николай Александрович миннән: «Тастымал», «билбау», «кыстыбый», «пәрәмәч», «өчпочмак», «бавырсак» нәрсә була?» — дип аптырата. Чөнки болар барысы да саф милли сүзләр, русчага тәрҗемәсе юк. Аларны мин текстта шул килеш калдыруны таләп итәм. Кайсын эш коралы, кайсын ашамлык ризык дип, аска атамалар биреп кенә котылабыз. Инде миңа махсус кунакка килгәч, шушы эш коралларының тотардаен тоттырып, ашардаен ашатып караттым. «Сөзмә» дигән затлы ашамлыгыбыз да бар бит әле безнең. Менә анысын ничек татытып карарга? Сыерым юк. Кызганыч һәм бик үкенеч. Булырга тиеш. Җитәр башкалар сауган сөтне генә чөмереп яшәргә. Монысы барыбызга да кагыла. «Уңыш» колхозының ул чактагы парторгы Фәхразый Шәйхеразиевичка гозеремне әйттем. Килегез генә, ди. Теләсә кайсы йортка алып кереп сыйлыйм мин сезне сөзмә белән, ди.

Башкалабыздан килгән кадерле кунагыма татар авылларының ямьлелеген, чисталыгын, пакьлеген, төзеклеген, гүзәллеген дә күрсәтәсем килгән иде. Партиянең дә яхшы чаклары бар иде, КПССның шәһәр комитеты яңа «Волга»сын бирде. Без Зәй-Каратайга киттек. Юлда ике-өч җирдә туктап, җир

куенныннан бәргән саф чишмәләрнең суларын эчтек, урманга кереп мәтрүшкәләр җыйдык. Алда без киләсе авыл күренде. Инде Зәй-Каратайга кердек дигәндә генә коры елга аша күпергә юлыктык. Кызганычка каршы, ул ватык. Моннан алда гына ишеп яңгырлар явып узган иде. Коры елга аша чыпчыкка да кендектән генә су саркый. Шофер егетебез шуның аша выж итеп кенә чыгып китмәкче иде дә, булмады. Арт күчәре белән сазга утырды. Азаплануын әллә ни азапланмадык та. Арттан килеп эттек тә, чыгардык та. Кунагым, алай да көрсенеп:

— Шушы күперне дә төзәтмәгәннәр, — диде.

Аның бу сүзләре йөрәгемә тисә дә дәшмәдем. И-и, аңа китсә, тормышыбызда андый гына китек яклар күп инде алар. Барысына да каян өлгереп бетәсең? Чыктык бит әле. Өс-башларыбызны кагып, кулларыбызны юып, янәдән машинага кереп утырдык.

Фәхразый Шәйхеразиевич Бәдертдинов безне чыннан да бик зурлап каршы алды. Бер гаиләгә кереп, кызыл чөгендер тураган татлы катык, икенчесенә кереп, салкын каймак салган сөзмә белән сыйланып чыктык. Ярар, бер кат ашагач-эчкәч, күңелләр дә күтәрелеп киткәч, парторг безне авылның Бөек Ватан сугышында һәлак булган уллары истәлегенә куелган һәйкәл каршына алып килде. Бирегә өч йөз сиксәнләп батырның исеме теркәлгән. Әйтергә генә ансат, өч йөз сиксән лачын бит!

Куен дәфтәремне чыгардым. Яу кырыннан Әюпов Әбүталип агайның дүрт улы, дүрт баһадиры кайтмаган: Әхмәди, Мөхәммәди, Гатаулла һәм Мөхәммәт.

Әкбиров Мөхәммәтҗан агайның өч бөркете: Камил, Мөэминҗан һәм Шәрифҗан.

Батталов Галиулла абзый ике улын, ике күз нурын югалткан: Кәлимулла белән Сәмигулла.

Вафин Ситдыйк агайның яу кырында дүрт улы һәлак булган: Хәниф, Садыйк, Хәбир һәм Кәрим.

Галиев Әхмәтгәрәй абзыйның сугыш кырында дүрт улы ятып калган: Мөэминҗан, Миңлегәрәй, Сабиржан һәм Сәетгәрәй.

Динекәев Хәбибулланың өч улы ят җирләрдә мәңгегә ятып калганнар: Хәмидулла, Хәйрулла, Нәбиулла.

Закиров Закир абзый өч улын югалткан: Сабиржан, Шакиржан һәм Моталлап.

Мортаза абзый фронтка бер-бер артлы алты улын озаткан, берсе дә исән кайтмаган: Өмет-Гали, Талип, Фатих, Фәхри-Ислам, Шәех-Ислам, Җәббар һәм Мостафа.

Берүк ялыга күрмә, укучым. Мин алфавит буенча төшәм. Илебезнең азатлыгы өчен корбан булганнарны искә алганда ялыгу килешмәс. Нуретдинов Сәетгәрәй чулак калса да, туган нигезенә кайта алган. Дошман пулясы, уң учыннан кереп, бармакларын чәрдәкләп чыккан. Ул кулы белән күлмәк сәдәфен дә төймәли алмый. Хәзер аңа 87 яшь. Ә менә әтиләре артыннан яуга киткән дүрт улы батырларча һәлак булганнар.

1901 елгы Факиһә әбинең сугышта өч абыйсы, өч улы һәм газиз ире Хасылов Фатих абзый һәлак булганнар.

Белмим, кайнар күз яшен түгеп Факиһә апа сугышка озаткан шушы җиде ирнең кайсы коралын ташлап, бандитлык юлына басар, тол хатыннарны көчли башлар икән? Моның булуы мөмкин түгел.

Чигринов дигән мөртәт — чын провокатор! Кемнәргәдер сатылган җан ул...

Һәйкәл катында байтак кына торганнан соң, Мәскәүдән килгән кунагыма әйтә куйдым:

— Әгәр шушы лачыннарның барысы да яу кырыннан исән-имин кайткан булсалармы?! Күперне төзәтү генә түгел, без киләсе юлга яшел келәм түшәп куйган булырлар иде, — дидем.

Иван Чигринов дигән мәлгуньнең романындагы Рәхим сугышның беренче көннәрендә үк чик буена ничек эләккәндер? Анысын ул әйтеп тормый. Ә мин «Бөек Ватан сугышы тарихы» дигән күп томлы китапны ачтым. Монда акка кара белән язылган: «Чик сакчылары булып хезмәт итүче татар егетләре Хәким Маннанов белән Шәмси Фәрдиев 1941 елның дәһшәтле 22 июнь иртәсен Белоруссия чигендә каршы алалар. Алар өстенә саранча өере булып ябырылган дошман явын берничә тәүлек буена Брестка уздырмый торалар. Дошман аларны әйләнеп кенә уза».

Ә Брестта аларны кем көтә, кем ут белән каршылый, диегез? Тиңдәшсез батырлыгы белән бөтен дөньяны таң калдырган Питрәч районында туып үскән татар егете Петр Михайлович Гаврилов лабаса. Бу каһарман башта үзенең 44 нче укчы полкы белән Брест крепостеның Төньяк утрау дип аталган өлешен саклый. Аның полкындагы татар егете лейтенант Ибраһимов кыюлыгы, батырлыгы белән күпләрне таң калдырып, сугышның беренче көннәрендә үк батырларча һәлак була. Майор Петр Гаврилов дошманга крепостьны 23 июльгә кадәр бирми. Бу бит сугыш башланганга 32 көн дигән сүз. Дошманның алдынгы частьлары, Брестны әйләнеп узып, Минскины алалар, Киевне камыйлар. Крепость комендантын дошман ныклы яралы һәм аңсыз хәлендә генә кулга төшерә, әсир итә.

Әмма аның тиңдәшсез батырлыгын искә алып, немецлар аңа әсирлектә дә ихтирам белән карыйлар, үзләренең полководецларына үрнәк итеп күрсәтәләр. «Татар халкы улы» дигән исемгә гомере буе мыскал тап төшермәгән бу каһарман үз үлеме белән 1977 елның гыйнвар аенда гына мәрхүм булды.

Узган сугышта совет халкы егерме миллионлап кешесен югалтты, дип укый идек. Яңа исәпләүләр буенча кырык миллион чамасы икән. Сугыш кырында башын салган татар егетләрен, исемсез геройларыбызны кем генә санап бетерер! Туган илгә эчкерсез бирелгәнлекләре, чын мәгънәсендә

каһарман булулары белән бөтен дөньяны таң калдырган улларыбызның исемнәрен атап кына чыкканда да калын томнар язарга кирәк булыр иде. 1945 елның апрель урталарында Гитлерның резиденциясен — Империя канцеляриясен подполковник Исхак Идрисович Гумеров җитәкчелегендәге 1050 нче укчы полк солдатлары штурмлый башлый. Чөнки бу полк Берлинга беренчеләрдән булып бәреп керә. Башта ул штурм белән Герлицк һәм Ангаль тимер юл вокзалларын, Главпочтамт һәм Гестапо йортын ала. Аннары Империя канцеляриясен штурмларга керешә. Әле 1 Май көнне үк Гумеров солдатларына кулларына ак флаг тоткан парламентерлар күренә. Совет подполковнигы Гумеров каршына немец генералы Г.Кребсны китереп бастыралар. И.Гумеров немец генералының документларын тикшереп, нинди ният белән йөрүен белгәч, аны 8 нче гвардия армиясе командиры генерал В.И.Чуйков катына озата.

Рейхстаг түбәсенә байрак кадарга тиешле кешеләрнең исемнәре Берлинны камый башлау белән үк билгеле була. Мөхтәрәм Егоров белән Кантариянең биредә мыскал да гөнаһлары юк. Өлешләренә чыккан көмешләре. Бәхет эше. Бәхет дигән нәрсә хәтта биредә, сугыш, кан, атлаган саен үлем, корбаннар булып торган җирдә дә буталган, тормышка, кешеләр язмышына үз төзәтмәләрен керткән.

Рейхстаг башына флагны ни өчен соң Егоров белән Кантария кадарга тиеш булган? Бик аңлашыла, берсе — рус халкы вәкиле. Ватан сугышы чорында иң күп җәбер-золым күргән, корбаннар биргән халык. Икенчесе — грузин егете. Чөнки Сталин да грузин. Шундый мөмкинлек чыгып торганда ничек инде үз халкың вәкилен бөтен дөньяга танытмыйсың? Әйтәм ич, мөхтәрәм Егоров белән Кантария агайларның биредә шәхси гөнаһлары мыскал да юк. Алар солдатлар. Ил кушкач, Сталин әмер биргәч, кешеләр Рейхстаг башына гына түгел, якты дөнья белән мәңгегә саубуллашып тирән шахталарга да төшкәннәр, юеш зинданнарда черегәннәр.

Әмма фашистлар Рейхстагы башына Кызыл байракны беренче булып татар егете Сәгыйть Заһитов кадый бит. Шушы каһарман түбә башында булып, байракны кадап төшкәннән соң, командование куполны фашистлардан чистартырга тагын бер батальон җибәрә. Ә Егоров белән Кантария үз сәгатьләре җиткәнне көтеп, әле һаман да подвалда утырып торалар. Әгәр алар белән ул-бу хәл була калса, «Корыч бабай» гаеплеләрнең җиде кат тиресен тунаячак. Әлеге автоматчылар куполны фашистлардан тәмам чистартып чыккач кына, Егоров һәм Кантария кулына байрак тоттыралар. Ә Рейхстаг түбәсенә беренче булып менеп басучы, Җиңү байрагын кадаучы татар егете Сәгыйть Заһитов. Бу — тарихи факт!

Бу юлларны мин һавадан алып түгел, ә ярты гомерен СССР Оборона министрлыгы архивларында казынуга багышлаган, халкыбыз язмышы белән бәйле күп яшерен материалларны яктыга казып чыгарган язучыбыз Шамил Рәкыйповның газета-журналларыбызда даими басылып килгән мәкаләләренә нигезләп һәм таянып яздым.

Ә сез Рейхстаг стеналарында бүгенге көннәргә тикле сакланган язмаларга игътибар итегез. «Здесь были волжские соколы. В Берлин их привел Насиров». «Вагапов — Казань», «Халиков — Казань». «Майор Хамидуллин, майор Малышкин — Казань». «Магуба Сыртланова, летчица — Казань». «Халим Яхин из Чистополя». «Казанская татарка приехала сюда с боями. Врач гвардейского полка Р.Ш.Насирова».

Бөек Ватан сугышы чорында Татарстан фронтка 560 мең иң булган, иң уңган, иң сәләтле улларын һәм кызларын озата. (Гыйльманов З.И. Татарстан хезмәт ияләре Бөек Ватан сугышы фронтларында. — Татар. кит. нәшр., 1981. — 22–23 б.)

Минем өемнән күп булса унбиш чакрымнарда Сугышлы дигән авыл бар. Бу авылда Советлар Союзы Герое Александр Матросов батырлыгын кабатлаган, үз гәүдәсе белән дошман утын каплаган Газинур Гафиятуллин туган. Бу каһарман Сугышлы авылыннан сугышка 1941 елның июнь ахырында чыгып китә. 1944 елның 3 июлендә гәүдәсе белән дошман амбразурасына ташлана. Үзен корбан итеп полкташларына алга юл ача. Тукаебыз әйткәнчә, без тыныч тормышта аттан артык эшлибез, яуга чыксак, арысланнан көчлебез. Халкыбыз әнә нинди уллар үстергән! Чигринов дигән кара эчле бәндә нык ялгыша.

Менә Бөек Ватан сугышы чорында үз гәүдәләре белән дошман амбразурасына ташланучы батырларның исемнәре: Александр Матросов, Газинур Гафиятуллин, Хафиз Зарипов, Алексей Исаев, Нух Идрисов, Николай Липатов, Абдулла Сәлимов, Мингали Гобәйдуллин, Арсений Карташов, Мансур Галиуллин, Сәләхетдин Вәлиуллин, Әхмәт Мөхәммәтов, Афанасий Панарин.

Игътибар итегез, саналган унөч каһарман арасында тугызы татар егетләре. Шушы халыкка, шундый егетләр үстергән газиз аналар исеменә шундый пычрак яланы ничек ягарга мөмкин? Баксаң, Александр Матросов үзе дә татар егете икән бит. Тиңдәшсез батырлыгы тарих битләренә алтын хәрефләр белән язылган бу егетнең чын исеме — Минсәгыйт Шакиржанов. Яшьли ятим калып балалар йортында тәрбияләнгән татар малаена берәү дә Минсәгыйт дип дәшеп тормаган. Сашка дигәннәр. Димәк, Александр.

Менә шулай, Ваня әфәнде Чигринов. Безнең халык белән авыз чайкама. Синең чын язучы булуыңа да шигем зур әле минем. Чөнки син язучылар арасында яшәгән, әмма беркая да язылмаган бик изге бер

әхлакый канунны бозгансың. Дөрес, тискәре персонажларсыз әсәрләр булмый диярлек. Күп әсәрләребезне яхшылык белән явызлык, тугрылык белән хыянәт, уңай персонажлар белән тискәре персонажларның тартышуына, көрәшенә корабыз. Әсәреңә тискәре образларны теләсәң күпме кертә. Анысы синең эш. Әмма үз халкыңнан, үз милләтеңнән. Башка милләтләр язмышына тыгылма. Без күп милләтле илдә яшибез. Башка милләт вәкилләрен дә әсәргә кертергә туры килә. Чын егет, киң күңелле ир икәнсең, син аларны тик уңай образ итеп кенә керт. Максат милләтләр арасында дуслык, татулык, туганлык тәрбияләү ләбаса!

Әнә Миклухо-Маклай, Фенимор Купер, Майн Рид, Джек Лондон, Максим Горький әсәрләрен укып кара. Әсәрләренә керткән башка милләт вәкилләренә карата аларның китапларында никадәр ихтирам, никадәр мәхәббәт! Әле мин санаган олуг язучыларның әсәрләрен укыган малайларның шунда ук папуас яисә һинд кабиләләренең юлбашчылары буласылары килә башлый. Чөнки бу мөхтәрәмнәр аларны гашыйк булырлык матур итеп тасвирлыйлар. Чөнки алар югары культурага ия! Ә бу дефицит сыйфат синдә юк, күрәсең.

Моннан бер еллар чамасы гына элек мин яңа әсәр тәмамлаган идем. Повестька исемне «Күз керфекләрем талганчы...» дип куйдым. Тәңрем кушкандырмы, шушындый хәлләр килеп чыгасын күңелем сизгәндерме, шушы әсәремә белорус агае Рыгор образын керттем. Вакыйга фронтта бара. Рыгор агайга кырык ике яшь, татар егете Зөфәргә әле егерме генә. Болар икесе дә укытучылар. Болар арасында искитмәле дуслык мөнәсәбәтләре урнаша. Мин тудырган белорус агае Рыгор образы татар егете Зөфәрнекенә караганда күп отышлы, күп уңышлырак. Чөнки мин моңа бөтен көчемне салдым, әсәремә кергән башка милләт образын матуррак, ягымлырак, кешелеклерәк итәргә тырыштым. Рыгор агай әлеге татар егетен аталарча ярату, сөю белән ярата башлый. Алар бер кәтилүктән ашыйлар, бер окопта йоклыйлар. Алай гынамы? Рыгор агай, Зөфәрне үз гәүдәсе белән каплап, дошман пуляларыннан саклый. Әйе, безнең халык һәрчак таш белән атканнарга аш белән атып яшәгән. Рыгор белән Зөфәр хезмәт иткән частька төнлә Кырым ярына десант белән төшәргә дигән әмер килә. Шунда Рыгор агай әйтә Зөфәргә, улым, утка керәбез. Мин аннан исән чыкмам инде. Күңелем шулай сизенә, ди. Фронтовиклар расларлар, фронтта андый хәлләр күп булган. Үтенечем сиңа шул, ди Рыгор агай, сугыштан соң минем гаиләмне эзләп тап. Син исән калачаксың. Белоруссиядә, фәлән авылда хатыным белән кызым калды. Минекеләрне ташлый күрмә. Ошатсаң, өйлән кызыма, хур булмассың, ди. Зөфәргә кул сәгатен салып тоттыра. Шушы сәгатьне күрсәтсәң, безнең авылда сине һәркем үз итәр.

Болай дигәч, хәзер Рыгор агайны Зөфәр сакларга керешә. Атака вакытында да аны күзеннән югалтмаска тырыша. Алай да Сапун тавын штурмлаган чакта Рыгор агай һәлак була. Зөфәр аны, сугыш кыршынан табып алып, үзе җирли. Белоруссияне азат итүдә катнаша. Яралана. Госпитальдән чыккач, Рыгор агай авылына китә. Барса, янып көл булган авыл. Тик моржалар гына калкып торалар. Рыгор агай исемен әйткәч, халык аны тиз үз итә. Рыгор агайның кызы Олесяны Германиягә коллыкка алып китәләр. Кызның әнисе, Рыгор агайның хатыны Макриддина түтәй кайгысыннан акылыннан яза. Сәгатьне дә танымый, Зөфәрнең сүзләрен дә аңламый. Урманга чыгып югалмасын, мина-мазарга басып шартлый күрмәсен дип, авылдашлары Макриддина түтәйне бер землянкага ябып, чылбыр белән бәйләп тоталар.

Минем героем Зөфәр, капитан дәрәҗәсе алып, Германиягә кадәр барып җитә. Сугыш беткәч, аларның ротасын бер немец алпавыты утарына ялга куялар. Аның фермасында Белоруссиядән коллыкка куып китерелгән белорус кызлары эшлиләр...

Ярар, бөтен әсәрне сөйләп бетермим инде, укучыга кызыгы да калмас. Әмма икмәк тотып әйтәм, Рыгор агай образы Зөфәрнекеннән күп матур, сөйкемле чыкты.

Чөнки мин шундый максат куйган идем, халыклар арасындагы дуслыкны ныгытуга да хезмәт итсен, дидем. Әйе, без — таш белән атучыларга аш белән атучылар.

Хәер, Иван Чигринов бу әсәрендә үз халкын белорусларны да дошманга бил бөккән мескен халык итеп күрсәтә. Һәм ул әлеге күп серияле кинода шулай итеп күрсәтелә дә. Хәтерегездәме, әле беренче серия башында ук колхоз председателе Чубарь атлы бер агай сугыш булып үткән арыш кырында, янган танк янында бер винтовка табып ала. Аны, штыгын җиргә каратып, иңбашына элде. Шул кыяфәттә ул ун серия буенча экранда күренгәләде. Әмма мылтыгын иңбашыннан алып, һич югында, һавага төбәп тә атмады. «Это было под Ровно», «Подпольный обком действует», «В лесах Белоруссии», «Константин Заслонов» дигән китаплар, кинолар аша, партизан шагыйребез Зәки Нури истәлекләре буенча без белорус халкын немец-фашист коллыгына каршы бердәм булып көрәшкә күтәрелгән батыр халык итеп белә идек. Ә биредә партизаннар хәрәкәтенең исе дә юк. Райком секретаре дигән бер мыеклы адәм, өстенә озын итәкле чикмән киеп, теге гаиләгә кереп ашап, монысына кереп көмешкә эчеп йөрүен йөри. Әмма аның отряды да, чурты да юк. Ә бит кайдадыр ераста канлы сугыш бара, илнең язмышы хәл ителә. Тышта инде декабрь. Дошман Мәскәүне камарга җыена. Ә боларның эше рәхәт. Ашарга да, эчәргә дә бар. Йорт аралаш япь-яшь тол хатыннар. Әйе, бу пычрак әсәрдә белорус халкы үзе дә әнә шулай мыскыллап күрсәтелә. Иван Чигриновның пүчтәк бер җан булуы әле бер хәл. Кемнәргәдер

шушы әсәрне күреп алып кино төшерү дә кирәк булган. Шушы катлаулы, милләтләр арасында ызгышлар чыгып торган көннәрдә бит.

Халкыбызның горурлыгы, аның чын улы, шагыйребез Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренең батырлыгына дөнья тан кала. Дошман алдында тез чүкмәгәч, унберенең дә башларын чабалар. Бөек Ватан сугышы тарихында бердәнбер очрак. Маңгаема борчак-борчак тирләр чыгарып уйланам. Җәлилчеләрнең бу гамәле Батырлык дигән төшенчәгә моңарчы күрелмәгән төсмерләр өсти. Аны поляр төн күгендә балкыган төньяк балкышыдай балкыта.

Сугыш башлануга, сентябрьдә үк Мәскәүдән Чистайга язучылар М.Исаковский, Н.Асеев, В.Билль-Белоцерковский, К.Паустовский, Н.Чертова, Д.Бедный, В.Бонч-Бруевич, В.Лебедев-Кумач, М.Лозинский, С.Маршак, И.Марчинкявичус, С.Мстиславский, А.Ахматова, Б.Лавренев, А.Толстой, А.Твардовский килеп төшәләр.

18 ноябрь көнне Чистайга тагын 61 язучы килә. (Чистопольские страницы. Таткнигоиздат, 1987.) Бу юлы алар арасында Б.Пастернак, Р.Розенталь, К.Федин да бар. Сез шунысына да игътибар итегез: Чистайга эвакуациягә килүчеләрнең беренче партиясендә үк белорус шагыйрьләре Янка Купала белән Ярослав Галан да бар. Имәндә икән чикләвек диярсең шул. Туган җирләренә дошман бәреп кергәндә, нигезләрен пыран-заран китергәндә, нигә алар кулларына корал алып көрәшкә чыкмадылар икән? Саулыклары белән комиссиядән уза алмаганнардыр, дисезме? Партизан булып дошманга каршы сугышу өчен комиссия торасы юк. Белорус язучылары сугыш үткәнне, еллар тынычланганны көтәргә Чистайга киләләр, иң авыр минутларда татар халкы канат астына сыеналар. Ә татар язучылары Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Гадел Кутуй, Фатих Кәрим, Нур Баян һәм тагын иллеләп лачын үз теләкләре белән фронтка чыгып китәләр. Гажәп инде безнең халык...

Инде бер сүз кузгаткач, шуны да әйтим. Руслар Марина Цветаева диләр дә ah итәләр. Әллә юри инде. Язган шигырьләрен кат-кат укып карыйм, мин ah итмим. Хәтта шикләнебрәк карыйм. Гомере бит, бичараның, шуның белән тәмам: үз-үзенә кул сала. Шуның сәбәбен кайлардан гына эзләмиләр. Бу турыда әдәбиятта йөзләрчә версияләр, имеш-мимешләр йөри. Минем үз версиям бар һәм иң дөресе минеке булырга тиеш. Безнең халык бу маржага нинди зыян эшләгәндер, безнең тарафтан нинди җәбер-золым күргәндер, әмма аның ижатының иң чәчәк аткан чорында «Спи, мой сынок, спи, крошка, а то псу-татарину отдам» дигән юллары бар. Гомереңдә күңелеңнән китмәс, гомереңдә күңелең эремәс. Тормыш бит куласа, бер әйләнә, бер баса. Менә шушы җилбәзәк хатын язмыш шуклыгы белән, сугыш башлангач, әлеге «пёс-татарин» иленә килеп чыга. Ачка интегеп, беткә батып җәй ахырларында пароход белән Чистайга килеп төшә. Бәлкем әле, пристаньда ук берәр татар хатыны, авызыннан өзеп, аңа ипи кыерчыгы биргәндер. Чирләшкә улына эчертергә берәр татар апае җылы кәҗә сөте биргәндер. Язучылар берлеге әгъзасы да булмагач, биредә ул кемгә хаҗәт? Кызганса, шул аны гади халык кызгана. Ялан аягына оекбашны, ялан кулына перчатканы бирсә, ул «пёс-татарин» дип атаган халыкның киленнәре бирсә бирә.

Безнең халык бит үчле түгел. Авызындагын өзеп бирүче. Сугыш елларында читтән кайтучыларны авылда «эваклар» дип йөртәләр иде. Аларны инде күп сыендырды безнең халык, күп ашатты. Ә Марина Цветаева ни дисәң дә шагыйрә. Оят, намус дигән нәрсә борчый башлагандыр аны. Җирле халык тарафыннан игътибар, шәфкатьлек күрә. Ә ул аны ижатының шаулаган чагында әнә кем дип атады. Шагыйрәне трагик финалга менә шушы нәрсә китергәндер. Минемчә, дөреслеккә иң якын версия бу.

Зур кыенлыкларны һәм каршылыкларны җиңеп, Татарстаныбыз мөстәкыйльлек өчен көрәшкән бу көннәрдә Иван Чигринов дигән әшәке җан һичкайчан кичермәслек һәм гафу итмәслек зыян эшләде безнең халыкка. Ул китергән зыянны тик су басу, җир тетрәү, кара гарасат белән генә тиңләп булыр иде. Миллионлаган һәм миллионлаган телевизор караучыларга «татарлар алар менә нинди коточкыч халык» дип күрсәттеләр. Тфү, бу мәлгуньнең йөзенә лач итеп төкерәсем килә.

Эчтәлек

ПОВЕСТЬЛАР

Җәнбәт җәвере.... 4
Дулкыннар аяк чала... 98
Йолдызлы учаклар 120
Төшмәсен лә күзең матур ярга... 212
Чатан 270

ХИКӘЯЛӘР

Булырлар сиңа аңгыра! 350
Вә Аллаһе әгъләм биссаваб! 352
Тормыш мәктәбе 364
Үтерә күрмәгез! 366
Мунча яратучы мәче 368
Тол сыерчык 369
Эт белән мәче төсле... 371
Хәйләкәрнең хәйләкәре!.. 374
Акыл иясе 379
Көзге урман аланында 381
Башкаларга кое казысаң... 383
Төп мәсьәләгә кагылмый да... 386
Баһбайлар ял йортында.... 396

ПУБЛИЦИСТИКА

Мин — Чыңгызхан ыруыннан 414
Алланың — каһәре, халкымның ләгънәте төшсен... 467

Литературно-художественное издание

Хасанов *Альберт Бариевич*

Племя Джанбатов

Казань. Татарское книжное издательство. 2007

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

Хәсәнов *Альберт Барый улы*

Җәнбәт җәвере

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамым *Л.П.Петрова*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *В.А.Савельева*
Корректорлары *Г.М.Хәбибуллина, Г.Г.Гарифуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 11.09.2007. Форматы 84x108 1/32. Офсет кәгазе. «Peterburg» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 25,20 + форз. 0,21. Шартлы буяу-оттиск 26,46. Нәшер-хисап табагы 27,74 + форз. 0,36.
Тиражы 2000 д. Заказ С-1095.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420059. Казан, Бауман урамы, 19.

http://www.tatarstan.ru/books/
E-mail: tki@books.kazan.ru

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.